

Вахит Имамов

# Тозлы яра

Роман

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
И 48

**Имамов Вахит**

И 48 Тозлы яра: Роман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 384 б.

Әлеге әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар Башкортостан төбәгендә үткән гасырда булып узган хәлләргә нигезләнгән. Роман язучының Октябрь инкыйлабына, колхозлашу хәрәкәтенә, япон сугышына һәм башка вакыйгаларга өр-яңа күзлектән бәя бирүе белән кыйммәтле.

ISBN 5-298-01353-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## Ул — язар өчен яши

Илһам килеп, язучы-әдип ак кәгазьгә иелгәндә, үзе патша да, үзе кол да була ала. Шундый илаһи мизгелдә ул үзен дөньяларны кузгатырлык кодрәт иясе итеп тоя, вакыт-вакыт чарасыз калып, күңелендә туган вакыйгалар авырлыгыннан сыгылып та төшкәли.

Бүгенге заманда язучы булып, фәкать каләмең белән шәхесеңне раслый алу — үзе бер фидакарьлек. Бу көч сирәкләргә бирелгән.

Вахит Имамов — әнә шундый сирәкләрнең берсе.

Ул — язар өчен яши.

Бу язучыны баштагы чорда күреп алып, күтәреп чыга алмыйча калган тәнкыйтьчеләрне кызганырга гына кала. Чөнки бүгенге көндә аларның хәлсез иңенә Вахит Имамовның әсәрләр йөген салып булмас шикелле...

* * *

Күктә бакый Җир-ананың сүзсез шаһиты — ялгызак Ай йөзә. Талгын нурларга коенган күк гөмбәзе астында Идел җәйрәп ята. Олуг елганың йокымсыраган дулкын читләре яр кашагасын иренеп кенә, сак кына сыйпап алгалый. Комлы ярда, мең йолдызга таркалган очкыннарын биеккә сирпеп, учак дөрли. Учак тирәли яшьләр, остазлар түгәрәкләнгән. Кылычка кылыч бәрелеп, елдырым очкын кабынгандай фикер көрәше бара. Һәммәсенең дә кынында үткен сүз хәнҗәре. Елгыр фикергә ия булалмаган аңы әкрен кыймылдаганнар гына, коралсыз яугир кебек, түгәрәкнең күләгәлерәк ягына басканнар. Әнә шулай итеп, таңга кадәр учак яны кайный анда.

Узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында, һәр язның май аенда «Идел» лагеренда үткәрелә торган иҗат семинарлары әнә шул ягы белән истә калган. Шул семинарларның берсендә мин Вахит дигән егет белән таныштым. Ул — буй дисеңме, йөз-кыяфәт чибәрлеге дисеңме, куе бәрхет тавыш дисеңме — Хак Тәгалә ир кешегә кирәкле күркәм сыйфатларны аның бөтен барлыгына тигез таратып биргән.

Вәкарь белән генә исәнләште егетем. Сорашып белдем: хикәяләр тырмаштыра икән. Аның минем белән дә тәкәббер

кылануын тыштан ошатып бетермәсәм дә, эчтән: мондый горур егетләр дә кирәк безгә, дидем. Мирсәй Әмир әйтмешли, «мокытлык дәрәҗәсендәге тыйнак»ларны күп күргән. Хәер, башта тыйнак рәвеш чыгарып, әйе, дип, гел уңайга баш селкеп йөргәннәрнең, бераз аяклангач, әрсез алабайга әйләнгәннәренә дә мисаллар китерергә була. Ә бу Актаныш егете, йөзенә алсулык чыгарып, тыйнак булып кыланмый, димәк, күңел галәмендәге гаярьлеген, әлегә ачылмаган көч-гайрәтен сизә, каһәр. Үзендә Актаныш канәгатьлеген җиңеп, иҗат дигән каты токымлы тауның катламнарын мыскаллап уеп алырга түземлеге җитсә, хикмәт чыгачак бу егеттән, дип уйлап куйганым бүгенгедәй хәтердә.

Заманында яшь шагыйрь Маяковский, Мәскәүгә килеп, яфрак юкалыгында гына беренче китабын чыгара. Язучылар җыела торган кафеда бильярд уйнаган җирдән аны Корней Чуковский (ул чакта ук танылган язучы) чакырып ала:

— Китабыгызны укып чыктым. Кызыклы гына шигырьләр язасыз,— дип сүз башлауга, Маяковский аны гөрелдектупас тавышы белән бүлдерә:

— Әнә залның теге башында мин яратып йөргән кызның әтисе утыра. Минем бөек икәнемне һич танымый, ышандырыгыз әле шуны! — ди дә уенын дәвам итәргә дип кереп китә. Әгәренки безнең татарда... берәр яшь шагыйрь шулай итсәме?.. Ай-һай, белмим, кичерерләр иде микән? Моның шаукымы дистә елларга барыр иде. Мескенлекне ярата шул безнең татар, көчлеләрне җене сөйми. Гаярь шәхес калкына икән, ул әллә нинди астыртын, мәкерле юллар белән аның рухын кыркый, юлын кисә, аяк чала, мескенлек хәленә төшереп утыртмыйча тынычланмый. Философ Гельвеций: «Җиңелгән милләттән бөекләр чыга алмый»,— дип хаклы әйтте микән әллә?..

Әмма нишлисең... Нәби Дәүли әйтмешли, мин дә шулай «держи его!» дип кычкырам... Эчтән Вахитның үзен горур, бәйсез тотуын ошатсам да, ул горурлыкның тәкәббер җиле миңа да кагылып киткәч, сискәнебрәк куйдым. Туктале, мин әйтәм, өйрәтәм әле бу егеткәччәйне... Җае да озак көттермәде... Миңа карата ниндидер якынлык тоепмы, өлкән дусты Гариф Ахунов киңәше беләнме — анысы нәмәгълүм, нигәдер, кулъязма китабын нәшриятка фатыйха кәгазе яздырырга дип, ул миңа китерде. Нәшриятның планы әле көз айларында гына кысаларга керәчәк икән, моны белешеп алдым да Вахитның кулъязмасын күз уңыннан читкәрәк тыгып куйдым. Белешергә дип бер килә бу Казанга, ике килә, өч... Килгән саен, егетебез йомшара бара. Әнә шулай «тәрбия мәктәбе» үткәргәннән соң, «Ир канаты» дигән исемдә басылып чыгачак китапның кулъязма нөсхәсе хакында уңай фикерләр язып

бирдем мин нәшриятка. Әлбәттә, аның беренче әсәрләре, барыбызның да башлангыч чорына хас булганча, әдәби кимәле ягыннан йомшаграк иде. Гадәттә, прозаиклар утыз яшьтән соң гына ныклап өлгерү чорына керәләр. Дөнья әдәбиятында бу мең мисал белән расланган, бишектән төшү белән шигырь язарга мөмкин, ә проза-чәчмә әсәр язу башка... Ул — милли әдәбиятның йөзен, бөеклеген, зурлыгын билгели торган олуг жанр.

Өлгерү, җитлегү чоры... Күпләрнең күңелендәге иҗат тирәге үз халкының тарихи катламнарына тамыр җибәрә алмыйча ябалдашка үсә алмый — гарип кала һәм шул гарип иҗатың белән олыгайганчы мактарып гомер кичерергә дә мөмкинсең. Шуны белгәнгә күрә яшь каләм иясенә бераз сагаеп каравың да бик табигый. Киләчәктә нинди юлдан китәр бу егет? Елдан-ел тарая, бертөрлеләнә барган прозабызның офыкларын киңәйтә алырмы, дип, Вахит турындагы уйлануларым өмет белән шик-шөбһә арасында бәргәләнеп алган иде. Өлкән әдибебез Гариф Ахунов тәэсире белән «эшче темасы» дигән чир йоктырып, җаны да, уй-гаме дә, мәсләге дә булмаган көнлекче эш атлары турында яза башламасмы, дигән уйларым, Вахит Чаллыга күчеп яши башлагач, тагын да куерган иде. Чөнки нәкъ менә КамАЗ заводына әллә кайлардан килгән, моңарчы әдәбиятта күренмәгән мөгезле геройлар табабыз, дөньяны шаккатырабыз, дип киткән язучылар күпме сәләтен юкка харап иттеләр. Мондый зур завод төзүнең киләчәктә нинди фаҗига-бәхетсезлекләр алып киләчәге хакында берәү дә уйлап карамады.

Чынлап та, Вахитның тышкы горурлыгы аның эчке үҗәтлеге, үзенең көч-кодрәтенә ышануының рухи чагылышы булган икән. Ул Алласыз һәм мулласыз әдәбият белән ерак барып булмаячагын аңлау баскычына нәкъ үз вакытында менә алды. Дөнья мәшәкатьләрен, гамь-борчуларын бер якта калдырып, Әбугалисина кебек мәгарәгә ябылып, халкыбызның үткәне, канлы да, шанлы да чор-дәверләре язма хәзинә булып сакланган, асыл мәгънәсе бибәһа торган чыганакларга, гаделлекне көтеп яткан тарих көшеленә чумды. Әнә шулай итеп, ул 1980 нче еллар башында ук, Казан, Уфа, Оренбург, Мәскәү, Уральск калаларындагы архивларда, китапханәләрдә гомерен уздырып, борынгы язмаларда күз нурын калдырды. Бу мәгарәләрдән исә олыгаеп, акыл-зиһен туплап, чынбарлыкның кайтавазыннан тетрәнеп, рухи баеп чыкты һәм милләткә үткән зурлыкларын бүгенге бизмәнгә куеп карарлык мәгълүмат бирүче, тузга язылган сүзгә, олуг мәгънәгә ия әдип — Вахит Имамов булып дөньяга чыкты, әдәбият мәйданында, бөтен буена күренерлек итеп, аягүрә басты...

Нәтиҗәдә «Запрятанная история татар» исемле хезмәте

(1993), зур тираж белән басылып чыгып, ил киңлекләренә таралды. Аның бу нәни китабы тышкы ялтырауга корылган рус империясенең эчке хасиятен шәрехләп, шул империяне нигезләгән һәм инде соңыннан дәүләтен җуярга мәҗбүр ителгән татар халкының нинди дәһшәтле язмышка дучар ителүен ул аяусыз ачып салган иде.

Ул чакта әлеге кайнар, кыю хезмәтне татарның мәшһүр әдибе Гаяз Исхакый публицистикасы белән генә янәшә куярлык иде.

Тыштан юка күренсә дә, асылы калын бу китап рус һәм башка халыкларның зыялыларына да барып җитте. Бүгенге рус сәясәтендә исем алган күренекле затлар үзәк телевидение экраннарыннан ул китапны селки-селки янадылар. Карагруһчыларның өнен алган бу хезмәтне кайбер урыннарда өеп яндырганнар икән дип тә сөйләделәр. Әгәр хак икән, язучы өчен бәхет түгелмени! Юаш-күндәм кол китабын өеп яндырганны тарих әлегә хәтерләми...

* * *

Иҗат дәрьясында үз кыйбласын табып, чирканчык алган әдип инде тирән-хәтәр чоңгылларга керергә дә үзендә көчдәрман сизә һәм ясканып эшкә тотына. Озак та үтми, «Сәет батыр» (1994) китабы табадан төшә, зур тираж белән таралып, аңы йокымсырап, акылы изрәгән халыкның кулына барып җитә.

Бу әсәре белән инде Вахит Имамов галим-голәма дөньясын да дер селкетеп алды. Без мәктәп елларыннан укып үскән Пугач восстаниесен Идел-Урал төбәгендә рус крестьяннарының патша самодержавиесе изүенә каршы дәррәү күтәрелүе, боларга әз-мәз татар-башкортларның кушылып китүе сыманрак күз алдына китерә идек. Тарих дәреслекләреннән кала, без, Толстойның «Хаҗи Морат» әсәренә ияреп, үзе белмәгән мохиттән экзотика эзләп язган Злобинның Салават Юлаев хакындагы әсәрен һәм Пушкинның «Капитан кызы»н укып, бу восстание мәхшәрен күңелебездән тетрәнеп үткәрә идек. Пугач патшадан кала иң олуг зат — халыкка татарча мөрәҗәгатьләр язган башкорт Салават булган дип ышана идек. Баксаң, Пугачев янәшәсендә бригадир дәрәҗәсенә ирешкән белемле татарлар Канкаев, Усаев, Кадыйрмөхәммәтовлар булган икән. Полковниклар гына да кырыклап, старшиналар исә йөз илледән арткан. «Генераллар»ы шулкадәр булгач, алар кул астындагы яугирләр күпме — моны чамалавы кыен түгелдер.

Вахит Имамов бу әсәре белән, ваемсыз татар галимнәрен көнләштереп, Башкортостан галимнәренең йөрәген киңәйтеп,

аларда кыргый дәрт уятты. Әйтергә генә ансат, узган гасыр катламнарын кубарып, архив документларын калкытып, бер учка эзлекле җыеп карасаң, гаҗәеп чынбарлык ачыла: Пугачев кузгалышының төп көчен татарлар тәшкил иткән бит! Бу — патша тәхетенә каршы дәүләтчелек рухын җуймаган халыкның кабаттан күтәрелеп чыгуы (әлбәттә, яңа, әйбәт патшага буйсынып...) түгелмени!

Бу әсәрендә язучы моңа кадәр беркем кузгатмаган һәм җөрьәт тә итмәгән бер хикмәтне ача: түнтәреш (восстание) барышында көч-корал дәһшәтен кабаттан тойган, зур-зур гаскәргә тупланган татарлар ханлыкны яңадан торгызу хакында да адарынып куялар. Акыллы, гаярь, фидакарь җаннар да җитә. Казанны алу, тәхетне кайтару шулкадәр якын тоела... әмма шәхси нәфестән өстен калалмау — татарның тумыштан килгән тарихи хастасы — астыртын шаукымын тарата; өметнең бәгыре киселә. Бу юлы да җиңеп җиңелә татар...

Вахит Имамов, бик күп архивларны өйрәнгән кеше буларак, Пугачев фетнәсе хакында моңа кадәр язылган бик күп хезмәтләргә таяна, аларның ялган битлеген ача, абруйлылар белән бәхәскә керә. Әлбәттә, фәнни дәрәҗәсе булмаган язучының исемле галимнәргә тибеп-тибеп алуын бик күпләр гафу итмәделәр, «нигә безнең уҗымга кердең» дип, аспирантура баскычын үтмичә генә саллы фәнни хезмәт язган әдипне талкый башладылар. Шалишь, брат! Замана бүтән, ялган тарих язучыларның чыраена дегет буйыйбыз әле, дип, Вахит Имамов үзенә бик күп яклаучылар тапты!

Бу хезмәт уйландыра... Һәр халыкта (рус шовинистлары арасында гына түгел) ялган тарих язучы намуссыз мөтәгалимнәр тирес корты урынына ни өчен үрчи икән? Тамак ялына сатылалармы? Әллә инде үз милләтен башкалар хисабына күтәрергә тырышу сөременнән исерәләрме? Мондый явыз, мәкерле галимнәр кешене үтерү өчен махсус агулар белән дәвалаган табиб белән бер бит. Гиппократ антына хыянәт иткән андый табибларны хөкемгә тарталар, эшеннән азат итәләр. Милләтләрнең тарихын, хәтерен бетерергә, аны саташтырырга теләп, чын фактларны яшереп калдырган яисә бозып күрсәткән галимнәрне дә намус хөкеменә тартып, фәнни дәрәҗәсенә күләгә төшерер вакыт җиткәндер шәт!

«Сәет батыр» китабы гадәти укучы өчен дә бик кызыклы язылган. Бу хезмәтнең гомумиләштерү сыйфатында бирелгән түбәндәге фикеренә генә игътибар итик. «...Урыс тарихчылары фетнәдә катнашкан крестьяннарның гомуми санын яшерә һәм фетнәчеләрнең милли составын күрсәтми. 1774 елның июленнән соң Казан һәм Оренбург губернала-

рында бер генә урыс отряды да фетнә күтәреп йөрми. Татар, башкорт, мари, чуаш, удмурт, калмык, казакъ фетнәчеләрен исә бөтен яу барышында, нигездә, старшиналар, тарханнар, солтаннар әйдәп йөри. Һәр мөселман отрядының үз байрагы була. Карательләр ул байракларны хәтта дар агачларына да кадаклыйлар. Татар, башкорт, мари, чуаш, удмурт, калмык халыклары фетнә барышында сыйнфый гына түгел, бәлки аеруча колониаль, милли һәм дини изүгә каршы көрәшәләр. Аларның төп максаты — урыс изүеннән, талавыннан азат тормыш була! Ләкин урыс тарихчылары алар турында да «дәшми».

«Сәет батыр» — соңгы елларда басылган сирәк ганимәтле китапларның берсе. Гаҗәп бит, Лобачевский бюсты артындагы фән сараена без белгән күпме яшьләр галим булабыз дип кереп киткән иде, әмма аларның чыккан эзе күренмәде. Нәрсә изеп йөриләрдер алар бүгенге көнгәчә?.. Вахит Имамов, язучы буларак, архивларны ничек казып чыгарып булуын, ниһаять, эшләп күрсәтте, фәнни дәрәҗә дәгъвалаудан артыкны белмәүчеләрне почмакка постыра торган мисал бу!

Әсәрнең үзеннән, шәрехләп тормыйча, тагын бер өзек китерик. Монда — язучының әрнү-уйланулары да, кисәтү-гөманлавы да, җан-бәгырь авазы да гыйбрәтле җирлектә тасвирланган.

«...Кайчандыр, инде йөз еллар элек үк башкорт даласында мондый кобайыр туган:

...Салаватның тугры дуслары —
Кинҗә-батыр белән Ханзафар.
Кыйгыр-бөркет булып, яу кыйратып,
Мәлгунь дошманнардан көл ясар...

Әйе, гади халык татар белән башкортның бергәлеген-дуслыгын йөз еллар элек үк шулай раслаган. Чөнки татар белән башкорт әле 1552–1553 елларда ук урыс итеге астына бергә килеп кергән. Хәтта әнә һәр милләтнең символлары булырдай ике каһарман — Салават белән Ханзафар да урыс патшасының бер үк зинданына бикләнгәннәр, 25 ел буе бергә, иңгә-иң торып, газап чиккәннәр. Башкорт вәкиле дөньядан алдарак китеп барган, аннан соң гына татар вафат булган. Шушы факт үзе үк безгә, татар белән башкортка, язмыш кисәтүе булып тоелмыймы?

Безнең милләтләр бүген дә урыс империясе тарафыннан иза чигә. Әле Салават һәм Ханзафар кебек иңгә-иң торып көрәшсәләр дә, аларның аерым, мөстәкыйль дәүләт төзи алуы бик икеле. Ә шул ук вакытта башкорт «зыялылары» арасында үз халкын татарга каршы котыртып ятучы «эшлекле-

ләр» дә бар. Уфада Әкрәм Бейеш, Асылгуҗа Багуманов кебек «даhи тарихчылар» табылган да, «Башкорт халкының тарихы hәм азатлык көрәше» дигән китапны нәшер итеп, алар татар халкы өстенә иң нәҗес пычракны өяләр. Имеш, татар халкы элек-электән үк илсез, җирсез, дәүләтсез, мәдәниятсез, кансыз, явыз, иң әшәке бер милләт булган да, шулар гына 1236 елда килеп, 2 миллион булып исәпләнгән башкортларны 300 ел эчендә 200 меңгә калдырган икән. Җитди тәнкыйтькә, гомумән, игътибарга да лаек булмаслык шушы ялган Башкортостанда 30 мең (!) данә итеп таратылган. Надан укучының шул ялганны хакыйкать дип кабул итүе бар. Хурлык, оят! Мондый милләтчеләргә каршы тарихның 1800 елда ясалган символик кисәтүен генә кабатлыйсы килә. Урыс империясенең Рогервик зинданында әүвәл башкорт, аннан соң гына татар вафат булган. Без бүген дә урыс коллыгында. Башкорт халкының саны бер миллионга якын, татарныкы — сигез миллион... Бергә кушылмасак, безне Салават hәм Ханзафар язмышы көтә. Бу сәясәт түгел, бу — тарих!»

* * *

Кулымда әдипнең яңа китабы. Тарихи роман — «Утлы дала».

Моннан өч-дүрт ел элек Вахит Имамов Чыңгыз хан турындагы романга тотынырга исәбем бар, дигәч, мин:

— Чыңгыз хан турында язганнан соң, берәү дә озак яши алмаган,— дидем.

— Мин аны бөек полководец — җиhангир буларак ачарга телим бит,— диде Вахит.

— Барыбер. Чыңгыз рухын кузгатырга ярамый, күрәсең...

— Юк-бар әсәр язып озак яшәгәнче, Чыңгыз хан кебек бөек шәхес турында язып, иртәрәк үлсәң дә ярый,— дигән иде Вахит шаярып.

— Бәлки, сиңа тимәс... Чыңгыз хан үзенең әткәсе нәселеннән — нәкъ менә татар улы гадел язарга тиеш дип ничә гасыр көткәндер дә...

Безнең арада әнә шундый сөйләшү булган иде. Бу фикерне ник әйткәнемә үкенеп тә куйган идем. Әмма Вахит Имамов андый гына хорафатларга ышанып, сыгылып төшә торганнардан түгел, үзалдына куйган максатыннан, үҗәтләгеннән Газраилнең үзе каршында да тайчанмас, үз мәсләгенә тугры калыр...

Чыңгыз хан турында гәпләшеп Чаллы урамнарында йөргәнебезгә күп тә үтмәде, яңа роман — «Утлы дала», әдипнең өстәленнән төшеп, ниhаять, дөньяга чыкты. «Бик җиңел укы-

ла»... — элегрәк елларда яңа әсәргә бәя бирүнең бисмилласы шушы фикердән башлана иде. Җиңел укылгач, үтә күренмәле, буш әсәр була түгелме соң ул, дип аптырап уйлануларым хәтердә. Юк, «Утлы дала» алай бер тында, йөгерек кенә укыла торган әсәр түгел, бу — саллы тел белән язылган чын тарихи әдәби роман. Моннан сигез-тугыз йөз ел элек барган вакыйга-сурәтләүләргә ышанып, шул дәвернең кан тибешен, һавасының исен-төсен, теленең аһәңен тоеп, тукталып уйлана-уйлана, хис-ләззәтемне кинәнеп түкмичә, алдагыга калдыра-калдыра, әкрен генә, вакыт сузу рәхәтлеген кичереп укыдым мин бу әсәрне. Никадәр хезмәт куелган (фатирында кунак булганда, Вахит күрсәтте: өстәл тартмасында картотека; кайчандыр кылыч тотып меңнәрне яуга күтәргән меңбашлары, ханнар, кенәзләр, дин әһелләре уч төбе кебек кәгазьләргә белешмә мисалында сыйганнар. Кан дошманнар бөтенесе янәшә, иңгә-иң терәлеп, язучыдан мәрхәмәт, гадел бәя көтеп мөлдерәп яталар. Боларның рухын да шулай Хак Тәгалә Күк катларында бергә җыйгандыр да, серле экраннан узган дәверләрне күрсәтеп, сабак бирәдер шикелле).

Мин романны бөртекләп анализларга җыенмыйм, аны Сорбонна университетын тәмамлап кайткан тәнкыйтьче-белгечләргә калдырыйк. Әйткәнемчә, бу — саллы тел белән язылган чын тарихи әдәби әсәр. Вахит Имамов колачны киң алган. Берничә кисәктән торачак, киმендә трилогия булачак бу эпик романнар циклының беренчесе — Җир шарының иң зур кыйтгасында капма-каршы бәрелешкән, дәүләтләр төзеп, дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырып, аксөяк даирәләрне үзара өйләнештереп — кан кушып, үзара дошман да, дус та булып яшәячәк өч халыкның — монгол, болгар-татар һәм русларның — үз язмышына нигез ташларын салудан башлана.

Өч баһадир халык...

Ирексездән Васнецовның «Өч баһадир» картинасы күз алдына килә. Олег Попович, Добрыня Никитич уртасында татардан чыккан Илья Муромец тора. Әгәр Васнецов милли кысалардан чыгып, киңрәк карашка ия булса, бу өч баһадир — монгол, татар, рус яугирләре булыр иде. Ялан дала уртасында, каплан кырда сөякләр яткан, учак урыннары калган кылганлы киңлектә, тарих чатларында өчесе өч якка аерылыр алдыннан илаһи тынлык аша киләчәккә төбәлгәннәр...

Язучы әдип, әнә шулай итеп, ерак гасырларга китеп, өч халыкның чишмә башына төшә, яшәү рәвеше, холык-фигыле, көнкүреше, хәрби ныклыгы аша аларның охшаш та, бик нык аерылган сыйфатларын да ачып сала һәм... вакыт дәрьясы аша сабыр гына, салмак кына бүгенгә күпер салырга җирлек әзерли. Әсәр өч тарафта өч халыкның аякка басарга омтылу дәверен эченә ала.

Заманында, төрки-кыпчак, славян кабиләләрен берләштереп, Киев кенәзлеген төзегән Скандинавия росларының бер исем астында (рос-кий, росныкы) төрле халыкларны туплап тантана иткән чоры үткән инде. Болардан аерылып чыккан яшь кавем, төньякка күченеп, андагы мукшы, вотяг, коми һәм башка халыкларны чәйнәмичә дә йота-йота яңа кенәзлекләр төзи. Арада иң көчлесе — Суздаль кенәзе Андрей. Кенәзләр тәхет бүлешә, ата — улны, ул атаны суюдан да тайчанмый. Кенәзлекләр арасында да кан кою, сугыш бер мизгелгә дә тукталмый.

Берләшеп кенә зур көчкә ирешеп булганын аңлап эш итүче кенәз Андрей ачынып болай ди: «Рус җире болганчык чор кичерә. Ата — улны, ана — кызны белми. Һәммә кенәзләр диярлек үзара суешалар, һәркайсы өстәмә биләмә, яңа шәһәр даулый. Бердәмлек юк. Әтәче, тавыгы, хәтта чебеше дә канлы елга эчендә ялгыз йөзә. Көчлерәк кулга ия икәнсең, кил дә теләсә кайсын батыр».

Болгарда да шул ук хәл. Әле бер хан баш калкыта, тәхетне дәгъвалап икенчесе күтәрелә, башкалалар алышына, үзара сугышлар тынып тормый.

Ерак көнчыгышта исә дөнья тарихын бөтенләй бүтән якка борып җибәрәчәк җиһангир — Тимучин атлы егет үсеп килә. Монда да монгол ырулары таркау, үзара килешә алмыйлар, аларны күрше-тирәдәге гаярь кабиләләр берәм-берәм талап торалар. Янәшәдә — һәммәсен үзара чәкәләштереп, хәйләле сәясәт йөртеп, мәңгелек Арыслан — Кытай иле җәйрәп ята...

Әсәрдә Тимучинның ачы язмышлы үсү еллары бик җентекле сурәтләнә. Ниһаять, ул мең бәлаләр белән үзенең тугыз чуклы байрагы астына төрле кабиләләрне берләштерүгә ирешә. Хыялы — үзара кан коеп яшәгән халыкларны басып алу, тынычлык урнаштыру, дөньяны имин-бөтен итү. Аныңча, дөнья үсешенә каршы килгән сәләтсез халыклар рәхимсез кырылырга тиеш...

Романда, әнә шулай итеп, бүгенге көндә Россия дип аталган кыйтганың өч ноктасында яшәү дигән учак тергезелә, өч баһадир халыкның ярлу чоры сурәтләнә.

Роман тәңренең тамгасы белән туган Тимучин атлы егеткә Чыңгыз (диңгез, дала) дигән кодрәтле кушамат бирү белән тәмамлана: «...Балдак-Дала үзәнлегендә шул кичтә үк ким дигәндә бер ай буена сузылачак тантана, туй мәҗлесе башланды. Үзәнлекне, әледән-әле уянып хәбәр биргән янартау сыман, күкрәү авазлары тетрәндереп, сискәндереп торды.

— Чыңгызхан! Чыңгызхан!»

Аннары инде кыят, нирун, мангыт, кирәй, татар һәм башка бик күп кабиләләрне уртак исем — монгол исеме астында

берләштереп, «Соңгы диңгезгә кадәр!» халыкларның бөек күченеше башланыр...

Гогольның «Үле җаннар» әсәрендә җилдереп барган тройка сурәтләнә. Әдәбиятчылар моңардан әллә никадәр символик мәгънә эзләп, аны Русьның киләчәккә ашкынып баруы дип тә аңлаттылар.

Өч баһадир халык... Өч аргамак...

Мичәүгә җигелгәне — Чыңгызхан нигез салган, татар ныгыткан империянең бүгенге варисы — рус аты. Ян-якларында, авызлыгын чәйнәп, башын кырыйга каерганнары — татар һәм монгол атлары. Шуларның берсе йөрәге ярылып егылса да, тройка сөрлегеп тукталыр...

Гоголь поэмасы азагында болай ди: «Русь, куда же ты мчишься, дай ответ?! Не дает ответа...»

Үзе куйган сораугa үзе җавап бирә алмас шул. Җавапны, ихтимал, утлы далада галәми җил тәмен тоеп үскәннәр табар...

* * *

Вахит Имамов: «Яңа әсәр яза башладым әле», — дисә, мин сискәнеп китәм, кайсы гасырга сикерде микән тагын егетебез, дип, сорау бирергә кыймыйчарак торам, чөнки аның каләме вакыт һәм яссылык каршында югалып калмый, гаярьлеген тоеп, ак кәгазь кырында сүз гаскәрен саф-саф итеп тезә тора. Бер карыйсың — ул моннан җиде-сигез гасыр артка — Чыңгыз ханнар дәверенә барып төшкән, икенче карыйсың — «Могикан» дигән әсәр язып ташлап, бүгенге болганчык заманда алтын балык тотып калырга адарынган шәхесләрне сурәтләп (танылганнарын танытып), бөтен Чаллы каласын егылып укырга мәҗбүр иткән.

Иң мөһиме — язучының бу дөньяга әйтер сүзе бар!

Инде борынгы чорларга үзләшеп, үз дөньясын, төп темасын шунда тапты дисәм... Тагын яңа әсәр... «Тозлы яра»... Узган гасыр башы, канлы дәвер. Октябрь түнтәрешеннән (1917) соңгы хәлләр: колхозлашу дәвере, нигезеннән кубарылган, ил буйлап чәчелгән, рәнҗетелгән, алданган, таланган фаҗигале язмышлар.

Мин әлеге әсәргә кереп китә алмыйча бик озак тартыштым. Бәләкәй чактан бирле бу чор хакында күпме әсәрләр укылган, зиһен үтмәсләнгән, күңел арыган шикелле... Әмма... бер тотынгач, үзең дә сизмичә, вакыйгалар өермәсендә бөтерелә башлыйсың. Вахит Имамовның язучыга иң кирәкле сыйфаты шунда: кайсы чорны алмасын, ул әлеге чордәвер рухына табигый керә белә; хәтта, табигатьне сурәтләгәндә дә шул чор кешесе күзлегеннән карап тасвирларга ты-

рыша. Персонажларның уйлау рәвеше, сүз сөреше дә үз гасыры төсмерен чагылдыра һәм ул сине саллы, ышанычлы теле белән ышандыра белә.

«Тозлы яра» романының төп герое — Әмир Нәгыймов. Ул партиягә дә, халыкка да ярарга тырышып, ике тегермән ташы арасына эләгеп харап ителгән шәхес. Әмир Нәгыймов үз авылдашларын колхоз дигән капкынга куып кертүнең ялгыш икәнен җаны белән аңлый, өч йөз грамм икмәк урлаган өчен Себергә сөрелгән туксан яшьлек Сафа карт өчен дә кайгыра. Ачлыктан интегүче авылдашларына ярдәм итәргә дип талпынып та карый. Әмма аяусыз, кансыз большевиклар властеның каты кулы аны да бөгеп китерә.

Вахит Имамов 1933 елгы коточкыч ачлыкны тетрәндергеч язмышлар аша сурәтли.

Романның икенче кисәгендә Камчаткадагы тормыш (кая гына барып чыкмый татар башы!), 1945 елда японнар белән сугыш вакыйгасы бирелә. Озынлыгы — егерме, киңлеге нибары унөч чакрым булган, тоташ таштан хасил Шумшу утравын яулау өчен, ике мең ярым совет кешесе һәлак була. Көнбатышта дүрт ел буе Германия гаскәрләренә каршы сугыш барган чакта, Камчаткада корсак үстереп яткан генераллар, әнә шулай итеп, түшләренә орден-медальләр кадыйсы хисапка меңнәрчә солдатларны ут эченә ташлыйлар.

Нәтиҗәдә, ике меңнән артык корбан биреп, японнардан талап алынган әлеге утрау бүген дә буш тора. (Анда сәрхуш балыкчылар төркеме генә хуҗа булып йөри.)

Колхозлашу елларын чагылдырган әсәрләрдән совет әдәбиятында иң күренеклесе булып, бәлки, Михаил Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»е калыр. Язучы таланты, билгеле кысаларга гына сыеша алмыйча, тетрәндергеч вакыйгалар аша шул чорның фаҗигасен биргән. Кызыгып яисә нәфрәтләнеп укыган каһарманнар әсәр соңында бер-берсен кырып бетерәләр. Култыгына папка кыстырган, надан, шаян, бераз тилемсә Щукарь карт кына торып кала. Сезнең колхозларыгыз менә кем җилкәсенә калыр, дигән символик мәгънә. Мин бу хәтәр мәгънәгә Михаил Шолохов алдан уйлап ирешкәндер дип һич тә гөманлый алмыйм. Чөнки бу әдипнең әдәби әсәрдән тыш язмаларында фикер тирәнлеген, эчке иманы бер дә сизелми иде. Зур форум трибунасыннан: «Без йөрәкләребез кушканча язабыз, ә безнең йөрәкләр партия карамагында»,— дигән язучы бит ул!

Хикмәт шунда: олы талант иясенең каләме әсәр тукымасыннан тайпыла алмый, ул аны үзеннән-үзе логик чишелешкә алып бара. Монда аң-зиһен кысалары, язучының үз ихтыяры көчсез...

Миллион язмышларны сытып узган канлы дәверне су-

рәтләгән әсәрләр татар әдәбиятында, Галимҗан Ибраһимовны маяк итеп (Пирамида булып калкасы Гаяз Исхакый чит илгә сөрелгән елларда), классик саналган әдипләребез тарафыннан күп язылган. Ул әсәрләр яхшы һәм яманга — ак һәм кара төскә генә манылып язылсалар да, мавыктыргыч укылалар. Чөнки үзәктә — канлы вакыйгалар ята. Бүгенге көндә бу классик әсәрләрне мәктәп баласына аңлатып, тоталитар режимда менә ничек ялган язып була дип, гыйбрәтле мисал сыйфатында гына тәкъдим итәргә мөмкиндер.

Ниһаять, ул чорга карата заманның күзе ачылды. Ялган томаны таралды. Хәтәр фактлар өскә калкып чыкты. Үткән дәверләргә яңадан кайтып, дөреслеккә якын итеп әдәбиятта чагылдырып калу — яшьрәк буын прозаиклары намусында. Вахит Имамов, менә шушы миссияне күңеле белән тоеп, нәкъ вакытында роман язарга алынган. Аның, «әйбәт»,«начар»га бүлмичә генә, ике лагерьны сурәтләгәндә чама белеп, дөреслеккә хилафлык кылмыйча язылган «Тозлы яра» романы әдәби мирасыбызга бәһале байлык булып керсен.

Вахит Имамов — үз-үзенә нык ышанган, үз кыйбласы, үз иманы булган әдип.

Ак кәгазь — аның илһамлы күге дә, эзләр ярып барасы япан кыры да.

Кешеләргә әйтәсе фикере булганга, ул үзен кодрәтле итеп тоя.

Ул — язар өчен яши…

*Марсель Галиев*

# Тозлы яра



*Коллективлаштыру елларында*
*корбан булган бабам (әнкәйнең әтисе)*
*Әмир Нәгыймов истәлегенә багышлыйм.*

*Автор*

# БЕРЕНЧЕ КИСӘК

## *Башлам*

Гөлзифа апа, биле яман сызласа да, тешен кысып, кер чайкарга җыенып йөри иде. Зал ягында телефон чылтыравы капылт кына аны эшеннән бүлде.

— Максуд әле бу, саумы, яшьти,— дип тиз-тиз эндәште дә чылтыратучы кеше, дыңгырдавык арба өстенә эләккән буш мичкә тавышлары чыгара-чыгара, ихахайлап көлде.— Тау Мөхәммәт янына бармаса, Мөхәммәт үзе килә, ди. Хәзер техника заманасы булгач бигрәк җиңел. Менә борчыйм әле.

Гөлзифа апа әүвәл аңышмыйчарак та торган иде. Танып алгач, ирексездән елмаеп ук куйды. Заманында Бәләбәй техникумында бергә укып йөргән сабакташы Зыя Максуд икән. Дистә еллар буена роман язам, китап чыгарам дип, күлнең төбен күккә аскан кебек туктаусыз шапырынса да, төрле гәзит-журнал тирәсендә буталып йөрүдән һәм, язучы халкыннан күрмеш, фамилия койрыгын кыскартудан ары уза алмаган Зыя шулай, онытканда бер чылтыраткалап, аның хәлләрен белештерә иде. Ләкин холкы, иске кәвеш сыман, үзгәрүне бер дә белми инде. Тормышында бер чеметем дә кайгысы юк диярсең, артын шүрәле кытыклаган кеше төсле, бер очкынсыз кабына да көлә.

— Әдәбият, матбугат эчендә кайнаган кешенең тормышы вулкан сымак бит ул. Сиксән яшьне сикереп узсам да, һаман тыныч кына өйдә ята алмыйм,— дип, Зыя һаваланып башлап киткән иде, бераздан күңелен бөтенләй гармун күреге сыман җәеп үк җибәрде.— Үзем сымак картлач өч-дүрт язучы әшнә белән җыйнаулашып Бәләбәйгә барып кайттык менә. Укучылар конференциясе дигән булып, Тузлукуш авылына да алып бардылар безне. Гәрчә хак исеме йә Тозлы, йә Тузлы Куыштыр инде аның. Мәгәр безнең татарны үзең дә беләсең бит. Мәскәү «айт» дидеме, мескен татар «тайт» итмичә калмый. Бер каләмдәш әшнә әйтмешли, медаль бирәбез дисәләр, безнең мокыт татар нәм-нәм кабиләсендәге бәндә булып та язылачак. Мәгәр сүзем әле ул турыда түгел.

Зыя, тукталып, әллә дару капты инде, әллә су гына эчте, трубка аша голт-голт иткән тавыш яңгырап алды.

— Тәк вәт. Менә шул Тозлы Куыш авылында бер зур йортка куна керттеләр безне. Фатир хуҗасы — туксан яшьлек Тимергали бабай — безнең Бүздәк районында туган булып чыкты. Алай гына түгел, ул әле утызынчы елларда Күзәй авылында колхоз рәисе дә булып торган икән. Утыз бишенчеме, утыз алтынчымы еллар тирәсендә генә шушы Бәләбәй якларына күчеп киткән. Чынлап баксаң, койрыгына талпан ябышканны сизенеп, аяк табанын майлагандыр инде. Ярар, шулай да булсын. Исән каласы килгән бәндә, суга батса, саламга да ябыша, гөнаһылы итмик.

Зыя, мөртәт, телефоннан сөйләшү белән рәттән чәй дә чөмереп утыра иде бугай, трубка аша янә голт-голт иткән тавыш ишетелде.

— Тәк вәт. Шул Тимергали бабайга утызынчы еллар турында кармак салган идем, ул синең атаеңны да белгән булып чыкты. Әйе, ул — Төркәйдә, мин Күзәйдә бергә-бергә колхоз төзеп йөрдек, дип, бер кабынып алды да, керәчене беткән лампа филтәсе сымак, капылт кына сүнде. Безнең татар әкәм-төкәм бит ул, салам кыштырдаган тавыш ишетсә дә, шундук кабык кия.

Зыя, ниһаять, төп тәкъдименә күчте:

— Син үзең шул Тозлы Куышка барып карамыйсыңмы соң, яшьти? Иплэп кенә кылын тарткаласаң, ул Тимергали бабай сиңа атаең турында үзе белгәннәрне сөйләп бирмәс микән? Атаең тирәсендәге томан пәрдәләре тарала төшәр, бәлки...

Гөлзифа апаны, әле «атаең» дигән сүзне ишеткәч тә, бизгәк тоткандагы шикелле калтырану сарып алган иде. Сабакташының киңәшен дә ишеткәч, өнен җуйгандай булды.

— Барырмын, Зыя, рәхмәт, барырмын,— диде дә, берни аңышмыйча, трубканы куйды.

Чайкаласы керләр кайгысы зиһененнән чыгып очкан иде. Магнит янына тартылган кадак шикелле сәгать телләренә текәлде дә кәнәфи почмагына сеңеп тик утырды. Хәзер сәгать тугыз, тугыз, тугыз... Автовокзалга хәтле егерме минутлык ара. Билет алу уңай килеп чыкса, ул караңгы төшкәнче Тозлы Куышка барып җитәргә дә өлгерә бит әле.

Гөлзифа апа капылт кузгалып аягына басты. Бил сызлаулар, картлык, җил юып алгандай, шундук юкка чыкты. «Рауза, балам! — дип язды ул, ашыгып, кулына эләккән гәзит почмагына.— Бәләбәй районында бабаңны белүче карт табылды. Мине югалтмагыз».

Пальто дигәннәрен тузган халат өстеннән эләктереп китүен Гөлзифа апа фәкать юлда барган чакта гына абайлады. Кабат кайтып йөрергә вакыт әрәм иде.

...Тозлы Куыш авыл советына кереп үз йомышын әйткәч, чәченә бәс кунган рәис хатын бик җылы елмаеп каршы алды аны:

— Тимергали бабай менә шушы каршы йортта гына яшәп ята, апа. Аның Бүздәк районыннан күчеп килгәнен дә, анда элек колхоз төзеп йөргәнен дә ишеткәләп үстем. Тик менә уңайсызрак чакка туры килдегез шул. Әле кичә генә Тимергали бабайны үзебезнең авылдагы участкавай больницага салдык. Йөрәк диме, кан басымы диме, аны шайтан белсен. Уен-муен түгел, бабабызга инде туксан ике бугай, ялгышмасам.

Гөлзифа апаның кыйналган каз сыман иңбашларын салындырып пошаманга төшүе сискәндерде бугай, рәис хатын юатуга күчте:

— Ул тиклем ерак юл үтеп килгән олы мосафирны Тимергали бабай белән очраштырмый калмабыз, хафаланмагыз, апа. Аллага шөкер, моңа кадәр минем сүзне аяк астына салучы булганы юк әле. Бу юлы да дежур врачларны, шаять, күндерербез...

Чыннан да, хастаханәдәге табибә рәис хатынның гозере белән җиңел ризалашты. Шулай да ул, хезмәт бурычын үтәп, Гөлзифа апаны кисәтеп куярга барыбер онытмады:

— Бик үк яшерен серләрегез юктыр бит, мөгаен? Алайса, мин сезнең рөхсәт белән яныгызда торам. Ни әйтсәң дә, Тимергали бабай унынчы дистәне кырлап килә. Бик тиз арый. Урынсыз сораулар белән борчымаска тырышыгыз инде. Алай-болай булса, киная биреп, сезне туктатырмын...

Палата шактый иркен һәм пөхтә күренсә дә, һавасы дымлы, бик тә авыр икән. «Ягу җитми, менә ул үзгәртеп кору галәмәтләре, ялгызың көн күрү» дигән бәя зиһенендә очкын сыман бер мизгелгә генә кабынып алды да шундук сүнде. Гөлзифа апаның хәзер бөтен уй-дикъкате авыруга күчте.

Тимергали бабай палата түрендә почмакка ук терәтеп куелган караватта ята. Кыяфәте — зур өметләр багламалы түгел. Кипшенеп беткән гәүдә, какча яңак, эчкә баткан төссез моңсу күзләр. Куллары-бармаклары мич башында киптерелгән тал чыбыгы сыман. Гөманлап тору артык, картның ошбу дөнья белән алыш-биреше бетеп бара инде.

Ялгызын гына калдырырга шикләнәләр, ахры, карт янына терәлеп үк диярлек артсыз урындыкта урта яшьләрдәге хатын утыра. Күз кабакларына зәңгәр сөрмә тарткан, киеме бик затлы, мөгаен дә, кала киленедер. Көтелмәгән кунакларны өнәмәде бугай, урыныннан күчкәндәй кыйланса да, барыбер артын куйды.

— Тимергали бабай, андый-мондый ярдәм кирәкмиме? — дип, кирәгеннән артык кычкырып, сүзне табибә үзе башлап

китте. Чит кешегә сәер тоелмасын диюедер инде, үз гамәлен аңлата да барды.— Колакка бик катыланды бабай, начар ишетә.

Как шикелле кипшенеп беткән иреннәрен салмак кыймылдатып, Тимергали карт та телгә килде:

— Миңа насыйп ярдәм Ходай Тәгалә кулындадыр, кәбәм. Дару, укыл гына дәрман өсти алмас.

— Менә сезнең яныгызга Уфадан кунак килде. Олы гозере бар,— дип, табибә элеккечә каты итеп кычкыруын белде. Аннан гына Гөлзифа апа ягына ияк кагып алды.

Әле картның кыяфәтен күздән кичергәч тә, Гөлзифа апаның күңелендәге өмет чаткыларын дым каплаган иде. Табибә кыстап дәшкәч, барыбер ничарадан бичара кыяфәттә яндагы бер буш урындык читенә иңде. Күршеләренә әҗәт сорарга кергән фәкыйрь кеше шикелле, кирәкле сүз тапмый изаланды.

— Бүздәк районыннан мин,— дип, ниһаять, сүз башлады. Әмма тавышы үзенә үк йомшак тоелды, ахры, катырак кабатлады.— Бүздәк районыннан. Төркәй авылыннан мин, Күчәрбай янындагы. Элек без Бүздәк районы булып йөри идек, хәзер Благоварныкы, утыз биштән бирле. Сезнең яклар инде, үзегез дә әйбәт беләсездер... Әткәй язмышын белмәкче, ачыкламакчы булып йөрим мин. Әйе, һаман. Исеме Әмир аның, Нәгыймов Әмир. Сезнең өчен, бәлки, Әмирҗандыр. Төркәй авылыннан. Әбелнәгыйм улы.

Тимергали картның карашына нур иңгәндәй булды, тик ул авыз ачарга да өлгермәде әле, ә зәңгәр сөрмә тарткан «шәһәр килене» инде, күркә сыман кабарынып, урындыгын ике уртага күчереп тә куйды. «Үлем түшәгендә яткан картка синең атаң гына кирәк иде, йөрисең монда, пеләш башка тимер тарак булып» дип төрттерергә маташуы иде бугай моның. Ләкин шулкадәр озын юл үтеп килгән Гөлзифа апаның, газиз әнкәсенең имчәгенә чытырдап ябышкан сабый бала сыман, үз уеннан кире кайтырга исәбе юк иде, ул камчылап куаланган кеше шикелле кызу-кызу тезде:

— Сезне Күзәй авылында колхоз төзегән, диләр. Минем әткәй үзебезнең Төркәйдә колхоз төзеп йөрде. Ике ара — унике чакрым гына. Мөгаен дә, аны белгәнсездер. Өстәвенә әле райком-фәләннәрдә дә очрашмый булмагандыр. Әткәй турында ниләр беләсез сез, шуны сөйләгез миңа, Тимергали абый?

Авыру карт кышкы кояш сыман сүрән генә елмайгандай итте, канәгать кыяфәттә ияк какты.

— Әтиеңне әйбәт беләм, олан. Бергә-бергә колхоз төзедек бит. Бар иде шул безнең дөньяны авызлаган, иярләгән чаклар! Бүгенге мәгыйшәт — ул соң тормышмыни? Боз капла-

ган елга. Ә теге заманалар! Менә кайчан иде ул авылларның тау елгасы, язгы ташу сымак котырынган чагы! Ә без шундый елгаларны да тәки авызлыкладык бит...

Палата түрендә доңгырт иткән тавыш ишетелде. Гөлзифа апа күз уңы белән генә шәйләп өлгерде: «шәһәр килене» аягы белән карават астына тибеп алган иде. Ул үзенең мондый галәмәтен яшереп торуны да артыксынды бугай, кычыткан шикелле зәһәр теле белән көйдереп алудан да тарсынмады.

— Колхоз төзеп йөрүләр савсим хата булган. Ул хакта сөйләшеп маташу да несовременно хәзер. Хәтта оят даже...

Ике ут арасында калып җәфалану Гөлзифа апа өчен яңалык түгел иде. Күңеле кыбырсынуга түзмичә, ул бераздан, күмер салынган самавыр шикелле, барыбер телгә килде:

— Безнең әткәйне утыз икенче елда алып киткәннәр иде. Бер гаебе булмаган көенчә, нахак яла ягып. «Җиденче август карары буенча» дип тә сылтау тапкан булдылар, «солтангалиевче» дә диделәр. Шуннан кайта алмады. Бәлки, аның язмышы турында сез ни дә булса ишетеп беләсездер?

Тимергали карт «аңга килгән» иде шул инде. Сүзләре мәгарәдән чыккан сыман тонык яңгырады:

— Синең атаңны колхоз симәнәсен әллә саткан, әллә урлаган дип кулга алдылар бугай. Халык дошманы итеп. Соңрак аның хакында «төрмәдән качкан икән» дигән хәбәрләр дә йөрде. Анык язмышын белмим.

Гөлзифа апа баш түбәсенә авыр күсәк белән орган төсле кисәк сынып төште. Ике күзен тоташ яшь каплады. Хәзер инде аның карашы да эштән чыгарылган кызныкы кебек мәэюс, мескен иде.

— Симәнәне сатмады да, урламады да бит ул. Муенына чалгы терәп талауга түзмәгәч, печән чабучылар өчен калдык симәнәнең утыз килосыннан икмәк пешерттерде... Ул бернинди дә дошман түгел иде. Гомер буе хөкүмәт эше дип, мир өчен дип йөрде. Ә аны барыбер нахак ялалар ягып кулга алдылар да, әллә төрмәдә башын череттеләр инде, әллә авылга кайткан чакта җанын ашадылар... Аның хакында, валлаһи, бер сүз дә ишетмәдегезмени соң, абый җаныкаем?

Палатада тагын доңгырт иткән тавыш ишетелде. Тимергали картның җавабы ерактагы инеш челтерәве сыман тагын да тоныклана төшеп яңгырады:

— Белмим бит инде, кәбәм, бернәрсә дә белмим. Минем үз хәлем хәл.

Керфек очларында әле һаман яшь ялтыраса да, Гөлзифа апаны мондый йомшаклыгы өчен үкенү хисләре биләп өлгергән иде, ахры. Ул яшь тамчыларын кул аркасы белән кисәк сыпырды да инде кырысрак дәште:

— Әткәйне төрмәдән чыгарганнар, мәгәр авылга кайтып

барган чакта, аны кулак куштаннары сагалап торып суеп үтергәннәр, гәүдәсен таш бәйләп күл төбенә салганнар, дигән сүз дә ишеткән идек. Ул хакта да берни белмисезме?

Янә палатада доңгырт иткән тавыш, янә коры җавап:

— Белмим, кәбәм, белмим.

Тимергали карт бераз вакыт авызына су капкандай ятты, аннары яңа «дәлил» китерүне кирәк тапты, ахры:

— Ул — мишәр, мин башкорт бит, олан. Ә без мишәрләр белән еллар буе аралашмый-нитми гомер кичердек ләса. Шуңа күрә атаң хакында белмим.

— Ә-ә-ә?

Гөлзифа апаның әүвәл ияге олы бияләй сыман салынып төште, аннары карашы тундрада чүл бүресе күргән шикелле кисәк сәерләнде.

— Безнең тирәдәге Аблай, Чишмә, Ахун, Әбзән, Чулпан, Түреш, Килем, сезнең Күзәй — барысы да йә мишәр, йә булмаса, типтәр авыллары. Район үзәге Бүздәк үзе — тоташы белән мишәр. Шулар арасында син ничек берүзең генә башкорт булгансың соң?

Гөлзифа апа инде «син»гә күчкән, тавышына очкын өстәлгән иде, әмма моны исәпкә алучы кеше әле күренмәде. Тимергали карт исә горурлана-горурлана янә тәкрарлады:

— Әйе, башкорт мин, апаем, паспортым да башкорт.

Гөлзифа апа өметсез кыяфәттә кул селтәде.

— Башкортстанда чеп-чи татар, мишәр авылларын тоташы-ние белән мәҗбүриләп башкортка күчерүләре яңалык түгел анысы. Әле Мәскәү кубып, иске абзарыгызны тартып алабыз дисә, элекке морзаларның яртысы шикелле урыс булып та язылырсыз, чукынырсыз да сез.

Басымчак булып утыру Гөлзифа апаны изде, сытты бугай, ул үзен-үзе белештерми кычкыруга күчте:

— Ул елларда колхоз төзеп йөргән риясызларның йә шул чорда ук, йә утыз җиденчедә башын ашадылар. Шулар арасыннан син берүзең генә ничек исән калдың?!

Оясына елан кергән ана каз диярсең, «шәһәр килене», урындыгын зәһәр дөбердәтеп, капылт сикереп торды. Тимергали картның кыяфәте генә йөзьяшәр имән кәүсәсе шикелле хәрәкәтсез калды. Тормыш, тәкъдир дигәннәре заманында аны шактый үтүкләгән, күрәсең, ул элеккечә, тыныч җавап бирде:

— Чит районга качтым, сеңелкәем. Совет тегермәненнән шушы авыл гына саклап калды мине...

Гөлзифа апа Тозлы Куыш авылын гомер буе буразна арасында йөреп картайган ат шикелле йончыган, өзгәләнгән хәлдә ташлап чыкты. Юл буе аны тик бер генә сорау утлы күмер сыман пешереп кайтты:

— Кем сөйләр соң миңа хакыйкатьне, Ходаем, кем сөйләр?!

Өенә кайтып кергәч, ул искереп беткән, инде илле еллар чамасы элек үк язылган кәгазьне табып алды да шундагы юлларны кычкырып укый-укый янә өзгәләнде.

Күл буйлары тулы яшел сукмак,
Кайсы сукмаклардан йөрисез?
Күзләремнән яшь таммый ла минем,
Йөрәк каным тама, күрмисез.

Күптән кайтмыйм туган якларыма,
Менә алмам Чатра үрләрен.
Әллә газапларым сүрлер иде,
Күрсәтсәләр яткан җирләрен.

Явыз ниятләрен тыялмыйча,
Кулы барып, кемнәр суйгандыр?
Бер гөнаһсыз калган өч ятимнең
Күз яшләре кая сыйгандыр?

Сөйләсеннәр иде ачык итеп,
Соңгы сүзен кемнәр ишеткән?
Юкса күңел һаман сагнып көтә,
Кайтып керер төсле ишектән.

Таратып ла җибәр чәчләреңне,
Кыйбла яктан искән җил үрсен.
Тәкъдир дигән нәрсә явыз бит ул,
Без күрәселәрне кем күрсен?..*

## БЕРЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Әмир Нәгыймов беренче мәртәбә Төркәй халкын уналтынчы елда шаккатырды.

Рөстәмбәк тегермәнендә төнгә куна калгач, бүре көтүе Әмирләр ихатасындагы бердәнбер алашаның гомерен кыеп китте. Әмирнең атасы Әбелнәгыйм, япон сугышыннан аксап кайтканнан соң, аягына ныклап баса алмый, абыйсы Әбелсаттар күптән башка чыккан, төпчек Әмир үзе унөч-ундүрт яшьтән бирле гаиләнең төп терәге булып исәпләнә иде дә, таланып-йончып беткән хуҗалыкта күз карасыдай карап торганнары шул юаш ат иде. Авызы бер мәртәбә пешеп карамыйча, кайнар ашны өреп кенә кабарга кирәклеген кеше ничек белсен? Әмир дә эшкә җигеп барган атының аякларына ты-

* 2000 елның 20 ноябрендә вафат булган зуринәм Зифа апа Нәгыймова-Үрәзмәтованың 1950 нче еллар тирәсендә язган шигыре.

шау салган иде. Бүре көтүен сизгәч, бичара ат ялан буйлап Торна күле ягына бер чакрым ара чамасы кушаяклап чабып барган әле. Мәгәр күл буендагы өстенә тәүге кар яткан сазлыкның үзе өчен тозак булачагын сизмәгән шул, малкай. Суга кереп котылырга ниятләве булгандырмы инде, сазлык эченә сикергән дә баткан. Әмир аның эзе буйлап барып җиткән чакта, бүреләр өере бичараның бугазын, бөерен чәйнәп, канын эчеп бетергән иде инде.

Тубыкка җиткән кар һәм ләпек боламыгын ерып, авыр арба тарткан Әмирне тегермән юлында шәйләүгә үк, авыл очына халык күп җыелды, әмма арадан берәү дә аңа ярдәмгә ашыкмады. Менә Әмир Чәрмәсән буеннан сузылган тигез яланлыкны узды, аякларын җайлап баса-баса, кат-кат тая-тая, шактый текә үрне кырлый башлады. Җыелган халыкның байтагы бөеренә таянып тау өстенә баскан, бичара егетнең гыжлап сулавы да, телен аркылы тешләп газап чигүе дә югыйсә ишетелеп, күренеп тора иде. Арба уртасында камыт, дуга, ыңгырчак, дилбегәләр белән аралашып яткан канлы ат башын шәйләп алгач кына, ниһаять, аһ иттеләр. Арадан берничә ир, сүзсез генә төшеп, тәртә белән үрәчәләргә ябышкандай итте. Ләкин Әмирнең үз ихаталарына борылмыйча, тәртә башын Рөстәмбәк йортына таба каеруын чамалап алуга ук, өсләренә кайнар су сипкәндәй, һәммәсе таралышты. Шулай да, беркадәр ара калдырып, барыбер иярделәр.

...Рөстәмбәкләр нәселеннән Төркәй халкы гомер буе дер калтырап торды. Бәкнең ерак бер бабасы әле мең сигез йөзенче еллар тирәсендә үк Җаек аръягыннан казакъ кызы урлап кайткан, диләр. Ул чагында төркәйлеләр генә түгел, якын-тирәдәге Әбзән, Түреш, Ахун, Күзәй мишәрләре дә меңәрләп патша хезмәтенә алынган һәм Җаек ярына барып, берәр ел буена Рәсәй чиген казакъ, кыргыз урдаларының һөҗүменнән саклап торган. Менә шул сак торуларның берсендә Айчүәк солтанга буйсынган олыс казакълары чикне, бозып, Җаекның уң ягындагы җәйләүләргә мал чыгарган, имеш. Ырынбурда утырган губернаторның әмере коры булган:

— Казакъларны үз далаларына куып чыгарырга! Җаекка якын утырган кышлакларын сабак булсын өчен яндырырга! Талардай мал үзегезгә була.

Әнә шул «мал» дигәненә кызыгып, әлбәттә инде, мишәр җайдаклары казакъ даласына саранча көтүе шикелле дәррәү ябырылган. Әрсезләр, шомараклар ул «поход»тан хәтта өчәр-дүртәр чаптар, унбиш-егерме куй талап кайткан, диләр. Ә Рөстәмнең ерак бабасы барын да уздырган. Аның кулына чаптар-куйлардан тыш әле тагын Айчүәк солтанның Зөбәрҗәт атлы кызы да «эләккән» икән. Айчүәк солтан соңыннан, кызы Зөбәрҗәтнең данын саклар өчен, яраннары

аша бирнә дә җибәрткән, ди. Бу хәбәрләр хак булгандыр инде, Рөстәмнең бабасы кисәк кенә баеп, күтәрелеп киткән. Ә солтан кызы исә баш иеп, әҗәт сорап килгән ярлы-ябагайга бер генә шарт куйган:

— Минем ирем сезнең хәерче морзаларыгыз да, гади бай да түгел. Аңа билегезне бөгеп, «бәк» дип эндәшегез...

Дистә еллар буена Рөстәмнәр нәселе «бәк» инде менә шулай...

Өерелеп килгән халыкны ерактан ук шәйләп өлгергән, ахры, Рөстәмбәк төркемне биек баскычта каршылады. Аның имән такталарны шыгырдатып баскан алыптай зур гәүдәсен, белен чаклы яңаклары уртасыннан чекерәйгән тәкәббер карашын күрүгә, халык капка төбендә үк, юлларына елан сузылып яткандай, капылт туктап калды. Әмир генә һаман морҗа сыман гыжлап ихатага узды. Тәртәләрне ташлап арба төбеннән канлы башны алды. Бик сөекле ярын күтәреп барган төсле күкрәгенә кысып, баскыч төбенә җитте. Чакрым буе араны арба сөйрәп узу хәлен алган иде, баскыч басмаларын сөрлегебрәк менде. Шулай да ерткаланган-таланган канлы башны Рөстәмбәк аягы астына бик тәвәккәл салды.

— Тимеркүк урынына миңа алмаш ат бир, — дигән сүзләр ярым гыжлау аша яңгыраса да, алар Төркәй халкы өчен аяз көнне чатырдаган яшен сыман булды. Капкадан иң ерак торган агайлар да эссе мунчага куып кертелгән кешеләр шикелле куырылып калды. Рөстәмбәк тә, камчы эләккән сыман, бер мизгелгә ис-акылын җуеп торды бугай.

— Ни сөйлисең, йолкыш? Нинди алмаш? — дигән сүзләре шактый сүлпән чыкты.

— Тимеркүкне синең тегермәнеңдә эшләгәндә бүреләр харап итте. Мин аны үз мәнфәгатем хакына дип түгел, ә синең дөньяң алга китсен дип җигеп бардым анда. Атам-бабамның да гомерләре сезнең нәселгә гел бил бөгеп үтте. Ихатада тәртә арасына җигәрдәй башка малыбыз юк. Тимеркүк урынына безгә алмаш тиеш.

Рөстәмбәк искә-аңга килеп өлгергән иде инде. Авыл гыйбадына җавап эзләп тел әрәм итмәде. Ул, яман каерылып, аяк астында яткан ат башына типте. Таланган баш, кан чәчрәтеп, Әмирнең чыраена бәрелеп гөрселдәде. Егет, әлбәттә, бу кадәрле үк кыргый дуамаллык көтми иде. Бүрәнә сыман ауды да чалкан барып төште. Халыкның аһ итеп йөз каплавы гына мәҗбүр итте бугай, теш арасыннан сытып, Рөстәмбәк ике-өч сүз ташлады:

— Гомер буе җаннарын мин асрадым. Килеп аяк табанын яласы урынга...

Канга баткан йөзен сөртә-сөртә, Әмир инде аягүрә торып баскан иде.

— Ялармын, бай, яламыйча калмам, — дип, яңак сөякләрен усал шыгырдатып җавап бирде.

Рөстәмбәкнең ярсуы язгы ташу сыман әле һаман басылмаган иде, кабат кубып сүгенүен белде:

— Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ул ямаулык сорар, дигән атай-бабай. Валлаһи, хак икән. Этләр өстермичә...

Хуҗасының сүзен әмер сыман кабул итте бугай, янда гына торган ялчы Госсам, кисәк кубып, абзар тактасына каккан чылбырга ябырылды. Аның бозау чаклы ике этне бәйдән ычкындыра башлавын күрүгә үк, берсен-берсе таптый-таптый сибелде, качты халык...

Шул көнне Рөстәмбәкнең Чәрмәсән өстенә салган тегермәне янды. Байның куштаннары атна буе Бүздәк, Бәләбәй, Уфа, Чакмагыш юлларында сак тордылар, Кузәй, Түреш, Күчәрбай, Ахун авылларына иярләренә камчы, аркан таккан чапкыннарны да юллап карадылар, әмма Әмирнең эзенә һичкем төшә алмады. Аптырагач, Әмирнең атасы Әбелнәгыйм белән агасы Әбелсаттарны Рөстәмбәк ихатасына алып килеп яман суктырдылар да байның ачуы шуның белән басылгандай булды. Әбелнәгыйм әлеге мәсхәрәне бик түземле кичерде, мәгәр Әбелсаттар, шартлар чиккә җитеп, и сүгенде:

— Кайтып күземә күренсен генә, кабих, авылга кайтсын гына. Мин ул денсезнең җанын алмасаммы!..

Әмир, суга төшкән балта сыман, бөтенләй юкка чыкты.

## 2

Югыйсә Әмир беренче атна-ун көн буена Рөстәмбәкнең борын төбендә үк, яшьти-ахирәте Хәбиләрнең сәндерәсендә ятты. Тышта кар китмәскә дип яткан, акылы камил кеше мондый салкында сәндерәдә көн итмәс, дип уйлаганнардыр инде. Печәнлеккә менүче түгел, хәтта лапас тирәсендә көзән сыман иснәнеп йөрүче шымчы да табылмады. Төннәрен генә ике яшьти чыш-пыш сөйләштеләр.

— Әй, кирәмәт, төкерәм бу Төркәйгә! — дип, күбесенчә Әмир, сер бирмичә, әтәч сыман кагынгандай итте. — Хет Уфага кит, хет Җаек йә Ырынбур ягына — дөнья иркен. Муен булса, камыт табыла ул. Аллага шөкер, тәндә тазалык бар. Бишәр потлы капчыкларны ыһ та итмим. Урал ягында заводлар адым саен, диләр, барам да берәрсенә керәм. Җан биргәнгә Ходай җүн биргән, ди, сыңар тамагымны гына туйдырырмын әле. Ичмаса, урысчага да өйрәнеп кайтырмын шуннан.

Хәби — кече яшьтән бергә үскән иптәш. Чын исеме Хәйберахман булса да, аңа Төркәйдә тулы аты белән эндәшкән бер кеше юк. Ул хәтта әнисе өчен дә Хәби. Астыртын, йомы-

кый егет. Шулай да, киная ташлап котырткач, яшь тай шикелле, ул да кыбырсына. Әмир дөм караңгы сәндерә эчендә дә, һәрбер төге белән тоеп, сизеп утыра: Хәбинең дә аңа ияреп әллә кайларга чыгып китәсе килә дә бит, итәк җибәрми шул. Итәк дигәне йорт-гаилә инде. Хәбиләрдә ул бигрәкләр дә ишле. Узган ел гына әтисе каx-кох килеп йөреп дөнья куйган иде, хәзер инде абыйсы кан төкерә. Нужа тарта-тарта яртылаш бөкрәйгән әнисе, чирле абзый, аның каз бәбкәсе сыман сабый улы, кызы, үзенең ике сеңелкәше белән ике энекәше — бөтенесе Хәби җилкәсендә. Шулар гына җитмәгән, әле корсагын тагын бәбәйгә түгәрәкләндереп йөргән җиңгәсе бар. Анысы — тач кычыткан. Эленке-салынкыланып, үшәнләнеп йөрсәң, чагарга гына тора. Хәби, бичара, әле Рөстәмбәккә, әле Гәрдән байга ялланып бил бөгә йә булмаса, ахыр чиктә, төн уртасы җиткәнче, каралты-кура тирәсендә эшләгән атлы булып йөри. Тик җиңгәсе генә чагып алмасын да җиңги чәпчемәсен... Әйе, Хәбинең койрыгы бозга нык ябышкан. Моны Әмир дә белә. Белә, әмма барыбер Хәбине үчекләми, кымтырыкламый түзми.

— Завут җирендә, кала җирендә кызлар да күп, диләр. Монда, Төркәйгә бикләнеп ятып, кызлар йөзе күрми егермене уздык, буйдакланып барабыз бит инде, кирәмәт. Завут җирендә анда егетләре-кызлары, яше-карты — бөтенесе бергә эшли икән. Аралашырга, танышырга җай табылып тора, күзең төшкән кызны сорап яучы озатсаң, калым кирәкми, ди. Кала җирендә анда хәрәм йортына тиклем бар икән бит, каһәр. Чыдашың беттеме, акчаңны гына түлә дә, теләсәң кайсы кызны сайлап, кочаклап ят. Аннары имчәген уалыйсыңмы аның, ботын сыйпыйсыңмы — бөтенесе синең карамакта. Акчаң түләнгән бит, бер сүз әйтүче юк. Менә рәхәт кайда!

Хәби борча өере талаган шикелле кыбырсый-боргалана, ул утырган җирдә коры печән сабаклары чырт-чырт килә. Түзми, көн дә сорый:

— Ә син шулай да тәгаен кай якларга китәргә җыенасың соң, яшьти? Кайда баш төртмәкче?

Әмирнең җавабы ничәнче көн инде күл бозыдай тайгак:

— Далада адашкан юлчы сак була икән ул, кирәмәт. Берьюлы биш-алты учакка очраса да, ул аларның иң якты янганы, иң җылысы янына бара икән. Олы казан янында очраклы мосафирга да калҗа табыла, ди. Мин дә үз казанымны тапмый калмам әле...

Әмирнең үзе тәгаенләп куйган сукмагы бар, әлбәттә. Әмма ул аны иң якын дусты Хәбигә дә ачмый. Ходай Тәгалә, үзе саклангынны гына саклармын, дигән бит.

## 3

Чакмагыш олысының Аблай авылындагы Рәҗәпләр ихатасына Әмир күз бәйләнгәч кенә барып керде. Әтисе Әбелнәгыйм күрше тавыгын күркә итеп күрмичә генә сөйли торган булган, «Ломовой Рәҗәп»нең хуҗалыгы чынлап та ипле, таза, җиткелекле икән. Бер-берсенә ялгап салынган ике зур йорт, аңа терәлеп сузылган бура-сарай, мал лапасы, ак мунча, икеме-өчме келәт. Каралты-кура рәтендә кырдагы әвен һәм зуратлардан кайтарып көлтә сугу өчен өсте ябулы аран, кыш көне арба-тарантаслар куела, миллек эленә, утын өелә торган чиннекләр, күчеп нигезләнергә әмер генә көткән өр-яңа нарат бура — бары да бар. Бәхет чүпрәсе ташыган бу Рәҗәпнең, күз тимәсен...

Хуҗалар үзләре кичке аш өстәле тирәли тезелешкән, әтисе арттырмаган, гаилә ишле икән. Түшәмгә эленгән уникеле лампа астында мыеклы өч егет, мичтән яңа гына чыккан ак күмәч шикелле бик сөйкемле йөзле, буй җиткән кыз, аннары боларга бөтенләй дә охшамаган аксыл-җитен чәчле бер ир утыра. Казан тирәсендә кулына агач җамаяк-кашыклар тоткан бер хатын йөренә, әледән-әле ках-кох килеп ютәлли — анысы хуҗабикәдер инде. Ә мөселманча итеп, түгәрәк, пөхтә сакал җибәргән ир — өстәлнең иң түрендә. Хуҗа кеше шул булырга тиеш, моңа шик юк.

Әмирнең сәламен дә башлап нәкъ шул алды.

— Вәгаләйкемәссәлам, апаем, кем дип белик?

— Төркәй авылыннан мин, Рәҗәп абзый. Әбелнәгыйм улы.

Әмирнең тәвәккәл җавабыннан бигрәк, күңелендә калыккан хатирәләр тәэсир итте бугай, кашыгын читкә куеп, хуҗа кеше урыныннан ук торды.

— Әбелнәгыйм кордашның малайлары да шушындый булып үсеп җиткәнмени? Мин белгәндә сез әле менә шулай, орчык чаклы гына идегез бит, бәрәкалла! Сине кайсы дип белик, олысымы, әллә төпчегеме?

— Төпчеге мин, абзый, Әмир исемлесе.

— И гомерләр! — диде дә хуҗа кеше бераз вакыт башын чайкап торды. Янә өстәл артына иңгәч, дога кылып алды. Шуннан соң гына өстәл почмагына ишарә ясап куйды.— Мактап йөрисең икән, олан. Аш янына утыр.

Әмир бисмиллалап өстәл артына иңгәч, әлбәттә инде, хуҗа кеше хәл-әхвәл белешүне дә артык санамады.

— Атаң-анаң исән-саумы, кәбәм?

— Барысы да исән, Ходайга мең шөкер.

— Әлхәмделилләһи-раббин. Атаң белән бергә-бергә юл йөрүләребезгә дә унөч-ундүрт еллар үтеп бара икән бит, и

гомерләр! — дип, янә кабатлады да хуҗа кеше өстәл артыннан купканчы башка сүз әйтмәде. Аның күзгә болыт сыман кабарынган хатирәләр диңгезендә йөзә башлавын сизгәннәрдер инде, тамак кырырга да шөлләп утырдылар. Әмир, ауга чыккан мәче шикелле ялт-йолт килеп, өстәл артындагыларны күзәтүен белде. «Ак күмәч»нең дә карашы аңа еш юнәлә, Әмирнеке белән очрашкач, ул җир җиләге кебек кызарып чыга, әмма икенче минутта ук тулган ай шикелле күзләре белән аны гына күзәтеп утыра иде...

Төп әңгәмә ихатага чыгып кече йортка иңгәч дәвам итте. Хуҗа беренче сүзеннән үк дилбегәне үз кулына алды:

— Туры карарга тарсынасың бугай, күзеңне яшерәсең, йә, нинди йомыш китерде миңа сине, турысын әйтеп сөйлә.

— Минем өчен Төркәй юлы бикле, — дип башлавы зур авырлык булып тоелса да, Әмир тора-бара, сүзләрнең өресен генә сайлый-сайлый, һәммәсен дә сөйләп бирде. Әмир тәмамлагач, Рәҗәп хуҗа да башын түбән иеп байтак тын утырды.

— Һе, ишкәнсең син ишәк чумарын, — диде ул, ниһаять. — Сиңа Төркәй юлы, чынлап та, ябылган шул. Кулына эләктеңме, Рөстәмбәк убыр синең җиде кат тиреңне шундук салдырачак.

Рәҗәп беркадәр вакыт янә тын торды да, тезенә сугып, тәвәккәлрәк дәште:

— Үткән эшкә — салават, дия торган иде минем әткәй мәрхүм. Терсәкне тешләр хәл юк, булган — беткән. Ә син шулай да нигә дип нәкъ минем янга килеп чыктың инде?

— Атай гомер буе кәсептәшләрен рәнҗетми, гадел дип искә ала иде сине.

Әмирнең сүзләре күңеленә сары май булып ятты, күрәсең, Рәҗәпнең карашы май кояшы сыман яктырыбрак китте. Бик вәземләп кенә башлаган хатирәләрендә дә үз-үзеннән канәгатьлек хисе ялтырап ята иде.

— Безнең кәсептә башкача эш итеп булмый да бит, нәнәм. Атаең сөйләве буенча беләсеңдер инде, мин бит гомер буе ломовой атларда байларга, куписларга кызыл тауар ташып җан асрадым. Синең атаең белән дә, ялгышмасам, без Уфа, Туймазы базарларына да, Җаек белән Ырымбур калаларына да тауар йөрттек бугай. Чыгып киткән саен, фәлән мең тәңкәлек байлык-зиннәт. Тәвәккәлләгән саен, йөзәр чакрым юллар. Тау арасы саен башкисәрләр. Мондый ут-хәвефне ышанычлы аркадашларыңнан башка мәңге үтеп булмый. Гадел эш йөртмисең, хилафлык кыласың икән, юлдашларыңның йә сыртыңа пычак кадауларын, йә башка бер хыянәтләрен көт тә тор инде син. Мин синең атаң Әбелнәгыйм кордаш белән дә гел шулай эш йөрттем. Эстәрле базарына барган чакта, Кармәсән өстендә олавы-ние белән боз астына кит-

кәч, аны бәладән мин коткарган идем. Бәләбәйдән кайткан чакта, Кушйөрәк тау үрендә юлбасарлар урап алып муенга сәнәк терәгәч, мине үлем тырнагыннан синең атаң гына йолып калды. Мин бүгенгәчә яшәвем өчен дә синең атаң алдында бурычлымын. Шуны оныткан булсам, мин синең белән сөйләшеп тә тормас идем, олан.

— Ә атай безгә бу хакта бөтенләй сөйләмәде дә бит,— дип, Әмир аны бүлгән иде, Рәҗәп үзенчә бәя бирде.

— Күпләр бу җиһанда аңа чит кешеләр ничә бакыр тиеш — шуны гына истә тотып яши. Ә үзе кемгә күпме алтын тиеш, нинди әҗәте бар — моны искә алмый. Вак җан белән асыл кешеләрнең аермасы шулдыр...

Әллә хуҗа кеше алдан кисәтеп куйган булган инде, әллә шундый гадәт — кече йортка әле генә өстәл янында бергәбергә тамак ялгап утырган җитен чәчле ир-ат килеп керде. Бармаксыз бияләй сыман шакмак иякле, бер эләктерсә биләнне сындырырдай әзмәвер иде ул.

— Минем аркадашым, Якты Күл керәшене Ягүр булыр бу. Килемдәге алпавыт Җантурин дәшкән иде. Ырымбурга тауар озатмакчы. Гомер буе буразнасын югалткан ат шикелле каңгырып йөри алмассың. Тамак дигән төпсез капчык, киләчәк дигән томанлы учак та бар бит әле бу дөньяда. Ният итәсең икән, әйдә, кушыл. Тик матри, мыегыңа чорна, хыянәт иткән бәндәгә бер генә юл бездә. Үзең сайла менә!

Рәҗәп әллә каян гына суырып чыгарды да идән уртасына ике ягы да үткенләнгән хәнҗәр кадап куйды. Чигенергә юл юк, Әмирнең язмышы хәл ителгән иде.

## 4

Килем авылы читендәге тау башына урнашкан алпавыт утарына килеп керүгә үк, Әмирнең ияге сапсыз соскы сыман салынды да төште. Бу җиһанда алпавыт Сәетгәрәй Җантурин да яши, Төркәй авылындагы мескен Әбелнәгыйм дә гомер сөргән булып исәпләнә икән, йа Ходаем! Әбелнәгыйм ихатасындагы чалшайган йорт, тезгә чүккән мунча, ярым җимерек лапас белән бер тамчы да уртаклыгы юк икән бит моның. Бизәкле чуен койма белән әйләндереп алынган болындай зур ихата. Койманың эчке ягында гаскәр сыман рәт-рәт тезелеп киткән каен, нарат, чыршы, зирек агачлары, канәфер, шомырт, сәрви куаклары. Ихата уртасында кызыл эре кирпечләрдән салынган ике катлы сарай. Аның ишекләре генә түгел, хәтта тәрәзәләре дә Әбелнәгыймнең чалшайган йортына караганда биегрәктер сыман. Җитмәсә, һәрбер ишегенең, тәрәзәсенең өсте әллә нинди шәрык бизәкләре белән нәкышләнгән. Сарайның һәр почмагы өстендә түгәрәк мана-

ралар, аларның түм-түгәрәк калай гөмбәзе астына мылтык, быргы тотып, бер үк төрле киемдәге сакчылар менеп баскан. Сарай алдында роза куаклары белән уратылган түгәрәк зур мәйдан. Аның уртасында чәчәк түтәлләре, ак таш сыннар, кышкы кар капласа да сихерлеген җуймаган фонтан урыннары. Ихатаның бер як читендәрәк акбурга буялган таш келәтләр, нәселле чаптар һәм юртаклар өчен аерым-аерым араннарга бүленгән олы-олы лапаслар тезелеп киткән. Сарайдан көньяктарак, тау итәгендә, җиләк-җимеш агачлары черем итеп утыра. Бакчадан астарак, үзәнлектә, кыш көне дә чишмә челтерәп ята. Шул чишмә буенда Рөстәм бәкнең ике катлы йортын да үз эченә йотардай олы нарат мунча. Һәм нәкъ кыйбла ягында бөтен Төркәй халкын кертеп тутырырлык ике катлы, биек манаралы, ягы-ягы саен уналты тәрәзәле зур таш мәчет. Авылның башка йортлары бөтенләй еракта, читтә. Анда тагын ике манараның ае кышкы сүрән кояш яктысында да ялт-йолт килеп утыра. Җантуринның берүзенә аерым мәчет салдыруы, имам, мәзин тоту нигә генә кирәк булган инде?..

Рәҗәпнекеләр, карга баткан толыпларын салып, тән язып алырга да өлгермәде, кунаклар өчен төзелгән аерым йортка Җантуринның наибе килеп керде.

— Алпавыт сезне күптән көткән иде, өстәл янына дәшә.

Әмирнең күзе шаккатудан маңгаена менде. Ничек инде болай, әтрәк-әләм Әмир бөтен Бәләбәй өязен үз кулында тоткан алпавыт Җантурин белән бер өстәл артында утырачакмыни?!

Күркәдәй кабарынып, күкрәген киртәгә менгән әтәч сыман киереп атлаган Рәҗәп чыш-пыш килеп барды.

— Бу юлы алпавытның малы күп булачак икән. Ломовойлар булып кына йөрсәк тә, без хуҗа кимереп ташлаган сөякне көтеп утыручы эт түгел бит. Алпавытның үз авызыннан өзелгән калҗа безнең кулда. Хуҗа белеп эш итә, шулай тиеш, кәбәм.

Әмир Төркәй мәчетендәге намаз залыннан да зуррак бүлмәләрне, идәннән түшәмгә кадәр сузылган, ап-ак кирәч белән бизәлгән дәү мичләрне, дивар тулы шәрык нәкыше, рәсем, кәкре кылыч, алтатарларны күргәч, тилебәрән орлыгы ашагандай, гел акаеп йөрде. Ә бүлмәгә инде алтын җепләр белән чигелгән иркен халат кигән, ефәк кушак бәйләгән, мыек чылгыйларын бөтереп колак артына салган Җантурин үзе иңгәч, Әмир, бичара, ут йотучы тылсымчыны күргән шикелле, бөтенләй теленнән үк язды.

Юк, ломовой, ач әрвах белән бер өстәл артына утырып ваксынмады хуҗа. Ул, Әмир белән керәшен Ягүрдән биграк, Рәҗәпнең әзмәвердәй ике малаен күздән кичереп чыкты.

— Улларыңны һаман үзеңнән калдырмыйсың, димәк, ышаныч бар, рәхмәт сиңа, кустым,— диде ул, ниһаять, Рәҗәпкә кул сузып. Башкаларга ияк кенә какты. Егетләр аның әвен шикелле мәһабәт гәүдәсенә, үгез ботыдай таза муенына, белен төсле кып-кызыл яңакларына текәлеп карарга да кыймыйча тик тордылар.

Җантуринның алдагы сүзләре һәммәсен сәерсетте:

— Пайтәхеттә чуалыш бара икән. Микулай патша үзе герман фрунтында әллә ниндәй солдат Советларын туздырып йөри, Питербурда завут эшчеләре баррикад коралар, ди. Ул әтрәк-әләмне куып таратыр өчен пайтәхеткә Доннан казакъ полкларын куып китергәннәр. Дөнья кая таба ага, аңламалы түгел. Мондый чакта итәк-чабуларны җыю хәерлерәк. Җыелган мал хәттин. Сезне Ырынбурга, янә дә бер олауны Эрбет базарына юлламыйча булмас. Тамак ялгагыз да син минем янга өске катка мен.

Җантурин соңгы итеп Рәҗәпкә текәлде дә, әвендәй буйсынын хәтәр җитез борып, залдан чыгып китте. Кунак йортына кабат җыйналышкач, «ломовойлар», колакларын тырпайтып, Рәҗәпне тыңладылар.

— Җантурин безгә моның чаклы ике йорт тулырлык тауар әзерләгән. Бәясе ун меңдә генә бетмәс. Пайтәхеттәге чуалыш, чыннан да, хак хәбәрдер. Моның ише алпавыт аяк чолгауларын тиктомалга барлап куймас иде. Ул заманында казакъларның Күк Урдасын тоткан хан нәселеннән бит. Борыны киек исенә дә, көеккә дә сизгер. Бер-бер хәл кӧтеләдер инде, нәгъләт, шулай булмый калмас...

Юраганнар юш килгән. Юлчыларны Ырынбур урамында язгы яшен сыман көтелмәгән хәбәр өтеп алды:

— Пайтәхеттә Микулай патшаны чәнчелдереп төшергәннәр! Газиз башларыбыз кем кулына калыр?!

## 5

Әмир Төркәй урамнарына тагын бер елдан, унсигезнең язында кайтып төште. Кайтуы да кешенекечә түгел, шаккатмалы иде.

Күчәрбай ягындагы тау битеннән кыр казлары кәрваныдай тезелеп төшкән җиде чаналы олауны күрүгә үк, төркәйлеләр тәрәзә пыялаларына капланганнар иде. Олау инде авылның иң киң, болын сыман иркен урамы уртасына да килеп кергәч, иңнәренә кайсы җилән, кайсы халат элеп кенә капка төпләренә чыгып тезелделәр. Арадан беркем дә үз күзенә үзе ышанмады. Йа Ходаем! Беренче артлы чанага, күкрәк киереп, җәелеп утырганы аксак Әбелнәгыймнең күлгә чумган балта сыман юкка чыккан улы Ташбаш Әмирҗан

бит! Кыланмышын кара хәчтерүшнең: кузлага аерым аткуар утырткан бу, дилбегә дә тотмый. Ә киеме инде! Башында яшь бәрән тиресеннән тегелгән кара камчат бүрек, өстендә кара төскә манган каеры тун, аягында кунычларын гармун күрегедәй җыйган сәхтиян итек. Кайтарылып төшкән тун изүләре астында якалары чиккән атлас күлмәк. Муенында бер очы тәкәллефсез генә артка ыргытылган ефәк тасма. Ә ул кыяфәте! Дошманның кыядай таш кирмәнен япа-ялгыз көе яулап алган Алып батырмыни! Иреннәрен кыскан, күркә сыман кабарып гоңгылтаудан чак тыелып бара. Инде, инде!

Янында, башын Әмирнең иңсәсенә таба авыштырып, сыңар кашык су белән йотып җибәрердәй чибәр бер кыз утырган. Анысы кем тагын?

Капка төбендәгеләр берьюлы ду килде.

— Ошбу Ташбаш ач әрвах Әбелнәгыйм йортына килен апкайта бит, җирләр йотсын менә!

— Бер байбичәнең суга салырга дип озатылган үги улы, күл төбеннән олы сандык якут ташлар табып, кенәз-морза булып кайткан, диләр. Бу Ташбаш та, шул әкияттәге сыман, асылташлар табып кайтты микәнни соң?

— Тапты менә сиңа! Әмир Аблайдагы башкисәр Рәҗәп янында ломовой булып йөри, дигән хәбәр кайткан иде. Юлда шул башкисәр белән берәр куписның олауларын талагандыр әле...

Шунда гына, ниһаять, башка чаналарга да игътибар юнәлттеләр. Икенче чанага хатыны белән бергә баш кода-кодагый булып утырып килгәне, валлаһи да, Аблай авылының «ломовое» Рәҗәп ләбаса, шайтан алгыры мәлгунь! Өченче чанадагы аның өлкән улы Бикми-Бикмөхәммәт тә элгәре елларда төркәйлеләр күзенә очраштырган бәндә. Ә калган дүрт чана... кибән сыман итеп өелгән сандык-тартмалар, эреле-ваклы кәрҗин, капчык-капчык бирнә белән тулы. Олау артына уйнаклап торган чаптар, япь-яшь тана тагылган булуы бер хәл, соңгы чанада хәтта тал кәрҗин эченә утыртылган бер оя казларына тикле бар икән бит. Рөстәмбәк җәзасыннан ут капкандай чыгып качкан шыр ялангач сукбай дип әйтеп кара хәзер бу Әмирне! Валлаһи, морза булып кайтып төшкән бит бу, канә!..

Әбелнәгыйм ихатасына бар ат та сыймады. Баш кодакодагый белән яшь кияү-кәләшне чаналардан төшергәч, беренче атларны урамга чыгардылар да бирнә төялгән олауны түргә уздырдылар. Төркәй авылының ярты халкы читән өсләренә капланып, капка төбенә тезелеп тел шартлатып торды. Әмирнең агасы Әбелсаттар, яшьлек ахирәте Хәби, тагын

ике-өч яшь-җилкенчәк кенә, ихата эченә узып, олау буена басты. Әбелсаттар белән Хәбинең — икесенең тиң — хисапсыз мал күрүдән күзләре маңгайларына менгән, көнләшүдән кабынган зәһәр ялкын күңелләрен яман корт шикелле талый иде.

Йорт эчендә исә «ломовой» Рәҗәп кода булып алган элекке кәсептәше колагына иң яшерен серләрен чишә иде инде:

— Болганды бу Рәсәй, әй болганды! Эрвәлүтсә өстенә эрвәлүтсә, аткуарсыз калган Рәсәй чанасының кайсы якка салулап китәсен чамалавы читен. Гомер буе тәкъдир белән уйнап, тир түгеп җыйнаган мал-зиннәтне сәвитләргә кереп тулган җыен ач әрвахтан талаттырып булмас. Кара көнне алдан күрәзәләп, булган малны ышанычлы кияү-кода белән бүлешеп кую хәерле. Әмир белән син — икегез дә — йөз тапкыр сыналган, үз кешеләр. Шуңа күрә синең белән кодалашырга риза булдым да мин. Хәер, хәер...— Өстәл почмагында бармак сикерткәләп Рәҗәп кода берникадәр вакыт сузып торды.— Аннары, минем хатын әйткәннәр раска чыкса, яшьләрнең мөгамәләсе дә үткән эшкә — салават, диярлек чиккә җиткән бугай инде...

Шул ук кичне Әбелнәгыйм өендә туй башланды. Кара төн уртасы җиткән чакта гына, шактый кызмачаланып алган Әбелсаттар энекәше Әмир колагына хикмәтле сүз әйтте:

— Борыны бер тигән мәче баласын имчәктән аеру читен. Акылга килүең шушы булса гына ярар иде, туган.

## 6

Чагылтау өстендәге мәһабәт карагай ботаклары өстендә җитез тиен сыман уйнап сикергәли-сикергәли, Бүздәк ягыннан кояш калкып килә, Әмир дә инде күптән түгел генә аягына торып баскан иде. Урам тәрәзәләре алдындагы бакча рәшәткәләренә таяк белән суккалый-суккалый мәчет карты Сафа узып китте.

— Бәләбәйдәге өяз кәнсәсеннән дә, Күчәрбай сәвитеннән дә вәкилләр килеп төште. Шулар ирләрнең җәмгысын да мәчет янына дәшә. Җирне яңадан бүлү булачак, диделәрме шунда, аларны шайтан белсен. Алтатарларын борын төбендә тотып селкиләр дә өнне алалар, каһәр...

— Ярар, барырбыз,— дип җавап кайтарса да, Әмир күңеленнән генә сүгенеп алды. Кояш торган саен ныграк чыбыркылый, бүген-иртәгә язгы чәчүгә төшәсе, хуҗалыкта булган бөтен сука-тырмаларны, чәчүлек орлыкны барлап куясы бар. Кылны кырыкка ярырдай кызу эш өстендә Бәләбәй тикле Бәләбәйдән әллә нинди вәкилләр килеп йөри. Халык

җыены дигәнен уйлап чыгарганнар, каяндыр казып табып җирләр бүлмәкчеләр. Башлары аяк астына килгерләре, тапканнар соң вакыт!..

Әмир аксак әтисен каударлый-каударлый барып җиткән чакта, мәчет каршысына ярты авыл җыелып өлгергән, кыска бишмәт кигән таныш түгел бер ир, әллә каян сөйрәп китерелгән арба өстенә менеп, нотык сибә иде:

— ...Ярман сугышы бетте, солыхка кул куелды. Рәсәй халкы кан-үлемнән туйган һәм дә ки ул сугышның тагын бер генә көнгә сузылуын да һич теләми иде. Әмма ләкин солых шартлары безнең бәлшәвикләр хөкүмәтенә көч илә тагылды һәм дә ки ул бүген һәрбер эрвәлүсинирның йөрәгенә агулы ук булып кадаладыр. Шөбһәсез ки, ошбу солых вакытлыча чигенү генә булыр. Атналар, айлар узар, ә аннары безнең илдән күрмеш, бәгъзе халыклар да буржуйлар алдында тез чүгеп күнеккән башларын калкытырлар. Алар да, бездән күрмеш, үзләренең илләрендәге шаһ вә корольләрне, солтан вә падишаһларны бәреп төшерерләр. Шуннан ары бөтен җир йөзенә тыныч хәят иңәр...

Моның ише бушбугазларны соңгы бер ел эчендә Әмир инде Ырынбур, Җаек, Уфа урамнарында да күреп туйган иде. «Суган әкияте!» дип кенә мөһер чәпәде дә, кулын селтәп, Әмир мәйдан читендәрәк торган Хәби ахирәте янына китеп барды. Әүвәл сүзсез генә сыңар кул сузса да, Хәби бераздан барыбер үзенчә төрттереп алды:

— Килен белән боткаң хәтәр пешә бугай синең, илгә-күзгә бер дә күренмисең.

Ул арада яннарына янә бер-ике авылдаш ир килеп баскан иде, Әмир җавап биреп тормады, кул селтәде. Бу гамәлне Мисхәт исемле ир үзенчә аңлады бугай, капылт элеп алды:

— Моның ише әгитчеләр тоз янына чапкан сыер сымак һаман килеп тора. Килгән саен «хөррият, тигезлек, гадәләт» дип шәрран яралар да, җил куып тараткан томан сымак, кабат югалалар. Аларның нотыгы белән тамак кына туймый...

Кыска бишмәт кигән нотыкчының сүзе бетте, ахры. «Яшәсен эрвәлүтсә!» дип яман кычкырып, арба өстеннән төште. Аны утыз яшьләр чамасындагы, хәрби гимнастерка кигән бер ир алыштырды. Монысы печән кибәнедәй зур гәүдәле иде, аның авырлыгыннан арба чүгеп куйды. Әмма әлеге вәкил, элеккесе сыман, һава кисеп, йодрык болгарга гына ашыкмады. Ул җилпучтай дәү кулларын киң каешына терәде дә, җыелган ирләрне күздән барлый-барлый, бик озак тын торды. Шушындый пәһлевандай кеше мыегын бәп-бәләкәй шакмак итеп кенә йөртә, читтән караганда аның йөзе кишер ашарга җыенган куянныкын хәтерләтә икән. Шуны күзаллапмы, төркәйлеләр дә җиңелчә елмаеп күзәтүен белде.

Хәрби кеше, җиз торбадан чыккан төсле калын тавыш белән, ниһаять, сүз башлады:

— Сез бу килмешәк безгә нәрсә вәгъдә итәр, тагын нинди тәртип урнаштырыр дип көтәсездер инде. Без гомер буе шулай өстән әмер көтеп кенә өйрәнгән кавемнәр бит. Патша фәрман бирә, юк, ул җитми, без әле губернатор әмерен көтеп тилмерәбез. Инде губернатор да әмер бирә икән, юк, анысы да җитми. Без аннары, волостьтагы исправникның, авылдагы старостаның артка типкәнен көтеп, кысыр сыер сыман таптанабыз. Юк, җаныкайларым, кардәш-карендәшләр, алма, пеш — авызга төш, дип кенә бармый икән шул дөнья. Питербурда падишаһның тәхеттән ваз кичкәненә елдан артып китте. Эшче-крәстиян Советлары хакимияткә килгәнгә дә ярты ел вакыт үтте. Рәсәйдәге бөтен кала-бистәләр диярлек хәзер, элекке хуҗаларын куып, Совет ягына күчте. Бөтен Рәсәй хәзер язгы ташу сыман актарыла. Тик сез генә һаман уянмыйсыз, һаман мәрткә киткән шикелле йокыда сез. Йә, әйтегез инде, крәстиян халкы гасырлар буе көтеп тилмергән азат, хөр тормышны сезгә Питербурдан йә Уфадан килгән завод эшчеләре Иван белән Сидор төзеп бирерме?!

Шакмак мыеклы хәрби бик тә гади, бик үтемле итеп сөйли иде, халык тып-тын торды. Әмир пышылдап кына күршесе Мисхәттән сорашты:

— Монысы кем тагын? Нинди япәтник бу?

— Моратов Шаһибәк бу, безнең Бүздәкнеке. Ярман сугышыннан яраланып, унтер булып кайткан. Кайтуының икенче көнендә үк бөтен вулыста Совет оештырган. Аннары Бәләбәйгә, өяз Советына алдырганнар аны. Хәзер Бәләбәйдә хәрби комиссар итеп тә куйганнар, ди. Безнең вулыстагы Җантурин ише алпавытларны куып тараткан кеше шушы була инде. «Шаһи-Морат» дип кенә йөртә аны халык. Бу — җил кайсы яктан иссә, шуңа авып йөри торган япәтник-фәлән түгел.

Әмир белән Мисхәт сөйләшкәнне тыңлап торган диярсең, Шаһи-Морат боларның сүзен элеп алып китте:

— Сезне еллар буе талап-имеп яткан Җантуриннар Себер ягына качты. Ә хәлсез-ялгызакны батрак итеп яллап эшләтә, кабып йота, канын эчә торган чуртан-кандалалар һаман калды әле. Сезнең Төркәйдәге Рөстәмбәк белән Гәрдән бай кандала түгелмени? Югыйсә большевиклар фиркасе әле хакимияткә килүгә үк «бөтен җир — крестьяннарга» дип игълан итте ләса. Рөстәмбәк, Гәрдән бай ишеләрнең ярлыябагайдан талап җыйган җирләрен өр-яңадан бүлешергә вакыт. Җан башына карап. Рөстәмбәктә дә авыз бер генә, ярлыда да бер әү. Дөрес әйтмиммени?

Шаһи-Морат әүвәл үзе тау шарламасын хәтерләткән сыман тавыш белән шаркылдап көлә башлады, аны төркәйлеләр дәррәү эләктереп алды.

— Авыз бер үк, корсак дигәне төрле. Кайберәүнең тезгә салынып төшкән, ә безнеке сыртка ябышкан.

— Дөрес, дөрес!

— Мин корсакларның төрле икәнлеген сез әйтмәсәгез дә беләм,— дип, Шаһи-Морат янә дәвам итте.— Берәү ачлыктан сикерә, берәү туклыктан бии, дип юкка әйтәләрмени? Менә шул артык бүксәләрне юнып чыгарга вакыт җитте безгә. Хәзер бөтен Рәсәй буенча имана җирләрен кабаттан бүлү бара. Әнә Урал аръягындагы Себердә дә, Дунай белән Идел буенда да алпавыт вә дворян утарларын янәдән бүлешәләр. Урыс халкы белми кыланмыйдыр. Без татарга да кузгалырга вакыт. Татар корсагы да урыс крәстияненекеннән ким түгел бит.

— Түгел, түгел! Урыс — ушлы халык,— дип, мәйдандагы ирләр янә очкын өстәп алды. Ләкин әле төркәйлеләрдәге дәрт-омтылыш коеп яуган яңгыр астында янган үшән учакны гына хәтерләтә иде. Шаһи-Морат сүз дилбегәсен кагып, уйнаткалап куйды.

— Совет власте — ул сезгә Рөстәмбәк өләшкән бер чәркә аш хакына бик җиңел генә буып куя торган Чәрмәсән елгасы түгел. Большевиклар фиркасе хакимияткә мәңгелеккә килде! Пайтәхеттә Ленин «бөтен җир — крәстияннарга» дип фәрман биргән икән, димәк, үтәячәкбез. Власть — безнең кулда! Сезне җыеп нотык сөйләргә дип кенә килмәдек без монда. Коры кашык авызны ерта, ди. Менә без сезгә Бәләбәйдән дә, Бүздәктән дә җир комитетчыларын алып килдек. Чәчү өсте җитте. Сезнең ул Рөстәмбәк белән Гәрдән кулак басуларын бүген үк бүләчәкбез. Мәгәр безгә мондый эшне ерып чыгар өчен, үз арагыздан бер кешене җир комитетына вәкил итү кирәк. Арагызда Рөстәмбәкләр каршында җебеп төшми торган куш йөрәкләр бармы? Үзенә күрә старшой итеп кемне күрсәтерсез?

Төркәй ирләре әйтерсең су капты. Байтак вакыт буе каш астыннан гына бер-берсенә күз йөртеп тик тордылар. Ниһаять, бер елгыры әүвәл пышылдап диярлек күршеләренә дәште:

— Әмир, Әмир. Зимагурлыкта йөрүгә ул күнеккән.

— Әйе, Әмир, Әмир! — дип, һәммәсе дә шундук эләктереп алды. Аннары барчасы берьюлы җиңел суладылар. Әмир үзе әле берни аңышмыйча як-ягына каранып тора иде. Шаһи-Морат җыенга нокта куйды:

— Әмир икән, Әмир. Кулыгызга таяклар алыгыз да, әйдә, киттек.

## 7

Төркәйгә бер ай ярым чамасы да тыныч кына яшәргә язмады. Халык майны үткәреп җәйгә аяк баскан гына иде, ә Уфадан инде җанны өшетерлек хәбәр кайтып җитте:

— Урал ягында ниндидер чех әсирләре фетнә күтәргән, ди. Алар Чиләбе белән Самараны кулга төшергәннәр, шулар саранча көтүе сыман ябырылып, безнең Уфа өстенә һөҗүм итә икән.

Ике-өч көн үтүгә, тагын да утлырак яңа хәбәр:

— Советныкылар Агыйдел буйлап качкан. Теге чехлар Уфага да бәреп кергән инде...

Әле кичә генә үзара төрткәләшә-төрткәләшә байбәтчә җирләрен даулашып йөргән ярлы-ябагай, утлы кисәү күргән эт баласы сыман, койрыкларын кысты, эчкә бөгәрләнде. Ярты авыл ире ихатасыннан чыкмас, аралашмас булды. Аның каравы Рөстәмбәкнең дә, Гәрдән бай белән Әхтәм хәзрәтнең дә йоны тиз кабарды. Болар инде, азау теше чыгып килгән сабый бала сыман, бөтен авылны шәрран ярып йөрде:

— Әһә, астыгызга су кердеме, гыйбад?! Әле кичә генә, чәбәкәйләп-биеп, безнең җирне талап йөрдегез бит. Сәвит вләсте мәңгелеккә килгән, тигезлек, хөррият, имеш. Сукыр ана төшендә койрыклы ай күргән, ди. Сез дә шулай, безнең җирне талап, алпавыт Җантурин сымак яшәргә ният иттегезме, җыен хөрәсән? Ә асылда исә без иген үстергән басуларны буш солыча белән сарут капладымы? Моның өчен без сездән кан костырачакбыз әле! Бер сынык икмәк теләнеп киләсе көннәрегез алда әле сезнең!..

Тиккә генә янамый икән болар. Чыннан да, җирләре киселгән, утары таланган байлар янә баш калкытты. Канлы үч алулар турындагы сүзләр бөтен тирә-яктан көне-төне, кар катламы астыннан бәреп чыккан язгы су шикелле, агып кына торды.

— Уфада Совет яклы булып йөргән эшчеләрнең мәетләре белән бөтен урам тулган.

— Самарада — Учредилка, Уфада ниндидер Комуч, Советларны куып, үзләренең властен урнаштырган.

— Уфа төрмәсендә урын беткәч, ике мең ирне чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган баракларга ябып куйганнар. Бараклар тирәсе тел белән ялап алган сыман, ди, бер үлән калмаган, ди. Хәзер Бәләбәй төрмәсе дә балык мичкәсе кебек шыплап тулган икән...

Әмирнең үзеннән бигрәк Әбелнәгыйм абзый белән Гөлтуташ килен гел ут йотып йөрде.

— Бәләбәйне урап алган икән, безнең якка да килеп җитәчәк бу кыяматтәй давыл. Уфа белән Бәләбәйдә эшче-га-

лахларны утлы табага тезеп биетсәләр, Төркәйдә, беренче чиратта, синең белән минем тиреләрне салдырырлар инде. Галах котырта дип, ул Рөстәмбәк белән Гәрдән кулак җирләрен бүлгән чакта, атаман булып йөриләр димени? Бигрәк прастуйлар без. Авызыннан сөякне талап алуга түзеп торамы соң инде ул бай этләр? Хәзер шулар безнең аяк табанын телгәләп, әллә нинди зәһәр тозлар сибә-сибә тантана итәр инде, — дип, бер яктан йорт хуҗасы кайгы-пошаманга төшсә, икенче яктан, түгәрәкләнеп килгән тәнен сыпыра-сыпыра, Гөлтуташ игәүләде.

— Җылы якта ерткыч-дошман күрсә, башын ком астына тыгып котылмакчы булган бер сантый кош бар икән, дип сүли торган иде безнең атай. Сезнең авылныкылар да хәзер артларыннан тын алгандай йөри, каралты-кура эченә бикләнеп кенә байларның үч алуыннан котылмакчы бугай. Айһай, җаныкаем! Тере килеш тәнендәге йонын йолыкканга кем түзсен ди? Кичә хәерче-алабай бәйрәм иткән иде, хәзер Рөстәмбәкләр биеп йөрер инде. Сезнең авылныкылар оста. Әмир атаман булып йөрде, без иярдек кенә дип, алар бөтен байбәтчәне безгә өстерерләр. Этлек эшләп койрыгыңны сыртка салуга син күнеккән. Син бу юлы да ялгыз башыңны алырсың да зимагурлыкка китеп котылырсың. Үксез, ятим булып калгач, без нишләрбез?..

Беркөнне Әбелнәгыйм бик соңарып кына Күчәрбай базарына чыгып киткән иде, кич җиткәндә, артына ут капкандай, хафаланып-янып кайтып керде.

— Бүздәктә бәлшәвикләр кәмитетын ябып куйганнар, ди. Иярле бер әтрәт Килемгә барып Җантурин басуларын бүлеп йөргән Кәлимулла дигән алабайны кое сиртмәсенә асып киткән. Шул ук әтрәт хәзер безнең Чәрмәсән буендагы авылларны бастырып килә икән. Килен белән миңа берни булмас, без гөнаһлы түгел. Илдә чыпчык үлми, без ничек тә җан саклырбыз әле. Ә син давай юлга җыен, улым. Бу Рөстәмбәк җир талаган өчен генә түгел, теге чакта янган тегермәне өчен дә үч алачак синнән.

— Исән җанга ясин чыкма әле. Дер калтырап торган малның тиресен җиңел туныйлар ул. Без бит сарык түгел, — дип, Әмир әүвәл сер бирмәгән булып әтәчләнә башлаган иде дә, нәкъ шулчакта Күчәрбай ягыннан мылтык аткан тавыш ишетелде.

— Газраилләр килә, кузгал, улым! — дип, Әбелнәгыйм әмер ташлады да бәрелә-сугыла тышка чыгып китте.

— Без, ятимнәр, яклаучысыз көе ничек көн итәрбез? — дип, яшь аралаш сукранган Гөлтуташ озатуында Әмир чыккан чакта, Әбелнәгыйм Аблайдагы кодасы бүләк иткән ярсу чаптар атны капка төбендә йөгәненнән тотып тора иде.

— Бәләбәй ягына юнәл. Анда, Йөрәктау буенда, Шаһи-Морат әрмис әтрәт туплый икән. Аерылганны аю ашар, диләр, шуның канаты астына сыен инде, улым.

Әмир, урлап үпкән сыман, Гөлтуташның яңагына гына иренен тидерде дә ярсу чаптар сыртына сикереп менде. Язмыш ни язганны өчесенең берсе белми иде.

## 8

Ике-өч ай саен, кайчагында атна саен диярлек власть алышына, әй айкалды дөнья! Хаста Кәримнең унөч яшьлек малае Шәрифулла берни аңлый алмый. Күршедәге Ташбаш Әмирнең зимагурлыкка чыгып китүенә күп булса, шул ике ел үткәндер инде, ә власть дигәннәре ничәмә-ничә тапкыр, күрше ихатадагы тавыклар янына ияләнгән кәнтәй әтәч никахы сыман, гел яңарып тора. Әле кайчан гына чехларны Уфадан яшел әләмле ниндидер «халык армиясе» куып җибәргән, дип сөйләгәннәр иде, аларны, үз чиратында, Кызыл Армия дигән гаскәр алыштырган. Аннары мөнбәргә Колчак дигән адмирал менгән иде, анысын Чапай Себер ягына куган, дип сөйләделәр. Уфаның үзендә шулай булгандыр да бит, ә Төркәй аша үтеп-сүтеп йөргән әтрәтне кем аерсын? Дәүләкән ягыннан әтрәт килеп керә, аны аклар, диләр. Аларның ат йә ризык талап чыгып китүе була, икенче көнне Бәләбәй ягыннан яңа әтрәт килә, анысы кызыллар, ди. Болары да барыбер йорт борынча ризык талап чыга, аермасы нидер? Мәгәр ризык талау белән генә бетсә икән әле, юк шул, кадалгыры! Тегеләре дә, болары да, ризык талап чыккач, бөтен Төркәй халкын мәчет мәйданына куып тутыра да һәр йорт саен бер олау таләп итә.

— Безне Чакмагыштa штабс-капитан Самойлов полкы көтә. Атлар җыеп шунда озатыгыз,— дип, бер атнада аклар корал селки.

Хаста Кәрим йортында дилбегә тотардай башка ир-ат юк бит, мин малай-шалай гына дип акланып калып булмый, Шәрифулла ничарадан бичара үзе юлга чыга. Ә икенче атнада инде кызыллар бәреп керә. Кайсы явыз мөнәфыйгы сатып өлгергәндер, халыкны мәйданга җыюга, кичәге олаучыларны агач стан өстенә салып камчылыйлар.

— Әһә! Пырлитарият тәненә сөлек булып кадалган аклар әтрәтенә хезмәт иттегезме? Һәрбер олаучыга егерме биш камчы!..

Шулай суктырып кына калсалар икән, каһәр! Болары да, үз чиратында, йә Дәүләкән, йә Бүздәк ягына илтергә олаучылар таләп итә бит аның. Канга батып беткән гәүдәсен чак-

чак кыймылдатып, Шәрифулла янә ерак юлга чыга. Икенче атнада исә тагын яңа әтрәт, яңа суктырулар:

— Җыен хәерче-алабайдан торган кызылларның артын ялыйсызмы? Һәрберегезгә егерме биш камчы!..

Кайсы якка хезмәт итәргә дә, кай тарафка качып котылыргадыр — шайтан үзе белсен. Яраларын өненә качып ялаган бүре сыман, Шәрифулла да, сәндерәгә менеп, кутырлап беткән сыртын уып ята. Күп йөргән — күп күрә, дигәннәре хактыр инде, чүп үләне белән шыплап тутырылган чорма сыман хәтер сандыгында искә алып яңартырлык хатирәләр шактый. Әле менә Бүздәккә баргач кына да, искитмәле хәлне яртылаш үзе күреп, яртылаш ишетеп кайтты.

Төркәй олавы барып җиткән чакта, Бүздәктә власть йөгәнен тагын аклар эләктереп алган икән. Куллары артка каерып бәйләнгән унсигез ирне урам буйлап авыл читенә таба алып чыгучы аклар әтрәте белән Кидәш елгасы күперендә очраштылар алар.

— Менә бөтен вулыста Совет төзеп йөргән бәлшәвикләр болар. Мәгәр мондый ач әрвахларның көне бетте инде. Яр өстенә тезеп атабыз боларны без хәзер,— дип аңлатты кулына үзе буе озын мылтык тоткан бер юантык абзый.

Болар юлны өйрәнеп куйиган, ахры. Күперне чыгуга, әсирләрне елга ярына куып төшерделәр дә Биек Чагыл дигән тау итәгенә таба алып киттеләр. Бераздан, шарт-шорт итеп, берсен-берсе уздырып аткан тавышлар ишетелде. Ә икенче көнне, чышан-пышан гына килеп, төркәйлеләр кунып чыккан фатир хуҗасы җан өшеткеч сәер хәл сөйләде:

— Теге кичәге унсигез бичараның берсе үлмәгән булган бит, исән калган булган. Атучылар китеп барган чакта, шул бичара, урыныннан кубып, боларга кул изәгән. Атучылар арасында моның бертуган энекәше дә булган икән. Артына борылып караган чагында шул бәдбәхет энекәше күреп алган моны. Мәгәр әфисәрләргә әле әйтмәгән, ди, башта. Соңрак Ракай кулак йортына кайтып эчә башлагач кына чишелгән, ди. Шуннан аккан кан эзе буенча барып тапканнар да көпшә терәп янә атканнар, ди, теге бичараны. Менә тегеләрнең, ичмаса, унҗидесе бергә, ә бу, мәрхүм, аерым ята инде. Энесе — абыйсының, улы атасының гомерен кыя торган нинди кыямәт соң бу, йә Илаһым?!

Шәрифулла, авылга кайтканнан бирле, шушы коточкыч хәлне оныта алмый иза чиккән иде, бактың исә мондый гомер кыюлар Төркәйгә дә килеп җиткән икән.

Бер кичне, Йосыф кулакларның бәрәңге бакчасында купкан галәмәт кыргый тавышны ишетеп, берсен-берсе узышаузыша, төркәйлеләр арткы киртә буена җыелдылар. Кара-

салар, Йосыф кулак олы кәтмән белән каерылып-каерылып рәт арасын кыйный, ә җиргә сузылып яткан ниндидер сын бәрәңге сабакларын сыта-сыта туктаусыз бөтерелә, гел качмакчы була. Йосыф илереп суккан кәтмән саллы төште бугай, берзаманны теге сын иясе бөтенләй тынып калды, бөтерелмәс булды.

— Байның абзарына төлке кергән бугай. Әнә сары булып йоны күренеп тора,— дип, арадан берсе гөманлап та карады әле шулчак.

Ләкин киртәләрне аралап якынгарак килгәч шаккаттылар: бәрәңге сабаклары арасында кан-балчыкка уралып яткан гәүдә — сап-сары чәчле, бер учына картуз кипкесен йомарлап тынган рус кешесе иде.

Икенче көнне авылга кызыл әтрәт килеп кергәч кенә, барысы да ачыкланды. Бу бичара — Бәләбәй төрмәсеннән качкан Кадомцев фамилияле зур бәлшәвик икән. Күчәрбай ягындагы сырт буйлап аклар әтрәте куа килгән аны. Юлда яралаганнар. Кадомцев, бичара, Йосыф кулак бакчасына кереп бәрәңге сабаклары арасына качып котылмакчы булган. Шунда Йосыф-мөртәт башына җиткән аның...

Кызыллар бик ашыга иде, күрәсең. Бәлшәвик Кадомцевны авыл читендәге бер калкулык өстенә чыгарып җирләделәр дә, мылтыклардан бердәм залп биреп, шундук югалдылар. Кадомцев өчен үч алырга атлыгып торучы кеше табылмады. Эзләсәләр дә бик соң, Йосыф кулак әле таң белән үк Уфа ягына чыгып качкан иде...

Шулай Йосыф ише байлар качып котыла белә, ә Хаста Кәримнеке сыман ишле, ярлы гаилә ни генә кыла алсын? Аклар киләме авылга, кызылларммы — аралап-яклап калырдай бер кешең юк, үз көнеңне үзең күр икән ул. Яшисе килгәч, барыбер җайлаштылар. Кызылларның әтрәтләре әле былтыр, әллә нинди «азык-төлек налугы, мәҗбүри налук» дигән сылтау белән йорттан-йортка кереп икмәк талап йөри башлагач та, Шәрифулла белән Хаста Кәрим келәт астына зур баз казып куйды. Булган бөтен ашлыкны шул баз эченә кертеп тутырдылар, сайгаклар өстенә ике-өч чиләк бәрәңге белән кишер тараттылар. Шуннан бирле авылга кайсы әтрәт килеп кергәнен сагалап баш ваталар. Аклар икәнлеге сизелдеме, Шәрифулла үзе сеңелкәшләренең бөтенесенә дә ак яулык бәйләтә дә келәт эченә кертеп утырта тегеләрне. Кызыллар күренә икән — кызыл яулык. Бәласеннән башаяк дип, җиткәнрәк кызыйларны — эчкә, сабыйларны алга утырталар. Шулай җан асрыйлар.

Чынлап баксаң, Кәримнекеләр генә түгел, бөтен Төркәй, ихата тузанында тибенгән тавык сыман, көн итәргә азаплана

иде. Бүген дә әле әнә Миркәйләр ягыннан гармун тарткан сәер тавыш ишетеп, Шәрифулла сәндерә тәрәзәсе янына сикереп менде. Миркәйләр ихатасына биш-алты җилкенчәк кыз, яшь киленнәр җыелган, шулар чыр-чу килгән булып җитен суга икән. Биш-алты кыз бергә җыелган җирдә борын астына мыек төрткән егетләр булмыймы соң?! Әнә шуларның берсе, түбән очтан менгән Сибәй-Сибгатулла, кыяр-кыймас кына гармун суза:

Ап-ак келәтләрнең алларында
Матур кызлар талкы талкыйдыр,
Үзләре лә талкы, әй, талкыйдыр,
Күзләрендә кояш балкыйдыр.

Элек егетләр бу көйгә шундый сүзләр тезеп җырлый торган иде, ә бүген менә каш сикертеп кенә моңаялар. Кызлар туктар, ә аннары егетләр олы ләгәннәргә салып җитен юар инде. Аларның кул көчле, җитен юу — ул егетләр эше.

И, бар иде соң урамнарны шаулатып өмә үткәргән чаклар! Бае-ярлысына бүленмичә авылның бөтен яшь-җилкенчәк кызлары-егетләре чират җиткән йортка җыелыр иде. Әүвәл ихата тутырып мәш килерләр, аннары, атларга утырып, гармун тарта-тарта, Чәрмәсән буена төшәрләр дә кич җиткәнче шунда җитен чайкарлар, ул җитенне соңыннан кызлар көянтә очларына элеп кайтыр, ә егетләр, бер капка төбеннән икенчесенә күчеп йөри-йөри, төн җиткәнче җыр сузарлар иде. Әллә егетләрнең чакыруына, әллә үз тәннәрендәге дәртнең кайнавына түзмичә, качып торган лапас асларыннан кызлар атылып чыгар, ә аннары инде башына тай типмәгән елгыррак егетләр тәне күлмәгенә сыешмаган һәрбер чытлык кызны сыер буазлыгын тикшергәннән дә остарак итеп баш түбәсеннән үкчәсенә хәтле кымтырыклап-капшап тинтерәтер, тегеләре шул сагынылган, талымлы рәхәтлектән, и-и, чырылдаган, и-и, оялган булып сыгылыр-бөгелер дә, ахырда исә үзе үк мондый уеннарны пар ат җигеп тарттырсаң да, мәңге ташлап китмәс, яңа бер җай чыгуга колын сымак сикергәләп килеп җитәр иде... Э-эх, кабат кайтыр микән соң инде ул андый хәвефсез, имин, истирахәт чаклар?! Питербур атлы пайтәхеттән күчкән бу кыямәт уты, ачы күз яшьләре, туктаусыз кан коюлар туктар микән берәр? Әнә бит әле Дүртөйле ягында тагын әллә нинди «Каракош» дигән фетнә кузгалган, ди. Кызылларның акыртып талавына каршы күтәрелгән сәнәкчеләр үзләренең кантурларын шулай атый икән. Анысы кайсы авылларны канга батырыр да кайчан тынар инде?..

# ИКЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

## 1

Әмир туган авылына кабат егерме икенче елның язы борынлаган чакта гына кайтып төште. Дөресрәге аны калын итеп салам түшәлгән чана төбенә салып кайтардылар. Үзенең үрәчәдән аяк салындырырлык та егәре юк иде. Бүздәктән бирле озата килгән ике солдат аны кулларына күтәреп алып керде.

Өзелеп төшкән яфрак сыман кибеп бөгәрләнгән ике-өч яшьлек бала өй эчендә берьялгызы иде. Теткәләнеп беткән иске-москы киемнәргә төренеп утырган бу сабыйның эчкә баткан күз төпләренә, каен тузы сыман бөрешкән иреннәренә карап ятты-ятты да, үзенең дә как шикелле кипкән иреннәрен чак-чак кыймылдатып, Әмир сорау бирде:

— Кем син, кәбәм?

— Дифа,— диде сабый, һичбер каушамыйча. Икенче мизгелдә исә татарча «з» авазы да яңгырап чыкты:

— Гөлтуташның кызы.

— Кызым, балакаем! — дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмый калды, сабый Зифа йөгереп килеп аның кочагына сеңде. Әмирнең ике күзен тиң ачы яшь каплаган, ул Зифаны күрми, чәчләреннән йомшак сыйпап кына үз сөяген танырга, юатырга азаплана иде.

Көттереп кенә, сыкрап-ялындырып кына ачылган ишек тавышы аерды аларны бер-берсе кочагыннан. Беренче булып хәл белергә керүче кеше — күрше малае Шәрифулла икән. Хәзер өрәк кебек бик ябык булса да, Әмир күрми торган өч-дүрт ел эчендә буйга нык калыккан бу күрше малаена инде яшүсмерләр кыяфәте кергән. Ишекне япкач та таптанып тормады бит, түргә кадәр узды да егетләрчә каты итеп Әмиргә кул сузды. Урындыкка иңгәч, бер аягын икенчесе өстенә салып утыруы да, тамак кырып алулары да хәтәр олыларча иде инде моның.

— Исән-сау көенчә кайтып җиттем, дисең инде, Әмир абый. Бик хуп, бик мәслихәт. Гөлтуташ апа, көн-таң атса, Бәләбәй йә Бүздәк ягыннан күзен алмый иде. Нык көтте ул сине.

Әмирнең керфекләрен кысып төбәлгән карашында ниндидер очкын кабынуны сиземләде бугай, Шәрифулла йөзен түбәнгәрәк иеп дәвам итте:

— Әбелнәгыйм агай белән Хәдичәттәй дә үзеңне дүрт күз белән көткәннәр иде дә бит, ул бахырлар мондый көнне күрә алмый китеп бардылар шул. Атаең белән Әбелсаттар агаеңны Рөстәмбәк, пакыч, син китеп югалгач, тагын суктыр-

ды бит. Әбелнәгыйм агай шуннан бирле мантый алмый йөрде, ә былтыр көз, ачлык башлангач, Хәдичәттәй белән бер-бер артлы гүр иясе булды. Аннан чират Зифаның игезәге Мортазага җитте. Анысын бер ай элек кенә илтеп куйдык әле. Һәр йорт саен диярлек шундый үлем-китем, ачлык кырды гына. Менә шулай гомер иттек инде, гаепләмә безне, Әмир абый…

Мондый гына бәяләүне азсынды, күрәсең, бераздан Шәрифулла авыл хәлләрен бәйнә-бәйнә тасвирлауга күчте:

— И-и, күрде инде башлар, Әмир абыкаем! Көз көне әллә нинди ЧОН әтрәтләре килеп йортлардагы булган бөтен икмәк-бәрәңгене актык бөртегенә чаклы кырып-себереп алып киттеләр дә авылдагы бәндәләрнең җәмгысын да коры алабута белән сөян, юкә оннарына утыртып калдырдылар. Карлар ятуга ук үзенең зәһәр чалгысы белән бәндәләрне урды гына ачлык… Иртән торгач, Күчәрбай йә Иванай юлына барып чыктыңмы, көнаралаш алты-җиде мәет. Кайсысы ачлыктан кибешеп каткан бичараларның, кайсысы шешенеп хәлсезлектән кар өстенә ауган да шунда йокыга киткән… Ул бичараларны зиратка илтеп күмәрдәй бер ир-ат юк. Йә Бүздәктән, йә Күчәрбайдан әтрәт килеп төшә дә берәр төрле ризык аламасы биреп кенә кеше яллыйлар… Бәрәңге белән он биргән чакларында мин дә катнашып йөрдем әле анда. Һәр мәеткә аерым кабер казып тору юк инде ул. Авыл читендә ат чанасы сыярлык чокыр казыйбыз да, мәетләрне ат белән тарттырып, шунда тутырабыз. Көнендә үк күмеп өлгермәсәң, аларны этләр талап киткән була… Хәер, авылларда хәзер этләре дә калмады шул инде. Аларның барысын да ашап бетерделәр… Этләр кеше түгел, алар беркатлы бит. Берәр хайваны миске-мазар шакып алдадымы, теге эчкерсезләр йөгереп килә дә җитә. Үз башларына килгәннәрен белмиләр шул алар…

Шәрифулла соңрак бармак бөгә-бөгә санап киткән хәлләр чәчне үрә торгызмалы иде:

— Теге Торна урамындагы, Зәмзәмбану апаны беләсең бит инде. Менә шул апа үзенең кызы Санияне сигез кадак онга саткан, диләр. Түреш авылындагы илле ике яшьлек бер ир алып киткән. Ә Саниягә унбиш әле яңа тулган гына иде.

— Сездән дүрт-биш өй аша гына яшәгән Сираҗи агай белән Хәмдүнә апаны да беләсең бит инде. Болар күрше Чураш авылыннан хәер сорашырга килгән ике баланы суеп пешергәннәр. Ашарга гына утырганнар икән, төтен белән ит исен сизенеп, күршеләре Фатыйх килеп кергән. Разбойны шул салды. Аннары бөтен авыл бергә җыелып, Сираҗи белән Хәмдүнәне таптап үтерделәр. Зиратка күмүче дә булмады үзләрен. Мәетләрен этләр талап китте.

— Авылларда, юлларда хәер сорашып йөрүче ятимнәр

күп хәзер. Бер-ике ай чамасы элек кенә безнең Төркәйдә алар иллеләп бар иде. Уфадан әллә нинди «ачлык кәмитеты» дигән әтрәт килеп төште дә шулар бер утыз тирәсе ятимне җыеп алып китте. Күчәрбайдан — бер йөз, Усманнан — егерме, Түреш белән Әбзәннең икесеннән җитмешкә якын ятимне җыйнаганнар, диләр. Менә шуларны Уфада мал вагуннарына төягәннәр дә Урал белән Себер якларына алып киткәннәр. Аларны анда әллә нинди махсус интернатларга, диттдумнарга япканнар ябуын, ашаталар да, ди. Мәгәр аларның һәммәсен дә Иван, Николай, Маруся дип чукындырып бетергәннәр икән шул...

Өй эчендә мәгарә тынлыгы урнашты. Сүзне бик озактан соң гына янә Шәрифулла үзе башлап китте:

— Гөлтуташ апа кичә иртән Аблайга, әтиләре янына кайтып киткән иде. Хәзер һәр кешедә тамак кайгысы бит, җан саклар өчен ни дә булса юнәтергә кирәк. Исән булса, бүген кичкә кайтып җитәр инде...

Гөлтуташ өйгә кайтып кергән чакта, Әмирне озата килгән ике ир дә, Шәрифулла да чыгып киткән иде. Елашып күрешсәләр дә, ир белән хатын бер-берсенең кыяфәтенә иләшә алмый озак утырдылар. Башлап, үзенең хәлен Әмир бәян итте:

— Шаһи-Морат комиссар белән бергә Ташкент якларына барып чыккач, чабартмалы тиф дигән нәгъләт аяктан екты мине. Ташкент янындагы Алмалык госпиталендә аунап яткан идем, аннан поезд белән Самарага кайтарып ташладылар. Инде ярты ел буе түшәктә ауныйм бугай. Алла боерса, терелəм инде хәзер.

Әмир үзенең үткән-сүткән юллары турында шуннан ары бер авыз сүз әйтмәде, аның каравы Гөлтуташ күз яшьләрен туктата алмый тезде:

— Биатай исән чакта җиңел булган әле. Үзе түшәктә ятса да, ул мине бер генә бәндәдән дә рәнҗеттермәде, гел-гел яклап килде. Ә ул китеп баргач, синең Әбелсаттар агаң и талап та торды инде безне! Бирнә булып килгән күпме малны аңа илтеп бирдем! Көмеш тәңкә, көмеш беләзекләр, хәситә, ике-өч төрле алка, ике җиз самавыр, күпме керәч чәйнек... Ул убырның туймас тамагына илтеп тыккан әйберләрне санап кына бетерерлекмени? Әллә ничаклы чиккән ашъяулыклар, күпме чаршау-пәрдә, бала итәкле батист күлмәккәем, биле бөреп теккән ике яңа бишмәт, күпме мендәр-ястык, минем мамык шәлләр — уф, егылып үләм!.. Ул менә шуларны төяп йә Күчәрбай, йә Каргалы базарына чыгып олага да әле юлда талаттым, дип кайта, әле әчмуха хакына гына сата алдым, дип алдый. Ә үзенең бөтен тәрәзә-ишекләре миңа бирнә булып килгән пәрдә-чаршаулар белән тулып бетте инде. Минем газиз балаларымның авызыннан өзеп алган хәрәм сый-

нигъмәтләр ул убырның тамагына аркылы да тормый бит ичмасам!..

Гөлтуташ күз яшьләрен сөртергә дип тукталган бер арада, Әмир сүз сөрешен икенче якка бормакчы иде дә, сәер җавап ишетеп гел шаккатты.

— Хәби дисеңме син? Нигә ярдәм-таяныч эзләп Хәби янына барып карамадың, дип соравыңмы миннән? И ыштансыз, и прастуй җан, бигрәк беркатлы син! Хәбигә соң аңа хәзер якын бармалымыни?! Ул Йосыф байлар, Гәрдән кулаклар белән генә аш йөрешә хәзер. Ничек инде алай дисеңме? Ә гап-гади, җаным. Унтугызынчы елны ул «халык армиясе» дигән әллә нинди әтрәтләргә язылып олакты да ике-өч айдан соң Себер ягыннан ярты вагун байлык төяп кайтты. Кайтса, монда кох-кох килеп йөргән абыйсы гүр иясе булган, җиңги ялгыз. Хәби хатынлыкка әллә нинди кәләш эзләп йөреп баш ватмады алай. Булган малны читкә таратып булмый, оя әзер дип, җим генә ташлады да тол җиңгәсе янына йортка барып керде. Ә аннары, үткән көздә ачлык башлануга, алар, парлап, бер-ике кадак икмәк йә атланмай хакына якын-тирәдәге бар ярлының бура-келәтләрен, шкаф-өстәлләрен үзенә җыярга тотынды. Хәби хәзер безнең ише галах ягына карап төкерми дә. Сиртмәле тарантасларда гына йөри бүген «ахирәтең» Хәби!..

Гөлтуташ, капкаларга дип, җылы аш әзерләгәч, әлбәттә инде, Аблайдагы Рәҗәп гаиләсенә дә чират килеп җитте. Мәгәр бабай тиеш кешенең хәл-әхвәле бер дә читләр көнләшерлек, сокланырлык түгел икән инде. Гөлтуташның гел сырхаулап йөргән әнисе әле өч ел элек үк дөнья куйган булган. Буйдак кеше нинди уйга килеп эш иткәндер инде, ай ярым үтүгә үк, үзенә иптәшкә өч балалы хатын алып кайткан. Хатыны бик тә саран, бик тә вакчыл булып чыккан икән, хәзер бер кабым ипине дә үлчәп ашата, ди. Шул үги анай тәэсир итте микән, әллә башка уймы — Гөлтуташның өлкән агасы Бикми-Бикмөхәммәт, Колчак гаскәрләренә ияреп, Себер ягына киткән. Бикминең югалуына ике елдан артык гомер үткән инде, ләкин бүгенгәчә аның хакында бер хәбәр дә юк, ди.

Менә шулай, дөнья зарын дисбе ташы сыман барлый-барлый, төн уртасы үткәнче сөйләшеп утырдылар. Хәзер яңа көнне каршыларга кирәк, Уфа яклап ал таң ата иде.

## 2

Әмир май ахыры җиткәндә генә беренче кат ныклап аягына басты. Ходай Тәгалә былтыр, аяусыз корылык җибәреп, адәм балаларын коточкыч газапларга дучар иткәне өчен

оялгандыр инде, быел язны иртә һәм мул яңгырлы бирде. Май башында ук агачлар канат ярды, ялан-кырда үлән тишелеп чыкты, ай ахырында чәчәкләргә тикле таҗ җибәрде.

Күк йөзендә кояш иртәдән бирле әйтерсең лә кунакка дәшә иде. Әмир беренче кат ихатаны ташлап чыкты да, салмак атлап, Чәрмәсән буена китте. Сагындырган, юксындырган икән бит, и туган як! Саумы, гүзәлем, саумы!

Бу якларны Урал тауларының бер итәге, Бәләбәй-Бөгелмә калкулыгы, диләр. Монда дөнья иркен. Көнчыгыштан көнбатышка таба дулкын-дулкын булып сузылып тау сыртлары ята. Әмир байтак кына юллар үткән кеше, гел чамалап йөрде: моныңише сыртлар, егерме-утыз чакрым саен кабатланып, бер-берсенә охшап сузылганнар. Ул сыртларда бүрек сыман түгәрәкләнеп, көязләнеп утырган түбәтәй-чалма таулар да, баскыч-баскыч булып күтәрелгән калкулыклар да бар. Ә ике дулкын-сырт уртасында һәрчак меңәр-меңәр баш елкы ат көтүләре йөртердәй гаҗәеп иркен дала. Шул далалар уртасында кызларның алсу яңагына сибелгән сипкел сыман эреле-ваклы күлләр, елга һәм инешләр. Күл тирәли — камыш, елга-инеш буйларында — тал, әрәмә, камырлык, гөлҗимеш, шомырт куаклары. Җәй җиттеме, инеш белән күлләр тирәсендә кыр казлары, торна тавышлары. Бу якларга килеп авыл корган ерак бабайлар очлы күзле, елгыр булган инде. Чәрмәсән буйлары, Чагылтау итәге җәннәт бакчасы бит!

Әмирләрнең ерак бабалары бу якларга әле өч йөз илледүрт йөз еллар элек үк килеп утырган бугай. Авылның анык шәҗәрәсе югалгандыр инде, төрле гөманлау яши. Чакмагыш, Чишмә, Каргалы, Күчәрбай, Әбзән, Бүздәк сымак типтәр-мишәр авылларын күпләр ак патша әмере буенча Касыйм ханлыгыннан күчерелгән, диләр. Күчәрбай авылында әле бүген дә Алатыр урамы, Алатыр яланы, Төмән чишмәсе дигән борынгы исемнәр бар... Күчергәндә безнең бабайларны, Рәсәй чикләрен ногай, калмык, башкорт, кыргыз-кайсак кабиләләреннән саклар өчен, атлы казакъ итеп, йомышлы катлам ясап утырткannar, имеш. Монысы да хактыр инде аның, бабайларның Җаек буена берәр-берәр еллык сакка йөрүләре төркәйлеләр күңелендә әле дә саклана бит.

Аннары беренче булып күчеп утырган типтәрләр һәм мишәрләр арасында морзалар да байтак булган, диләр. Каргалы ягында әле бүген дә Еники, Яуш, Туиш дигән морза нәселләре яши икән әле. Андый нәселләр Төркәй белән Күчәрбайда да бардыр инде. Бүген аларны кем ачыклап йөри?

Әмма шәҗәрә дигәннәре кайсы якка гына борылмасын, бабайларның яшәр нигез өчен урын сайлаулары бик отышлы булган.

Чәрмәсән елгасы бу тирәдә, әй, бормаланып-уйнап ага да соң инде! Ун-егерме дилбегә хәтле араны үтүгә, елан сыман боргаланып, кирегә борыла ул. Бер җирендә, уенга нык бирелеп, ныграк кергән бугай, ул урында аерым күлгә охшап култык хасил булган. Аның ярларын инде әллә кайчан чикләвек, гөлҗимеш, сәрви куаклары сарып алган. Хәзер бу култыкны «Латыйфа куагы» диләр. Берәүләрнең сөйләве буенча, алтмыш яшьлек муллага өченче хатын булып чыгасы килмәгәнгә бу култык суына Латыйфа исемле чибәр бер кыз батып үлгән, имеш. Икенчеләр нindидер бай малае Латыйфа исемле кәләшен аргамактай чаптарга алышкан да соңыннан үкенүдән аты-ние белән шушы култык төбенә сикергән икән, дип сөйли. Кайсы дөрестер инде, аны кемнәр белсен? Иллә мәгәр әлеге култык урыны ничәмә-ничә дистә еллар буе «Латыйфа куагы» дигән кушамат белән яши.

Бу култыкның болын як ярында үскән тирәкләр бигрәкләр дә сәер. Әллә нишләп бу тирәк яфракларының өсте тоташ яшел төстә, ә аслары — акбур шикелле ап-ак һәм каз мамыгыдай йөнтәс. Башка исем тапмагангадыр инде, төркәйлеләр аны «ак тирәк» дип йөртә. Яр астындагы суның өсте һәрвакытта төнбоеклар белән тулы була. Бу култыктан су алучы, анда коенучы да юк. «Латыйфа куагы»ннан әллә нишләп бик куркалар иде.

Әмир менә шушы култык ярындагы куакларны аралап утырды да су төбенә текәлеп уйга чумды. Әмирнең туган нигезенә кайтып төшүенә өч ай вакыт үтеп бара бит инде, ә аның әле аркылы яткан саламны буйга да алып салганы юк. Иренең авызына җылы ризык керсен, тизрәк ул аякка бассын дип, һаман да шул бер Гөлтуташ кына гел ут йотып йөри. Әле «яңа буржуй» Хәби йортына барып кер юа ул, әле Әхтәм мулла ихатасыннан кайтып керүне белми. Йосыф яки Гәрдән кулак дәшсә, алар ихатасына барып та бил турайтмый эшли. Ә Әмирнең үзенә ни хәл итәсе соң? Хатын җилкәсендә әрәмтамак булып яту, ай-һай, туйдырды бит! Мәгәр ул да, Гөлтуташ шикелле, бер кабымлык икмәк хакына Йосыф-Гәрдән байлар йә булмаса кан дошманы Рөстәмбәк каршына барып тезен чүксенмени? Шаһи-Морат сыман комиссарлар белән иңгә-иң басып тиккә генә дүрт ел буе Советларны яклап йөрдемени? Юк, ачлык-мохтаҗлыктан кәңкәеп үлсә үләр, әмма Рөстәмбәк ише канечкеч каршына барып тезләнмәс ул!

Ә шулай да, хәлсез ир җиңәрдәй бер эш сорап, кемгә генә барып карыйсы соң? Күчәрбайга китсәң, анда Рөстәмбәкләрнең, Гәрдән кулакларның мәсхәрәле карашыннан ерак буласың инде, анысы бер юаныч. Ләкин Күчәрбай — базарлы, зур авыл, аның үзендә дә Әмир сыман хәер эстәүчеләр мыж-

гып торадыр шул. Ә тагын кая гына барып сугыласы? Төркәйдән ике чакрым чамасы ераклыкта, Чәрмәсән буенда, аерым хутор булып яшәгән Яшке каршынамы? Аның хакында күп кенә мал асрый, аерым тегермән тота, хәлле крәстиян, диләр. Әмма Рәсәйнең әллә кайсы почмагыннан куылып Чәрмәсән буена килеп утырган ул урыс агаен Төркәй халкы бер дә өнәми бит. «Печән чаба торган иң яхшы тугайлыкны эләктерден, килмешәк тәре! Вандулый, ычкын моннан!» — дип, төркәйлеләр беренче елны ул агайны куып-өркетеп тә караганнар. Рөстәмбәк, Гәрдән бай яллаган бер-ике куштан аның печән кибәннәренә ут та салган хәтта. Волостьтан урыс урядниги килеп бер җикергәч, басылганнар алар басылуын. Аннары, урыс белән чөкердәшеп яшәү дигән гадәт мәңге булмаган бит инде ул. Җирле халык бу Яков атлы урыс агаен да «Яшке» генә дип мөһерләгән дә өзгән. Ул Яшке дә бик аз сүзле, үз кабыгына бикләнгәнрәк кеше бугай инде. Шуңадырмы, Төркәй белән әлеге ялгыз утар арасына сукмак салынмаган. Ләкин мең яманның — бер рәхәте дигәндәй, бүген ачлык-чарасызлыктан интегеп ятучы Әмир өчен бернинди начарлыгы да юк бит мондый өзеклекнең. Яшкенең төркәйлеләр белән алыш-бирешсез гомер кичерүе Әмир өчен әле кулайрак та. Бердән, син, авылдашларың алдында мескенләнеп, эт типкесендә йөрмисең, үзеңне һичбер кайчан бурычлы санамыйсың. Икенче яктан, синең чит-ят кавем каршында бил бөгеп йөрүеңне үзеңнекеләр күрми. Әмма ничә әйтсәң дә бер сүз: ул Яшке дигән килмешәк урыс кешесе синең кебек хәлсез-хәерчене үзенә эшкә аламы соң әле?..

Шадра күл өстенә текәлеп, көтүдән аерылып калган ялгыз каз шикелле каңгырып утырган Әмирне авыр уйларыннан шәрран ярып кычкырган тавыш аерып алды:

— Үл-ләм, коткарыгыз!

Әмир урыныннан җитез генә сикереп торды, энә күзе аша үткәргәндәй, су өстен айкап чыкты. Култыкның иң түрендә, Төркәйнең бәрәңге бакчалары белән тоташкан урынында ук, кечкенә бер көймә әвеш-тәвеш килә, хуҗасының гына эзе дә юк.

— Бат-там, коткарыгыз-з! — дип, сузып-сузып кычкырган тавыш янә ишетелде.

Әмир шул чагында гына тәгаен шәйләп алды: көймәнең аръягында, бәрәңге бакчалары җәелгән текә яр астында бата-чума тилмерүче кеше — гомер буе балык тота-тота җан асраган Сәетгәрәй дигән бер карт иде. Гомере буе елга белән көн иткән кеше суга батсын инде, и тәкъдир, диң! Әле ярый, яр астында үскән талларга тотынган бу, шулар саклап калган.

Әмир атлый-чаба диярлек култык түренә таба кузгалып киткән иде, аннан өлгеррәк яшьләр табылдылар. Бакчада бер килен белән аның сеңлесе бәрәңге арасын утап ята икән, колга сузып, шулар Сәетгәрәй картны яр өстенә тартып чыгардылар. «Ә» дигәнче, бичара карт янына әллә ничаклы халык җыелды.

— Җәен сукты минем кәмәгә, сары җәен сукты. Үзем күреп калдым. Албасты чаклы җәен иде, каһәр! — дип, тәненә җан кергән Сәетгәрәй карт хәзер инде һәммәсен авызына каратып шапырынуга күчте.

— Әйтәм аны каз бәбкәләре югала торган иде, шушы явыз ашап яткан икән, — дип, аның сүзләрен Чәрмәсән буендарак яшәгән бер-ике хатын да шундук эләктереп алды.

Бик озак вакыт сатулашып торгач, ниһаять, төркәйлеләр «Латыйфа куагы»н олы ятьмә белән сөзәргә килештеләр. Әллә каян гына тиз арада ике дилбегә буе ятьмәсе дә, аның төбенә тагарга тимер герләр, яннан сөйрәп йөрергә сүс арканнар да табылды. Икегә бүленгән ирләрнең бер өлеше алдан зур күсәкләр белән шапы-шопы китереп су өстен кыйнап барды, калган ирләр ятьмә өстерәде. Берзаманны теге албасты җәен ятьмәгә кереп эләкте бугай, сүс арканнар дәүдәү ирләрне биетеп уйнадылар. Ниһаять, яр өстенә ятьмәләргә уралып беткән җанвар чыгып ятты. Аны күрделәр дә һәммәсе аһ иттеләр.

Юк, Сәетгәрәй карт шапырынмаган, арттырмаган икән. Башы — җиз самавыр, буе бастырык чаклы, чабата олтырагы кадәр бик озын мыеклы, корсак ягы бөтенләй саргаеп беткән карт җәен иде бу. Коры җир өстенә сөйрәп чыгаргач та бирешәсе килми. Ул имән кәүсәседәй юан койрыгы белән, дөп тә дөп китереп, җирне кыйнап ята.

Төркәйлеләр бик озак вакыт әле аның янына якынаерга да кыймый тик тордылар. Аннары кемдер бу албасты башына авыр күсәк белән китереп состы. Җәен койрыгын сузып салгач кына, самавыр чаклы башны дилбегә белән чорнап бәйләделәр.

Ул арада кемдер җигүле ат белән килеп җитте. Әллә ничаклы ир, көч-хәл белән сөйрәп, карт җәенне арбага мендереп салды. Мондый албастыны күрүдән ат дулады. Карт җәенне янә башыннан да, уртасыннан да бәйләп кат-кат беркеттеләр. Ләкин мондый галәмәт зур җәен арбага да сыймый, аның дәү койрыгы җир өстенә төшеп тора иде.

Һаулый-кыздыра торгач, ат кузгалып китте. Әмирнең зиһене баш түбәсенә авыр күсәк белән сугылган карт җәеннеке шикелле миңгерәйгән, ни галәмәт, ул тозакка эләккән бу җанкайны бик кызгана иде. Әмир әле байтак вакыт буе «Латыйфа куагы»ннан күз алалмый торды.

## 3

Бер-ике көннән соң Әмир тәвәккәлләп килгән чакта, хуторда яшәүче Яков ихата түрендәге лапас күләгәсендә камыт бөятен көйләп утыра иде. Капка артында чит кеше күренү хакында иң беренче булып чылбырларга бәйләнгән ике танадай эт хәбәр итсә дә, килмешәк Яков урыныннан сикереп кузгалырга бер дә ашыкмады. Ул Әмирне җеп тагып борын очына элгән күзлек өстеннән генә ихата уртасына килеп җиткәнче күзәтеп утырды да, ниһаять, камытын читкә куеп, зур бүкәннән купты.

— Һи-и, яны кунак кильган, здравствуй, Амир,— дип, аның әүвәл ике кулын сузып күрешүен, аннары кочагына алуын да күргәч, Әмир тораташ шикелле телсез калды. Вәт әкәмәт! Бу килмешәк урыс татарчаны кайчан өйрәнгән дә, каян гына Әмирне белә соң ул?

Кунакның тирән аптырашта калуын сизеп алды бугай, янә хуҗа үзе ашыкмый-кабаланмый гына тезеп китте:

— Что син кайткан, без давно ишеттик, Амир. Что син авыр, что син постельдә, ул да ишеттик. Без син давно пиләбез пит. Когда син Рустамнын басу кистен, без карадык пит. Син молодец кеше, тогда дурес кистен. Рустам мера пелми. Землякларны грабить — это нехорошо. Постель яту — тоже нехорошо. Ай да ладно! Син казыр укез. Сина казыр яны катын давай.

Яков башта, җиңелчә генә итеп, Әмирнең иңбашыннан кагып-сөеп алды да аннан кычкырып көлде. Чарасы юк иде, Әмир дә аңа кушылып көлде. Ә үзе, хуҗадан күзен ала алмыйча, янә аптырап торды. Яковны төркәйлеләр гомергомергә карт та карт, дип сөйлиләр, нинди карт булсын бу? Аңа чама белән шул илле-илле биш тирәседер инде. Башында ак чәчләр дә берән-сәрән генә күренгәли, сакалы сап-сары. Күз тирәләрендә, маңгаенда тирән җыерчык эзләре бар барын да, ләкин көне-төне басу белән ихата арасында йөгереп йөргән кайсы крәстияндә генә юк инде ул? Ә беләкҗилкәләре, көрәктәй уч төпләре Әмир шикелле салам торханнарның әле икесен-өчесен бергә кушып, бау шикелле үреп ишәрлек бит моның!

— Мин сиңа олы гозер белән килгән идем бит әле, Яков дәдәй,— дип, ниһаять, Әмир авыз ачкан иде, хуҗа шып туктатты:

— Пиләм, эшен бардыр, но эш хакта соннан, соннан, Амир. Минем Анюта әйтә, буш корсак — буш разговор. Давай сперва буш корсак булмасын. Суннан суляширбез.

Ирләр бер-берсенә ике бураны ялгап салган иркен йорт эченә кергәч, барча почмак җанлангандай булды. Гаилә иш-

ле икән. Әмирдән яшь буенча чак-чак кына калышкан ике әзмәвердәй егет. Буй җиткән сөйкемле кыз. Күрше Шәрифулла сыман ундүрт-унбиш чамасындагы бер яшүсмер. Барысы да буйга калку, эре сөяклеләр. Ә хуҗабикә инде! Аңа текәлде дә Әмир күз алалмый торды. Ишек ниргәсенә җиткән озын буй-сын. Су мичкәсе сыман юан гәүдә. Самавыр шикелле мул күкрәкләр. Куәс чиләгеннән ташып чыккан камыр сыман кат-кат салынган ияк. Сугымга дип симертелә торган тана ботыдай түп-түгәрәк беләк. Дөньяда моның ише алпамша хатын-кыз да була ала икән, йә Илаһым!..

— Минем Анюта бу. Точь Илья Муромец. Мин отдельно ятам. Анюта кул салса, мин сразу хана,— дип, хатынына таба ияк какты да хуҗа Яков күтәрелеп көлде. Бу йортта шаян сүзгә күнеккәннәр иде, күрәсең, һәммәсе кушылдылар. Көлешеп туйгач кына, Яков балалары ягына борылып басты.

— Болар — минем тягла укезләре. Иван — старшой, Николай — ике малай. Потом Нина кызым, ул невеста инде. Атай, жених давай, дип сули. Рус жених юк бит, монда кругом татар.

Тагын һәммәсе бердәм көлештеләр, Нина гына җиләк сыман кызаргандай булды. Кызарса да, әллә нишләп, Әмирнең йөзеннән карашын аермады. Кысыла төшкән керфекләре арасыннан көйдерерлек итеп, сынап карый иде ул. Әмир белән алар, көч сынашкан сыман, байтак ара карашларын бер-берсеннән аера алмыйча интектеләр бугай...

— Ну ә менә монсы — Вася. Ул наследник минем. Безнен бабочек ловить итькан ул яратмый. Как укезләр куа. Давай, давай.

Шулай таныштылар. Килеп кул бирешкәндә хуҗаларның һәммәсе дә үзенә татар телендә эндәшүен ишеткәч, Әмир гаҗәпләнүдән башын чайкап куйды. Моны Яков шәйләп калган икән, өстәл янына тезелешкәч, аңлатып үтүне кирәк тапты.

— Раз татар билән бер илдә яшисен, татарча белү киряк. Русь царьлары татарны, башкир, чувашны уважать итми правил. Алай дурес тукел. Татарны уважать киряк. Рус билән татар тикез. Дус яшәркә киряк...

Ашап алганнан соң, Яков Әмирне Чәрмәсән буена, тегермән янындагы кечерәк йорт куләгәсенә алып китте. Әмир бөтенләй көтмәгән дә иде, ә Яков шунда нишләптер үзенең күңел пәрдәләрен ачты да үткән язмышы турында сөйләп китте. Әмир өзек-өзек, саран җөмләләрдән шуны аңлап калды: Яков Булгаков атлы бу рус агае Мәскәүдән ерак түгел генә урнашкан Орехово-Зуево дигән бер каладан икән. Бишенче елгы революция башлангач, Яков шундагы сүс туку фабрикасында стачкалар оештырган, кораллы отрядлар туплаган, шәһәрдә беренче Советлар төзүдә әйдәп йөрүче бул-

ган. Ләкин яңа партия корал алырга дип, Тула каласына юлга чыккач, янәшәсендәге бер «сасы көзән» кайсыдыр станциядә полиция этләренә барып саткан аны. Аннары төрмәдә кыйнаулар, күз буяу өчен генә үткәрелгән хөкем утырышлары. Әүвәл аңа «Себер каторгасы» дигән карар чыгарылган, соңрак аны «кала-авыллардан читтә, аерым хутор итеп утыртырга» дигән хөкем алыштырган. Аксаков, Нефедов атлы язучыларның китаплары аша укып белгән булган, Уфа губернасын үзе сайлап алган. Вася — Яков монда, Чәрмәсән буена килеп төпләнгәч туган бала икән инде.

— Китарга возможность куп булды, ә мин калдым,— дип сөйләде Яков.— Мин — енелгән кеше. Ә яуда енелгән или раненый бурене стая да киный. Жизнь кизык, ана яуда енелгән кеше ярамый икан. Шуна мин менә мунда калдым. Чармасанга да привык...

Авыр уйлар урап алды бугай, Яков буа өстенә текәлеп байтак вакыт буе тын утырды.

— Миңа эш кирәк иде бит, Яков дәдәй. Берәр булышчың итеп алмыйсыңмы? — дип, Әмир үз гозере хакында искә төшергәндә, хуҗаның җавабы әзер иде инде.

— Рустам тегермәнга кеше бармый, мина куп киләләр. Мин етешмим. Мина засыпщик та, механик та киряк. Син булырсын.

Җылы сүз ишеткәч, Әмир рәхмәт укый башлаган иде дә, Яковның соңгы уйлары сагайткандай итте.

— Казыр большевикларда яны политика. Батрак тоткан, магазин ачкан кешене кинамилар. Крестьян баесын, әйтәләр. Потом как йон йолкырлар, аны шайтан белсен. Анюта шулай әйтә.

## 4

Кыш җитеп, лапас түбәләре, бәрәңге бакчалары юрган ябынуга, авылда каз өмәләре йорт борынча тезелешеп китте. Гөлтуташны көндез Торна урамындагы Фазылбәкләр өмәгә дәшкән икән, кичен Әмир белән икесен тиң, парлап, ашка чакырдылар. Яков тегермәнендә батрак булып йөргән һәм «засыпкачы» урынына «ясепкәче» дип койрык тагылган Әмирне авылда әле кунакка дәшеп торган кешеләр сирәк иде. Фазылбәкләр йортына алар тәүге тапкыр аулак өйгә чакырылган яшь кызлар шикелле киенеп-ясанып барды. Кунаклар күп, нарат йортның буеннан-буена сузылган озын өстәлнең бер башына яшьләр тезелешкән, Әмир Ташкент якларында сугышып йөргән чакта, авылда әллә ничаклы кызлар-егетләр үсеп җиткән икән. Менә шул яшьләр башлаган бер хикмәт Әмирне таң калдырды.

Яңа каз итеннән пешерелгән бәлешләрне өстәлләргә чыгарырга вакыт җиткән генә иде, мич буйлап тарттырылган чаршау артында яшь киленнәр әйткәләшкән ыгы-зыгы авазлары купты.

— Җиде бәлеш ясап салдым, дип әйттем бит инде! Кат-кат санап салдым. Җиде санын да бутарга дүрәк түгел бит мин сиңа!

— Монда бишәү генә. Ә икесе кая соң алайса?

— Ә-ә! Әле бая гына чаршау артына Илдерхан зимагур кереп чыкканые. Тастымал кирәгие, кул майланды, дигән булып. Шул зимагур гына чәлдереп чыккан икесен, вәт чукынчык!

Киленнәр әле чаршау артыннан да чыгарга өлгермәде, ә ишек катындарак утырган Илдерхан белән Кәшби урыннарыннан сикереп тә торды. Кәшби гармун сузып җибәрде, Илдерхан биеп китте. Кунаклар урындыкларын күчерә-күчерә олы гына мәйдан ачып куйды. Ә Илдерхан белән Кәшби, кара-каршы әйтешеп, бик сәер җыр башлап җибәрделәр.

Әүвәл гармун суза-суза Кәшби тезеп китте:

Әйдә, Илдер, җебеп торма,
Тыпырдый төш, бии төш.

Илдер болайрак кушылды:

Биегәч пешә, каеш төшә.

Кәшби: Пешсә, төшсә, кыса төш.
Илдер: Кыса төшкәч, эч пешә.
Кәшби: Эчең пешкәч, тышка чык.
Илдер: Бераз торгач, син дә чык.

Ай күрде, кояш алды диярсең, болар шундук ишеккә ыргылдылар. Өйдәгеләрнең әле күбесе берни аңламый, кайберәүләр генә күз яшьләрен сөртә-сөртә хихылдап көлә иде. Өстәл очындагы кызларның зиһененә тизрәк барып җитте, күрәсең, алар Кәшби белән Илдерхан артыннан тышка атылдылар. Бераздан болар, чыр-чу килеп, ике егетне өстерәп тә кертте. Илдерханның җилән канаты бер якка аерылган, каеш астыннан җайлап тыккан ике кечерәк бәлеш читләре күренеп тора. Яшьләр үзләре бертуктаусыз, иелә-сыгыла көлә. Әлбәттә инде, башка кунаклар да аларга кушылып әллә никадәрле вакыт көлештеләр…

Менә шушы хикмәтне күңелендә кат-кат яңартып, Әмир юл буе үзалдына көлемсерәп кайтты. Әллә нинди сәер, гаҗәеп тырыш, үҗәт, яшәргә омтылучан бу безнең халык. Әле бер ел элек кенә бер сынык икмәк теләнеп, ачлыктан шешенеп йөргәнен, урам саен дистә-дистә корбан озатуларны ул оныткан да

инде. Әнә ул бүген бәлеш урлап шаяра, җырлый, бии. Әкияттәге тылсымлы кош шикелле, ул мең кат үлеп, мең кат көлдән ярала, һаман башкалар каршында ким-хур булмыйча баерак, мулрак тормыш алып барырга омтыла. Менә Төркәй кешеләрен генә барлап кара. Хәби хәзер Рөстәмбәкнеке шикелле чардаклы йорт төзергә хыялланып йөри, ди. Яңа нарат бура да кайтарып куйган икән. Халык телендә «Ибни» генә булып йөргән Түбәноч Ибниулла агай мәчет мәйданының бер читенә зур-зур кирпечләрдән таш келәт тергезгән. Элек ул Эстәрле, Бәләбәй базарларыннан ташыган гәлүш-итекләрне, керәчинне, ыңгырчак-камытларны өеннән генә сатып ята иде, хәзер яңа таш келәттә кибет ачмакчы, ди. Аларның күршесендәге Карун Мирсәяф тә тик ятмый, ахрысы. Аның хакында тирә-як авыллардан мал тиресе, үпкә-бавыр, эчәге, чәкән җыя да шуларны Уфа, Кушнарин, Иванай урысларына илтеп сата, диләр. Бер дә отышсыз эш түгелдер инде, Мирсәяф үзенең лапасына ике туры бия кайтарып куйган бит әнә. Шулай һәммә кеше ком түшәлгән ихатага чыгаргач та, тик торуны белмәгән тавык сыман, тырмаша, юньлерәк-иплерәк итеп көн күрергә тырыша. Әмирне дә ат-сукасыз батрак булып йөрү бик туйдырды. Аның да, Хәби сыман, Төркәй урамнарын сиртмәле тарантасларда җилдереп бер узасы килә. Мәгәр менә бу үз утарыннан ары дөньяны күрә белми торган Яшке-Җәкәү, тамак ялына эшләтүдән узып, бер тиен дә түләми бит аңа. Чабата олтырагы, итек олтаны булып йөрүләрдән туктап, ничек кенә кеше буласы соң?!

## 5

Раштуа бәйрәме җитәргә санаулы гына көннәр калган иде, көтмәгәндә Әмирне Яков чакырып алды. Әмирнең соңгы көннәрдә болытлы күк йөзедәй бик төксе кыяфәттә йөрүен чамалаган, ахры, сүзне кыска тотты.

— Без синен билән нинди хак суләштик, Амир? Бер ай алты таньгамы? Менә сина тугаль ике йуз таньга.

Яков өстәлгә aклы-каралы кәтүк җепләре белән бәйләнгән алты төргәк акча чыгарып салды. Әмирнең уклау йоткан кеше сыман күз акайтып утыруын күргәч, ниндидер кәгазь кисәген дә шапылдатып җәйде.

— Минә мунысы адрес. Зайцев Иван бу. Без Орехово-Зуевода Иван билян биргә Совет салдык. Казер минә Иван Томскида. Тиге елдан бирле. Минә письмо салган. Томскида атлар табун-табун, хакы арзан, әйткән. Давай син Томски кит. Ике якши ат давай син мина.

...Әмир авылга язгы кояш җылысыннан карлар челтәрләнә башлагач кына кайтып керде. Зифа абзар түбәсенә бәрәннәргә печән йолкырга дип менгән иде. Күчәрбай ягында-

гы сырт буйлап озын-озын арканнарга өч ат тагып кайтучы әтисен беренче ул күрде.

— Ин-нәй, ин-нә-кәй! — дип чырылдап кычкырды ул, итәгенә ут капкан сыман.— Әтәй ката! Әтәй баеп ката!

Өй эчендә бала имезеп утырган Гөлтуташ, нарасыен аннан-моннан төреп, Зифасын җитәкләп, капка төбенә чыгып каршылады. «Баеп кайтучы» Әмирнең йөзен сакал басып бетергән, ул зур арыш капчыгын, почмакларыннан бәйләп, аркасына аскан. Ике кулында да таза сүс арканнар. Уң ягында — йөгәнне бугаз астына китереп бәйләгән бау очында — гаҗәеп киң сыртлы, үзе биек, үзе озынча сынлы, керәчтәй ак тояклы, ак бәкәлле айгыр биеп килә. Сул кулында — бер бауга тармаклап бәйләгән ике яшь тай. Алары да үшән түгел бугай, бер-берсен алга үткәрмәскә маташып тешләшәләр.

Әмир әнә шул ике тай бәйләнгән бау очын Гөлтуташ кулына ыргытты да үзе айгырны ихата эченә кертеп, аркан очын лапасның имән капка баганасына бәйләп куйды. Арканны озынрак калдырган булган икән, айгыр икенче мизгелдә үк арткы аякларына күтәрелеп, лапас түбәсенә аркылы салган усак киртәне кимерә дә башлады.

— Атың ачыккан бит, печән бирик, әтәй,— дип, Зифа лапас янына таба элдертә башлагач кына, Әмир аны күтәреп кочагына алды.

— Якын бара күрмә, кызыкаем. Йә тибәр, йә тешләр үзеңне. Шайтан бу, валлаһи.

Әмир, Зифаны төшереп, юл капчыгын салды. Гөлтуташ белән сабыйга да чират килеп җитте. Әмир аларны да, ниһаять, кочагына кысты.

— Кем? — дип сорады ул, Гөлтуташның колагына гына пышылдап.

— Малай инде, малай. Исемен Тимерҗан дип куштырдым. Монысының гомере озын булсын.

— Тимерҗан, Тимерҗан! — дип шашынып дәште Әмир.— Кайгырма. Яшибез болай булгач, яшибез, хатынкаем!..

Яков Төркәй юлын әллә кайчаннан бирле күзәткәндер инде. Тугайлыкта өч ат җитәкләгән Әмирне күрүгә үк, ул гаиләсе белән җыелып юлга чыгып басты. Тегермән йортында төн кунарга тукталган өч-дүрт агай-эне дә баскыч өстенә тезелешкән иде.

Яков гаиләсе каршына килеп җиткәч, Әмир аркан очларын кулыннан ычкындырмыйча гына хисап тота башлады.

— Менә исән-сау көе әйләнеп кайттым, Яков дәдәй. Томскиның үзенә, Иван янына ук барып җиттем. Синең ике йөз тәңкәңә шушы өч ат тиде. Бер тиенеңне дә җилгә туздырмадым.

— Ну, ну, шыттырма син. Анюта шулай әйтә. Гульту-

таштан каракуль жакет, ике шаль урлагансын. Анюта такын сине пер яны итек, кытынынның кумеш танкаларын урлагансын, әйтә. Казер герой килана, кара. «Бер тин туздырмадым». Яков бар да билә. Син шыттырма. Анюта шулай әйтә.

Яков әлеге сүзләрнең барысын да читкә карап сөйли, бу минутларда аның күзләре гел айгырда иде. Урынында бер мизгел дә тик торуны белмәс гаярь айгыр аны тоташ сихерләде бугай. Ул өлкән улына юллаган әмерен дә аңа таба борылмыйча әйтте:

— Иван, кнутны бир. Озын кирякми, короткийны давай.

Иван йөгертеп кенә кыска чыбыркы китереп тоттыруга, Яков Әмир кулындагы бер арканны алды. Аны әүвәл озынайта төште, чыбыркысын бер шартлатып куйды. «Монысы нинди хөрәсән инде тагын?» дигән сыман башын иеп күзләрен алартты да айгыр бик вәкарь кыяфәттә читкә таба сикермәкче булды. Ләкин Яковның «Но-о, зар-ра-за!» дип кычкырып янә чыбыркысын шартлатуы булды, айгыр түгәрәк буенча арткы аякларын югары чөя-чөя юыртып та китте.

Оһ, мәһабәт иде, гүзәл иде айгыр кыяфәте! Ул башын да, койрыгын да югарыга чөйгән. Ялы камыш көлтәсе шикелле уйнап-тузгып бара. Борын тишекләре йодрык сыярдай булып киерелгән. Үзе тәвә кошы сыман сикереп-сикереп баса. Ул сикергән саен, күкрәгеннән док-док иткән тавыш ишетелә. Аннары ул әле, арткы аякларына күтәрелеп, башын чайкый-чайкый, усал итеп кешни. Әле арткы санын югарыга чөеп, әйтерсең лә бөтен дөньясына тибеп-тибеп ала. Ә Яков яңа бер түгәрәк саен аркан очын беләгенә, терсәгенә чорный, айгыр белән ике ара һаман кими бара.

Ниһаять, ара ике-өч адым чамасы гына калгач, айгыр шып туктады. Арткы аякларына күтәрелеп «кәҗәләнерлек» тә, вәкарь сикергәләп уйнарлык та җай калмаган иде шул инде аңа. «Ярар, син җиңдең, күңелең булдымы соң?» дигән кыяфәт белән, борын тишекләреннән поф-поф өреп, ул Яковка яны белән текәлеп карап торды. Яков шулчак, әллә каян гына тартып алып, айгырга бер шакмак шикәр каптырды. Ә аннары инде, бөтенләй янына ук килеп, айгырның муеныннан хуҗаларча итеп, шап-шоп сөйде.

— Исем ничек монын? — дип сорау ташлады ул Әмиргә, җилкә аша гына.

— Мин моны Себер татарыннан барып алдым. Ул аны колын чагыннан бирле Заһир дип йөрткән.

— Так не пойдет! — дип кычкырды Яков, кырт кистереп.— Бездә Захар якши.

Әмир-батрак берни эндәшмәде. Яков янә өлкән улы ягына күз ташлады.

— Иван, ал Захарны! Казер ана без хозяин була.

Шуннан соң гына Яков Әмир тарафына борылып басты. Әле аны, әле бер арканга тагылган ике тайны күз агыннан кат-кат кичереп чыкты.

— Синен малаен бар, мин так ишеттим,— диде ул бер дә көтмәгәндә.— Анын исем ничек?

Әмир тотлыга-тотлыга гына җавап бирде:

— Тимер... Тимерҗан.

Яковның йөзе, өстендәге көлен җил сирпеп төшергән утлы күмернеке сыман, кинәт яктырып китте.

— Ә-ә, Тимур, теге хромой ханмы? Тимурга ат тиеш. Мин сина буляк ясим. Кайсы якши, шуны сайла давай.

Әмирнең күзләренә яшь тамчылары бәреп чыккан иде. Ул сайлап-аралап та тормады, якындагы тайны барып кочаклады.

— Монын исем ничек? — дип сорады Яков бу юлы да.

— Афонька, Афоня,— диде Әмир ашыга-кабалана.

— Минә булай пойдет. Афоня исем якши.

## 6

Бу Афоня атлы малкай гаҗәп сәер холыклы булып чыкты. Сатып җибәргән урыс агасы аны монгол токымыннан дигән булган иде, юк, алдады бугай. Буйга-сынга Афоня, чыннан да, тай чагыннан әллә ни калыкмады. Ә эрелек инде!

Әмир аңа Яков биргән иске камыт-дирбияне кидерә башладымы, сыртына иң зәһәр кигәвеннәр болыты килеп ябырылган диярсең, бер урында тик кенә тора алмый, Афоня шундук быжгып уйнакларга тотына бит, әйкәй. Гөлтуташ белән Зифа капканы ача гына башлаулары була, Афоня урамга ыргылып та чыга. Капка такталары чытырдыймы, берәр тәгәрмәч күчәреннән чыгып ычкынамы, әллә бөтенләй хуҗасы ук үрәчәдән чәнчелеп төшкәнме — моның бер эше юк. Урам буйлап ул артына утта кыздырылган без тыккандай чаба. Ә авылның соңгы ихата турын узып тигез тугайлыкка чыктымы, һәр аягына берәр потлы гер ташы таккандай, йөрешләре шундук акрыная. «Бер аягын атлаганчы, икенчесен эт ашый», дип, нәкъ шушының ише үшәннәргә төбәп әйтәләрдер инде. Кешесез тугайлыкта ник чыбыркыламыйсың, ник бүре сыман улап кычкырмыйсың — Афоня сыңар колагын да селкетми бит, каһәр. Аның каравы авылга кайткан чакта тагын нәкъ киресе. Йөкне ник бура хәтле итеп төямисең моңа, мәгәр урамның очына килеп кердеме, ул янә ак-караны күрмичә котырынып чаба. Гөлтуташ белән Зифа капканы ачып өлгерсә өлгерә, өлгермәсә — юк, ә Афоня исә аны йә маңгае, йә тәртә башы белән сөзә дә барып керә.

— Нинди мангул парудысы булсын бу Афоня? Валлаһи, урысныкы бу, валлаһи, урысныкы! Алар гына шулай кәпрәя, куразлана белә,— дип, авылныкылар инде әллә ничә тапкыр үз мөһерен сукты. Көнләшүдән шулай сөйләгәннәре сизелеп тора инде. Ләкин Әмир ыжламый да моңа. Аллага шөкер, ихатадагы малга сүз әйтмәле түгел. Әллә нинди, үз көннәрен үзләре күрә торган булды һәммәсе дә.

Гөлтуташның кулы бигрәк җиңел бугай. Аңа «бирнә» булып килгән ике оя казны, чынлап баксаң, күрүче, белүче дә юк. Яз көне утыз-кырыклап бәбкәләрен ияртеп, бәрәңге бакчалары аша аккан ерганакларга утырып, Чәрмәсәнгә төшеп китәләр дә көз җиткәч, ни хикмәт, һәммәсе диярлек исән-сау көенчә, самавыр сыман түгәрәкләнеп, кайтып керә алар.

Әмир түшәктә яткан язда, тагын бер мәртәбә әтисе янына барып, Гөлтуташ Аблайдан алып кайткан өч баш куян да нәкъ шундыйлар. Әмирнең балта-чүкеч тотардай куәте булмагач, Гөлтуташ аларны, мич буеннан чыгып йөрердәй бер ара гына калдырып, идән астындагы базга салган иде. Зифа белән чиратлап, ихатада табылган кабак кисәкләрен, кишер, шалкан, бәрәңге кабыкларын, ялан-тугайлардан кыркып кайткан печән, көнбагыш, солы калдыкларын, борчак кузакларын идән астына ташлап ашаттылар инде. Куяннар идән астындагы ниргәлектә, җирне чокып, үзенә күрә һәркайсына аерым оя ясаган икән. Куяннар да хикмәт. Елына ике тапкыр — яз башында һәм җәй уртасында — мич янында калдырылган ярыктан күтәрелеп, болар хуҗалар алдында мактанырга чыга. Чыккан саен — егермеләп бала. Кыш җиткәч, шуларны суеп, Әмир хөкүмәткә ит салымы түли, Гөлтуташ аларның йонынннан бияләй, шәл, оекбашлар бәйли. Тире-сарыны Мирсәяф кырып-себереп алып китеп тора. Куян асрагач, сирәк-мирәк бәлеше дә өстәл өстенә кунак булып менә. Ул Мирсәяфләр, Гәрдән, Йосыф байлар, шул ук Яков белән дә терәшерлек, узышырлык чамалары юк инде анысы, ә шулай да барыбер җан асраган булып яталар бит әле.

Яков тегермененә халык көн дә агылып тормый. Язгы чәчү беткәч, кеше гел өзелде. «Ярар, узинин дунья кара»,— дип, Яков Әмиргә ял биргәндәй итте. Торна күле артындагы ерак бер басуга Әмир язын киндер чәчкән иде. Ял көннәренең берсендә иртә таңнан торып шул басуга баргач, Әмир үзенең күзләренә үзе ышанмады. Киндер билгә җитәрлек булып бердәм күтәрелгән, һәммә сабак зәңгәр төстәге шау чәчәккә баткан. Таҗлар өстенә кунган чык тамчылары иртәнге кояш нурында энҗе тезгән сыман ялтырыйлар.

Әмир хыял диңгезенә чумды. Көн кыздыра башлагач, киндер басуы өстенә шөпшә, төклетура, күбәләк, бал кортлары җыелырлар, туй итәрләр инде. Ә көзен, сабакларын урып

әвеннәргә куйгач, көлтәләрне сугып орлыгын аерырлар. Гөлтуташ шул орлыкларны төелгән бәрәңге боткасына кушар да матур-матур пәрәмәчләр пешерер. Киндер сабакларын юан киртәләр белән бастырыклап күл төбенә салырлар. Аннан алгач, кояшта киптерерләр дә, агач талкышларда талкый-талкый, сүсне сабакларыннан аерырлар. Сүсләрен көздән кар астына салып калдырырлар, язга алар ап-ак төскә кергән булыр. Шуны эрләрләр, кирәк тапкан төскә манарлар. Гөлтуташ агач станнарда шуннан киндер сугар, Әмирнең үзенә, Зифа кызына, төпчек Тимерҗанга күлмәк-ыштаннар, тастымаллар тегәр...

— Әм-мир-р-р, Әм-мир-р аб-бы-ый! — дип, сузып-сузып кычкырган аваз гына хыял болытлары өстеннән җиргә сөйрәп төшерде аны. Әйләнеп караса, авыл ягыннан бер җайдак җан-фәрманга ат чаптырып килә. Тезген очын уңлы-суллы болгап куалаган җайдак күрше малае Шәрифулла икән. Аты бер хәл, аннан бигрәк Шәрифулла үзе тирләп, гыжлап чыккан. Сүзләрен дә таш чәйнәгән сыман өзеп-өзеп тезә:

— Ыстарысты Йосыф бай җиб-бәрде мин-не син-нең арттан. Күч-чәрбайдан Дин-ни килгән анда. Ау-уыл шур-расыннан. Дин-ни әйтә, Әмирне тап, миң-ңа ул кирәк, ди. Миннә синең арттан махсус җибәрделәр.

— Тишекле бер тиен кебек, әй, йөриләр дә соң! Көннең җан кебек кадерле чагында бит. Әй, тапканнар вакыт! — дип кабынып сүгенде дә, барыбер, ничарадан бичара булып, атын кире борды.

Йосыф бай үзе махсус җибәргән бит, мах-су-ус! Юк-бар өчен дә бәйләнеп җелегеңә үтәр аннары, бармый гына кара. Хөкүмәткә тиеш икмәк йә итеңнең өч кенә кадагын вакытында тапшырмасаң да, җиде кат тиреңне салдырачак бит ул. Юк, староста белән санлашмыйча булмый. Аның белән ике арадагы тезгенне уяу тоту хәер.

Ә Дини кем инде ул? Элек гомер буе байлар абзарында ат караучы булып йөргән бер ач әрвах. Хак булса, аның хатыны инде әллә кайчан, бер узгынчы казакъ сәүдәгәренә ияреп, Җаек аръягына чыгып качкан. Аңа чын исеме белән, тутырып, «Динислам» дип эндәшүче кеше дә булмады бит. Каз бәбкәсе саклаучы малай-шалай өчен дә фәкать «Дини» генә һәм вәссәлам! Шушы ач әрвах нindidер юл белән большевиклар фиркасенә үтеп кергән дә Күчәрбайда авыл шурасы рәисе булып алган менә. Аның хакында «ике-өч ай буе кызыләрмис булып йөргән» дип тә, «Чапай янында ат караучы булган икән» дип тә сөйләделәр, дөреслеккә кайсы туры киләдер инде. Әмма шушы «кызыләрмис» хәзер бөтен тирә-як авылларны ду китерә бугай. Аның турында әллә нинди сүзләр ишетелгәләп торды:

— Дини унтугызынчы елны Усманда Хәләф байның келәт астындагы яшерен базыннан җиде йөз пот икмәк табып чыккан!

— Дини сәнәкчеләр фетнәсе вакытында Түреш авылыннан алты көпшә мылтык талап кайткан!..

Хуш, шура рәисләре нинди була икән? — барып күрик әле...

Әмир үрне менеп урамга кергән чакта, мәчет мәйданына ярты авыл җыелган иде инде. Челлә җәй уртасында да бүреген салмаган, кое сиртмәседәй озын буйлы бер ир мәчет коймасының ярыкларына тонык-кызыл чүпрәк элеп йөри. Анда ак буяу белән эреле-ваклы итеп тырмаланган язу: «Искелекне себереп түгәрбез!» Аста кечерәк хәрефле тагын бер юл: «Яшәсен ярлылар ширкате әгъзалары!»

Ниһаять, бүрекле ир халык тарафына борылды да, әтәч сыман әтәтерләнеп, арба үрәчәсе өстенә менеп кунаклады. Бу — әлеге дә баягы авызын ачса, үпкәсе күренә торган галах Дини икән.

— Лелин җитәкләгән бәлшәвикләр фиркасе безне ысталбауай юлдан алып бара. Безнең ысталбауай юл — камунизым һәм, тагы да килеп, бөтен дөнҗа буйлап мирауай эрвәлүтсә. Шундай эрвәлүтсә өчен тиктомалдан гына, кызыләрмис булып, акупларда сугышып йөрмәдек без. Без выласка мәңгелеккә килдек һәм, тагы да килеп, искелекне себереп түгәчәкбез. Лелин төзегән терти интернасал безгә шундый юл күрсәтте. Без, пырлитарьят...

Әмирнең сөмсере шундук коелып төште. Кичә ат тизәге җыеп йөргән томанадан нинди рәис чыксын? Юк, күңелгә ятышлы сыңар сүз дә әйтә алачак түгел бит бу Дини. Алтындай вакытын әрәм итеп, Әмир монда юкка гына килгән.

Янәшәдә тезелеп баскан башка ирләрне дә шушындый ук үкенү хисләре талый иде, күрәсең. Торна урамындагы Фатыйх төрттереп тә куйды:

— Пырлитарьят, пырлитарьят. Пырт ит тә ят, терт ит тә ят. Моның эше ансат.

Тыелып кына көпләр көлештеләр. Әмма тагын бер ир сүгенми түзмәде:

— Балак бете башка менсә, әтәч булып кычкыра, ди. Башына бүрек кигән өчен генә ир-ат булып чутлана бит шушы сөрхәнтәй дә...

Дининең алдагы сүзләрен ишеткәч, Әмир колакларын торгызарак төште.

— ...Бәләбәйгә кантун ләчәнниге булып хәзер Шаһи-Морат камисар кайтып төште. Сез беләсез аны, ул эрвәлүтсә елларында сезнең авылдагы ярлыларны җирле-сулы итеп киткән кеше. Менә шул камисар хәзер бөтен кантун буйлап

ярлылар ширкате эшен яңартуны бездән таләп итә. Илгә икмәк кирәк һәм, тагы да килеп, илнең яраларын төзәтергә кирәк. Безгә шулай диләр. Ә бөтен дөнҗа күләмендәге мирауай эрвәлүтсә дошманнары Лелин хөкүмәтенә налукны аз түлиләр, алар ярты икмәкләрен итәк астына яшереп калдыралар да базарларда сатып мал җыялар. Күчәрбайда да бар андый сөлек-ырвачлар, сездә дә бар. Менә шул ырвачларны мир каршына сөйрәп чыгарырга һәм, тагы да килеп, яшереп саткан малларына сак куярга кирәк...

— Һе, авылны астан чагып ятучы елан эзли икән бит бу Дини, япәтникләр эзли,— дип ысылдады тирә-юньдә берьюлы өчме-дүртме тавыш.

Менә шул чагында гына, ниһаять, Әмирнең исемен телгә алды Дини.

— ...Без беләбез, сезнең авылда кеше утарында батрак булып йөргән пырлитарлар бүген дә бар. Заманында Шаһи-Морат камисар белән бергә сезгә җир бүлеп биргән кызыләрмис Нәгыймов Әмир бүген бөтен тирә-җак пырлитарьятының канын кандала сымак эчеп яткан Яшкегә бил бөгә. Аның тегермәндә ясепкәче булып йөрүе начар түгел анысы түгелен. Барсын күрә, барсын белеп тора. Безнең шура менә шушы батрак Нәгыймов Әмирне сезнең авылдагы ярлылар ширкате булсын дигән тәкъдим кертә бүген. Моңа сезнең арада каршы кешеләр юкмы? Без һәммәсен дә исәпкә алачакбыз.

Бөтен мәйдан җиңел сулап куйды. Арадан кемдер барыбер усал кычкырып дәште:

— Әмир япәтник булсын, аңа диңгез күптән тубыктан. Ул андыйга бик чос...

Берочтан Әмирне Күчәрбай шурасына да әгъза итеп сайлап куйдылар. Кызыл чүпрәкләрен җыеп култык астына кыстырган Дини арба үрәчәсенә утырган килеш кенә күрсәтмәләр бирде:

— Шурада ике-өч көн саен җыелышлар була, килми калма. Син хәзер Төркәйдәге безнең төп таяныч. Кем кайсы кырда күпме орлык чәчә, күпме уңыш җыя — һәммәсенә күзколак бул. Хафаланма, ялгыз калдырмабыз...

Дини хәрәмләште. Әмир авылда берьялгызы калды.

## 7

Печән өсте җиткән бер көндә Яков эндәште дә Әмирне янә тегермәндәге эшеннән аерып алды.

— Иртәгә пичань тушәбез, Амир. Син тоже, давай, безгә пичань чабу йыйын. Казер Захар бар бит. Тагин бер бозауны кыш калдырмак булам. Пичань бик куп киряк. Без

шулай халь иттек. Сина Туркай белән рядом чабу якши тугел. Шуна Иван белән Николай Табор куль ян бара. Мин Василий белән Торна куль ян китәм. Ә син Чармасань аша тиге яр чигарсын. Анда улән якши, ул пичаньны кыш калдырсак була. Тигермәндә эш аз булса, Нина да синен ян чигар.

Бер уйласаң, Яковнықылар начар хәл итмәгән иде. Авылдашлары белән янәшә бастырып, һәр тезмә өчен әрепләшүякалашудан азат итүләре Әмир өчен аеруча кулай. Ләкин нишләп, печән чабуның бер рәтен дә белмәгән япь-яшь кызны ярдәмгә билгеләп, Әмирне мыскыл итә соң әле болар? Читтә зимагурлыкта йөргән дип көлсәләр дә, туа-тумыштан бирле крәстиян эшендә катнашып чыныккан авыл ире лә ул! Ярар соң, Нина белән чабар дип хәл иткәннәр икән, димәк, Нина белән. Әле Анюта түтәңне «буксирга» билгеләмәгәннәр икән, шунысына да сөен...

Икенче таңда Чәрмәсән аръягындагы бер күл тирәли җәелгән тугайлыкка аяк басуга ук, Әмир табигатькә карап гел шаккатып торды. Ходай Тәгаләнең шушылай юмартланып сипкән җәннәт бакчалары да булса була икән! Тугайлыкта кайчы белән кыркып, тарак аша тарап үстергәндәй тигез, хәтфә үлән. Чигүле түбәтәй яисә сәйлән шикелле сибелеп-сибелеп киткән акбаш, казаяк, күкчәчәк, тукранбаш түтәлләре. Күл тирәли зифа камышлыклар. Күлнең ике башында аклы-сарылы матур төнбоеклар. Яр буенда аз-азлап, әйтерсең лә кадерләрен белеп кенә үскән шомырт, зелпе, юкә агачлары, яшел әрәмәлек. Яр читендәге камышлык һәм таллар арасында, мөгаен, кыр үрдәкләре дә йөзеп йөридер әле. И матур да, бай да соң бу туган як табигате! Эш-эш дигән булып, юк-бар мал артыннан чабулап йөргәнгә генә күрми икән бит мондый гаҗәеп матур дөньяны адәм балалары!..

Кояш Дәүләкән ягындагы тау өстеннән бер дилбегә буе күтәрелгән чакта, Әмир, күлне тирәләп йөреп, кыяк үләнне өч теземгә егып чыккан иде инде. Крәстиян эшеннән байтак еллар буе аерылып тору үзенекен итте, күрәсең, өченче әйләнәне урап бетергән чакта, Әмир гыжлап чыкты, шабыр тиргә батты. Яңа теземгә керешкәнче, ул өстендәге юка киндер күлмәген салып атты, кулына беләү алып чалгысын җиренә җиткереп янамакчы булды. Шул чагында Чәрмәсән буендагы үр өстеннән күлгә таба төшеп килгән Нинаны шәйләде дә, иңбашы аша үрелеп, аңа текәлгән көе агач сын шикелле тын калды ул.

Үләннәрне, чәчәк түтәлләрен аралап, яшь кыз төшеп килә. Өстендә зәңгәр төстәге борчаклар тезелгән ап-ак кофта, тәненә сыланып торган яшел сатин итәк. Гәрәбәдәй саргылт толымнарының берсен иңбашыннан төшереп күкрәгенә сал-

ган. Зифа гәүдәле кыз аяк атлаган саен, калын толым тыгыз күкрәкләрнең берсеннән икенчесе өстенә күчеп-күчеп уйный. Куе керфекләр арасыннан төбәлгән фирәзә зәңгәр күзләр, чия төсендәге мул иреннәр кояш нурларында асылташлар кебек җемелдиләр. Кызыкайның ике алсу кулы аккошларның пар канаты кебек. Гомумән, бу яшь кызның атлап килеше дә дәрья дулкыннарында йөзгән гүзәл аккош сыман...

— Алла ярдәм бирсен, Әмир абый! Боларны кая куйыйм? — дип, Нинаның көмеш кыңгырау чыңлагандай тавыш белән эндәшүе генә Әмирне сихри томан эченнән асыл җиһанга кайтаргандай булды. Нина кулларындагы тырысны һәм ашъяулыкка төрелгән ниндидер савытларны аңа сузган икән. Әмир шуларны кулына эләктерде дә әүвәл ни кылырга белми аптырап торды. Аннары гына, ниһаять, исенә килде бугай, төенчекләрне уйсурак җиргә тезеп, өсләренә үлән каплап куйды.

— Тегермән буп-буш. Бөтен кеше печән чабуда бит. Кем килсен инде хәзер?

Нина үзалдына сөйләшкән шикелле шул рәвешчә тезеп киткәч кенә, Әмир игътибар итте. Элек өстәл артына сирәкмирәк кенә бергә утырудан ары күрешкәннәре юк иде, бу кызый ят телне әнә никадәрле камил белә икән. Хәер, бишектә чагында ук ике тел ишетсәң, алар икесе дә бертигездер инде. Шаһи-Морат комиссар юкка гына «Ленин инглиз, немец телләрен дә белә, аны әти-әнисе сабый чактан шулай тәрбияләгән» дип сөйли идемени?

— Миңа чалгы кая, Әмир абый? Мин кай якка басыйм?

Нинаның суга сусаган җәйге челләдәй талымлы карашын күтәрә алмады Әмир, әрәмәлекләргә таба кул изәде.

— Арбаның тимер хутлысы бар, агач күчәрлесе бар. Син минем белән бер хуттан чабалмассың, Нина. Давай, син әнә теге шомырт төбеннән ал да менә бу якка төш. Мин шушыннан сиңа чапырыш чабам. Ходай кушса, кичкә чаклы күлнең бу ягын бетермәбезме әле...

Җиләк кебек өлгереп җиткән яшь кыз белән бер болында икең генә эшләү читен икән шул ул. Әмир биш-алты адым да атлап үтә алмый, Нина ягына таба күтәрелә дә карый, күтәрелә дә карый. Инде кайвакытта үзен мәҗбүр итеп булса да җиргә төбәлеп эшли. Ләкин алай да котылу мөмкин түгел. Үзенә гел караш салмасаң да, кояшның бу минутта күк йөзенең кайсы тирәсендәрәк икәнлеген чамалап булган сыман, мондый яшь чибәркәй синең күз алдыңнан бер мизгелгә дә китми тора икән.

Капма-каршы төшеп чаба башласаң, бигрәк кыен. Тәнгә сыланган итәк теземне киң алып чабарга комачаулый, ахры. Нина алгы яктан итәк уртасын бил буена бөрештереп куй-

ган. Кызның таза алсу ботлары ялык-йолык килә. Әмир шулардан тәки күз алалмый, җитмәсә, әллә нинди кәс-түмгәкләр табып, чалгысы да төртелеп җәфалый бит тагын!..

Кояш тәмам баш түбәсенә менеп җитте бугай, беренче булып Нина чалгысын тезем өстенә атты.

— Шабаш, Әмир абый, әбәт ялына туктыйк. Син тимер хутлы дип аяк сузып булмас.

Үзе янә көмеш кыңгыраунныкыдай тавыш белән көлеп җибәрде. Әмир инде үзе дә өзлегеп чыккан иде, кабат әйттереп тормый ризалашты. Анда-санда калган төенчекләрне шомырт күләгәсенә ташыдылар. Әмир хәтфә үлән өстенә тезләнеп инде икмәк кисәргә әзерләнгән иде, Нинаның тәкъдимен ишеткәч, зәһәр чыбыркы очы эләккән шикелле сискәнеп үк китте.

— Юынам дисәң, күлнең әнә теге очы сиңа, Әмир абый. Ә мин икенче якта коенып чыгам әле...

Күл буенда үскән әрәмәлек арасыннан берни шәйли алмаслык чытырманлык түгел иде, билгеле. Үзен күпме генә мәҗбүриләп-көчләп карамасын, йөзен кояштан һич аермас көнбагыш төсле, Әмир дә кызны яшеренеп кенә күзәтүдән барыбер тыела алмады. Күрше хатыннарның мунчада юынуын тәрәзә почмагыннан тәүге тапкыр кача-поса гына күзәтүче әрсез малайлар шикелле, ул да Нина киткән якка керфекләрен кысып төбәлде дә, гөнаһсыз, керсез кызның сихри тәне белән иләсләнеп, утлы күмер капкан сыман тын алалмый торды.

Менә Нина кыю-җитез хәрәкәтләр белән зәңгәр борчаклы кофтасын салып атты, яшел итәге җиргә шуып төште. Ул инде кыска эчке күлмәген дә биленә тикле күтәреп куйган иде, соңгы мизгелдә генә бүтән төрле уйга килде бугай. Бармак очларын күлмәк итәгеннән аерды да, болан сыман сикереп, күл төбенә чумды.

Әмир яндагы тезем өстенә чалкан сузылып ятты. Хәтфә үлән йомшак, күл яны тын, тән саулыгын тоеп яту чиксез рәхәт иде. Әмир шушы илаһи ләззәткә бирелеп күзләрен үк йомды.

Күкрәгенә салкын су тамчылары таму сискәндерде аны. Күзләрен ачты да су анасын күргән кеше сыман кымшаналмый ятты. Аксыл толымнарын иңбашына салган Нина аның янына килеп тезләнгән. Тәненә сыланган затлы күлмәк аша таза алсу ботлар, тыгыз, мул күкрәкләр, алар очындагы ике кызгылт чия үтәли күренеп тора. Нина ике кулын алга сузган да бармак очлары белән сак кына кагылып Әмир тәнендәге җөй эзләрен барлый. Әллә җиһан туктап калды инде, Нина тик бераздан гына сорау бирде бугай:

— Нинди яралар бу синдә, Әмир абый?

Бер-берсенә ябышкан иреннәр арасыннан сытылып чыккан җавап чак-чак ишетелде:

— Кайсы — сугыш, кайсы тиф эзләре, Нина.

Җавап кызгандыргыч булып тоелды, күрәсең. Көтмәгәндә Нина түбән иелде дә алсу, йомшак иреннәре белән бик сак, назлы итеп кенә тирән яра эзләрен үбә башлады. Бераздан йомшак, назлы үбүләр күкрәктән муенга, аннары яңакларга, күзләргә, иреннәргә күчте. Тик колакка гына ишетелгән кайнар сүзләр Әмирнең бөтен җанын-күкрәген айкап, көйдереп чыкты.

— Мин яратам сине, Әмир абый. Безгә эшкә килгәннән бирле, үткән җәйдән бирле. Мин бер ел буе көттем шушы көнне. Гомер буе көттем. Ходайдан гел сине ялынып йөрдем. Менә кавыштырды. Син минеке бүген, тик минеке. Мин сине бүген беркемгә дә бирмим...

Гөнаһсыз Нинаның күзләреннән кайнар яшьләр тама, аларның һәр тамчысы утлы күмер сыман көйдерә иде. Нарасыен күкрәгеннән аерган назлы ана кебек, Әмир ипләп кенә Нинаның көзге чия яфрагы кебек кызарган йөзенә кагылып куйды.

Нина күк йөзендәге ялгыз айныкыдай моңсу караш белән төбәлеп торды аңа. Күзләре гүя дымга сусаган чәчәк таҗы иде. Әмир аларны назлап үбеп алды да үзара пышылдашкан көзге агач яфракларыдай йомшак итеп дәште:

— Нина, Нинакаем, чибәрем, сылуым син. Акылыңа кил, җаным. Мин — ике бала атасы, сиңа унсигез дә юк бит. Синең әле гомер итәсең бар. Килер сиңа бәхет, килми калмас. Син чибәр, син гүзәл бит, җаным. Гафу кыл син мине. Мин үзем ашаган табакка үзем төкерә алмыйм...

Нина карлыгандай тулы күзләре белән озак карап торды. Кайнар сулыш өркегән ачык изүләрен, күкрәк очларындагы чияләрен дә каплап маташмады. Ул агач сын шикелле хәрәкәтсез-нисез текәлде дә торды. Бераздан зәңгәр күзләрендә балкыган очкын сүнде аның, карашы да бик күп су сибелгән мунча ташы сыман салкынаеп калды. Берзаманны, ниһаять, айныды ул. Томан артында янган учак сыман тоник күзләре белән Әмир тарафына соңгы тапкыр караш ташлап алды. Аннары итәге белән кофтасын кулына эләктерде дә, ярты гына сүз дә әйтми-нитми, биек үр өстенә йөгереп менеп китте.

Күк йөзеннән кояш качкан иде.

## 8

Әмир дөньяда Дини шурачы барлыгын гел оныткан иде, янә уттай кызу эш өстендә ат менгән йомышчы җибәреп чакыртты бит теге.

— Габидулла камунисны үтереп ташлаганнар. Маминт килеп җитсен...

Кырлардагы ашлык урылып эскертләргә куелган, Яков тегермәненә халыкның болыт сыман убылып килгән чагы иде. Яковтан әҗәт теләнгән шикелле кыюсыз гына сорап юлга чыкты Әмир. Мәет озату борынгыдан килгән саваплы эш, ни хәл итәсең бит.

Белә, күптән белә иде Әмир бу Габитны. Бастырыктай озын буеннан бигрәк Габитов Габидулла атлы булган өчендер инде халык аны гел «Ике катлы Габит» дип кенә йөртте. Әмир ялгышмаса, әнисе белән икесе генә Бәдрәш елгасы буенда, җиргә яртылаш сеңгән йортта яшәде ул. Советка кадәр Габитның шылт иткән тавышы-тыны да ишетелми иде, инкыйлаб елларында да әллә ничә ай буена юкка чыгып йөргән. Кайтып керсә, күчәрбайлыларның күзләре шакмак булган, диләр. Габит большевиклар фиркасенә кереп кенә калмаган, өстәвенә, үзе белән ияртеп, марҗа килен алып кайткан икән!

— Габит дөньяны җайлы көйләде ул. Марҗасы белән лыкынганчы эчеп алалар да, урамга чыгып, чәтә-бәтә килеп сугышалар,— дип сөйли иде Яков тегермәненә килгән күчәрбайлы ирләр.

Берзаманны әле шушы Габитны, урысча шәп сукалый дип, Дини урынына да куярга йөргәннәр, ди. Бичарага шул «кара сакалы» — марҗа белән хикмәтләре генә киртә булган икән. Шундый кеше китеп барган менә...

Әмир ике авыл арасына яткан сырт өстеннән үк чамалап төшә башлады: күчәрбайныкылар Ишмай Харисы имам-хатыйблык иткән Кызыл мәчет каршындагы мәйданга җыелышкан. Халык бик күп түгел. Күбесенчә чабаталы, кылка киемлеләр. Арада берән-сәрән хәрби шинель кигән ирләр күренгәли. Башларына кызыл яулык бәйләгән япь-яшь кызлар да бар. Элек Сәгыйт байныкы булып торган ике катлы йорт каршына Әмир өчен әле Төркәйдән үк таныш булган ике-өч кызыл чүпрәк тарттырып куйганнар. Калкурак җирдә ат арбасы тора. Анда — шинельгә төреп салынган Габит мәрхүм. Каяндыр китереп куелган таш өстенә басып, әлбәттә инде, Дини йодрык селки.

— ...Ата камунис Габитов Габидулла безнең бәлшәвикләр фиркасе линиясенә бар йөрәге белән бирелгән әрмис иде. Сәвит выласының дошманнары гына башына җитте аның, шулар башына җитте. Әмма ләкин безне, әктиф шурачыларны, сыйнфый дошманнарның андый кабахәтлеге генә һич өркетә алмас. Бер Габит әрмис урынына биш камунис белән җавап бирербез без...

Әмир тирә-якка күз йөгертеп чыкты. Кемнәр генә җыелмаган монда! Чүпрәк Нәби, Кысыр Гаташ, Төнлекче Рауза, тагын әллә кемнәр. Нәби дигәне элек саилче сыман, йорт

борынча йөреп, иске чүпрәк җыя, шулардан хатыны теккән-суккан идән, сәке, сандык япмаларын сатып кына җан асраган булып исәпләнә иде. Гаташы да, Нәбиулла кебек, «Гатаулла» дигән тулы исемен мәңге ишетмәде. Анысы көтү-көтү ат тоткан байлар кымызын сатып көн күрде. Раузасының ире герман сугышында ятып калган. Хактырмы, юкмы, аның турында «байлар аны мунча төнлекчесе итеп тота икән» дигән гайбәт йөри иде. Бәрәкалла, Күчәрбайның «әктиф шурачылары» хәзер шулармыни?..

Ике катлы Габит җеназасын зират эченә куймый, читкә — текәрәк бер тау итәгенә җирләделәр. «Камунислар искелеккә сыймый»,— диде кемдер, мыштым гына көлеп. Дини исә монда тагын бер мәртәбә нотык тотып алды, әлеге дә баягы «ата камунисның башына җиткән дошманнарны» сүкте. Тау итәгеннән аска төшә башлагач кына, янә арадан кайсыдыр үз-үзе белән сөйләшкәндәй яман сүгенеп алды:

— Дошман, пычак. Теге исерек марҗасы сәнәк белән кадап үтергән бит аны...

Менә сиңа мә, коммунист шурачыны исерек хатыны суйса, ул да сыйнфый дошман була икән!..

Кабат Бәдрәш елгасы буендагы шура йорты янына кайтып җиткәч, Әмир инде Төркәй юлына таба кыйракларга ниятләгән иде дә, Дини рәиснең әмере шып туктатты.

— Син нәрсә кияү кулы күрмичә картайган сазаган кыз сымак читкә таярга гына торасың, Нәгыймов Әмир иптәш? Син хәзер безнең шур-ра әгъзасы һәм, тагы да килеп, сәвит выласы каршында Төркәйнең бөтен ярлы пырлитары өчен җаваплы бит. Үзебезнең шур-рага керәбез хәзер, җитди сүз бар. Син хәзер безнең арбада. Аерым йөрү бетте. Безнең җырны җырла, иптәшкәем. Ырраз шур-ра әгъзасы булып күтәрелгәнсең икән, давай, безнең йөзгә кызыллык китермә инде син. Бездә бит тәртип әрмиядәге кебек. Ничек әле? Ие, дисиплина. Син, давай, безнең дисиплина линиясен бозма...

Өч фәкыйрь мунчасын сыйдырырдай олы залга кергәч, Дини, әлбәттә инде, өстәлнең иң түренә үк барып утырды. Печән чабып кайткан диярсең, изүләрен ачып җибәрде, маңгаен һәм муенын сөрткән сыман итте. Әмир: «Бу тагын суган әкияте сата инде хәзер»,— дип уйлап бетерергә дә өлгермәде, Дини үз янында утырган нindидер таныш түгел иргә таба иелеп, ни турындадыр пышылдашып алды. Әмир шул чагында гына ныклап игътибар итте. Бу ир күн курткадан, бил каешының артында алтатар савыты да кабарып тора икән.

— Хәл итәсе мәсьәләләр җитди,— дип башлады Дини.— Менәтерәк безгә Уфадан кайтышлый гына Бәләбәй канту-

ындагы чекисләр кәмититеннән камунис Әбуяров Хәким иптәш кергән. Бу җаңа иканумик палитика линиясе башлангач, элекке байлар белән ырвачлар үзләрен бик иркен тота башлаганнар, ди. Ну, менәтерәк теге ни, камыт белән чөелдерек бавын бушаткан ат кебек. Ие, сәвит дошманнары әктифлаша, Уфадагы хәлләр бик кискен, ди. Менәтерәк сүзне камунис чекис Әбуяров иптәшнең үзенә бирик әле.

Бу Әбуяров дигәннәре пулеметтан аткан сыман бик тә кызу сөйли, җитмәсә, йә каешын, йә алтатар савытын бертуктаусыз төзәткәләп кенә тора икән. Әмир ул сөйләгәннәрнең тик беразын гына хәтеренә сеңдерергә өлгерә алды.

— ...Уфа каласында нэпман активлаша. Калада бүген тугыз меңгә якын йорт исәпләнсә, ие, ызначит тәк, шуларның төрле почмагында, подвалында-ниендә эреле-ваклы бер мең дә ике йөз кибет эшли. Мәгәр шуларның егерме бише генә Советныкы, калганына нэпман, буржуй хуҗа... Ситсы ише чүпрәк сатуны Галикәевләр белән Миңнебаевлар үз кулында тота. Ит кибетләренә — Нагельләр, кирпеч заводына Гутманнар хуҗа. Шырпы фабрикасы, пилорамнар Рыгалов белән Долгушев дигән байлар кулында хәзер. Ә күн заводларына Панаев белән Исхаков дигән нэпманнар менеп атланды... Без боларның һәммәсен дә күз уңына алдык. Чөнки боларның күбесе кибеттә дә, фабрикта да булган малны астан, яшереп кенә сата. Алар хөкүмәткә тиешле налукны түләмиләр. Алар, шулай итеп, Совет властен егып төшермәкче, капитал дигән кара чорны кире кайтармакчы, ие, ызначит тәк... Мәгәр нык ялгыша булыр ул нэпманбуржуй. Юк, власть дигән йөгән безнең кулда хәзер һәм дә ки, ул нэпман-буржуйларның утлы табада биисе көннәре алда, алда әле...

Әмир Төркәйгә төбәп юлга чыккан чакта, төн уртасы җиткән иде инде. Ул һаман да гел чекист Әбуяров сөйләгән сүзләр тәэсирендә атлап кайтты. Һе-һе, Яков тегермәнендә бикләнеп ятканга күрә генә берни белми, сукыр, томана икән бит ул. Әбуяров кына күзен ачты. Бер Уфада гына да бер мең ике йөз кибет ачылган, ди. Әле тагын Бәләбәендә, Бөресендә, Чакмагыш, Эстәрле, Бүздәгендә күпме? Кибетләреннән тыш пилорам, май, күн, җитен, ситсы мастерскойлары, фабрикалар ачучылар күпме? Саный китсәң, шушы якын-тирәне генә дә ун меңләгән нэпман сырып алган икән бит. Әле үзләренең кеп-кечкенә Төркәендәге Мирсәяфләр, Ибни, Гәрдәннәр кибетләр ачсын, сәүдә корсын, канат ярсын да, башкасына ни сан? Ә, Әмир? Дүрт елга якын гомер буена әле Колчак белән Дутовка, әле Бохара әмире белән басмачыларга каршы көрәшеп, кан коеп йөргән кызыләрмис Нәгыймов Әмир ни кырды да нәрсәгә иреште соң? Колчаклылар белән сәнәкче-

ләр килгән чакта, «Әпипә» биеп йөргән Гәрдән кулак бөтен Төркәеңә төкереп бирә, ул бүген дә бай. Ә дүрт ел буе окопларда борча симерткән кызыләрмис Әмир һаман шыр хәерче, һаман батрак. Ләкин ничек кенә итеп, ничек кенә итеп кеше буласы соң? Нинди юллар белән Гәрдән кулакларның, Рөстәмбәк, Йосыфларның борынына чиертә алырдай ияр өстенә менеп атланасы? Гап-гади, шыр хәерче Нәгыймов Әмирне бәхет тауларына алып менә алырдай канатлы аргамак дигәннәрен ничекләр генә һәм каян табарга соң?..

Икенче көнне үзе дә тоймас-аңламастан Әмир шушы хакта Яковка сүз кузгатты. Яков аның уй-хәсрәтен инде күптән тоеп йөргән бугай, сүзләрен керешсез-нисез генә башласа да, ул аларны кабадан тартып җеп эрләгән шикелле иплəп кенә, үлчәп кенә тезде:

— Кеше ике яктан бәхет була, Амир. Или байлык, или власть. Син мина ачуланма. Синнән байлык булмый. Синдә Рустамбек, Гардан кебек жилка юк. Син гади трудяга, син рвач тукел. Значит, син икенче юл бар. Ансы власть... Бу большевиклар без биш елда забастовка, стачка йурган шалапайлар тукел. Болар буре кебек, все умырып ала. Большевиклар властька бик озакка килде... Син шулар ян бар, шулар рядом атла. Однако бел: если алар йырын йырламасан или строй барганда хата бассан, алар сине чигара да ата. Как суяк, как ите ашалган суяк... Большевиклар көтуэндә как кыр казы, как аккош булу ярамый. Большевиклар көтуэндә как буре бер булырга, бер таларга киряк. Только так син ярыйсын, только так алар сине яклый.

Бик озак дәшми торганнан соң, Яков янә өстәп куйды:

— Син әле яш, Амир. Как алаша бабай ябылып яшау грех. Сина узиннан сун эз калдыру киряк... Большевиклар янга бар. Алар казан асты, анда сина да ит море. Большевиклар сина файда куп. Алар — сина, син аларга киряк. Йоклау грех, алар ер ерла...

## ӨЧЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Егерме дүртенче елның апрелендә Әмир коммунистлар партиясенә кереп кайтты. Гәрчә үзе әле фиркале булырга җаны-тәне белән атлыгып та тормый, моңа әзер түгел һәм мондый эшнең рәтен-тәртибен дә юньле-башлы белми иде. Читтән бәя бирсәң, барысы да бик гади һәм күз ачып йомгандай бик тиз килеп чыкты.

— Кантунда ярлылар кәмититләренең җәмгысын да ча-

кырган кәнфиренсе була, ә син безнең әктиф,— дип, аны Дини рәис үзе белән Бәләбәйгә алып чыгып китте.

Дини үзенең шурачыларын калага шактый иртә алып килгән икән, «кәнфиренсе» булачак элеккеге Зотов дворян йортының баскычына тезелеп байтак вакыт буе кәккүк баласыдай каңгырып утырдылар. Менә шул чагында бөтенләй дә көтелмәгән кайнар бер очрашу Әмирнең язмышын үзгәртте дә куйды.

Бервакытны Зотов йорты каршына сиртмәле тарантаска утырган күн курткалы кунак килеп төшкәч, таш коймалы иркен ихата диварлары буйлап тезелешкән йөзгә якын делегатның һәммәсе дә урыннарыннан сикерешеп торды.

— Кантун ләчәнниге үзе бит бу. Шаһи-Морат килде, Шаһи-Морат! — дигән пышылдашу һәр төркемне өермә шикелле дәррәү урап узды.

Азия сәхрәләрендә басмачыларны кыйнап йөргән комиссарның төсе-кыяфәте айлар-еллар узса да үзгәрмәгән икән. Шул ук күн тужурка, күн итек, гәлифе чалбар, киң күн каеш. Керпе энәләре сыман тырпаеп торган кып-кыска чәч, борын астында гына калдырылган шакмаклы чал мыек. Барысы да нәкъ элекке шикелле, ләкин... Ләкин кичәге комиссарның сул кул урыны бөтенләй буш, күн тужурканың бер җиңе каеш астына кыстырылган.

Шаһи-Морат Әмирне ерактан, әле ике-өч кеше белән күрешүгә үк аерып, танып алды. Таныды да, ана корт куены астына ашкынган бала кортлар сыман үз тирәсенә җыелышкан башка байтак ирне куе камышлыкны ерып барган очлы каек сыман аралап, кичәге полкташы янына йөгереп килде.

— Әмир! Брамат! Җаныкаем минем!

Шаһи-Морат әүвәл сыңар кулы белән аны кочагына алды, икеме-өчме мәртәбә җилкәсенә шап-шоп китереп суккан сыман итте, аннары йөзен Әмирнең муенына төртте дә кайнар учак өстеннән алынган казан кебек тынып хәрәкәтсез калды. Ул йөзен Әмир җилкәсеннән аерган чакта, ике яңагы да яшьле, юеш иде.

— Үзем белән бергә утны-суны кичкән җан дустымны таптым,— дип телгә килде ул, үзләрен тирәләп баскан авыл ирләре алдында күз яшьләре өчен аклангандай талгын тавыш белән.— Мине Чал-Курган янындагы бер яуда үлемнән коткарып калган кеше менә шушы инде. Шушы Нәгыймов килеп җитешмәсә, беткән идем инде мин анда, әйе, беткән идем. Зиядулла дигән бер паша минем менә шушы кулга китереп чапты, ә аннары инде башны кыярга дип тә кылыч күтәргән иде. Шул чагында менә Әмир килеп чыкты да Зиядулланың муенына сызып җибәрде. Ә аннан соң инде берни хәтерләмим. Мине Акбалыктагы госпитальгә дә шу-

шы Әмир якташым илтеп биргән, диделәр. Аннары Әмир үзе яраланган. Аны Самара ягына алып киткәннәр, мин Ташкентта яттым. Шуннан бирле күрешкән юк безнең...

Зотов дворян йортының фикус гөлле аулак бер бүлмәсенә кереп хәл-әхвәл белешкәч, Шәһи-Морат, кадак түбәсенә сугарга күтәрелгән чүкеч сыман сыңар кулын Әмирнең маңгаена төбәп, кискен сорап куйды:

— Мин сине безнең фиркадәдер дип беләм?

Әмирнең үз гомерендә беренче мәртәбә аю кәмитен күзәткән сакаллы карт кебек авыз ачып утыруын күргәч, Шәһи-Моратның күзләре дә маңгаена менгән сыман булды.

— Ә-ә? Ничек? Әле син шушы көнгә чаклы партия сафына да кермәдеңмени, әзи? Наданлык бит, брамат, гарьлек, гарьлек!

Шәһи-Морат сыңар кулы белән ике-өч мәртәбә тезенә сугып алды, умырып төшерердәй кискен хәрәкәтләр белән гимнастеркасының өске ике сәдәбен ычкындырып куйды. Шуннан соң да тынычлана алмады әле ул, башын чайкый-чайкый, үрмәкүч пәрәвез ятьмәсе үргән шикелле тиз-тиз тезеп китте:

— Син ничәмә-ничә ел буена фронтларда сугышып, ничәмә-ничә кала-бистәләрдә Совет власте урнаштырып йөрдең. Немец коммунисты Карл Либкнехт исемендәге, Троцкийның үз кулыннан Кызыл байрак алган революцион полк сугышчысы бит син! Инде син дә аның сафында тормагач, Ленин партиясе социализм төзү өчен бу көрәштә кемгә генә таянып эш итсен соң? Юк, бер тәртәгә дә сыймый бу синең болай күләгәдә ятып черүең. Ярамый болай, әзи, һич ярамый! Синең урының алда, әле дә булса революцион көрәшнең алгы сызыгында!..

Бераздан Шәһи-Морат комиссарның да тавышында югары төсмерләр, кәнфит төрә торган шытырдавык кәгазь төсле ялтыравык сүзләр җил юып алгандай юкка чыкты. Ул инде кытыршы, иске бер тактадан тәрәзә йөзлеге ясарга алынган авыл агайларындагы шикелле талгынлык белән кичәге көрәштәшен «эшкәртүгә»күчте:

— Партия һаман үсә, галәмәт олы Рәсәйнең һәр почмагын үз кулына ала, авызлыклый бара, Әмир дускай. Менә мин әйтте диярсең, озакламый илнең иң ерактагы сала-авылларына да, хәтта без синең белән күреп үткән печтик кенә кышлакларга да хуҗа булып алачак и үз кубызына биетә башлаячак ул. Социализм җиңәчәк бу илдә, коммунист булсам да, валлаһи дип әйтәм, җиңәчәк ул. И син үзең дә күреп торасыңдыр, акылы мәрткә китмәгән байтак шома җаннар партия канаты астына килеп сыена бүген. Партия кайчагында хәтта тынчу, хәрәкәтсез күлгә төшерелгән көймә төбенә дә охшап кала. Аның төбенә әллә нинди кырмавыклар, ярым

черек төрле суүсемнәр, әкәм-төкәмнәр, бакакайлар да килеп ябыша. Чөнки шул җансыз кырмавыклар, бакакайлар да алда нинди язмыш көткәнен белеп тора сыман. Олы көймә су өстендәге таллыклар йә камышлар эченә килеп керсә, аларны ерып, сытып, егып барган чакта көймәнең төбенә йә булмаса артына ябышканнары түгел, ә иң очына, алгы башына ябышканнары коелып калачак бит. Бәлки, менә шуңа күрә бүген ул Мәскәүдә Бухариннар, Троцкий, Зиновьевлар арасында ызгыш барадыр да...

Шаһи-Морат, үзенең хискә нык бирелеп, багорны бик тирәнгә ыргытуын чамалады бугай, кесәсеннән көмеш портсигар чыгарып, авызына дәү тәмәке капты. Сыңар куллы булса да, ияләнгән икән, тәмәкегә утны бик тиз элде. Әмир ачык калган портсигар капкачындагы сүзләргә күз йөгертеп өлгерде. «Комиссару полка Шагимуратову за революционную доблесть. Командующий Восточным фронтом Лев Троцкий». Ал-лай!

— ...Партия сафына баскан кешеләрне генә яклау, үсеш көтә киләчәктә, мин шулайрак уйлыйм,— дип дәвам итте Шаһи-Морат, ни өчендер Әмирнең йөзенә бөтенләй дә карамыйча гына.— Фронттагы сугыш, строй белән атакага йөрүләр бетте, артта калды инде. Мәгәр сыйнфый көрәш әле бетмәгәндер дип беләм. Әнә күрәсең бит, нэпны игълан иткәч, күпме байбәтчә белән никадәрле кулак баш калкытты. Ленин партиясе — пролетариат, ягъни мәсәлән, эшче белән гади крәстиян партиясе лә ул. Байбәтчә белән кулакларга түзеп тормас, димәк. Шулай булгач, алда әле безне тагын көрәш көтә. Анысы стройларга тезелеп, кылыч күтәреп йөрү булмас инде. Мөгаен дә, ипләп кенә, тавыш-тынсыз гына җыеп алу булыр...

Шаһи-Морат ашыгып кына ике-өч мәртәбә тәмәке суырып алды, тын утырды, бераздан соң гына, ниһаять, керфекләрен күтәреп, Әмиргә күз салды.

— Гыйнвар аенда юлбашчыбыз Ленинны югалттык без,— диде ул бу юлы, бик сагышлы итеп.— Хәзер партиягә «Ленин чакыруы» дип аталган кабул итү бара. Сукыр кеше сыман әле теге почмакка төртелеп, әле чокыр-чакырларга бата-чума хак юл эзләп булмый. Давай, партиягә кер син. Килмешәк Яшке кулак тегерменендә батрак булып йөрүләргә чик куярга кирәк. Башына тай типмәгән бөтен кеше партиягә керә. Әнә шулар хәзер каласында да, авылларында да әллә нинди комитет башлыклары, чекист булып, партячейка секретарьлары йә инде сезнең Дини сыман авыл советлары рәисе булып йөри. Андый пәртфил артыннан куучылар дачурта ул хәзер. Әмма шунысы кызык: илдә нинди генә хәл булмасын, менә шулар тизәк кебек өстә калачак та, алар

батмаячак. Ә син кичәге кызылармеец, Әмир. Хәләл каның-ны коеп сугышып йөргән гадел кызылармеец. Синең урын өстә, батраклыкта түгел. Конференция бетүгә, кантон комитетына алып китәм, давай. Шаһи-Морат комиссарга каршы килүче юк, юлламаны сиңа үзем язып бирәм. Давай, туган, партиягә кер син.

## 2

Тупса аша узып яңалыкны әйткәч, Гөлтуташ Әмирне өй эченнән пумалалап куды.

— Фартионный булам дип чукынып кайтуыңмыни? Сасы урыс аягың белән басып, минем намаз укый торган келәмемне пычратасы булма. Нигә кадалып китмисең шунда, сәндерәгә сыптыр!..

Әмир шулай итеп мунчада төн кунды. Ләкин газиз хатынының уртак түшәктән баш тартуы иргә салкын чәй ясап бирү кебек бер тузыну гына булган, ә чәчәк таҗлары астына яшеренгән энәләр алда көткән икән.

Кич белән караңгы төшүгә, Әмирләр йортына шакымыйнитми генә бертуган абыйсы Әбелсаттар килеп керде. Йөзе ат көтүе тояклары астында калып изелгән җиз табак сыман җимерелгән, карашы куе болытлар каплап киткән күзге күк йөзе шикелле шыксыз-нурсыз иде. Сәлам-мазар биреп маташмады, тавышы төксе, бик тә коры чыкты.

— Колагыңа гына әйтәсе аерым сүзем бар. Әйдә, чыгыйк әле.

Өйалдыннан төшеп ихата түренә таба атласалар, сарай күләгәсенә поскан ике шәүлә тора. Караңгылыктан күз шактый бәйләнгән булса да, аерды аларны Әмир. Берсе — кайчандыр аны үзләренең сәндерәсендә Рөстәмбәкнең үч һәм җәзасыннан качырып яткан яшьлек дусты Хәби. Икенчесе — шул ук Хәбиләргә беркадәр кардәш тиешле, Төркәйнең үзенә сирәк кенә кайткалап, күбрәк айларын авылдан-авылга йөреп хәлфәлектә үткәрә торган Озын Закир абзый. Беренче булып менә шушы абзый Әмирнең күлмәк якасын төбетамыры белән умырып алды.

— Кая, камунислар тагып җибәргән тәреңне күрсәт, кяфер!

Әмир күрше ихатадан килеп кергән көндәшенә каршы сикергән әтәч кебек бик ярсу кыяфәттә тыпырчынырга тотынган иде дә, ике яктан ике кулына абыйсы Әбелсаттар белән Хәби килеп асылынды. Ә Озын Закирны инде бөтенләй кыргый вәхшилек ярсуы чорнап алды бугай. Ул әүвәл Әмирне бугазыннан буып әләктерде, аннары каерылып торып маңгае белән аның югалып, өшәнеп калган чыраена ор-

ды. Әмирнең күзләреннән көлтә-көлтә очкын чәчрәгәндәй булды, бер мизгелдән соң ул лап иттереп чалкан барып төште. Күзләрен янә ачканда, Хәби белән Әбелсаттар абыйсы тезләренә чүккән һәм икесе тиң ике яклап авыр йодрыклары белән аның йөзен изә иде.

— Әһ-һә, фиркале булам дип, Коръәннән баш тарттыңмы, хәсис?

— Кяфер булып, Алла юк дип, урыс юлына бастыңмы?

— Мәчетләребезне җимереп, безне Алласыз калдырмакчы йә чиркәү төземәкче буласыңмы, эт җан?!

Әбелсаттар белән Хәбинең икесенең тиң йөзләре чалшаеп чыккан. Тыелу, кызгану дигән чаманы бөтенләй югалтканнар. Битәрләп, сүгенеп кенә дә калмыйлар бит ичмаса. Сүз арасында тын алган саен, лач иттереп йөзенә төкерәләр дә, әле йодрыклары белән дөмбәслиләр, әле сикереп торып аяклары белән лас-лос типкәлиләр.

Бәла-хәвефне сизенгәндер инде, чәр кычкырып берзаманны өйдән Гөлтуташ атылып чыкты. Балаларын тилгәннән якларга ташланган ана каз сыман Әбелсаттарның кулларына килеп асылынган иде, тегесе киленне эт баласыдай иттереп читкә болгап атты.

— Синең эшең түгел, кысылып йөрмә, марҗа!

Шулай да Гөлтуташның шәрран ярып кычкыруын ишеткәннәр бугай, күрше ихаталар ягында да, урам як койма өстендә дә дүрт-биш кешенең йөзе чагылып китте. Ләкин ихатага узу түгел, арадан һич югы берсе дә аваз салмады аларның. Ә батыраеп, очынып киткән Озын Закир әллә каян гына Коръән сүрәләре тартып чыгарды да, тезенә чүгеп, аны Әмирнең иягенә төртте:

— Мә, үп Коръәнне, тәүбә ит, кяфер! Кызыл билетыңны кая яшердең? Аны чыгарып ташла. Әле соң түгел, тәүбә ит, дим, давай!

Юк, билеты турында да бер сүз әйтмәде Әмир, Коръән сүрәләрен үбәргә дә омтылыш ясамады. Ә Озын Закир әле тагын ике-өч мәртәбә Коръән китабын Әмирнең иреннәренә төртеп карады да ахырда, күн итекле аягы белән кизәнеп торып, яклаучысыз ирнең иягенә типте. Аңа янә ярсый-ярсый Әбелсаттар белән Хәби кушылдылар. Ләкин Әмир инде авыртуны сизми, әйтерсең лә ул упкын төбенә төшеп чумган иде.

## 3

Әмир айдан артык вакыт буена түшәктә гел кан косып ятты. Янына бер-ике мәртәбә Яков килеп китте. Һәрбер килүендә, әллә каян табып, чиста бал китерде. Аблайдан кем ашадыр Гөлтуташ дәштергән бер имче карчык килде. Әмир-

нең кабыргаларына, корсагына уч төпләре белән басып карады да сырхау сәбәбенә бик тиз бәя бирде:

— Бөер белән бавырларың эштән чыккан, кәбәм. Менә сиңа яшь имән кайрысы, менә кипкән шомырт. Иртә-кичен гел шуларның төнәтмәсен эч син. Аннары... аннары менә үзем сихергә дип кенә тота торган бер мал сеңере сиңа. Моны да калай чүмечтә кайнатып, шулпасын эчер, килен...

Өч-дүрт көн буе шул шулпаны эчергәннән соң гына, Гөлтуташ Әмиргә серне ачып салды. Имче карчык калдырган ул «сихерле байлык» — мур кыргыры бүре дигән «мал»ның аяк сеңере икән. Әмир укшый-укшый төкеренеп ятты, ә Гөлтуташ имче карчыктан ишетеп калган «сихерләр»не тезде.

— Сунарчылар бүре сугып кайтса, бөтен имче шулардан аяк сеңерләрен ялынып җыя икән. Ул сеңерне әүвәл төнлек юлына куеп киптерәләр дә аннары дога китаплары арасына кыстыралар икән. Менә шуннан соң авылда берәр кешенең малынмы, нигъмәтенме урлау була калса, имчеләр менә шул бүре сеңерен тотып дога укыйлар, ди. Дога дөрес укылса, бүре сеңере дә тартыша башлый, шул чагында теге карак кешенең дә кул-аягы тартышып ята икән. Азгын ир-егетләр кыз-кыркынны бозса, аларның да кайбер шәрифләре шулай тартыша, ди...

Әмирнең кычкырып көлмичә чарасы юк иде...

Беркөнне, Әмирнең хәлен белергә дип, Күчәрбайдан Дини шурачы белән бик төксе кыяфәтле милиционер килде. Ләкин хәл белешүләре шул бәйнә-бәйнә төпченүгә генә охшап калды.

— Сине кемнәр кыйнады? Кулларында корал юк идеме? Камунислар партиясен бик нык сүктеләрме?

Әүвәл боларның тел төпләрен аңышмаган Әмир булган хәлне бәйнә-бәйнә тезеп салмакчы иде дә, соңгы минутта акылына килеп, иреннәрен кысты.

— Юк, болай гына, юк-бар өчен генә булган бер ызгышу ла ул. Кыз-кыркыннар үсеп җитә тора, ә мин ир-ат. Шуннан чыккан низаг.

Башлап, елмаюның ни икәнен дә белми торган милиционер мунча ташы сыман кыза башлады:

— Сине авылдашларың партиягә кергән өчен тотып кыйнаганнар. Аларны Гәрдән белән Йосыф кулаклар котыртып яллаганнар. Шуларга бүләккә кибетче Мирсәяф аша Уфадан өч яңа сабан кайтартканнар, диләр. Бу хактагы хәбәрләр безгә инде әллә кайчан килде. Исемнәре дә мәгълүм. Син койрыгына баскан елан сыман боргаланып ятма инде монда. Гариза язып бир дә мин аларны, хәзер үк җыеп, Бүздәк каталашкасына алып китәм.

Әмир туздырып ташлаган кырмыска оясы шикелле күк-

рәген талый башлаган ачу-ярсуын көч-хәл белән генә тыеп җавап бирде:

— Партиягә авылдашларым өстеннән донос язар өчен кермәдем мин. Фронтта чагында чигенергә туры килсә дә, мин күрше окоптагы кешене гаепләмәдем. Окопны беренче булып кем ташлап качкан, әһәмияте юк бит. Мин аларга ияргәнмен икән, ахыргача сугыша белмәгәнмен икән, мин үзем үк гаеплемен, димәк... Мин коммунист, партиямнән танмыйм. Авылдашларым белән дә килешеп яши белергә өйрәнермен әле.

— Оһ, шикләнәм,— диде аңа милиционер, сыртына бер капчык йөк салган шикелле өзек-өзек сулап.— Сине кемнәр изгәнне ярты авыл халкы күзәтеп торган, мәгәр берсе дә аралап алмаган бит. Бу — сиңа бөтен кеше артын куйган дигән сүз ләбаса. Син алар белән килешә алырсың микән? Оһ, шикләнәм...

Китәргә дип урыныннан купкач, Дини дә сүз катты.

— Савыгып аягыңа басуга ук, шурага кил. Чирләп ятып син язгы чәчүне дә үткәрә алмадың, ызначит, лар төпләрең, келәтләрең такыр. Кайгырма, без камунисларны ярдәмнән ташламыйбыз. Без синең гаиләне аерым давулствигә куябыз. Әрмиядәге кебек. Камунис кешегә аңа аерым паюк тиеш. Ите, оны, ярмасы — барысы да булыр.

Урыныннан кубып, ишек төбенә җиткәч, Дини, тоташ яңгырлы көндә кызыл балчыклы үрне яулый алмый интеккән карт мосафир сыман, кире әйләнеп килде.

— Ә Сәхиб брат менә милисинер булса да, хаклы. Төркәй сиңа, чынлап та, артын куйган. Пырлитарьят дошманнары үзеңне изгән чакта беркем якламаган. Син зрә генә аларны яшерәсең. Изгелекнең кадерен белми бездә халык. Камуниска аңа тимер сымак салкын, җансыз булу кирәк. Хәер, хәер...— Дини ашыга-ашыга иренен чәйнәп алды.— Син әле партиягә яңа кергән кеше. Классный көрәш закуннары дигәннәрен аңларга да өлгерерсең берчак. Үзеңне җиргә салып таптаган пырлитарьят дошманнарын да утлы табага салып биетерсең. Дөнҗа бит ул куляса, туганкаем, бер әйләнә, бер баса. Сиңа да тантана итәр көннәр җитәр әле. Шулчак, ух, без аларны!..

Дини, йодрыгын каты төйнәп, тәрәзә аша әллә нинди билгесез дошманнарына усал янады да, баш түбәсен ишек ниргәсенә бәрә-бәрә, өйдән чыгып китте.

Әмирнең хәтерендә гел бер уйлар ватык арба тәгәрмәчләренең шыгырдавы сыман кабатланып ятты.

— ... Бөтен Төркәй сиңа артын куйган. Беркем якламаган... Изгелекнең кадерен белми бездә халык... Камуниска тимер сымак салкын булу кирәк...

Түшәгеннән кубып тәүге тапкыр урамдагы бүкән өстенә чыгып утырган Әмирне авылдашлары гүя танымады. Ирен-нәре бөрешкән, уртлары боз чәйнәгән шикелле гел уйнаклап тора, күзләрендә нур юк, йөзе кырыс, тезләренә салган ике кулы усал йодрыкланган. Беренче булып, Әмирләр турыннан Латыйфа куагы буенда яшәгән Кәримә белән Әсма дигән ике карчык үтеп бара иде. Чәчәкле, матур шәлләр ябынганнар, боларны берәрсе ашка-чәйгә дәшкәндер, кәефләре шәп булгандыр инде. Әмирнең таш сын шикелле авыз ачмый утыруын күргәч, төртмә теллерәк Әсма дигәне дәшми-тынмый гына үтеп китә белмәде шул моның.

— Нәстә, анаң сыман өлкән карчыкларга сәлам дә бирми утырасың, бүкән? Әллә без синең бетле тавыгыңны кереп урлаганмы?

— Ах, анагызның кабер тактасын! — дип җен күргәндәй шашына-шашына сикереп торды Әмир.— Сәлам кирәк булган икән бу ике сөрхәнтәйгә. Бер аягыгыз җирдә, икенчесе гүрдә. Үзегез бил бөгәргә ашыгыгыз, җыен саб-бакы җан. Мин сезнең улларыгыз-кияүләрегезне тотып измәгән бит әле. Гөнаһларыгыз сырттан!

— Әстәгыйфирулла, тфү-тфү! Бу бөтенләй ниткән, ычкынган бит,— диделәр дә ике карчык та, авыз эченнән нидер укына-укына, адымнарын ялт-йолт тизләттеләр. Әмирнең ычкынуы турындагы хәбәр тиз таралды бугай, урамда күренгән ике-өч авылдаш алар турын инде урап узды.

## 4

— Син ачуланма инде, Яков дәдәй, мин китәргә булдым.

Сәлам дә бирми генә тегермәнгә килеп кергән Әмирнең бу рәвешчә сүз башлавын ишеткәч, хуҗа кешенең йөзендә бер төк тә селкенмәде. Әйтерсең лә ул мондый сүзләрне инде күптән көткән, Әмир карары аның өчен алдан мәгълүм иде.

— Якши, Амир,— диде ул, йон җегерләп утырган йөкле хатын сыман тыныч, ипле генә.— Син сам себе хозяин, якши биләсендер. Син мина куп ярдәм иттен, мин сина куп рәхмәт. Сина да вольный казак булырга вакыттыр, значит.

Шулай да Яков бүген үзенең Әмир алдында кем булуын онытмады, ахры, гадел хуҗаларча сорап куйды:

— Синен алда сколько бурычлымын, син дурес әйт, давай. Чтобы соннан мина суз булмасын.

Шул чагында Әмир, бирнә әрәм итеп, ике-өч айга гына иргә барып кайткан булдыксыз кыз шикелле югалып калгандай булды, вәкарь тавыш капылт юкка чыкты.

— Нинди бурыч ди инде ул, Яков дәдәй? Син һәрвакыт

юмарт, гадел булдың. Атлы иттең мине, ризык бирдең. Шулай булгач, мин сиңа үпкәләп нинди сүз әйтим ди?..

Чәрмәсән елгасы буена чыгып, инде икесе дә тиң хуҗалар кыяфәтендә янәшә утырдылар. Табигать искиткеч тын, гүзәл, аның белән хозурланмый мөмкин түгел иде.

Әнә еракта тау өркәчләре арасыннан елан кебек тавыш-тынсыз гына шуышып, кибәргә эленгән сарык тиреләре сыман, вак болытлар йөзә. Чәрмәсәннең аръягында күптән түгел генә яңгыр коеп үткән, күрәсең. Хәзер әнә җир астында пәһлеван бер дию юан тәмәкесен пошкылдата диярсең, яңгыр явып узган басу өстендә зәңгәрсу рәшә әлҗе-мәлҗе килеп уйнаклый. Еракта, бик еракта кып-кызыл кояш офыкка якынлашып килә. Ул яктагы болытларның һәммәсе дә ут капкан чүмәләләр төсле күренәләр. Тын, бөтен табигать тыптын. Аяк астында Чәрмәсән генә, барча кешеләрнең үпкәяраларын төзәтергә ашыккан шикелле, челтерәп агып ята. Елганың яр буйларын дулкыннар еллар буе үбү-иркәләүдән шомарып беткән эреле-ваклы ташлар каплап киткән. Елга өстендә «ә-әй, без дә бар бу дөньяда, безне онытмагыз» дигән шикелле сикерә-сикерә чабаклар уйнаклый. Мондый сихри, илаһи кичтә моңсу хатирәләр үз эченә бөтереп алып китә...

Яков чынында да уйга чумды бугай, капылт сорап куйды:

— Дуресне әйт, Амир. Син нига дип менә мин, Яковка, килден?

Әмир үзен-үзе мәҗбүриләп елмайгандай итте:

— Яраланган бүре үзенең мескенлеген башкаларга күрсәтми, өненә качып, ялгыз гына ялап терелә, диләр, Яков дәдәй. Ул яралы көе көтүгә ияреп йөрсә, аны башкалары ботарлап ташлый икән. Менә мин дә шулай. Үземнекеләр алдына барып бил бөгәсем килмәде. Мескен булып, йолкыш булып күренүдән качтым. Шуңа сиңа килдем.

— Ә мин сина рәхмәт тиеш, Амир,— диде Яков, аның беләгеннән йомшак кысып.— Син тогда Юсуф или Гардан ян бармадын, Рустамбек бармадын, мин ян килден. Син мине алардан югары куйдын. Кеше курде моны. Шуна алар мин тигерман килде. Мин сина бик куп, бик куп рәхмәт тиеш.

Аерылышкан чакта, онытма дигәндәй, Яков гел бертөрле киңәшләрен тезде:

— Син коммунист булдын, аерылма, Амир. Алар сине пока как ат куар, однако бер-бер вакыт кучер итеп куяр. Может, син даже старший да булыр. Однако алар алда син дикий каз булма, арба тушеп калма. Арба тушсән, яна не поднимут...

Күчәрбай яклап яткан тау сырты астыннан Төркәйгә таба атлап кайткан чакта, зирек агачлары ышыгыннан бер шәүлә аерылды да, күл өстендәге аккош кебек тавыш-тынсыз гына килеп, Әмир каршына чыкты. И гөнаһсыз гыйшык! Тәүге мәхәббәте белән гомерлек аерылышу сәгате килеп җиткәнен керсез күңел сизми-тоймыймы соң?!

— Әмир абый, җаным,— дип учак кайнарлыгы бөркеп пышылдады ул, аннары ялгыз юлчының күкрәгенә килеп сыенды.— Син безне бөтенләйгә ташлап китәсең, мин барын да беләм. Әткәй дә мине Кушнариндагы бер кибетче малаена кияүгә бирмәкче була. Мөгаен, мин сине инде үз гомеремдә бөтенләй дә күрмәм.

Ачыргаланып елап җибәрүдән бик нык тыелырга тырышса да, Нинаның гәүдәсе барыбер дә назлы ана кулындагы бишек сыман тирбәлә, чайкала, ыңгыраша иде. Әмир аны яңа туган сабыйны назлагандагы шикелле кадер-саклык белән генә күкрәгенә кочты.

— Минем гомерлеккә синеке генә булып каласым килә. Ярат мине, өзгәләмә мине, Әмир абый?!

Аның кочагыннан зирек агачлары ышыгына томан кебек сизелмичә генә әүвәл Нина шуып төште, аннары, үзе дә ни кылганын аңламый-тоймыйча, Әмир чүгәләде...

Алар айнып җирдән калыкканда, үзәнлектә гомер кабатланмас сихри таң аткан иде инде.

— Хуш, Әмир абый,— диде Нина, соңгы кабат аны кочагына кысып.— Минем сине яраткан сыман башка ярым булмас. Мин бәхетле. Мин бу төнне мәңге онытмам.

## 5

Дини тарафыннан бернинди хәбәр-хәтер ишетелмәсә дә, Әмир Күчәрбай авыл советына үзе җыенып китте. Дини, әлбәттә инде, үзенең иярендә, ул чираттагы ниндидер җыелышта «дөньякүләм мирауай эрвәлүтсә» турында нотык тота иде. Әмирне сау-сәламәт күргәч, чынлап торып күңеле булды бугай, урыныннан кубып шундук йөгереп килде. Кулын озак вакыт кысып торса да, әйтер сүзен колагына гына пышылдады:

— Әллә никадәрле сүз җыелды, Әмир. Монда түгел, миндә сөйләшербез.

«Миндә» дигәне Дини яши торган йорт икән ул. Анысы җыелыштан чыккач ачыкланды. Ә Дининең ихатасын-йортын барып күргәч, Әмир, елан йоткан шикелле, бөтенләй телсез калды. Йа Ходаем! Шушы хуҗалык та ике кулы, ике аягы сау-сәламәт булган ир-ат ихатасы дип атала бит!

Аны ике-өч ягыннан кай урынында читән үргән, кай уры-

нында бау белән бәйләп кенә җепсә асылган «койма» каплап тора. Бәдрәш елгасы ягында анысы да юк, череп, кыйшаеп беткән баганалар гына тезелешеп баскан. Мунча бөтенләй юк, сарай черек. Бер күгәненнән купкан ишек аламасы читкә янтаеп төшкән. Кайчандыр печән, салам өяргә дип әзерләнгән әвенлек өстендә хәзер алабута, билчән тырпаеп утыра. Бу ихатага кәҗә сыман әрсез мал да аяк басмый, ахры. Бөтен җирдә әрекмән, шайтан таягы, кычыткан, кырмавык. Капка белән өйалды ишеге арасында гына кеше йөргәне сизелә. Анысында әрекмән белән кычыткан юк-югын, шулай да бар сукмакны бәбкә үләне, тузганаклар сарган.

Дини өйалды ишеген ачкач, Әмир кабер эчен күргәндәй тукталып ук калды. Өйалдының идәннәре юк, кап-кара җир, өй ишеге белән ике арада гына ике-өч такта ята. Өйгә керәсе ишек төбендә ташлар өстенә салынган сыңар такта. Бер почмакта шундый ук ташлар өстенә куелган агач мичкә, янда ләгән, чүмеч. Әллә бу Дини хәерсезнең юыну-коену урыны да шушында гына микән?

Өй ишеге «нигә мине тартып тинтерәтәсез, картайдым бит инде» дип зарланган сыман бик сыкрап, калтырый-калтырый гына ачылды. Өй эче дигәненең дә җимерек сарайдан кайтыш төше бөтенләй юк иде. Почмакта — ниндидер өч-дүрт япма өелешеп яткан агач сәке. Уртада — соңгы тапкыр су тамчысын күрүләрен инде әллә кайчан оныткан савыт-саба тезелгән кыек өстәл. Берсе ауган, икенчесе чалшаеп утырган ике-өч урындык. Тәрәзәләрдә пәрдә урынына саргаеп беткән гәҗит. Ишекнең сул ягында корым басып бетергән тәбәнәк мич. Идәндә — тәмәке төпчекләре, кәгазь кисәкләре, мамык, тузан. Бурсык-төлке яши торган өн дә бу рәвешчә ташландык булмый торгандыр ул.

Әмирнең бик аптырап күзәтүен абайлады бугай, Дини исе дә китмичә кул гына селтәде.

— Баеуай камунисның өе аның акуп сыман булырга, анда бер артык әйбер дә тормаска тиеш. Байлык артыннан куган камунис баеуай була алмый. Ул мал дип чукынып ята, кул-аягы гер асылган йә богау салынгандай була. Байлык — сазлык ул, брат. Кулымнан килсә, мин әле камунисларны, солдат сымак, казармага гына ябып тотар идем. Караватың бар, тумбычкаң бар, җитте. И, тагын да килеп, аның винтуфкасы булсын, кылычы булсын. Шуннан башка бөтен нәрсә артык. Команда була икән, ияргә сикер дә мен. Кылычыңны күтәр и эфпирүт. Партиягә менә шундый кызылләрмис кенә җиңү яулап бирә...

Дини «окобындагы» корымлы мич артында «склад» бар икән. Хуҗа шуннан борыны җилем белән бөкеләнгән шешә, дуңгыз мае, суган, тимер савытлы ярма, кирпеч рәвешендәге

икмәк алып килеп өстәл өстенә тезде. Әмирнең һаман да сәерсенеп, ятсыныбрак күзәтүен өнәмәде, ахры, шешәнең җилем бөкесен суырып ишек төбенә аткач, юлбасарлар өерендәге атаман кыяфәтендә кырыс әмер бирде:

— Яшь тай белән бер аранга куып кертелгән алаша сымак ни кылырга белми аптырама, давай. Без синең белән икебез дә бер әрмия салдатлары. Эрвәлүтсә салдатлары без, эрвәлүтсә! И, тагы да килеп, безгә якынаерга, аңлашырга вакыт. Эрвәлүтсә салдатлары ул, җаныкаем, струйда гел бер аякка басарга, буталмаска тиеш. Син сул аякны күтәрәсең икән, мин сул аякны. И, тагы да килеп, мин уң аяк икән, син уң аяк. Менә шулай, брат. Әйдә, җиффәр.

Ике-өч мәртәбә нык кына «якынайгач», Дини күңел серләрен дә шактый ачып салды:

— Иптәш Лелин икспрәпрәсия дип язып, вәгъдә биреп калдырдымы безгә? Җәгъни дә мәсәлән, кичә безнең тирене салдырып, безне талап байлык җыйган буржуй-кулакларның дөнҗасын кире талап алу, бүлешү ул. Ә без бит синең белән камунислар, брат. И, тагы да килеп, пырлитарьят. Килемдәге Җантурин алпавытлар, Бәләбәйдәге Зотов дуарәннәр беренче чиратта кемне таладылар? Мине таладылар и, тагы да килеп, сине. Әй-йе, сине. Чөнки син ярты гомерең буе җә батрак булып йөрдең, җә акупта яттың. И менә хәзер инде син үзеңә тиешне кайтарырга тиеш. Ул сезнең Төркәйдәге Рөстәмбәккә, Гәрдән, Йосыфларга хан сарае сымак йортларда түшәмгә төкереп кенә яшәүләргә чик куярга вакыт. Без дә бит адәм баласы, чурту-матыр, и, тагы да килеп, безнең урамга да бәйрәм тиеш. Менә Дини камунис әйткән иде, диярсең, у-у-у, без ул Гәрдән, Йосыфларны биетәчәкбез әле! Әйдә, җиффәр...

Өйалдындагы барча чиләк-табакны коеп, ишекләрне дөбер-шатыр китереп кайтып кергән Әмирне Гөлтуташ, әлбәттә инде, күз яшьләре белән каршылады.

— Бу юлы инде чынлап торып чукынып кайттыңмыни, әҗәтханә?! Үзеңне җир дә йотмый бит ичмасам! Кеше күзләренә чыгып ничек күренерсең?

— Йоттырмый тор әле, җитешерсең! — дип үкерде Әмир, идән тибә-тибә. Аннары җилкәсенә аскан капчыкны салып, өй түренә атты.

— Ашарыңа ризык алып кайттым. Кәнсирләнгән итләр, поты белән ярма. Мин Яшке батрагы түгел, мин коммунист хәзер. Сүз әйтәсе булма!..

Гөлтуташ эндәшмәде, ләкин Төркәй сыңар коммунист каршында тешен кысып, түзеп тормады шул.

Икенче көнне Әхтәм мулланың азан әйткән тавышы ишетелгәч тә, әле үзе дә алтынчы яше белән генә барган нәни

Зифа, энекәше Тимерҗанны алып, мәчеткә таба чыгып киткән иде, ничәдер минуттан соң икесе тиң күз яшенә батып кайтып керде.

— Абыйлар мәчет яныннан куды. Сез кяфер хәзер, әнә сиңа төньяк, шуңа карап чукын, диләр. Галимулла малае артыма да типте...

— Бу гөнаһсыз балаларны тагын ничекләр итеп җәфаларсың, җир бит?! — дип, күз яшьләре аша Гөлтуташ Әмирне тотып табалады, аны гына сүкте. Ә йорт хуҗасы, усал бөтәрләнгән йодрыгын мәчет тарафына болгый-болгый, үз сүзләрен тезде:

— Ничава, ничава, эт җаннар! Мин кычкырган азанга биеп йөрер көннәрегез дә җитәр, җитәр әле!

## ДҮРТЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Егерме бишенче елда Әмир Нәгыймов авыл старостасына әверелеп куйды. Мондый гамәл, беренче булып, әлбәттә, Күчәрбай шурасында хәл ителгән иде. Ә Төркәйгә килеп, бар халык алдында моны һаман да шул Дини игълан итте.

— Партия безне Лелин төзегән ысталбауай юлдан алга алып бара, сәвит нык көрәйде. Әмма дә ләкин, сәвит бластеның болай итеп үр артыннан үр яулавы мирауай и, тагы да килеп, сыйнфый дошманнарның эчен төртеп тишә. Әгличәннәр әнә безнең сәвит хөкүмәте белән диплумлы араны өзгән булып маташа, ягъни мәсәлән, әглин буржуйлары сысысыр дигән илне танымыйлар, имеш. Шулардан күрмеш, теге чепи күзле япуннар да Кытай гурнисасында тимер юл шартлатканнар. Мәшрикътә асларына ут капкан сымак Пүлшеләр котыра. Ие, безнең сәвит бластеның бөркет сыман мирауай канат җәюе буржуй дошманнарын кандала и, тагы да килеп, борча сымак талый, җокы бирми ул. Мирауай буржуйлардан күрмеш, үзебезнең сысысырдагы сыйнфый дошманнар да тик ятмыйлар, тәгәрмәчкә таяк тыгарга маташалар. Шул эт җаннар менә күптән түгел генә безнең сысысырның данлыклы палкавае Катаускиның башын ашадылар. Пырлитарьятның сыйнфый дошманнары шулай итеп бездән үч алмакчы, үзләренең капитал бластен җаңадан безнең өскә кайтармакчы була. Мәгәр Лелин партиясе и, тагы да килеп, сәвит бласте моңа эрвәлүтсиюн әрмия булып туплап җавап бирә. Без сыйнфый дошманнарга каршы атакага күчәбез и, тагы да килеп, аларны сысысырдан сыпырып түгәчәкбез. Рөстәмбәк сыңары, Йосыф ише кулакларның көне

бетте хәзер. Моңа чаклы сезнең сугыгызны эчеп яткан Йосыф та бүгенгесе көннән башлап ыстарыста түгел. Далуй аны мир өстеннән, далуй!..

Бөтен халык, сыртына камчы белән китереп суккан шикелле, дерт иттереп куйды. Йосыф кулак, Әхтәм мулла, Гәрдән, Мирсәяфләр мәчет мәйданының Торна урамы ягында, Ибниулла карт төзегән таш кибет ышыгынарак җыелып баскан иде. Һәммәсе дә «хәзер без кем кулына калабыз инде?» дип, хафага чумган ятим балалар сыман, Йосыф йөзенә текәлеп тын тордылар.

Мәгәр Йосыфның үзенең кыяфәте, ай-һай, вәкарь иде. Үгездәй таза гәүдәсе өстенә килештереп тегелгән соргылт яңа җилән. Балаклары гармун итек кунычлары өстенә салынып торган затлы постау чалбар. Якалары аллы-гөлле җепләр белән чигелгән атлас күлмәк. Башында бүрек. Түгәрәк, тигез итеп киселгән, пөхтәлегән мәңге җуймас чем-кара сакал. Һәм куе кашлар, шешенке күз кабаклары астыннан керфекләрен кысып төбәлгән эре, җансыз караш. Йосыф: «Әһә, совет власте, тигезлек, хөррият, дип даулый идегез бит. Ярык тагарак янына җыелган ачлар хәленә калдыгызмы хәзер?» — дигән сорау белән мыскыл итә сыман. Кабарынкы, кызгылт йөзендә бер генә төк тә селкенеп карамый бит.

— ...Моннан ары Төркәйдәге былач сәвит әктифләре, пырлитарьят кулына күчә. Йосыф кулак урынына хәзер сезнең авылда Әмир камунис сәвүтски ыстарыста була. Лелин партиясе и, тагы да килеп, хөкүмәт линиясен сезнең Төркәйдә моннан ары сәвүтски ыстарыста Әмир үткәрәчәк...

Тау өстеннән аска тәгәри башлаган таш өеренең юлына киртә кордың ни дә, ялгаш ясадың ни? Таш өерен туктатып булмый, син теләгән эзгә барыбер керми бит ул. Төркәй халкы менә шундый ташкынны күзәткән шикелле беравык тын торды да, кояш баер алдыннан гына арып-талып кайткан мал көтүе сыман, ипләп кенә үз ихаталарына таралышып бетте. Иртәгә малларны яланга яңа көтүче туплап чыгарачак, тирә-юньдәге бар тугайлык таныш, көтүче кулында усал чыбыркы юк, маллар көр кайтачак — кыскасы, хәвеф-хафага чумарлык бер сәбәп тә күренми, халык тыныч иде.

## 2

Гаилә инде ятарга җыенган бер минутта, ишекне ипләп кенә шакып, Әмир килеп кергәч, Әхтәм мулла йортындагылар коелды да төште. Әмир бер мизгел эчендә бар гаиләне күзләп, барлап өлгерде. Мулланың өлкән улы Хәлил ниндидер китапка текәлгән, Мәрьям абыстай җеп җегерли, кызлары Гөлбану кулында чигү киергесе, төпчек малайлары Муса

әле унбер-унике яшьләр чамасында гына булса да, иске киез итеккә олтан көйләп утыра. Көтелмәгән кунакны күрүгә үк, билгеле инде, һәммәсе дә эшләреннән бүленеп хәрәкәтсез калды. Әмир тамак кыра-кыра сәлам биргән булды, итекләрен ишек катындагы чыпта почмагына сөртеп азапланды, ә өйдәгеләр, сәерсенү тулы карашларын төбәп, һаман тын тордылар. Ниһаять, беренче булып, өй хуҗасы ис-акылын җыйды.

— Әллә тагын берәр төрле налук өстәлдеме? Без элеккеләренең җәмгысын да түләп бетердек бит. Нишләп таңны да көтми ашыгып килдең, диюем.

Әмир киеренке хәлне таратмакчы булды, көлемсерәп куйды.

— Әллә мин байлык талап йөрүче юлбасарга охшаганмы, хәзрәт?

— Сезнекен белмәссең. Атаң Нәгыйм дә, син үзең дә заманында ерак юлда ломовойлар булып йөргән кешеләр лә. Угры-юлбасарлар белән ничек килешкәнсездер дә, ничек бүлешкәнсездер, анысы безнең ишеләргә гүпчем караңгыдыр.

Әхтәм мулла, Әмир килеп кергәндә, өстәл түрендә, ырмакларына кереш таккан күзлеген борын очына гына элгән көенчә, ниндидер гәҗит кисәкләрен барлап утыра иде. Ул Әмир алдында юхаланып маташуны да, күзлек салып торуны да кирәк санамады. Күзләрен кыса төшеп күзлек кысасы өстеннән генә текәлсә дә, ул күңелендәге уйларын турыдан ярып салды:

— Аннары ул сезнең Кысыр Дини сымак советларыгызга да ышанырлыкмыни? Бер айда миңа икмәк налугын утыз пот түләтәсез, икенче айда инде илле потка тикле күтәрәсез. Сез ак җонлы малдан елына ике мәртәбә кара җон кыркып алырга җыенасыз бугай.

— Телең, валлаһи, кычыткан сымак, хәзрәт. Мин бусагадан узып авыз ачарга да өлгермәдем әле, ә син, инде ничә тапкыр мине усал тәкә сыман сөзеп, кадап алдың.

— Урыс белән ара якынайтсаң, балтаң яныңда торсын, ди. Күршеләрне талап кына көн күрә торган урыс белән иманын фиркагә алыштырган гыйбад арасында аерма зур булмас.

Хәзрәтнең соңгы сүзләре Әмирнең үтенә барып кадалды. «Шулай, фиркагә кердем ни дә, староста булып алдым ни, ә сезнең өчен барыбер элекке батрак, гыйбад шул мин», — дигән уйлар күңелен тырнап узды. Әмма мондый төерле, кайнар ташны да сүзсез генә йотып җибәрми чарасы юк иде, ул талгын, ипле тавыш белән янә телгә килде.

— Безне, совет активларын, җыеп, Аблай авылына да, Усманга да апбарганнарые. Андагы яңалыкны, сезнекечә әйт-

сәң, тәрәккыятне күреп, шаклар катып кайттык. Ике авылда да яңача итеп мәктәп эшләп ята. Берсенә — Сәлим хәзрәт, икенчесенә Җәвит мулла укытырга кергән. Алар да совет властеның мәңгелеккә дип, кире китмәскә дип урнашуын аңлаганнардыр инде. Таш стенаны аны астан чыра белән чокып кына түгел, күсәк белән сугып та җимереп булмый. Сәлим белән Җәвит хәзрәт менә шуның белән килешкәннәр, димәк. Икесе тиң менә дигән итеп балалар укытып йөри.

Әмирнең сүзләре Әхтәм хәзрәт өчен кытай әлифбасы сыман көтелмәгән яңалык булды, ахры. Ул алдындагы гәҗит кисәкләрен читкә этеп куйды, борын очына элгән күзлеген дә салды. Хәзрәт инде урыныннан кубарга да чамалаган иде, ләкин әтисенең ниятен егермегә җитеп килгән улы Хәлил ымсыз-нисез көенчә дә чамалады бугай. Хәлил, өстәл артыннан җитез кузгалып, Әмир каршына өстенә бизәкле япма салынган урындык китереп куйды. Әмир шәйләп калды: Әхтәм мулла күзләрендә лампа филтәсе сыман җемелдәгән ут кабынган иде. Дөрестән дә, хәзрәт тартып-сузып тормый сорашуга күчте:

— Яңа мәктәп эшләп ята, диген. Сәлим хәзрәт белән Җәвит мулла укыталар, диген. Ыһы, ыһы. Нинди гыйлем укыталар микән инде алар анда? Сәвиткә аңа, яңа мәктәп булгач, искечә ярамый торгандыр бит инде?

Урындыкка җайлап урнашып алгач, Әмирнең тавышы көрәеп үк китте:

— Әйе, Әхтәм хәзрәт, советныкы булгач, искечә ярамый шул. Анда хәзер Коръән ятлатмыйлар. Мәгәр ул әлифба белән исәп-хисап дигәннәре инкыйлаб булуга йә совет хөкүмәте килүгә карап үзгәрми бит. Әлиф элек тә әлиф иде, ул хәзер дә әлиф булып кала. Ике икең дә барыбер дүрт килеш. Аның башка гыйлемнәре дә шул көенчә бугай. Җәгърафия, мантыйк, тарих, әдәбият. Дөрес инде анысы, балаларга хәзер Заһир мулла, Кандалый хәзрәт язганнарны ятлату юк югын. Бүгенгеләр Тукайларны, Камалларны, үзебездән чыккан Галимҗан язганнарны өйрәнәләр бугай.

— Мин аларны белмим.

Әхтәм хәзрәт авызыннан шундый сүз ишеткәч, Әмир урыныннан сикереп торудан чак тыелып калды. Әмир әле тәкъдим түгел, киная да ясап карамады, ә Әхтәм мулла инде мәктәп ачуны, балаларга гыйлем бирүне күз алдында тота. Күз генә тия күрмәсен, маһир итеп кыстый белсәң, болар күнәчәк бит!

— Ялгышмасам, сезнең Хәлил Уфаның үзендә, «Галия» мәдрәсәсендә укып йөрде бугай. «Галия»дә анда гел яңача гына укыталар дип ишеткән бар. Разый булса, яңа гыйлемнәрне әнә ул укытыр.

Әңгәмәнең болай көтмәгәндә бик тирәнгә кереп китүе Әхтәм хәзрәтнең үзенә дә ошамады сыман.

— Туктале, тукта, дуга белән печән чапмале син,— диде ул, үртәлгән-үпкәләгән кеше шикелле ярсу тавыш белән.— Атмаган куянга, асмаган казанга кунак чакырасың. Сиңа мөгаллим булырга ялланган кешеләр бөтенләй юк бит әле.

Ләкин Әмир күзенең уңы белән бөтенесен дә шәйләп өлгергән иде инде. Киная рәвешендә генә әйтелгән тәкъдимне ишеткәч тә, Хәлил угланның карашы очкынланып китте. Мәрьям абыстай белән Гөлбану яшүсмер дә Хәлил тарафына сокланулы, җылы күз аттылар. Хәтта Әхтәм мулланың үзенең дә Хәлилгә күз ташлавында ихтирамлы, канәгать хисләр чиктән ашкан иде. Әмир Әхтәм хәзрәтне бөтенләй дә үгетләп маташмады, ул бары авыл хәсрәтен үз иңенә алган хуҗалар тавышы белән яңа сүзләр тезде.

— Беркөн теге Торна урамындагы Корык Талипның малае Нурисламга гәҗит сузган идем. Ике сүзне дә дөрес итеп укый белми, мескен. Ә аңа инде, адәм тәганәсе, ундүрт тулып киткән. Шуннан өй борынча барлап, санап чыктым. Төркәйдә бүген мәктәп яшендәге утыз җиде бала әлифне таяк дип тә белми икән. Авылда, ялгышмасам, инде алты ел буена мәдрәсә ишегенең ачылганы юк. Ярты авыл надан. Ә югыйсә мулла белән мәзин авылга азан әйтер, намаз укыр, аштан-ашка йөрер өчен генә кирәкми бит. Ашка гына калса, анысына аның күрше Иванайдагы урысны да чакырып сыйлап була. Совет, совет дип сүгенүдәмени соң ул хикмәт? Балаларның гыйлемле, ушлы булуы бер советка гына кирәкми бит. Советка гына калса, ул Төркәйнең берүзенә генә дә укымышлы утыз-кырык мулланы яллап китерә ала.

Әмирнең көтелмәгән яктан китереп төрттерүе Әхтәм мулла өчен тулып борынлаган шешкә таяк белән суккан сыман тәэсир итте бугай. Ул, теше сызлаган кеше шикелле, йөзен чытып куйды. Кая куярга урын тапмагандай, кулларын әле аска яшерде, әле бер-берсенә ышкый-ышкый янә өстәл өстенә куйды. Тавышына югалып калу, кыбырсу аһәңнәре өстәлгәндәй булды. Сүзләрен берәмтекләп кенә, сайлый-сайлый тезде:

— Заманасы да замана түгел бит, нәгълӛт. Әле сәвит, әле Колчак, аннан торып ачлык. Кай тарафка кыйбла тотаргадыр, берни аңлап булмый. Дөрес инде анысы, авылны надан калдыру саваплы эш түгел. Ие, ие, мәдрәсәне тергезергә, балаларны укытырга кирәк. Мәгәр аларны җыеп утыртырга күзгә күренеп торган йорты-каралтысы да юк бит әле аның, каһәр суккыры.

Әмирнең тәненә җылы дулкын йөгергәндәй булды, җиңел сулап куйды. Хәзрәтнең сәбәп эзләве — үзенең бәясен күтә-

ргә тырышып тарткалашу гына, аны ризалатып була болай булгач.
— Бөтен нәрсәне дә каһәрләргә ашыкмале, хәзрәт. Советны каһәрлә, фиркане каһәрлә, юк, гел-гел алай булмый. Шул совет чорында да мулла булып саналасың икән, игелегеңне дә күрсәт. Элек заманда мәдрәсә өчен аерым йорт дауламадың, балаларны үзеңнең әнә теге як йортыңда җыеп укыттың бит. Хәзер дә, шаять, шулай башлап була, аннары күз күрер. Совет власте китәргә дип килмәгән бит әле.
Муллалыктан колак кагу хәвефе хафага салды бугай, Әхтәм хәзрәт монысына да ялындырмый күнде.
— Ие, әһе, укытуны аны минем йортның теге яртысында да башлап була инде. Үзең авылда мәптек яшендәге утыз җиде бала бар, дисең бит. Кысан булыр инде кысанын. Мәгәр, үзең әйтмешли, сәвит власы китми торган булгач, Ходай бирмеш беркөн, ул безнең Төркәйгә дә яңа мәптек төзеп куяр әле…
Югыйсә Әхтәм хәзрәт сынган иде инде. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, шул чагында хәзрәтнең өлкән улы Хәлил сүз кузгатып, бөтен эшне бозып куя язды.
— Утыз җиде бала, дидең бит әле, тәкъсир,— дип телгә килде ул бер дә көтмәгәндә һәм Төркәй халкы мәңге ишетмәгән сәер сүзләр белән.— Утыз җидесе дә бер үк затмы аларның, әллә инде ике җенестәнме?
Ат дагалаганда нинди бака ботын кыстырасың тагын? дигәндәй, Әмир Хәлилгә текәлеп авыз ачты да катты. Хәлнең мөшкеллеген чамалады бугай, Хәлил үзе башлап янә телгә килде:
— Ул утыз җиде баланың барысы да малайлармы, тәкъсир, әллә кызлар дамы? Аннары аларның кайсысы кайсы яшьтә? Араларында элек мәдрәсәдә гыйлем эстәгәннәре бармы? Барысы да сабак алуны беренче сыйныфтан башламый торганнардыр?
— Ә мин аларның барысы турында да каяннар гына белим? — дип бүлдерде аны Әмир, лапастан алып кергәндә бер кипке йомырканы төшереп ваткан ачык авыз сыман бөтенләй өнсез калып.— Мин алар белән бергә каз бәбкәсе саклап йөргән малай-шалаймы әллә? Араларында Корык Талипның малае Нурислам сыман шыр томанасы бар. Кайчандыр мәдрәсә ишеген ачып япканнары да бардыр ул, эзләсәң. Аларын хәзрәт яхшырак беләдер, син атаңнан сора.
Әхтәм мулланың авызына су капкандай утыруын күргәч, Әмирнең тавышына янә корыч чыңы өстәлгәндәй булды. Ул әле һаман бернинди хәвеф тә тоемламый-сизми бармак бөгеп сөйләнүен белде.
— Минем күршедәге мәрхүм Кәримнең йорт эчендәгеләр,

Шәрифулладан кала, барысы да надан. Аларның теге ягындагы Шәйсолтаннар өй эче белән надан. Шахмайныкылар надан, Сәмикъныкылар надан. Алай баш-аягы белән саный китсәң, сабакка барырга тиешлеләр саны утыз җидедә генә бетмидер дә әле. Утыз сигезенчесенә әнә минем алты яшьлек кызым Гөлзифа да: «Укырга бир, укырга бир»,— дип такылдап тора.

— Әстәгъфирулла, әстәгы,— дип, шул чагында Әхтәм мулла чыбыркы белән сыдырган шикелле капылт сикереп торды.— Син нәрсә, имансыз, Корыкның малае Нурислам шикелле күсәк белән кыз балаларны бергә, бер бүлмәдә ябып укытырга җыенасыңмыни? Кит, адәм тәганәсе, гомер булмаганны, тузга язмаганны! Җыен алабай малайлар белән кыз балаларны бер бүлмәгә тезеп утыртырга минем башыма тай типкәнме әллә? Ике аягымның берсен дә атлыйсым юк. Иманыңны фиркагә алыштыргач, хәтәр ушлысыңдыр, үзең җый да укыт.

— Әткәй, әткәй! Хәзер бик күп яңа мәктәпләрдә шулай укыталар,— дип, Хәлил тынычландырырга тырышып караса да, мунча ташы сыман кызган Әхтәм хәзрәт төкеренә-төкеренә сүгенүен белде:

— Иман саттым, ыстарысты булдым дигәчтен дә. Кит, адәм тәганәсе! Корыкның күсәк сымак малае белән кыз балаларны бер бүлмәгә ябып укыталармыни? Тузга язмаганны! Ыстарысты булдым дигәчтен дә...

Үгетләр сүзе, түзәр әмәле калмагач, Әмир дә урындыгыннан купты.

— Ярар инде, хәзрәт, миннән калмады, йөз суымны түгәтүгә байтак үгетләп карадым, син ризалашмадың, бары да аңлашылды,— диде ул, бер дә исе китмәгәндәй тыныч тавыш белән.— Син кәҗәләнә дип кенә совет власте комга тәрәлеп калмас. Мәдрәсә тота алырдай укымышлы мулла-хәлфәләрне Уфаның үзеннән булса да барыбер китерербез. Ә син, давай, элеккечә бәлеш пешерт, ашка-суга йөре... Чакыручы калса...

## 3

Икенче көнне таң атуга, беренче эше итеп, Әмир Әхтәм муллаларның йортын барлап узды. Күңеле ялгышмаган, Мәрьям абыстай белән Гөлбану кызыкай хәзрәт йортының алты ел буе буш көенчә торган ярты ягын янып-пешеп юып ята иде. Әмир канәгатьләнүдән хәтта учларын бер-берсенә ышкып-ышкып куйды, урам уртасында биеп китүдән чак тыелып калды. Әмма яңа староста җиңү яуладым дип бик иртә шатланган, беренче белен төерле була, дигәннәре хак икән шул.

Хәлил хәлфә балаларны яңа ачылган мәктәпкә чакырырга дип, ярты урамны да әйләнеп чыгалмады, кулларын кыйнап ташланган аккош канатлары сыман салындырып, инде Әмирләр ихатасына да килеп җитте.

— Юк, булмый, томана бит болар, Әмир абый, — диде ул, авылдашлары өчен гарьләнүдән ярсып. — Малайларын укытырга бөтенесе риза. Кайберләре хәтта шундук аларны минем итәккә тагып җибәрмәкче. Ә инде кызлар белән бергә кушып укыту турында авыз ачтың икән, бетте-китте. «Коръәндә каралмаган нинди эш ул? Бүреләр белән сарыкларны бер аранга ябып укыталармыни?» — дип киреләнеп тик торалар. Ә Хәерниса түтекәй бөтенләй суеп салды. «Минем түшләре беленә башлаган Миңлебикәм Корыкның бастырык буе Нурисламыннан корсак төяп кайтсынмыни? Печелмәгән үгез бит ул, печелмәгән үгез», — дип, мине авыз да ачтырмыйча куып ук чыгарды. Теләсәң нишләт, Әмир абый, мәгәр моннан ары мин беркемгә дә кермим.

Әмир әүвәл Хәерниса түтинең сүзләрен кабатлый-кабатлый, ботларын чаба-чаба рәхәтләнеп көлде.

— Печелмәгән үгез, диме? Корсак төяп кайтса, диме? Вәт төрттергән бу, вәт әкәмәт! Вах-вах, вах-вах!..

Ә аннары кинәт җитдиләнеп калды да пошаманга төште. Малайлардан гына торган сыйныфлар ачсаң, ярты гына җиңү була бит бу. Хәтта алай да түгел, бу Әмирнең шәхси җиңелүе, бөтен авыл алдында хурлыкка калуы була. «Советский староста булып, мөгез чыгармакчы булып йөргән идең, мөгезеңне сугып сындырдыкмы?!» — дип, бөтен Йосыфы, Гәрдәне бот чабарлар. Ул кызларны мәктәпкә китертү өчен нишләргә соң аңа, йә, нишләргә?..

— Тәк, болай хәл иттек булды, — дип башлады ул, кышкы йокысыннан типкәләп уятылган аю шикелле каударланып, ярсып. — Син, Хәлил туган, кайсы йортлар буенча йөрергә өлгергәнсең, шуларга кире кер дә, бөтен малайларын иярт тә кайт. Ә мин менә күршедәге Шәрифулланың сеңелкәшләрен җыеп аптөшәм дә, үземнең Гөлзифаны шуларга ияртәм. Кем кемне төп башына утыртыр, карарбыз аннары!..

Хәлил хәлфә артыннан ишек-капка ныклап ябылырга да өлгермәде, күз яшьләренә буылып Гөлтуташябырылды:

— Җилдән тапкан бала түгел лә ул! Син имансыз аркасында минем кызым гел эт типкесендә йөреп үссенмени? Инде болай да күзен ачырмыйлар. Мәчет ихатасына якын килдеме, җыен эте-бете ул балакайны урыс урынына, болай, болай итеп, өч бармакларын куеп чукындыра икән. Урамга чыгарлыгы да калмады бит инде балакайның. Сиңа гына сөйләми ул бер дә. Тешләк бит ул, тешләк! Ә югыйсә...

Шуннан ары Гөлтуташ эндәшмәде, Әмир исә барыбер үзе-

некен итте. Балаларны җыйдылар, кызларын-малайларын бер сыйныфка туплап укыта башладылар. Ләкин, Гөлтуташ кисәткәнчә, таякның авыр башы, беренче чиратта, җиде яше дә тулып өлгермәгән Зифа балакайга төште. Үткән-сүткән саен диярлек йә болдырдан төртеп төшерәләр сабыйны, йә мәктәп юлындагы нинди дә булса пычрак эченә кертеп батыралар.

— Мәктәпкә кызлардан беренче син кердең бит. Күтең түгел, әйдә, чыда, денсез!

Үзләре сыман ук ярым хәерче Шәйсолтаннар, Нургалиләр, Гаптериләр шулай мыскыл итә аны. Әмма Зифа, әле сабый гына булса да, һәммәсен дә күрә. Юк, Шәйсолтаннар, Гаптериләр үчле түгел аңа. Болар ялчы гына. Ә котыртуяллаучылары — Гәрдән белән Мирсәяф малайлары. Әле көнбагыш, әле бер шакмак шикәр биреп, хәерчеләрне менә шулар яллый. Ләкин Зифа боларның берсе хакында да әтисенә кайтып әләкләми. Чөнки әтисе кылны кырыкка ярырдай булып йөри, болай да вакыты юк. Ходай бирмеш ике көннең берендә аны йә Күчәрбайга, йә Бүздәккә дәшеп аптыраталар. Советныкылар, коммунистлар ниндидер Каюм бандасын тотарга йөри икән. Әтисе беренче чакыруларында гел Афонькага гына атланып чаба иде, соңрак Афонькаһың сыртлары-кабыргалары иске лапас бәпкәләре сыман калкып чыккач, җәяү генә элдерә башлады. Әнисе яңа бәби көтеп йөри, аңа ике-өч адым селкенү дә кыен, шулай булгач, әтисе юк чагында лапастагы маллар да, Афонька да нәни Зифа кулларына калды инде хәзер.

Әллә нинди сәер холыклы мал булса да, ярата иде Зифа Афоньканы. Үзе ярата, үзе барыбер Афоньканы аңлый алмый иде. Зифа ничәмә-ничә тапкыр урам уртасында, әле алдап-йолдап, әле усалланып, Афонькага йөгән кигезмәкче йә сыртына атланмакчы булды. Чакырдың исә каруланмый, Зифа менеп баскан утыргыч йә булмаса киртә буена килә. Зифа иркәләгәндә, муенын сузып, хәтта күзләрен үк йомып рәхәтләнеп тора. Ләкин Зифа кулына йөгән-муенчак алдымы — бетте. Сыртына камчы белән китереп суккан сыман сикергәли дә кача.

Мәгәр Чәрмәсән буендагы тугайлыкка төштеңме — җан рәхәте. Зифа ике-өч мәртәбә эндәшүгә үк чабып килә теге. Зифа аның маңгай ялыннан тартуга, шундук башын ия. Зифа йөгән кидерсә дә, берәр агач төбе янына алып килеп сыртына үрмәләсә дә, һич карышмый. Зифа Чәрмәсәнгә алып кереп үзе дә рәхәтләнә-рәхәтләнә йөздерә тегене, Усман авылы ягына киткән юлдан чаптырып алып кайта — Афонька шуларның һәммәсенә иң күндәм эт баласы сыман тик буйсынып йөри. Иң гаҗәбе шул: Зифа Афоньканың авызлыгына

бәйләнгән озын дилбегәнең бер очын үзенең неп-нечкә аягына урап утырып китап укыган йә җеп җегерләгән чагында, күндәм малкай ялгыш кына да тартылып карамый бит...

Зифаның ат атланып йөри башлавын, беренче булып, карткоры ошатмады.

— Һи-и! Кяфернең аның баласы да кяфер, тфү! — дип, әллә ничаклы карчык аның артыннан төкеренеп-каргап кала торган булды. Арада әллә нинди сәер сүзләр әйтеп кисәтүче «изгерәк» җанлылар да табылды.

— Атка атланган кызлар кыз булмый ул. Болай атка атланып йөрсәң, үскәч кияү йөзе дә күрмәссең син, денсез!..

Зифа мондый сүзләрнең мәгънәсен аңлар яшьтә түгел иде әле, шуңа күрә Афонька сыртында теркелдәвен белде. Тугайлыктан өйгә таба кайтып баруларының берсендә нинди бәла сагалап торуын да сизенмәде, мескен.

Кичке эңгер-меңгер бервакытта Афонька үшән генә атлап Гәрдән кулаклар ихатасы янына гына җиткән иде, капкадан әллә нинди йөнтәс җәнлек тәгәрәп-мәтәлеп килеп чыкты да, ат каршына килеп җиткәч кенә, капылт сикереп, аягына басты. Зифа аның Гәрдәннең төпчек малае Рәйхан икәнлеген дә өстендә кире әйләндереп киелгән тун булуын гына шәйләп калды. Ә икенче мизгелдә инде өне алынган Афонька читкә сикерде, Зифа исә ат башы аша мәтәлеп җиргә барып төште. Аның сул як иңбашын коточкыч авырту уттай пешереп алды, шул мизгелдә үк аңын да җуйды.

Ул күзләрен ачканда, аның янында, таягына таянып, Гәрдәннәрнең чапырыш күршесе Гайнавал әби чекерәеп карап тора иде:

— Шул кирәк сиңа, Алланың ачы каһәре төшкере, денсез! Әй, шәп булды, муенның өзелгере!..

Зифаны ярты сәгатьтән соң күршеләре Шәрифулла гына күтәреп алып кайтты. Балакайның иңбашыннан кулы тайган иде...

## 4

«Советныкылар Каюм бандасын тотарга йөри икән» дигән сүзләр ялган түгел иде. Чыннан да, Бүздәк, Ахун, Чакмагыш волостьларына караган авыл советларындагы актив көчләр соңгы атналарда, башка эшләрен читкә куеп торып, гел Каюм бандасындагы каракларны аулауга гына җәлеп ителде.

Әлеге банда турындагы хәбәрләр телдән-телгә күчеп инде күптән яшәп килә иде. «Татарстанда Шәкүр карак булса, Башкортстанда — Каюм» дип кенә бәя бирә иде рәсми органнар да, гади кешеләр дә. Ә Каюм үзе кем дә ул, ниндирәк кыяфәттә — моны һичкем анык кына белми. Шуңа күрә

аның турында, тау башыннан ычкынган кар йомгагы сыман һаман саен зурая-зурая, әллә никадәрле имеш-мимеш йөри.

— Каюм карак үзенә каршы кыек сүз әйткән теләсә кайсы ләчәнникнең атын урлап китә, йортын талый икән. Ләчәнник үзе генә йөриме, бер руты сак беләнме — аңа барыбер, ди. Ул, теләсә, морҗадан төшеп тә любый ләчәнникнең маңгаена левольвирын илтеп тери икән. «Малыңмы, җаныңмы?» Шулай дип сорагач, тегеләр малын бирә инде. Шуңа күрә бөтен ләчәнник аннан дер калтырап кына тора икән.

— Алай гынамы соң? Ләчәнникләр аны юри күрмәмешкә сабышалар икән. Ә Каюм, шуңа аркаланып, отыры азына, ди. Ул Әбзән дигән авылда яши бит. Төп оясы менә шунда икән. Үзенең йортын биек, текә тау буена терәп салдырган, ди. Койма булып күренеп торган җире — капка, ә аның эчендә олы мәгарә бар икән. Каюм чираттагы талаудан труйка атлар белән генә кайтып төшә дә файтуны-ние белән бергә әнә шул мәгарәсенә кереп кача икән...

Каюм карак, чыннан да, төп оясын Әбзән авылында корып яши бугай. Берзаманны күрше-тирәдәге барча авыл халкы Әбзәнгә барып килен алмас булды. Моңа җавапны бик тиз сапладылар.

— Әбзәннән төшкән киленнәр соңыннан авылыңдагы бөтен шәп ат турында Каюм каракка хәбәр генә җибәреп ята икән...

Шулай да мәхәббәт маңкага карамый икән шул ул. Берзаманны Чишмә дигән авылның бер егете ерак юлга чыккач, Әбзәндә төн тукталып, Каюм каракның шактый якын кардәшләрендә куна калган. Иртән ихатага бит юарга чыккач, хуҗаның җиләктәй пешеп җиткән кызы белән йөзгә-йөз килеп очрашканнар болар. Очрашканнар да гашыйк та булышканнар. Шуннан, инде кабат авылына кайтып барган чакта, юри шушы ук йортка куна тукталган, ди, теге егет. Ничек итеп хәбәр бирешкәннәрдер инде, анысы дөм караңгы. Ләкин ике яшь йөрәк шушы төнне мунчада үткәргәннәр. Иртән кызый әтисе янына кереп үзе сөйләп биргән.

— Инде буласы булды, уты итәккә төште. Син бирмәсәң, үзем ябышып чыгам, каршы килмә, әткәй...

Шуннан соң бөтен яшь кыз-кыркын, бергә җыйналып, киленне, Себергә озаткан шикелле ике көн буе елый-елый, «угыр» егеткә биреп җибәргәннәр. Ләкин ни гаҗәп, Каюм Чишмә авылындагы бер генә йортка да зәүрәт салмаган, ди...

Көлкесен көлке, әмма, чыннан да, берзаманны Әбзән кешеләрен бөтен тирә-юньдә төн кунарга да кертми башладылар. Эшләр шуңа тикле җитте ки, Әбзән егетләрен волкомнарда хәтта комсомолга алмыйча борып кайтара торган булдылар. Бу очракта да шул бер остасы гына волком ячейка-

сына япа-ялгыз көе килеп кергән дә, Усман авылы хәерчесе булып кыйланып кына, РКСМ билетын эләктергән, ди. Инде билетны куенына яшергәч кенә әйтеп салган теге.

— Мин элегрәк Әбзәннеке идем, Каюм каракның утарындагы бар тишекне беләм. Мин сезнең шундагы уң күзегез булырмын...

Ни үкенеч, бу егетнең гәүдәсен соңыннан Әбзән буендагы бер чокырдан сыңар күзсез көе табып алганнар...

Мондый яман хәлләр тирә-як халкына инде болай да астына учак ягылган казан эчендә яшәү сыманрак тәэсир итә иде. Ә Каюм каракның кыңгыр эшләре турындагы хәбәрләр, тынгылык-ял белмәс февраль бураннары шикелле, һаман куера торды.

— Каюм карак Чакмагыштагы җир бүлегенең айгырын урлап качкан.

— Каюм каракның бер шәйкесе Бәләбәйдәге ятимнәр йортының складларын тоташ талап чыккан...

Татарстаннан инде Шәкүр каракның кулга алынуы турында хәбәр килеп иреште, ә Башкортстандагы Каюм каракның бандасында күпме кеше бар, аларның кайсысы нинди-рәк төр җинаятьләр эшли? — беркем белми. Кайдадыр Уфада Каюм карак бандасын кулга эләктерү турында баш ватучы берәр нинди үзәк оешма да бардыр инде. Ә Күчәрбай, Аблай ише авыл советларында, дөм караңгы бүлмәдә кара мәче тотарга җыенган шикелле, иртә саен, кич саен юкны бушка аударып тик утыралар. Динине комар биләп алды, шурачыларның берсенә-бер тынгы бирми, шул исәптән Әмирне дә ординарецы сыман гел үз янында тота.

— Син утлар-сулар кичкән әктиф безнең. Син берүзең биш кешегә торасың. Өйдәгеләреңне паюктан өзмәбез, әйдә, миңа булыш.

Тора-бара шурачыларда да комар купты бугай. Төн саен юлларга сакка чыгалар, аеруча Әбзән белән ике арага дозор корып яталар. Ә көндезләрен һәркайсы диярлек базарда шымчы булып йөри. Каюм каракның берәр планы турында хәбәр ишетелмәсме? Аның бандасына кергән берәр төрле агент ачыкланмасмы?

Шикләнерлек кешеләр өч мәхәлләле Күчәрбайның үзендә дә байтак. Аеруча Илмурзиннарга тамчы да ышаныч юк. Авылның Әбзәнгә алып бара торган урамында, шактый гына тирән ерым буенда яшәп ята болар. Бакча-мазарлары юк. Җиргә сеңеп утырган йортлары белән мунчалары биек Кызылъярга терәлеп үк тора. Өн дисәң дә өн инде, башка берни түгел.

Шунда биш егет бер өйгә тупланып яшәп ята болар. Гомер бакый җир сөргәннәре юк, беркайда эшләмиләр. Бөтен

шөгыльләре — базар саен әллә нинди шикле тауар сату. Йә хатын-кызлар тараклары боларның кулында, йә киелгән кием. Базарга берчакта да бишәүләп чыкканнары юк. Икесе, һичшиксез, кайдадыр йөри, юлда. Икесе көн-төн базарда, өлкәннәре — Мәхмүт. Күзләре акаеп чыккан, маңгае тар, колаклары олы, борыны бәрәңге чаклы, бәлеш сыман аскы ирене иягенә төшкән. Сап-сары эре тешләре тырпаешып тора. Ирен читләреннән туктаусыз селәгәй ага. Бу адәмдә матурлык, ыспайлык дигән сыйфатларның эзе дә юк. Казан сыман дәү башын сак кына боргалап, базар буйлап әрлебирле йөрүне генә белә.

Ярый әле, боларның төпчекләре Габбас белән сеңелләре Зәйтүнәне адәм рәтле, диләр. Ни әкәмәт, Габбасы бик зәһәр итеп гармунда уйный һәм ике сүз дә сүгенә белми, ди. «Аттан ала да туа, кола да туа» дигән сүздә дөреслек юк дип әйтеп кара инде шуннан. Аннары боларның Зәйтүнәләре дә бик чибәр икән дә бит, ләкин аның янына якын килергә теләүче егетләр генә бер дә юк икән, ди. Кыз чибәрдер, шәптер дә бит, ләкин Илмурзиннар кияве булып йөрергә Күчәрбай егетләренең башы икемени?!

Әмир — күчәрбайлылар өчен беркадәр чит-ят кеше, шуңа күрә аңа базарда күбрәк Мәхмүт Илмурзин артыннан күзәтү йөкләтелгән иде. Икенче көнне ияреп йөргәндә үк, көтелмәгән хәлгә тап булды ул.

Ул көнне базарга әллә каян гына бик сәер бер карт килеп төште. Чегән дә түгел үзе, ә йөзе, куллары барыбер каракучкыл. Чәче озын, мәгәр бөтәрләнеп тормый. Иңбашына тутый кош утырткан, күкрәгенә агач тартма аскан. Күчәрбайныкылар көн саен тутый кош күреп торамыни, билгеле инде, бөтен кеше шул карт тирәсендә. Әле аның тутый кошы да теләсә кайсы кешегә язмышын әйтеп бирә торган күрәзәче икән ләбаса. Ышанмасаң, әнә кара: картның тартмасына йөз төрле язмышлар язылган кәгазь кисәкләре кисеп ташланган. Күрәчәгеңне беләсең килә икән, биш тиенеңне түлә дә тутый кошка сызгыр. Ә ул хуҗасының иңбашыннан сикереп төшә дә, әүвәл бик борчулы, бик тәкәббер кыяфәттә йөргән булып, бер кәгазь кисәген томшыгына ала да синең учка суза. Аннары теләсәң кычкырып укы ул кәгазьне, теләсәң эчеңә йот.

— Ой, молодец, Гоша, ой, молодец! — дип, теге сәер карт үзенең тутыена рәхмәт әйткән була, авызын киң ачып яңа кунакларны дәшә. Ул елмайган саен, авызында дүрт алтын теш ялт-йолт итеп куя.

Шушы карт тирәсеннән ачык авызлар көне буе диярлек өзелмичә торды. Инде базар ябыла башлагач кына, ниһаять, таралдылар. Менә шул чагында, әллә каян сикереп, карт янына ике бертуган Илмурзин килеп чыкты. Мәхмүте чүл-

мәк хәтле йодрыгы белән картка китереп сукты. Карт эһ тә итми җиргә авып төште, тутый кошы нәзек пискелдәп бер як читкә очты. Илмурзиннарның Маннуры картның муенына тагылган күн янчыкны түшеннән тартып алды. Ә Мәхмүте картның авызын каерып ачты да дүрт алтын тешне төбе-тамыры белән каерды да алды. Әмир искә-аңга килеп алга ыргылганчы, Илмурзиннар базар янындагы әрәмәлек эченә кереп чумган иде инде...

— Ачык авыз син, җебегән, ачык авыз! — дип, эт урынына сүкте аны Дини.— Мин белеп торам бит, Каюм бандасыннан алар, Каюм бандасыннан...

Илмурзиннар йорты янындагы ерымда өч төн буена тозак корып яткан булдылар, өч тиенлек тә файда табылмады. Һәр кич саен кара төн уртасына кадәр Габбас өздереп гармунда уйнады, Зәйтүнәсе гел моңланып чыкты. Ә Илмурзиннар үзләре, бөтенләй көтмәгәндә, Дини рәис янына ярдәм кулы сузып килде.

Әмир инде Төркәйгә кайткан һәм, Зифа белән бергәләп, шактый соңарып булса да, көзге сөрү үткәреп азаплана иде. Әмир үзе, билгеле инде, төрән артына баскан, ә кеп-кечкенә Зифа атлый-йөгерә Афоньканың авызлыгыннан тартып барган була. Афонька күндәм ат, Зифа кызулатып бармаган булса да сыңар төрәнле сабанны тартыр иде әле. Ләкин кәҗәсеннән бигрәк мәзәге дигәндәй, Зифаның юлдаш булып килүе барыбер ярап тора. Кызының кул арасына керергә тырышуы — Әмиргә зур юаныч.

Шул чагында ерактан ук сөрән сала-сала тау сыртыннан түбәнгә таба Дининең йөгереп төшкәне күренде.

— Әм-мир! Әм-мир бырат! Бетте, бетте минем башлар!

Эштән тукталдылар да Зифа белән Әмир икесе тиң, көтелмәгән кунакка текәлеп, таң калдылар. Дининең тез башлары ләмгә буялып беткән, үзе тиргә баткан. Юлда йөгергәндә ул берничә мәртәбә абынып егылгандыр инде. Хәзер дә күзләре анык кына берни күрми сыман. Төссез, нурсыз, яртылаш рәвештә кабак астына качкан.

— Шура лапасыннан ике айгырны да урлап чыкканнар бит,— дип башлады ул сүзен, чабыштан кайткан юртак шикелле гыж-гыж килеп.— Ике атны да, Әмир. Шул хәсис Илмурзиннар эше генә бу, шулар эше. Безнең засада корып ятканга үч алганнар алар. Атларны тапмасак, минем үземне алып китәләр бит. Йә, нишлибез, Әмир?

Шөбһәле хәбәрдән соң Әмир үзе дә кырау суккан җиләк үсентеләре сыман коелып төшкән иде, авыз да ача алмыйча баганадай басып торды.

— Эзлибез,— диде ул тик бераздан гына, нык, тәвәккәл итеп.— Эзлибез. Бу шул Илмурзиннар эше булырга тиеш,

моңа шигем юктыр. Барабыз да өсләренә басып керәбез. Каталашкага ябып койрыкларын кыссак, айгырларны кайтармыйча чаралары калмас...

Ни галәмәт, Дини белән Әмир, ике-өч ир ияртеп, өйләренә барып кергән чакта, Мәхмүт Илмурзин япа-ялгыз булып чыкты, өстәвенә әле йоклап ята икән. Ирләр аның өстенә атланып кулларын бәйли башлагач кына, ниһаять, айныды ул. Айнуын айныды, мәгәр, күзләрен акайтып, бер гаепсез кеше шикелле сорашуын белде:

— Ни гөнаһым өчен, Дини? Нигә рәнҗетәсең?

Мәхмүтнең куллары бәйле, ә Динигә җан кергән иде инде.

— Барысы өчен дә, зараза, барысы өчен,— дип, урынында әтәч сыман сикергәләп, биеп кычкырды ул.— Теге тутыйлы картның алтын тешләре өчен. Миннән урлап киткән ике айгыр өчен.

— Нинди айгырлар ул тагын, Дини? — Бу юлы Мәхмүтнең тавышы усал яңгырады, карашына да зәһәрлек бәреп чыкты.— Мин алтын тешләр урлавымнан танмыйм, мәгәр син үзеңнең ике айгырыңны минем сыртка такма. Аларына минем кысылыш юк.

— Ярар, таныма монда, таныма. Мәгәр Бәләбәй төрмәсенә илтеп, андагы тимер стан өстенә сузып салыйк әле. Анда моннан ун ел элек эшләгән гөнаһларыңны да танытырлар синнән. Шунда сөйләшербез.

— Ярар, Дини агай,— диде Мәхмүт, һич тә көтелмәгән күндәм тавыш белән.— Төрмә икән, төрмә. Давай, апкит.

Урамга чыгып арбалар өстенә җайлап утырдылар. Юл таудан түбәнгә, Бәдрәш буена иде. Атлар тыелып кына төшә башладылар. Асылкошның кулга болай бик җиңел генә килеп эләгүе ир-егетләрнең сизгерлеген юып алды бугай. Берәү дә көтмәгәндә, Мәхмүт кинәт бүре тавышлары чыгарып улагандай итте. Өннәрен җуйган атлар, күзләрен тондырып, аска томырылды. Секунд саен тизлек арта башлады, ис-акылын җуйган ирләр үрәчәләргәябышты. Ә Мәхмүт шул чагында арбадан сикереп төшеп калды да таудан түбәнгә таба тәгәри башлады. Аның эзеннән үк арбадан сикергән Әмир Мәхмүт артыннан йөгереп карамакчы иде дә, тегенең галәмәтләрен күргәч, авыз ачып, карап кына торды.

Юк, аягына басарга, йөгереп качарга җыенмады Мәхмүт. Арбадан бүкән сыман гына сикереп төшкән карак әүвәл таудан түбәнгә таба агач әрдәнәсе кебек тәгәрәде-тәгәрәде дә, берзаманны керпе шикелле йомарлана башлады, ә аннары инде тәгәрмәч йә булмаса йомгак рәвешен алды һәм шул көенчә Бәдрәш елгасы буендагы таллар янына җиткәнче тәгәрәп кенә төште. Моны куып җитеп булмый, мылтыктан атып та зыянларлык-мазар түгел иде.

Әлеге «аулары» да шул рәвешчә бушка гына үтеп киткән иде, ике көннән соң, кичен, шура йортына Илмурзиннарның өлкәне үзе килеп керде.

— Айгырларың урамда, кабул итеп ал. Без аларны Ахун авылыннан табып алып кайттык. Кемнәр кулыннан, анысын бездән көтмә... Үзләре белән бераз якалашырга да туры килде менә.

Илмурзин йөзенең сул ягы беләнрәк борылып басты. Аның колак төбе, чыннан да, гөмбә сыман күгәреп чыккан иде. Тагын да таптанып торуны артыксынды бугай, Илмурзин ишек тоткасына кулын сузды. Ләкин ишекне эткәнче, яртылаш борылып, җилкә аша соңгы сүзен әйтте:

— Илмурзиннар үз авылыныкына тими, гөнаһлама безне, Дини абзый.

## 5

Каюм каракны да советныкылар эзләп таба алмады, аны үзенең бер яраны килеп сатты.

— Каюмның Бүздәктәге милиция ләчәнниге йөри торган айгырга күзе төшкән. Атнакич төнлә аны урлаячак.

Каюмның җене кузгалса, губернаторның хәтта үзеннән дә ат урлый торган ташбаш кеше булуын беләләр иде белүен. Ләкин тагын бер кат инану, сынау өчен сатлык җан хәбәренә кул гына селтәгән булдылар.

— Каюм сине үзе җибәргән бит, беләбез без сезне. Бүген Каюм фәлән кешене талый, дип, милицияне шунда өстерәсез дә үзегез башканың утарын йә кибетен ялап чыгасыз.

— Ипи йөзен күрмим, валлаһидыр менә,— диде сатлык җан рәнҗүдән бигрәк ярсу тавыш белән.

— Ә аны безгә килеп сатудан сиңа нинди мая?

— Бернинди мая юк, мәгәр Каюмнан үч алам. Без соңгы өч-дүрт атнада гына да Дүртөйленең мануфактур кибетен, Уфада Глоберның ике алтын кибетләрен талап кайттык. Глобер кибетләреннән алган алка-йөзек, беләзек-муенсалар үзләре генә дә бер чиләк бар иде. Ә Каюм шулардан безгә сыңар алка булса да өлеш чыгармады. Кырхабурланып һаман байлык җыя да байлык җыя. Аның пирвай япәтниге Кылый Гата әйткәннәр хактыр инде. Каюм Әфган чиге аша Төркиягә чыгып качарга әзерләнә икән. Шәкүрне эләктерделәр, мине буарга салынган элмәк тә көннән-көн тарая бара, дип әйтә, ди.

— Ә алай Төркиягә чыгып качарга җыенгач, Бүздәк милициясенең айгыры аңа ник кирәккән инде?

Мондый сабый төчкереге сыман риясыз сорауга каршы сатлык бәндә ихахайлап көлде.

— Эх-ма, карендәшләр, бигрәк беркатлы сез. Каюм карак дәже әҗәл түшәгенә менеп яткан булсын, мәгәр берәр

кайда ул күрмәгән берәр шәп ат калганлыгын ишеттеме, түшәгеннән сикерә дә тора. «Давай, апкайт, бер атланып карыйм». Ат дигәндә бөтен дөньясын сукыр бер тиенгә дә санамый торган алабай бәндә бит ул…

Атнакичкә күп калмаган иде, иң сыналган, сугыш юлы үткән коммунистларны гына Бүздәкнең үзенә туплый башладылар. Мондый «бәхет» Әмир белән Динигә дә эләкте. Юлда Килем авылы аша узасы бар иде. Аңа якыная башлагач та, очына-очына Дини телгә килде:

— Җантурин бай утары яныннан узабыз бит. Убыр китте, урыны калды дигәндәй, үзе чыгып сызды, аның дуарислар кебек йорты сәвит власына торып калды. Хәзер ни урнашкан икән анда, карап үтик әле.

Әмирнең күңелен, әле Җантурин дигән сүзне ишетүгә үк, аҗаган уйнагандагы яктылык сыман өзек-өзек булып, ялт-йолт килеп, әллә никадәрле хатирәләр өермәсе күмеп китте. Бабасы Рәҗәп белән беренче кат монда килгән вакыт, Җантуринны күрү, аның колак артларына бөтереп салган мыек чылгыйлары, ломовой булып йөргән ирекле, иркен чаклар — бөтенесе дә гаярь җәйрәннәр елдамлыгы белән күз алдыннан йөгерешеп узды. Сагынырлык гүзәл дә вакыт түгел иде югыйсә, ә әллә нишләп Әмирнең йөрәге чеметеп-чеметеп куйды. Яшьлек дигән байлык һәрвакыт әнә шулай кадерледер инде…

Элекке алпавыт ихатасына килеп кергәч, Әмир үз күзләренә үзе ышанмыйча, тышауланган ат шикелле тораташтай калды. Алпавыт сарае каршындагы фонтан, аны тирәләп алган ап-ак сыннар, сарай түбәсенең почмакларында утырган каравыл манаралары — барысы юкка чыккан. Сарайдан бер як читтә тезелешеп торган келәтләрне, иң гаярь чабышкы-аргамаклар тотылган араннарны, Җантурин кыш көне дә төшеп коена торган буа урыннарын — бөтенесен җимереп бетергәннәр.

Элек гаскәр сыман тип-тигез булып тезелешеп утырган зирек агачлары, канәфер, шомырт, сәрви куаклары урыны-урыны белән йолкынып, сынып беткән. Сарайның түбәсендәге калайлар ике урыннан умырылып чыккан. Соңгы тапкыр кайчан акшарланган булуларын да оныткан сарай диварлары, хәзер кай урында күгәреп, кай урында җимерелеп, еллар буе юынуның ни икәнен дә белмәгән сукбай чырае шикелле, ала-кола булып ямьсезләнеп тора. Тәрәзә пыялаларының яртысы гына исән, алардан җил сызгыра, ике ишек күгәненнән каерылып төшкән. Мәгәр шул ике ватык ишек өстендә күзеңә керәм-керәм дип чекерәеп торган дилбегә буе язу: «Гасырлар буена сузылган йокыдан айнып индустриаль бөек державага!»

«Болай итеп, булганны кырып-җимереп барып җитәрсең, тот,— дип ачынып сүгенде Әмир эчтән генә.— Элек Җантуринныкы булган йорт түгел бит бу хәзер. Атай малын катай, валлаһи, шул инде. Йа Ходаем! Мондый сансызлыкка ничек ирек куйдың?!»

— Ну, яшәп тә караган соң Җантурин! — дигән Дини тавышы гына уйларыннан аерып алды аны.— Бер генә көнгә булса да шушы йортка кереп, Җантуринның бәллүле караватларында йоклап чыксаң иде!

Үзенең артык хискә бирелеп китүен чамалады, ахры, Дини ашыга-ашыга күзгә ком сибә башлады.

— Ничава, бу болай да безнең байлык инде. Аждаһадай убыр авызыннан маминт каерып алдык. Ярлы пырлитарьят балалары укый монда хәзер. Шулар Җантуринның караватларында йоклап рәхәтләнә. Шул кирәк ул убыр дуарянга!..

Әмир тагын, базга төшкән сыман, хатирәләр диңгезенә чумды. «И сансыз да, очсыз да соң бу кеше гомерләре! Менә шушы Җантуриннарның Сәетгәрәй дигәннәре хакында моннан унбиш-егерме ел элек ничек авыз суларын корытып сөйли торганнар иде! «Сәетгәрәй әллә ничә калада мануфактур тота, кибетләре хәтсез, ә үзе әрлән-йомраннар сымак бер дә кырхабур түгел. Әнә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен төзергә генә дә кесәсеннән утыз мең тәңкә акча чыгарып биргән, диләр. Ул үзенең эшчеләрен дә урыс сымак изеп тотмый икән». Әйе, хак иде бит ул өермә шикелле бөтен Казан, Уфа губерналарын шаккатырып айкап йөргән сүзләр. Үз милләтен укымышлы итеп күрәсе килгәч, утыз меңен дә җәлләп тормады бит. Шәп нәселле сыер алты тәңкә тирәсе бәяләнгән заман. Шуннан чутлап кара. Ә Сәетгәрәй аннан тыш нихәтле акчасын Уфадагы Җәмигъ мәчетне, Ырынбурдагы Кәрвансарайны яңартуга чыгарып салган, диләр. Сәетгәрәй, Диничә уйласаң, халыкны талаучы убыр дуарянмы, әллә үзе савым сыерымы? — бизмән тап та үлчәп кара инде. Ә яңа власть дигәннәре төкереп бирде аңа. Уфадагы мануфактурларын, кибетләрен җимереп бетергәннәр. Ул яшәгән йортка ниндидер кәмитит кереп оялаган, Сәетгәрәй үзе урамда торып калган, ди. Мәгәр яңа власть дигәннәре аны гына да азсынган, күрәсең. Сәетгәрәйне үзе төзегән кайсыдыр бер мәчет буена бастырып атмакчы булганнар, ди. Шуннан соң хәбәре юк. Әллә чынлап та атканнар инде аны, әллә Себер ягына качып өлгергән ул? — моны эт тә белми. Ә ул, бичара, халык халык ди-ди, күпме җан аткан бит! Вәт хезмәт итеп кара син бу халыкка, бөкрең чыгарып кара...»

Кабат юлга чыккач, Дини Әмир өчен бөтенләй дә ишетмәгән яңалык ачып салды.

— Ә син беләсеңме соң, кордаш, Каюм карак дуарян Җан-

туринны отыры сөймәгән, отыры талаган бит. Ни өчен дисеңме? Мыеклары өчен. Икесе дә бер үк төрле мыек йөрткән алар. Менә мондый озын. Очларын колак артларына кыстырып йөрткәннәр, ди. Каюм карак Микулай армиясендә бер янаралда кучер булып йөргән. Теге янаралның мыеклары тач менә шулай озын булган икән. Каюм да, Әбзәнгә кайткач, менә шундый мыек үстереп җибәргән. Угрылык юлына баскач, мин хәзер каракларның янаралы булам, дип шәрран ярган, имеш. Ә берзаманны Җантуринда да шуның төсле мыек күреп алгач, үчләшә башлаган инде бу. Бер үк губернада ике янарал булмый, мин Җантуринны моннан иблис сымак куам, дип әйткән, ди. Менә шулай, кордаш. Кан дошманлыкка мыек та сәбәп була ала икән...

Бүздәктә аларны милиция башлыгы үзе каршы алды. Кырык яшьләр чамасындагы, бик коры холыклы, аз сүзле, Янгуразов фамилияле бер ир икән. Кемгә дә булса сорау биреп торырга урын калдырмады, кырт кистереп үз ниятен әйтте.

— Операция белән башыннан аягына тикле үзем камандывать итәм. Мин приказ бирмичә берегез селкенмисез, берегез ут ачмыйсыз. Кайчан нишләргә икәнен мин үзем хәл итәм.

— Ярар, үзең икән, үзең. Аның каравы Каюмны ычкындырсаң, безгә җавап бирәсе булмас,— диделәр дә Күчәрбай, Ахун, Килем, Түреш, Шыгай авылларыннан килгән коммунистлар милиция бүлеге ихатасы буенча таралып утырдылар. Бераздан Янгуразовның ярдәмчеләре чыгып «сугышчыларны» өч отрядка бүлде. Шулар ук алда торган бурычны да азмы-күпме аңлаткандай итте.

— Ат урларга Каюм күп очракта үзе генә килә. Мондый эшне бер дә башкаларга ышанып тапшырмый ул. Мәгәр аның бүген берүзе генә килүе бик икеле. Янгуразовның айгырын алып чыгарга лапаска-мазар берүзе килеп керсә дә, Бүздәк башында йә булмаса Кидәш ярында яраннары көтеп торуы бар. Шуңа күрә өч катлы чылбыр ясап тозак корабыз. Бер отряд Биек Чагылтау сыртына менеп ята. Икенчесе — Кидәш буенда. Ә өченчесе инде, иң көчлесе, Каюмны Янгуразов айгыры ябылачак амбар тирәсендә көтеп торыр...

Әмир әнә шул иң көчле отрядка эләккән иде, шуңа күрә Каюм каракны тотарга дип кулланылган барча хәзерлекхәстәрлекне башыннан аягына чаклы күреп-күзәтеп торды.

Эңгер-меңгер төшеп күз бәйләнә башлагач та, гаярь, шәп айгырын Янгуразов шәхсән үзе бөтен Бүздәк буенча әйләндереп, аны Колчакка ияреп киткән бер бай лапасына илтеп япты. Калын тимердән ясаган эшермәләрне ике ачкычлы әллә нинди сәер йозак белән бикләп куйдылар.

— Каюм дөньяда мин ачкыч яратмаган йозак юк, дип әйтә, ди. Монысына теше үтәр микән, карап карыйк әле,— дип, Янгуразов үзенең максатын белдереп тә куйды.

Качак бай келәтен тулгамага алып оста яшеренделәр. Нәкъ капка турысына Янгуразов үзе, аның янәшәсенә ике мәргән ятты. Ихатаны кисәк яктырту өчен дип ике-өч якта әллә нинди лампалар көйләп куйдылар. Салам да кыштырдатмыйча сак тору башланды. Җәя сыман киерелгән түземлекне сынап, минутлар артыннан минутлар акты, ә берзаманны инде төн уртасы да үтеп китте. Хәрәкәтсез көе ятудан сакчыларның тәннәре сызлана башлады, түземлекләре дә корыды.

— Каюмның шымчылары адым саен бит аның. Безнең тозак турында әллә кайчан хәбәр иткәннәрдер инде,— диде төнге караңгылыкта Янгуразов янәшәсендәрәк яткан берәү.

— Каюм каракның тактикасын начар беләсез сез,— дип акыл сатты башлык Янгуразов.— Безнең баштук үзебезне ачмаячакны, аны келәт ишегенә хәтле җибәрәчәкне Каюм карак белә. Ә аннары инде үзенең кулларының осталыгына и ахырда, айгырны каптырып алса, аңа ут ачмаячагыбызга да ышана ул. Айгырны каптырып алса, аңа сикереп кенә менмәкче дә, аннары безгә койрык күрсәтмәкче. Менә аның тактикасы нинди! Но бит без дә юеш борын түгел. Әтәйләр безне күәс апарасыннан гына ясамаган. Килсен, килсен, Каюм. Без үзебезнең кем икәнне күрсәтербез әле!..

Янә минутлар артыннан минутлар үтә торды. Сакчылар инде Ходайдан Каюм каракны ялвара башладылар. «Җибәр инде Каюм каракны безгә, йа Ходаем! Кил инде, Каюм җаныкаем, интектермә безне, кил инде син!»

Биек Чагылтау өстеннән таң сызыла башлагач, ниһаять, Карга-куак күле ягыннан атлап килгән ике-өч кешенең аяк тавышлары ишетелде. Барча сакчыларның гәүдәсе янә җәя тәтәсе сыман киерелде, сулыш алулар ешайды, тамак төпләре кибеп чыкты. Һәрберсе карашы белән җирне бораулардай булып келәт алдындагы кечкенә мәйданга төбәлде.

Килүчеләр, чыннан да, өчәү генә икән. Икесе келәтнең ике почмагына барып сыенды. Каюм карак, парадка чыккандай төп-төз атлап, келәт ишеге төбенә килеп басты. Әллә каян килеп кулларында дүрт-биш төрле ачкыч аламасы пәйда булды.

— Ут ача күрмәгез! — дип ысылдады уртада Янгуразов.— Каюм йозакларны ничек ача икән, башта шуны белик.

Шырпы сызарлык та ара узмагандыр, Каюм кулындагы йозак келт итте дә тимер эшермәләр җиргә шуып төште. Тагын бер мизгел узар, ә аннары инде ишек ачылыр һәм Каюм карак ялт итеп келәт эчендәге караңгылыкка чумып

юкка чыгар сыман иде. Нәкъ шул мизгелдә, колакларны ярып, Янгуразовның әмере ишетелде:

— Пл-ли, мать якасын!

Тәртипсез чыккан ату тавышлары берсен-берсе узып яңгырады. Келәт почмакларына поскан ике карак киселгән агач сыман гөрселдәп җиргә ауды. Ә Каюм егылмады, сыңар аягына тезләнсә дә, ул әле һаман уң кулы белән ишек тоткасына тотынып тора иде. Әмма икенче кулы белән ул инде күкрәгенә ябышкан, бармаклары аша кан тамчылары җиргә тып-тып тама.

Янгуразовны һәвәсләнү, комар хисе чолгап алды, күрәсең.

— Атуны туктатыгыз! — дип кычкырды ул, үз-үзен белештермичә.— Утларны кабызыгыз, утларны! Каюмны тере килеш эләктерергә кирәк!

Шул мизгелдә үк бердәм кабынган утлар яктысында Каюмны күрде дә Әмир хәйран калды. Чукынып кына китсен, Каюмның колак артына кыстырып куелган озын мыеклары нәкъ Җантуриннныкы белән бер икән бит. Каюм килеш-кыяфәте белән генә оттыра. Уртача буй, какча гәүдә, маңгай өстендә ике яклап пеләшләнә башлаган сирәк чәчләр, түгәрәк кара сакал. Әмир шуннан артыгын күрергә өлгермәде.

— Акылың котмы, Янгуразов? — дип беркем көтмәгәндә усал кычкырды да, Каюм, болан сымак сикереп, келәткә терәлеп торган киртәләр артында юк та булды. Каны тамып торырдай булып яраланган кешегә бу кадәрле көч-куәт каян килгән диген?!

— Артыннан куа чыгарга, артыннан! — дип Янгуразов янә чираттагы әмерен ыргытты, әмма кисәтеп куюны да артык санамады.— Атмаска Каюмга, атмаска! Барыбер бездән качып ерак китә алмый.

Юк шул, ерак качты Каюм. Бүздәк урамнары артта калды. Алда — анда-санда, эреле-ваклы инеш-күллекләр белән ермаланган кыр да, шул кыр башында көзен-кышын иген көлтәләре алып килеп сугар өчен корылган, өсте ябулы әвенлекләр иде. Ул әвенлекләрнең түбәләре шәп-шәрә баганалар өстенә генә утырып тора, һич югы бер генә ягыннан булса да дивар капламый аларны. Һәммә тараф уч төбендәгедәй ачык күренеп тора, адәм кереп кача алырдай бертөрле тишек юк иде бер уйласаң. Мәгәр юк, нәкъ менә әвенлекләргә таба йөгереп киткәч, кибән өстенә төшкән инәдәй юкка чыкты Каюм.

Паровоз морҗасыдай гыжылдап Янгуразов килеп җитте. Авызында адәм рәтле сүз юк.

— Кая качырдыгыз Каюмны, анагызны сатыйм?! Өстән хет тере, хет үле, дигән фәрман булды. Аны кулдан ычкындырган өчен, мин сезне берәм-берәм тотып атам бит!

Ирләр, бер әвенлек тирәсенә җыелышып, һәм, көтүдән аерылып киткәч, усал бүре каршына килеп чыккан маллар сыман, ни кылырга белми тора иде. Шул чагында каяндыр әвенлек мачталары арасыннан авыр гыжылдаган тавыш ишетелде дә бераздан, гөрселдәп, җиргә Каюм каракның гәүдәсе килеп төште. Янгуразов алтатарын төбәп аның янына бүре сыман сикергәләп килеп җитсә дә, инде бик соң, Каюм карак дөнья белән алыш-бирешне өзеп өлгергән иде...

## 6

Әмир читтә «хөкүмәт эшен куып» йөргән чакта, Гөлтуташ та, билгеле, өйдә тик ятмады, үзе дә аңламыйча-нитмичә совет тегермәненә чиләктән су койды.

Беркөнне кич, инде деготь сыман куе караңгылык яткач, боларның өенә бөтенләй дә көтелмәгән кунаклар килеп керде. «Бүген кайтмасмы, бүген кайтмасмы?» дип, Гөлтуташ үзе кич саен ирен көтеп утыра, шуңа күрә ул капка-ишекләргә келә элү гадәтен әллә кайчан ук оныткан да иде. Бу көнне дә ул капка шыгырдап ачылуга бер дә аптырамады, ләкин болдырда аяк тавышларының күп булып шакылдавын ишеткәч, кулына тоткан энә-җепне итәгенә куеп һәм сагая төшеп тыңланырга мәҗбүр булды. Әмирнең абыйсы Әбелсаттар белән Хәби яшьтәшенең, әче бал-мазар эчеп алдылармы, шулай икәүләшеп килеп иренә бәйләнә торган гадәтләре бар иде. Бүген дә шулар җан телгәләп йөриләрме әллә?

Өйалдында капшанган шикелле акрын гына баскан һәм тыенкы чыркылдаган хатын-кызлар тавышы ишетелде. Шул чагында гына Гөлтуташның җанына җылы йөгерде. Күршедәге хатыннар аларга йомыш-фәлән төшеп бик тә сирәк керә, Әмирләргә караганда алар үзләре баерак. Болай соңарып йөрүчеләр кем булыр соң?

Гөлтуташ урыныннан кубып ярты араны да үтеп өлгермәде, дәртле генә тартып ишек ачылды да, берсен-берсе төрткәли-төрткәли, өйгә җитлеккән дүрт кыз килеп керде.

— Кабул итәсезме безне, Гөлтуташ апа? — дип сәлам бирүчесе үзләреннән ике-өч йорт аша гына яшәгән Җиһаншаның кызы Зәйнәпбикә иде.

— Бәрәч, таптың син сүз, бәрәч,— дип җавап кайтарса да, Гөлтуташ бөтенләй коелып төште бугай. Анадан-тума көенчә су коенып яткан хатын-кыз өстенә чит-ят ир-ат килеп чыккан чакта, ул, үзе дә тоймый-аңламыйча, иң элек гаурәтен түгел, ә имчәкләрен каплый. Гөлтуташ та шулай, иң элек чәчен-башын түгел, итәкләрен һәм бер дә кирәксезгә өстәл өстен сыпыра башлады. Әмма барыбер бертуктаусыз сөйләнүен белде.

— Ничек инде кабул итмик ди? Сездәй хур кызлары безнең тупса аша көн дә узып тормый. Керегез, бәбкәччәйләрем, зинһар, керә күрегез.

Хуҗабикәдәге тәмле теллелек кунак кызлар күңеленә сары май булып ятты, ахры, бер-икесе, алга кыю атлап, тәрәзәләр буена куелган эскәмия читендә урын алды. Килен булып төшкәннән соң ничә ел яшәсә дә, Гөлтуташ әле һаман төркәйлеләрнең һәммәсен дә йөзгә танып бетерми иде, шуңа күрә кунакларның үзләренә бик үк сиздермәскә тырышып күз йөгертеп чыкты. Эскәмиягә барып утырганнары урамның каршы ягында, алардан чапырышрак йортларда яшәгән Гыйниятулла белән Зәйни кызлары. Берсе Сәҗидә исемле, ахры, икенчесе Маһруй. Ә тегесе, Зәйнәпбикә күләгәсенәрәк ышыкланып ишек төбендә торганы, Гәрдән кулак кызы Гөлсем түгелме соң? Әстәгъфирулла, бу кулак кызына кайсы ярлы, кайсы әз-мәз хәлле крәстиян балалары янында, җитмәсә, Әмирләр йортында нәрсә калган инде, әстәгы?!

Шушы Гөлсемне күрү тәэсир итте бугай, Гөлтуташ әле һаман үзен кулга алып бетерә алмый иде. Шулай да калган ике кыз каршына урындыклар китереп куярга барыбер ушы җитте.

— Утырыгыз, җаныйларым, әйдә, утырыгыз.

Урындыкларга җайлап урнашып алгач, сүзләрен сәйлән сыман сайлап тезә-тезә, әлеге дә баягы шул Зәйнәпбикә башлап җибәрде:

— Тагын бер кыз алып кайткансың дип ишеттек, Гөлтуташ апа. Ә үзебез күршеләр генә булып яшәсәк тә, ни кереп күрә алганыбыз юк шул баланы, ни үзеңне котлаганыбыз юк. Үзебезгә кайчан андый бәхет эләгәсен бер Ходай гына белә. Кеше балалары ничек була икән, әйдә, күрсәт әле.

Кызларның һәммәсе дә тыенкы гына көлешкәндәй итте. Ә Гөлтуташ ике айлык нарасый Вәзирәне күтәреп килгәч, бер үк вакытта сокланулы да, моңсу да караш белән барысы тиң аңа текәлделәр. Вәзирә нәни иреннәрен бөрештереп, кечкенә борыны белән сызгыра-сызгыра йоклап ята иде, аңа эндәшүче, кагылучы кызый табылмады. Гөлтуташ шул чагында гына ныклап игътибар итте: кызларның һәркайсына бүген ким дигәндә унҗиде тулып киткән бит инде. Шундый җитлеккән кызларның сабый бала күрергә дип керүләре гаҗәпмени!

Кабат урындыклар өстенә утырышкач кына, кызлар Гөлтуташны мактый башладылар.

— Бигрәк сылу бала апкайткансың, күз тимәсен!

— И-и, сез Әмир абый белән матур итеп яши беләсез дә инде!

— Вәзирәгә күз генә тимәсен дә, берүк бәхетле генә була күрсен инде!

Мондый изге теләкләрне, бигрәк тә Әмирне мактап-олылап телгә алуларын Гөлтуташның инде күптән ишеткәне юк иде. Әллә шуңа, күзләренә яшьләр бәреп чыкты.

— Шулай булсын инде, бәхетле була күрсен.

— Амин, амин,— дип, кызлар яңакларына бармак очларын да тигергәләп алды.

Шуннан соң үзләре дә сизмичә тын калдылар. Аралыкны янә Зәйнәпбикә өзде:

— Син ачуланмасаң, без китмибез әле, күрше җиңгәчәй,— дип башлады ул Гөлтуташ колагы өчен бөтенләй дә сәер сүзләр белән.— Бүген Түбәночтагы Гапсаттарларда аулак өй икән дип ишеткәч, шунда борын төртеп караган идек тә, Гапсаттарлар өе җыен менә шундый кәтүк белән тулган. Олы башыбызны кече итеп ничек шунда утырыйк ди инде? Сездә йә ике көннең берендә, йә атналар буена аулак өй икәнне беләбез. Шуңа монда килдек. Син бездән әллә ни олы түгел, кистереп әйтсәң, чордаш дияргә дә була. Серләр серләшеп бер утырыйк әле.

Гөлтуташ янә коелып төште, ләкин монысы инде — җылы сүзләрдән эреп китү иде.

— Нинди чордаш булыйм ди инде мин, кызлар? Өч бала анасы ла инде мин хәзер, карт пәри лә.

— Йә, йә, кылтыйкланма инде, Гөлтуташ апа,— дип, чапырыш күршедәге Гыйниятулланың кызы Саҗидә дә сүзгә кушылып китте.— Бөтен кыз да синең төсле пәри булсын иде әле ул. Синеке шикелле чибәрлек миндә булса, мин Төркәй егетләренә әйләнеп карамас та идем.

Бөтенесе бердәм кузгалып гөр-гөр көлештеләр. Бер аралыкта Гөлтуташ көлә-көлә генә сорап куйды:

— Алай булгач, синекечә әйтсәм, мин сезнең Әмир абзыегызга ябышып чыгып ялгышканмын инде?

Тагын көлештеләр. Ләкин бу юлы инде көлүләрне Саҗидәнең җитди сүзе бүлде:

— Юк, бер дә хаталанмагансың, кемгә ябышып чыгарга икәнен дөрес чамалагансың син, Гөлтуташ апа. Әмир абый бөтен кешегә дә әйбәт тормыш тели, изге җанлы бит ул. Тик нишләптер тормыш үзе аңа гел-гел артын куя. Белмим инде, әллә ничек шунда. Әмир абый сабагыннан өзелгән төнбоек шикеллерәк ул. Җил аны әле тегеләй, әле болай куа. Ә ул үзе һаман килеп сыенырдай бер җылы яр тапмый. Шуңа күрә аңа гел тырышып, гел тырмашып яшәргә туры килә. Юк, Әмир абый бөтенләй башка чут бит. Ул авылга берәү. Аңа тиктомалдан тел-теш тидерерлек түгел.

Шушы сүзләрне тыңлаганда, Гөлтуташның йөрәге парә-парә килеп бәргәләнде, ул бөтенләй эреп китә язды. Карале син. Ул бит әле моңа кадәр Әмирне авылдагы барча халык дошман күрә, берсе дә сөйми, аны эт типкесе итә, дип уйлап йөри, хәтта әле кызгана да иде. Ә бактың исә авылда Әмирне якын итүчеләр дә, аның хәленә керергә теләүчеләр дә бар икән бит. Бу яшүсмер Саҗидә берүзенең генә бәясен-фикерен тезми. Үз өйләрендә, күршеләрдә, яшьләр арасында ишеткәннәрен әйтеп салды ла ул. Димәк, Төркәй халкы өчен кирәк аның Әмире, кирәк, кирәк!..

Зифа балакай, әлбәттә инде, әле кызлар кергәч үк торып утырган иде. Гөлтуташ әле генә күргән шикелле аны кочып алды, назлап кына эш тә куша белде.

— Яз көне йомырка басарга утырган ана каз шикелле булмыйк, балакаем. Самавыр әле суынып өлгермәгәндер. Шулай да барыбер беркадәре кызулатып ал да матур апаларың белән утырып чәй эчәрбез...

Икенчеме, өченчеме чынаякны бушаткан чагында, кызлар инде җырга күчкән иде. Бу гамәлне, иң беренче булып, Зәйнәпбикә башлап җибәрсә дә, биш-алты минуттан соң ук дилбегә очлары Гөлсем туташ кулына күчеп бетте. Гөлтуташ шаккатып утырды: әлеге кызый гаҗәеп моңлы тавышка ия булып кына калмаган, аның өстенә ул әле әйтерсең лә җиһандагы барча җырларны, мөнәҗәтләрне, бәетләрне яттан белә иде.

«Сак-Сок» белән «Морадым» бәетләрен җырлаганда, кызларның барчасы да, Гөлтуташ үзе дә көйгә күмәк кушылып утырганнар иде. Ләкин Гөлсем бервакытны «Зөлхәбирә» бәетен сузып җибәргәч, кызлар, бер-берсенә ым кактылар да бердәм шым булдылар. Гөлтуташ боларның бөтенесен дә шәйләп өлгергән иде инде, ул да тын алырга да курыккан кеше шикелле моңга чумды. Ә өй эчендә үзәкләрне өзеп, бәгырьләрне телеп, Гөлсемнең саф чишмәнекедәй тавышы гына акты.

Зөлхәбирә күлмәк тектергән,
Итәгенә ука тоттырган.
Мостафа ла мулла, йөзе кара,
Кәртле уйнап, кызын оттырган...

Йөрәкләрне, бәгырьләрне телеп бәет агыла. Әнә инде Гөлсем Зөлхәбирәнең үз-үзен суеп үтерүе турында бәян итә. Күңелдәге хисләр көзге болыт сыман тулып ташкан. Өстәл өсләренә капланып, идәннәргә тәгәрәп күз яшьләренә ирек бирәсе, илереп-илереп елыйсы килә. Ләкин кызлар, ике яңаклары буйлап аккан күз яшьләрен сөртергә дә куркып, ахи-

рәтләренең моңлы тавышын тыңлыйлар. Алар инде күңелләре, хыяллары белән еракка-еракка киткән…

Гөлсем әле җырдан туктагач та, озак вакыт сүзсез утырдылар. Кемдер мышык-мышык килеп борынын тартты, икенчесе яңакларын сөртте.

— А-ай-яй, бигрәкләр дә матур җырлыйсың, сеңелкәем, — дип, беренче булып Гөлтуташ мактарга керешкән иде дә, шул ук сүзләрне хуҗабикә тарафына кабатлап, аны инде Гөлсем шаккатырды:

— Әткәй мине Уфага алып барып, әллә нинди профессорларга тыңлатып карады. Бик уш китмәле тавыш булмагандыр инде, алып калмадылар. Ә мин менә синекедәй чиста, тигез хатын-кыз тавышын беренче кат ишетәм. Авылыбызда шундый тавышлы җырчы яшәгәнен белмәгән дә идем. Яраткан җырларың аз түгелдер инде. Әйдә, шуларның берсен җырла әле, Гөлтуташ апа. Без бер-беребезне тыңлап туеп беткән инде.

Үзенең азмы-күпме моңлы тавышка ия булуын Гөлтуташ, әлбәттә, әле яшүсмер чагыннан ук белә иде. Сирәк-мирәк эләккән аш-су вакытларында да гел аның салпы ягына салам кыстырып килделәр. Ләкин бу юлы инде үзе искиткеч бай моң иясе кеше, өстәвенә кулак кызы мактый башлагач, Гөлтуташ һич көтмәгән егеттән яучы каршылаган кәләш шикелле аптырабрак калды.

— Кунак ашы — кара-каршы, дигән кебегрәк булды инде бу. Мин сине мактадым, син мине, — дип, Гөлтуташ тәкъдимне өстән генә үткәреп җибәрмәкче иде дә, кызлар дәррәү рәвештә кыстауга күчтеләр.

— Валлаһи, матур җырлыйсың, Гөлтуташ апа. Әйдә, үзең яраткан бер җырыңны җырлап күрсәт инде.

Гөлтуташ артык ялындырып маташмады. Сирәк башкарса да, бар күңелен салып җырлый торган көйләрнең берсе «Суга баткан Гайшә» бәете иде, Гөлтуташ шуны сузды.

Чәршәмбе көн кер юарга
Ник җибәрдең, әнкәем?
Барма, Гайшә, дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем…

Кызлар кайтырга дип сикерешеп торган чакта, төн уртасы якынлашып килә иде инде.

— Өйгә кайткач асып куялар мине, баш бетте, — дип, этешә-төртешә тышка атылсалар да, болдыр төбендә кире борылып, хушлашу сүзләрен әйтергә дә онытмады кызлар.

— Иртәгә тагын аулак өйгә килеп утырабыз. Югалта күрмә безне, Гөлтуташ апа.

# БИШЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

## 1

Әмир тырыша-тырыша ачып йөргән мәктәп нибары бер генә ел буе яшәп калды. Көзге яңгырлар башланган гына иде, авылга Уфадан ирле-хатынлы Зәкия белән Хәсән атлы яңа мөгаллимнәр килеп төште. Аларны Бүздәк мәгариф бүлегеннән махсус озата килгән атлы кешенең белдерүе трибунал хөкеме сыман усал яңгырады.

— Мәдрәсәләр бетте, муллаларны долой! Хәзер латин имлясы белән укытуга күчәбез. Совет ышкулларында фәкать шулай тиеш.

Кичәге мәдрәсәләр хәзер «совет мәктәбе» дип атала башлый икән, анысы чукынып китсен. «Мәдрәсә» дип аталды ни дә, «мәктәп» булды ни — әгәр балалар анда шул ук, кичәге белемне ала икән, барыбер түгелмени? Мәгәр аның «латин имлясы» дигәннәре ни дә, гарәп язулары кая китә, өстәвенә тоташ төстә гарәп хәрефләре белән генә укыган-язган авыл иртәгә ни кылырга тиеш? — менә шушылары төркәйлеләр өчен дөм караңгы һәм мондый четерекле хәл һәркайсын да уттан алып утка сала иде.

Халык җыенында: «Балаларны иртәгә үк укырга китерәсез»,— дисәләр дә, икенче көнне Әхтәм хәзрәт йортының буш як яртысында сыңар аяк эзе дә күренмәде. Нарасыен күкрәгенә кыскан Зәкия мөгаллимә белән ире Хәсән әле болдырга, әле урамга чыгып күпме генә көтмәсен, ут йотмасын — букча аскан бер генә сабый да сабакка дип аяк атламады. Аның каравы эш-шөгыльсез калган малайлар Чәрмәсән буена төшеп көн буе шар сукты. Төркәй «совет мәктәбен» әнә шулай, умарталыкка төшкән ач аюны боҗрага алган сыман, бердәм битарафлык сәнәк-сөңгеләре белән каршылады.

Әмир булып Әмир дә ул көнне иртән иртүк «сугылмаган ашлык зуратларын карап кайтам» дигән сылтау белән Табор яланына чыгып качты. Кулы тамчы да эшкә бармады, билгеле. Өстәвенә берзаманны җир өстенә тубалдан кул белән чәчелгән орлыклар сыман берән-сәрән һәм тигезле-тигезсез булып яңгыр тамчылары сибәли башлады. Аннары яңгыр, зәһәрлегән бер мәртәбә күрсәтеп өлгергән усал килен сыман, аза-көчәя барды. Әмир, эштән туктарга сәбәп табылуга сөенгән юеш борынлы малай-шалай кебек, кыйгачлап өелгән көлтәләр ышыгына кереп оялады да, олы йомгактагы өзелеп югалган җеп очын табарга тырышкандай, иксез-чиксез уй-хәсрәтләр диңгезенә чумды.

Яңа мәктәп, диләр. Латин имлясы, диләр. Соңгысына советча кушамат та уйлап тапканнар инде. Ул «яңалиф» икән.

Нигә кирәк тә ул, кемгә кирәк? Моңа кадәр гарәпчә белән дә менә дигән итеп яшәп яталар иде бит әле. Төркәйдә гарәпчә укый-яза белмәгән кеше бөтенләй юк иде дә сыман. Ә хәзер киләчәктә ничек була инде? Әмир латинча басылган бер-ике газетаны волость комитетында күреп кайтты. Ләкин аны укучы түгел, кулга алучы да юк иде. Әле бу волбашкарманың үзендә бит! Ә авылда? Төркәйдә ул латин хәрефләре ни пычагыма кирәк? Нигә дип әле телне, гореф-гадәтләрне, илне сындырырга?

Ярар, Зифа балакай яшендәгеләрне, абзарга малны куып керткән сыман, көчләп-мәҗбүриләп укытырлар, өйрәтерләр дә инде ул. Мөгаен, алар әле үзләре дә бик карышып тормас. Алар — сабый, аларның хәтерләре бер саплам җеп шикелле бик кыска бит. Ә гомерләре буена Коръән ятлап яшәгән, «Сак-Сок», «Кыйссаи Йосыф», «Бәдәвам» китапларын изге ядкарь итеп кенә йөрткән өлкәннәр нишләсен? Советка латинча гына кирәк дип, хәзер инде Коръәннәрне, «Сак-Сок», «Йосыф»ларны утка ягыйкмыни? Бөтен тарихыбыз, мирасыбыз, хәтеребез, иманыбыз утта янсынмыни?!

«Берни дә юк, шул ук китапларыгызны хәзер латинча бастырырбыз» дип юатырлар, шаять. Ләкин тел дә, кул да үләнен чабып чыккан ялан түгел лә ул. Юк, хәрефне-әлифбаны алыштырдың икән, үткән мирасны кискәләдең, өздең дигән сүз. Яңача басылганнары инде аның яшел, сусыл үлән урынына киптереп-сындырылып беткән печәнне ашаткан кебек була. Инде яме-тәме дә башка була аның, рухы-иманы да. Өстәвенә җыйган-җилгәргән чагында нихәтлесе эзсез югалачак, тапталачак аның. Шулай булгач... шулай булгач, халыкның хәтере дә, иманы-кальбе дә кыскарачак, ватылып бетәчәк бит. Исән кулны кисеп ташлап, аның урынына протез тагу кебегрәк була бит инде бу. Протезның соң аның җаны булмый ласа! Тәнгә берекмәячәк бит ул, сулыш алмаячак, ләззәт бирмәячәк!

Латин зур яңалык, алга китеш булгач, ә нигә соң руслар үз әлифбаларын бер дә үзгәртмиләр? Нишләп аларның Евангелиеләре дә, Нестор белән Никон елъязмалары да шул көенчә кала? Бу Совет хөкүмәте шул безне, мөселманнарны гына, телсез, имансыз калдырырга җыена микәнни соң ул, и Ходаем?!

Йә, нишләргә, ни кылырга сиңа, Әмир староста? Кичә генә сине санга санап, сүзеңне тыңлаган Әхтәм мулла, Хәлил хәлфә күзенә хәзер ни төсле багарга? Кичә сиңа балаларын ышанып тапшырган утызга якын авылдашың күзенә ничек күренергә? Синең өчен хафаланып-үлеп торган шул ук Зифа балакаеңа бу яңалиф, мондый үзгәрешләр турында ничек аңлатырга?

Ә кире чигеним, бу старосталыгына, партиясенә төкереп китим дисәң, хутың юк бит синең, җаныкаем. Син кайчандыр бу партия камытына муеныңны илтеп тыктың инде, ә камыт — кәлүш-кәвеш тә йә булмаса иске бүрек тә түгел бит ул.

Син камыт киеп кенә дә калмадың, син әле тәртә арасына кереп җигелдең, артыңа «Төркәй» дип атала торган олы арба тактың. Синең тәртәләрең дә агач кисәге генә түгел, «партия», «совет» дип аталган таш стена бит ул. Аны җимерердәй көч-куәт юк синдә. Тибенгәләп карасаң да, сине камчылап-чыбыркылап тәртә арасына кире кертәчәкләр. Син хәзер тау елгасы өстенә эләккән бер йомычка кебек. Агым кая — син шунда. Син инде берничек тә яр өстенә сикереп чыгалмыйсың. Җитмәсә, әле ярым җимерек өеңдә синең совет паегы алып кайтканыңны карга балаларыдай авыз ачып көтеп утыручы гаиләң бар. Шулай булгач, телисеңме-теләмисеңме, тәртәсенә үз ихтыярың белән җигелгән арбаңны тарт инде син. Камчылаганнарын көтмә.

## 2

Әмирнең йөрәге-җаны, нәкъ сабан белән ерып чыккан шикелле, кыл урталай ярылгандай булды. Икенче көнне Төркәй халкы аны гүя танымады. Үзенең кызы Зифа белән күршедәге үксез Шәрифулланың берсеннән-берсе шәрәрәк эне-сеңелләрен «яңа ышкул»га таң тишегендә үк җитәкләп китереп куюы бер хәл, иң гаҗәбе — Әмирнең телен, кыйбласын адәм рәтле аңламаслык иде.

— Гарәпчә укыту — искелек. Аурупада әнә бөтен илләр әллә кайчан латин имлясына күчеп беткән. Татар гына түгел, иртәгә үк әзери, үзбәк, казагы да тоташы белән яңалифкә керешәчәк икән. Гарәпчә укыганнар — көя кисеп ташлаган иске тун шикелле кирәкмәс йөк. Андыйларны социализм арбасыннан поты белән долой!..

Әмир шундый сүзләр тезеп йорт буенча күченеп йөргән чакта, бик күпләре әле тегеләй, әле болай килеп төпченеп тә карады.

— Әмир, апаем, туктале, туктале син. Ярар, балаларны синең ышкулыңа илтеп бирдек тә ди. Ә Коръән шәрифне менә кая куябыз соң? Син кяфер сымак хәзер гареб якка карап чукына башлыйк та мәчетләрне җимереп ташлыйкмыни?

Башын ишек ниргәсенә бәрә-бәрә чыгып киткән чакта, Әмир төркәйлеләрнең өенен алырдай җавапны барыбер таба белде.

— Балаларыгызны яңа ышкулга илтми генә карагыз. Аннары Ибни кибетендә сезгә тауар сату бетә. Елы бик шәп килде, ипикәй налукларыгызны да арттырмаммы әле!..

Төркәйдәге власть булып исәпләнгән кеше шушылай итеп

күсәк болгап торгач, сүз тыңламый калган гаилә табыламы соң?! Әлбәттә инде, икенче таңда тиешле һәммә йорт та балаларын букчасыз-нисез көенчә булса да, Әхтәм хәзрәт йортына төшереп бирде. Алланың рәхмәте, әле ярый, Зәкия белән Хәсән мөгаллимнәр балаларга төркәйлеләрнең аз-маз гына исен китерердәй «галәмәт» өләшеп җибәрә белгәннәр.

— Монысы хәрендәш, монысы грифел такта,— дип, бик тә укымышлы кыяфәттә сабыйлар кулындагы «байлык» белән ул көнне олысы-кечесе үз тамгасын куеп карады.

Ә берәр айдан соң инде Әмирне яшь мөгаллимнәр белән бергә Бүздәкнең үзенә чакыртып, яңа фәрман биреп кайтардылар.

— Бөтен кешене укымышлы итү өчен, илдә яңа эрвәлүтсә бара. Наданнарга урын юк. Авыл саен ликбез мәктәпләре ачасыз да бөтен кешене шуннан үткәрәсез. Наданнарны калдыру — сатсиялизымга турмыз. Сезгә ыззадәнҗә — төптөгәл җөз прасинт!..

«Вәт, әкәмәт, боларча санасаң, без бөтен авылыбыз, милләтебез белән надан икән ләбаса! — дип, юл буена үз эченнән генә сүгенеп кайтты Әмир.— Совет властена безнең һәммәбезнең гарәпчә укый-яза белүебезнең поты бер тиен икән. Болай биетсәләр, безнең милләтне нинди генә сукбай хәлләренә төшермәсләр болар? Безгә гомер буе шулай чит-ят кубызына биеп яшәргә генә язган микәнни соң?..»

Ә Төркәйгә кайткач, Әмир үзе үк, беренче булып, яңача укыту кичләренә йөгереп килде. Зәкия белән Хәсән бөтенләй үк хәйләсез мөгаллимнәр түгел икән. Бер кичтә ил-көн тоткан гаилә башлыкларын җыеп укытсалар, икенче көнне йә Зәйнәпбикә шикелле кыз-кыркынны, йә Шәрифулла кебегрәк ярлы егетләрне тезеп утырттылар. Шунысы гаҗәп, Әмир бар ни дә, юк ни дип тормыйча, Гөлтуташ янына утырмага йөрергә гадәтләнгән Гөлсем белән Зәйнәпбикәләр көннәрдән бер көнне яшь мөгаллимнәр янына җыела башладылар. Хәсәннең бик оста гармунчы булуы боларны бер яклап сихерләсә, ирле-хатынлы мөгаллимнәр авылдагы байтак яшьләрнең күңеленә икенче яклап та юл таба белгән бит. Кич саен диярлек егетләре-кызлары Зәкия белән Хәсән алып кайткан «Яңа юл», «Яшь юксыл», «Яңа авыл» дигән гәзитләрдән укып әллә нинди «Зимагурлар», «Кара йөзләр», «Галиябану» дигән пьесаларны өйрәнәләр икән. Әмир әүвәл әле моны колак чите белән ишеткәләп йөрүдән ары узмый иде, әмма көннәрдән бер көнне Хәсән мөгаллим старостаны кәкре каенга китереп терәде бит.

— Бөтен илдә спитәкел бара, без генә йоклап ятмыйк. «Кара йөзләр»дәге Закир урынына Шәрифулланы таптык. Галимәне әнә һич югында Зәйнәпбикә уйнар. Гәрдән кызы

Гөлсем уйнаса шәбрәк булыр иде дә бит, мәгәр, заразы, ул Гәрдәнне сындырып буламыни?! Ә Сафи хәзрәт роленә сиңа җигеләсе булыр инде, Әмир абзыкаем. Үзебезнең авылда коммунист була торып, әртисләр табарга Бәләбәйгә чыгып китмәбез бит? Ә аннары... ә аннары спитәкелне кайда куябыз, кайсы йортта күрсәтәбез, шул турыда уйла. Бәләкәйрәк авылга килеп эләктек, заразы, клубы да юк бит...

«Каһәр генә суксын,— дип сүгенде Әмир, бу юлы да эчтән.— Фәлән бала атасы булган килеш кәмит куеп, кеше көлдереп йөрисе дә бар икән әле. Кемнәр генә булып йөрергә туры килер тагын, йа Ходаем?!»

Күнмичә чарасы юк иде, кичләрен Сафи хәзрәт булып та йөри башлады ул. Ә берзаманны инде үзен дә комар биләп алды. Бу Хәсән мөгаллим хак әйтә шул, канә. Төркәйнең, заразы, клубы да юк бит. Совет йорты да юк. Менә Динигә рәхәт ул, ичмаса. Алпавыт сымак бөтен авылга хуҗа булып утырырга аңа шура йорты әзер. Минем сымак, йорт борынча йөреп сансызланмый. Кем налук түләмәгән, кемнең власть алдында берәр төрле гаебе-китеге бар — теләсә кайсын, йомышчы җибәреп, чакырта да сүгә. Үзе хуҗа сымак, кулак сымак. Аның хөкүмәт аты-чанасы да сырт астында гына. Кирәк икән, шул Ишмай Харисының йортын ук ул клуб итә дә куя. Ә мин кая барыйм? Совет булам дип, үземнең өйне кәмит йортына әйләндериммени?..

Чынында да, беренче спектакльне Әмирләр ихатасына җыелып уйнадылар. Кәмит уены гына булып чыкмады бу, моның мәшәкате, ай-һай, байтак икән. Яшь егетләр килеп, иртәдән үк бөтен ихатаны тел белән ялагандай җыештырып чыкты. Әллә кемнәрдән табып ташый-ташый, ихатаны эскәмияурындыклар белән тутырып бетерделәр. «Булгач булгач, тормыштагыча булсын. Сәхнәгә атлар белән чыгабыз»,— дип, ике-өч алашаны, шуларга кушып Афоняны да Чәрмәсәндә юындырып кайтардылар. Ярар, инде барысы да әзер дип, уен башланыр сәгатьне генә көтә башлаганнар иде, көтмәгәндә Галимә-Зәйнәпбикә баш күтәрде:

— Галимә хәерче баласы түгел лә ул. Ә минем аякка кияремә кәлүшем дә юк бит. Мин сәхнәгә чыкмыйм!

«Революция дигәннәренең әле мондый яклары да бар икән бит, чукынып кына китсен»,— дип, тагын да шул эчтән сукрана-сукрана, Әмир Гөлтуташтан ярдәм сорамакчы булып кереп китте. Ләкин Гөлтуташ инде, Әмир тамаша әзерләргә дип, Әхтәм хәзрәт йортына кичке утырмаларга йөри башлагач та, артын куйган иде. Аңа ялваруның комнан бау ишү сыман файдасыз эш буласын аңлады да Әмир, бер сүз әйтми-нитмичә, хатынының сандыгындагы өр-яңа читекне куен астына яшереп кенә Зәйнәпбикә «кәҗә»гә чыгарып бирде.

Бирүен бирде, мәгәр чын «спектакль»нең ниндирәк булачагын чамалый белмәде шул...

Йә, ул Зәйнәпбикәсенә артына чуан чыккандай ашыкмаса ни була иде инде?! «Кара йөзләр» тәмамланып, бөтен ихатаны тутырып утырган халыкның яртылаш таралып бетүен дә көтмәде бит. Сыдырганчы-ниткәнче дип, чигүле читекләрне салды да, ипле генә төреп, Гөлтуташ кулына кертеп бирде яшь кыз.

— Читекләрең бигрәк йомшак икән, куанып кияргә язсын, Гөлтуташ җиңгәчәй.

— Әһә, минем читекләрем килешле дә, мин карт җиңгәчәйме?! Әллә ул кәмитләрдә уйнап, минем өемә яшь хатын булып төшәргә җыенасыңмы, йөзең кара?! — дип чәрелдәп, Гөлтуташ әүвәл Зәйнәпбикәне кулындагы читекләре белән әле өй эчендә генә чәбәкли башлаган иде дә, «спектакль» тора-бара ихатага күчте.

— Гөлтуташ, Гөлтуташ, дим, иманыңны киям! — дип янаган булып Әмирнең ике арага кереп каравы да ярдәм итмәде. Сыер дуласа, аттан яман, дигәннәре, валлаһи да, хак шул. Читекләре белән лас-лос бәрә-бәрә, Гөлтуташ Зәйнәпбикә белән Әмирнең икесен тиң бөтен ихата буенча каз мамыгы урынына куып йөртте.

— Син бүген кәмитеңдә Сафи байны уйнап җәмгы хәзрәтләрне дә, Коръәннең үзен дә мыскыл иттең, канә, — дип тезде ул ахырдан, болдыр баскычына утырып елый-елый. — Минем тупсаны атлап керәсе булма. Сәндерәңә ычкын, сиңа шул төс!..

## 3

Тамаша киченнән соң икеме-өчме көн дә вакыт үтмәгәндер, Әмир артыннан Дини җибәргән чапкын килеп җитте.

— Иртәгә Бүздәктә ниндидер парткәнфиренсе була, син депутат икән. Сезгә анда берәр нәрсә өләшә торганнардыр инде, Дини партбилетын алып килсен, диде...

Кара төн уртасы, басу-кырлар тоташы белән пычрак дип тормыйча Бүздәккә юл тоттылар. «Партиянең алдагы съездына зур хәзерлек бара, конференциягә кантоннан Шаһи-Морат үзе киләчәк» дигәннәр иде дә, аның урынына Бәләбәйдән милиция башлыгы Кинҗәкәев кенә катнашты. Юкка түгел икән. Ярты сәгать буена сагыз чәйнәгән шикелле нотык тотып, Кинҗәкәев әүвәл, икмәкләрен-малларын яшерә-яшерә базарларда сатып, хөкүмәткә тиешенчә салым түләмәгән буржуйларны тетте.

Ә аннары инде нэпманнарга, кулакларга каршы көрәштә җебегәнлек, кода-кодачалык күрсәткән партячейкаларга, авыл советларына да чират җитте.

— Сталин җитәкчелегендәге Совет хөкүмәте илне хәзер индустрияләштерүгә таба алып бара,— дип, бик укымышлы кыяфәттә тезде Кинҗәкәев.— Яңадан-яңа завутлар, электр стансалары төзү дигән сүз бу, ягъни мәсәлән. Ә моның өчен, әлбәттәген, акча кирәк инде, дахут кирәк. Ә фәлән ел буена әле Колчакка, әле Деникинга каршы яу аппарган Совет хөкүмәте ничәмә-ничә завут төзердәй акчаны каян алсын? Бер генә юл: гражданнар сугышы елларында, менә бу не-эе-пе чорында авылдашларын, тирә-юньне талап байлык җыйган кулакларны, буржуйларны налук белән буу-кысу кала. Бүреләргә ничек итеп ау оештырылганы турында ишеткәнегез бармы? Моның өчен бүре качкан төшне бөтен яктан кызыл чүпрәкләр бәйләнгән баулар белән уратып чыгалар, ягъни мәсәлән. Явыз булса да, бүре менә шул кызыл чүпрәкләрдән курка, бауны сикереп чыга алмый. Ә аучылар аның саен боҗраны тарайталар, берзаманны инде бүре-явыз үзе үк мылтык көпшәсе астына килеп керә. Совет дошманнарын да менә шулай итеп тимер боҗра белән уратырга кирәк...

Кинҗәкәев тезислар чәчүче генә булган икән әле. Һәрбер авыл советына аерым-аерым күрсәтмәләрне соңыннанрак Бүздәк милициясеннән Янгуразов бирде:

— Һәр авылда батраклардан, активлардан махсус отрядлар оештырасыз. Авылларга керә-чыга торган бөтен юлны сак астына алырга, авыл аша үткән һәр олауны астын-өскә китереп актарырга кирәк.

— Һәр авылда кайсы кулак күпме җир чәчкән, күпме уңыш җыйган, нихәтле мал асрый — энәсеннән җебенә чаклы исәпкә алынган булсын...

Болары әле Әмир-Дини сыман шурачылар өчен әллә ни зур яңалык түгел иде. Янгуразов инде җәза-бүләк мәсьәләсендә сүз кузгаткач, конференциягә җыелган һәммә делегатның ияге салынып төште.

— Яшереп базарларга озатылган олауларның, кулакларның лапас-келәтләрендә яшереп калдырылган икмәк-бәрәңгенең, мал-туарның бөтенесе дә уптым-илаһи рәвештә хөкүмәткә тартып алына. Ул байлыкны ачыклауда ярдәм иткән ярлы-ябагайга канфискавайт ителгән мал-нигъмәтнең дүрттән бер өлеше бүлеп биреләчәк.

— Өендә батрак тоткан, байлыгын яшереп калдыруы ачыкланган, җиткерелгән салымны көне-сәгате белән илтеп түләмәгән һәрбер мулла-мунтагай, кулак-буржуй советларга сайлау хокукларыннан да, авыл җыеннарында тавыш бирү ирегеннән дә мәхрүм ителә. Андый лишуннарга моннан ары авыл советы белешмәләре язып бирелмәячәк и бер генә кибеттә дә аларга тауар дигән әйбер сатылмаячак...

Таралыр вакыт җиткәч, шура рәисләрен генә аерып алып,

милиция бүлегендә аларның һәрберсенә мылтык-наган өләшә башладылар. Болар — отряд башлыклары булачак кешеләр, андыйларга корал тиеш икән. Дини рәискә юлдаш булыйм дип кенә милиция бүлегенә Әмир дә барган иде. Тартар теленнән табар, ди, кысыласы итте бит шул чагында.

— Син һәр авылда отряд төзергә кирәк, дип, үзең үк әйттең ләбаса, иптәш Янгуразов. Ә мин бөтен Төркәйгә берүзем. Миңа да мылтык-мазар мишәйт итмәс иде.

— Ә-ә? — дип, Янгуразов әүвәл, папуас күргән сыман, Әмиргә текәлеп тынсыз басып торды. Ә аннары, җай чыкканга сөенгәндәй, тегене тетеп атты.

— Бәрәч-бәрәч, син инде фәлән ел буена коммунист булып йөрисең түгелме соң, иптәш, кем, Нәгыймов? Шул вакыт эчендә үзеңә ярдәмчеләр дә эзләп тапмадың, комсомоллар да тәрбияләп үстермәдеңмени? Ю-ю-ук, коммунист түгел, единоличник, ягъни дә килеп, кулак-буржуй ише кеше икәнсең бит син, панимаешь. Сиңа пащада юк. Синең сымак сукыр коммунистларны утлы табага бастырып биетергә кирәк…

Әмир инде ник туганына үкенердәй хәлгә төшкән иде, Ходайның рәхмәте, әле ярый шул вакытта Дини сүз кыстырып өлгерде.

— Алай ук каты кирәкмәс. Ул, безнең гражданнар сугышын от и до үтеп, Шаһи-Морат камиссар белән Фирганәнең үзенә тикле барып җиткән кызыләрмис кеше бит, иптәш Янгуразов. И, тагы да килеп, әле кайчан гына ул синең кул астында Каюм каракны тотуда да булышты бит. Һәммәсенә шаһит кеше, диюем. Ышанычлы кеше. Аңа да бер мылтык тапсагыз, үзе әйтмешли, мишәйт итмәс иде.

Әллә «Шаһи-Морат комиссар» дигән сүз тәэсир итте инде, әллә «һәммәсенә шаһит кеше» дигән киная бер-бер төс уйнады, мәгәр көтмәгәндә-нитмәгәндә Янгуразов Әмиргә ике көпшәле ау мылтыгы чыгарды да бирде. Кисәтергә онытмады үзе:

— Вакытлыча гына бирәм, иптәш, кем, Нәгыймов. Кәк отрядларның бурычы-руле бетә, тәк мылтыкны назад. Ике кат әйттереш булмасын.

Әмма, Әмир рәхмәтләр укый-укый кире борылганда, усал төрттереп калырга барыбер онытмады:

— Ә комсомолларны аны, иптәш-кем, булдырырга кирәк. «Комсомоллар алар — искелеккә бомбалар». Такташ шулай әйткән…

Ни галәмәт, Әмир авылга мылтык күтәреп кайткач, иң беренче булып аның янына, чакыру-фәләнне дә көтеп тормыйча, күршедәге Шәрифулла белән Идрис дигән ярлы килеп җитте. Яшьләре буенча болар шул унсигезләр чамасында булыр, ә хәзер исә йөзләре-кыяфәтләренә бөтенләй малай-

шалай төсмерләре кергән. Әмирнең йөзенә карап тору да юк, ике күзләре тиң ау мылтыгында гына.

— Әллә ауга барырга җыенасыңмы, Әмир абый? Моның белән ниләр атып була? Ауга барсаң, безне дә ал инде син…

— Юк, ау өчен түгел бу. Махсус отряд төзим,— дип сөйли башлагач, Әмир егетләрнең борыны салынып төшәр, болар кул селтәр дә качып китәрләр, дигән сыман шактый шикләнеп-икеләнеп көткән иде. Ләкин сәер, гаҗәп: икесе тиң үзләренең карарларын өзеп әйттеләр бит:

— Кайчан, бүген үк сакка чыгып басабызмы, Әмир абый? Син калдырма, без бит синең белән…

Беренче-икенче төннәрдә Әбзән авылы белән ике арадагы юлда каравыл торулар бернинди дә юаныч китермәде. Ноябрь — хуҗасыз этне дә берәр төрле лапас ышыгына качыра торган ай бит инде ул, андый чакта юл йөрүче сирәк. Шулай да ул кулак, дошман дигәннәренең, Кинҗәкәев әйтмешли, бүре сыман яши торганнары да бар икән бит. Дөресрәге, болар бүре сымак итеп, беркем уйламаган-көтмәгән юлны да сайлый белә икән.

Бер төнне Әхмәт авылыннан читтә, сөзәк тау астында яткан иске зират ягында, атлар пошкырган тавыш ишетеп әсәренде болар. Әхмәтнекеләр Бәдрәш елгасы буенда инде әллә кайчан яңа зират башлаган, искесе белән алыш-бирешне күптән өзгән иде. Аннары, төн уртасында зиратта кемнәр нишләп йөрсен? Шушыларны уйлап ни Әмир үзе, ни егетләр Әхмәт ягына әүвәл әле аяк та атламады. Ләкин әлеге зират Төркәйдән күп булса чакрым ярымдадыр. Анда ат пошкырган тавыш янә ишетелде. Төне тып-тын, алданырга нигез бөтенләй юк иде. Казлар чылбыры сыман, гел бер эзгә басып, зират ягына таба юнәлделәр.

Маңгайлары белән барып төртелә язгач кына, бары да ачыкланды. Ике атны зират коймасы эченә кертеп бәйләгәннәр. Куе чытырманлык уртасына чокыр казып, элек шунда капчык-капчык ашлык яшергәннәр икән. Хәзер бер ир чокырдагы капчыкларны өскә биреп тора, икенчесе арбаларга ташый.

— Кулларыгызны күтәрегез! Селкенсәгез, атам! — дип кычкырып, әүвәл Әмир, аның артыннан тагын ике олы сынлы шәүлә килеп чыккач, ыгы-зыгы кузгатырдай батыр табылмады.

Яшергән икмәкләрен Чакмагыш базарына озатырга ниятләгән ирләр үзләренең авылдашлары — аталы-уллы Хафиз абзый белән Борһан булып чыкты. Иң гаҗәбе шул: Әмир дә, егетләр дә бу Хафизны икмәкләрен чокырга яшерердәй бай кеше дип белми, ә баксаң-казынсаң, ул кемгә көтүдән кайтмый калган чит-ят тәкәләрне, кемгә урланган каз өлә-

шеп, якын-тирә авыллардан йөге-йөге белән байлык-нигъмәт җыеп яткан икән.

Табылган малны, әлбәттә инде, Күчәрбай шурасына илтеп тапшырдылар. Икенче кичтә Идрис белән Шәрифулла шуннан олы бер олау ашлык төяп кайтты. Авыл кайнап ташый башлаган аш казаны сыман гөж-гөр килде.

— Хафиз байны тотып илткән өчен, Идрис япәтник белән Шәрифулла галахка уникешәр пот өлеш чыгарганнар.

— Хафиз абзый белән Борһанның икесен дә лишун ясаганнар.

— Бу имансыз Әмирнең үзенең дә, аның япәтникләренә әйләнгән Идрис белән Шәрифулланың да муеннары сынсын!..

Әллә ниләр әйтеп каргый-каргый, төркәйлеләр юкка төкеренде. Ил-замана кешеләрнең күңеленә агулы җим салган иде инде. Алдагы көнне әле караңгы да төшеп өлгермәде, ә Әмирләр ихатасының капка төбенә авылның иң мескен кешесе булып исәпләнгән Ләпәй килеп җитте.

— Менә дә-шәрәфә-кемәк-керәк. Менә дә-вазар. Карала-мәнә дә-рам.

Ләпәй — бала чагында нindидер яман авыру кичергән кеше. Башка авыл кешесе булса, аның телен мәңге аңлый алмый. Төркәйнең үзендә дә байтак кешеләр ул әйткәнне пупалап бетермиләр. Хәтта аның әле чын исемен дә бөтенләй белүче юк. Ләпәй, Ләпәй, гомер буе шулай. Сөйләшкәндә ярым әпә, ярым сакау кеше. Ә тормышта белгән бар шөгыле — йә кешеләргә ялланып көтү көтү, йә йомышы булган кешегә елгадан су ташу. Шуңа күрә Ләпәйгә бер генә ихатадагы эт тә өрми.

Әмир аңлады Ләпәйнең ни әйткәнен. Башта колак артын кашый-кашый, ни кылырга белми аптырап тик торды.

— Һе, сиңа да Шәрифулланыкы шикелле икмәк кирәк, дисең инде. Миндә дә авыз бар, каравылга барам, дисең. Ай-һай, Ләпәй. Безнең эштә ярты сүздән бер-береңне аңлау, дошманның өнен алу өчен яман итеп кычкыра да белү кирәк бит ул. Булдырырсың микән?

— Мә-шәрәфә дә рә ир. Мә-шәрә,— дип кулларын болгый-болгый, төкерекләрен чәчә-чәчә Ләпәйнең кире чигенмәскә маташуын күргәч, Әмир ихтыярсыз рәвештә кул селтәде.

— Ярар, барырсың соң, Ләпәй...

Әмма атна-ун көн буе саклап ятсалар да, отряд ятьмәсенә һичкем эләкмәде. Кулак дигәннәре Хафиз абзый белән Борһан үрнәгеннән сабак алып өлгерде, ахры, булган байлыгын җилгә чыгарып селкергә атлыгучы кеше табылмады. Аның каравы, Ләпәй тик ятмаган. Кай арада иснәнеп өлгергәндер дә, ничек сизенгәндер, шул берзаманны көпә-көндез Йосыф

кулакның бәрәңге бакчасындагы тирес өеме астыннан кырык капчык икмәк казып алды. Сүз дә юк, Йосыфны көнесәгате белән «лишун» ясадылар. «Уяу совет активисты» Ләпәйгә ун урынына әллә нишләп алты гына капчык икмәк эләкте. Ләкин Ләпәйнең шунысына да бәхете чиктән ашкан, әйтерсең, ул бөтен авыл бакчасын яланкулы белән сөреп чыгарга да әзер иде...

Берәр айдан соң югарыда әллә нинди үзгәреш булды бугай, Әмиргә мылтыгын кичекмәстән китереп бирергә, дип фәрман юлладылар. Бер рәхәтнең бер михнәте дигәндәй, Бүздәккә «отряд»ны ияртеп баруның юанычы да булды — Шәрифулла белән Идрисне комсомолга алып кайтардылар.

## 4

Беркөн кичтә Әмир өенә кайтып керсә, Гөлтуташ аны елый-елый шешенеп беткән көе каршылады. Сәбәбен ире бик озак төпченгәннән соң гына аңлатып бирә алды:

— Әтәйне Чакмагыш юлында тотып кыйнаганнар. Аны Мәгъфүр белән Сибәй дигән ике кулак качырып җыйган икмәкләрен базарга илтергә яллаганнар икән. «Син элеккеге ломовой, син оста, син булдырасың», — дип котырткannar инде. Мәгәр хәзер теге еллармыни? Чакмагышка җитәрәк, Итәкле тау буенда, камсамуллар әтрәте көтеп яткан булган. «Мин — ломовой, мин — гомер буе юлда кеше олауларын ташып йөргән кеше, чит-ят малын югалтырга минем хокукым юк» — дип, әтәй боларга каршы төшкән, сантый. Тегеләр ни, тотып изгән инде. Әтәйнең соң яшь вакытымыни? Хәзер кан косып, саташып урын өстендә ята, ди инде менә.

— Ярар, юкка өзгәләнмә. Рәҗәп абзый беренче кат кыйналган кеше түгел, сыну-шешенүләрдән котылуның рәтенюнен белә, аякка тиз басар. Хәлен белим, барып кайтыйм, дисәң, иртәгә үк Афоньканы сиңа үзем җигеп бирәм, — дип юаткач кына, Гөлтуташ, ниһаять, үксүеннән тынды...

Икенче көнне туган йортына кайтып төшкәч, Гөлтуташ әтисен бөтенләй дә таный алмый торды. Аллага шөкер, әтисе түшәгеннән купкан, аягына баскан басуын. Ләкин бөтен тәне, куллары бизгәк тоткан сыман дер-дер килеп тора, гәүдәсе шыр-сөяк, күзендә бертөрле нур юк, тирә-яктагы һичкемне танымый, төсмерләми.

— Алышынды атаң, алышынды. Карт көнемдә шушындый сантый белән торып ятарга туры килә менә, — дип, үги ана булган кеше елап та җибәргәч, Гөлтуташ берничә кичкә туган йортта калырга карар кылды.

Әтисе ушсыз-зиһенсез булса да, бер дә өй эчендә генә утырып тора белми. Әле кулына йөгән-нукта ише әйбер эләкте-

рә дә әллә нинди дөньяда булмаган Тимеркүк йә Рәмзис дигән атларын эзләп чыгып китә. Әле сарай артына кереп яшеренә дә, уңга-сулга куеп, йөз кат бутап, ниндидер Галимулла, Җантурин, Шәйморза атлы байларның «тиреләрен, постауларын, сандыкларын» бүлә. Янына якынаер, ипкә-сапка китерер бер әмәл юк. «Байлык» бүлгән чакта күренденме, йә утын әрдәнәсе алып тондыра, йә сәнәк белән балта эзләргә тотына.

Берзаманны күк йөзендә көньякка китүче торналар, кыр казлары йә үрдәкләр кәрваны күренә башлады. Рәҗәп картта яңа «зәхмәт» купты. Әллә кайда, күз колачы җитмәс биеклектә очып барган казлар тавышын ни рәвешле, ничек ишетәдер, Аблай өстендә кәрван күрендеме, аягына-өстенә киеп тормыйча, ялан-кырга йөгереп чыга. Аннары:

— Бикми балакаемнан сәлам китердегезме әллә? — дип кычкыра-кычкыра, авыл очына җиткәнче, казлар кәрваны артыннан йөгереп бара. Казлар күз күременнән югалгач, юеш җир өстенә тезләнә дә бала-чага сыман лышык-лышык елый.

Гөлтуташ беркөнне аны эзли чыккач, әтисенең ниндидер җыр сузганын ишетеп, тораташтай калды.

Казлар, сезгә кычкырам:
— Минем янга төшсәнә,
Канатыңа хат кыстырам,
Бикмиемә илтсәнә.

Гөлтуташның зиһененә шундук барып җитте. Әтисе үзенең өлкән улын, әле унсигезенчеме-унтугызынчымы елларда ук Колчак армиясенә ияреп Себер ягына киткән һәм шуннан бирле суга төшкән балта сыман эзсез-хәбәрсез югалган Бикми-Бикмөхәммәтне сагынып елый иде...

Мондый хәл көн саен кабатлана башлагач, Гөлтуташның түзәр чамасы калмады. Әтисенең корыган-кипшенгән гәүдәсен күкрәгенә кысып елады да, шул күз яшьләреннән арына алмаган көе, үзенең балалары янына ашыгып кайтып китте.

## 5

Тагын берәр елдан, йокычы карт кышны ашыктырып ишек-тәрәзләрне шакый-шакый яз килеп җиткәндә, Әмирне яңа «зәхмәт» белән чирләттеләр. Тирә-юньдәге барча совет активларын бу юлы да шул Бүздәккә чакырып җыйнаганнар иде. Уфаның «БашЦИК» дип аталган җиреннән олы түрә килеп төшкән икән, «зәхмәт»не шул чәчте:

— Мәскәүдә әле генә унбишенче съезд булып үтте. Ул партиянең курсын коллективлаштыру дип игълан итте. Ан-

да мин катнаштым, ул тарихи съезд. Чабаталы Рәсәй сазлыгыннан ялгыз чыгып булмый. Агач сукалы Рәсәйгә чик куярга вакыт.

Моннан котылу өчен бер генә юл — күмәк хуҗалыклар. Һәр авылда коммуналар вә ширкатьләр төзеп, Рәсәйне сука сазлыгыннан чыгарырга кирәк...

Төркәй халкын мәчет мәйданына җыйнап, коммуна, ширкать, дип сөйли башлаган Әмир сүзләрен әүвәл әле беркем аңламады. «Алары ни? Тагын нинди мөгез чыгармакчы була бу хәерсез?» — дигән сыман барысы да, Әмирдән бигрәк, мәйдан читендә торган Гәрдән белән Йосыф кулаклар ягына текәлеп тик тордылар. Беркадәр ачыклыкны, чынлап та, беренче башлап арада өлкәне — Гәрдән кулак кертте.

— Син нәрсә, бөтенебезне дә бер абзарга куып кертергә җыенасыңмы әллә? Авылда өчәр-дүртәр атлы кешеләр бар, бөтенләй сукасы-тырмасы булмаган хәерче алабай бар. Син шуларның җәмгысын да бер тәртәгә җикмәкчеме әллә?

Бәхәскә калса җиңеләсен аңлап, Әмир, тәртә арасына тәүге тапкыр җигелгән яшь тай шикелле дулый-дулый, ярсу һөҗүмгә күчте:

— Йосыф кулак белән икегез дә сез лишуннар. Сезне коммунага чакырган кеше дә юк, киңәш-уңашка да. Төркәй халкы сездән башка да үлмәс, а ну давай аттырыгыз моннан!

Әйе, соңгы айларда Гәрдән, Йосыф, Мирсәяф ише кешеләрне җыелышка-мазар кертү түгел, аларга инде кибетләрдә тауар сатулар да туктатылган иде. Әмир бу юлы да иң авырткан сөялләренә баскач, берсе дә бәхәсләшеп-карышып маташмады, икесе тиң, вәкарь генә атлап, үз йортлары ягына кайтып китте. Бәласеннән башаяк, бу каһәрнең ашлык, ит, май салымы дигәннәрен арттырып куюы бар бит. Ул коммуна дигәненә берәүне дә куып кертмиләр, һәркемнең үз иреге, нигә чукынышып бетмиләр соң шунда!..

Сука-тырмаларын берләштереп, атларны бер сабанга җигеп ярдәмләшү күрше-күлән, туган-тумача арасында гомергә бар иде. Бергә-бергә тормыш иткән авылдашлар арасында кем генә берәрсе белән уртакка дип печән чапмаган да, кайсысы гына өмә ясап өй салмаган йә булмаса киндер-җитен суктырмаган инде? Аннары бу Әмир дә бер байлыкны да талап алырга, нindiдер малдан коры калдырырга җыенмый бит әле. Әнә коммунага кергәннәргә хөррият, ялгызларга михнәт булачак, ди.

— Коммунаны Табор күле янында нигезлибез. Үзегез дә беләсез, андагы туфрак кап-кара, тәртә тыксаң, арба үсеп чыга. Кырлары тип-тигез. Печән чабар өчен тугайлыклар иркен. Ул кулай җирләрнең барысы коммунага. Ә коммунага кермәгәннәргә әнә Чәрмәсән буендагы җыен чокырлы-чакыр-

лы, комлы-ташлы яланнарны бүлеп бирәчәкбез. Миңа димәгәе, симәнәләрен нигә шыр ком өстенә илтеп чәчмиләр, бер эшем юк. Кем аерым көе генә яшәргә исәп итә, аңа шундый сәхрә. Ә коммунадагыларга, әлбәттә, җирнең иң майлысы...

— Совет хөкүмәте сезнең бер малыгызны да талап алырга исәп тотмый. Кемдер сыңар ат белән керер коммунага, кемдер пар ат белән. Симәнәләр уртак, сука-төрән уртак. Язын күмәкләшеп чәчү чәчәбез дә көзе белән бергә җыячакбыз, уртак бүләчәкбез...

Беркем беркемне рәнҗетми, сорыкорт булып ятмый, барысы да ал да гөл килеп чыгар төсле — нигә кермәскә ди? Аннары, бу совет власте дигәннәре, усал бианай сыман, күбрәк менә Йосыф-Гәрдән ише байларга, кулакларга гына каныга бит әле. Ә Әмир ише, Шәрифулла ише ярлы-юксылларга ярдәм кулын сузарга тырышып тора. Шулай булгач, советның һәр адымыннан этлек кенә көтеп яту бөтенләй урынсыздыр...

Менә шулай фикер йөрттеләр дә утызга якын кеше Әмир староста кулына гариза язып бирде. Коммунага «Кызыл байрак» дигән исем сайладылар, рәислеккә, билгеле ки, бертавыштан Әмир үзе үтте.

Табор күле авылдан дүрт-биш чакрым чамасы төньяктарак, тирә-юнендәге басу-тугайлыклар, асылда да, гаять иркен иде. Күле бик зур, тау сырты астында олы дага ясап сузылып ята. Суы ак күмәч манып ашардай чип-чиста, дилбегә буедай тирән, балыгы күп. Бер ягында, Чәрмәсән белән ике арада, шомырт, камырлык, чикләвек куаклары тезелешеп киткән. Сырт астында кузгалагы, юасы, җиләкләре котырынып үсә. Кыскасы, җаның ни теләсә, шул бар. Элеккерәк елларда анда-санда үтеп йөргән чегән олаулары юкка гына шушы күл буенда зур-зур ыстан корып ятмагандыр инде.

Иң беренче итеп, эшне лапаслар, келәтләр корудан башлап җибәрделәр. Кемдер яңа мунча өчен әзерләнгән бурасын төяп килде, кемдер иске келәтен сүтеп ташыды. Әмир ат-арбасы булмаган бер генә кешене дә коммунага якын җибәрмәгән иде, эш тиз барды. Бер атна дигәндә, сөзәк тау сырты белән күл арасында келәтләр бистәсе калкып чыкты. Сөрелгән җирләрен тырмалап, әле төрән күрмәгән яланнарны сөреп чәчүгә керешкәч, шунда куна-төнә яши башладылар. Хәл белергә дигән сылтау белән, әтиләре-ирләре янына йә хатыннары, йә малай-шалай килергә гадәтләнде, чынлап баксаң, ярты авыл күл буена күчте. Ә ялан-җиргә бер кичтә генә илле-алтмыш кеше җыелсын да кызык та булмасын ди! Китте тамаша, ярыш. Ике кичнең берендә йә бала-чага арасында бил алышу үткәрәләр ирләр, йә ятьмәләр белән күл-

нең астын-өскә китереп бетерәләр, йә аркан тартышлы ярыш оештырып бер-берсенә чирәм сөрдертәләр.

Әмир әле беренче көннәрдә кырыкка ярылырдай булып чәбәләнде. Ул коммунадагы һәр эшкә дә күз-колак булырга тырыша, җитмәсә, коммунага керми калганнарга җир бүлеп бирү дә аның өстендә иде. «Ялгызаклар» арасында талашып-әрепләшеп чыкмаган бер кешесе калмады диярлек, әле анда чапты, әле монда. Ниһаять, берзаманны инде тынычланып, коммунанықылар белән бергә куна башлаган иде дә, ике яңа «әктиф» — Шәрифулла белән Идрис — авыртмаган башка тимер тарак тапты.

— Әхтәм хәзрәтнең Гөлбанулары белән Гәрдәннәрнең Гөлсеме күреп кайткан. Чакмагышта әктивисләр әнә әллә нинди өр-яңа «Галиябану» дигән спитәкел күрсәткәннәр икән. Бөтен авыл елый-елый караган, Гөлсем хәтта «әтәй-инәйгә дә карап тормасыем, Галиябануны үзем уйнарыем» дип әйтә ди.

Әмир әүвәл әле ыжламаган иде, ләкин бу «әктифләр» инде Зәкия һәм Хәсән мөгаллимнәр белән дә сүз беркетеп өлгергәннәр икән.

— Коммуна — крәстиян халкын якты киләчәккә илтүче кораб бит ул. Шулкадәр крәстиян бер түбә астына җыелышкан икән, аларны агарту чараларын да онытмаска кирәк,— дип нотык укый башлаган мөгаллимнәргә Әмир инде каршы тора алмады.

Галиябану роленә, чынында да, һичбер төрле үгетләүсезнисез Гөлсем риза булды. Яшьләр дә, Әмир үзе дә әүвәл бу эш барып чыкмас, Гәрдән кулак Гөлсемнең иләсләнеп йөрүен тиз җилгәрер дип шикләнгәннәр иде, ни галәмәт, ата кеше халык арасына чыгып бер тапкыр да быжгып карамады. Гөлсем — гаиләдәге бердәнбер кыз бала, авылда аның күзе төшәрдәй бай егетләр юк, иләс-миләс килеп йөри торган чагы үтеп киткән, буйга җиткән кызый гел әнисенең итәгенә ябышып кына яши алмас инде, җитмәсә, тавышы-моңы матур, үз сәләтен халык алдында да күрсәтәсе килә торгандыр бит — менә шушы уй-тарафларның барысы да тәэсир итте бугай, Гәрдән кулак үзенең кызына аяк чалып-мазар маташмады.

Яшьтәшләренең, мөгаллимнәрнең ахылдау-ухылдавына карамыйча, Хәлил ролен Шәрифулла юксыл талап алды.

— Хәлил — ярлы егет, мин дә ярлы. Спитәкел дип кенә карау ярамый, гадел булу кирәк. Исеме-яше туры килгән дип Хәлил рүлен Әхтәм хәзрәтнең малае Хәлил хәлфә уйнамас бит инде? Юк, Хәлил рүлен берегезгә дә бирмим, Гөлсем белән кара-каршы басып үзем генә җырлыйм!..

Аптырагач, ризалаштылар инде. Чәрмәсән ягындагы куаклыклар буена җыелып, әллә ничә кич буена роль өйрәнеп яттылар. Исмәгыйль буласы Идрис кәҗәләнгәч, Динидән

ялвара-ялына наган алып кайттылар. Аннары күл буендагы сөзәк тау сыртында ике кич рәттән спектакль барды. Беренче кичтә тамаша әле коммунаныкыларга гына күрсәтелгән иде. Ара ерак-фәлән дип зарланучы кеше табылмады, икенче кичтә бөтен Төркәй халкы җыелышып килде.

Тамашалар үтте, ә авылдагы ике яшь йөрәк арасында нинди сәер гыйшык кузгалганын әүвәл кубып һичкем аңламады. Коммунадагы өч-дүрт ир-ат Әмиргә иртәләрен әллә нинди кинаяләр ташлап карады каравын.

— Шәрифулланың болай да сөрхәнтәй бия аламасы шыр күбеккә баткан. Мөгаен, ул бүген төнлә дә ял-фәләнне күрмәгәндер инде.

— Гәрдән кулак кичә чүт кенә үзенең бакчасында бер карачкыны әләктермәгән, диләр. Теге карачкы Гөлсемнең тәрәз төбенә килеп Хәлил булып җырлап маташкан, ди…

Әмир соңгы көннәрдә Шәрифулла-комсомолның ничектер суырылып калуын да, үз эченә бикләнеп йөрүен дә сизә иде сизүен. Мәгәр җитәкче кешенең үз кайгысы, үз мәшәкате баштан ашкан була бит ул. Әнә үләннәр өлгереп җитте, тугайлыкларның кайсын коммунага, кайсын «ялгызаклар»-га бүлеп, Төркәй халкын печән чабуга төшерергә кирәк. Аннары атлы ургычларны, чалгы-уракларны барлап куясы бар, печән артыннан ук арыш уру җитә.

Менә шушы мәшәкатьләр белән июле дә, августы да узды. Күмәк көч тау күчерә, дигәннәре, валлаһи да, хак шул. Сентябрь башына бөтен арышын, бодаен, арпасын урып, әвеннәргә куеп бетерделәр. Хәзер һәммә кеше Төркәйгә кайта торган юлны онытты, барысы тиң, тоз сипкәндәй, коммунада ята. Яңгыр сибәли, җил ыжгыра дип торучы юк, таң аттымы, каз бәбкәләре сыман бер-бер артлы тезелеп басалар да һәр әвенне энәсеннән җебенә тикле тикшерәләр болар. Әмир баштарак моны крәстиян тынгысызлыгы, уртак мал өчен җан ату дип кенә кабул иткән иде, бер кичтә, учак янына күмәкләп җыелгач, күзен тиз ачтылар.

— Крәстиянның аның ни, ел буена түккән тире-көче келәтенә кергән икмәгенә карап билгеләнә инде. Ә без бу нине, уртак җыеп алган, өйгән әвеннәрне, ничегрәк итеп бүлешербез микән, Әмир туган?

Әмир беркатлы шул, күңелендә йөрткән уй-ниятен яшермичә әйтте дә салды:

— Ничек дип, соң шул, җан башына карап булыр инде. Авызларның кайсы да икмәк кетердәтә бит. Кемдә күпме авыз — шулкадәрле икмәк.

— Ничек инде, ничек? — дип, өлкән яшьтәге ике ир-ат бер-бер артлы сикерешеп торды.— Әнә Галимҗан белән Харисның сәкеләрендә сигезешәр бала тезелешеп утыра да, Са-

бирларда, Әслахларда дүртәр. Рамай исә әле яңа гына башлы-күзле булган кеше, хатыны бәби көтеп кенә йөри. Ә синең коммуныңа кергән чакта, Рамай да сабан-тырма салган бер ат җигеп килде, Харис та шул ике суксаң бер атламый торган үшән алашасын җитәкләп килде. Өстәвенә Рамай әле алты капчык орлык алып килеп бодай чәчте, ә синең ул Харис белән Галимҗанның дүртәр капчык кына. Чәчкән, урган, чапкан чагында да бөтенесе тигез эшләделәр. Ә хәзер, синең кубызыңа биесәң, ул ач әрвах Харис семиясына ун өлеш итеп ашлык бүлеп бир икән дә, Рамай, мескен, ике йә өч өлешкә эппәр итсен икән. Акылларың котмы?

— Туктагыз әле, тукта, — дип, Әмир үз ниятен аңлатырга тырышып караган иде дә, кыргый гарасатны аны коры тәпәч белән генә тыеп буламы соң?

— Мәгъсүм абзый белән Таһир абзый икесе дә хаклы. Үзем чәчеп үзем урган икмәкне Харис белән Галимҗанга өләшергә мин дүрәкме әллә? — дип, шул минутта ук Түбән очтан Фазылбәк сикереп торды. Аны инде икенче мизгелдә башка ирләр эләктереп алды.

— Харис белән Галимҗан шикелле әрәмтамакларның поты бер тиен!

— Сез теләсә нишләгез, ә мин үземә тиешле әвеннәрне төйим дә кайтып китәм. Моннан ары ике аягымның берсен атлыйсым юк, Әмир коммунының кирәге барые!..

Көтмәгәндә купкан ызгыш-талаш ахырда канга батып сугышу белән бетте. Икенче таңда кайсы тырналган, кайсы күгәреп беткән олы-олы ирләр янә Әмир каршына тезелешеп басты.

— Атлар әзер. Әйдә, теләсәң ничек бүл дә, без кузгалдык. Коммунаңа бүтәнчә аяк атлаш бетте...

Чынлап та, ике-өч көннән соң Табор күле буенда келәтсарайларның эзе генә ятып калган иде.

## АЛТЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

### 1

Егерме тугызынчы елның февраль азагында һаман да шул волость комитетына җыйнап, барча коммунистны утлы күмер йоттыргандай өнсез калдырдылар.

— Коммуналар төзү үзен акламады. Крәстияннан малларын, басуларын каерып алмыйча хата җибәргәнбез. Хәзер коммуналар урынына авылларда колхоз төзеләчәк. Колхозга кергән һәммә кешенең малы — күмәк абзарларга. Булган

бөтен җир — уртак. Орлык, чәчкечләр, тырма-сабан, арбачана — бөтенесе күмәк. Уңыш хезмәт көненә карап бүленә, калган бар икмәкне дәүләткә тапшырасыз.

— Кем колхозга керми, аңа салымнарны икеләтә-өчләтә арттырасыз. Кулак анысын илтеп түли икән, шундук яңа салым. Тегермән эше, триер, молотилка, косарка эше байлыгы бар икән, һәммәсен — колхозларга. Нәселле айгыры, үгезе, тәкәләре булса, алары да колхозга. Кулакка көн бетте. Рәсәйнең бөтен терәге-өмете колхозларда хәзер...

Бик соңарып кына булса да, җыелышка Бәләбәйдән кантон башлыгы Шаһи-Морат килеп төшкән иде. Аңа сүз бирделәр. Тик комиссар әллә нишләп нотыгын, артыннан кемдер камчылаган сыман, бик тә кыска тотты.

— Тәк, партия хәзер бөтен ставканы колхозларга куя. Коммуна, ширкать ише вак-төякне төзү — социализмга ярты адым гына. Җиңү юлы — фәкать колхозлашу. Унбишенче съезд бөтен Советлар Союзы өчен менә шундый курс билгеләде. Әле бер ай элек кенә Себер өлкәләрен тикшереп чыккан чакта, иптәш Сталин колхозлашуның авылда социализм төзү өчен бердәнбер юл икәнен янә раслап кайтты. Әйе, иптәш Сталин әйтте, ялгыз хуҗалыклар, аеруча кулак — социализм өчен тормоз. Кулакны класс буларак бетерергә вакыт. Иптәш Сталин базарларда ашлык сатуны тулысынча тыярга, икмәген яшереп калдырырга маташкан кулакларның бар байлыгын тартып алырга, үзләрен төрмәгә утыртырга, ә крестьяннарның икмәген дәүләт амбарларына җыеп тутырырга чакыра. Крестьяннар үзләре күмәк хуҗалыклар төзүгә күптән әзер, бу эштә без — коммунистлар — җитәкчеләр генә, әшнәлек-ялкаулык күрсәтәбез, хәтта саботаж оештырып ятабыз икән. Кулакларга каршы көрәштә җебегәнлек күрсәткән кешеләрне кызгану юк, андыйларны, ахыр чиктә, төрмә сәкеләре көтә...

Җыелыш беткәч, Әмир Шаһи-Моратны көч-хәл белән генә эзләп тапты. Элекке байлар йортының тар гына бер бүлмәсенә кереп утырган да, Шаһи-Морат ашыга-ашыга тәмәке суыра иде. Әмирне күргәч, әлбәттә, аны сыңар кулы белән булса да кочагына алды. Ләкин карашы-кыяфәте элеккечә, көне буе эссе кояш астында сабан тартып хәле-егәре беткән атныкы сыман төшенке, арыган килеш калды.

— Аңлат әле, комиссар, кая барабыз без? Бу колхоз дигәннәрен ничек төзергә дә, алар Төркәй, Күчәрбай халкына ни бирә соң? — дип төпченә башлаган Әмирнең соравына каршы Шаһи-Морат кулын гына селтәп җавап бирде.

— Аһ, мин аны үзем белсәм икән! — Бераздан ишек ягына таба урлап каймак ашаган мәче шикелле ялт-йолт карыйкарый гына өстәп куйды.— Соңрак, соңрак, Әмир. Якын-

тирәдә колаклар күп йөри. Хәзер генә юлга чыкмыйсыңдыр бит? Соңрак сөйләшербез...

Бүздәктән Бәләбәй белән Күчәрбай аермасына кадәр ара утыз чакрымнар чамасы бар иде. Аллы-артлы юлга чыгып Бүздәк артта калгач, Шаһи-Морат Әмир чанасына күчеп утырды да, төпчендереп-кыстатып тормыйча, үзе сүз башлады.

— Колхозларны ничек итеп төзик, алар нигә кирәк, дисең инде син. Ә мин каян белим? Ул хакта уйлана-уйлана башым катты, туган. Ул өстәгеләр нинди уен уйный торганнардыр, аңлар хәл юк. Әле моннан өч-дүрт ел элек кенә Бухарин «Правда»да менә болайрак дип язып чыккан иде. «НЭП крестьяннарга аякка басарга ирек бирде. Ләкин хөкүмәтнең һаман талау сәясәте алып баруы крестьяннарны байлык туплаудан тыя. Хәле булса да, крестьян хәзер йорт түбәсен калай белән япмый, чөнки ул үзен кулак исемлегенә теркәп куюларыннан курка. Берәр нинди машина сатып ала икән, моны коммунистлар күзеннән качырып кына эшли. Мондый сәясәт алып бару хилаф адым. Крестьянга ныклы хуҗалык булдыру өчен мөмкинлекләр тудырырга кирәк». Вәт менә шундый сүзләр. Ул вакытта аны Сталин да яклап чыккан иде. Әле үзең дә хәтерлисең булыр, ул чагында базарларда сату итәргә дә, батракялларга да тулы ирек ачылды. Әйдә, бае, крестьян, илне генә күтәр, янәсе. Ә хәзер? Хәзер, «син кулак җырчысы» дип, Сталин, эт шикелле котырып, шул ук Бухарин өстенә ябырылды, аны гәҗиттән алып атты. Ә кем НЭП елларында ныгыган, аякка баскан — болар бары да кулак. Башта үзе үк ашатты-ашатты да, хәзер хәлле крестьянның баш түбәсенә сугып, кан костыра, кабих...

Бүздәктән аермага кадәр җиткәнче, Кара Якуб, Таулар, Сабай, Килем, Шыгай, Түреш дигән авыллар аша үтәсе бар иде. Авыл урамнарына кергән чакта, авызына су капкандай булса да, яланнарга чыккан саен Шаһи-Морат янә туарылды.

— Аннары ул Троцкий белән ни эшләде, кара. Троцкий бит заманында «социализм төзү өчен хәрби тәртипләр кертергә, бөтен илдә хәрби частьлар тибындагы хезмәт армияләре төзергә, бөтен кешене мәҗбүри хезмәткә җигәргә кирәк» дип, и, лаф орган иде. Хәтта хезмәткә түләүне дә солдат паегы хәленә калдырмакчы иде. Мондый хилаф саташулары өчен Троцкийны изде, таптады, юк итеп бетерде теге грузин. Чыдамагач, Троцкий илдән чыгып качты. Ә хәзер карале син. Нәкъ шушы ук ысулларны кулланып, Сталин бөтен крестьянны колхозларга куып кертергә чакыра. Малны, җирне тартып алмакчы, сабан-тырмаларны җыеп чыкмакчы. Хезмәткә түләү — эш көненә карап. Ягъни, дөресен

әйтсәң, шул ук мәҗбүри хезмәт инде, шул ук паек. Йа Илаһым, ни эшләр бу халык?!

Аермага җитә башлагач, Шаһи-Морат кызу-кызу итеп киңәшләрен тезде.

— Алдан ук белеп тор, Әмир туганкаем, крестьян халкы мәҗбүри төзелгән колхозларны кабул итмәячәк. Крестьянны акыртып талау, җирсез калдыру бу. Крестьян өчен ул тере тәнендәге сөягеннән ит аерган төсле. Мин әйткән иде диярсең, берзаманны, колхозларга бирмәс өчен, крестьян булган малын да суеп бетерәчәк, кирәк икән, үзен яклап, әле коралга да барып ябышачак. Ох, авыр көннәр, канлы көннәр көтә авыл җирен. Ә син сак бул. Крестьянны чыбыркылап кума. Төркәйлеләрне булдыралган хәтле таланудан коткар. Әйе, аңлыйм инде. Без синең белән икебез дә партия арбасына мәҗбүри җигелгән атлар. Алай гына да түгел. Артка чана-арба таккан килеш тау төшәргә мәҗбүр ителгән атлар хәлендә без. Өстән чыбыркылап, һаулап торалар. Инде аякларны камыт-дуга чырайга килеп төшәрлек итеп терәсәк тә, тарткан йөкне тау сыртында туктатып калып булмый. Ике генә юл, Әмир. Йә шул йөкне чыбыркы хуҗалары куалаган җиргә илтеп җиткерәбез. Йә... инде дулап, котырынып чаба калсак, безнең муен сына. Вәт менә шул, туган, башка юл юк...

## 2

Төркәйгә кайтуга, беренче эше итеп, Әмир Әхтәм муллаларның ишеген барып какты. Хәзрәт дөньяда Әмир дә бар икәнен бөтенләй оныткан, ахры, авылдашын күргәч, яучы килеп төшкән тол хатын шикелле гел аптырап калды.

— Бәрәкалла, Әмир ыстарыста түгелме соң? Тагын нинди йомыш алып килде сине? Болай кара төн уртасында диюем.

— Җитди сүз бар. Әйдә, авырсынма, өстеңә киен дә чык әле, хәзрәт. Мондый сүзне колактан колакка сөйләшү хәерлерәк булыр.

Әмирнең бик тә серле, тыныч итеп сүз кушуы тәэсир итте бугай, Әхтәм мулла, өстенә кыска бишмәтен генә эләктереп, борылып та чыкты. Абзар ышыгына барып баскач, Әмир көттерми сүз башлады.

— Хәлләр хөрти, хәзрәт. Хөкүмәт крәстияннарны колхозларга куып кертергә куша. Рөстәмбәк, Йосыф сымак байларга, синең ише мулла-мунтагайга бөтенләй көн бетәчәк. Уфадан, Мәскәүдән упалнамучлар килеп төшәчәк, диләр. Шулар һәрбер йортны тентеп чыгачак, ат чәчкече, косаркасы-фәлән булган бар кешене кулакка салачак, ди. Ә кулак

итеп язылгансың икән, сиңа каюк. Башта салым өстенә салым, аннан төрмә. Байлык колхозларга. Берзаманны бөтенләй шыр ялангач көенчә урамда торып калуыгыз бар. Чишендереп, талап чыкканчы аягыгызга ыштыр урый башлау хәерлерәк булмасмы, диюем, Әхтәм хәзрәт?

Кышкы кич гаҗәеп тын, Әхтәм мулланың хәтта борыныннан сызгыртып сулыш алуына кадәр ишетелә иде. Хәзрәт көттермәде, үзе дә турыдан ярып салды.

— Ә син әллә безнең турыда бу хәлләрнең берсен дә белми дип уйлыйсыңмы, Әмир? Ай-һай, энекәем, бик нык ялгышасың. Хөкүмәт тоташ наданга чыгарса да, әллә нинди астыртын юллар белән без бер Төркәйгә генә дә җәмгысы биш-алты төр гәҗит алдырабыз булыр, бик белеп тор. Ә анда камунислар күкрәк сугып яза. «Дәүләкәндә биш кулактан ике молотилка, өч нәселле айгыр талап алдык». «Зилаерда, салымнарны үз вакытында түләмәгән өчен, алты семияны Себергә үк сөрдек». Тагын әллә ниләр. Юк, син ялгышма, Әмир. Бүген мине кисәтеп күз күрмәгән, колак ишетмәгән кыйтга ачмадың син. Без бу сәвиттәге талаукысу дәрьясының кай таба акканын бик белеп торабыз. Мин генә түгел, Йосыф, Мирсәяф, Гәрдән — барысы да гәҗит алдыра. Кичләрен әле тегеңә, әле моңа җыелып сөйләшәбез. Менә әллә нинди шәйкеләр оештырып, син юлларда кулак көтеп йөрдең. Ә без Аблай, Әбзән аша урап булса да, күз төшәрдәй малны базарларда сатып бетердек. Әлхәмделиллаһи, без ыштырларны әллә кайчан урап куйдык инде.

— Ярар соң, хәзрәт, мин сезне кисәтмәкче генә булган идем,— дип, Әмир хәтта беркадәр үпкәләгән төсле тавыш белән инде кузгалмакчы да булган иде, Әхтәм мулланың тавышы куып җитте.

— Анысы өчен рәхмәт. Тел төбеңне аңлыйм. Урамда шәрә калып адәм мәсхәрәсе булганчы, авылдан кач, дип әйтергә килүең инде бу синең. Хәлил Уфада әллә кайчан эш белеште инде, качам, качам, Әмир. Тере килеш йонын йолкуга мескен тавык та түзми. Ә мин ничә еллар буена бар Төркәйне авызыма каратып торган, мәдрәсәләр тоткан ир бит әле. Качам, качам, Әмир. Кисәтүеңә рәхмәт.

## 3

Икенче таңда Яков Булгаков йортына барып кергәч, хуҗа кеше әүвәл, аю күргән сыман, хәрәкәтсез торды.

— Парач, парач. Амир килгән, Амир,— дип, тик бераздан гына телгә килде ул, анда да нык тотлыгып.— Сколько лет, сколько зим, как әйтелә, пер дә куриньмисен.

Төпчек Вася, йөгертеп дигәндәй, Әмир каршына урындык китереп куйды. Кунак ялт-йолт килеп күз йөртеп чыкты. Өлкән уллар — Иван белән Николай — берсе-бер күренми. Нина кияүдә инде, Әмир анысын белә. Чөйдә киемнәр аз. Димәк, хәзер өчәү генә яшәп ята болар.

Хуҗа да Әмирнең кемнәрне барлавын чамалады бугай, аңлатма бирүне кирәк тапты.

— Иван да Николай Кушнаринда казер. Петро кияу дашти, пилорамда эшләп юри алар. Ә без өч штук казер, ие, өчау.

Әмир боргаланып торуны кирәк санамады, турыдан ярып салды.

— Качабыз, дисең инде, Яков дәдәй. Колхозлар төзүне шулай хәзерләнеп каршылыйбыз, дисең. Ул турыда ишеткәнсеңдер инде. Булган малны, әз-мәз булса да, аткара белдеңме соң?

Яков та күңелендәгене яшереп маташмады, Әмир күзләренә туры карап әйтте.

— Авыл өскә нинди ураган, нинди кошмар килә — аны анламаска дурак булу киряк. Ә мин, син үзен дә белә, совсем идиот тукел. Конечно, казер син зур начальник, власть синен кулда. Максат куйсан, Себер аткарасын. Однако мин дуресен сулим, син белеп тор. Крестьянны кнут билян куып, колхоз ясап, совет нык ялгыша. Кнутны ат, сыер да яратмый. Ә кеше скот тукел. Ул үзен так просто бауга илтеп тыкмый. И суя башласалар да, аяк-кул бәйлятеп, скот кебек ятмый. Так что Россияне әллә нинди пожарлар да, кошмарлар да кутеп тора әле.

Әмир уйчанланды, яңагында урт сөякләре сикергәләп алды. Ә Яков, мин синең кулда, ихтыярың — бәрәңге дигәндәй, һаман турыдан ярды.

— Минем синнән яшерә торган байлык юк, конечно. Однако ике тана билян бер сыерны без базарда саттык. Калганнар уз урынында. Колхозына талап алырсын син, видно... Захарны бик яраттым. Ярар, ал Захарны. Сарык, казлар киряк әйтсән, алар да ал.

Яковның тавышы кинәт сынган сыман булды. Күзләренә яшь тамчылары бәреп чыккан иде. Юатырга ашыккан шикелле, Әмир тиз-тиз телгә килде.

— Юк, Захарны мин Себернең үзенә тикле барып алдым. Аны Ләпәй ише бәндәләр кулына биреп сансыз итеп булмас. Волкомда әнә атларны РККАга тапшыру өчен комиссия бара. Лутшы шунда илтик. Син дә зерәгә бирдем дип үкенеп яшәмәссең, минем дә җан сызмас. Ну, ә тегермәнең белән теләсәң-теләмәсәң дә хушлашырга туры килә инде. Бер генә тегермән дә, ургыч-суккычлар да

кулак кулында калмый, һәммәсе колхозларга алына, указ шундый.

Көтелмәгән тәкъдим кыстырып, Яков шаккатырды.

— Тигермянда ян юк, однако минем байлык. Чит-ят кулга биру все равно жалко. Колхоз аласынмы мине, юкмы — анысын син решай. Ә мине, давай, уз тигермянда синен кебек засыпкачы калдыр.

— Яков дәдәй, Яков дәдәй,— дип сөйләнә башлады Әмир, ә чынында исә үзе ни әйтергә дә белми, сөенеченнән ике чигәсен тиң әллә нинди көчләр китереп кыскан иде. Яков та Әмирнең нинди хәлгә төшүен чамалады бугай, капылт кына урыныннан сикереп торды да тышка томырылды.

— Мин колхозчы казер, әй, наплевать. Моны юмый булмый. Яков — колхозник, о, боже мой!

Хуҗа тавышы тынгач, пышылдаган шикелле итеп, Анюта түти дә, ниһаять, сүз алды.

— Нинанын малай бар. Ике яшьтә инде. Странно, сина бик ошаган. Нина сагынам әйтә. Чармасянны, тиге якта кулне. Сина салям әйтте. Амир прав, ул дурес юлда, ди...

Чирекле зур шешә белән бал күтәреп кергәч, хуҗа кеше дә шул сүзләрне тезде.

— Син ике сосна арасында адашып калмадын, дурес юл сайладын. Партия арба сикереп утырмасан, син бы пропал, Амир. Наверняка, син иртәгә уже председатель булыр. Однако вожжи не теряй, Амир, вожжи нык тот...

Шундый сүзләрдән соң Әмиргә әле бал тотмаган көенчә дә рәхәт, кайнар иде.

## 4

Колхоз дигән нәмәрсәләр төзелә. Бөтен кешене дә, байлыгын-малын талап, шул колхозга куып кертәләр икән, дигән хәбәр бар Төркәйне яшен уты сыман көйдереп чыкса да, Әмир халыкны җыенга тупларга һаман ашыкмады.

«Мин бер тапкыр коммуна төзеп карадым, авыз пеште инде. Алны-артны чамаламый яр өстеннән баштүбән сикерергә мин бит ахмак түгел,— дип фикер йөртте ул.— Мин коммуна төзеп йөргән чакта, әйдә, мөгез чыгар, ә мин күзәтим әле дигәндәй, Дини гел тик ятты. Күчәрбай — зур авыл, шура үзәге дә. Әйдә, бу юлы Дини, башлап, Күчәрбайны тәртә арасына җигеп карасын әле. Төркәй өчен юрганны аңа карап та сузарга өлгерермен».

Төркәй халкы Күчәрбай базарына йөреп кенә тора. Дини чыгарган «мөгезләр» турындагы хәбәрләр дә бик тиз агыла башлады.

— Дини, хәерсез, камбит җыеп кереп, Габидулла хәзрәт

йортының астын өскә китереп тентегән, ди. Теге аның сандыкларында казына башлагач: «Имансыз кулың белән Коръән шәрифкә кагыласы булма, кяфер», — дип, Габидулла хәзрәт каршы төшеп караган каравын. Мәгәр Дини, хәерсез, наганының түтәсе белән төеп, Габидулланың баш чүмечен чәрдәкләп бетергән, ди. Хәзрәт, мескен, хәзер инде үлем түшәгендә ята икән.

— Сәгыйт байның тегермәнен тартып алганнар, базарда сатарга дип әзерләгән бөтен итен актык кисәгенә тикле җыеп чыкканнар, ди.

— Дини явыз белән Чүпрәк Нәби һәркөн саен әллә ничаклы ирне чиратлап шурага чакыралар да калхузга керергә гариза яздыралар, диләр. Кем гариза язмый, андыйларны Дини, имансыз, Ишмай Харисыннан калган келәтләргә бикләп куя икән...

Имеш-мимешләр болай күпкә киткәч, Әмир, барып, Күчәрбайдагы хәлләргә үз күзләре белән инанмакчы булды. Белеп килгән икән. Кичәге Ишмай Харисының йортына килеп керсә, авылның «камбит» башлыгы Чүпрәк Нәби киемнәре кат-кат ямалып беткән йолкыш кыяфәтле бер ир аламасыннан сорау ала иде. Чит-ят күзнең пәйда булуын ошатмады, ахры. Кәгазьләрен аслы-өсле каплап, җәһәт кенә сикереп торды да Нәби Әмирне янә ишек төбенә хәтле озатып куйды.

— Дини каграз келәттә, Дини каграз Моталлап Вәҗиеннән калхузга гариза яздыра. Сиңа мишәйт итмәс, янына төш тә өйрән...

Кичәге Харис байның олы келәт ишеген каерып ачкач, Әмир әүвәл киселгән агач төбе сыман урыныннан кымшаналмый торды. Таш идәнле келәтнең ике-өч сәнәк чамасы салам түшәлгән бер почмагында әллә суыктан, әллә куркудан бөрешеп-бөгәрләнеп беткән бер ир утыра. Икенчесе стенага беркетелгән агач эскәмия буена тезләнеп бөгелгән дә, кулындагы каләм кисәген тел очына тидереп ала-ала, кәгазьгә нидер яза. Дини үзе үксез бәбкә өстенә ташланырга җыенган карчыга шикелле аның янына баскан. Бер кулында куыгы корымланып беткән уникеле лампа, икенчесендә — наган. Әмирне күргәч, кыяфәтендә кыл да селкенмәде.

— Менә сәвит дошманнарын әлефне таяктан аерырга өйрәтәм әле, туган. Юкса яңа гырамытаны пычак та аңларга теләмиләр болар. Калхуз — алтын арба, ул сезне оҗмах бакчасына илтеп җиткерәчәк, димен. Юк кына бит, канә, берсе-бер гариза язмый. Ну, ничауа. Бөтен атларын, сыерларын, сарыкларын, талап, Харис белән Сәгыйт байның утарларына ябып куйсам, иртәгә үк, ачка тилмергән көчек сымак, минем янга килеп җитә болар.

Келәт ишегенә йозак элеп, шура баскычына менеп барган чакта, Дини янә сукрануын белде.

— Яңа туган песи балалары сымак сукыр безнең халык. Кайда яхшы, кайда яман, һични аермыйлар. Үгет-нәсихәт юлы белән булмый. Песи балаларын да баштагы мәлдә аналарының имиенә көчләп кушалар бит. Боларга да башкача һич ярамый. Бер генә юл — наган, йодрык, камчы. Безнең надан халыкны шулай итеп кенә ипкә китереп була.

Өй эченә кергәндә, Чүпрәк Нәби белән йолкыш ир аламасы урыннарыннан селкенмәгән көе утыра иде. Тупса аша атлап керүе булды, Дини акырып та җибәрде.

— Син әле һаман шушы чирмеш белән чиләнәсеңмени? Ах, анаңны, кабереңне, ялки-палки!

Әмир чамалап-шәйләп кенә калды: Дини керә-керешкә үк теге ирнең муен тамырына наган белән орды. Ир болай да хөнҗү иде, тәнендә чак җаны. Наган сырты әләгүгә, өстәл астына тәгәрәп тә китте.

— Тор, анаңны сатыйм! Кул куй, давай. Юкса бетерәм, изәм хәзер! — дип акыра-акыра Дини сөйрәп чыгаргач, теге мескен тамчы да карышып маташмады, алдына Чүпрәк Нәби китереп тезгән кәгазьләр почмагына тамга төшерде дә, диңгез дулкыны юып алгандай, шундук юкка чыкты.

— Әбзән урамыннан бу, Илмурзиннар күршесе,— дип ачыклык кертә башлады Дини.— Йорт дип аталган алачыгында таракан белән борчадан башка бер җанвар юк. Әле үзен бер атна элек кенә камитит битнатага керткән идек. Шушы йолкышны ияртеп, Сәгыйт бай белән Минҗан кулак ихатасын тентергә кереп чыктык. Эскерт-эскерт байлык тапмадык инде табуын, шулай да бар. Ә бу чирмеш, анасын сатыйм, актыга кул куймый, кулаклардан курка. Мин надан да, мин шыр ярлы, имеш. Менә наган сырты белән китереп соскач, күзе ачылдымы? Шулай, болар белән вәсвәсәләп булмый. Или без үз кубызыбызга биетәбез ул җыен кулак ялчыларын, или алар. Мәгәр совет безнеке, кубыз безнең кулда. Давай, син дә үзеңнең Төркәеңне менә шулай итеп биетергә өйрән.

## 5

Юк, Әмиргә Төркәй халкын биетү кирәкмәде. Март ахырларында, Әхтәм мулланың тулысынча бушап калган йортына беренче кат дәшеп җыйнагач та, егермегә якын гаилә башлыгы колхозга керергә гариза язып бирде. Боларның күбесе шул үткән елда коммунага кергән таныш ирләр, арада Шәрифулла белән Идрис шикелле сыңар арык ат аламасыннан кала сабаны-тырмасы да булмаган яшьләр дә бар

иде. Кеше өйрәтеп торгач, гаризаны ике кулын кесәсенә тыккан Ләпәй дә язып бирде. «Атсыз кешене колхозга алмаска» дигән күрсәтмә булмады бит, шуңа күрә Әмир Ләпәйне дә алды. Ләкин яңа колхоз кешеләрен иң сөендергәне абыйлы-энеле Фазылбәк белән Дәү Сөләйман булды. Болар инде хәерче-йолкыш түгел, икесе тиң абзарларында икешәр ат, өстәвенә колын тота иде. Әмир кызыксына калгач, җавапны тиз бирделәр:

— Авызга су кергәч кенә йөзәргә өйрәнмиләр. Ә безнең өскә, изеп-сытып, ташкын килеп ята...

Колхозга нинди исем бирү турында сүз купкач та, карар кыска булды.

— Безнең исем бар бит. «Кызыл байрак». Коммунадан калган. Бу юлы инде таралмабыз, шаять. Әллә ярамыймы?..

Шулай итеп, яңа колхоз да «Кызыл байрак» булды. Рәислеккә дә, янә килеп, Әмирне сайладылар.

— Син өйрәнгән инде, әйдә, син тарт...

Атларны, дирбия-камыт, арба-чаналарны хуҗасыз калган Әхтәм мулла ихатасына тупларга дип хәл иткәннәр иде. Икенче таңда ук, авылда беренче булып, Әмир Афоньканы шунда илтеп бирде. Ихатасына кайтып инде сыерны да аранынннан чыгара башлаган иде, әтәч сыман, тырнак-бармакларын кабартып, Гөлтуташ очып кунды.

— Сәвит бүлеп биргән сыерың бармы әллә? Миңа ияреп, минем бирнә булып килгән мал булыр бу. Дәхелең булмасын!..

Башка хуҗалыкларда да нәкъ шул рәвешчә тавыш булган икән. Ходайның рәхмәте димичә, ни әйтерсең? Сыерлар турындагы ызгыш-талаш шуның белән бетте. Атларны бер лапаска җыю белән генә чикләнделәр. Ләкин мал мал шул инде ул, гариза язып колхозга кермәгән бит. Су эчерергә йә яланга чыгарырга дип капка ачтылармы, элекке ихаталарына кайталар да керәләр. Хуҗалары яшереп кенә сыйлыйлар бахырларны, муеннарына борын төртеп балавыз да сыгып алалар. Ләкин башка чаралары юк, ахырда барыбер Әхтәм мулла абзарына китерәләр инде...

Май аенда, авылга терәлеп торган иң якын басуларны алып, сука-тырма эшләрен башлаганнар гына иде, чәчүлек орлык җитмәве ачыкланды. Дәү Сөләйман белән Шәрифулланы алып, яңа рәис Күчәрбайга китте.

— Мин бер авылга өч калхуз төзедем, үземә дә җитми,— дип, Дини аны эт өсләткән шикелле кире борды.— Минем кебек әнә кулакларны тала.

Ятып калганчы, атып калыйм, дип, Әмир бик өметсез кыяфәттә Бүздәкнең үзенә үк чыгып киткән иде. Волостьны-

кылар бөтен тирә-юньне талагандыр инде, «Кызыл байрак»-ның өч арбасына да бодай, солы, арыш төяп җибәрделәр. Шулай итеп, беркадәр сузыбрак булса да, чәчү барыбер үтте. Ә аннары инде янә келәтләрне, сарайларны җыеп, Әхмәт авылы белән ике арадагы калкулыкта ферма төзеделәр...

Әмир, ызгыш-бозылыштан, таралудан куркып, уңыш бүлеп биреләчәк көнне көткән иде. Күңеле сизгән икән. Август ахырында ферма янындагы ындыр табагы булып исәпләнгән әвенлек астына җыйнап, Әмир «хезмәт көне» дип авызын әле ачкан гына иде, Дәү Сөләйман белән Фазылбәк икесе берьюлы ырлап ябыштылар.

— Нинди хезмәт көне ди инде ул, Әмир? Без икешәр ат белән кердек, сабан белән кердек, орлык белән. Ә Ләпәйнең әнә чурты да юк. Галах Ләпәйгә алтмыш хезмәт көне язгансың, безгә дә шулмы?

— Юк, сез сабан сөргән, чәчү чәчкән кешеләр. Өстәвенә, балта тотып, абзар-кура төзүдә эшләдегез. Сезнең һәрберегезгә дә берәр йөз хезмәт көне,— дип, Әмир тынычландырырга тырышып караса да, Дәү Сөләйман инде бала башы чаклы йодрыкларын селки-селки кызды.

— Галах Ләпәйгә алтмыш, миңа йөзме? Кит, анаңны сыпырыйм. Атларны алам да мин лутшы кулакларны басарга юлга чыгып китәм. Төкерим колхозыңа, кадалып кит!

Әмирнең йөзе-кыяфәте тамчы да үзгәрмәде, ә сүзләре ирләрне җиргә кадаклап куйган сыман итте.

— Колхозга төкерәсең икән, төкерәсең инде. Колхоз — берсеннән-берсе яшьрәк киленнәрне хатын итеп алган мулла түгел бит ул. Көчләп тотучы юк, дүрт ягың кыйбла. Мәгәр шунысын бел: колхоз — ул бит сиңа коммуна гына түгел. Колхозларның фонды мәңгелек, кат-кат бүленми ул. Кичә китереп биргән атларыңны да, арба-чанаңны да син колхоздан кире алалмыйсың. Муллалар гына элек «талак, талак» дип кычкырган да хатын аерган ул. Ә колхоз белән, Сөләйман дускаем, алай уйнап булмас. Менә шуннан соң инде үзең уйла. Мулла сымак «талак» дип кычкырып ике атыңны ташлап китәргәме сиңа, әллә инде гомереңнең соңгы сәгатенә тикле бергә-бергә тормыш итәчәк колхозда калыргамы?..

Галах Ләпәйгә җиде, үзенә унөч капчыкка якын икмәк эләксә дә, Дәү Сөләйман калды. Чыбык белән суккалаудан балта түтәсе сынмый дигәннәре хак шул инде, ни хәл итмәк кирәк?

## 6

Көзен Күчәрбайда Әмирне утлы таба өстенә бастырып биеттеләр. Бәләбәйдән нindидер җир комитеты башлыгы Яковлев дигән бәндә, аңа ияреп волость үзәгеннән тагын алты-

җиде кешелек комиссия килеп төшкән икән. Барыннан да бигрәк шул Яковлев, дагалы итекләре белән тибә-тибә, идәннән ут чыгарды.

— Йөз дә кырык хуҗалыклы авылдан нибары унҗиде гаилә колхозга тартылган, оят, хурлык! Иптәш Сталин быелгысы елны «бөек борылыш елы» дип атады, «бишьеллыкны дүрт елда үтәргә» дип, партиянең генеральный курсын игълан итте. Бөтен ил күләмендә кулакның класс буларак нәселен корыту, авылдагы барча ярлы һәм урта хәллеләрне колхоз-совхозларга тарту өчен көрәш бара хәзер. Ә сезнең бу Нәгыймов дигән рәис кисәгегез авылындагы бер генә кулакны да Себергә озатмаган. Ул хәтта Рөстәмбәк кулындагы тегермәнне дә тартып алмаган бит. Юк, бу коммунист түгел, бу — либерал! Бу — корт шикелле йомшак эчле бәндә. Алай гына да түгел. Иптәш Сталин җитәкчелегендәге Үзәк Комитетның корыч сәясәтенә, тәгәрмәчкә таяк тыккан кебек, мыштым гына аяк чалып ятучы оппортунист бит бу, ревизионист! Йөзенә коммунист битлеге киеп алган троцкийчы бу һәм дә эчке дошман! Моның ише икейөзле, умырткасыз, җебегән бәндәләргә партия сафларында урын булмаска тиеш. Оппортунистлыгы, либераллыгы өчен төрмә сәкесенә моны, лагерьларга!..

Әмирнең бөтен тәне уттай кызып чыкты. Күз алдыннан Зифа, Тимерҗан, тәпи йөри башлаган нәни Вәзирә, тагын авырга үтеп, яңа бәби көткән Гөлтуташның йөзләре йөгереп узды. Йа Ходаем! Хәзер шушыннан ук кулларын каерып алып чыгарлар да, Әмир үзенең газизләрен моннан ары мәңге күрмәсмени?! Шаһи-Морат әйтте: «Син арба җигеп тау төшәргә мәҗбүр ителгән атсың. Йә арбаны хуҗалар чыбыркылап куалаган җиргә илтеп җиткерәсең, йә булмаса муеның сындырасың», — диде, кат-кат кисәтте бит. Нигә тыңламадым, нигә Гәрдәннәр, Йосыфларны җәлләп маташтым? И мин, ахмак! Синнән башка торып калгач, ул Гөлтуташ ничек көн итә дә, ул балалар ятим көе ничек үсә инде?..

— Күчәрбай авыл советы да совсем эшләмәгән, Динислам иптәш тә моңа нык гаепле, — дигән сүзләр генә Әмирне җиһанга кабат кайтаргандай итте. — Колхоз төзү өчен гаризалар җыйган вакытларда Төркәйгә бардыңмы син? Партячейкадан, авыл советыннан, йә булмаса комбед составыннан ярдәмчеләр-фәлән җибәрдеңме? Волость үзәгеннән берәр милиция хезмәткәрен чакыртып, Нәгыймов янына юллап карадыңмы? Әһә, юкмы, кем, Динислам? Димәк, син Нәгыймов белән бер үк тегермәнгә, кулак тегермәненә су коясың. Димәк, син үзең дә оппортунист, сиңа да шул мөһер...

Кара төн уртасына кадәр сузылган җыелышта Әмиргә, заманында Кызыл Армиядә йөргәнлеген, коммуна төзүен ис-

кә алып кына, каты шелтә биреп җибәрделәр. Шелтә кирпеч түгел, муенга асып йөрисе юк, монысына түзеп була иде. Шулай да нинди зәһәр ут белән шаяруын барыбер аңлады ул, «төрмә, лагерь» дигән янау-кисәтүләр аны юл буенча талап-көйдереп кайтты...

Урамга килеп керсә, өендә ут яна. Гөлтуташның аны сукыр лампа яндырып көтүләре яңалык түгел иде. Бүген исә уникеле лампаларның икесенә дә ут эленгән, нинди туй бу?

Ихата түрендә ялкау-үшән генә пошкыргалаган ат тавышын да ишеткәч, Әмир бөтенләй сагаеп калды. Яков дәдәй төн куна килеп йөрмәс, Рәҗәп бабай чирле, Әбелсаттар агасы белән алыш-биреш беткән. Кунак итеп көтәрдәй бер кеше юк, кем булырга мөмкин?

Бусагадан узып өй эченә кергәч, өстәлне тирәләп утырган бер көтү ят кешеләрне күрде дә, уклау йоткан сыман, Әмир туктап калды. Йөзен урысныкы кебек сакал-мыек баскан, поп шикелле гел кап-кара киемгә төренгән бер ир утыра. Янында, салам сабагыдай сап-сары чәчләрен кылт икегә ярып, толымнарын иңбашына салган, түгәрәк якалы күлмәкләре өстенә саргылт төстәге катлы-катлы муенсалар аскан олы күкрәкле, дәү гәүдәле хатын. Өстәлнең каршы ягында — кайсы теге хатынга охшап сап-сары чәч үстергән, кайсы иргә тарткан берсеннән-берсе кечерәк өч сабый. Аңлатасы-сорашасы түгел, бер гаилә булырга охшаганнар болар.

— Әмир, Әмиркәем, зур сөенеч бездә. Менә теге чакта китеп югалган Бикмөхәммәт абый табылды бит,— дип, Гөлтуташ урыныннан сикереп торып аңлата башласа да, Әмир әле һаман бүкән шикелле хәрәкәтсез калды, баш миендәге бер генә сыр да селкенергә ният итми иде. Нинди Бикмөхәммәт? Кайчан, нишләп югалган ул? Бер югалып, бер табылып торырга ул соң саулык бәрәннәргә ияреп китә торган азгын тәкәмени?

— Дәлни Вастуктан Бикмөхәммәт абый кайтып төште бит, Бикмөхәммәт абый. Җәмәгате, балалары белән. Танымыйсыңмыни? — дип, Гөлтуташ килеп аның кулыннан сөйри башлагач та, Әмир әле, яшь кияү белән бер мунчага керергә шүрләгән сазаган кыз шикелле, аяк тери-тери каршы торды. Гөлтуташны кара, вәт әйтте бу! Әмир кайчан да булса Бикмөхәммәт дигән кешенең җәмәгатен, гаиләсен барып күргәнмени?!

Өстәл артыннан, ниһаять, бер сукса үгезне егардай таза гәүдәле ир калыкты.

— Исаньмы-саумы, Амир.

Хуҗа шул чагында гына кунакның каш астыннан көйдереп карый торган карашын тотып алды да, утка пешкән кеше шикелле, дерт итеп куйды.

— Бикми! Ломовой! Быр-рат!

Икенче мизгелдә инде ирләр, бер-берсен кочакларына алып, шап та шоп суккалый башладылар. Өстәл артыннан, тыйнак кына елмаеп, сары чәчле хатын торып басты. Агартылган мич буеннан, яулык очын яңак-күзләренә тидергәләп, Гөлтуташ күзәтеп торды. Әмир исә боларның берсен-бер күрми, ул Бикмөхәммәтне кочагыннан аермаган көенчә төпченүен генә белә иде.

— Безнең туйдан соң ук бертөрле дә хәбәрең булмады бит. Кая гына китеп югалдың да кай якларда йөрдең бу кадәрле гомер? Сине сөйли-сөйли Гөлтуташның теше төшеп бетте. Бабай, мескен, анда сине сагынудан чиргә сабышкан, ди. Кайда югалып йөрдең син, сөйлә, давай.

— Сейчас, сейчас, Амир, не торопи, родной, — дигән җавап сүзләрен ишеткәч, Әмир аптырап китте. Бәрәч-бәрәч, нишләп әле урысча сөйләшә дә, үгез сыман таза гәүдәле ирнең иреннәре, кулы нигә бизгәк тоткан сыман калтырана?

Бикмөхәммәт үзе бик кыенсына иде, күрәсең, ул читкә борылып кына күз төпләрен сөрткән сыман итте. Йөзе белән кабат борылгач та, Әмир сорауларына җавап бирергә ашыкмады әле ул. Беренче эше итеп, сары чәчле хатынны терсәгеннән алды.

— Познакомься, Амир, это моя жена. Ее Лизой зовут. А это — наши дети. Миша, Артем, Зина.

Ничарадан бичара кыяфәттә Әмир сары чәчле хатынның кулын барып кысты. Югалып калуы шул дәрәҗәгә җиткән иде, күрәсең, ул хәтта сабыйларның да берәм-берәм кулын кысып чыкты. Ә зиһенендә мең төрле уй кайнады. Тукта, нишләп монның хатыны марҗа да, үзе ник гел урысча гына сөйләшә соң әле? Туган телен онытып бетергәнме бу, әллә инде белдеклелеген күрсәтмәкче булып кыланамы? Аңа калса, без дә хәерче арбасыннан төшеп калган шөшле-мазар түгел, урысның «нет» белән «нельзя» дигәнен генә аңлыйбыз бит инде.

Әмирне ниндирәк ут-ялкын көйдерүен чамалады бугай, бер дә уйламаганда-көтмәгәндә Бикмөхәммәт аны ихатага дәште.

— Когда заходил, ты не обратил внимания, конь на месте? Он же не мой, я в Аблае у соседей занял. Если потеряю, долой башка. Айда, выйдем, посмотрим.

Ихатага чыгып, лапас буендагы каен бүрәнәләр өстенә җайлап утыргач кына, юан итеп төргән тәмәкесен пыш-пыш тарта-тарта, Бикмөхәммәт үз башыннан кичкәннәрне сәйлән сыман тезеп бәян итте. Ул, чыннан да, туган телен нык оныткан икән. Әмиргә ул сөйләгән һәрбер сүзне күңеле аша үз ягына ябарга туры килде.

— Адәм баласын, күрәчәктән бигрәк, томаналык, нәфес сукбай итеп йөртә, Әмир туган. Мин менә ул Колчак дигән эткә ияреп, туган җирдән нигә киткән инде? Советлар булган бар байлыкны талый, ә адмирал Колчак гаделлекне кабат урнаштыра, һәр кешегә югалган-таланган малын кайтарып бирә, имеш. Кайтарган ди сиңа, тот капчыгың. Эткә бишенче сыйрак сымак, бик кирәк иде ди аңа минем шикелле җыен хәерче-хөрәсән... Казанга барып бер эшелон алтын урлады да Колчак, эт җан, океан аръягына чыгып ычкынмакчы булды. Әле ярый кызыллар Иркутскида койрыгыннан каптырып алдылар да Байкал өстенә чыгарып чәпәделәр... Ә без, яңа гадел патша таптык дип алданып, аңа ияреп йөргән җыен сантый, көтүчесез калган мал көтүе сыман таралышып беттек. Кем атаман Семенов бандасына ияреп китте, кем Кытайга. Мин, кызыллар, коммунистлар үченнән куркып качкан буржуйларга, үзем сымак томаналарга ияреп, Владивосток янындагы Артем дигән калага барып чыктым... Син белмисең инде, Тын океанның Япон диңгезе буенда утырган бер шәһәр ул. Бәләкәй генә үзе. Анда ике катлы йортлар өчәү-дүртәү генә. Туфрагы, яртылаш диярлек, таштан гына тора. Багана утырта башласаң, ярты көн буена чиләнергә кирәк. Менә шундый Алла каргаган җирдә дә суган, кәбестә, бәрәңге, шалканише вак-төякне тырыша-тырмаша үстереп ята халык...

Тәмәкесе беткән саен, Бикмөхәммәт һаман юанрагын, «кәҗә тоягы» дип аталган яңасын төрә торды. Әмир тәмәке сасысына көч-хәл белән түзде.

— ...Вәт менә шунда, Николай дигән попка барып ялландым мин. Алдан әйтим инде, минем хатыным буласы Елизаветаның әтисе иде ул. Усал булды, мине батрак урынына тотты, җикте-изде, дип һич зарлана алмыйм. Крестьян хуҗалыгында нинди эш бар — шулар булды инде. Ат карадым, печән чаптым, утынына йөрдем, хәтта әле кайчагында чиркәвендә каравылчы да булдым... Ләкин, ай-һай, саран поп иде ул. Карт-карчыклар сәдакаише әйбер китердеме, анысын идән астына. Сөт өсте, май, балавыз, эремчек китерделәрме, шалт келәткә. Әнә шулай, йомыркалар өстенә утырган ана каз шикелле, гел үз астына җыйды... Мәгәр егерме икенче елда Артемга да Совет власте дигән тәртип килеп җитте. Чиркәүләрне, кулакларны, җыен байбәтчәне талый башладылар. Менә шул чагында Николай атакай үзенең кызы Лизаны миңа бирде дә безне яңа йортка бүлеп чыгарды. Лиза бердәнбер балалары иде, шуңадырмы иң шәп атларын да, тарантасын-кошевкасын, сыерын-кәҗәләрен, шарлы караватларын да — бөтенесен җыеп безгә бирде. Менә шулай итеп, попның култык астында гына яшәп яттым мин...

Авыр хатирәләр көтә иде бугай, Бикмөхәммәт тынып калды. Озын-озак итеп тәмәкесен суырып утырды. Ә аннан соң, чыннан да, усал, тонык тавыш белән дәвам итте.

— ...Бәла ялгыз йөрми дигәннәре хактыр инде. Былтыр Лизаның әтисе белән әнисен бер-бер артлы җирләгән идем, быел менә, синең сымак коммунистлар килеп, колхоз абзарына күченергә кыстый башладылар. Син ачуланма инде. Ләкин мин солдат сымак бер стройга басып, бер үк табактан бер үк төрле чиле-пешле, майсыз ботканы сосып йөрергә шыр сантый ук түгел. Николай атакайдан калган бөтен малны булдыра алган кадәр саттым-өләштем дә, балаларны, төенчек-сандыкларны җыйнап, менә монда кайттым. Тик гади халык өчен кайда да ут икән...

Шактый гына вакыт буе тын утыргач, Бикмөхәммәт сүзен очлап куйды.

— Син курыкма, Әмир, мин сиңа күләгә-мазар төшерәчәк түгел. Минем хатыным — марҗа, балаларым — урыс, үзем дә «Ләилаһәиллаллаһы» дигән гыйбарәдән башка бер авыз да татарчаны белмим. Авыл җирендә безгә урын юк. Әле кайтышлый ук, Уфада тукталып, мин белештем инде. Уфада әллә ничаклы завод-фабрикалар, пилорамнар, мастерскойлар ачылган икән. Йорт-каралты сатарга әзер торучылар да байтак. Кесәдә — рәт, тәндә куәт бар. Исән-сау муенга камыт табыла ул. Сиңа авырлык салмыйм. Бер-ике көн торам да мин Уфага китәм...

Әмир таңга кадәр йоклый алмый чыкты. Ерак Көнчыгышта яшәп яткан Бикми кайтып төшкән. Партия нык тотынган, каты буа, димәк. Бөтен Рәсәй ут эчендә икән. Камыт бауларын кысарга, дилбегәне кыскартырга кирәк.

## ҖИДЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Кайтуына әле ике тәүлек тә үтеп китмәгәндер, Күчәрбайдан шомырт кара атны ак күбеккә батырып килеп җиткән чапкынның сүзләре Әмирнең бер мизгел эчендә ис-акылын алды.

— Дини-апартунисны, кул-аягын бәйләп, Бәләбәй өтермәсенә алып киттеләр. Аның урынына хәзер Сәхипгәрәев дигән яңа рәис килде. Бүген кич үк олы җыелыш була. Сине камсамулларын ияртеп килеп җитсен, диде...

Менә сиңа мә! «Сәүвит быласте, калхуз» дип йөрүдән кала бер дога-сүрәне дә белмәгән, «дөнҗада мирауай эрвәлүтсә» ясарга хәзерләнеп үзен «казарма»да яшәргә мәҗбүр

иткән «ата камунис» Динине дә дошманга чыгарганнар. Боларда, чыннан да, вәс-вәс килеп, баштан сыйпап маташу, үгет-нәсихәтләп тору юк икән бит. Син — боларның арбасына җигелеп, камыт кигән бәндә — мылтык обоймасына кертеп утыртылган патрон кебек икән. Болар кушкан чакта, болар теләгән җиргә чыгып очмадыңмы яки эчеңдәге дары-филтә ише әгъза-нигезләрең бозылган булуы ачылдымы — нәкъ атмый калган патрон рәвешендә обоймадан чыгарып ыргыталар икән бит сине. Болар өчен кеше язмышлары, адәм җаны тишекле бер тиен хакы гына икән...

Шушындый уйлар эчендә янган Әмирне һәм аңа ияреп килгән Төркәй комсомолларын Күчәрбайдагы олы шура йорты халык белән шыгрым тулган көе каршылады. Кичә генә «яңа тормыш» юлына баскан колхозчылар, кызыл яулыкларын баш түбәсенә чөйгән комсомолка кызлар, җидееллык ШКМ укытучылары, ярлылар һәм «алласызлар» комитетларында әгъза булып торучылар — кем генә юк. Әмир танып-белми торган чит-ятлар да байтак. Әнә түрдәге тәрәзләр буена, президиум өстәле дигәннәреннән билгеле бер ара калдырып кына, күн курткалы милиция вәкилләре, шәһәр киемендәге эреле-ваклы, мыеклы-мыексыз унга якын ир-ат тезелеп утырган. Һәрберсе аякларын тезләренә атландырып салган, куллар кушырулы, йөзләр җитди, вәкарь. Күрәсең, боларның һәркайсы да нотык тотарга әзерләнә инде.

Әмир, алга узып, иң беренче рәттә урын алды. Кызыл төстәге яңа постау япкан өстәл артында, кызып-кызып, таныш түгел ир-ат сөйли иде.

— ...Әле быел гына «Правда»да Владимир Ильич язып калдырган өр-яңа бер хезмәт басылып чыкты. «Бөек башлангыч» дип атала ул. Социалистик ярышны ничек оештырырга? Ильич менә шул турыда безгә бәян иткән. Советлар Союзының барча коммунистлары аны бүген Ильичның төп васыяте сыман кабул итте. Илнең һәр почмагында крестьяннарны колхозларга тарту буенча ярыш бара хәзер. Менә безнең Башкортстан җөмһүрияте дә күрше Татарстан белән үзара ярышка чакырган килешү төзеделәр. Кем җиңеп чыга да кем хурлыкка кала — үзебездән тора. Моның өчен безнең максат ачык. Ул крестьяннарны тоташ рәвештә, йөз процент итеп колхозларга тарту...

— Кем бу? Сәхипгәрәев дигән яңа рәисме әллә? — дип сорады Әмир янында утырган яшь егеттән, ярым пышылдап кына.

— Шул инде, шул. Яңа себерке... Канкай.

Әһә, исеме Канкай икән. Әмир аның төс-кыяфәтенә җентекләбрәк күз йөгертеп чыкты. Беркадәр какча булып кү-

ренсә дә, озын, таза буй-сын. Чәчен пәке белән кырып алгангадыр инде, кавын шикелле шоп-шома булып ялтырап торган түгәрәк баш. Очлары өскә бөтәрләнгән куе, кара кашлар. Кылыч сыман борын. Шакмак мыек. Нурсыз, салкын караш. Бу кеше коры холыклы гына түгел, бик эре дә сыман. Әмир кергәннән соң да ун минутлап сөйли торгандыр инде, ә бармакларын ике каптырмалы киң каеш астыннан чыгару турында уйлап та карамый бу. Монда Дини сыман йодрыкларын югары чөеп сөйләү гадәте бөтенләй юк бугай. Хәер, кыяфәт тә башка. Өстә — сәдәпләре генә түгел, хәтта тукымасы да ялык-йолык килеп торган өр-яңа гимнастерка. Мөгаен, ул аны әле кичә генә берәр кала әртилендә тектереп алгандыр инде. Аста — зәңгәрсу төстәге киң галифе чалбар. Аякларында — кунычлары үтүкләгән шикелле ялтырап торган күн итекләр. Бары да яп-яңа, бу кеше үз кадерен бик тә белә бугай. «Яңа себерке» бит, карап карыйк, син ничекләр итеп себерерсең икән?..

Канкайдан соң сүзне Бәләбәйдән килгән Гарипов фамилияле ир алды да тәрәз буена тезелеп утырганнар белән таныштыра башлады. Бәрәкалла, болар кунак түгел, ә күчәрбайлылар, төркәй, әхмәтлеләр янына колхоз төзешергә килгән ярдәмчеләр икән. Әмир аларның элекке хезмәт урыннары турында ишеткәч тә, ачы суган капкан сыман, шундук йөзен сытты.

— Мирсәяпов — моңа кадәр «Әктәберски натисык» типагырафиясендә эшләп килгән иптәш. Сәлимов канат-аркан завутыннан. Бикбулатов иптәш элекке Гутман завутында чыныгу алган. Ходайбирдин фанир фабригыннан... Авылларда калхузлар төзүдә ярдәм итү өчен, Уфаның бер үзеннән генә ике меңгә якын эшче-камунислар барча вулысларга чыгарып җибәрелде. Үзәк кәмитит әле тагын егерме биш мең алдынгы эшчене авылларга җибәрү турында карар кабул итте. Эрвәлүтсиянең гигимуны булган пырлитарият менә шул рәвешчә сезгә ярдәм кулын суза...

Йа Ходаем! Айлар-еллар буе типографиядә хәреф хатасы санап торган Мирсәяпов белән фанера keләйләп яткан Ходайбирдин, авылга килеп, төркәйлеләрне иген игәргә өйрәтмәкчемени? Моннан соң Табор тугаенда йә булмаса Яшке яланында кайсы иген орлыгын кайчан чәчү турында кичә аркан ишкән Сәлимов белән шөреп-гайка борып торган Бикбулатов сыман килмешәкләр күрсәтмә бирәчәкме? Җитмәсә, Мәскәү, Ленинградтан, башка калалардан тагын егерме биш мең кеше киләчәк, ди бит әле бу бәләбәйле Гарип. Ну, ишәк чумарын ишәчәк соң болар! Болай итеп сузылган «ярдәм» кулларын сугып сындырасы!..

— Моннан ары һәр калхузда аерым бер упалнамуч бу-

ла. Партия алдында алар персидәтелләр белән бер үк дәрәҗәдә җавап бирәчәкләр, — дигән яңа сүзләрне ишеткәч, Әмирнең колаклары тырпайгандай булды. Әһә, безнең өлешкә нинди балык эләгер микән? Чуртан булырмы ул, табан-кәрәкәме? Авылга килеп нинди мөгез чыгарыр да, ни майтарыр? Волкомга йә ячейкага барып Әмир турында сата-чага торган елан булып чыкмаса ярый әле тагын...

— Төркәй авылына упалнамуч булып Сабаев Сабит иптәш билгеләнә, — диде бәләбәйле Гарип.

Әмир, ялт итеп, тәрәз буендагыларга күз йөгертеп чыкты. Әнә арадан берсе аңа текәлгән дә елмаймакчы була. Төскәбиткә өлкән түгел икән, бик күп булса, моңа егерме җидеегерме сигез яшьтер. Чәче күмер эскәге белән кыздыргандай бөдрә. Күлмәк-пинжәкләре әллә ни яңа түгел, әмма үтүкләнгән, пөхтә. Башкалар сыман кулларын күкрәгенә кушырып утырмый, эрелек юк, димәк, чуртан булмас...

— Бер арбаны җигелеп тартасы бит. Әйдә, таныш булыйк инде, Әмир абый, — дип, тәнәфестә упалнамуч Сабит үзе килеп аңа кулын сузды. Аннары «бик белеп тор» дигән кыяфәттә өстәп куярга да онытмады. — Фамилиям Сабай булса да, халык миңа яңа кушамат такты. Хәзер эте дә, бете дә мине Чапай дип кенә йөртә. Чапай Сабиты, Упалнамуч Чапай, бетте-китте.

Тиз-тиз генә булса да, берничә авыз сүз алышып өлгерделәр. Сабит соңгы елларда Уфаның шырпы фабрикасында партячейка сәркатибе булып торган, тумышы белән әллә ни ерак түгел, алтмыш-җитмеш чакрымдагы Бозаяздан икән.

— Мин синең колхоз эшләреңә кысылырга, сине өйрәтергә исәпләмим, — диде ул, үзе үк ике арадагы ызаннарны ачыклаган сыман. — Минем бурыч: Төркәйдәге һәрбер ярлыны да, урта хәллене дә колхозларга тарту, миннән шул сорала.

— Ә кулаклар? Каршы торучылар? — дип күзләрен акайткан Әмиргә каршы Сабит кулларын ишек ягына төбәп җавап бирде:

— Әйдә, керик. Хәзер аңлатырлар.

Ишектән эчкә узуга ук, Әмир елан туе күргән шикелле гаҗәпләнеп калды. Иркен өй эчендәге барча урындык-эскәмияләрне тәрәзә буйларына алып бетергәннәр. Уртада икеөч кеше утырырлык сыңар эскәмия генә торып калган. Кызыл постаулы өстәл артына яңа рәис үзе, янәшәсенә Бәләбәй түрәсе Гарип, күн курткалы ике милиционер, кызыл косынкалы комсомолка бер кыз тезелеп утырганнар. Әмир белән Сабитка бүлмә уртасындагы ялгыз эскәмиядән урын күрсәттеләр. «Вәт, анаңны сатыйм! — дип сүгенә башлады Әмир, әмма үзе моны тышка чыгармады. — Әйтерсең болар — ка-

зыйлар да, ә мин — җинаятьче. Гел судтагы сыман кыланалар болар».

— Йортларын-байлыкларын канфискавайт итеп, үзләрен бер кат киемнән Себер җиренә сөреп җибәрәчәк кулакларны ачыклыйбыз хәзер, — диде бәләбәйле. — Төркәй авылына зәдәние — төгәл унбиш прасинт. Давай, Нәгыймов, кулакларны сана. Син әйткәннәрне, эспирвай, авыл сәвите исемлегенә теркәп куябыз да аннары аны Бүздәк валкумында раслатабыз.

Әмирне әле беренче сүзләр үк елан чаккан шикелле куырып алган иде. Тора-бара ул инде ярга чыгарып ташланган балык кебегрәк авыз ачты да катты.

— Ничек, ничек инде ул, төгәл унбиш прасинт? — диде ул бераздан гына, ияген чак селкетеп. — Безнең Төркәйдә хуҗалыклар саны йөз кырык та юк бит. Унбиш прасинтың... ул егерме йорт була. Безгә аның чаклы кулак каян килсен?

Төкерекләрен чәчә-чәчә кычкырып, Гарип урыныннан кырт сикереп торды.

— Син безнең партия карарына эрвизия ясамакчы булма! Эрвизәнист булсаң, әнә Дини сымак, таш өтермә сиңа! Унбиш прасинт дип зәдәние җиткерелгән икән, ызначит, унбиш прасинт. Бер прасинт ким түгел! Татарстаннныкылар белән ярышта оттырырга без дүрәкме әллә?.. Аннары... без дөнҗада мирауай эрвәлүтсә ясарга җыенып йөргән мондый баеуай чорда син әллә каммунизымга ак якалы чиста күлмәк киеп кенә барып кермәкчеме? Акылың котмы синең, кем, Нәгыймов? Мирауай эрвәлүтсәне аны, эрвизәнист, кулны канга буямый гына ясап булмый. Һәрбер эрвәлүтсә корбан таләп итә. Дошман каны — дуңгыз каны бит ул, шуны аңладыңмы? А ну, давай, кулакларны сана!

Әмир сынган иде, тиз-тиз тезеп китте.

— Рөстәмбәкне языгыз. Йосыф белән Гәрдән кулакларны. Итче Мирсәяфне... Икмәк качырып яткан Карак Хафиз белән аның улы Борһан... Аерым кибет тоткан Ибниулла карт та канфискавайт ителәсе исемлеккә кертеләдер инде... Аннары... теге, ни, итәкләренә ут капканны сизеп авылдан чыгып качкан Әхтәм мулла белән Хәлил хәлфә дә сезнең исемлеккә кергән булыр иде.

— Юк, Әхтәм мулла чутланмый! Качыргансың икән, әле моның өчен җавап бирәчәксең! — дип, Гарип яшелле-кызыллы тавышлар чыгарып кычкыргач, кайнар су белән сибеп өркетелгән кеше шикелле, Әмир янә куырылып калды. «Пычагым кергере, кемне генә кара исемлеккә яздырырга тагын?!»

— Авылыгызда калай түбәсе булган, атлы чәчкечләре, косаркасы булган кешеләр юкмы әллә? — дип, күн курткалы

милиционерларның берсе ярдәмгә килгән шикеллерәк итте.— Аннары, башкаларны колхозга кермәскә дип котыртып ята торган, аяк чала торган дошман элемент та дачуртадыр әле.

Берзаманны Әмир теленең ни әйткәнен колагы ишетмәс хәлгә килгән иде инде.

— Хәбине языгыз соң алайса, Хәйберахман дигән кырхабурны. Аның куписларныкы сыман сиртмәле тарантасы гына да икәү...

## 2

Берәр атнадан соң Күчәрбайдан, күптән түгел генә явып үткән беренче кар боламыгын ерып, дүрт-биш арбалы олау килеп җитте. Арба саен Чүпрәк Нәбинең аерым биләмәсе булып исәпләнгән комитет ярлылары, яннарында наган кобураларын корсакларына ук китереп таккан ике милиционер. Олау башлыгы — әлбәттә инде, Упалнамуч Чапай.

— Кулакларны канфискавайт итүне кайсы йорттан башлыйбыз? Давай, команда бир,— диде ул үтә коры, боздай тавыш белән.

Әмир атарга хөкем ителгән бичара корбан күндәмлеге белән Рөстәмбәкләр ихатасына таба атлап китте. Бераздан барыбер дә аяк атлаулары ышанычлы, башы текә иде. Аю биеткәнне тамаша кылырга баралар диярсең, күчәрбайлыларның олавы артыннан ярты Төркәй халкы ияреп йөрде. Әле кайчан гына спектакль куеп йөргән Сажидә, Зәйнәпбикәләр, Идрис, Шәрифуллалар, ярым әпә-ярым сакау Ләпәй, колхоздан чыгып качмавына сөенеп туя алмаган Дәү Сөләйман, яңа мәктәптә латин әлифбасын су урынына эчә башлаган бер көтү бала-чага — кыскасы, санап кына бетермәле түгел.

Үзен нинди язмыш көтеп торуын чамалагандыр инде, Рөстәмбәк комиссия әгъзаларын бер генә сүз дә әйтмичә, камчы белән ярылган ат шикелле күндәм каршылады. Упалнамуч Сабит, ике милиционер, Нәби ярлылары бөтенесе дә, беренче булып, эшне өй эчендәге бар байлыкны кәгазь битенә теркәүдән башладылар. Әмир үзе, аны-моны уйламыйча, олы чаршау белән бүленгән хатын-кызлар ягына барып кергән иде. Бакса, Рөстәмбәкнең олы кызы Сәйдә почмактагы тимер сандык янына килеп баскан да инде өченчеме-дүртенчеме кат күлмәген, тартып-сузып, өстенә киеп тора. Кызлар мунчасына килеп кергән төсле коелып төшкән Әмир тавыш-тынсыз гына кире борылырга мәҗбүр булды.

Әмма бөтен кеше дә Әмир сыман юмартлану, күз йомулар күрсәтеп маташмады. Рөстәмбәкнең унбер яшьлек уртанчы улы Гамил, өстенә кигән киемнәреннән кала, тагын бер өр-яңа бишмәтен дә култык астына әләктереп чыккан икән. Рөстәмбәкнекеләрне урамдагы буш олауларның берсенә те-

зеп утырта башлагач, моңа кадәр шәүлә сыман сүзсез генә йөргән Дәү Сөләйман кисәк ыргылды да беркатлы һәм хәйләсез Гамилнең аска салып яшермәкче булган бишмәте белән бер пар бияләен, тегеңә ыкы-мыкы килергә дә ирек калдырмыйча, кисәк йолкып алды.

— Болар бөтенесе дә калхуз малы хәзер. Әндри казнасы юк, безгә мишәйт итмәс.

Себергә сөреләсе Рөстәмбәкнекеләрне үләксә өстендә бөтерелгән карга көтүе сыман сырып алган Төркәй халкы арасыннан ник бер кеше, мескен Гамилне яклап-җәлләп, бер авыз сүз әйтсен?..

Арба өстенә менеп утырганда, авылдашлары каршында гафу үтенгән сыман башын ия төшеп, Рөстәмбәк нибары бер җөмлә сүз ташлады.

— Моңа кадәр мин ашаткан-туендырган идем, ә хәзер менә Әмир паегы хакына бил бөгегез инде…

Гәрдән кулак йортын тентеп чыккан чакта да, әүвәл барча гамәл тавыш-тынсыз гына үтеп киткән иде. Гәрдәннең сыер-сарыкларын колхоз фермасына илтеп бикләделәр, соңыннан ярлы-юксылларга бүленәсе чүпрәк-чапракларны, өстәл-урындыклар, мендәр-юрганнарны колхоз идарәсе булып исәпләнгән элекке Әхтәм мулла йортының бер ягына күчереп тутырдылар. Инде Гәрдән кулак белән хатыны Зәмзәмия дә, барча балалар да буш арбалар өстенә менеп тезелеште. «Лишуннар»ны Бүздәк төрмәсенә алып китәчәк олау Күчәрбай юлына төбәп чыккан иде. Шул чагында күчәрбайлылар, төркәйлеләр мәңге ишетмәгән бер хәл булып алды.

Олау олы юл буенда утырган соңгы йорт янына килеп җиткән генә иде, Гәрдән кулакның өлкән кызы Гөлсем үзе утырып барган арба үрәчәсеннән сикереп төште дә, башын иеп, сүзсез генә аларга ияреп килгән шыр ярлы Шәрифулланың муенына барып асылынды.

— Юк, мин Төркәйне ташлап китә алмыйм, йөрәккәйләремнең ярты яккайлары туган-үскән җирләремдә кала!

— Акылыңа кил, чү-чү, балакаем, — дип, әүвәл Зәмзәмия түти, сикереп төшеп, җиткән кызының кулларына килеп асылынды.

— Гөлсем апа! Алма апакаем! — дип чәр кычкырып, ярсып елый-елый, эне-сеңелләре төрле яктан килеп ябырылдылар.

Гәрдән кулак кына берни эндәшмәде, башына авыр күсәк белән орган кеше шикелле, таш сын кыяфәтен алып, тын утырды.

Бүздәк милиционерларының мондый гайре табигый хәлне беренче кат кына күрүләре түгел иде, ахры. Арадан берсе, шап-шоп сикергәләп, Гөлсем янына йөгереп килеп җитте.

— Кулак атаңнан баш тартасыңмы син, юкмы? Баш тарткан очракта гына без сине монда калдырабыз.

— Тартам, тартам! — дип кычкырды Гөлсем-Галиябану, акылы зәгыйфьләнгән кеше шикелле ачыргаланып, ярсып. — Шулай кирәк дигән шарт куясыз икән, камсамулына да керәм. Мине шушы Шәрифулла-Хәлилемнән генә аермагыз берүк...

## 3

Итче Мирсәяфне, Ибниулла картны, Хәби-Хәйберахманны авылдан сөргәннән соң ике-өч көн дә вакыт үтмәгәндер, Әхтәм мулла йортында кулаклардан тартып алынган байлык-зиннәтләрнең исемлеген барлап утырган чакта, Әмиргә беренче мәртәбә тәрәзәдән аттылар. Кара төн уртасы, Әмир белән аның янындагы ирләр унлы лампа гына яндырып утыра иде. Пуля менә шул лампаны кыеп төшерде дә, филтәдәге ялкын бер мизгел эчендә өстәлдәге постауга, идәндәге паласларга капты. Урамнан кабат ату куркынычы янавын үлчәпчамалап та тормыйча, Әмир үзе, ул исемлекләрне укыган чакта аның һәрбер сүзен җөпләп-раслап барган Дәү Сөләйман, аның Фазылбәк абыйсы, комсомол егет Идрис — барысы тиң, ялкын телләре бии башлаган чүпрәкләр өстенә ташланып, утны сүндерделәр. Ләкин шуннан соң да һичкайсысы урамга йөгереп чыгарга ашыкмады. Ике тәрәзә арасындагы бүрәнәләргә сыртын терәп утырган Дәү Сөләйман, гыжлый-гыжлый, үз гөманын әйтте.

— Бу дошманнар — авылдан чыгып качкан Хафиз белән аның улы Борһан түгелме икән? Алардан тыш Төркәйдә синнән үч алырдай кеше калмады, бөтенесен җыеп Бүздәк төрмәсенә озатып бетердек бит.

Сүз урлап җыйган икмәген Әхмәт зиратына яшереп йөргән Карак Хафиз гаиләсе турында иде. Себергә сөрәбез дип җыелып баргач, кызык булдылар шул. Комиссия тентү үткәрергә ниятләп килеп кергән чакта, хуҗалыкта сукыр тавык та калмаган, елгыр Хафиз, үзенең бөтен мал-мөлкәтен туплап, инде кара төн уртасында ук чыгып качкан иде.

— Ай-һай, моның Хафиз булуы бик икеле, — диде Әмир хәзер. — Аңа урлап киткән малын аткарырга, ә үзенә балалары, хатыны белән бергә, таракан шикелле тар тишеккә посып, тын ятарга кирәк. Карак Хафиз үзе дә, аның Борһаны да мондый чакта байлыкларын ташлап, сантыйланып йөрмәс. Башка кеше кулы бу, моңа хәтле мылтык тотып карамаган чит-ят дошман кулы. Минем кебек окопларны кичкән кеше булса, ул тидерер иде...

Кулакларны Себергә сөрү хәрәкәте купкач, байтак җир-

дәге дошманнар баш калкыткан икән. Бүздәктәге ниндидер бер Абдул, колхозныкылар моның йортын тентергә дип килгәч, үзенең ихатасына ут төрткән, ди. Аны Себер урынына Уфа төрмәсенә илтеп бикләгәннәр, алган срогы унике ел икән.

Күчәрбайдагы хәлләр дә, казанны тутырып кайнаган су шикелле, ярларыннан ургылып ташый башлагандыр инде, беркөнне, кичке яктарак, Әмир белән комсомол Идрисне дә авыл шурасына чакырттылар.

— Дошман азды,— дип башлады яңа рәис Канкай, кыска, коры гына.— Авылдан әллә ничаклы кулак Урал якларына, Донга чыгып качты. Берәүләре Магниторск дигән җирдә яңа завод төзелгәнне сәбәп итә, икенчеләре Себергә сөрелүдән шахталарда качып калмакчылар. Без беләбез, мондый качакларның бик күбесенә ат-олаулар белән карак Илмурзиннар ярдәм итеп ята. Шулар ук кулакларга әллә кайлардан, әллә нинди ялган белешмәләр дә юллап-табып бирә. Заманында сезнең Дини башлаган засадалар кору ысулына кайтмый булмас, ахры. Бүген без дә ике-өч кешелек төркемнәргә бүленеп чыгыйк та, юлларда дозор корып ята башлыйк әле...

Әмир белән Идрискә ярдәмгә Чүпрәк Нәбине бирделәр дә Аблай юлына чыгарып җибәрделәр. Күпме генә посып ятмасыннар, юлдан үтүче эт тә күренмәде. Аның каравы Әбзән юлында яткан укытучы Хөллә коммунистка бәхет дигәннәре әллә инде күктән егылып төшкән: ике айгыр җигеп каяндыр кайтып килгән Илмурзиннарның уртанчысын — Маннур атлысын — кулга эләктергән бу. Маннур каракны сәгате-ние белән, кул-аягын бәйләп, Бүздәк төрмәсенә озатып җибәрделәр. «Хөсниулла» дигән тулы исемен айга-елга бер мәртәбә генә ишетергә гадәтләнгән Хөллә исә, алтын-зөбәрҗәт каурыйлы асылкошны тоткан кеше сыман, көне буе иләсләнеп йөрде. Ләкин ашыккан шул.

Икенче төндә Әмир белән Идрисне, Аблай юлыннан алып, һаман да шул Илмурзиннар күбрәк йөри торган Әбзән очына җибәргәннәр иде.

— Син засадаларда бик күп яткан кеше, сиңа Илмурзиннарның һәр сукмагы таныш,— дип, салпы якка салам кыстырырга да онытмадылар тагын.

Хөллә коммунист кереп яшеренгән Бәдрәш буендагы таллык белән Әмирләр качкан чокыр арасы, күп булса, ук очышы кадәр генә ераклыкта иде. Кайчакларда хәтта Хөллә төчкергән яки сүгенгән авазлар да аермачык булып ишетелгәләп торды.

Берникадәр вакыттан соң Хөлләнең тавышы тынган сыман булды, мәгәр берзаманны, инде таң атканда, өстенә аю баскан бичара шикелле, гыр-гыр итеп кычкыра башлады бу.

— Әм-мир, Әм-мир!.. Җибәр, дим, муеннан, анаңны ек-кыры, Мәхем-м-м... Әм-мир, Әм-мир-р-р!..

Әбзән ягында шарт-шорт килеп агач ботаклары сынды, әллә кемнәр ох-ух итеп яман ухылдады. Әмир белән Идрис йөгерешеп барып җиткән чакта, таза гәүдәле ниндидер ир Хөллә коммунистның күкрәгенә атланып утырган да, сыңар кулы белән дөп тә дөп китереп, теге бичараның яңагын төя иде. Хөлләнең бөтен муен, колак тирәләре кискәләнеп, канга батып беткән, ә үзе, мескен, һаман бирешергә исәпләми, ияген күкрәгенә китереп кыскан көенчә елан шикелле боргаланып, бөтерелеп ята. Моның өстенә менеп атланган ир, Хөллә бөте-релгән саен, икенче кулындагы озын пычак белән бичараның муенына йә булмаса яңагына чәнчеп-чәнчеп ала.

Әмир гыжлый-гыжлый йөгереп килешкә үк кулындагы мылтык түтәсе белән өстә утырган ирнең муенына орды. Кар өстенә әйләнеп төшкән бу дошманның чыраена бакса — Ил-мурзиннарның милициягә мәңге тоттырмый торган хәйләкә-ре Мәхмүт.

— Алланың рәхмәте... Әле ярый... килеп җиттең... Әмир, — дип, көч-хәл белән генә сулыш ала-ала, ниһаять, Хөллә коммунист та урыныннан купты. — Суеп үтерәдерие бит бу мине... Ярый килеп җиттең... Валлаһи, дип әйтәм, суя иде мине... Иякне бирмәдем, шуңа гына бугаздан суялмады...

Хөлләнең килеш-кыяфәте котчыкмалы, бөтен яңаклары, колак тирәләре буй-буй телгәләнгән иде. Күчәрбай ягыннан беренче ат килеп җитүгә үк, Хөлләне, муенын-яңакларын ан-нан-моннан ертып алынган күлмәк кисәкләренә төреп, Аб-лайдагы имче карчык янына салып җибәрделәр. Явыз Мәх-мүт тә Ишмай Харисының келәтенә чаклы, Алланың кашка тәкәсе шикелле, салам түшәлгән киң чана түрендә аунап кайт-ты. Билгеле, аның кул-аяклары инде күптән сүс арканнар белән богауланган иде. Ләкин авыл уртасына җитәрәк уш-ка килгәч, яннан атлаган Әмирнең йөзенә туры карап дәште.

— Тәк, бу юлы ләчәнникләргә ярадым, мине тоттым, ди-сең инде син, Әмир абзый. Мәгәр чебешләрне көз көне генә саный торганнар иде бит ул, ярар, ярар...

Ишмай Харисының таш келәте янына килеп җиткәч, Әмир бөтен кешегә дә ишетелерлек итеп, аермачык тавыш белән ярып салды.

— Бу кабахәтнең теләсә нинди тау-ерымнан аска таба тәгәрмәч шикелле тәгәрәп төшә торган гадәте бар. Бүздәк яки Бәләбәй төрмәсенә бу көенчә генә алып китсәң, тагын кача Мәхмүт.

— Качмас, качмас, — дип бүлдерде аны яңа рәис Канкай шул чагында. — Әллә нинди шома эчәкләргә дә бөке булып утыра торган ризык табыла ул. Моның ише дошманнар

кулак җырын җырламасын өчен без менә болай иттерәбез аны.

Канкай шул мизгелдә үк Мәхмүтнең итекләрен йолкып салдырды да, тегенең аяк табаннарын, үкчәләрен наган сырты белән котырынып ярсый-ярсый төя башлады. Яңа рәискә мондый ысул инде күптән таныш булган, ахры. Бер-ике минуттан соң ук Мәхмүт бугазыннан әллә нинди кыргый җанвар авазлары сытылып чыкты.

— А-а, у-ух, хай-ван! Булды, сукма, үл-ләм!

Ә инде таш келәт эченә аякларыннан сөйрәп кертә башлагач, Мәхмүт Әмирнең күзләренә төбәлеп соңгы сүзен әйтте.

— Дөнья — куласа, бер әйләнә, бер баса. Безнең сукмаклар да кисешәчәк әле. Бүгенге хатаны бүтән кабатламыйм. Сине суячакмын. Бүгеннән үк колагыңа киртлә. Валлаһи, дип әйтәм, барыбер суячакмын...

Шул көнне үк Бүздәк бүлегеннән килеп җиткән өч-дүрт милиционер Әмиргә ике көпшәле ау мылтыгы, кемнәндер талап алынган өр-яңа велосипед, шуларга кушып тагын Пальма кушаматлы ау этен дә биреп җибәрделәр.

— Үзеңне Төркәй хуҗасы итеп тоя башларга вакыт,— диде аңа Канкай, аерылган чакта.— Гаиләң-нисң белән күчену өчен авылыгыздагы берәр кулак йортын чамалый, сайлый башла.

## 4

«Прасинт давай, прасинт» дип өстән бертуктаусыз йолыккалап-чукып торсалар да, Төркәйдә гаризасын язып, малларын күмәк абзарларга китереп биргән яңа колхозчылар саны елның соңгы көннәренә чаклы унбиш-егермедән артып китә алмады. Утызынчы елга аяк баскач, рәис Әмирне дә, Упалнамуч Чапай Сабитын да шура утырышларына чакырып кыздыра башладылар. Гыйбрәт рәвешендә генә әйтелгән яңалыклар да әллә нишләп кинаяле, кадау, төртмә иде.

— Күзәй авылындагы рәис Тимергали, урта хәлле крәстияннар калхузга керүгә аяк терәп каршы торуны күргәч, авылдагы берденбер чишмә янына мылтыклы каравылчыларны сакка бастырып куйган. Таләбе бик гади: кем колхозга керми, шул су алмый. Бер атна чамасы интеккәчтен, авыл халкы тулысы белән моңа гариза язып биргән.

— Ә Ижау ягындагы Юскә белән Лүҗә дигән авыллардагы арлар әнә нишләгәннәр. Алар, «җыен карары шундый» дигән сылтау тапкан булып, колхозга керми калган ярлы-ябагайны авыл мәйданына сөйрәп китергәннәр дә, ыштаннарын салдырып, ирләрен-хатыннарын бөтен халык ал-

дында тал чыбыгы белән өшкергәннәр. Шуннан соң, хак булса, ике авылдагы алтмыш крәстиян гаризалар язып биргән, диләр...

Упалнамуч Чапай ушсыз-хәйләсез кеше түгел икән, ишеткән киналәреннән бик тиз сабак алды. Бер иртәдә Әмир Әхтәм мулла йортына килеп утырган гына иде, аның үкчәсенә бастырып дигәндәй, ат сыман пошкыра-пошкыра, Сабит килеп керде.

— Кулаклардан калган бодай-арыш уйма. Шуны калхузга керми йөргән җыен ярлы-ябагайга үтечкә өләшәбез.

— Ә-ә? — дип, Әмирнең шайтан күргән сыман каш астыннан акаюын күргәч, бөтенләй исе китмәгән кыяфәттә теге янә тезде.

— Башта өләшәбез, берәр атна үтсен, ул арада бөтен кеше аны йә Рөстәмбәк, йә Яшке тегермәненә барып тарттырып бетерәчәк. Ә ун-унбиш көн вакыт үтеп киткәч, шалт без яңа таләп. Йә үтечкә алган бодай белән арышыгызны икеләтә итеп кире кайтарасыз, йә калхузга давай.

— Кит инде, авыл кешеләрен колхозга алдап-йолдап, мәҗбүриләп куып кертү бит бу. Аннан-моннан суккалап кына өелгән чүмәлә дә озак чыдый алмый, катырак җил истеме, маминт ишелә ул, — дип, Әмир әүвәл җаны-тәне белән каршы төшеп карамакчы булды.

— Чүмәлә кую буенча бик маһир бәндә икәнсең, бар, син чүмәлә яса. Ә минем, Дини артыннан китеп, Бәләбәй төрмәләрендә бик черисем килми. Тегеннән... — Сабит югарыга бармак төртеп алды. — ...Мәскәүнең үзеннән төшерелгән фәрман — ул бит тауның иң биек очыннан тәгәрәтеп җибәрелгән олы бер таш кебек. Юлындагы бөтен вак-төякне сытып бетерәчәк, үз артыннан әллә ничаклы яңа ташларны ияртеп алып китәчәк. «Авылларда тоташ коллективлаштыру үткәрергә» дигән күрсәтмә дә шундый. Мәскәү түзеп тормый, иртәме-соңмы, ул барыбер крәстияннарның һәркайсысын калхузларга кертеп бетерәчәк.

Упалнамуч Чапай бу чаклы ук нәсыйхәтләр тезгәч, Әмир инде каршы тора алмады. «Үтечкә икмәк өләшенә» дигән хәбәрне ишетүгә, колхоз абзарлары янына әүвәл ярлы төркәйлеләр генә җыелып килгән иде, тора-бара урта хәлләләр дә тезелешеп басты.

— Һи-и, Әмиргә бушка гына килгән байлык ла бу. Рөстәмбәктән, Гәрдәннәрдән калган. «Атай малы катай», аңа соң җәлмени? Шуңа өләшә ул. Аннары, чынлап баксаң, калхузы да таралдыр әле, — дип, берсен-берсе котыртып сөйләнделәр.

Ун көннән соң Әмир белән Сабит һәркайсын Әхтәм мулла йортына аерым чакыртып, «үтечкә алынган» һәр пот ик-

мәк урынына биш пот таләп иткәч, бер көн эчендә уннан артык ярлы-ялгызак колхозга керергә гариза язып бирде. Икенче иртәдә урта хәллеләр колхоздан алып киткән барча капчыкларын баулары да чишелмәгән көенчә кабат китерә башлаганнар иде, Чапайның усал тавышы һәммәсен төп башына утырткандай итте.

— Яңа ел башланды, салым түләр вакыт. Бүген кич җиткәнче һәркайсыгыз бер пот урынына ун пот китерәсез. Соңгы кеше кичке биш тулганчы китереп бирми икән, иртәгә үк һәрберегезгә янә шул ук салым…

Күп булса унлап ялгызак үзеннән таләп ителгән капчык-капчык ашлыкларны җыеп тапшыргандыр. Ә егермеләбе, бер-берсеннән качып-посып кына, көндез — Әхтәм мулла, кичен Әмир йортына гаризаларын язып китерделәр…

Әмир белән Сабитның ысулын ошаттылар, ахры, Бүздәкнең үзендә уздырылган волость коммунистларының гомуми җыелышында икесен тиң Уфада узачак ниндидер тантанага делегатлар итеп сайладылар. Тантана дигәннәре — партконференция, анда Татарстан белән Башкортстан арасындагы ярышка йомгак сыман әйбер ясалачак икән. Әмир өстендәге киемнәрнең тегелгән-ямалган булуын күргәннәрдер инде, Бүздәктә үк аңа өр-яңа күн итекләр белән беркадәр киелгән булса да фасонын-төсен бөтенләй югалтмаган күлмәкчалбар биреп җибәрделәр.

Конференция турында кабат февраль уртасында гына искә төшерделәр. Кып-кызыл төстәге папкаларга әллә ничә төрле рапорт тутырып килгән волость вәкилләрен «Коминтерн» дигән ниндидер йорт залына тезеп утырттылар. Инде армиядән кайтып кергәннән бирле Әмирнең бу чаклы күп халыкны күргәне юк иде. Авызын ачты да, башын төрле якка боргалый-боргалый, гел күзәтеп утырды. Яртысыннан артыгы гимнастерка кигән, култык асларына калын-калын папкалар кыстырган бик җитди кыяфәттәге ирләр. Күзлекләрен борын очына элгән берничә яшь егет. Мул күкрәкле шәһәр хатыннары. Алдагы бер чокырда җиз торбаларын күз явын алырдай итеп ялтыраткан карт-карт музыкантлар. Һәм, ни гаҗәп, залга кергән кешеләрнең яртысы диярлек үзенә билгеләнгән урынга утырып торуны белми, әллә нинди йомышлар тапкан булып, әрле-бирле йөренәләр.

Ниһаять, берзаманны тантана башланыр вакыт җитте бугай, залда гөр-гөр килеп сөйләнүләр, йөгереп йөрүләр бетте. Залның алгы ягына асылган бәрхет пәрдәне ике якка тартып җыйнадылар. Сәхнәдә галәмәт озын өстәл ачылды. Түрдә Ленин белән Сталин рәсемнәре. Зал тын калды. Сәхнәгә, каз көтүе сыман тезелеп, зур корсаклы, калын иякле ирләр чыгып утыра башлады. Әмир боларның берсен-бер белми

иде, иң ахырда пәйда булган Шаһи-Моратны күреп алгач кына, йөзенә елмаю чаткылары бәреп чыкты.

— Шаһи-Морат бу, минем комиссар,— дип, тизрәк үзенең шатлыгын Чапай Сабиты белән бүлешмәкче иде, тегесе үзе танып белгән түрәләрнең исемен саный башлады.

— Әнә тегесе, иң уртага чыгып утырганы — беренче секретарь Быкин. Аның сул ягында икенче секретарь Исәнчурин бугай. Аннан бер кеше аша кәгазьләргә төртелеп утырганы Афзал Таһиров булыр. Үзе язучы, үзе тарихчы ул. Соңгы елларда бик тиз күтәрелә башлады, аны тучны беләм. Ә калганнарын танып бетермим әле. Танысам, аңлатырмын...

Тәүге сүзне, әлбәттә инде, Быкин үзе алды. «Хәзерге революцион момент, илдәге сыйнфый көрәш, культура революциясе, индустрияләштерү, тоташ коллективлаштыру» дигән сүзләрне еш кулланып, таза муенын, белендәй яңакларын кульъяулыгы белән сөртә-сөртә, сәгать ярым буе нотык тотты. Ахырда ул ике республика арасында барган ярыш күрсәткечләре турында сүз кузгатты. Һәр иҗекне йотардай булып тыңлап утырган Әмир ике генә санны ятлап калды. Татарстанныкылар бер ел эчендә өч мең дүрт йөз күмәк хуҗалык төзеп өлгергәннәр, Башкортстандагы колхозлар саны аларныкыннан йөзгә артык, мәгәр үзара ярыш әле төгәлләнмәгән, ул тагын бер елга озайтылган икән.

— Без өлкә конференциясе исеменнән ВыКыПыбының Үзәк Комитетына рапорт юлларга тиешбез,— диде берчак Быкин. Аннары өстәл читендә яткан яңа бер папканы мөнбәр өстенә суырып алды да, гәүдәсен тактага кадаклап куйган шикелле кырт төзәйтеп, тамакларын кат-кат кыра-кыра, күтәренке тавыш белән укып китте.

— Тоташ коллективлаштыруга йөз тоткан хәлдә без республикадагы унөч мең җиде йөз кулак хуҗалыгын пыранзаран китердек, кырык меңнән артык кулак Себергә озатылды. Кулаклардан алты мең ат, биш мең сыер, болардан тыш тагын тугыз миллион сумлык байлык тартып алынды һәм барысы да колхозларга бүлеп бирелде... Башкортстан өлкә комитеты, республикадагы барча коммунистлар сездән яңа күрсәтмәләр көтә...

Бөтен зал, аягүрә басып, тәрәзә пыялаларын зеңләтерлек итеп, әллә ничә минут буена доклад ясаучыны алкышлады. Әмирнең зиһене һич эшләми, ул рапортта телгә алынган саннарны күзалларлык, колачларлык хәлдә түгел иде. «Тәк, нәселле сыерның иң кыйбат дигәне дә йөз утыз тирәсе, иң шәп юртак ике йөз сум тора. Тугыз миллионны йөз утызга бүлсәң, ...йөз утызга бүлсәң... тәк, ул, ничә баш сыер чыга да, бу ниндирәк көтү була икән?» — дип, күңеленнән генә хи-

сап итмәкче булып карады, ләкин аның бу чаклы саннарны ерып чыга алырдай белеме юк иде.

Җыелыш ахырында, Шаһи-Морат белән сөйләшмәкче булып, ул сәхнә артындагы бүлмәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә барып төртелде. Күрүче-белүче кеше табылмады, кочак-кочак кәгазьләр күтәреп йөргән бер марҗа хатыны гына серне ачып салды.

— Шаһиморатовмы? Ул банкетта. Хәзер шундый тәртип.

«Банкет» дигәннәре нинди галәмәт тә анда ни эшлиләр? — Әмир боларның берсен-бер белми иде. Башын түбән иеп кенә, Уфа буйлап, ул Гөлтуташның абыйсы Бикми-Бикмөхәммәтнең йортын эзләп китте.

## 5

Бикми тимер юл вокзалына якын гына бистәдә бер агач йортта яши булып чыкты. Йорты әле хәтәр яңа күренә, бәләкәй ишегалдының түрендә сарае, мунчасы бар, янда кечерәк кенә бакча, тирән кар базы булган уртача таш келәт — хуҗалыкка һич тә тел-теш тидерерлек түгел иде.

Бикми үзе дә, Елизавета җиңги дә кунакны колачларын җәеп, җылы каршылады. Хәзинәдә ни бар — тозлы кәбестә, гөмбә, ат казылыгы, каклаган каз, кырылган кишер тутырып пешергән вак-вак кабартмалар, эремчек, дуңгыз мае — бөтенесен өстәл өстенә тезеп утырттылар. Әлбәттә инде, сый-нигъмәт янына өстәлеп, шайтан суы — көмешкә дә чыкты. «Кайнарланып» алгач, Бикми әүвәл мактануга, шапырынуга күчте. Ул агач эшкәртү комбинатында эшли башлаган, яшелчә, балык тозлау өчен зур мичкәләр ясый, эш урыны кул сузымында гына икән. Аннары, ни хикмәт, Бикми гел авылдагы хәлләр, колхоз төзү, ялгыз крестьяннар турында төпченүгә күчте.

— Кулаклар, байлыкларын талап, гаиләләрен Себергә сөргән чакта каршы тордылармы?.. Үзенең хуҗалыгына ут төртүче яки мылтык-сәнәк күтәреп каршы килүче кулак күп булдымы?.. Төркәйдә юк икән, кайсы якын-тирә авылда колхоз йә булмаса шура рәисләрен атып үтерделәр?.. Авылда ничаклы мал суелган, базарларга сыер-сарык ите, елга сыман агылып, каян килә?..

Тоташ рәвештә гел менә шушындыйрак сорауларны тезгән Бикминең кайсы якка таба боргалавын-салулавын Әмир әле байтак вакыт буе аңлый алмый утырды. Бикми колхозлар төзүне кабул итмәде, авылны ташлап китте, ә хәзер аңа Төркәйдәге, Аблайдагы хәлләр турында төпчену нигә кирәк инде?

Тәмәке тартасы килүдән бигрәк, икәүдән-икәү генә калып сөйләшүне кулай күрде бугай, берзаманны Бикми аны йортка терәп салынган тар бүлмәгә дәште. Аңа ян стенадагы имән ишек аша гына керәсе, бүлмә эчендә тозлы кыяр-кәбестәләр тутырылган эреле-ваклы агач мичкәләр тезелеп киткән, чөй һәм кадакларда камыт, ыңгырчак, пычкы, ләгән эленеп тора, хак-турысын әйтсәң, бу, күбесенчә, зур келәтне хәтерләтә икән. Бикми Әмиргә әллә каян табып җыйнак кына бүкән китереп бирде, үзе агач мичкә өстенә утырды. Байтак вакыт буе сүзсез утырдылар. Көтмәгәндә, Бикми кабынып китте.

— Мин, кайтып төшкәннән бирле, бу татарны күздән кичерәм дә торган саен шакката гына барам, Әмир. Татарның соң горурлык, мин-минлек умырткасы, сүле-җаны гел калмаганмыни? Тегеләр дүрт йөз ел буе изү дәвамында нүжәли татар инде шушы чаклы колга әверелгән? Аның үзенә көчләп тагылган богауларга, мәҗбүриләп кидергән агач камытларга, чыбыркы белән кыйнап керткән тәртә-кысаларга каршы килә торган табигый гыйсъянлыгы, горурлыгы, затлы каны-җаны кая киткән? Бабайлардан күчеп калган булырга тиешле ирек сөю, дошман алдында тез чүкмәү, газиз малыңны яклап утка-суга керү, ахыр чиктә инде үч алу кебек сыйфатлар кайда бу татарда?..

Әмир әле һаман Бикминең нинди кыйблага таба йөз тотуын аңлый алмый иде, күзен шакмакландырып хуҗага төбәде дә агач сын шикелле тын утырды. Бикми үзе дә моны тойды бугай, җентекләбрәк аңлатуга күчте.

— Менә фәлән телдә, фәлән төрле гәзит чыга хәзер. Укыпчагыштырып карарга мөмкинлек күп. Укыйм да шаккатам. Донбасста әнә нindидер инженерлар, җыелып, шахта шартлатканнар. Дондагы казаклар, кабат йөзлекләргә, эскадроннарга берләшеп, колхоз идарәләрен, авыл советларын гына түгел, волость комитетларына хәтле җимереп ташлаганнар, коммунистларын, рәисләрен кырып бетергәннәр. Себердәге крестьяннар, колхозларга кермәс өчен, авылы-авылы белән кубып, тайгаларга качкан. Урта Азиядәге диһканнар, Памир, Тянь-Шань тауларына китеп, яңадан-яңа басмачылар отряды туплап йөри. Һәм инде мин үзем дә Владивосток белән Артем тирәсендәге күпме фетнәләргә шаһит булып кайттым. Шахталарны юри су белән бастыру, күмәк әртилгә керергә маташкан балыкчыларның кораб-катерларын яндыру, крестьяннардан байлык-җир таларга килгән кызыл отрядларны тоташ суеп чыгу — берсе-бер калмады бит. Әйе, әйе, дүрт йөз кешелек бер отрядны төнлә тоташы белән суеп чыктылар да Кытай җиренә качтылар. Ул отряд яшәгән баракларны җирле халык хәзер «Кызыл казармалар» дип йөртә.

Менә шулай, Әмир, Советлар Союзы дигән илнең әллә никадәрле почмагында урысы, казахы, хохолы, хәтта әле шул ташташ надан булып исәпләнгән таҗигы, үзбәге дә үзен талауга, колхозларга куып кертүгә, совет тәртипләренә каршы баш күтәрә. Ә татарың…

Кинәт кенә Бикми тынып калды. Дер-дер килеп куллары калтырый иде, сүнгән тәмәкесен озак вакыт буе кабыза алмый торды. Тәмәкесен суыра башлагач та, әллә никадәрле төкеренде.

— Менә мин синнән, бәйнә-бәйнә итеп, ут төртүләр, берберләрен яклау, күмәкләшеп каршы торулар турында сораштырдым,— дип дәвам итте ул, тартмый-сузмый гына.— Әлбәттә, мин башка волость, башка кантон кешеләреннән дә белешеп торам инде. Уфада агач мичкәләр ясаучы бүтән әртилләр юк, безгә Башкортстанның һәрбер почмагыннан килеп торалар бит. Ну, шуннан, син безнең татар ничек итеп холык күрсәтә дәниләр кыра, дип уйлыйсың инде? Эшерә генә, ура безнең татар.

Бүздәк авылында әнә Абдул дигән берәү ихатасын, йортын яндырган. Зилаердамы, Бөрҗәндәме шунда, бер «авыл карриспандинты» дигән әләкчене балта белән бәреп үтергәннәр. Тегендәге, мондагы ике-өч крестьян, колхоз талап алып киткәнче дип, сыер-сарыкларын суеп бетергән. Ә аннары инде шул: фәлән волостьта кулаклар авыл советы рәисен юлда сагалап торганнар, үтермәкче булганнар. Фәлән авылда колхоз рәисен үтерергә җыенганнар. Аңлыйсыңмы, «җыенганнар, булганнар», җыен имеш-мимеш. Ә конкрет алсаң, төптән чокып карасаң, бер фетнә юк. Берәр волостьта берәр авыл советын ут төртеп яндырганнары турында ишеткәнең бармы? Кайсы якта да булса татар крестьяннарының, атларына атланып, сәнәк-чалгы тотып, отряд туплап, берәр волость комитетын туздырып, коммунистларны йә милицияне суеп чыккан берәр болганышы-фәлән булдымы? Яки алар, үзләренең авылларындагы берәр урта хәлле, гөнаһсыз крестьянны Себергә алып киткән чакта, аны якалашып-даулап аралап калдылармы? Юкмы, Әмир? Менә шулай, юк шул. Ачуың килмәсен, мин барыбер әйтәм. Коллык баскан, битарафлык баскан безнең татарларны. Бөтен горурлыгы, кешелеге иттәге сүл урынына агып чыгып беткән. Шуңа да ул, абзар аранына ашыккан сыер-сарык сыман, артыннан куганны да көтмичә, колхозына-ниенә барып керә. Чыбыркы очы күрсәтәләр икән, анда рәхәт дип котырталар икән, ул әле, аңгыра бозау сыман, ярдан баштүбән дә, сазлык эченә дә сүзсез сикерәчәк. И-и, томана, и-и, умырткасын җуйган, күндәм безнең халык!..

Бугазына кылчык килеп кадалган кеше шикелле Бикми

кисәк кенә сүзеннән туктады да, башын аска иеп, күзләрен Әмирдән яшереп тын утырды. Ә үзе һаман авыр төйнәлгән йодрыклары белән әле уң яктагы, әле сул яктагы тез башларын төйде.

— Миңа күптән түгел мылтыктан аттылар бит,— дип телгә килде Әмир, акланган, юаткан кеше кыяфәте белән.

Бикми бөтенләй дә исе китмәгәндәй җавап бирде.

— Ишеттем, Әмир, мин ишеттем аны.

Бераз вакыт сулыш алгандай итте дә, Бикми янә кабынды.

— Юк, мин кемнәрнеңдер сине үтерүләрен дә, татарның тоташ кубып кан коюын да һич теләмим, Әмир. Мине дөрес аңла. Ләкин татарның шушы кадәр юаш, күндәм булганына минем эчем сыза. Теге чакта ломовой булып йөргәннәрне искә төшерәм. Югыйсә безнең кулда кеше малы, чит-ят байлык иде. Күпме юлбасар, нихәтле полицай бездән ул малларны тартып алырга, өлеш чыгартырга тырышып карадылар. Ә без бирмәдек бит. Чит-ят малы иде, ә барыбер бирмәдек, ничәмә-ничә мәртәбәләр канга бата-бата каршы тордык, һәммәсе исеңдәдер. Ә хәзер соң, кара, ничәмә-ничә мең кулакны бер кат ыштаннан гына калдырып Себергә озаттылар. Ничәмә-ничә мең татар, власть «айт» дидеме, «тайт» итә дә колхоз камытына әүвәл башын, ә аннары малын илтеп тыга. Мин чамалыйм инде, дөрес, татар кулында туп-мазар да, мылтык-кылыч та юк. Әле ничәмә-ничә гасыр элек патшалар ук татар кулындагы коралны тартып алган, татарга тимерчелек белән шөгыльләнүне гүпчем тыйган. Әйе, буш кул белән әллә ни майтарып булмый, бу теге фәлән йөз энәле керпене шәрә артны куеп куркыткандай була. Тик шулай да... нигә бу кадәрле куркак, җебегән, таркау безнең халык?..

Бикми Әмирнең йөзенә күтәрелеп карамады. Караса да файдасыз, Әмир бу чаклы сорауларга җавапны барыбер белми иде.

## 6

Авылга кайтып төшүгә үк, Әмир утлы күмер түшәлгән җир өстенә яланаяк баскан кебек булды.

— Халык ярты малын суеп бетерде. Ниндидер дошманнар «колхоз бөтен малны җыеп күмәк абзарларга ябачак» дигән гайбәт тараткан да бөтен кеше, шуңа ышанып, ике сыерының берсен, өч сарыгының икесен тоташ суеп чыккан,— дип каршылады аны Упалнамуч Чапай. Ызгыша-ызгыша, үгетли-үгетли әллә ничә йортны әйләнгәндер инде, тавышы хырлап кына чыга, утырып беткән иде.

Сәгате-минуты белән бар халыкны мәчет мәйданына җый-

надылар. Әүвәл Әмир, аннан Сабит яртышар сәгать буе сөйләгән-аңлаткан булды, ә халык мәрткә киткән шикелле гел тын торды. Буаларны җимереп аткан язгы ташу сыман, яман хәвеф инде үтеп киткән, чалып ташланган сыер-сарыкларны беркем дә кабат аякка бастырырлык, җан өрерлек хәлдә түгел иде. Аптырагач, икенче көнне Әмир инде икмәк өчен дә, май өчен дә итләтә салым җыеп озатырга мәҗбүр булды.

Бәла-каза ялгыз гына йөрми диюләре хак шул. Март аена кергәннәр генә иде, барча коммунистларны, комсомоллар, «алласызлар», тагын әллә нинди активистларны Күчәрбайга җыеп телсез калдырдылар. «Правда»да Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе чыккан, илдәге бик күп колхозларны ашыгып төзегәннәр, кулак исемлегенә теркәп Себергә озатылган кешеләр арасында гөнаһсыз урта хәлләләр дә байтак булган икән.

Шура йортына шыгрым тулган халык әүвәл тын утырды, ә аннары идән уртасында утлы ядрә шартлагандай булды.

— Әх, инәгезнең кабер такталарын! «Прасинт давай, прасинт» дип, чыбыркылый-чыбыркылый, үзегез кудыгыз бит.

— Безгә барып җитте. Ул «тоташ коллективлаштыру» дигән күрсәтмәне сез үзегез уйлап чыгаргансыз. Әнә Сталин да, Мәскәү баярлары да сезгә андый фәрман төшермәгән. Сез Уфадагы, Бәләбәй, Бүздәктәге ләчәнникләргә ярарга тырышып кына әллә нинди ялган күрсәтмәләр биреп яткансыз икән. Үзегезнең кәнәфиләрегезне саклап калыр өчен шулай кыланганмсыз...

Җыелган халыкның эресе-вагы шулай пырдымсыз ат шикелле арткы аякларына күтәрелеп дулагандай итте, умарта оясы сыман туктаусыз гөж килде. Ә Әмир өстәл артына тезелешкән кешеләргә текәлде дә башына күсәк белән китереп бәргән шикелле тын утырды. Каһәр генә суксын, анда ике-өч ай элек кенә «прасинт давай, кулакларны сана» дип камчылап утырган Бәләбәй түрәләре Яковлев белән «Гарип» та, Янгуразов та, хәтта аның милиционерларыннан булса да бер кеше юк. Хәтта «дөнҗада мирауай эрвәлүтсә шулай таләп итә» дип дулаган Дини дә юк. Ә моннан өч-дүрт ай элек кенә килеп төшкән Канкай белән Упалнамуч Чапайга, «арканчы» Сәлимовка, «хәреф хатасы санап торган» Мирсәяповка каршы өрүдән ни файда? Боларга өрдең ни дә, урамга чыгып күк йөзендәге айга уладың ни. Болар да, шулар белән бергә Әмир үзе дә өстәгеләр кушканны «тагын ни боерасыз?» дип карышусыз-нисез үтәп торучы гади солдатлар гына бит. Ә көн торышын көйләп ятучы, Әмир сыман солдатларны биетүче-йөгертүче тузлар-генераллар өстә утыра шул. Алар әнә биек кәнәфиләрен, йомшак мендәр-ястыкларын саклап ята, алар күләгәдә, гади крестьянга килеп кү-

ренмиләр. Ә Әмир иртәгә бөтен Төркәй халкы алдына япаялгыз чыгып тезләнергә мәҗбүр...

Халык надан түгел, яңа гәзитләрне авыл саен әллә ничәшәр кеше алып тора. Билгеле, Сталин мәкаләсен дә укыганнар инде. Ике-өч көн вакыт үтте микән, болар чылбыр сыман тезелеп Әмир янына килә башладылар.

— Син Җантурин да, Рөстәмбәк тә түгел. Синең эшләр хәл юк. Сиңа китереп биргән ат белән косаркамны кире кайтар да, мин калхуздан чыгам.

— Мин калхузга син әллә ничәшәр салым белән кысканга гына кердем. Яңасы белән янадың, мәҗбүр иттең мине. Син чаманы белми кыйлангансың, артың юеш икән, Ысталин дөрес әйткән. Калхузыңда арканлап тотарга бер тин хокукың юк. Атларымны, сабан-тырмаларны кире кайтарып бир...

Барлыгы кырыкка якын кеше колхоздан чыгарга гариза күтәреп килде. Бөтенесендә бер җыр: «Малларымны кире кайтарып бир!» Әмир баштарак юхалап карамакчы булды, төрле хәйлә тапты.

— Мин сезнең атларыгызга да, арбаларыгызга да ябышып ятмыйм. Мәгәр тегеннән, югарыдан, «чыгарга теләгәннәргә тарат» дигән бертөрле күрсәтмә дә юк бит.

Ләкин кайбер кайнарбашлар инде:

— Әй, төкерәм мин синең күрсәтмәңә! Ысталин хаклымы, син Саламторханмы? Ферма тулы безнең маллар ла ул. Барам да үземнекен алып кайтып китәм,— дип, күмәк абзарларны тирәләп йөри башлагач, Әмир тавышына да корыч чыңы өстәлгәндәй булды.

— Колхоз фонды мәңгелек, ул бүленми. Атларыгыз, симәнәгез, арба-чана — барысы да монда кала. Талап алырга ниятлисез икән, миндә — мылтык, Сабитта наган әзер. Башыгыз ике булса, колхоз малын өр-яңадан бүлешәсез инде...

Юк, Төркәйдә ике башлы кешеләр табылмады. Ә март ахырларына таба авылларга инде «директива» дигән яңа төрле фәрман килеп җитте.

— Колхоздан чыгучыларга һичбер байлыкны да кайтарып бирмәскә! Партиянең курсы элеккечә: крестьяннарны йөз процент рәвештә колхозларга тарту! Кем колхозга керми, аннан салымнарны ун мәртәбә арттырып түләтергә!..

Халык шомга төште. Хәллерәкләр ерак авыллардан атлар, «Торгсин» кибетләреннән орлык, сабан сатып алып кайтты. Рәте югы, яңа салымнардан курыкканы, күмәк абзарларны тирәләп, балтасын суга төшереп югалткан бичарадай йөрде-йөрде дә, язгы чәчү бугазыннан алгач, колхозга кабат кабул итүләрен сорап, яңа гаризасын китереп бирде. Тормыш янә, язгы ташулардан котылган елга сыман, иске ярларына кайтып төшкәндәй булды.

«Директива» дигәннәре өстәгерәкләрнең дә астына су кертте, ахрысы. Бер атнада унлап арба тезеп китерделәр дә, Рөстәмбәк йортының әүвәл өске, аннан аскы катын сүтеп, Бүздәкнең үзенә үк алып киттеләр.

— Республикаларны районнарга бүлү бара бит хәзер,— дип аңлатты Канкай, хәрби сер чишкәндәй читкә дәшеп кенә.— Кантун, вулыс дигән бүленешләр бетә. Яңа нәчәлникләргә яңа кабинетлар, яңа йортлар кирәк. Шуңа тырышабыз.

Ә аннары инде, шәхси ихатасындагы артык малын бүлгән хуҗа сыман, «юмартлык» күрсәтеп алырга да онытмады.

— Син, давай, ул Әхтәм мулла йортындагы мәктәпне Йосыфныкынамы, Хафизныкынамы күчер. Мулла йорты тулысы белән калхуз идарәсе булып калсын... Тә-әк, тә-әк... Аннары мин сиңа элек тә үзең өчен берәр йортны чамалый тор, дип әйткән идем инде. Менә карап чыктым. Гәрдән байның йорты да, хуҗалыгы да иркен, таза. Давай, шунда күчен, тартма, сузма... Тә-әк, тә-әк... Ә Хафиз, Хәби, Йбни йортларын — барысын да әмерикәнски торг ясап сатып җибәрәбез. Кем акчаны күбрәк, мулрак бирә — йортлар шуңа булыр. Уфаныкылар алып китәме аларны, Чишмәләрме — бер эшем юк. Акчасына калхуз өчен малатилка, лабагрейкалар алырсың, ичмасам...

Ни әкәмәт, икенче көнне үк Күчәрбайдан өч-дүрт кешелек әртил килеп төште дә Хәби йортын сүтә башладылар. Аңа инде яңа хуҗа табылган, акчасын «Кызыл байрак»ка Канкай үзе китереп тапшырачак, ә бура-келәтләрне Дүртөйлегә алып китәчәкләр икән.

Әмирнең эченә корт төшкәндәй булды. «Канкай Күчәрбайда Сәгыйт байның йортын сайлап алган, аны гына азсынгач, Габидулла хәзрәт ихатасындагы мунча-келәтләрне дә үзенә күчереп куйган, диделәр. Моның нәфесе аждаһа корсагы шикелле, туя белми бугай. Болай кылануын дәвам итсә, Төркәйдәге йортларны да сатып бетерә бит бу, вәт, зараза!»

Әмир Афоньканы куалый-куалый кайтып керде дә, әле арбасыннан сикереп төшкәнче үк Гөлтуташка, күлнең төбен күккә аскан сыман, җикеренеп дәште.

— Бирнә итеп алып килгән бөтен әйбереңне җыйна! Бәби юрганнарын, ястык-мендәрләрне — барысын җый! Гәрдән кулак өенә күченәбез. Бер әйберне калдырасы булма!

Гөлтуташ мокыт түгел, ул берничә секунд кына авызын ачып торды. Ә аннары артына без кадаган шикелле сикереп кузгалды да дүрт-биш баскычны ике генә атлап өйгә томырылды...

Гәрдән кулак йортында никах яңартып йокыдан торуга ук, иң беренче эше итеп, Әмир ике-өч ихата аша гына яшәп

яткан Шәйсолтаннар йортына барып керде. Боларның әтисе авырып дөнья куйган, әниләре ярым сукыр, өстәвенә аксак, ә җиргә яртылаш сеңгән өй эчендә уналты яшьлек Шәйсолтанның үзеннән кала тагын берсеннән-берсе кечерәк дүрт ятим бала гомер асраган булып азаплана иде. Өсләренә кияргә юньле-рәтле киемнәре булмаганга күрә, төпчекләрнең айлар буена урамда күренгәннәре дә юк. Йорт эченнән бер Шәйсолтан гына, сирәк-мирәк булса да, колхоз эшләренә катнашкалап йөри. Шуңа күрә уналты яшьлек арык, хөнҗү егет гаилә башлыгы булып исәпләнә.

— Атны алып килдем. Бүген үк, хәзер үк минем иске йортка күченегез,— дип әмер бирә башлады Әмир, ярым бөгелеп ишектән узуга ук.— Анда әллә ничаклы ләгәннәр, иске-моски кием, ярып өйгән утын калдырып киттек, барысы сезгә булсын. Идарәдә Хәби балаларыннан калган күлмәкыштаннар да бар иде бугай әле. Алары да сезгә, кичке яктамы, шуннан бер урарсың...

Билгеле инде, Шәйсолтаннар сәгате-минуты белән күченеп тә куйдылар. Гәрдәннең иркен ихатасында Гөлтуташ, Әмирнең кичәге йортында Шәйсолтаннар авыз ерып йөри, ике як та бик канәгать иде. Тавыш кичен чыкты.

Әмир нык кына соңарып, арып-талып кайтып килә иде, капка төбендә Гөлтуташ белән Зифа еламсырап тора.

— Тегендә иске йорт базында куяннар онытылып калган бит. Кичә син ут капкандай ашыктырдың да, куянкайлар гүпчем истән чыгып очкан. Менә бүген без икәүләп эзләп барганыек, өч ана куянның берсе дә юк. Шәйсолтаннан сорыйм, ә ул авыз ера. «Мин ахутник түгел, каян белим инде». Ә үзе менә болай, менә болай итеп бертуктаусыз теш казнасын казый. «Ит изгелек, көт явызлык» шулай була икән...

Әмир котыра-котыра, җил-җил атлап үзенең иске ихатасына барып керде дә Шәйсолтанны якасыннан алып дер селкетте.

— Куяннарны ник ашадың, падла? Ничек кулың барды?

Шәйсолтанның йөзендә ник бер төк селкенсен.

— Мин ахутник түгел. Нинди куян?

— Тф-фү, җир бит! — дип, Әмир кире борылырга мәҗбүр булды...

Ә бер атнадан аяз көнне уйнаган яшен сыман искитмәле хәбәр:

— Хатыны белән балаларын ияртеп, Хәби кайтып төшкән. Хәби әле Себергә барган чагында ук Кәлининнең үзенә хат язган, ә Башглавсуд аларны кулак иттереп танымаган икән...

## СИГЕЗЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Җәй башында Зифа дүртенче сыйныфны тәмамлады. Югарыдан җиткерелгән тәртип-йола буенча ул хәзер Күчәрбайдагы җидееллык ШКМ мәктәбенә барырга тиеш иде. Бу хакта гаиләдә беренче мәртәбә гөман кубуга ук, Әмир хатынының ниятләрен, агачның төбеннән төрткән яшь үсенте шикелле иттереп, тамырыннан өзде.

— Татар теле белән абзар артына да чыгып булмый. Балам кеше булсын дисәң, русча укыт. Әнә Килемдәге Жантурин йортында яңа урыс мәктәбе ачылган, ди. Урысча укырга теләгән бала-чаганы элеккеге бөтен Бәләбәй кантуныннан җыеп тутыралар икән. Интернаты да, ашханәсе дә үзендә, балачага өчен бөтен җае тудырыла, диләр. Зифа балакайны шунда бирү хәер.

— Килем әллә кайда, җәһәннәмдә бит ул,— дип, чәр кычкырып елый-елый каршы төште Гөлтуташ.— Зифаның бит аның Яшке хуторыннан ары киткәне юк. Буе-сыны да катмаган баламны җыен урыс Иваннары арасына илтеп әрәм итиммени? Килен булып төшкәндә ияртеп килгән йә уйнаштан тапкан бала түгел әле. Аны, адаштырасы эт баласы сымак, Килем хәтле Килемгә илтеп ташлап, бер күрергә заринтизар булып, елап ятып булмас. Йә Күчәрбайга илтәбез Зифаны, йә бөтенләй бирмим!..

Бу турыда кабат сөйләшүдән кача-кача, озын җәй айлары узып китте. Уку дигәннәре беренче октябрьдә башланачак иде. Сентябрьгә кергәч, Гөлтуташ Әмирне күбесенчә түшәккә ятканнан соң гына «игәүләде».

— Килемгә илтсәң дә, Күчәрбайда торып укыса да, Зифа балакай барыбер ачка гына кыркылачак инде. Аның тәненнән әле егерме беренче елгы ачлык михнәтләре дә чыгып бетмәгәндер. Чит-ят кулына бирсәк, тагын бер тәлинкә җылы аш та күрми җәфа чигәр микән?..

Әмирнең әле Зифа чит-ят җирдә күрәчәк мохтаҗлыкюгалтуларны күз алдына китереп караганы юк иде. Гөлтуташ бигрәк тә тамак-тәгам өлкәсендә сүз кузгаткан чакта, Әмир аның белән ризалашкан шикелле тып-тын гына ятты. Ә Гөлтуташ исә, акрын-иплəп кенә төрткәләп, ирен үзе сайлаган эзгә төшерә торды.

— Син әйтмешли, Зифаны русча укытып кеше итү хәерлерәк инде анысы. Ике авыз да русча сүз белмәгән көе кая бармак кирәк? Мәгәр Килем, ай-һай, еракта бит. Безнең балакайны анда кем карасын? Әллә аны Бикми абыйларга илтеп бирәбезме? Чит-ят кешеләр түгел. Ичмаса, тамагы тук,

өсте бөтен булыр иде. Житмәсә, «Әмирләр кызларын Уфаның үзендә укыталар» дигән сүзне ишетүкәйләр генә дә ни тора!..

Ниһаять, Зифаны Уфада укытырга хәл иттеләр. Сентябрь уртасы үткәч тә, Әмир аны үзе озата китте. Ходайның рәхмәте, Бикми белән Лиза бернинди дә авырсыну, ят итү чалымы күрсәтмәде, хәтта әле туганлык җепләрен өзмәүләре өчен рәхмәт укый-укый алып калды.

Лиза Зифаны вокзалдан әллә ни ерак булмаган иске мәктәпкә илтеп урнаштырды. Чеп-чи татар авылыннан килеп гел рус телендә генә уку җиңел түгел иде, күрәсең, Зифа өйгә кайткач та әле икешәр-өчәр сәгать буе китап-дәфтәрләренә капланып утыра торган булды. Ләкин Зифа уяу, елгыр икән. Хуҗаларның өлкән балалары Михаил белән Артем, караңгы төшүгә, кулларына бау яки капчык тотып киенә башладымы, Зифа да өстәл арасыннан шундук сикереп тора һәм тегеләр белән рус телен вата-сындыра тәтердәтеп, бергә чыгып китә. Сукмак таныш: йә вокзал тирәсендәге тимер юл буена төшеп ташкүмер ватыклары, йә Бикми эшли торган агач фабрикасы ихатасыннан такта-токта калдыклары җыеп кайта алар. Әле сабыйлар яшендә генә булсалар да, һәммәсе төшенәләр: алма пеш, авызга төш дип яши торган заманалар түгел, тибенгән-чемченгән тавыкның гына тамагы тук була.

Шулай ике ай чамасы вакыт үтеп китте. Ноябрь уртасында һәр тарафка бала итәге шикелле нәфис, матур булып кар юрганы ятты. Зифа Уфаны шактый үз итеп өлгергән иде инде. Кирәк-ярак булса, кибетләргә йөрде. Артем белән Михаил кәшәкә сугарга киткәч озаграк югалып торса, олы капчыкны култык астына кыстырып, әрдәнә-йомычкалар артыннан да йөгерә торган булды. Әнә шул «дөнья көтәргә» дип чыккан кичләренең берсендә искитмәле, коточкыч хәлгә тап булды ул.

Зифа ул көнне дә, тимер юл тирәләрен айкап чykканнан соң, агач фабрикасы ихатасына барып кергән иде. Монда мәйдан иркен, олы басу хәтле. Әле тегендә, әле монда фәлән эскерт сыйдырышлы пилорама сарайлары. Һәр сарайга олыолы вагоннар йөри торган тимер юллар керә. Һәм менә шул сарайлар, тимер юллар арасында тау-тау, эскерт-эскерт булып тезелгән бүрәнәләр, шпаллар, брус, такта, рейка өемнәре, агач калдыклары. Монда алдыңны-артыңны абайламый йөрсәң, берәр аратасына җайсызрак кагылсаң, тау хәтле бүрәнә-такта астында калуың да бар. Ләкин агач эскертләре арасына кермичә дә булмый. Чөнки бүрәнә башлары, такта кисәкләренең иң-иң корылары нәкъ менә шул эскертләр арасында ята.

Зифа Төркәйдәге Рөстәмбәкнең ике катлы йорты чаклы

итеп өелгән такталар тирәсендә эзләнеп йөри иде. Көтмәгәндә Агыйдел ягындагы пилорама сарайларының берсе каршыннан акырып җырлап килгән ирләр тавышын ишетте дә сискәнгәндәй итте.

Фабрикада эш сәгате күптән бетте, эшчеләр дә әллә кайчан таралды бит инде. Мондый чакта кәефләнеп йөрүчеләр кемнәр булыр? Аларга соң агач фабрикасыннан башка урын беткәнмени?

Запрягайте, хлопцы, кони...

«Бәладән башаяк» дигән шикелле Зифа такталар өеменә ышыкланып басты. Әле кичке караңгылык күз бәйләрлек булып төшмәгән, «җырчылар»ны шәйләр-абайларлык кына яктылык бар иде. Зифа аларга дикъкать белән күз йөгертеп чыкты. Ирләр өчәү. Өчесе дә билләренә — балта, кул асларына пычкы кыстырганнар. Кәефләнеп алулары ару булган, ахры, аяк атлаулары чалыш-полыш, изү ачык.

Зифа ирләрнең икесен таныды да җиңел сулап куйды. Әнә берсе — сай кәстрүл сыман казакин бүрек, икенчесе муенына ук төшеп яткан төлке бүрек кигән агайларның Бикми абзыйның ихатасына да килгәне бар бугай. Ялгышмаса, аларның берсе Бикми абзыйда мунча кереп чыкты. Кысык күзләргә, киң яңакка ия икенчесе агач мичкә сатып алды сыман. Болардан шөллисе юк, болар, тотсалар да, Зифаны милиция-фәлән кулына тапшырмыйлар инде.

Зифа яшеренгән җиреннән кузгалмакчы гына булган иде, арадагы бер ирнең әтәчләнеп кычкыра башлавын ишеткәч, янә посты.

— А ты почему не поддерживаешь, татарин гололобый? Что, тебе мои песни не нравятся что ли? Нравятся или не нравятся, мне наплевать. Они — песни твоего господина. Ты их обязан петь. А ну, давай, подхватывай, чурка!

Запрягайте, хлопцы, кони...

Төлке бүрек кигән юлдашы нindидер иҗекләр шыңшып булса да моңа кушылды, ә казакин бүреклесе һаман авызына су капкан шикелле дәшми-тынмый, җитмәсә, башын түбән иеп кенә баруын белде. Җыр хуҗасына ошамады, ахры, ул кисәк кузгалып казакин бүрекленең артына китереп типте.

— Пой тебе говорю, татарин гололобый! Ведь это тебе надоело гнуть спину у нэпманов, да в кооперативах. Это ты первым рвался в коммуны да в артели. Это ты мечтал сделать всех равными, как редька. Вот сегодня мы все равны. Мы поем, и ты пой. А то покажу, кто на этой земле хозяин! Я...

Урыс «әтәче» тагын нindидер янау сүзләре тезә башла-

ган иде дә, аларын әйтергә өлгерә алмый калды. Моңа кадәр дәшми-тынмый барган татар ире, кисәк борылып, урыс адәменең ияк астына китереп сылады. Татар йодрыгы усал төште бугай, урыс адәме сагызлы шпаллар өстенә тәгәрәп китте, малахай бүреге, пычкы, бияләйләре төрле якка очты. Ә татар ире үзе, берни булмаган шикелле салмак кына атлап, ары китеп барды. Әмма аңа алай җиңел генә котылу язмаган икән шул.

Менә тоташ яңгырлы күк йөзе шикелле караңгы чырайлы урыс адәме шпаллар өстеннән капылт сикереп торды. Бүреген-бияләйләрен дә эзләп маташмады. Билендәге кушакка кыстырылган балтасын суырып алды да, баудан ычкынган эт шикелле йөгереп, татар иренең баш түбәсенә арттан китереп состы. Ап-ак кар өстенә мәк таҗлары шикелле кан чәчрәтеп, татар ире җиргә тәгәрәде. Яңа кан исе урыс адәмен кыргыйлыкның соңгы чигенә илтеп кертте бугай. Ул әүвәл, илереп-шашып, татар иренә ике-өч мәртәбә тибеп алды да аннары, котырынып-ярсып, моңа кадәр шәүлә сыман сүзсез генә йөргән «төлке бүрек иясе»нә әмер салды.

— Что ты стоишь, как истукан, узкоглазый? А ну, тащи пилу!

Кысык күзле, киң яңаклы бәндә җеп белән тартып китерелгән шикелле, шул минутта ук татар гәүдәсе янына килеп чүгәләде. Котырынган урыс исә һушсыз яткан татар ирен тимер юлның бер як рельслары өстенә күтәреп салды һәм канга баткан кулын пычкы сабына сузды.

— А ну, дай мне пилу! Дай, тебе говорят, узкоглазый! Я этого татарина-активиста на части изрежу!..

Зифа такта өеменә терәлеп баскан көенчә зәхмәт суккан шикелле хәрәкәтсез-тынсыз калган иде. Үз күзләренә үзе ышанмады. Менә котырган урыс пычкыны татар иренең бугазына салды, ялт-йолт итеп тарткалый да башлады. Ап-ак кар өстенә янә кан чәчрәде, әллә нинди гыжылдауга, пошкыруга охшаш аваз чыкты. Төлке бүрекле ир укшый башлады, ахры, ике-өч мәртәбә ян-ягына төкеренеп алды. Моны күреп, вәхши урыс янә котырынды.

— Что ты сачкуешь, узкоглазый? Это — твой враг. А ну, давай, тяни!

— Тартам бит инде, хужам, тартам. Вәт әсәеңне һатыйм! — дип, кысык күзле ир әүвәл үрсәләнеп сүгенде, аннары «миңа да мондый тәкъдир эләгә күрмәсен» дигән шикелле, пычкының үз ягын ашыга-кабалана тартуга күчте. Корбан татар тарафыннан гыжылдау авазлары күптән тынган иде. Вәхши урысның да күңеле булды, ахры. Ул канга баткан пычкыны кысык күзленең кулына ташлады да тезләренә ябышкан кар кисәкләрен каккалый-каккалый урыныннан тор-

ды. Һич тә ашыкмыйча бүреген, бияләйләрен, балтасын җыеп чыкты. Аннары, эшенең нәтиҗәсенә инанырга теләгән сыман, корбан татарның гәүдәсе янына килеп басты, усал тибеп куйды.

— Готов татарин. Одним меньше. Туда им всем дорога…

Чалт иттереп татар иренең йөзенә төкерде дә, балта-пычкыларын барлый-барлый, вәхши урыс фабриканың җимерек коймалары ягына атлап китте. Аңа хуҗасыннан калмаска тырышкан тугры эт шикелле, тавышсыз-тынсыз атлап, кысык күзле, өтек ир иярде.

Башын рельсның бер ягына, гәүдәсен шпалларга сузган көенчә татар ире канга баткан кар өстендә ята. Сабый Зифа тезләре белән ак кар өстенә сыгылып төшкән дә, агач сын шикелле хәрәкәтсез калып, мәеткә текәлеп каткан. Ачыргаланып кычкырмакчы, еламакчы була — авызыннан пышылдауга тиңләрлек тә аваз чыкмый. Бу коточкыч җинаять, канлы мәет яныннан үкерә-үкерә йөгерәсе килә — җеп өзәрлек тә куәт таба алмыйча, каккан казык сыман кымшаналмый тора. Ә күз алдында һаман канга баткан муен, ап-ак сөяк…

Аны фәкать ике-өч сәгатьтән соң гына Бикмөхәммәт агасы эзләп тапты. Сабый Зифа кар өстендә хәрәкәтсез-һушсыз ята иде, Бикмөхәммәт аны кулларына күтәреп алып кайтты.

Зифаны хастаханәдән бер айдан соң, анда да әле Әмир үзе килеп кат-кат ялынгач гына биреп чыгардылар. Башкалада укулар шулай тәмамланды.

## 2

Әмирнең үзенең дә Төркәйдәге хәлләрен ал да гөл диярлек түгел иде әле. Көзге туңга сөрүләр башлангач та, Әмир Бәләбәйгә барып «Фордзон» дигән трактор алып кайткан иде, файдасын өч-дүрт көн чамасы гына күреп өлгерделәр. Аннары кайсыдыр явызы төнлә керосин савытына ком тутырды, тракторчы егет Бүздәктән килеп төшкән ярдәмчеләре белән бергә двигательне атна буена әле сүтеп, әле кат-кат җыеп иза чикте. Шуннан соң, Канкай биреп кайтарган ике көпшәле ау мылтыгын тоттырып, Әмир трактор янына төнге каравылчылар да билгеләгән булды. Ләкин бабайларның «бәхетсезнең чалкан егылса да борыны каный» дигәннәре хак, күрәсең. Бер атнадан соң, күк йөзенең мендәре тишелгән шикелле, тоташ яңгырлар коя башлады да авыл халкы «гыйфрит» дип тәгаенләгән тракторның гел кирәге бетте.

Колхозга күрше Чакмагыш районыннан юллап алып кайткан нәсел үгезе дә төркәйлеләр малын әллә ни кинәндермәде. Мал кадәр мал мондый этлек чирен каян эләктергәндер? Нинди генә аранга, нинди генә «кәләш» белән ябып

карамасыннар, теге азгын үгез «кодаланган» сыер-таналар янына якын да килеп карамый. Дежурга билгеләнгән ирләр ферманың икенче башынарак китеп уяулык киметтеме, кибән кадәр үгез ярым черек киртәләрдән каккаланган араннарны җимерә дә кача.

Беркөнне шулай качкач, ул Торна күле ягындагы урамга барып кергән. Күзе-башы тонган үгезне күрүгә үк урамдагы бөтен бала-чага капка асларына, читән артларына качып беткән бетүен. Ләкин «бәла казык башыннан түгел, адәм башыннан йөри» дигәннәре шулдыр инде. Харис атлы йомыкый гына иргә күрше Усман авылыннан килен булып төшкән сакау, шадра Рәүфә Чәрмәсән буеннан каз эчәгеләре юып кайтып килгән җиреннән үгезгә тап булган. Көянтәсенә элеп кайткан эчәк-бавырларны ташлап качкан булса, бәлки, әле котылыр да иде. Ә Рәүфә килен, ни хикмәттәндер, көянтәсен әрле-бирле селтәп һөҗүмгә томырылган. Котырган үгез бер кадауда ябык, җиңел гәүдәле хатынны баш аркылы алып аткан инде.

Әмир йөгереп килеп җиткән чакта, Рәүфә килен инде җан биреп өлгергән, олысы — биш, кечесе өч яшьтә көенчә ятим калган ике сабый әниләренең гәүдәләре янына тезләнеп баскан иде. Бөтен күрше-күлән малайлары җыелып кыйнаган чакта да, авызыннан ике-өч сүз дә алалмаган өчен балачактан бирле Каты кабык кушаматын йөрткән Харис шул вакытта Әмиргә барча кеше ишетерлек итеп әйтеп салды:

— Гел тантана итеп кенә көн күрүләр үтәр. Котылырмын, димә. Бу ятим калган балаларның күз яшьләре өчен кан косачаксың әле син, бик белеп тор!..

Мондый янауларны ноябрь ае башлангач янә ишетте ул. Шул вакытта аңа Күчәрбай шурасыннан яңа әмер биреп кайтардылар:

— Аллага табыну — агу, дин тотулар — хата. Искелекне тамырыннан корытырга кирәк. Барча авыллардагы мәчетләрне ябып бетерәбез дә алар урынына клуб ачачакбыз...

«Октябрь революциясенең ундүрт еллыгы» дигән көнгә туры китереп, Әмир Төркәйнең әллә ничаклы халкын мәчет янына җыйды. Әлбәттә, Упалнамуч Чапай Сабиты да, Идрис, Шәрифулла, Гөлсем кебек комсомоллар да иртә таңнан бирле шунда иде. Мәчет кенә бикле, аңа керерлек түгел. Ә мәчет каравылчысы булып йөргән Сафа картны ничәмә-ничә «чапкын» җибәреп карасалар да, таба алмадылар. Аптырагач, каравылчы картны юллап, Әмир үзе китте. Ә ул, бактың исә, беркая да качмаган, чип-чиста, ап-ак ыштан-күлмәкләрен киеп, өенең иң түренә куелган сандык өстенә утырып чираттагы «чапкын»ны көтә икән. Әмир килеп кергәч, төге дә селкенмәде.

— Нәрсә, олан, инде мәчетне дә калхузыгызга алып, барчабызны кяфер итмәкчеме? Барып чыкмас. Мәчетне син төзеп бирмәдең, дәхелең булмасын! Үзем исән көе бер ачкыч та бирмим! Гөнаһсыз адәмнәр канын суыруга син күнектең инде. Бу юлы да талап алырга җыенасың икән, мин барысына да әзер. Мә, әүвәл минем җанымны суыр, аннан ачкычны ал...

Әмир баш түбәсен ишек нигрәсенә бәрә-бәрә, яман сүгенә-сүгенә чыгып китте. Чигену шура тарафыннан гафу ителәчәк адым түгел иде. Әмир бер кызган көенчә җил-җил атлап килеп җитте дә, әллә кайдан бер тимер кисәге табып, мәчетнең йозак-элмәкләрен каерып атты. Аннары алар, Упалнамуч Сабит белән бергәләп, мәчет мөнбәрен дә җимереп ташладылар. Шәрифулла белән Идрис — комсомоллар — элекке Әхтәм хәзрәт йортыннан өстәл алып килде. Аны кызыл җәймә белән капладылар, мәчет идәненә эскәмия белән урындыклар тезеп чыктылар. Халыкны, кабат йорттан йортка йөреп, әллә ниләр белән өркетә-өркетә, мәчеткә тутырганнан соң, Упалнамуч Сабит «революция, бөек борылыш, индустрия, колхоз» дигән сүзләр тезә-тезә доклад укыган булды. Соңыннан колхоз яшьләре «Зимагурлар» дигән драма уйнадылар.

Зимагурлар талчукта,
Кайгырмыйлар мал юкка.
Кайгырсалар кайгыралар
Тәмәкеләре юкка.
Әй, зимагур, кайт иленә,
Илдә иген игәрсең.
Бутылкаңны ат итәрсең,
Чабатаңны җигәрсең.

Комсомоллар дулый-дулый шулай җырладылар. Ләкин Төркәй халкы гына озын кич буена мәет озаткан шикелле тын утырды. Әмир кайтырга чыккач, караңгы тыкрыклардан, койма артларыннан тыелып кына сүгенгән сүзләр яңгырап калды.

— Балак бете башка менсә, әтәч булып кычкыра, ди. Аллаһ йорты булган мәчеткә кул күтәрде бит, явыз!

— Ничава, бүген шәп үгез булып йөрсә дә, иртәгә үләксә ул. Аңа да кәкрәергә чират җитәр әле!

— Шул пычрак кулкайлары корышып катса, соңгы минутында авызына су салучы да булмый җәфа чиксә иде, йа Илаһым!..

Әллә шушы каргыш-гөнаһларның әҗере төште инде, кыш башланып бер ай чамасы вакыт үтүгә үк, фермада маллар кырыла башлады. «Ялгызаклар» дип типкәләү аркасында авылдагы бик күп крестьяннар кышлык печән белән фураж

әзерли алмаган, шуңа күрә һәммәсе диярлек, колхозларга кереп, ат һәм сыерларын күмәк ферма эченә илтеп япкан иде. Ләкин колхоз дигәннәре дә мондый кисәк тизләнешне көтмәгән, аның барча малларга да җитәрлек араннары, печән-саламы юк, ә фураж итеп калдырырга тиешле солы-арышларын Бүздәк белән Бәләбәй элеваторларына озатып бетергән иде. Менә хәзер көн-таң атса бәла. Йә алашалар-бияләр кайсы да булса юашкайны тибеп үтергәннәр, йә алты-җиде сыер күгәргән бәрәңге сабагы ашатканга тәгәрәшеп ята. Ә инде олы маллар тарафыннан таптап-сытып харап ителгән колын белән бозауларны санап бетермәле түгел.

— Фураж бирегез безгә? Яңа абзарлар төзү өчен агач кайтарыгыз?

Әмир әнә шул рәвешчә ялына-ялвара Бүздәктәге бөтен оешма ишекләрен, барча кабинетларын айкап чыкты — аның сүзенә колак салучы түрә табылмады. Җан аткан — елан ите ашаган дип, Әмир колхозга кергән әллә ничаклы авылдашлары каршына барып та йөз суы түгеп караган иде, монда да аның сүзенә ыжлап бирмәделәр.

— Безнең мал түгел. Колхоз-колхоз, дия-дия, авыз суларыңны корытып, үзең талап җыйдың бит. Хуҗа булып алгансың, үзең кара инде...

Әмир басу уртасында яшен сугып янган агач төбе сыман япа-ялгыз иде. Әмир белән авыл арасындагы дошманлык-салкынлык әүвәл әле сай ерганакны гына хәтерләтсә, хәзер инде ул төпсез, тирән ерымга охшый башлады. Ә Төркәйнең аннан-моннан җыеп әвәләнгән кысан һәм хуҗасыз фермасында һаман мал кырылды, һаман мал кырылды...

## 3

Зифаны Төркәйгә алып кайтканнан соң, Әмир Күчәрбай мәктәбенә әүвәл ялгыз көе генә сөйләшергә барды. Элек бер дә мәктәп хәлләре белән кызыксынганы юк иде, барып кергәч, аптырап ук калды. Көзен Күчәрбайга дүртме-бишме яңа мөгаллим килгән, директоры да бу яклар өчен бөтенләй читят булган яңа кеше икән.

— Усманов Галимҗан,— дип таныштырды ул үзен, Әмирне әллә кайчан күреп белгән үз кешесе сыман шат елмаеп.— Шамил Усманов дигән язучыны ишеткәнең бармы? Мин менә шул кешенең энесе булам инде.

Яңа директорның өлкән туганы хакында да ишеткәч, Әмир коелып төшкән шикеллерәк булды.

— Шамил Усманов? Язучы? — дип сүз катты ул, бик озак вакыт көттереп торганнан соң.— Юк, андый атлы язу-

чыны белмим. Ә менә Усманов дигән комиссарны беләм. Без Фирганә, Бохара тирәләрендә басмачыларга каршы сугышып йөргән чакта, Азия далалары өстендә ике генә комиссарның исемнәре яңгырап тора иде. Шаһи-Морат комиссар да Усман комиссар. Мин менә шуларны гомер буе онытачак түгел.

— Рәхмәт, рәхмәт,— дип елмая-елмая, яңа директор һаман Әмирнең кулын кысып торды.— Ә ул син белгән Усман комиссар белән Шамил Усманов дигән язучы икесе дә бер үк кеше була инде. Урта Азиядә яулар кичеп кайткач, минем абый үзе үткән михнәт-казалар турында «Легион юлы» дигән китап язды. Ул әле элеккерәк елларда да «Ил кызы», «Ай чыкканчы» дигән, «Көчле Мандат», «Таң» дигән, тагын әллә никадәрле повестьлар, хикәяләр иҗат иткән иде. Синең ул язмаларны укыганың булмаган, шуңа күрә Шамил Усманов дигән комиссарның язучы да икәнен белмисең син, Нәгыймов Әмир иптәш.

Икесе дә шаркылдап көлештеләр. Яңа директор иркенләп, туктала алмый көлде, Әмир кыенсынуын яшерергә тырышкан шикелле тыелып кына. Әмма арада бер киеренкелек тә калмады, икесе тиң аңлашкан, килешкән кешеләр кыяфәтен алды.

— Нинди йомыш китерде сине монда, дважды председатель? — диде Галимҗан Әмиргә, ниһаять, көлүеннән туктап.— Кызың Зифа өчен кайгырып йөрүеңме? Юкка баш ватма син, җитәклә дә китер. Гади Төркәй авылыннан барып Уфа хәтле Уфаның үзендә, җитмәсә, әле урыс мәктәбендә укый алган икән, башлы синең кызың. Монда да ярты ел эчендә яшьтәшләрен куып җитәчәк ул.

Әмир яңа директорга текәлде дә авыз ачып катты. Гаҗәпләнүе, әлбәттә, йөзенә үк бәреп чыккан иде. Галимҗан да моны сизде бугай, елмая-елмая Әмирнең җилкәсенә кагыпсугып алды.

— Уфага укырга киткән минем кызый турында каян белә соң бу? — дип аптырыйсыңмы, кордаш? Аптырама. Шуңа күрә дә мине директор итеп куйганнар бит инде. Мәктәптә бүген укучы һәм иртәгә укыячак бөтен балаларны да белеп, барлап тормасам, миңа ни сан? Шулай итсәң генә мәктәпләрнең дә, гомумән, мәгарифнең дә иртәгәге бурычлары, йөзе ачыклана. Гәрчә, гәрчә...

Йөзендәге җиңелчә елмаю чаткыларын уч төбе белән сөртеп алдымыни, Галимҗан кисәк кенә җитдиләнеп калды. Карашы читкә юнәлгән, күзләре сагыш баскан шикелле уйчан иде. Әмир аның бөтен кыяфәтенә күз йөгертеп чыкты. Озын, зифа гәүдә. Куе-коңгырт чәчләр. Текә һәм киң маң-

гай, озынча йөз. Усаллыкны мәңге күрсәтә белмәс шикелле мөлаем, җылы күзләр.

— Син коммунист бит. Ә менә күңелеңдәге бөтен уйларны да уч төбең шикелле ачып салып сөйләшә беләсеңме? — дип телгә килде Галимҗан, Әмирнең күзләренә сынаулы караш төбәп. Әмир кайнар пар белән өтелгән сыман булды, Галимҗан, җавап та көтеп тормыйча, янә дәвам итте.

— Татар мәктәпләренең, шуннан чыгып карасаң, гомумән, татар теленең киләчәге, аны саклап калу безнең үзебездән генә тормый бит ул, кордаш. Менә үзебез шаһит булган тормышның соңгы ун елын гына күз алдыннан янә кичерик әле. Искелек, дин, фәлән, дигән булып, мәчетләр каршындагы бөтен мәдрәсәләрне ябып бетерделәр. «Советныкы» дигән яңа мәктәпләрдә «Йосыф» китапларын, «Бәдавам», «Сак-Сок» кебек милли мирасларны укыту туктатылды. Шулар белән һәм әле тагын ислам дәресләре белән бергә татар мәктәпләреннән милли рух, милли мохит тартып алынды. Совет мәктәпләре нурсыз, умырткасыз мәктәп төсен алды. Әйтерсең лә алар барысы да безнең балалардан гомумсовет, гомумурыс баласы әвәли башладылар...

Галимҗан белән Әмир басып торган коридор буйлап әле теге, әле бу тарафка, ач эт шикелле иснәнә-иснәнә, бер ир узып китте. Үзе әңгәмәдәшчеләрнең йөзенә карамаска тырыша, әмма килеш-кыяфәте урлап май ашаган мәченеке төсле астыртын, юха иде. Галимҗан, арты белән торганга, аны бөтенләй күрмәде, Әмир дә, үз чиратында, бу кешене күз чалымына китереп карамады.

— Ә ул хәреф алыштыру? Анысы да безне телсез калдырырга тырышу түгелмени? — дип әңгәмәгә кушылып киткәнен Әмир үзе дә абайламый калды.

Галимҗан әләктереп алды.

— Әйе, кордаш, әйе. Гарәп әлифбасы белән укып калган булсак, алар безнең җанга-аңга үтеп керә алмаячак иде. Гарәп имлясы — Көнчыгышка йөз тоту, мөселман дөньясында калу дигән сүз бит ул. Урыска алай ярамый, аңа безнең милләт уллары-кызларыннан эш атлары, телсез гавам үстерергә кирәк. Менә шуңа күрә алар безгә латин әлифбасын көчләп такты. Күңелем сизә, аның белән генә дә бетмәс, алар безне тора-бара үзләренең урыс әлифбасына, урыс тәртәсенә дә куып кертер әле...

Беренче мәртәбә танышу көнендә үк яңа директорның бу кадәрле ачылып сөйләшүеннән Әмир бик канәгать калды. Ул Галимҗан сөйләгәннәрнең һәрбер сүзе белән риза, шуңа күрә фикердәш, сердәш булырдай иптәш табуына күңеле очына, канатлана иде.

## 4

Әмир соңгы берничә айда Гәрдән кулактан калган Сал-Сал кушаматлы айгыр белән әүвәл тарантас, аннан кашевка чана җигеп йөрүгә күчкән иде. Күрми күргән — чабатасын түргә элгән, ди. Әмир дүшәмбе көнне Зифаны мәктәпкә бер кузгалса тукталуны-тыюны белми торган шул ярсу айгыр белән китереп куйды. Төркәйдән Күчәрбайга йөреп укучы балалар аз түгел бит, Әмир юлда аларның байтагын куып узды, әмма атын тыеп берсен дә утыртмады. Аның мондый эрелеген, әлбәттә инде, Төркәйдә сәнәк очына элеп җилгәрделәр.

— Гәрдән иминҗәсенә кереп оялады да, аның урынына үзе кулак булды. Шул сигәк кызын да мәктәпкә айгыр белән генә илтеп куйсын әле! Табылган хан кызы, аягы чергере!..

Әмир Зифаны Сәмигулла дигән бер бабай йортына фатирга кертеп калдырды. Бабай белән Хәмдениса атлы карчыгы ялгыз көе генә яшәп ята, яшьләре сиксәнгә җиткән иде инде. Мәгәр сиксәнгә җитсәләр дә, адәм балаларында нәфес дигән яман чирнең уты сүнәмени! Олы сыер, ике баш сарык өстенә бозавын-бәрәннәрен дә, каз-үрдәкләрен дә асрап ята болар. Ләкин үзләренең сәндерәгә менеп печән төшерергә дә, су ташырга, сыер саварга, сепарат әйләндерергә, идән юарга, мунча ягарга һәм тагын аяк астыннан табылып кына торган кырыкмаса-кырык эшне ерып чыгарга да куәтләре беткән. Мәктәптән кайтып керүгә, әлеге мәшәкатьләрнең һәммәсе артыннан Зифа йөгерә хәзер. Караңгылар төшеп, ниһаять, дәрес хәзерләргә утырса да, аңа ял юк. Сәмигулла бабайның иң яраткан ашы — тары боткасы. Ләкин анысы да гади ботка түгел. Бабай ботканың көнбагыш төше кушып пешерелгәненнән генә шат-канәгать кала. Шуңа күрә Зифа иртәкичен берәр җамаяк көнбагыш өеме чиертеп утырырга мәҗбүр. Көн саен тешләр, аңкаулар авырту бер хәл, бала кешегә кабыкны төкергәндә төшне йотмый калу мең җәфа. Зифа — ашауга дигәндә бик нәзберек, һәммә ризык каршында егылып китми. Ә көнбагыш төше үтә тәмле. Кайчагында эчтә бүреләр улый, шул тәмле төшкәйләрнең икесен-өчесен булса да йотып-йотып җибәрәсе килә. Мәгәр кич саен аның каршында ике күзен дүрттәй шарландырып Хәмдениса карчык утыра шул. Зифа балакай, нәфес җенен басып, төкерек йотып кына утырырга мәҗбүр. Ичмаса, шимбә көн тизрәк килеп җитсен дә, әтисе аны ике генә кичкә булса да үзләренә алып кайтсын иде!..

Көттерде, ялындырды, әмма кияү егетләре сыман җил-җил атлап, берзаманны яз да якынлашты. Апрель ае башлангач,

бер шимбәдә Әмир Күчәрбайга ат атланып килде. Үзе генә җайдакка әверелмәгән, ияр аелына бәйләп, йөгәнләгән Афоняны да алып килгән әле. Атларны Сәмигулла картның сарай эченә япкач, һаваланып алырга да онытмады үзе.

— Юллар беткән анда, ни кашевка, ни тарантас җигеп йөрмәле түгел. Икәүләп бер ат сыртына атланып йөреп булмас. Фермада мал море. Менә үзебезнең Афоньканы сиңа алып килдем. Бүген Канкай силсәвиттә ниндидер киңәшмә була, дигән иде. Шул киңәшмәләренә генә кереп күренәм дә, аннары икебез ике атка атланып кайтачакбыз...

«Күренеп» кенә китәргә язмагандыр инде, Әмир Сәмигулла бабайлар йортына тәмам күз бәйләнгәч кенә кайтып керде. Күтәреп килгән күчтәнәчләрен чыгарып салгач, карткарчык белән бергәләп чәйләр эчкәннән соң кайтыр юлга чыкканда, Күчәрбай һәм Төркәй арасындагы сырт өстенә куе караңгылык яткан иде инде. Кар катламы, чыннан да, сазлык сыман көпшәкләнеп, җебеп беткән икән, юлдан аз гына читкә чыктыларммы, атлар тез тиңентен ботка эченә керә дә бата. Шуңа күрә Әмир алгарак чыгып, караңгы бүлмәдә ишек эзләп капшанган шикелле, бик сак кына барды, Афоньканың йөгәнен дә кулдан җибәрмәде. Әхмәт авылы янына җиткәндә, төнге салкын үзенең көчен күрсәтеп өлгергән иде бугай, атлар инде каты басып, сикергәләп бара башладылар. Әмир хәтта хыялга бирелеп алудан да тарсынмады.

— Бу Күчәрбайдан соң сине берәр техникум-мазарга кертми булмас, кызым. Бәләбәйгәме шунда, әллә Уфаның үзенә үкме. Башта техникум бетерерсең, аннан институт. Кеше булам дисәң, укымыйча булмый. Сине Төркәй, Күчәрбайда гына калдырып булмас. Кешеләр алдында оят, гарьлек аннан. Үзе персидәтел, ә балаларын укытып кеше итә алмады, дип, миннән тавык көләр. Юк, Аллага шөкер, кулда рәт бар, мин сезне берәм-берәм юлга бастырам әле. Картлык көндә күкрәк киереп йөрерлек, «кемнеке» дигәндә «батрак Әмирнеке» дип, авыз тутырып әйтерлек булсын. Анагыз да җиңел...

Көтмәгәндә Әхмәт авылы янындагы иске зират ягыннан мылтык аткан тавыш ишетелде, шул мизгелдә үк җайдаклар баш өстеннән әйтерсең лә усал бал кортлары чыелдашып узды.

— Кызым, засада! — дип кычкырды Әмир шундук һәм Афоньканың йөгәнен усалланып какты.— Безне көткән болар. Мине аулыйлар, мине атмакчылар.

Әмир атының касыгына тибеп өлгергән иде, атлар җанфәрманга Төркәй фермасына төбәп чаба башладылар. Аларның баш очыннан янә усал корт өере сызгырышып узды, бераз соңгарак калып инде берьюлы ике яктан ике мылтык аткан тавыш ишетелде.

— Кызым! Иелебрәк утыр! Ялына нык тотын!

Атларның да өне алынган иде, күрәсең. Алар гыжлый-гыжлый һаман саен кызулый, ярсый барды. Афоньканың йөгәнен ныграк тарткалый-тарткалый, Әмир сытып-җимереп сүгенә-сүгенә чапты.

— Юк, мылтык күргән бәндә түгел бу эт җан. Мин булсам, инде күптән чүкеп алыр идем. Һаман теге юлы Әхтәм хәзрәт тәрәзәсеннән аткан черек кул иясе булырга тиеш бу. Һаман шул сасы көзән сагалый, һаман шул атмакчы.

Аннары Әмир белән кисәк кенә әллә нәрсә булды. Ул үз атының йөгәнен усал итеп сул якка каерды да, аңа Афоньканы да ияртеп, атларны авылга кертмичә, Торна күле ягына алып китте.

— Сантый, нәгаләт, бозау! — дип сүгенә башлады Әмир, Зифа гына бу сүзләрнең кемгә аталуын аңламыйча барды.— Мылтык күрмәгән кеше шикелле мәрткә киткәнмен бит. Мылтык тавышлары берьюлы ике яктан ишетелде ләбаса, кызым. Зират ягыннан куркыту өчен генә аттылар. Чын дошман ферма янында көтеп тора иде бит мине...

Торна басуы буенча байтак баргач, бер салам эскерте өстенә менеп яшеренделәр дә, атларны үз ирекләренә калдырып читкә җибәрделәр. Хәтәр озак күзәтеп ятканнар иде дә, аларның эзенә бастырып килүчеләр барыбер күренмәде.

Таң аткач кына кайтып кереп дөресен сөйләүгә үк, янә бәбәйләргә җыенып йөргән Гөлтуташ мич башына һәм сәкеләргә җәелгән барча юрган-түшәкләрне идәнгә сөйрәп төшерде дә елый-елый тезде:

— Һи-и, җанкайларым кебек газиз балаларымны тәрәз төбенә яткыраммы соң, дүр-рәк! Ю-ук, моннан ары сәкедә йоклау бетте. Ә син теләсә кая сузыл. Син башкисәр, алар башкисәр, алыш-бирешне үзегез ачыкларсыз.

## 5

Гөлтуташ шул көнне үк кич белән бәби тапты. Әмир, икенче таңда Күчәрбайдан шура сәркатибен алып килеп, балага исемне үзе куштырды.

— Борынгылар шикелле килде-китте исем куеп булмас. Мин — коммунист. Партиягә Ленин чакыруы вакытында кердем. Кызга Лена кушам!

— Нигә аны кяфер кушаматы белән мыскыллыйсың? Мөселман кызы ла ул,— дип, Гөлтуташның яулык читен кабып үкселдәве бернинди дә файда китермәде, сәркатиптән Әмир «Лена» дип язылган кәгазь алып калды...

Лена вакытыннан иртә туды, шуңадырмы атна-ун көн буе көтеп караса да, Гөлтуташның күкрәкләренә барыбер сөт төш-

мәде. Әүвәл күрше-күләннәргә Зифа балакайны юллап карадылар, аннары Гөлтуташ үзе ике урамдагы барча өйне тоташ урап чыкты — хуҗаларның берсе генә дә аларны сепаратка якын җибәрмәде.

— Кулак кадәр кулак йортында яшисез, байлыгыгыз билдән. Безнең сымак калкуз батраклары өенә кереп вакланмагыз әле.

Гөлтуташ елый-елый кайтып шуларны сөйләгән саен, Әмир котыра гына төште. Соңгы көннәрдә ул иске фермага терәтеп яңа ат абзары төзетә башлаган иде. Эчендә булган бөтен ачу-ярсуын шунда эшләгән ирләр өстенә түкте.

— Сез кыш көне дә атнасына ике бүрәнә каезлап җанны ашадыгыз, хәзер дә үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын дигән сымак кына селкенәсез. Моннан ары һәркайсыгыз көненә дүрт бүрәнә бурамыйсыз икән, сөннәткә утырткан шикелле иттерәм мин сезне, хезмәт көннәрегезне икеләтә кисәм!

Авылда Озын Закир, Илдерхан шикелле зимагурлыкта йөреп кайткан ирләр дә аз түгел, аннары Бүздәк, Бәләбәй, Уфаларны күргәннәр дә байтак. Җавапны тиз таптылар.

— Завутларда эш көннәре сигез сәгать кенә. Без сиңа ялланып эшли торган батрак-фәлән түгел. Сине безнең сыртта персидәтел итеп утыртсыннар диеп, бушка эшләр хәл юк...

Әмир сүгенде, котырынды, әмма берәүне дә кичке биш-алтыдан ары эштә таба алмады. Төркәйлеләр безгә диңгез — тубыктан, дигән исерекләр кебек көн итүгә күчте. Өйләренә кайтып кергәннән соң да, ихата-абзар ныгыту, мал карау, дөнья көтү белән беркем шөгыльләнми. Колхозлар төзелгәнче каравыл кычкырып эзләсәң дә урамда һичкемне табып булмый, элек алар, тирес корты сыман бертуктаусыз ихаталарында казынып ята иде. Ә хәзер өйгә кайтып бирән бастылармы, бөтенесе дә, малай-шалай сыман, урамга чәчелеп чыга. Йә колхоз кәнсәсе булып исәпләнгән элекке Әхтәм хәзрәт йортының баскычына тезелеп утыралар, йә мәчет ихатасында, йә мәктәптә. Кайсы тәмәке көйрәткән була, кайсы кабак төше яра. Үзләре, тәмам караңгы төшкәнче, берсенберсе уздырып лыгыр-лыгыр. Әмир яннарыннан үтеп киткән чакта гына тынып торалар да, ул күздән югалуга, тагын ләчтит. Әмирнең шуларның кайбер сүзләрен генә булса да ишетеп каласы, ачыклыйсы килә. Ләкин тегеләр уяу шул, авызны шып биклиләр. Шуңа күрә Әмиргә гел аның белән авыз чайкыйлардыр сыман тоела. Ул һаман үрсәләнә, һаман котырына. Әмир үзенең авыл уртасында япа-ялгыз утырып калганын адым саен тоеп-сизеп йөри. Шул ялгызлык газабыннан котылырга теләп, кайларга гына барып карамый, әмма бер җирдә дә үз-үзенә урын таба алмый, ялгызлык

тойгысы аны мунча пары сыман теләсә каян куып чыгара иде...

Май аена аяк басуга, районнан язгы чәчү буенча кыздыра башладылар.

— Борчакка төштегезме? Тары чәчтегезме? Юкса фәлән-төгән.

— Нәрсә, аларның кабинетларыннан безнең басулар шәбрәк күренәме соң әллә? Нигә безне ләпек өстенә чәчәргә куалыйлар? — дип, Әмир шура утырышында Канкайга йә район упалнамучларына каршы сырт йонын кабартып караган иде дә, комын тиз койдылар.

— Язгы чәчүне унбишенче майга бетермисез икән, авыл халкы өчен Сабантуй үткәрергә рөхсәт булмаячак!

Әнә шундый юллар белән «тәрбияли» торгач, әлбәттә инде, төркәйлеләр дә чәчүне уникенче-унөченче май тирәләренә ерып чыкты. Авылның бик күп карты чәчүне ашыктырган өчен ачынып-көеп йөрде, ирләр исә, сыртларыннан олы бер йөк төшкәнгә, ахрысы, бөтенләй икенче тормыш җаена күчеп яши башладылар. Көн-таң атса, Әмирне колхоз кәнсәсе каршында ике-өч ир көтеп ала.

— Аблайдагы кодаларга кунакка барырга җыенган идек. Күптән аралашкан юк. Җаен тап та минем элекке үз атымны бер генә көнгә булса да биреп тор инде син, иптәш персидәтел? Чит ат белән барсаң, кодалардан оят.

«Әһә, колхоз кирәк булдымы? Персидәтел дә иптәшкә әверелдеме?» — дип, Әмир кайберсенә хәтта җикермәкче, тәкәбберлек күрсәтмәкче була, әмма, үзен көчли-көчли, һаман тыелып кала. Чөнки сукыр-саңгырау түгел, барысын да күреп, ишетеп тора.

Бу бәндә дә Әмир авызыннан рөхсәт алуга ук, иң элгәре, үзенең тирәсендәге барча күршеләре янына кереп баш иячәк.

— Син теге чакта «Зимагурлар» дигән төятерне карарга өр-яңа күн итекләр киеп чыккан идең. Шуны миңа бер генә көнгә биреп тор инде, яшьти? Юлда барганда-кайтканда кул тигермим, Аблай башына җиткәч кенә киям. Без дә Шәмсенисага быел кышын өр-яңа, зәңгәр төстәге камзул тектереп алдык. Син Усмандагы үзеңнең Фәрвай җизнәң янына җыена калсаң, без дә сине бәладән коткарырбыз...

Әнә шулай кайсыннан яңа итек, кайсыннан яңа бишмәт, читек, камзул, галош алып тора-тора гына, кайсы да булса гаилә кунакка җыенып китә. Кайтыр юлга чыккан чакта, әлбәттә, хуҗаларны да Төркәйгә кунакка чакыралар инде. Ләкин тегеләрнең дә хәле хәл икән шул, җаваплары чорына күрә яңа:

— Ил җибәрсә, барырбыз...

Әмирнең үзенең кунакка йөргәне юк, ул болар хакында

ишетеп кенә белә. Ул хәзер көне-төне Сабантуйга әзерләнү белән генә мәшгуль. Иртән комсомоллар, әле теге, әле бу урам буенча йөреп, яшь киленнәр, яшь җиңгиләр чиккән-теккән тастымаллар, кулъяулыклар, тәрәз пәрдәләре, яулык, җәймә җыеп алып кайта. Аннары Әмир фермадагы, көтүләрдәге малларны барлап-санап чыга да, беркемгә дә әйтми-нитми генә Афоньканы алып, Табор күле буена төшеп китә. Теге Әмирнең төп йортында калган, аның куяннарын суеп ашаган Шәйсолтан белән бергә алар, кеше күзеннән яшереп-нитеп кенә, Афоньканы чабышка әзерлиләр. Соңгы арада алар менә шул сәбәпле якынаеп китте. Бер яктан, Шәйсолтан — тешләк, авызыннан сүз чыкмый, икенчедән, ул җиңел сөяклерәк. Афонька аның кубызына иләсләнеп чаба.

Ниһаять, район башлыкларыннан рөхсәт булды бугай, авылларда Сабантуйларны башлап җибәрделәр. Тантаналар бөтен авылларда да бер көнгә туры килгәнгәдер инде, алардагы халык быел бик аз санлы булып, ярышлар-уеннар бик күңелсез үтте. Чабышларда да, күп булса, шул алты-җиде чамасы гына ат узышкандыр. Ләкин Афоняга шул аз санлы чаптарлар арасында да мәйдан уртасына кайтып җитәргә язмаган, ул, бичара, ярты юлда ук туктап калган икән. Моның сәбәпләрен Әмир караңгы төн җиткәч, анда да әле Шәйсолтанны бугазлап алгандай сораштыргач кына ачыклады.

— Афонька куып уза башлагач, Кара тавык камчы белән аның чыраена сукты. Кем дип инде, шул — Кара тавык Гайсә.

Әмир кычыткан түтәле өстенә төшкән сыман булды. Гайсә, Гайсә... Хәбинең энекәше. Яшь чакларда ахирәт булып йөргән, соңыннан юллары капма-каршы якка аерылып киткән Хәбинең бертуган энекәше. НЭП елларында авылдан китеп, әллә ничә айлар буена кайдадыр буталып йөргән Гайсә. Аның хакында әле Каюм карак бандасында, әле Агыйделдән Бөре тирәли узган пароходларны басучы шайкада йөргән икән, дип тә авыз чайкадылар. Төтен дигәннәре утсыз чыкмагандыр, бу Кара тавык Гайсә ау мылтыгының җаен белә иде. Аның осталыгын очраклы рәвештә генә Әмир үзе ачыклады. Ул узган ел көздә «Фордзон» тракторы янына чираттагы төнге каравылны куярга барган иде. Дары исен иснәү түгел, әле саламнан печәнне дә аермаган яшь егеткә ау мылтыгының җаен-рәтен аңлатып торган чакта, яннарына шушы Гайсә килеп чыкты. Әүвәл сүзсез генә күзәтеп торган иде дә, яшь егетнең сантыйлыгы үзәгенә үтте бугай. Көтмәгәндә мылтыкны егет кулыннан тартып алды да «ә» дигәнче аны сүтеп-җыеп күрсәтте.

Хәзер менә шул вакыттагы кич күз алдына янә килеп

баскач, Әмирнең зиһене аша яшен шикелле бер уй яктырып узды. «Әхтәм хәзрәт тәрәзәсеннән дә, Күчәрбай юлында да кем атты, дип йөрим. Моның Гайсә булуы да бик мөмкин бит. Абыйсын кулак итеп сөрдем, беренче тапкыр Әхтәм хәзрәт тәрәзәсеннән аткан чакта Хәби Себердә иде. Ләкин... ләкин... икенче тапкыр Күчәрбай юлында миңа аткан чакта, Хәби әллә кайчан авылга кайткан иде бит инде. Әгәр Гайсә булса, бу юлы ник аткан?..»

Әмир озак уйланып торды, сорауларына җавап таба алмады. Гайсәгә ачуы бик нык кабарса да, үзен кулга алырга, тыелырга булды. «Ярар, Афонькага суккан икән, суккан. Афонька өчен үч алам дип, Гайсә-башкисәрне тотып кыйнап булмый. Мин болай да Хәбине нык рәнҗеттем. Гайсә шуның әҗерен алырга җыенгандыр, ә мин, давай, түзим».

— Ә без болай итәбез, Шәйсолтан туганкаем, — диде Әмир икенче минутта ук.— Чакмагыш районы белән Благоварда Сабантуйлар ике-өч көннән соң гына узачак бит әле. Давай, без беркемгә әйтмичә-нитмичә, Афоньканы Бәрдәс авылына аппарып чаптырабыз. Анда минем сугышларда бергә йөргән иптәш тә бар. Бер көн алдан барып, шуларда төн кунарбыз...

Бәрдәс авылында чабышка килгән атлар бик күп булып чыкты.

— Әмир абый, кара, монда исемлеккә язылып өлгергәннәре генә дә утыздан артып киткән,— дип, Шәйсолтан башта ук пошаманга төште.— Әле тагын Кыркаен, Тозтүбәдән килгән чаптарлар да бар, ди. Алар әле язылмаган гына. Безнең Афоньканы болар күз чалымына да кертми.

Әмир мәйданны тирәләп йөргән чабышкыларга күз йөгертеп алды да үзе дә шик һәм хәвеф мичкәсенә чумган сыман булды. Һе, карале, әнә теге Әбзән, Чишмә, Бөре якларыннан килгән атлар бигрәк гаярьләр шул. Һәммәсендә диярлек озын сыйрак, уйнаклап торган ботлар, сыгылмалы гәүдә, киң күкрәкләр, аккошларныкына охшаш озын муен. Болар бер урында гына басып торуны белми, туктаусыз биенәләр, читкә сикерәләр. Ә Афонька ничек? Әнә читтә үшән, юаш булып, башын салындырып басып торган була. Кыяфәте дә тегеләрнең янәшәсендә ташка үлчим генә. Биеклеге метр ярымга да җитмәгән тәбәнәк буй, кысып әвәләнгән камыр кисәге шикелле кеп-кечкенә гәүдә. Сыйраклары, муены, ботлары да кыска. Һи-и, монгол монгол шул инде, урыс йә булмаса татар пәһлеваннары янына бастырмалы түгел.

— Яшьти, яшьти,— дип, берзаманны Әмир янына Бәрдәстәге дусты йөгереп килде.— Узышка җибәрергә анда юртаклар юк. Сабантуйга килгән кунаклар арасыннан җыеп кына исемлеккә дүрт ат яздырдылар. Синең Афонька җигү-

гә күнеккән бит. Анда бүләкләр затлы. Бүләкләрне ничек яуласаң да барыбер түгелмени? Әйдә, Афоньканы юртаклар бәйгесенә яздырабыз...

Авыл читендәге яланга килеп тезелгән йөзәрләгән тарантаслар арасыннан иң җиңелен, иң купшысын сайлап, Афоняга камыт кидерделәр. Чабыш көтеп йөргән бичара ат әүвәл үзенең нинди хәлгә төшкәнен аңламады әле. Тарантаска Әмир үзе менеп утыргач, ул кайтыр юлга чыгабыз икән, дип тә уйлагандыр әле, мескен. Буш ялан читенә алып китеп, үзе сыман тарантас-арбаларга җигелгән алты-җиде атны бер сызыкка тезә башлагач кына, нindидер бәйге көткәнен сизенеп ярсырга тотынды ул. Старттан да бик тиз алдырып китте. Көндәшләре гәүдә-кыяфәткә эре булсалар да, алар һәммәсе дә кичә генә тәртә арасында йөргән эш атлары, җитмәсә, бәйге-узышларга әзерләнмәгәннәр иде шул. Алар икеөч йөз адым ара үтүгә үк, лап-лоп китереп, тоякларын берберсенә бәрә башладылар. Тагын ике йөз-өч йөз адымнан соң һәммә юртак йә сызгыртып, йә пошкырып тын алуга күчте. Дүрт-биш юртак артта калып күздән югалса да, колакларда гел Әмир әйдәкләп кычкырган авазлар гына яңгырап барды.

— Афонька! Давай, тырыш, җаным, тырыш! Алдагы әнә теге кола бияне дә куып узыйк инде!..

Финишка, кола бия белән тәртәне-тәртәгә терәп, бер үк мизгелдә килеп керделәр. Әмир белән кола бия хуҗасының икесенә дә бүләккә саулык бәрән эләкте.

Әмир әле Төркәйгә кайтып җиткән чагында да шатлык хисләрен тыеп торыр хәлдә түгел иде. Афоняны фермага да илтеп тормады, үз ихатасында гына туарып калдырды. Афоняның да кәефе шәп иде, күрәсең, ул, ике дә уйлап тормыйча, чылбырда утырган Пальма янына барып, аны борыны белән төрткәләп уйный ук башлады. Пальма әүвәл аңа ырлап кына җавап биргән иде, «җиңүче»дә эрелек купты бугай. Әһә, син әле шулаймы, дигән сыман башын күтәрде дә этне ташлап китәргә әзерләнде.

Шуннан Пальма үзе моның әле алгы аякларына сырпаланып, әле муенына ышкынып шаяруга күчте. Әмир шундук әмер бирде.

— Зифа, кызым, этне җибәр, давай. Рәхәтләнеп, ихата буенча куышып уйнасыннар.

Әтисендәге юмартлыкның серен бишенче сыйныфны тәмамлап кайткан Зифа да бик тиз сизеп өлгерде.

— Әти, әтекәем! Ибни керәте янында Иванайдан килгән урыслар алма сата. Акча бир дә, әйдә, мин дә үзебезгә алып кайтыйм әле.

— Мә соң, балакаем,— дип, Әмир кесәсеннән бер уч вак

акча чыгарып бирде.— Үзеңә һәм апайларыңа гына түгел, Афонькага да алып кайт соң, давай. Бер чиләк тия икән, бер чиләк, мать якасын! Мин Ләпәй сымак әтрәк-әләм түгел, персидәтел әле!..

Иренең ихатада күркә-тавис сыман кәпрәеп йөрүен тәрәзә аша тыңлый-тыңлый түземлеге корыгач, өй эченнән нарасыен күкрәгенә кочкан Гөлтуташ чәрелдәп килеп чыкты.

— Тагын таш кирмән яулаган батыр сыман кәефләнеп кайткан бит бу убыр. Хәзер тагын сандыгындагы соңгы ыштанын, ларындагы соңгы гөрәнкә онны да күрше-күләнгә өләшеп бетерәчәк инде.

Гөлтуташның чәрелдәп битәрләвендә дөреслек бар, колхозда эш җайлы барган, кәефе шәп чакларда Әмир кием йә булмаса ризык сорап кергән һәр кешегә соңгы кисәген дә биреп чыгара иде. Ләкин Әмир бүген битәрләү-игәүләүләрне тыңлап торырга теләк күрсәтмәде, хатынының авызын икеөч сүз белән үк япты.

— Мин сиңа әнә саулык бәрән алып кайттым. Эшең булмаса, давай, шуны кара. Ә мин синең чәйнәнгәнне гүпче тыңлап тормыйм. Бүген минем бәйрәм. Мылтыкны алам да Табор күле ягына ауга чыгып китәм...

Зифа капчыктагы чиләктән артык алманы өстери-өстери кайтып кергән чакта, әтисеннән инде җилләр искән, ихатада Тимерҗан энекәше белән нәни Вәзирә генә саулык бәрәнне лапаска таба куып йөри иде. Баскычка тезелешеп өчесе тиң нәфес-тәгам басканнан соң, Зифа Афоня белән Пальма тарафына да икешәр-өчәр алма тәгәрәтте. Ә аннары бөтен ихатаны тутырып чәрелди дә башлады.

— Инәй, инәкәем, чык әле, чык! Карале, кара, икесе дә алма ашый бит болар!

Әллә берәр хәвеф-мазар essarмы дип, баскычка йөгереп чыккан Гөлтуташ Афоня белән Пальманың алма ашауларына шаккатып карап торды да, үзалдына дога укыган шикелле әйтеп куйды.

— Эт белән атка да алма ашатканны бөтен ихатаны ярып кычкырма инде, кызым. Күрше-күлән «Әмирнекеләр азындылар» дияр. Аннары Ходай Тәгалә дә күпсенмәсен берүк...

Әмир кич белән ике кыр үрдәге, ике торна күтәреп кайтып керде. Бер торнасы бигрәкләр дә зур, канатларын җәйсәң, аңа дәү ирләр колачы да җитә алмый иде. Әмир аны капка төбенә алып чыгып, канатларын җәя-җәя кич буе шапырынды. Өй эчендә Гөлтуташ кына берьялгызы укынуын белде.

— Без ятимнәреңнән ошбу шатлыкларны күпсенмәсәң иде инде, йа Илаһи-Раббем?!

## 6

Дөнья алдын бер күрсәтсә, артын биш күрсәтә, дигәннәре хактыр инде. Әмиргә дә каза көтмәгәндә килде.

Чакмагыш, Благовар, Чишмә, Бүздәк районнарына кергән бөтен тирә-як авыллар өчен дә печән өсте башланган, төркәйлеләр дә ике бригадага бүленеп, бер төркем халык Яшке хуторы ягына, икенчесе Табор күле буендагы тугайлыкка төшкән иде инде.

Җәе коры килде. «Үләннәр буйга аз үсте бит әле, инде булмасмы, инде булмасмы?» — дип зарыга-зарыга атналар буена яңгыр көтеп карадылар. Юк, күк йөзендә өметләнерлек болыт әсәре барыбер күренмәде. Шуннан соң ничарадан бичара кыяфәттә башладылар инде. Ләкин үләннәр бик тә юка, кыска, аларны югалтмыйча җыеп алыйм дисәң, ирләргә тезләнеп һәм, җитмәсә, кайчы белән кыркып чыккан сыман, һәр сабакны кырып барырга туры килә иде. Мондый хезмәт пәһлевандай ирләрнең дә җегәрен соңгы тамчысына тикле суырып ала. Ә бичара төркәйлеләр тәмуг газабыдай мондый сынауларга ничек итеп түзсен? Авылдагы ике ирнең берсе атналар-айлар буена итле аш күргәне юк. Ярты авыл халкы хәтта әле икмәк-бәрәңгесен дә авыз тутырып ашый алмый интегә. Ә монда әнә район үзәгеннәнме, Уфаның үзеннәнме «кырда куна-төнә ятып печән чабарга» дигән фәрман җиткерделәр. Төркәйлеләр мең кат сынаган инде, сәвит фәрманнары белән шаярып-мазар булмый. Сәвитнең кул коры, аның фәрманнарын санга сукмадыңмы, рәхим итеп, әнә Себер юлы.

Төркәйлеләр дә менә Табор күле янына шалаш, чатыр корып, куна-төнә ята. «Көндез кояш аяусыз кыздыра бит, күбрәк өлешне иртән чабып калыйк» дип, икедә-өчтә үк торып тотыналар. Иртәнге алтылар тирәсе якынайдымы, бөтенесенең карашы ирексездән юлда. Бүген балалары яисә хатыннары итлерәк бер ризык китермәсме дә, аларның сынган ботак шикелле кипшенеп, суырылып калган беләкләренә бераз хәл кермәсме? Югыйсә һәммәсе дә беләләр бит инде, тикшереп киттеләр бит. Юк аларның йортларында ит-май! Ичмаса, йомырка да, авыз тутырып ашарлык икмәк тә юк! Ләкин өметсез — шайтан ди, көтәләр бит менә, көтәләр бит!..

Алтылар тулып киткәч, чыннан да, авыл белән ике арадагы юлда хатын-кызлар белән балалар күренә башлый. Төенчекләрен итәк артларына, алъяпкыч асларына яшереп кенә килеп җитәләр дә, кичәге табак-савытларын җыеп алгач, ирләре яисә әтиләренең күзләренә туры карарга да кыймыйча, шәүлә сыман тавыш-тынсыз гына кирегә юнәләләр. Иртә саен бер үк төрле күренеш, бер үк газап.

Аның каравы бригадирлар, Упалнамуч Сабит белән персидәтел Әмир бер дә ялындырып тормый. Үч иткән шикелле, көн дә нәкъ ирләр күләгәгә кереп чирәмгә сузылган сәгатьтә килеп җитә алар. Һәркайсының авызында да гел бер үк җыр:

— Печән чабуны июльнең унына да калдырмыйча төгәлләргә кирәк. Аннары, мөгаен, арышка керешербез. Райкум шулай куша. Күрсәтелгән срокларга сыешмасак, райкумның моны корткычлык йә саботаж дип кабул итүе бар. Каталажкка йә төрмәләрне күрергә язмасын, срокларга сыешыйк, җәмәгать. Даваегыз, давай...

Бүген исә бригадир Сөләйман белән Әмир әллә нигә кичәге графикларыннан иртәрәк килеп җиттеләр. Яландагы ирләр печән чабуларын ташлап әле генә күләгәгә кергән, хәлсезлек белән эсселектән телләрен салындырып утыралар иде. Тере килеш кешеләрне ашаучы кыргыйларны күргән диярсең, Әмир әле Гәрдән айгырының сыртыннан да төшеп тормыйча, эт шикелле ырлап, боларга ябырылды.

— Аулак өйгә утырмага килгән кияү егетләреме әллә? Кылны кырыкка ярырдай кызу эш өстендә нишләп әле ике кулны кушырып утырасыз? Төрмә әллә кайда, җәһәннәмдә түгел, Буздәктә дә бар. Шунда ябып череткәнне көтәсезме әллә?

— Әх, ананны сатыйм! — дип, иң әүвәл, Озын Закир урыныннан сикереп кузгалды да күз ачып йомган арада Әмирне ияреннән сөйрәп төшерде. Икенче мизгелдә инде хатынын үгез сөзеп үтергән Харис, Хәбинең энекәше Кара тавык Гайсә, Рөстәмбәктә ялчы булып йөргән Госсам, тагын әллә кемнәр Әмирне үләне кырып алынган җир өстенә сузып салган иде. Күмәк бунтны күргәч, Озын Закирга гайрәт иңде бугай, ул Әмирнең бугазына чалгы китереп салды. Тавышы да кыргый, зәһәр иде.

— Безне төрмәдә черетмәкче булдыңмы, персидәтел? Айһай, ашыкмый тор. Без хәзер синең үзеңне суябыз да менә шушы күлгә салып черетәбез! Или син, ананны еккыры, колхоз фермасыннан бер сарык китереп суйдырасың да бер капчык оннан пешереп икмәк ашатасың. Сиңа бушка эшләп җыгыбыз чыкты инде, җитәр! Гәрдән кулаклар да, Рөстәмбәкләр дә бер эшләрен дә бушка гына эшләтмиләр иде. Ә хәзер менә синең калхузың да, ул кадалып киткере Сәвит власте да безнең ише кара халыкны бушка гына эшләтеп үтермәкче.

— Совет властена тимә! — дип кычкырды, гыжлап, җирдә яткан Әмир.— Миңа эшләмисең син. Үз колхозың, үз авылың өчен эшлисең. Ә инде алай бер сарык белән икмәк китертүгә генә кайтып кала икән, ярар, давай, җибәр.

Ирләр аның бугазыннан, беләкләреннән кулларын алуга ук, Әмир җир өстенә торып утырды да, карашын бригадир Сөләйманга төбәп, катгый итеп әйтте.

— Әхтәм хәзрәт чоланындагы ларда ике пот чамасы тары калган иде, язгы чәчүнеке. Шуны Әсма апа белән Хәдичә җиңгиләргә биреп кул тегермәнендә тарттыр. Аннары шундук икмәк пешерсеннәр. Ә фермада бүген Шадра Гата каравылда тора. Бер сарыкны сайлап алыгыз да шуның белән икегез эш итегез. Ике пот тары белән бер сарык баш бәясе түгел. Ичмаса, давай, бер мәртәбә булса да, егетләрне сыйлыйк.

Әмир әлеге сүзләрне, канатланган шикелле, очына-очына тезде. Ләкин Әмир күрәзәче түгел, басудагы арыштан уып алынган бер уч икмәкнең дә бу илдә иртәгә баш бәясе тора башлаячагын ул, әлбәттә, белми иде әле.

## 7

Август уртасы җиткәндәрәк авылдагы һәр йортны тәмуг утыдай кайнар хәбәр айкап чыкты.

— Үткән атнада Сталин-падишаһ калхуз малын урлаучыларга каршы закун чыгарган, ди. Басудан биш башак өзеп тотылсаң да, ун елга өтермәгә илтеп тыгалар, бәрән-сарык имше мал-туарга кул сузасы булсаң, стенага терәп атачаклар икән…

Үз бармагын пешереп карамыйча утның кайнарлыгын беркем белми. Төркәйлеләр өчен дә югарыдан килеп ишетелгән хәбәр — ул Каф тавы артындагы билгесез бер гарасат-давыл гына, аның җиле беркайчан да аларга килеп җитмәс, алар авылын урап кына үтәр кебек иде. Ләкин ике-өч көннән соң ук инде гарасатның кайнар сулышы күрше-тирә авыллардан да ишетелә башлады.

— Күзәй авылында өчме-дүртме хатынны калхуз басуыннан бер кесә башак кыркып кайтканда юлда тотканнар, ди. Персидәтелләре Тимергали дигән явыз, тегеләрне калхуз кәнсәсенә алып кереп, ыштан төпләренә хәтле кармый-кармый, үзе тентегән. Хатыннарның берсенең ире бөтенләй юк, икенчесенеке гарип булган икән. Бичараларның барысын да Бәләбәй өтермәсенә илтеп бикләгәннәр. Һәрбер өй эчендә өчәр-дүртәр сабый утырып калган…

Менә берәр атнадан каһәр суккыры ул гарасат Төркәй авылына да килеп җитте. Бригадир Дәү Сөләйман белән Чапай Сабиты ындыр табагыннан чыгып килгән чакта, «искитмәле корткыч»ны кулга эләктергәннәр. Кемне, диген әле, гомере буе Чәрмәсәннән тоткан балык белән генә җан асра-

ган, туксан яшьне узган Сәетгәрәй картны. Ике кәлүш эче белән ике кесәсенә тутырылган өч кадак тары өчен.

Рәис Әмир үзе ул көнне, колхоз өчен нәселле тәкәләр алырга дип, Чакмагыш ягына чыгып киткән иде. Кояш баеган чакта кайтып керсә, Әхтәм хәзрәт йорты каршында Сабантуйга җыелган кадәр халык. Кәнсә баскычында билләренә алтатар таккан ике милиционер йөренә. Карчыклар, хатыннар яулык очлары белән генә күз төпләрен сөртеп мышкылдыйлар. Ир-атлар, мәет озатырга җыелган кешеләр шикелле, бөтенләй тын тора.

Авылга ниндидер олы хәвеф килүен ерактан ук сизеп алды Әмир. Халык төркемен ерып кәнсәгә үткән чакта, авылдашларына бер авыз сүз катмады, эчкә узгач инде гаҗәпләнүдән тынсыз калып торды.

Бүлмәдәге рәис өстәле артына Бүздәкнең үзеннән үк килеп җиткән Янгуразов менеп кунаклаган. Бүлмә уртасындагы ялгыз утыргычта ап-ак чәчле, чал сакаллы Сәетгәрәй карт дер-дер килеп утыра.

— Колхоз малын урлап Совет властена корткычлык итүеңне таныйсыңмы, картлач?

— Хәтер алышынган инде хәзер, олан, хәтер алышынган…

Туксан яшьлек картны берникадәр вакыт шулай сыгымлагач, ниһаять, Янгуразов Әмир ягына таба төбәлеп басты.

— Йә, нишләтәбез инде бу картлачны, иптәш персидәтел? Ул «мин икмәкне махсус урладым» дими, попугай шикелле, «икмәкнең тәмен оныттым, күптән ашаган юк бит» дип тәкрарлый да тора. Тегендә алып китеп яңадан допрослыйбызмы моны? Әллә «мондый тәртипне мин үзем урнаштырдым» дип, син бу картны йолып каласыңмы? Картны йолсаң, сине алып китәбез. Йә, җавап бир.

Угрылык өстендә үзе тотылган кеше шикелле, Әмир коелып төште.

— Нишләп мин андый тәртип урнаштырыйм ди инде, иптәш Янгуразов? Колхоз малын урлауга юл куеп торырга минем башыма тай типкәнме әллә? Нишләп инде аның ише тәртип урнаштырыйм?

— Димәк, син каршы түгел, картны алып китәбез?

Әмир, әле ярга чыгарылган балык шикелле ашыга-ашыга авыз ачкалады, әле суга баткан бичара кыяфәтендә ниндидер тотынып, котылыр әйбер эзләгәндәй, бүлмә эченә кереп тезелгән авылдашларына күз йөгертеп чыкты.

— Син милиция нәчәлниге бит инде, иптәш Янгуразов. Син законны күбрәк беләсеңдер.

— Ярар, син ризалык бирдең, картны алып китәбез. Давай, кузгал, картлач…

Сәеттәрәй карт бөгәрләнеп утырган олау кузгалганда, мәйданга җыелган хатын-кызлар тоташ елауга күчкән иде инде. Мәйданнан таралган чакта, ирләрнең берсе дә Әмир йөзенә караш ташламады, әмма һәркайсы, аның ягына карап, кат-кат төкеренә-төкеренә китеп барды.

## ТУГЫЗЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

### 1

Сентябрьгә кергәч, Әмир авыл өчен өчме-дүртме генә изгелек эшләргә өлгереп калды. Колхозга, Бәләбәйнең үзенә тикле барып, атларга җигеп йөри торган ике төрле чапкыч кайтардылар. Ләкин хәзер инде көзге яңгырлар әрсез хатын шикелле колач җәя бара, мондый чапкычларның көчкуәтен киләсе җәйдә генә сынап булачак иде.

Аннары Әмир шыр хәерче, ятим Шәйсолтанны Ленинград каласына укырга җибәрде. Җәһәннәм аръягындагы иске башкалага колхоз юлламасы буенча махсус кеше җибәреп укыту бигрәкләр дә сәер адым иде, бары да шаккаттылар.

— Чукып — карга, укып кына мулла булырлык булса, бөтен кеше дә шулай итәр иде. Ул галах Шәйсолтанны калхуз акчасын түгеп нигә җибәрә дә, ул томананы Лелингыратта укытып кем итмәкче була?

Әмир:

— Паровозлар буенча инженер итәбез аны,— дигәч, янә бот чаптылар.

— Бәрәч, бәрәч, андый инчилер безнең калхузга нигә кирәк инде? Аллага мең шөкер, безнең якта ул пыравуз дигән гыйфритләр юк бит әле.

— Булмаса, булыр,— диде Әмир, сүзләрен кырт кискәндәй.— Яңа машиналар заманында яшибез. Бүген юк икән, иртәгә паровозлары да, ил тотынса, әле пароходлары да килеп җитәр. Казанны йортка кунаклар килеп кергәч кенә асмыйлар ул. Юньле хуҗаның йортында һәрвакыт аш була.

Әмиргә аш темасын кузгатырга һич ярамый иде. Кырлардан җыеп алынган ашлык көлтәләре амбарларга кайтарылып әвеннәр астына куелса да, район үзәгеннән әмер-фәлән юк, шуңа күрә ашлык суктыра торган машиналарны әле һаман кушып караучы юк иде.

— Синең әле августта суктырылган ашлыгың да җитәрлек. Көзге чәчүдән калган орлыгың да байтак. Давай, шуларны Бүздәк элеваторына китерттерә башла,— дип, күрсәтмә бирүчеләр табылды табылуын.

Ләкин Әмир сөзгәк сыер сыман каты торды.

— Мин халыкка көзен бер хезмәт көненә кило ярым икмәк бүлеп бирергә вәгъдә иткән кеше. Алдаганым өчен мине халык тотып суйсынмыни? Юк, картлар әйтмешли, Гәрдән байлар да батракларын алдап эшләтмәгән. Ә мин — халык үз теләге белән оештырган колхоз рәисе. Кешеләрне бушка эшләтә алмыйм.

Ә халык, чыннан да, ачлыктан әле шешенә-шешенә, әле коргаксып-кипшенеп соңгы чиккә килеп терәлгән иде инде. Күпчелек йортлардагы бала-чага белән карт-корылар өй эченнән ихатага да чыга алмый ята. Урамнарда адәм баласы түгел, эт тә калмады бит.

Менә шул ач балалар турында кайгыртып, Әмир Уфаның үзенә тикле барып җитте. Анда бөтен өмете Шаһи-Морат комиссарда иде. Аны сорап Республика башкарма комитетына барып кергәч, бавырын суырып алган шикелле өнсез калдырдылар:

— Кулга алдылар синең комиссарны. Солтангалиевчеләр белән бергә эш йөрткән ул. Татар, башкорт, ногай, әзәриләрне берләштереп, аерым дәүләт төземәкче булган. Халык дошманы ул. Төрмәдә чери синең комиссарың. Үзеңнең дә буяласың килмәсә, аны эзләп йөрмә...

Мондый утлы хәбәрдән соң башына авыр күсәк белән суккандай миңгерәсә дә, үзенең төп гозерен онытмыйча, Әмир мәгариф министры янына барып җитте.

— Мәктәпләр ябылып бетте. Балалар урыннарыннан да куба алмыйча ачка кыркылып ята. Ичмаса, мәктәпләрдә көненә бер мәртәбә генә булса да хөкүмәт хисабына ашау кертегез сез. Ашату турында хәбәр булуга ук, бөтен мәктәпләр дә өр-яңадан эшли башлаячак.

Әллә Әмир шулай эчкерсез ялварганга йомшады бу министр, әллә башка сәбәп, әмма ул кунакның кулын кат-кат кыса-кыса, ишек төбенә хәтле үзе озатып куйды.

— Барысы да сез әйткәнчә булыр, тик башка оешмалар ишегеннән үтеп, бу турыда кычкырып йөрмәгез инде берүк, җаныкаем...

Әмир әле Шаһи-Морат турындагы кайгы-хәсрәттән дә айнымаган, бу Уфа каласы аның өчен хәвеф-хәтәрнең еланнарныкыдай иң зәһәр оясы булып күренә башлаган иде. Нинди башка оешмаларга кереп йөрү ди ул! Әмир башкаладан, артына ут капкан шикелле, бик тиз чыгып качты.

Министр кеше алдамаган икән. Әмир кайтканнан соң төп-төгәл бер атна үтүгә, Төркәйнең үзендә дә, Күчәрбай мәктәбендә дә балаларны бер мәртәбә бушлай ашатуны башлап җибәрделәр. Ашау хакына балаларның мәктәпкә килү-килмәвен тикшерү бик тә кызык тамаша тоелгандыр инде, Кү-

чәрбайга райком секретаре Әсәнбаев белән милиция башлыгы Янгуразов үзе килеп җиткән. Әмир аяксыз калган Зифаны Афонька арбасына салып илтә килгән иде. Моны күреп-белеп торганнардыр инде, Әмирне дә Сәмигулла карт йортыннан мәктәпкә чакырттылар. Әмир ялгышмаган: мәктәп ихатасы ач-ялангач бала-чага белән шыгрым тулы иде. Директор Галимҗан Усманов аны күкрәгенә алып кат-кат кысты. Райком секретаре Әсәнбаев кына койрыгына күсәк төшкән елан шикелле усал ысылдады.

— Һин нимә тип Өфөгә тикле йетеп бедде сагаһың, кустым? Әллә турылан-туры йетәксеңдең кайда ултырганын гүпсе оныттыңмы? Иһеңә төсерербед!.. Колхоз келәтләрендәге аслыкты ла районга килтерергә асыкмыйһың икән. Аны ла искәрербед!..

Әмиргә Күчәрбайдан әнә шулай сөенеч-шатлык хисләрен татымыйча гына кайтып китәргә туры килде.

## 2

Әмирне октябрь башында, караңгы төн уртасында килеп кулга алдылар. «Бүген-иртәгә ашлык суктыра башлыйбыз. Аллага шөкер, озакламый халыкның ирене дә икмәккә тиенә бит»,— дип, көне буе йөгереп йөрүдән соң эт шикелле арып кайткан иде. Күн курткалы ниндидер чит-ят бер ир төрткәләп уятканга күзләрен ачса да, байтак вакыт аңлый алмый ятты. Нинди кеше соң бу? Нигә наган тоткан? Ул ничек итеп Әмирләрнең йортына үтеп кергән әле? Төшме соң бу, өнме?

— Бай хатыны сымак иркәләнеп ятма. Син кулга алынасың. Сикереп тор да киен!

Баш очында шундый әмер яңгырагач кына, Әмирнең зиһене ачылгандай булды. Гөлтуташ, өлкәннәре Зифа белән Тимерҗанны күкрәгенә кочкан килеш, мич янында еламсырап тора. Ишек төбенә тагын алтатарлы ике адәм кереп баскан. Берсенең дә йөзендә миһербан, нур юк. Газраилләр шундый була икән.

— Нигә кулга алынам, нидә гаепләнәм? Анысын әйтәсезме?

Әмир, күлмәк-чалбарларын кия-кия, шул рәвештә авыз ачкан иде дә, алтатарын кулына тотып аның янында торган «башлык» телен тиз тешләтте.

— Сораулар бирү, сөйләшү запрещено! Юлга өйдән ризык-мазар алу запрещено! Качарга ымсынсаң, кисәтмичә атам!

Әмир киенеп беткәч, «башлык» аны, читлеккә япкан шикелле, ишек төбендәге бер почмакка кысрыклап утыртты да, алтатарлы кулын селки-селки, ике юлдашына әмер бирде.

— Тентүне башлагыз. Берегез монда кала, икенчегез — чоланга.

Уникеле лампаларның берсен күтәреп тышка чыгып киткәне биш-алты минуттан соң ук кире әйләнеп керде.

— Боларның чоланында арыш-бодай түгел, тычкан-күсе дә юк бит. Келәт-сарайларын айкап чыккан идем, алар да тап-такыр.

— Яшереп өлгергәндер инде бу заразы. Ярар, давай Гөргөригә булыш. Мужыт, кәгазьләре арасыннан берәр ни табарбыз,— дип, җәһәт кенә ризалашты «башлык», әмма күренеп тора, кәефе бер дә шәптән түгел иде.

Әмир белән Гөлтуташның еллар буе җыеп барган кәгазьләре, хатлары, гәзит кисәкләре, китаплары — бөтенесе тиң иске нигездә, хәзер Шәйсолтанның ятим эне-сеңелләре яшәп яткан йортта калган иде. Гәрдән кулак йортына күчкәннән соң җыйган «байлыклары» егерме-утызлап гәзит мәкаләсе белән ун-унбишләп китаптан артмагандыр. Икәүләп тотынгач, алтатарлы ирләр аны бик тиз ерып чыкты. Гөргөри сайлап кулына тотканы да ике-өч юка китаптан артык түгел иде. Башлык бәндәнең канәгатьсезлектән үртәлә башлавы инде йөзенә бәреп чыкты.

— Ярар, пыртакул төзегез дә аннары, давай, кәнсәләргә киттек. Анда Кәрим белән Сабир да моның әшнәләренең эшен бетергәндер инде, алардан аерылып, юлда ялгыз калмыйк. Сикәязда әнә бер милиционерны юлда сагалап торып чәнчегәннәр, диләр...

Ирләр дөбер-шатыр килеп җыена башладылар. Гөлтуташ белән Зифа, үкереп елый-елый, Әмиргә килеп сарылды. Бер Тимерҗан гына урыныннан да кымшанып карамады. Әмир хатыны белән кызын кочакласа да, Тимерҗаннан күз алалмый торды. Каян килгән аның тугыз яшьлек малаена мондый гадәт-холык?

Ул әнә, аякларын киң аерып, басудагы ялгыз имән сыман горур басып тора. Йөзендә бернинди хәвеф-шөбһә юк, куллары йодрыклы. Өтеп алырдай усал карашы белән әле «башлык»ка, әле алтатарлы ирләргә күз йөгертеп ала. Юк, бу бала дошманнары, көндәшләре алдында тезләнәчәк, кимсенәчәк түгел!

— Алып чыгып китегез! — дип боерды «башлык».

— Әмирҗан, җаныкаем! — дип, Гөлтуташ иренең муенына асылынды. Аңа чәрелдәп елаган Зифа тавышы кушылды.

— Әти, әтекәем!

— Алып чыгып китегез, дидем бит мин сезгә! — дип кычкырган «башлык»ның тавышы янә колакларны сытып яңгырады.

Әмир Гөлтуташ белән Зифаның кулларын көч-хәл белән генә үзеннән аерып алды.

— Минем бернинди гаебем дә юк. Тыныч яшәгез, мин кайтырмын! — дип кычкырды ул, баш түбәсен ишек ниргәсенә бәрә-бәрә чыгып барган чакта.

Кем белә бит әле...

Җиһан бик караңгы, юл күренми иде.

## 3

Суд Бүздәктә булды. Анда нинди статьялар буенча хөкемгә тартылачагын Әмир анык кына белми иде әле.

Тикшерү барышында Янгуразов белән Карачурин дигән бәндәләр, әллә нинди сораулар бирә-бирә, үзәгенә үтеп беттеләр.

— Шаһи-Морат комиссар белән бер үк сәяси платформада торасыңмы да Шаһи-Морат сиңа нинди шәхси заданиеләр бирде? Уфага баргач мәгариф министрыннан тыш тагын кайсы оешмаларга кердең дә Бүздәк авылларындагы ачлык-ялангачлык турында кемнәр каршында гайбәт сатып йөрдең? Күчәрбайдагы Усманов Галимҗан белән кайчан таныштыгыз?..

Уйлый-уйлый Әмирнең башы катты. Ярар, Уфага бару турында төпченүләрнең үз җаннары, үз кәнәфиләре хакына алып барылганын Әмир әле барыбер дә сиземли-төшенә иде. Ләкин нигә Шаһи-Морат комиссар турында сораштырып аңа бәйләнәләр? Нинди сәяси платформалар бергәлеге дә, нинди шәхси заданиеләр соң ул? Усманов Галимҗанның Әмир җинаятенә нинди катнашы бар? Өстәвенә тентү вакытында Гәрдән бай йортында табылган ике гарәп китабы белән һаман-һаман күзләренә төртеп, Әмирне тагын нинди җинаятьтә гаепләмәкче булалар? Гарәпчә хәрефләр белән басылган ике китап икән, ике китап инде. Гәрдән кулактан калган йортның һәрбер киштәсенә менеп йөргәнме дә, аның өеннән табылган һәрбер китапны да шәхсән күргәнме ул? Коммунист Әмир яшәгән йортта яткан икән, яткан. Коммунист Әмир аларны үзенең мендәр астына салып йокламаган әле. Белмәгәннең беләге авыртмый. Күргән юк, белгән юк. Шаһи-Моратны да күрмәдем, «платформа»ның да фәкать тимер юлда урнашканнарын гына беләм. Миннән таләп юка, белемем дүрт сыйныф...

Әнә шул рәвешчә бөтенесен инкарь итеп торгач, Янгуразов белән Карачурин да кул селтәде бугай. Ниһаять, җинаятьне бер статьяга гына кайтарып калдырдылар: дәүләт малын урлау һәм корткычлык. Бөек Сталин кул куйган җиденче август карары нигезендә ким дигәндә ун ел.

Менә шушы җинаять буенча гаепли башлагач кына, ниһаять, тикшерүче бүлмәсендә Әмирне бригадир Дәү Сөләйман белән йөзгә-йөз очраштырган булдылар. Кирәкми дә иде. Гаепләрен һичкем танымады бит.

— Әйе, ачлыктан өзлегеп беткән колхозчылар муенга чалгы китереп терәгәч, әмерне мин бирдем. Бригадир Сәлимҗанов фермадагы бер баш сарыкны минем әмер буенча пешерттерде,— дип, Әмир бар гаепне фәкать үз өстенә генә алмакчы булган иде дә бит, Сөләйман чәчрәп чыкты.

— Мин чит кеше «айт» иткәнгә «тайт» итеп йөри торган бала-чага түгел. Авылдашларымның ничек ачка интеккәнен барып күргәннән соң, мин персидәтел Нәгыймов түгел, хәтта туган атам юлыма аркылы ятса да, барыбер ул сарыкны суеп бирә идем...

Судта гына, ниһаять, шикаять язучыларның исемен атадылар. Чит-ят кешеләр пычратмаган икән: «нахакка рәнҗетелгән» Хәби-Хәйберахман белән аның бертуган энекәше Кара тавык Гайсә. Моны белү берни үзгәртмәде. Әмир белән Сөләйман икесе тиң «гаеп бездә» дип тәкрарлап тордылар. Хөкем карары үзләре көткәннән артык яңгырамады:

— Бригадир Сөләйман Сәлимҗановка — биш, төп гаепләнүче Әмирҗан Нәгыймовка ун ел...

Сак астында Бәләбәй төрмәсенә алып китәр вакыт җиткәч кенә, нindидер җай табып, Әмир янына тикшерүче Карачурин керде. Тоткынның күзенә туры карарга кыймый иде, ахры, башын түбән игән хәлдә ашык-пошык тезде.

— Әсәнбаев белән Янгуразов сине сәясәткә бәйләп пычратмакчы иде. Һәммәсен дә дөрес итеп кире кага белдең, ул яктан молодец син, Әмирҗан абый. Ә менә бу — сарык суйдырту, тары пешертү мәсьәләсендә бөтенләй ачык авыз. Шул вакытта акт төзеп, ике-өч колхозчыңнан кул куйдырткан булсаң, сиңа бүген пычак та буласы юк иде. Әле дә соң түгел. Өйдәгеләреңә ничек тә хәбәр сал да авылдашларыңнан акт төзеттер. Ә аннары Башглавсудка бирерсең. Куркып торма, хакыйкать синең якта...

Әмирнең бу Карачурин йөзенә төкерәсе килде. Ләкин нинди файда? Карачурин кол бит...

Бәләбәйгә алып барган чакта, юлда Салаяз дигән авылның мәктәп директоры белән таныштылар. Ул Күчәрбайдагы Галимҗан Усмановны да белә торган кеше булып чыкты. Ни өчен тоткынлыкка эләгүе турында сораштыра башлагач, Әмирнең куенына кереп китәрдәй булып, нык иелеп, колагына гына пышылдады.

— Бу Сталинны бик нык бутыйлар, ахрысы. Юкса бу энкеведенекеләр үләксәгә мәңге туя белмәс чүл бүресе сыман котырмаслар иде... Хәер, Сталинның үзенә дә бик зур

ышаныч юк. Заманында революциянең төп тоткасы булган ничаклы кешенең башын ашады, канын эчте инде, ә барыбер властька туя алмый. Миңа калса, ул әле берзаманны тирә-юнендәге яраннарын урман сыман кырып бетерер дә басу уртасындагы имән кыяфәтендә япа-ялгыз торып калыр кебек. Имеш, күрәсезме аны, бер ул гына бөек... Менә шушы чистарту-кыруларны ул иң әүвәл татарлар өстендә сынап карый сыман. Тәҗрибә үткәрә ягъни. Шунысы гаҗәп, татарларны сайлап ялгышмаган. Рәсәйдә тагын бездән дә таркаурак, бездән дә күндәмрәк халык бармыни ул?!

Салаяз директоры йөрәгенең ачынуына чыдамады, ахры, тамак төбендәге төерләрне голт-голт йотып, берникадәр вакыт гыж-гыж сулап барды.

— Мин әле бер ел элек кенә Казанның үзендә эшләп йөри идем бит, Мәгариф министрлыгында. Бервакытны карыйм, мин көн саен аралашып йөргән әллә ничаклы татар җитәкчеләрен җыеп ала башладылар. Сасысы тиз чыкты. Имеш, болар һәммәсе дә солтангалиевчеләр икән дә, болар мөселманнар өчен аерым дәүләт төземәкче икән. Шуннан игътибар итәм, бу Сталинның кулы бик озын бит. Кырымда ЦИК рәисе булып утырган Ибраһимов Вәлине җыеп алды бу, чечен белән ингушларда комитет башлыклары булып йөргән Абдулла Чолак белән Мостафаны җыйды. Имеш, алар Төркиягә качкан Әхмәтзәки Вәлидиләр белән яшерен бәйләнештә торганнар да Совет властена каршы фетнә әзерләп ятканнар... Нишләптер бөтен этлеге гел мөселманга каршы юнәлтелгән моның...

Салаяз директоры, тирә-ягына ялт-йолт карап алгач, тагын да иелә төшеп янә дәвам итте.

— Берзаманны безнең Казанда да күз уңында торган бөтен укымышлы татарларны туздыра башладылар. Уйлап тапкан гаепләре шул ук, янәсе, алар һәммәсе дә Солтангалиев җырын җырлаучылар инде. Казанның үзендә генә дә утыздан артык кешене җыеп алды болар. Татарның каймагы булган бик күп укымышлы кеше, «мине кайчан килеп кулга алалар инде, кайчан алып китәләр» дип, төн йокысын югалтып яши башлады. Шушындый хәлгә чыдамагач, Газиз Гобәйдуллин Бакуга чыгып качты. Син аны белмисеңдер инде, ул тарихчы. «Син дә солтангалиевчеме?» дип, аның тирәсендә иснәнеп йөри башлагач, Һади Атласи Бөгелмәне ташлап чыгып китте. Ул да тарихчы. Аннары бервакытны сизәм, минем тирәдә дә бөтерелә болар. Мин дә качтым. Ләкин менә барыбер эләктерделәр. Аларның кул озын. Алар татарның әллә ничаклы асыл егетләрен юк итәчәк әле...

Тоткын директор, беркадәр тын алганнан соң гына, сүзен йомгаклап куйды.

— Шаһи-Морат белән бәйләнештә торуыңны танымыйча дөрес эшләгәнсең. Юкса сине дә, халык дошманы дип, политически статья буенча яндырырлар иде... Сталин канечкечнең ерткычлыгы инде бу, тик шуныкы гына. Безгә кире кайтулар насыйп булмас инде...

## 4

Октябрь урталарында ук «Кызыл байрак» колхозына яңа рәис китереп утырттылар. Ул бу як кешесе түгел, әллә кайдагы Баймак районыннан китерелгән чит-ят бәндә иде. «Белеме — ташка үлчим, мәгәр Бүздәктәге Әсәнбайга туган тиеш бугай»,— дигән хәбәр үзенә ияреп килде.

Фамилиясе Сөлтекбаев икән. Карап торышка метр ярымнан чак калкурак буйлы, җәенке, табак йөзле, чепи күзле, иске арба күчәре сыман гел мыгырданып-чәйнәнеп йөри торган бик тә алама бәндә булып чыкты. Кушаматны үзенә тиз тактылар. Өтекбай, килмешәк Өтекбаев һәм вәссәлам!

Эшкә каты тотынды бу. Бригадирлар, хисапчылар, ферма һәм ындыр табагы мөдирләрен җыеп үткәргән беренче «киңәшмә»сендә үк дәүләткә икмәк тапшыру мәсьәләсен кабыргасы белән китереп куйды.

— Калаларда эшчеләр яңа завутларны индустрлаштыру дип көчәнәләр анда. Сезгә яңа трактор молотилкаларын кайтарып бирергә дип. Ә сез монда келәтләрне тутырып икмәк черетәсез. Дәүләткә икмәк тапшыру планы бер генә прасинга да үтәлмәгән. Хәзер авылдагы бар көчне дәүләт табынына ашлык чыгаруга! Соңгы килога тикле, бөртегенә тикле!

Шул чагында хәтта кысу-көчләү белән крестьяннарның үзәгенә үткән упалнамуч Чапай Сабиты да урыныннан капылт сикереп торды.

— Ни сөйлисең, иптәш прсидәтел? Нинди икмәк черү? Келәтләргә әле киләсе язга җитәрлек тә орлык салынмаган. Фураж әзер түгел. Ә инде ул колхозчыларга бүлеп бирелергә тиешле икмәк турында әйтеп тору да юк. Әгәр элеваторларга ашлык чыгару хакында авыз ачсак, Төркәй халкы безне сәнәк белән кадап үтерәчәк. Бөтен авыл буйлап җыйнасаң да, Төркәй хәзер бер капчык он тарттырырлык та икмәк җыялмый бит. Бүген авыл анадан тума, шыр ялангач калган мескен сыман утыра. Кешеләр ач. Алар алабута белән бәрәңге боламыгы пешереп кенә җан асрыйлар.

— Кулак коткысы бу, кулак җырчысы син! — дип, яңа рәис, урындыгына тезләнеп баскан көенчә күтәрелеп, өстәл өстен төйде. — Синең кебекләргә упалнамуч түгел, төрмәләрдә урын. Әгәренки иртәгә үк сине алдырмасам, фамилиям Сөлтекбаев түгел!..

Чынында да, ике көн үтүгә, Чапай Сабитын район үзәгеннән килеп «җыйнадылар». Кая китте егет, кая озаттылар? Күрүче, белүче юк. Аннары Чапай Сабиты бу якта килмешәк, өстәвенә крестьяннарны кысып йөргән бәндә, шуңа күрә Төркәйдә аның өчен җан атучы кеше табылмады.

Төркәйгә ике яңа упалнамуч килде. Берсе — Ырымбур ягындагы Кызылтау дигән керәшен авылыннан, икенчесе — ни өчендер Днепр буеннан Уфага күчереп китертелгән хохол. Икесе дә гәүдәгә шәп, албастылар сыман. Келәтләрдәге ашлыкны да иң беренче олауга шулар үзләре төяде. Төркәй ирләре, мәет озаткандагы сыман кара көеп, сүзсез тора иде. Рәис Сөлтекбаев нотык укый-укый рәхәтләнде генә.

— Чит илләрдән машиналар алып кайту өчен безгә икмәк кирәк. Юлбашчыбыз Ысталин безгә шулай куша. Ул сызып күрсәткән юлдан тайпыламын икән, фамилиям Сөлтекбаев түгел! Мин сезнең келәтләрдәге икмәкнең бөртегенә тикле элеваторларга чыгарып бирәчәкмен. Авызымнан кан китсә китә, әмма ләкин барыбер бирәчәкмен! Әгәренки шулай эшләмәсәм, фамилиям Сөлтекбаев түгел!..

Бер атна үтүгә, чыннан да, келәтләрдә бер бөртек тә ашлык калмады. «Шәрә калдык, инде тыгынганнардыр», — дип, Төркәй халкы, сугымга бәйләп ташланган мал шикелле ризалашып, дөньясына төкерә башлаган иде дә, ай-һай ашыкканнар.

— Район үзәгеннән яңа задание биреп кайтардылар. Әвеннәргә куелган көлтәләрне сугарга керешәбез, — дип тезде Сөлтекбаев, Төркәйнең барча ирләрен һәм хатыннарын ындыр табагына җыйнап. — Кемнәр молотилка артына баса, кемнәр чабагач белән. Көн саен кич бөртегенә тикле үлчәп тапшырасыз. Урлауга юл куймыйм. Кем ашлыкны әрәмшәрәм итә, аңа җиденче август карары буенча элекке карак прсидәтелегез Нәгыймов Әмир юлы. Әгәренки шуны үтәмәсәм, фамилиям Сөлтекбаев түгел!..

Гөлтуташ та, билгеле, барча хатын-кызлар шикелле үк, ындыр табагына чакыртылган иде. Сөлтекбаевның кадау сүзләренә эчтән сыза-сыза, чак-чак кына түзде. Төркәйлеләр Әмирне һич кызганмый, ул моны белә иде. Шуңа күрә чабагач белән көлтә кыйнаса да, молотилка авызына көлтә ташлап торырга куйсалар да, ал-ял белмәде, кәҗә маен чыгарып эшләде ул. Хатын-кызларның бик күбесе чая, юк сәбәпне дә бар итеп ялга тукталалар. Артлары ашлыкка тидеме, «сагыз ясыйк әле» дигән булып, ике-өч учлап икмәкне авызга озаталар. Гөлтуташ һәммәсен дә күреп-шәйләп тора. Кичләрен күкрәк каплавычларына, итәк бөрмәсенә дүрт-биш уч ашлык тутырып китүчеләр дә бар араларында. Бер Гөлтуташ кына мондый адымга һич бара алмый. Чөнки ул «тамгалы»,

төркәйлеләргә аны Әмир артыннан озату берни тормый. «Колхоз үзенең ярдәменнән ташламас бит инде, хезмәт көннәренә икмәк бирер әле» дип, көтеп-ышанып йөргән иде дә, тагын алданды шул.

— Башкаладан яңа заданиеләр җиткергәннәр анда,— дип котырып кайтты беркөнне Сөлтекбаев район үзәгеннән.— Кем шуларны үтәми, андыйлар «кара такта»га эләгүче авыллардан, йорт буенча йөреп, соңгы бөртек икмәкне дә җыеп чыгачаклар. Пазурга юл куймыйм! «Кара такта»га эләктерәләр икән, фамилиям Сөлтекбаев түгел!..

Суктырылган ашлыкны бөртегенә тикле Бүздәк элеваторына озатып барды, әмма «кара такта»дан котылмады шул бу килмешәк Өтекбаев. «Дәүләт планына аяк чала, саботажник» дип, әүвәл аның райком башында утырган туганы Әсәнбаевны Бәләбәйдәге төрмәгә аткарганнар, аннары Сөлтекбаевның үзенә «яңа задание» дигән камыт кидергәннәр.

— Атнасына төп-төгәл мең пот икмәк! Шуны китереп тапшырмыйсың икән, Төркәйдәге һәрбер йорт буенча йөреп, булган бөтен онны-бәрәңгене җыеп чыгачаксың. Аларын тапмасаң, сыер-сарыкларын, каз-үрдәген җыеп китерәсең. Или сиңа төрмә!..

Бер кичтә урам капкасыннан ихатага килеп кергән яңа упалнамучлар белән Хәбине күрүгә үк, Гөлтуташ киселгән агач төбе сыман хәрәкәтсез калды.

— Икмәгең, бәрәңгең кайда? — дип җикеренеп сорады аннан Ырымбур керәшене.

— Булганын ашап бетердек бит инде, каян килсен безгә, ятимнәргә?

Гөлтуташның көч-хәл белән генә телен әйләндереп әйткән җавабыннан соң, керәшен упалнамуч, әрем капкан сыман, йөзен сыткан иде. Шул чагында ир тавышы ишетүдән ни дә булса өмет итте бугай, лапас эчендә мескен тавыш белән сыер аваз салды. Э-эх, дәшми генә торган булса иде, малкай! Шуның тавышын ишетте дә, бәйдән ычкынган усал эт шикелле, лапас капкасына таба ыргылды бит Ырымбур керәшене.

— Э-һей, әҗәтханә! Икмәгең, бәрәңгең юк икән, аяклы мал да ярап тора безгә. Һаман-һаман «кара такта»да торып, синең ирең артыннан өтермәгә китәр хәл юк. Сөт эчмичә дә кадалмассыз әле!..

Йоны ачлыктан яртылаш коелып беткән, оча сөякләре төртүдән тиресе ярыла башлаган арык, хәлсез сыер, муенына аркан ташлауга ук, карышмый-мөгрәмичә шундук ияреп чыкты. Ул үзен сутымга алып китүләренә сөенә дә сыман иде әле, артына да борылып карамады. Гөлтуташ, дөнья җимерелә, тарала барганга күнегеп беткән кебек, талап алып кител-

гән сыерны да карачкы шикелле сүзсез-хәрәкәтсез генә озатып калды.

Иң элгәре, аларның ихатасыннан Пальма юкка чыкты. Мөгаен дә, атна-ун көн чамасы элегрәктер. Ул үз янына якын җибәрү түгел, чит-ят кешене хәтта ихатага да кертми торган иде. Авылдагы бердәнбер кешегә генә өрми кала иде: ул да булса — Ләпәй. Хәзер йортларда ачлыктан кибеп йә шешенеп ятучы карт-карчыклар, бала-чага күп бит. Өстән кемнеңдер фәрманы төшкән, ахры, ярым сакау-ярым әпә Ләпәйгә колхозның иң арык атын җигеп биргәннәр дә йорт буенча су өләшеп йөрергә әмер биргәннәр. Чираты җитеп Гөлтуташлар ихатасына килеп кергән чакта, фәкать шушы Ләпәйне генә Пальма бер дә өрми каршы ала иде. Әллә аның ярым сакаулыгына ташлама ясаган ул, әллә башка сәбәп — аны кемнәр белсен? Ләкин менә нәкъ Ләпәй су кертергә килгән бер сәгатьтә юкка чыкты шул ул. Хәзер эт суеп ашаучылар да пәйда булган, диләр. Ачлыктан шашынган этләр үзләре дә юлда очраган теләсә нинди мәетне талап китәләр, ди. Кемгә генә гаеп салып, ни уйлыйсың инде? Юкка чыкты бит Пальма, капылт юкка чыкты. Инде менә сыер. Барча якын җаннар китә, аерыла. Тагын ниләр генә күрәседер әле?..

Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, дип, борынгылар белеп әйткәннәр шул. Күрсәтә бу дөнья! Унбиш-егерме көн чамасы да вакыт үтмәгәндер, колхоз абзарындагы бичара Афонька кортлап-шешеп үлде.

Төркәйдән Бүздәк элеваторына ашлык ташый башлагач та, аны Хәбинең энекәше Кара тавык Гайсә башка кешеләр кулыннан талап диярлек үзенә җигеп алган. «Бу Гайсә ташбаш малай чагында күршеләр ихатасыннан кергән бер тавыкны тотып көчләгән, шуңа күрә кушаматы Кара тавык икән дигән сүзләр йөри иде. Аның барча хатын-кыз тереклеккә ач күз белән каравы хак булгандыр инде, авылдагы кызларның берсе генә дә аны үз янына якын җибәрмәде. Ә Афонькага ябышуының нияте-максаты ни булгандыр — аны шайтан белсен.

Менә шушы Гайсә белән бергә элеваторга ашлык илтә киткән олаучылар Килем янындагы бер эскерткә төн кунарга туктаганнар икән. Атларны яндагы инеш буена тышаулап җибәргәннәр. Гайсә, кара төн уртасы җиткәч кенә, үзенең юлдашлары янына кайтып ауган. Иртән инде, билгеле, һәммәсе дә үз атларын олауларга җигә башлаганнар. Дирбия кидергән чагындамы шунда, Афонька Гайсәгә кушаяклап китереп типкән, диләр.

— Ах, анаңны сатыйм! Колхоз арбасына җигеләсең килмиме әллә, хайван? Колхоз абзарына иң беренче булып син

керден бит. Күтеӊ түгел, чыда, сөйрә давай! Хәзер күрмәгәнеӊне күрсәтәм мин сиӊа!

Гайсә әнә шулай итеп яман сүгенгән дә, төнге учактагы әле сүнеп өлгермәгән бер кисәүне алып, аны Афоньканыӊ артына китереп тыккан. Үзе һаман котырып акырган ди:

— Иӊ беренче булып колхозга син керден бит. Чыда, сөйрә, кәнтәй!..

Юлда үлеп калса, хөкемгә тартылудан курыкканнардыр инде, арты шешеп чыккан Афоньканы ике арбага салып кайтардылар. Гөлтуташ аныӊ янына өч-дүрт мәртәбә үкереп елый-елый барып кайтты. Афоньканыӊ ул алып килгән унбиш-егерме солы бөртеген дә кабарлык куәте юк, арты кортлап-шешеп газаплануларлан ул дөнья белән алыш-бирешен инде өзгән иде. Берәр атна чамасы газаплангач, ул бөтенләй тынды. Ни галәмәт, аныӊ итен ач кешеләргә дә бүлеп бирмәделәр. Афоньканыӊ гәүдәсен котырынган-шашкан этләр талап китте.

## 5

Артта авыр тимер ишек шартлап ябылуга, Әмир тынчу, кысан камераныӊ түренә текәлде дә коточкыч зур буар еланныӊ үзен күргән сыман өнсез-җансыз калды. Мәгарә шикелле караӊгы камераныӊ рәшәткәле төннек аша беркадәр яктылык төшкән урта бер җиренә уннан артык тоткын тезеләп баскан. Ә иӊ алда күзләрен тасрайтып, тешләрен ыржайтып карап торучысы — Күчәрбай башкисәре Мәхмүт Илмурзин...

— О-һо, братва! Менә нинди кеше килгән безгә. Калхузларны төзеп йөрүче, Совет илен алга җибәрүче ата коммунистларныӊ берсе Нәгыймов Әмир бит бу! — дип шәрран ярып, Илмурзин әүвәл бөтен камера эченә сөрән салып алды, аннары кургаш сыман авыр карашын янә яӊа тоткын йөзенә текәп басты.

— Дөнья бит ул куляса, бер әйләнә, бер баса, дип әйттемме мин сиӊа? Ә-һә, инде менә коммунистларга кәнәфи белән пүртәфилләр җитми башлады да бер-берегезнеӊ башын ашыйсызмы? Дөнья менә шулай, бер мәртәбә алдын үптерсә, биш мәртәбә артын үптерә ул. Ә монда мин командир. Калхуз башлыгы да, силсәвит, пыркарур да — мин берүзем. Ясинны да мин сиӊа берүзем генә чыгам.

Илмурзин бер-ике адым чамасы алга чыгып басты. Әмирнеӊ күзләре караӊгылыкка ияләнгән иде, Илмурзинныӊ йөзенә текәлде дә чагар елан өстенә яланаяк китереп баскан сыман кымшаналмый торды.

Илмурзинныӊ башы җиткән кабакмыни — олы, шома,

ялтырап ук тора. Йөзе олы табак сыман, җәенке һәм итләч. Тегендә, якты җир йөзендә, адәм балалары меңәрләп кырыла, ә бу монда, рәшәткә артында да, ачлыкның ни икәнен күрми, белми икән. Хәер, ачлык монда үтеп керсә дә, барыбер теләсә кемне суеп ашардыр бу. Әнә бит бәлеш сыман калын ирен читләреннән төкерек-селәгәй түгел, әйтерсең лә кан салынып чыккан. Ике ирен астыннан ыржайган тешләре теләсә нинди җанвар бугазын чәйнәп өзәргә әзер.

— Күчәрбайдагы Харис байның келәте исеңдәме? — дип, паровоз тавышлары чыгарып үкерде Илмурзин, кымшаналмый торган яңа тоткынның йөзенә төкерекләрен чәчеп.— Мин бетле коммунист Хөлләне суеп яткан чакта, син минем башыма мылтык белән бәрдең. Чанага бәйләп салдың... Әзвир Канкай минем үкчәләрне наган белән төйде... Мин шунда елый-елый ялындым бит аннан. «Качмыйм, качмыйм, сукма гына»,— дидем. Ә ул барыбер төйде, кызганмады мине...

Илмурзинның йөрәгенә яткан яралар кисәк кенә яңарып китте бугай, әзмәвердәй башкисәр лышык-лышык итеп икеөч мәртәбә борын тартып алды. Янә кубып үкерә башлаганда тавышы яраланган җанварныкы төсле кыргый, ярсу иде.

— Мин шул чагында «барыбер суям, барыбер суям» дип кисәттемме сине? Ышанмаган, ихахайлап көлгән булган идең. Менә Ходай Тәгалә җаен чыгардымы? Мә, мине газаплауларыңның әҗерен ал инде!

Илмурзин, бар куәтенә кизәнеп, Әмирнең чигәсенә яман китереп состы. Ялан кулы белән генә сукмагандыр, ахры, соңгы көннәрдә тәмам кипшенеп җиңеләйгән Әмир өч-дүрт адым араны очып кына үтте дә таш идәнгә бәрелеп гөрселдәде. Ләкин үзе һаман әле акылында иде. Калын табанлы олы ботинкасы белән ярсып тибә-тибә, Илмурзин аны камера идәне буенча каз мамыгы шикелле очыртып кына йөртте.

— Юк, бүген суймыйм әле. Көн саен менә шушылай иттереп изә-изә, газаплый-газаплый, мин синең каныңны тамчылап эчәчәкмен! Бер тапкыр кыйналдым да котылырмын, димә. Мин сине ахырдан гына, инде кешелегеңне изеп тезләндергәч кенә, акыртып суячакмын!..

Икенче көнне үк камерадагы тоткыннарның бер ярты-сын Бәләбәй читендәге ниндидер химия заводы төзелешенә алып киттеләр. Әмирнең сулъяк чигәсе яман шешеп чыккан, күзләренең берсен куе кан элпәсе каплап алган иде. Ләкин конвой арасында аны кызганып-мазар торучы сакчы табылмады. Кичке караңгылык күзне бәйләгәнче һау-һаулап куа-куа, этләр өстерә-өстерә, ялсыз эшләттеләр. Көч-хәл белән аякларын сөйрәп камерага кайткач, чебеш алырга килгән карчыга шикелле, Әмир өстенә янә Илмурзин килеп ябырылды.

— Кичә кыйналдым да котылырмын, димә. Мин синең

каныңны көн саен кич тамчылап эчәчәкмен! Аннан гына суям!..

Әлеге җәза газаплары атна буе берөзлексез дәвам иткән иде. Кайсыдыр бер таңда тоткыннарның икенче яртысына да төзелештә эшләргә чират килеп җитте. Ә кич белән кире кайтып керсәләр, көтелмәгән хәбәр:

— Урмандагы бер тирән ерым яныннан үтеп барган чакта, Илмурзин машина әрҗәсе аша җиргә сикереп качкан. Конвойныкылар аның артыннан атып та, куып та караганнар. Ләкин Илмурзин, җен шикелле боларның күзен буып, божра ясап аска тәгәрәгән. Хәтта этләр җибәреп тә эзләп караганнар, таба алмаганнар...

Башка берәү бу хәбәрне алса, мөгаен дә, сөенечтән бии башлар иде. Әмир исә ыжлап та карамады. Ул бичара түбәнсетү-кимсетүләргә инде әллә кайчан күнегеп беткән, күңеле сәхрә сыман буп-буш, анда бертөрле дә хис калмаган иде.

## 6

Көннәр язга таба авыша башлагач, ачлык кешеләрне гел аяктан екты. Зифа мәктәпкә дә хәзер инде көч-хәл белән аякларын сөйрәп, шул бер тапкыр ашау хакына гына барып йөри иде.

Хәмдениса карчык белән Сәмигулла карт күптән инде түшәккә егылдылар. Сәмигулла картның көнбагыш төше кушып пешерелгән тары боткалары хәзер төшкә генә булса да кереп чыкмый. Өй эчендәге барча җиһазларны хәллерәк көн күргән күрше-күләнгә сатып, җан асраган булып интегәләр. Менә бүген дә Сәмигулла карт мүкәләп диярлек урыныннан кузгалды да хәзинәдә иң кадерле ядкарь булып исәпләнгән соры шинель белән папаха бүрекне Зифа балакай кулына китереп салды.

— Улым Гарифның соңгы истәлеге. Аллам сакласын, рухы-мазар рәнҗемәсен инде... Берни эшләр хәл юк, Хәмдениса түтәң белән синең җанны саклап калырга кирәк, балакаем... Теге чишмә буендагы Садриларга илтеп бир шуларны. Садри әле дә булса ару яши, китергән әйбергә он алмаша, диләр. Илт шуларны аңа, балакаем... Иманы калган булса, без фәкыйрьләргә алабута белән тары боламыгы табып бирмәс микән?..

Сәмигулла картның элек әллә ничә тапкыр очына-очына сөйләгәне бар бит. Аның улы Гарифҗан Чапай дивизиясендә эскадрон дигән олы бер отрядның командиры булган. Уфаны алган чакта, шул Гарифның отряды кала урамнарына иң беренче булып бәреп кергән. Ләкин үзен аклар сагалап торган. «Балчыклы» дигән бер инеш аша кичеп чыккан

чакта, Успенья соборының гөмбәзенә менеп яшеренгән дошман пулеметтан атып үтергән шул аны. Гарифҗанны соңыннан Чапай үзе Дума бакчасында зурлап җирләгән, ди. Залплар биргәннәр, мәрмәр таш куйганнар. Ә Гарифҗанның обоз арбасында калган соры шинеле белән папаха бүреген Кучәрбайдагы Сәмигулла карт кулына полк командиры үзе китереп биргән. «Улың белән горурланырга тулы хокукың бар, ул барча халыклар бәхете өчен көрәшеп вафат булды»,— дип, Сәмигулла картны бөтен авылдашлары каршында мактаган да, юаткан да әле.

Менә өй эчендәге иң кадерле, олы ядкарьне дә җан саклау хакына Кырхабур Садриларга илтеп бирергә вакыт җиткән икән. Ә ул Садри Сәмигулла картның изге ядкарен алып каламы да, җан сакларга никадәрле һәм нинди генә ризык биреп җибәрер соң әле? Хәзер һәр авыл саен хәер эстәүчеләр, әйбер сатучылар көтү-көтү булып йөриләр бит. Ул Кырхабур Садри Зифаны берәр төрле карак-мазар санап, эт өстергән шикелле, ишек төбеннән үк куып чыгармаса ярый әле тагын...

— Ә-ә-ә, Сәмикъ картта асрау булып торган кызый бугай бит син. Синең атаңны әле көз көне үк алып китеп югалттылар бугай,— дип, бик күптәннән белгән кешесе шикелле, һич тарсынмый-нитми каршылады аны бу Кырхабур Садри. Ә соңгы сүзләрне аермачык ишетеп торган Зифаның йөрәге табан астына төшкән сыман булды. «Нинди югалу ул? Аның әтисен кайда югалтканнар?»

— Нәрсә, бу иске-москыны ипигә алышырга дип китердеңме әллә? Кирәге барые, поты бер тиен, алар миндә мүре.

Шул чагында гына Зифа энә белән китереп кадаган шикелле айныгандай булды.

— Алабута белән тары боламыгы гына булса да биреп җибәр инде берүк, Садриҗәләл абзый! Сәмигулла бабай белән Хәмдениса түти ачтан үләләр бит.

Садри күзләрен әллә ничек итеп, сәер әйләндереп, Зифаның әүвәл күкрәгенә, аннан ботларына караш ташлады да, кибеп калган иреннәрен теле белән ялап, авыз эченнән генә сөйләнгәләп куйды.

— Һе, алабута белән тары боламыгы булса да ярый, дисең инде син. Ярар, бу иске-москылар да иш янына куш булыр, алайса. Әйдә, келәт белән чоланнарга кереп, лар төпләрен кырып-себерештереп, бар булганын җыйнап карыйк әле. Бәлки, ни дә булса табар абзыкаең.

Садри чолан ишеген ачып җибәрүгә, Зифа бичараның исакылы китте. Нинди генә байлык-җиһазлар тупланмаган монда! Түшәмгә кагылган озын бер колгада биш-алтылап толып, кайралган тун, итәкләре-изүләре бөрмәләнеп тегелгән

уннан артык иң затлы хатын-кыз күлмәкләре асылынып тора. Өске киштәләрдә чип-чиста җизләре һәм көмешләре белән елкылдап утырган алты-җиде гармун, самавырлар. Аскы киштәләрдә гаиләсе-тупланмасы белән җыйнап тутырылган аш-су тәлинкәләре, чәй-мәй савытлары. Кайсы чиста керәчтән, кайсы бәллүр. Идәндә әле тагын дистәләгән чуен казаннар, вак-вак мичкәләр тезелешеп киткән. Шулар өстендә кайсына — ак он, кайсына соры яки карасу төстәге ярма тутырылган пыяла тартмачыклар...

Зифа үзе дә тоймый-аңламыйча төкерекләрен йотты. Өй хуҗасы сизеп алды бугай, ул яндагы агач сандык капкачын тартып күтәрде дә, аннан бербөтен сары күмәч алып, аның уч төбедәй кечерәк кыерчыгын Зифага сындырып бирде. Зифа үзен-үзе белештермичә ипи кыерчыгын чәйнәргә тотынды, ә Садри, сыерның буазлыгын тикшергән мал врачы шикелле, җитлегә башлаган кызның күкрәкләрен, эчен, бот һәм иңбашларын капшап-айкап чыкты. Зифа мондый кыланышларның асылын әле һаман аңлый алмый, шуңа күрә кымшанмый да басып тора иде. Максаты-нияте турында Садри аңа үзе җим ташлады.

— Казанына су ташып куелган, мунчаны як, давай. Күңелемне күрсәң, бер туя ашауга гына интекмәссең. Садриҗәләл белән мунча кергән бер хатынның да бу йорт тупсасыннан ач көенчә чыгып киткәне юк әле...

Атналар-айлар буена ачлыктан кыркылган кешегә юньле ризык йөзен күрсәтмә икән ул. Зифаның бодай күмәченнән пешерелгән тәмле кыерчыкны кабып йотуы булды, күңелендә-зиһенендә әллә нинди шашкын хисләр өермәсе уйнаклый башлады. Көннән-көн үсә, тулылана барган яшүсмернең тәне бер кыерчык ипидән соң хәзер инде итен-маен да, кайнар шулпасын да таләп итә, Зифа, менә шуларны күз алдына китереп, ярым тилемсә халәтенә кереп бара иде. Кырхабур Садри ташлаган киная аның зиһененә дә барып җитә алмый, «туя бер ашау» дигән сүзләр генә, әйтерсең лә аның кан юлларына кушылып тибә иде.

— Ягам, ягам, Садриҗәләл абзый. Тагын бер кыерчык кына икмәк бир, зинаһар,— дигән сүзләрне дә ул асылын аңламаган көе генә тезде.

Күндәм коллар кемгә ошамасын? Күзләрен ач мәче шикелле уйнаклаткан Садри янә бер кисәк кыерчык сындырып бирде, эш арасында Зифаның нәни, тыгыз күкрәкләрен кыскалап караудан да тартынып маташмады.

Бодай күмәче арык тәненә хәл өстәде бугай, Зифа кызу эш өстен йоклап үткәргән яшь киленнәрдәге төсле кайнар ярсулык белән мунча мичен якты, ләүкә-идәннәрне ялт-йолт юып чыкты. Казандагы су быгырдый башлаган чакта, ни-

һаять, кызларын кияү урлап киткәннән соң гына туйга төшәргә мәҗбүр ителгән баш кодалар кебек көттереп-ялындырып кына Садри килеп җитте. Зифа әле һаман мунча эчендә, ул түрдәге ләгән-чүмечләрне чайкап, чиләкләргә салкын су тутырып азаплана иде. Садри яшүсмер чит кызны күз уңына да алып тормады, өстендәге киемнәрен бөтенләй салып ташлаган көе мунча эченә килеп керде дә багана шикелле катып калган Зифаны үзенең кочагына суырып-сосып алды.

— Арканы уарсың, миллек белән чабарсың, өстеңне сал, давай.

Зифа шул чагында гына акылына килде һәм мунча эчен яңгыратып чәрелди дә башлады.

— Ни эшлисең, Садриҗәләл агай? Мин мәктәп баласы бит, ничек оялмыйсың?

— Йә-йә, кызый, йә-йә, чәрелдәмә. Узган атнада хәер сорашырга килеп кергән Иске Күзәй кызы сиңа караганда ике яшькә бәләкәйрәк иде. Сырланып маташмады бит әле. Бер бөтен икмәк чыгарып тоттыруга, сузылды да ятты. Ачтан үләсең килмәсә, син дә сузылырсың.

Садри шулай сөйләнә-сөйләнә янә өстенә килә башлагач, Зифа тагын «Ю-ук, ю-ук!» дип чырыйлап кычкырды да, әүвәл шәрә ирне, аннары ишекләрне җан ачысы белән усал бәрә-бәрә тышка атылып чыкты. Аның күзе-башы тонган, ул юл читләрен, чокырларны абайламый-нитми Төркәйгә таба лас-лос йөгерә иде.

## 7

Ләкин Төркәйдә дә Зифа бичараны көтеп торган кеше юк иде шул.

Өенә кайтып керсә, сеңелләре Вәзирә белән Лена урын-җирдә тәгәрәшеп ята. Нинди дә булса ризык эзләп урамда йөрүдәнме бу, әллә һаман да шул ачлык газабыннанмы? — икесенең тиң аяклары бот төбенә чаклы гөбе сыман шешкән. Яңаклары суырылып калган, иреннәре кибеп яргаланган, яннарына сузып салган куллары корыган тәпәч кебек, күзләрендә нур юк. Ишектән Зифа килеп кергәч тә, йөзенә-күзенә түгел, күбрәк апаларының кулларына карап ятты алар. Өметләнердәй ризык булалмасын сизенделәр бугай, бераздан карашларын түшәмгә текәделәр дә янә тын калдылар.

Ун яшен әле генә тутырган энекәше бакча башында койма-читәннәрне сүтеп азапланган икән. Берзаманны ул, икеөч кушучка сыеп бетәрдәй чыбык-чабыкларны, такта кисәкләрен күкрәгенә кочып, ахылдый-ухылдый кайтып керде. Хәлсез көе эшләп кызуның хикмәтедер инде, ике яңак ур-

талары да алсуланып тора, хәтта борын очына да ике-өч тамчы тир бәреп чыккан. Ләкин Тимерҗан да шәүлә сыман ябык, гәүдәсе, куллары, ботлары неп-нечкә. Аның муенына тикле тарттырылган, озынайган кебек.

Авылдашлар гына түгел, хәтта бер өй эчендәге туганнар арасында да бер-берсенең хәлләрен сорашу гадәте күптән бетте, онытылды инде. Тимерҗан да апасына сәлам-фәлән биреп маташмады, әле биш минут элек кенә аерылышкан кешеләр шикелле, үзләренең гаилә хәлләрен тезеп алып китте.

— Әйдә, казанга берәр чүмеч чамасы су өстә дә, ут элдерик, апа. Инәкәй үзенең бирнә киемнәрен алып Түбәночка китте. «Убыр Әбелсаттарга булса да илтеп сатам, он тапмыйча кайтмыйм, өне тыгылсын», — ди. Үзенең кыз вакытта кигән читекләрен, ике тастымалны төреп алып китте. Әбелсаттар убырның күзе кызар инде. «Юк бит, җиңги, бер умач ясарлык арыш оны да юк», — дип карунланып сөйләнә-сөйләнә дә, ахырында барыбер дә инәкәйгә он чыгарып бирә. Мин ул убырның сасык карахтирын яттан беләм инде. Башта гел «юк» дип ялындырып тора, аннары инәкәй «ярар, Сабитка керермен булмаса» дип ишеккә тотындымы, әйберенә килепябырыла. Инәкәй күтәреп барган самавырларның, шәлләрнең, керәч савытларның берсен генә дә кире бормады әле, алдап-йолдап бөтенесен дә үзенә алып калды. Бу юлы да читкә типмәячәк, инәкәйнең читекләрен алып калачак ул...

Гөлтуташ кайтып кергән чакта, казанда су быгырдый, өй эченә дә берникадәр җылылык таралган иде инде.

— Кайттыңмы, кызыкаем? — дип кенә сорау ташлады да, җавап-мазар көтеп тормастан, Гөлтуташ әүвәл күәс чиләге белән куна тактасына барыпябышты, аннары вокзалда поезд көткәндә йокыга бирелмәскә тырышкан юлчы хатыннар уяулыгы белән тиз-тиз тезеп китте.

— И-и, ичмаса, бирәне дә тыгылмый бит шушы абзыкайның! Җан кебек читекләр белән ике тастымал өчен ике кадак онны да тутырып бирмәде бит. Оны да он булса ярар иде әле. Анысы да кул тегермәнендә тарткан солыны, тарыны, алабута орлыгын катнаштырып биргән кара боламык бит. И-и, бер каз оясы ятим бала белән утырып калган тол хатынның кадере буламы соң?! Без хәзер кемгә кирәк тә, безгә ни сан? Атагыз гына ул үз кадерен үзе белми яшәде, ай-һай, очсызланды. Шушы убыр Әбелсаттарга утызынчы елда башкалар күзеннән яшереп кенә ничәмә-ничә капчык арышын да, бодаен да бирде. Саттар ул чагында, колхозга кермәс өчен, кул-аягын терәп каршы торды. Упалнамучлар тегеңә

әле теге, әле бу яктан китереп налукларны чәпәделәр генә. Саттар иртән колхозга бертөрле налугын китереп түли иде, ә атагыз, дүр-рәк, караңгы төшкәч, шуларны ук янә агасына бакча артлап кына илтеп бирә иде. Партиягә кереп кайткач, ярты авылны җыеп кыйнаткан өчен атагыз, дүр-рәк, шул убырга тырнак очы хәтле генә дә үпкә йөртмәде бит. Ә менә хәзер атагызның шушы игелекләре өчен нинди этлек белән түли бу хәерсез. Э-эх, бирәне дә тыгылмый бит, ичмаса, йа Ходаем!..

Әниләре пешергән умач боламыгын чөмереп ачлык талавын баскач, Тимерҗан белән төпчекләр урман кискән шикелле мыш-мыш килеп йокыга да китте. Ана белән кыз, берберсенең кочагына сеңеп, байтак кына сүзсез утырдылар. Берзаман Гөлтуташ, сабый бала чәчен тарагандагы шикелле, саклык белән генә кызының күңел кылларын чиерткәләүгә күчте.

— Болай итеп, читек-тәлинкәләр өләшеп йөреп кенә, биш җанны да саклап калып булмас, балакаем. Өй эчендә чыгарып өләшердәй әйбер дә калмады бит инде. Үзең кара инде, әнә теге әтиең мине килен итеп алып кайткандагы кайма тун белән сезнең бөтенегезне дә тирбәтеп үстергән бишекне дә чыгарып бирикмени? Аннан соң шул казан белән табаларны, чүмеч белән кашыкларны гына өләшәсе кала. Ә безгә алай ук мескенәергә, авыл каршына, мир каршына чыгып тезләнергә ярамый бит, Зифа балакаем. Ни әйтсәң дә, атагыз бит авыл тоткан кеше, авылның йөзек кашы. Ишетеп-белеп алса, аның күңеле рәнҗер.

Әнисенең күкрәк җылысында эри-эри Зифа сүз кыстырды.

— Әтәй сыман берәрсенә батрак булып яллангып карасам да алмаслар микән, яшь диярләр микән, инәкәем?

Гөлтуташ ачуыннан Зифаны хәтта этеп үк җибәргәндәй итте. Тавышы да ярсу, коры иде.

— Әле генә шуны сөйләп утырдым түгелме соң сиңа? Батрак булу, яллангып бил бөгү, кешелегең белән сату итү — болар барысы да очсызлану, тезләнү бит инде. Колагың ишетеп калсын, күңелеңә гомерлеккә биклә: беркайчан да, беркем каршында да тезләнергә ярамый ул адәм баласына. Аерым бер кеше сынса да, олы-олы милләтләр бер генә мәртәбә тезләнсә дә — бетте, кабат аягына күтәрелә, тураеп баса алмый инде ул. Кеше бер тезләнсә, үзе теләп богау кигән кол хәленә төшә. Ә колга хуҗалар һәрчак табылып тора. Менә шуңа күрә тезләнә күрмик инде без дә, балакаем, кеше булып калыйк.

Гөлтуташ Зифаны күкрәгенә янә нык итеп кысты да,

башын кызының иңнәренә салып, башта бәллүләгән шикелле селкенгәләп утырды, аннары акрын гына җыр сузып җибәрде.

Тып-тын гына басып өй-түбәгә,
Гөрли-гөрли йөри күгәрчен;
Моңлы итеп гөрли, тагын туктый,
Бәхетләрең юк, ди, күрәмсең.

Ике лә генә җирән, ай, бер көрән,
Әйдәп алып булмый юл белән;
Маңгаеңа язган хак язмышны
Җуеп алып булмый кул белән…

Тышта күптән караңгы төшкән иде инде. Түшәккә сузылгач, кызын кочаклады да Гөлтуташ аның белән киңәштабыш иткән сыман булды.

— Аблайга бер баргач белешеп кайткан идем. Ачлык китереп кыскач, анда бик күп кеше йортын саткан икән. Такта түбәле, алты почмаклы яңарак өйләрне алтмыш-җитмеш кадак онга аткарып була, диләр. Безнекенең түбәсенә затлы калай япкан, аннары ни әйтсәң дә, Гәрдән йорты әле. Рәтле кешесен тапсаң, мөгаен дә, мондый кулак ихатасы өчен бер йөз кадакны да каерып булыр иде. Мәгәр бүген аның рәтле кешесен каян табасың соң?

Зифаның тәне корт чаккан шикелле дерт иттереп куйды.

— Ә без кая? Урам уртасында торып калабызмы?

— И-и, бушап калган өйләр авыл саен да, урам саен да әллә ничаклы бит. Берсенең хуҗалары ачтан үлеп бетте, икенчеләренеке ишек-тәрәзәләренә аркылы-торкылы такта кадаклады да, йә ил буенча хәер эстәп йөри, йә завут-фабрик тирәсенә элгәшеп калаларда яши. Безнең анау Яшке хуторы очында гына да Сабира әбинең йорты бүген буш көенчә тора. Тагын Тутык Кәримнәр йорты буш, Галимәрдәннәрнеке буш. Мин әле рәтлерәк йортларны гына санап чыктым, бөкре әбиләр шикелле кыегаеп утырганнарын әйтеп тә тормыйм. Дөрес инде анысы, башлар исән-сау чакта Төркәйне ташлап икенче бер авылга күченсәң, бу еланнар оясыннан чыгып качсаң, әйбәтрәк тә бит. Мәгәр кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмый, диләр. Атагызның башын ашап, төрмәгә тыгучылардан бик тиз генә котылып булмас шул инде.

Йорт эче дөм караңгы булса да, Зифа күзләрен шар иттереп әнисенә озак карап ятты.

— Бәрәч, бәрәч, безнең әтәй алай аның башын ашарлык нинди гөнаһ эшләде соң әле?

Гөлтуташ әллә ничә тапкыр авыр сулап куйды.

— Берьюлы ике хуҗага тәлинкә тотып булмый, балака-

ем. Аннары япа-ялгыз кеше берьюлы дөрләп яна башлаган ике йортны хәтта шартласа да, дөньядагы иң елгыр бәндә булса да, барыбер сүндерә алмый. Йә берсен сүндерү өчен йөгерергә кирәк, яисә икенчесен. Ә атагыз менә берьюлы ике хуҗага ярамакчы, ике утны сүндермәкче булды. Имеш, ул коммунист, шуңа күрә сәвит көенә бии. Шул ук вакытта янәсе авылдашларына да каты бәрелми, Төркәйгә дә ярый. Менә ни өчен ике тегермән ташы арасына килеп эләккән бодай бөртеге сыман изелде дә әрәм булды бит ул. Бер яктан, авылдашлары өчен начар булып калды, икенче яктан, ул алар каршында әпипә биеп йөргән райкумы да, сәвите дә якламады аны. Атагыз йөгерде-йөгерде дә ахырда чаба-чаба янган ат шикелле булды. Ни авылга керәге калмады, ни сәвиткә. Асыл башкайлары кысан төрмәләрдә чери газиземнең...

Ана белән кыз икесе дә бер-берсенең иңнәренә борын төртә-төртә, лышык-лышык килде. Бераздан, сөрүгә чыгарылган ат кебек, Гөлтуташ барыбер дә үз эзенә кайтты.

— Башларыбыз исән-сау чагында бу Гәрдән бай йортыннан котылмыйча булмас, балакаем. Безнең ише ятимнәргә мондый сарай эчендә көн итәргә ирек куймаслардыр. Без Төркәйгә күз көеге булып, аяк табаннарына кадалган шырпы сыман булып утырабыз. Көнләшүчеләр бик күп. Ишекләрне бикләп, яндырып куюлары да бар, Аллам сакласын. Аннары бездәй ятимнәргә мондый йортта яшәү үзе үк бөкресе чыккан әбигә туй күлмәге кидергән шикеллерәк. Белеп торам, иртәме-соңмы барыбер дә аны бездән тартып алачаклар. Әнә теге вакытта сыерыбыз Сандугачны алып киткән сыман. Ул чагында авыз ачып калдыкмы? Менә шуның шикелле, өсне-башны алдан киенмәсәк, бу юлы да урам уртасында шәрә көе басып калачакбыз. Яклаучы, жәлләүче юк. Иелгән башны кылыч кисми, диләр. Әйдә, бу тәмуггтан исәнимин көе чыгып ычкыныйк та, азмы-күпме он юнәтеп, җанны саклап калыйк. Ник кадалып китми бу Гәрдәннең йорты. Өннәре тыгылсын төркәйләрнең. Котылыйк, качыйк моннан...

Икенче көнне үк дүрт баласы белән тол Гөлтуташ авылның иң чокырлы урынында ике-өч ай элек кенә япа-ялгыз көе яшәп яткан Сабира әбинең черек нигезле, бер якка янтая башлаган иске генә өенә күченде дә куйды. Гәрдән йорты өчен Гөлтуташка кырык кадак арыш оны һәм, балалар өчен иң сөенечлесе, арык булса да сөтен ташламаган олы сыер китереп бирделәр. Элекке Гәрдән байның ихатасына кереп оялаган яңа хуҗа — әле ике ел элек кенә эт типкесендә йөргән Хәби-Хәйберахман иде.

# УНЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

## 1

— Торыгыз, балалар, торыгыз! — дип, беркөн таңда Гөлтуташ төрткәли башлагач, төпчекләре Лена белән Вәзирә генә түгел, Тимерҗан белән Зифа да байтак вакыт буе бернәрсә дә аңлый алмый ятты. Ә Гөлтуташ өйнең почмагына ут капкан шикелле әрле-бирле сугылды, бертуктамый тәтерди дә башлады.

— Саттар абзыкайның хатыны килеп әйтте. Анда да кача-поса, яшеренеп кенә. Торна күл очындагы Фазылбәк хәзер Бәләбәйгә чыгып китә икән. Төрмәгә, ди, Сөләйман абзыйсын күрергә, ди. Олапайның әйткәне хак булса, күршекүләннәре әллә нинди дүкәмит оештырганнар, ди. Ниндидер актымы инде шунда, гаризамы, аны чуртым белсен. Сөләйманны әллә нинди парукага сораганнар, әшен сутта кабат каратмакчылар, ди. Без — ятимнәр бит, безнең өчен кемнәр йөрсен инде?.. Тф-фү, кая гына китте соң инде ул минем ак муенса? Зифа, күрмәдеңме? Аннары, давай, тор да минем теге чактан калган көмеш каптырманы эзләш әле... Ә-әй, бу Фазылбәкне! Бигрәк пакыч икән. Абзыйсы янына барасы турында безгә әйтмәгән дә. Шу-ул, безне һаман дошман итә, көчсез итә инде болар. Имеш, Сөләйман гөнаһсыз да, бөтен гаеп бер Әмирдә генә. Ай-һай, җаныкаем! Сәвит дүрәк түгел. Гаеп аттамы, тәртәдәме — аны гына аера белә инде ул. Әмир теле белән генә кушкан, ә Сөләйман фирме сарыгын үз куллары белән суйган әле. Сөләйман гаеплерәк. Алай булмаса да, барыбер икесе дә бер ыстатия буенча утырганнар. Тегене йолып алдым да, монысын калдырдым юк. Шулай булгач, энә белән җеп шикелле без хәзер, Фазылбәк җаныкаем. Япа-ялгыз коткарырмын, димә.

Зифа оек-күлмәкләрен киенеп беткән иде. Гөлтуташ аңа күз йөгертеп кенә чыкты да янә тыр-тыр тезеп китте.

— Булган бөтен әйбереңне өс-башыңа киен. Көннәр майга таба барса да, тышта суык әле. Минем бәйләм кофтаны ал, бумази күлмәкне ал. Син грамытлырак, Бәләбәйгә син барырсың, кызым. Бала кешесе дип, үзеңне атаң белән дә очраштырмаслармы әле? Берүк бирсен Ходай, берүк бирә күрсен... Ә ул Фазылбәк таш бәгырьне, алларына тезләнеп булса да, барыбер эретәм мин. Алмый гына карасын сине, алмый карасын. Аннарымы? Аннары Төркәйдә яшәрлеген калдырмыйм мин аның, борынын тешләп өзәм!.. Аның җигеп китәчәк аты да үзенеке түгел, калхузныкы әле. Ул утырган икән, безгә дә ярый. Калхузны Сөләйман белән Фазылбәк

төземәде, Әмир төзеп бирде. Һи-и, утырмыйбызмы соң!.. Йә, булдыңмы, кызым? Мә, менә боларны ал, менә боларны да. Эчкәрерәк яшер. Бәләбәйдә төрмә сакчысына булса да ярап куяр, йә грамытлы итеп хат яза белүчегә... Юлда авызыңны ачып, йоклап йөрмә. Әрсезрәк бул. Фазылбәк бик ертлач, ашау-эчүне көйли белер. Син дә җебеп торма. Кулыңа ни эләгә, кап та йот, кап та йот... Ходай кушса, бу Фазылбәкләр дә йөргәч, атагыз белән Сөләйман котылмасмы әле?..

Ни хикмәт, ни галәмәт, Фазылбәк Зифаны һичбер сүз карышмый-нитмичә үзе белән алды. Әүвәл Шыгай авылына төбәп юл тоттылар. Кар инде бик җепшегән, кайбер уйсулыкларда урыны-урыны белән күлләвекләр җыелып тора иде, беренче чакрымнар арттан тарткан сыман сызландырып үтте. Аннары юллар гел югарыга таба күтәрелә башлады, салкын җил сизелде, карлар катыланды, җирән алаша да адымын кызулатты.

Зифа озын юл буена, авызын ача-ача, гел шаккатып барды. Төркәй-Күчәрбай җиренә бер дә охшамаган, үзе сәер, үзе матур икән бит бу яклар. Чәрмәсән буенда таллар, өянкеләр, усак, каен гына үсә, ә мондагы агачларның күпчелеге нарат, чыршы, имән, карагайлар икән. Үзләре бик биек, юан, мәһабәтләр — һәркайсыннан иң олы бурага да яраклык икешәр-өчәр буй бүрәнә чыгар сыман. Ә таулары инде, ә таулары! Чәрмәсән тирәсендәге түбәтәй шикелле бәләкәй, ыспай гына сикәлтә-калкулыклар түгел инде болар. Мондагы таулар киң далага ял итәргә сузылып яткан әкияттәге пәһлеваннар сыман. Әнә карале син, уртада киң мәйданлы олы күкрәкләре калкып тора. Яннарына, өркәч-өркәч булып, гайрәт чәчеп торган кул-аяклары сузылган. Кечерәк булып, ялгыз утырганнары да, аһ, матур бит. Гаҗәеп түгәрәкләр, шома, сафлар. Тфү-тфү, җитлегеп килүче кер-гөнаһсыз кыз балаларның күкрәкләре шикелле бит болар. И-их, бу тауларның түбәсенә менеп бассаң иде дә, чәчләреңне җилләргә таратып, күкрәк тутырып бер җырласаң иде!..

Ә ул тирә-юне! Биек тауларның аяк очлары буйлап, йоклап яткан пәһлеваннарны уятмаска тырышкан шикелле, җәйләшып-бормаланып, әллә никадәрле матур елгалар ага. Бу тирәдәге елгалар ярсу, кызу агымлы, күрәсең, байтак урыннар боздан арчылып өлгергән. Елга буйларында бөдрә куаклыклар. Тау сыртларында чишмәләр күп, ахры. Байтак урыннарда чәч толымнары сыман үрелә-үрелә вак-төяк инешләр челтерәп агып ята. Ачык су өсләренә, агач ботаклары аша үтеп, кояш нурлары сибелгән, алар, күз кысып шаярткан шикелле, җем-җем килеп тора. Кояш та йокы белми. Ул да, су өстендә сикергәләп уйнаклаган елгыр чабак сыман әле

агач һәм тау башларына менеп ялтырый, әле болытлар арасына качып-чумып йөзә. Ачлык-кайгыңны онытсаң, и, матур соң дөнья!..

Зифа үзләренә үтәргә туры килгән авылларга да гел күз атып барды. Йа Ходай, никадәр таланган, картайган соң бу як авыллары! Ихаталар арасындагы койма-читәннәрне сүтеп бетергәннәр. Әллә ничәшәр йортларның ишек-тәрәзәләренә такта кадакланган. Бик күп кенә сарай-келәтләрне, хәтта кечерәк йортларны да ярты түбәсенә чаклы көртләр каплап киткән. Лапаслардан бертөрле дә җанвар-мал авазы ишетелми. Урамнарда кешеләр генә түгел, этләр дә күренми. Кайбер авыл араларында ябыгып өрәккә охшаган бала-чага белән карт-коры очрый икән, алары да хәер эстәүчеләр. И-и, кешеләрне ничек итеп кенә тезләндермәгән дә, авылларны ничек кенә таламаган бу ачлык! Ходай Тәгалә күбрәк көч бирсен һәм исән калган адәм балаларын тизрәк кузгалагына, юа, кaкы, кычытканга булса да кинәндерә башласын иде инде!..

Кичке эңгер-меңгердән күз бәйләнә башлаганда, Сазлыкүл дигән авылга килеп җиттеләр.

— Артыгын барып булмас, шушында куна керербез. Монда минем берникадәр таныш ахирәт бар, — диде Фазылбәк, киңәшүдән бигрәк аны кисәткәндәй.

Зифа эндәшмәде. Болай да чамалавы кыен, читен түгел. Мондый коточкыч ачлык заманында юлда кеше талаучыларның очравы бик мөмкин. Хәтәр ару атны да, Фазылбәк тутырып чанасына салган олы капчыкны да, мөгаен, алар «юлыгызга ак җәймә» дип кенә үткәреп җибәрмәсләр. Ходай «үзе сакланганны гына саклармын» ди, вакытында чама белү хәер.

Авыл уртасында янып кара күмергә әйләнгән бер йорт хәрабәләре яныннан үттеләр. Мондый олы бәладән соң бик күп вакыт үтмәгән иде, күрәсең, бүрәнә калдыкларыннан әле дә булса күмер, төтен исе аңкып утыра. Шулай, бәла дигәннәре казык башыннан түгел, кеше башыннан йөри бит ул...

Фазылбәк җимерек капка аша ихатага кереп туктаган йорт хуҗасы Локман атлы кеше булып чыкты. Күз тимәсен, кыяфәте-сыны тулы, таза икән. Шулай да, бәрәңге белән катык куелган өстәл артына кереп утыруга, тәүге сүзләрен үк ачлык хакында башлап җибәрделәр.

— Бер йорт янган икән сезнең монда. Яңасын төзү хуҗаларына, ай-һай, авыр булыр, — дип, Фазылбәк сүзне ирексездән генә башлап киткән иде, Локман йөзен-кашын җыерып шундук элеп алды.

— Юкка кайгырасың. Ул урында яңа йорт-каралты бик тиз булмас әле. Каһәрләнгән урын ул. Хуҗалары да юк.

Бөтен авыл белән җыелып, ишек-тәрәзләрен бикләп яндырдык без аларны. Кеше ашаган өчен. Ул хайваннар күрше Караяздан килеп хәер сорашырга кергән бер баланы суеп ашаганнар. Сигез яшьлек кызны бит, малайкаем, сигез яшьлек кызны! Андыйларның җир йөзендә яшәргә хокукы юк! Шуңа яндырдык без аларны. Бөтен авыл белән. Җәза күрәсе икән, бергә күтәрербез...

Тамак ялгап алгач, икесе тиң Совет хөкүмәтен ду китереп тетте.

— Юк инде бу властьтан, туганкаем, юк бит инде. Калхузга керергә кыстаганда, и-и, оҗмах бакчалары вәгъдә иткән булдылар. Бөтенегез тигез, һәммәсе дә уртак булачак дип, и-и, лыгырдадылар, и-и, лыгырдадылар. Ә ахыры? Менә көздән бөтен икмәкне талап апкиттеләр дә бөтенебезгә дә, тигез итеп, ачлык элмәге асып куйдылар. Вәт оҗмах бакчасы бу! Җырла, бие, шатлан!

— Безнең Төркәйдә һәр башакны, һәр саламны молотилкадан ике кат чыгарырга мәҗбүр иттеләр бит. Бер бөртек ашлык калмады амбарда. Бөтенесен кырып себерделәр. Ул гынамы әле? «План үтәмисез, кара такта» дигән булып, өйдән-өйгә йөреп, базларны актарып, бәрәңгегә тикле талап чыктылар бит.

— И-и кем, ни, Фазылбәк туганкаем. Күзәйдәге теге Тимергали дигән дивананы кара. Калхузчылар упалнамуч белән аны үзләренең ихаталарына кертми торгач, ул әзвир ни эшләгән? Районнан ГеПеУны чакырып китергән дә, әүвәл бөтен авылның ирләрен амбарга бикләткән, аннары йорт борынча йөреп, барча ризыкны талап җыйдырган, ди. Шуннан, ГеПеУлар киткәч, авылныкылар моннан сорый икән: «Ярар, син план үтәдең, «кара такта»дан төштең, ә без кыш буена ни ашыйк соң инде?» Теге болай дигән: «Сезнең һәрберегезнең лапаслары артыннан унбиш сутый җир бүлеп бирделәрме? Вәт шуны ашагыз соң, давай». Менә нинди әзвир җитәкчеләр кулына калдык, туганкаем.

— Аның каравы икмәк хәзер Бәләбәй, Бөре, Уфа, Эстәрле элеваторларында череп ята, диләр. Хак булса, ул черегән ашлыкны спирт заводларына озаталар икән. Әнә үткән атнада гына Иванайдагы, Спастагы бөтен урыс лычма исереп йөргән. Болар, ахры, бер яктан, ачлык белән кырсалар, икенче яклап, безне исертеп буарга исәп тота инде.

— И-и, Фазылбәк, алай гынамы соң? Ул Сталин, явыз, ил өстенә ачлык килгәнен күрә-белә торып, нихәтле ашлыкны читкә озаткан бит. Унсигез миллион ситнер, ди, туганкаем, унсигез миллион ситнер! Чит ил кулакларына бит ул, Фазылбәк, чит-ят буржуйларга! Шулар хәзер икмәк урынына ГеПеУныкылар утырып йөрсен өчен җиңел машиналар кай-

тарта, ди. Вәт әкәмәт! Ә монда бөтен Рәсәй халкы ачтан кырылып ята. Ни иман юк бу сәвиттә, ни миһербан!..

Ирләр әле озак гөрләштеләр. Зифада аларны тыңлап утырырлык куәт калмаган иде инде. Ул бер почмакта мәче сыман гына бөгәрләнеп йокыга да талды.

## 2

Бәләбәйгә икенче көнне, җир өстенә караңгылык тәмам иңгәч кенә барып керде алар. Йорт тәрәзәләрендә, урамнарда сирәк-мирәк кенә утлар яна, шуларга карап фикер йөртсәң, Бәләбәй эреле-ваклы таулар уртасындагы казанлыкка урнашкан бәләкәй кала икән. Бәләбәй — бәләкәй, кызык яңгырый бу...

Зифа үзләре барып кергән һәр урамның ике ягына да ялт-йолт карап барды. Төрмә кайда монда, төрмә күренмәсме? Аның газиз әтисе кайсы койма артларында интегә дә, иртәгә ул аны күрә алыр микән? Э-эх, әтиең белән күрешсәң һәм иртәгә үк аны алып кайтып китсәң иде лә ул!..

Бәләбәй кәрлә кешеләрдәй тәбәнәк, бәләкәй йортлы вак-вак урамнардан гына тора икән. Фәлән дистә зур-зур адәмнәрне ябып тотардай чәнечкеле биек коймалар күренмәгәч, Зифаның хәтта сөмсере үк коелгандай булды. Әтисен күрми калгандай хис итте ул үзен.

Сазлыкүлдәге Локман юлны бик белеп, җайлы итеп өйрәтеп биргән икән, Бөкре Хәсән атлы картның йортын тиз таптылар. Карт тар гына ихаталы йортның бик тә кысан бер бүлмәсендә яши булып чыкты. Фазылбәк иске-москы бишмәтләрне җәеп идәнгә сузылды. Зифаны мич башына мендереп яткырдылар. Монда кызу иде, Зифа төн буена диярлек керфек какмый чыкты. «Йокладың бит» дигән сылтау белән Фазылбәк аны калдырып китмәсә ярый инде берүк...

Юл кешеләре иртүк сикереп торды.

— Бу вакытта этләрне дә якын җибәрмиләр. Әфисәрләр төрмәгә сигездә генә килә,— дип, Хәсән карт кат-кат кисәтсә дә, Фазылбәк аның сүзләрен колагына да элеп карамады.

— Ризык дигәннәре йоклап яткан дөянең авызына үзе килеп керми, хәрәкәттә бәрәкәт,— диде дә Фазылбәк, юл буена саклап килгән күчтәнәчләрен төп-төгәл икеләйгә бүлеп, шуның бер яртысын аркасына салды һәм ишекне көндәшен сөзәргә җыенган үгез кызулыгы белән ачып юк та булды. Кофта-бишмәтләрен йөгереп барган көе кия-кия, Зифа аны урам башында гына, ниһаять, куып җитте. Үпкәләгән иде, эндәшмәде. Кире кайтасы бар...

Төрмә дигәннәре каланың читендә урнашкан булып чык-

ты. Мунча төнлеге шикелле кеп-кечкенә тәрәзәләрдән торган, өч катлы, карап торышка ук җансыз, шыксыз бина. Бөтен ягыннан да чәнечкеле, биек коймалар белән уратып алынган. Почмакларда — каравыл каланчалары, һәркайсында мылтык тоткан солдат.

— Мин белешеп чыгам, ерак йөрмә,— диде дә Фазылбәк әллә нинди тар капкадан кереп юк та булды. Капка артында сак торучы кеше бар иде, ахрысы, чыш-пыш килеп сөйләшкән тавышлар ишетелде, бераздан соң алары да тынды.

Зифа шушы капка тирәсеннән китмичә гел сагалап йөрде. Сәер икән монда. Капкадан әле күн куртка, әле соры шинель кигән хәрбиләр дә, гади киемлеләр дә минут саен диярлек кереп китә тора, ләкин кирегә бер кеше дә чыкмый. Әллә кешеләрне шулай бертуктаусыз йотып бара торган дию йә булмаса гыйфрит микән соң бу?

Берәр сәгатьтәндер, ниһаять, биек койма артында урак өстендәге сыман ыгы-зыгы купты, гөр-гөр килеп сөйләшкән әллә ничаклы ирләр авазы яңгырап ишетелә башлады. Хәсән карт кисәткәннәр хактыр, әфисәрләр тоткыннарны төрмә ишегалдына чыгардылар бугай. Капкада Фазылбәк кенә күренми. Кайчан чыга инде бу, кайчан чыга?

Зифа ярык ише әйбер эзли-эзли койма буйлап йөренә башлады. Йа Ходаем, тырышсалар, безнең илдә дә җиренә җиткереп эшли беләләр икән бит! Һичбер тишек, ярык, аралык юк. Әһә, бар икән шул!

Зифа бармак сыярлык ярыкка капланды да, ихатаның эченә кереп китәрдәй булып күзәтергә тотынды. Әнә эчтә әрле-бирле килеп зур абыйлар йөри. Кыяфәтләре теләсә кемне дә котсыз калдырмалы. Һәрберсе озын, әмма чыра сыман нечкә. Яңаклары, күзләре эчкә баткан, борыннары ишек тоткасы сыман тырпайган, ирен тирәләрен, иякләрен сакал басып киткән. Өсләрендәге киемнең бер рәте юк. Кайберләренең бишмәт-чалбарлары кырык ямаулы, икенчеләренеке әле аннан, әле моннан умырылып төшкән. Аякларына дәү итек йә ботинкалар киеп йөргән адәмнәр бар, такта кисәген табаннарына юкә җеп белән бәйләп йөрүчеләр бар. Валлаһи, карачкы дисәң дә карачкы бит болар! Әнисе аны Бәләбәйгә озатып калганда, «ул як урманнарда җиргә оя казып, узгынчыларны талап ятучы бандитлар бар икән, юлда сак бул» дип, бик елаган иде, менә шул әтрәк-әләмне тотып япканнардыр инде. Шулар инде бу, алайса, нәкъ шулар бу. Аның ыспайлыкны бик ярата торган әтисе бу хәлләргә төшмәс...

Төш вакыты үтеп киткәч кенә, капкадан Фазылбәк атылып килеп чыкты.

— Әтәйне күрмәдеңме? Әтәйне күрмәдеңме? — дип, Зи-

фа йөгереп килгән иде дә, Фазылбәк аңа күз тутырып та караш ташламады.

— Ярты капчык малны алып калдылар, җыен бирән тәре! Тагын икенче яртысын алып килмичә булмый инде.

Һавада шундый сүзләре генә эленеп калды, ә үзе янапешә Хәсән карт йортына йөгерде һәм элекке кызулыгын киметмичә бик тиз килеп тә җитте.

— Менә болар белән майлап-җайлап булса, мине Сөләйман белән очраштырырга тиешләр. Мужыт, атаңны да күрермен. Ерак китеп йөрмә!..

Фазылбәк шул рәвешчә янә юкка чыкты, Зифа исә тагын, лышык-лышык итеп елый-елый, барча койма ярыкларын санап-барлап йөрде.

Фазылбәк кабаттан көн кичкә таба авыша башлагач кына пәйда булды. Сүзләре күңелләрне телгәләрдәй ачы һәм ялы иде.

— Абыйны күрдем, ныклап сөйләштем мин. Абыйны күрешергә чыгардылар, ә атаңа рөхсәт юк, ди...

Куе караңгылык төшкән чагында да, Зифа әле һаман, япаялгыз көе, Хәсән карт бүлмәсендә үкерә-үкерә елап ята иде. Иплән кенә, шыгырдатмый ачып, ишектән чит-ят ирнең килеп керүен дә бөтенләй сизмәде ул. Теге кеше шырпы сызып янына килгәч кенә айныгандай булды.

— Син Зифамы? — дип сорады таныш түгел кеше. Кыз баланың куркудан телсез калуын күргәч, җитез-җәһәт кенә аңлатырга керешә.

— Төрмәдән мин. Кирәк чакта чыгып йөри алам. Әтәң җибәрде мине. Синең янга. Гариза алып килдем. Башглавсудка. Шуны чиста кәгазьгә күчереп язасың бар. Әтиеңнең эшен өр-яңадан карауларын сорап. Бала кеше язса, судьялар җебемәсме? Менә шулай диде. Вакытым күп түгел. Әйдә, тор, яз.

«Ә» дигәнче лампа кабыздылар. Зифа чиста кәгазь битенә тигез итеп рус сүзләрен тезде. Яза, кирәк булса әле тагын унны да, йөзне дә язачак ул. Тик әтисен чыгарсыннар, кайтарсыннар гына!

Чыгып киткән чакта, таныш түгел ир дә канат куеп китте:

— Булды, бу кәгазьне язгач, чыгаралар. Берәр айдан кайтыр әтиегез.

## 3

Май аена аяк басканнар гына иде, и кырылды, и чирләде халык!

Ачлык газапларының соңгы чигенә килеп җитүләре булгандыр инде, җир өстендә үлән-үсентеләр аз гына борын төртә башлауга ук, бөтенесе шуңа ябырылдылар. Нинди үлән-

не йолкыйлар, агулымы ул, түгелме — моны һичкем аралап тормады. Кулларына ни эләксә, авызларына шуны озаттылар.

Иң беренче булып Ленинградка укырга китеп барган Шәйсолтанның төпчек сеңлесе Бану аяк сузды.

— Балтырган дип, Яшке яланыннан кандала үләнен йолкып ашаган ул. Әүвәл коскан гына, аннан эче киткән. Менә шул эч җәфасы белән китеп барган да, ди.

Элеккерәк елларда төрле үлән җыеп, хасталарны озын кыш буена им-том итеп йөргән карт-карчыклар шулай сөйләделәр. Ә күрше-күлән «Гөлтуташ очынып йөри башлады, йөрәге янсын әле» дигән шикелле, тиктомалдан һаман да шул Әмир белән авыз чайкауларын дәвам итте.

— Әмирнең этлекләре инде бу, Әмир этлекләре. Семия башлыгы булып йөргән бердәнбер ир-атны әллә кайдагы Лелингыратка, бер тиенгә яраксыз инчилерлыкка укытырга җибәрәләрмени?! Юри эшләде бит ул моны, әйе, юри. Иске йортын шул ятимнәргә биргәненә үкенеп. Аның өч баш үләксә куяннарын суеп ашаганнарына үч итеп. Бетсен болар, Шәйсолтансыз калып коргаксыннар, диде. Менә иреште дә. Үзе дә шул өтермәсендә кәкрәеп катсын иде ул, ичмаса...

Мондый каргыш нахагын нахак та бит, ләкин ул Әмиргә түгел, ә аның төпчеге Ленага барып төште.

Гөлтуташ ул көнне дә, иске юрган тышлыгыннан теккән балалар күлмәкләрен төйнәп, һаман да шул үзенең туган авылы Аблайга ризык эзләп чыгып киткән иде. Тимерҗан белән Зифа мәктәптә чак. Вәзирә ике яше дә тулмаган Лена-ны иярткән дә Латыйфа куагы буена төшеп киткән. Ниятләре шул — яр буенда үскән нинди дә булса үләнне йолкып ашау инде. Чәрмәсәннең бу тыныч култыгы янына башка урам балалары да җыелып төшкән булган. «Мә, менә моны аша, менә бу тәмле»,— дип, бер-ике малай Ленага әллә нинди бер үлән сабакларын сыдырып ашатканнар.

Гаиләдәгеләр моны соңыннан Вәзирәне сөйләтеп белештеләр. Ә ул көнне, Зифа Күчәрбайдан кайтып кергән чакта, кеп-кечкенә, кибеп беткән Лена, тып-тын калып, сәкедә ята иде. Йөзе ап-ак, тәне дер-дер калтырый, күзләрендә газап. Ул берникадәр вакыт кына мәрткә киткән шикелле тын ята да, аннары кисәк кубып коса, төкерә башлый. Авызыннан ак күбеккә уралып ниндидер балчык кисәкләре, ап-ак орлык чыга.

Зифа шуларны кулларына алып карагач, тыны бетеп катты.

— Тилебәрән орлыгы түгелме соң бу, Вәзирә апакаем? Лена сеңелеңә ниләр ашаттың син?

Вәзирәнең үзенең дә һични аңламыйча тын торуын күр-

гәч, Зифа ике йорт аша гына яшәгән Сания әбиләргә йөгереп барып керде.

— Лена апаем үлә бит, әбекәем! Зинһарлап сорыйм, бер стакан гына булса да катык бир син миңа?!

Сания әбинең аяклары бүрәнә кебек шешкән, урыныннан да куба алмый икән. Зифа артына ут капкан шикелле үзе баз эченә чумды, балчык ниргәдә торган җамаяктан катык агызып алды. Ул янә ут капкандай йөгереп кайтып кергән иде дә, Лена, бичара, катыкны ике-өч мәртәбә дә йота алмый, шундук буыла-буыла коса-укшый башлый. Шул вакытта күзләре акаеп чыга балакайның, ыңгыраша да алмый.

Тагын ни кылырга да белмәгәч, чәче белән бар урамны себереп чыгарга да әзер торган Зифа ике күршедәге Нәҗип карт белән Зәбирә түтигә эндәшеп карады.

— Хәзер бөтен кеше чирли, һәммә кеше коса. Кадалмас сезнекеләр, — дип кенә сөреп чыгардылар.

Алардан ерак түгел генә йортта им-том белән шөгыльләнгән Гайникамал дигән карчык яши иде. Зифа шуңа чапты.

— Ярар, — диде карчык, һич каршы төшмәде. — Көздән җыеп куйган бөтнек белән андыз тамырларын гына эзләп табам да, хәзер килеп җитәм. Син көтеп утырма, бар, кайта тор.

Зифа тагын өйләренә чапты. Лена һаман шул көенчә хәрәкәтсез ята иде. Ләкин хәзер инде космый да, ыңгырашмый да. Карашын урам тәрәзәсенә таба төбәгән дә һичбер төрле җан әсәре бирми.

— Үлә күрмә инде берүк, сеңелкәем! Берүк үлә күрмә! Аннары мин әтәй-инәйнең күзләренә ничек күренермен?.. Ташлап китмә безне, сеңелкәем?..

Зифа шулай итеп ялварып карады, шулай өзгәләнде. Сеңлесенең гомерен сузасы, Гайникамал карчыкны көтеп җиткерәсе килде. Ләкин юк, юк, ул убырлы карчык та алдады, барыбер кермәде шул...

Кич әнисе кайтып кергән чакта, сабый Ленаның тәне суына башлаган иде инде...

## 4

— Авылга пушты килгән икән, — дигән хәбәр төш вакытында ук ишетелсә дә, Гөлтуташка аны Тимерҗан, көн инде тәмам караңгылангач, анда да әле су буенда бергә агач тоткан яшьтәш малайлары авызыннан гына эләктереп алып кайтты.

— Фазылбәк абыйларга Уфадан мөһерле хат килгән. Пушталиун апа аны кул куйдырып кына калдырган, ди. Фазылбәк шундук юлга җыена башлаган. Әллә Бәләбәй-

гә, әллә Уфаның үзенә үк бара, ди инде, анысын кем дә белми...

Гөлтуташның эченә ут төшкәндәй булды. Каһәр генә суксын, бездән качып-посып кына тагын Сөләйман абзыйсын коткарырга бара бит бу! Теге юлы ике капчык мал төяп киткән, дигәннәр иде. Аннан соң да тегесен-монысын сатып байлык җыйды бугай. Хәзер шуларны биреп судияларны сатып ала да Сөләйманның эшен яңадан каратырга бара инде бу. Тукта, шомарма әле! Сөләйман белән Әмир — икесе бер тәртәдә. Хәзер барып иснәнәм дә бу юлы да Зифаны койрык итеп тагып җибәрәм мин сиңа...

Очына-очына шулай уйланды да Гөлтуташ Фазылбәкләр йортына йөгереп барып җитте. Валлаһи, хак икән, өй хуҗасы юлга җыенып ята.

— Әйе, барам,— диде ул, бер дә яшермичә.— Сөләйманның эше кабат каралачак. Сезнекенме? Ә мин каян белим? Синеке камунис бит. Аны Шаһи-Морат камисар белән бер кыршауга утырталар икән, дигән сүз дә йөри. Татар камунислары нindидер Туран дигән дәүләт төземәкче, Рәсәйдән аерылып чыкмакчы булганнар, имеш. Кыскасы, әллә нинди «солтангалиевчеләр» инде шунда. Аларныкын кемнәр аңлаган да, кемнәр ерып чыккан? Партиягә кермәсен иде, вәт менә шул.

Гөлтуташ тупсага сыгылып төшеп үкерә башлагач кына, Фазылбәк кинәт айныгандай булды.

— Бәрәч, тукта, тукта, үкерми тор әле. Соң, бүген сезнең Әбелсаттар абзагыз да нindидер хат алган бит. Аңа да кул куйдырып тапшырганнар, диләр. Монда балавыз сыгып утырма, абзаң янына сыптыр. Язмыш — шайтан бит ул. Бактың исә сезне дә шулай кабат судка чакырулары бар...

Гөлтуташ Әбелсаттарлар йортына канатланып барып кергән иде, тегесе үзе Гөлтуташны эзләп чыгып киткән икән. Ялгыз хатын янә канатлана-канатлана үз өенә очты. Йөгереп кайтып керсә, балаларның һәммәсе дә башларын түбән иеп, кара күмергә охшап утыралар. Әбелсаттарның да йөзе өстен калын боз каплаган чоңгыл төбе сыман, анда бертөрле дә нур, җылылык әсәре юк. Гөлтуташ тупса аша атлап керүгә үк, карчыга шикелле җилпенә-җилпенә аңа ябырылды.

— Нинди выласлар өстеннән жалу язып ятасың син, минең черегән нәрсә?! Нинди «судиялар хата җибәргән дә, райкум якламаган» дигән сүз ул? Нигә шаһитлар исемлегенә мине илтеп тыктың? Әмир имансыз гына эләгү җитмәгән, инде мине дә өтермәдә черетмәкчемени?! Яучы җибәреп, кодалап алган килен түгел әле, мин хәзер синең иманыңны киям!

Әбелсаттар йодрыкларын усал төйнәп, тәкерек чәчә-чәчә өстенә килә башлагач, Гөлтуташ ис-акылын җуеп ишеккә ябырылды. Артыннан ук өйалдына әллә таба, әллә казан чәчрәп очып чыкты. Өй эчендә балалар чәр акырды. Ә баскыч төбендә дөньясын вата-сыта Әбелсаттар япа-ялгыз көе сүгенеп йөрде.

— Эшне кабат карау билгеләткәннәр, судка бармакчылар. Бармый торыгыз әле, анагызны сатыйм! Әмирне суырып алыр идегез дә мине илтеп тыгар идегезме? Тыкмагыз, болай да элмәктә мин. Йә төн саен Хәби белән Гайсә килеп буа, йә Илмурзин. Тын алмалы түгел. Энекәш-фәлән дигән булып, пычак асларына барып ятасым юк. Дөньяны ул болгатты, әҗерен дә хәзер үзе алсын.

## 5

Уку елы дигәннәре ахырына якынлаша башлаган иде инде. Менә тагын ике-өч атна үтәр дә Зифа инде алты класс белемле галиҗәнап булыр. Мондый чорда алты класс белем аз түгел ул. Төркәйдә андый белемгә ия тагын берәр кеше бар микән әле? Рөстәмбәк балаларын, Гәрдәннеке белән Йосыф балаларын гына каядыр Эстәрле ягына барып укыганнар, диләр иде. Аннары шул Әхтәм мулла малае Хәлил Уфаның үзендә, бик данлыклы «Галия» мәдрәсәсендә укып йөргән булган. Хәзер аларның бөтенесе китеп бетте инде. Димәк, Зифа бүген авылда иң беренче, иң белемле кеше! Күчәрбайдагы бу мәктәптә тагын бер ел гына укып, аны очлап чыгасы иде дә, тизрәк-тизрәк бу Төркәйдән китеп олагасы иде!

Зифа, әнә шундый хисләр кичерә-кичерә, әллә нинди хыяллар белән очына-очына, ике авыл арасында йөгереп йөрде. Ач көенчә юлда интегүләр бер дә рәхәт түгел, ләкин һаман да шул аны киләчәккә өмет — читкә чыгып китү дәрте куалап йөртә иде.

— Усманов абый каяндыр ит тапкан, соңыннан өмәчеләрне сыйлау була икән,— дигән вәгъдә ишетелгәч, Зифа беркөнне мәктәп стеналарын, тәрәзәләрен юарга калган иде. Вакыт сизелмичә дә үтеп киткән икән, Зифа Төркәй юлына аяк баскан чакта, кояш офыкка якынлаша иде. «Ярар, күрмәгән юл түгел, мин мондагы һәр чокырны, һәр түмгәкне беләм» дип, үз-үзен юата-юата, каударланмый-нитми, үз көенә генә атлады да атлады ул.

Әхмәт авылының иске зираты яныннан үткән чакта, көтмәгәндә алдында, җир астыннан калыккан шикелле, олы гәүдәле бер ир пәйда булгач, Зифа, бүре капкынына баскан кеше сыман, капылт катып калды. Бу ир кымшанмый-нит-

ми, йөзен-фәлән аерырлык түгел. Балбал да балбал инде. Ләкин иң гаҗәбе шул — ул үзенең буе-сыны, басып торышлары, томан артындагы килеш-кыяфәте белән нәкъ әтисе сыман. Аның каршына торып йөгерәсе, куенына барып сарыласы килә. Куянйотар елан сайлаган корбанын шулай сихерләп үзенә тарта, диләр. Нинди галәмәт бу?

Билгесез ир озак көттермәде, урыныннан кузгалды да Зифа янына үзе атлап килде. Багана шикелле каршына килеп баскач, Зифа имәнеп китте. Йа Ходаем, кайчандыр әтисен ихаталарына килеп кыйнап киткән Хәбинең бертуган энекәше Песәй Гайсә бит бу. Аны селәүсен яисә песи шикелле сиздерми генә килеп каравылчыларны суя белгән өчен, Әбзәндәге ат карагы Каюм да кайчандыр үзенең шайкасында тоткан икән, дигән байтак сүзләр йөрде. Авылдагы кызлар карамагач, шушы Гайсә берзаманны тавык тотып баскан, шуңа күрә үзенә Кара тавык дигән кушамат тагылып калган, дип тә сөйләделәр. Хакмы, юкмы — бар, тикшереп кара. Ә хәзергә менә, җаныңны суырып алырга килгән Газраил шикелле, каршыңда тора ул. Ияк-яңакларын дуңгыз төге сыман сакал баскан. Күзләре кай җиреннән каптырып алыйм микән дип, теш шыкырдаткан җанварныкы шикелле ялт-йолт килеп тора. Сулыш алуына кадәр чабышкыдан кайткан атныкы шикелле.

— Көчлимме үзеңне? — диде дә Гайсә капылт кына Зифаның кулыннан каптырып алды. Зифа авыз ачарга өлгергәнче, икенче кулы, кызның изүе аша үтеп, аның шәрә имчәкләрен чытырдатып кысты. Зифа күкрәкләрен ике куллап кочкан гына иде, Гайсәнең бушап калган кулы шул мизгелдә итәк астына ук шуышып кереп китте.

— Кар-ра-вы-ыл, кар-ра-выл! — дип, Зифаның чырыйлап кычкыруы исен алды бугай, Гайсә, утка пешкән шикелле кабаланып, кулларын тартып алды. Шуннан файдаланып, Зифа артыннан бүре куган болан җитезлеге белән авыл ягына очты. Артыннан куа чыкса, Гайсә, һичшиксез, өлгерәчәк иде. Ләкин ул үзенең этлеген иртәгә дә кылып буласына ышана иде бугай, артта тамак ярып кычкырган тавышы гына яңгырап калды.

— Кайтып әниеңә сөйләнәсе булма, юкса бөтенегезне суям!..

Ярсып елый-елый йөгерүдән кызарынып-пешеп кайтып кергән бала йөзендәге хәвеф-хәсрәт утын ана кеше сизми каламы соң?!

— Нәрсә булды, кызым? Әллә бәла бармы? — дип, ул кызын иңнәреннән кочып алган иде, Зифа гына ачылып китәргә бер дә ашыкмады. «Бөтенегезне суям, бөтенегезне!» дигән янау, чүкеч белән китереп суккан шикелле, чигәләрен

төйде. Юк, хакыйкатьне хәтта газиз әнкәсенә дә әйтә алмый икән бит ул, әйтә алмый икән.

— Юлда бүре күрдем. Әхмәт зираты янында утыра иде. Юл уртасында. Мине көткән сыман...

— Ярар, укырга йөрмәссең бүтән, балакаем. Укыганы җиткән. Кыз балага уку түгел, җүнле ир-ат кирәк. Кыз баланың бәхете ирдән аның.

Әнисенең болай юатуы Зифа өчен ачык ярага тоз сипкән шикелле генә булды. Янә ярсый-ярсый елый башлагач, үзенең әнисен этеп җибәрүен сизмичә дә калды.

— Юк инде, бер бүре түгел, йөз бүре сагаласа да, барыбер чигенмим мин. Укыйм дигәч укыйм. Әтәй шулай кушты...

Икенче таңда янә Күчәрбай юлына чыккан гына иде, Әхмәт авылы буендагы сыртны үтүгә үк, бу юлы инде аның каршысына Хәби-Хәйберахман килеп чыкты. Йөзендә-кыяфәтендә бернинди усаллык, мәкер чаткылары ялтырамый иде. «Әһә, Кара тавык өчен гафу үтенергә килгәндер әле бу» дип уйлап гайрәтләнде дә Зифа хәзер инде монысының каршына үзе эре-эре, гаярь басып китте. Тик ялгышкан икән.

— Гомер уздырып, чабата туздырып ник укып йөрисең инде син? — дип, һич тә көтелмәгән яктан сүз башлады Хәби.— Инәңә мәшәкать ясыйсың. Калхуз эшенә чыгып инәңә булышсаң, гаиләгә файда килер иде. Укып кем булырсың? Синең эше ятимә хәерчеләр кемгә кирәккән ди?..

Зифа тешләрен кысты, бер сүз эндәшмәде. Хәби моның тешләклеген тоеп алды бугай, күзләрен Күчәрбай юлына юнәлтеп, Зифаның йөзенә бер дә төбәлмичә генә, салмак тезеп китте.

— Бу юл белән, туры юлдан йөрмә син, апаем. Яхшылык белән әйтәм. Бу арада йөрмә. Олы агачны аударганда, аста калып сытылачак вак-төякне җәлләп тормыйлар ул. Ие, тиешле кеше үзе җавап бирсен, ә син буталып йөрмә. Читтән урап йөре, әнә тегеннән, Яшке сырты буйлап. Бу юл безнеке. Син бу юлдан йөрмә. Ие, бу арада йөрмә.

Зифа аның быдылдавыннан һични аңламады, шуңа күрә бераз гына түзеп торды да Күчәрбайга таба атлап китте. Мәзәк, бертуганнарның чирләре дә бер үк төрле икән. Хәбинең арттан кычкырып калган тавышы ишетелде.

— Син бу юлдан йөрмә. Юкса Гайсәгә әйтәм. Тавык сыман иттереп тапалар үзеңне...

## 6

Суд ишеге аша атлап чыккач, иң беренче булып Сөләйман сүз кушты.

— Йә, башта берәр кибеткә кереп юабызмы, әллә маржа

табып куна калабызмы? Төрмәдән көн саен котылып тормыйлар. Тота-каба авылга чапмассың бит инде?

— Син миңа ачуланма, Сөләйман,— дип нык көттереп кенә сүз башлады Әмир.— Марҗалар да эзләмим, авылга да чапмыйм. Син котылдың, ә мин котылмадым әле, Сөләйман. Койма артындагы төрмә ерунда ул. Менә мондагы төрмәдән качып котылу кыен.

Әмир ачу белән сулъяк күкрәгенә сугып-сугып алды. Сәер, хәтта аның күзләре дә сагышлы, дымлы иде.

— Мин бик үк дөрес яшәмәдем бугай. Минем гомер ашлык җилгәргәндәге кибәк сыман читкә-бушка очып әрәм үтте бугай,— дип дәвам итте ул.— Мин кайдадыр, кайчандыр нык абындым, ахры. Миңа ялгыз калып уйланырга, үз-үземне аңларга кирәк.

Сөләйман ике кулы белән ботын чабып куйды.

— Соң, сиңа «сөекле» хөкүмәт ярты ел буена уйланырга җай бирде бит инде. Шул җитмәгәнмени?

— Төрмә — ул үз ирегең, үз ихтыярың белән уйлана торган урын түгел. Анда син — тоткын. Анда уйлаганда да шул тоткынлык турында гына уйланасың. Бабайлар ничек дигән әле? «Былбыллар читлектә сайрамый» дигәннәрме? Вәт менә мин дә шулар кебек инде. Камерада чакта мин үткән тормышым турында да, киләчәк хакында да әллә ни уйламадым. Төрмәдән котылдым. Хәзер миңа иректә көенә, ялгызым көенә бар гомерне күз алдыннан янә кичерергә, уйланырга кирәк. Ачуланма миңа. Син монда кал, ял ит, ә мин япа-ялгыз көе генә юлга чыгыйм әле. Ат-фәләнгә утырмыйм. Төркәйгә җиткәнче җәяү кайтачакмын. Әле синең мине куып узуың да бар... Мин атлый башлыйм. Хушлашмыйбыз, бигайбә, Сөләйман...

Авылдашы башын чайкап гаҗәпсенеп калды, Әмир капчыкка тутырган кечкенә төенчеген җилкә аша сыртына аскан көе, акрын гына атлап юлга чыгып китте. Табигать бик матур, күзләре дә гүзәллекне сагынганнар иде. Шуңа күрә бөтен тирә-юньне кат-кат күздән кичереп, ашыкмыйча, салмак атлады ул.

И табигать! Синең дә шушы кадәр камил, талымсыз, патшабикә чакларың бар икән лә! Күр әле син, ике якта горур гаскәр сыман тезелеп киткән урман. Талир тәңкәләрен таккан зифа каен кызлары, билләрен каеш белән буган, күкрәкләрен тын алырга дип киергән нарат егетләре, тәүге тапкыр аулак өйгә килгән шикелле оялып кына утыручы сөян белән зирек агачлары, битләренә мул итеп иннек яккан мут кызларга охшаш юкә, камырлыклар, чәчәкләрен калфак итеп кигән әллә шомырт, әллә элмәлекләр. Их, табигать җанашым! Беренче мәртәбә, анда да көттереп кенә буйга узган яшь ха-

тыннар кебек назлы да, ягымлы, горур да син бүген! Исакылны җуеп, сабый бала сыман итәгеңә капланып бер эрисе, иркәлисе һәм иркәләнәсе килә синең кочагыңда! И-и, нинди гүзәл яклар бар бит! Үз илемә кайткач, ятим бала булып көн күргәнче, синең кочагыңа килеп сыенырга, синнән сихәт алып сафланырга кирәк миңа. Кыйбласын, илен, иманын, кальбен җуйган бер балаңны кочагыңа ал да сакла, якла, савыктыр син мине!

## 7

Әбзән авылын үтеп, каршысында Кучәрбай ачылгач, Әмир, әүвәл әле хатирәләргә бирелеп, җиңүче тантанасы белән елмаеп бара иде. Әһә, заманында менә шушы юлда Каюм каракны сагалап йөрде бит ул. Соңыннан Кучәрбайдагы Хөллә коммунист белән бер дозорга басып, биш бертуган Илмурзиннар арасында иң башкисәр булган Мәхмүтне сагалап ятты. Каптырды бит ул аны капкынга, ычкындырмады бит. Әнә теге төштә, элек-электән «Бүре чокыры» дип йөртелгән ерымда каптырды ул явыз башкисәрне. Шап тегенең муен тамырына мылтык түтәсе белән. Әйлән дә төш, Мәхмүт. Шулай кирәк иде, шул төс иде ул каһәр суккырыга!

Фәлән ел элек булган хәлләрне әле генә кылган кеше сыман, Әмир хәтта барган көйгә сикергәләп тә алды. Хәзер җитәчәк ул урынга Әмир, хәзер барып җитә...

Шул мизгелдә Бүре чокырының яр читендә Әмир әллә нинди шәүләләр күргән кебек булды. Әллә ике кеше, әллә ике җанвар чокыр буйлап бер куак астыннан чыгып икенче куак күләгәсенә качкан сыман булды. Кешеләр булса, болар, яртылаш иелеп, дүртаяклап диярлек йөгереп үтте бугай. Башлары түм-түгәрәк, койрык дигәннәре бөтенләй юк, өсләрендә дә тире түгел, кием иде бит, нәгъләт кенә төшсен!

Әмир, тукталып, күзләрен кат-кат уып карады, керфекләрен кыса төшеп әле теге, әле бу куак төпләрен ялт-йолт айкап чыкты. Юк, куак төпләреннән һичбер төрле җанварны төсмерләп булмый иде. «Курыкканга — куш, койрыгы белән биш. Әллә күземә күренде генәме соң?» — дип, күңеленнән генә сүгенеп тә алды.

Мәхмүт төрмәдә аның сулъяк чигәсенә китереп типкәннән соң, Әмирнең бер күзенә яртылаш ак сауган, шуңа күрә ул хәтта әле үрдәк-тавык йомыркасын да илле-алтмыш адымнан аермачык итеп шәйли алмый иде. «Ярар, бернинди шәүләләр дә юктыр, күземә генә шулай күренгәндер»,— дип нәтиҗә ясады да Әмир, туктаган җиреннән янә атлап китте. Ләкин хәвефләнү-шөлләү барыбер дә үзенекен итте, Әмир Бүре чокырын да, Кучәрбай урамнарын да читтән урап уз-

ды. Бердән, ул алты ай буена камерадагы тоткындашларының күз алдында туктаусыз елкылдавыннан да туеп беткән, аннары Күчәрбайда да күрергә атлыгып торган кешесе юк иде. Яшке яланы өстендәге сырт буйлатып кына Әмир Төркәйгә юл тотты.

Сырт өстендә тигез бер рәт ясап тезелешеп киткән сәрви куаклары янына килеп җиткәч, явыз бүредән качкан кыр куяны сыман, Әмир шулар ышыгына кереп утырды да, сыңар күзен кысып, Төркәй өстенә еракта күз ташлады.

Исәнме-саумы, авылым! «Кендегем сиңа береккән» дип сөйләүләр хактыр инде. Мин дә ничәмә-ничә тапкыр бәхет эзләп китеп дөнья дәрьясында айкалдым-чайкалдым да, дулкын бәргән-каккан йомычка кисәге сыман, янәдән синең ярларыңа әйләнеп кайтып аудым. Элекке кайтуларымда назлы бала итеп иркәләп йөртмәсәң дә, үги итеп читкә дә типмәдең син мине. Барыбер ничектер җайлашкан, тынышкан идек әле. Әмма менә бу юлы кабул итәрсеңме дә, кирәкме мин сиңа? Һәм, гомумән, синең куеныңда миңа урын бармы?..

Әмир, авыр сулап, җир өстенә аякларын сузды. Кесәсендә әллә кайчаннан бирле кагылмыйча кайткан тәмәке бар иде. Гәзит кисәге табып, шуны кырып салды. Тәмәке тән тиреннән дымланып беткән икән, тирә-юньгә ачы төтен исе таралды. Җиңелчә ютәлли-ютәлли, Әмир янә авыл өстенә текәлде, янә уйга калды.

Чынлап та, бүген Төркәйгә кирәк микән соң ул? Хыянәтче ирне хатыннар кабул итә, ә менә хыянәтче бала, аның күкрәгенә менеп бүген мәҗүсинекеләр кебек тол да, ирдәүкә дә булып яшәп яткан ялгызак анага кәкәй иткән бала кабат кирәк микән?

Әйе, әйе, Рәсәй буйлап сибелгән авылларның һәркайсы да хәзер яклаучысыз калган, теләсә кайсы баскынчы килеп талап китә торган, ачык изүле, мәсхәрәләнгән-тапталган япаялгыз ана хәлендә бит. Кулларына сәнәк-чалгы тотып аны үз уллары, үз нарасыйлары яклап чыгарга тиеш тә бит. Әмма... әмма Әмир сыман соран хыянәтчеләр һәрчак табылып тора. Соран җәнлек сыман, хәвеф туган саен, төс алыштырып кына торсалар түзәр идең әле. Юк шул, хакимият алышынган саен, хыянәтче уллар үз анасын талый, бәгырен өзеп ала, аны сансыз мал урынына чыбыркылап йөртә.

Эх, Әмир, Әмирҗан! Менә син дә Ленин шулай куша, Совет властена ярыйм, дигән булып, әүвәл аның балаларын ана күкрәгеннән аерып алдың. Ничәмә-ничә гасыр буе җир белән туенып, җиргә кендекләре белән берегеп яшәгән авылдашларың Төркәйнең үз эчендә дөм ятимә калды. Аннары Төркәй үзе дә ирен генә түгел, балаларын да чәчеп-җуеп бетергән, өстәвенә әле узгынчы бер явыз көчләп киткән тол

хәленә төште. Кешелеген җуйган ана кебек назы да юк аның бүген, дәрте-дәрманы да. Әллә тагын да явызрак ир килеп көчләячәк аны, әллә үзе шикелле үк үксез бер ир каршысына килеп тезләнәчәк — аңа бөтенесе дә барыбердер сыман. Әнә малын-җирен талап күмәк келәткә япканнар. Изүе ачык, күкрәге салынып төшкән. Талыйсыңмы аны, үбәсеңме — ул битараф.

Бу авылга мин кирәкмәм инде. Елый-елый яше кибеп беткән, талап имүдән ике имчәге тиң коргаксыган, дәрт-дәрмансыз, көч-егәрсез анага узгынчы баскын, явыз ирләргә ияреп үзен көчләгән иман-миһербансыз улы кирәкмени? Юк, куенына кертмәс, елмаймас ул аңа. Туганнары да аны барыбер гомер буе кагып-сугып яшәр. Инде гел какмасалар да, бөтенләй күрмәмешкә салынсалар да, үзең яккан учак эчендә яшәү яшәүмени? Юк, хокукы юк аның биредә нигезләнергә, биредә тукталырга.

Үзеңне әйткән дә юк, хәтта балаларыңа да гомер буе сан булачак түгел. Монда калма, чык та олак инде син, Әмир хыянәтче!

Юкка гына газиз балаларымны сәвит камытына китереп тыктым. Партия дигәннәре минем камытым булмаган икән бит ул. Аңа да бит әнә ярамадым. Төркәйне җимереп, талап бетергәнче кирәк идем әле. Камчы булып йә бер җәллад булып. Авылдашларны күмәк көтүгә куып кертү өчен. Авылның бөтен иманын-сүлен коргаксыту өчен. Ә аннары мин көпшәдән чыгып очкан пуляның гильзасы кебек булдым. Яу үтеп киткәч, чормадан табылган сынык хәнҗәр сыман булдым. Елганы йөзеп чыкканнан соң тишелгән иске көймә кебек булдым. Тагын әллә ниләр. Ә иң мөһиме — ике тегермән ташы арасына эләгеп изелгән-сытылган бөртек кисәге мин. Япа-ялгыз бөртек. Бер олауда килеп, бер ларга салынган меңәрләгән, миллионлаган бөртекләрнең берсе булсам, әле түзәр идем. Бөтен халык белән бергә бит, күмәк язмыш белән, дип юаныр идем. Ә болай — беркемгә дә кирәксез, һичнигә кушып булмас алама солыча мин. Чәйнәп төкерелгән солыча. Үзәге суырып алынган, зиннәтлеген җуйган кадерсез зат. Сине хәзер елганың бер генә яры да кабул итмәс инде. Башыңны ал да олак, сиңа шул төс. Шуңа күрә исәнме һәм мәңгегә хуш инде, газиз туган авылым!

## 8

Баш түбәсенә арткы яктан авыр күсәк белән китереп оруларын Әмир тоймады да. Ул һушына кабат килгән чакта, әзмәвердәй дүрт ир аны дүрт саныннан тотып ялан буйлап күтәреп бара иде. Җир өстенә куе караңгылык яткан, мөга-

ен, төн уртасыдыр. Кемнәр болар, кая алып бара — берни шәйләрлек түгел.

Аңга килгәч, ыңгырашып аваз салды бугай, Әмирнең уң кулыннан күтәреп баручы шәүлә капылт туктап калды.

— Тавыш бирде түгелме соң, ирләр? Дөмекмәгән икән ләбаса бу явыз!

— Ы-һы, бар, тот, дөмектерерсең син ул хәсисне алай җиңел генә. Мин аны Бәләбәй төрмәсендә атна буе издем, ә ул кан косып та карамады, пакыч!

— Алайса, «издем» дигәнең шул бала бугы сыман сыек булган инде. Минем кулга килеп капкан булса, моментында кан костырыр идем!

— Менә каптырдык бит. Изеп күрсәт давай...

Әһә, төрмәдән качкан Мәхмүт Илмурзин белән Хәби кырхабурның энекәше Кара тавык Гайсә сөйләшәләр. Кара тавыкның имансызлык чиген билгеләве читен, әмма башкисәр Илмурзинның элмәгеннән исән-имин котылырмын димә.

— Әт-тәк, ни пычагыма дип күтәреп барабыз соң әле без моны? Исән икән, кабере буласы күл буена чаклы үзе атлап барсын,— диде дә Әмирнең бер аягыннан күтәргән өченче ир телгә килде. Шул мизгелдә үк махсус әмер булган шикелле, «шалт» иттереп, яралы ирне җиргә ташладылар. Әмир бу тавыш хуҗасын да танып өлгерде. Мәхмүт белән Кара тавыкка юлдаш булган кеше — моннан ике ел элек хатынын колхоз үгезе сөзеп үтергән буйдак Харис иде. Әһә, Әмирнең кабере дә күл генә буласы икән. Бу Харис та хатыны өчен үч алырга ният иткәндер дә шул максаттан теге ике башкисәргә кушылгандыр инде. Ярар, монысы да мәгълүм. Әмирнең җанын кыярга исәпләгән дүртенче канечкеч кем генә булыр микән?

Әмиргә аның тавышын көтеп җиткерергә ирек бирмәделәр.

— Ни пычагыма дип ята соң әле бу хәсис? Әйдә, тор, ананңны сатыйм, кабереңә атла! — дип, усал ысылдады да Кара тавык җан ачысы белән корбанының кабыргасына китереп типте. Аңа албастыдай шөкәтсез карачкы булып баскан янә өч ир кушылды. Әмирнең тәне беренче тибүләрне әле тойган иде, ул аларга ыңгырашу, ухылдау авазлары белән җавап биреп барды. Бераздан тәне авыртуны тоймый башлады, ахры, җан әсәре бетте. Тугайлыкта байтак вакыт буе лас-лос килеп дөпелдәгән һәм ирләр катлы-катлы итеп сүгенгән авазлар гына яңгырап торды.

Телсез-җегәрсез калса да, Әмир аңында иде, шәйләп-сизеп ятты. Менә аны кабат күтәрделәр дә таудан түбәнгә алып төшеп киттеләр. Ут кебек янган йөзенә, тәненә салкынча, җиләс һава бөркелгәндәй булды. Нинди дә булса су буедыр

инде бу, гадәттә, агымсу елга ярында төнлә һава җиләс була. Ялгышмаган бугай, бутамаса, һаман да шул Мәхмүт белән Гайсә сөйләшәләр.

— Әйттем бит мин сиңа, баштук Торна күленә аппарыйк дип. Синең үз кырыгың-кырык, монда алып килдең. Ушлы кеше күт янындагы Латыйфа куагына мәет саламыни? Таштан ычкынып өскә калкып чыкса, эте дә, бете дә күрәчәк бит аны.

— Валлаһи, хатын-җәмәй булдың, әй, чәйнәндең инде. Тегендә калыкты ни дә, монда калыкты ни — барыбер түгелмени? Торна күленә хәтле күтәреп йөрергә кәҗүнни кулларым юк. Әйдә, суябыз да чумдырабыз шушы күлгә генә.

— Юк, җәмәгать, монда килешеп бетми,— дип, ниһаять, дүртенче ир бәхәскә таяк тыкты. Тонык ишетелсә дә, Озын Закир, Хәлфә Закир тавышын хәтерләтә ул. Ләкин Әмирдә җегәр беткән, һич ачыклый алмый.

— Монда көн саен ярты авыл халкы кер чайкарга төшә. Әмир мәетенең үләксә кисәкләрен тәндә йөртеп булмас, әйдә, чукынсын, Торна күленә илтик...

Тагын кайсыдыр урында ком-таш өстеннән өстери-өстери, кайдадыр, бик югарыга күтәреп, һавада чайкалдыра-чайкалдыра, Әмирне Торна күле буена алып киттеләр. Ләкин монда да гүр иясе булырга язмаган икән әле. Авылны чыгып ярты чакрым буе ара үтүгә үк, колакларны сытып-ватып Гайсә ысылдады.

— Кадалып кына китсен, кара, Торна күле янында колхоз көтүе йөри. Кайсы миңгерәве генә шушы җиргә көтү керткән инде?!

«Миңгерәүләр» берәү генә түгел, икәү икән әле. Гыжылдап атлап килгән тавышлардан ук сизгәннәрдер инде, берзаманны аз гына тарала башлаган караңгылык эченнән ярым сакау Ләпәй белән унбиш-уналты яшьләрдәге, Ләпәй сыман ук ярым җүләр, ярым томана Фәхри пәйда булды. Ирләр кадак белән кадаклап куйган шикелле бердәм катып калды.

— Мәт-тәт-терә тә көт-тет төния-ну. Мән-сә-күр, сә-мин,— дип тезеп китте Ләпәй. Үзе шундук гаепле кыяфәттә чигенә дә башлады.

Мәхмүт Илмурзин шул чагында гына ушка килде бугай. Ул Әмирнең йөзен каплый төшеп басты да, азат кулын яман болгый-болгый, Ләпәй тарафына ике-өч сүз ыргытты.

— Син безне күрмәдең, без сине. Дөрес, Ләпәй, дөрес. Мәгәр кара аны. Авызыңны ачсаң, мин сине өеңә кереп суям!

Илмурзин соңгы сүзләрен әйткән чакта, Ләпәй белән Фәхри инде юкка чыккан иде. Артта янә корык тавышлы Закир телгә килде.

— Вәт тискәре бу Әмир персидәтел! Ипләп кенә, тавышсыз гына дөмектерергә дә җай бирми бит, авызына төкерим!

Шул чагында Мәхмүт Илмурзинның атаманнарныкы сыман кырыс әмере һәммәсен хәл итте.

— Ярар, Торна күле дә моңа ярамаган икән давай Табор күленә. Ичмаса, авылдан да ерактарак булыр. Үләксәсе авыл сасытып ятмас...

Янә ике чакрым буе бара-бара Әмиргә хәл керде. Моны сызак кына булып сибелә башлаган таң яктысында башкисәрләр дә сизеп алды бугай. Дага сыман булып сузылган күл ярына китереп салуга ук, аның каршына иң беренче булып Гайсә килеп тезләнде.

— Суд гафу итте дә исән-сау калдым, дип сөенгән идеңме, Әмир? Сәвит күтен, ай-яй, күп яладың. Әйе, сәвит суды гафу итәр сине. Мәгәр менә без, синең авылдашларың, сине мәңге-мәңге гафу итәчәк түгел. Күп котылдың син моңа хәтле үлемнән, ай-яй, күп котылдың. Әхтәм хәзрәт йортында утырган чагында аттым мин сиңа. Күчәрбайдан кайткан чакта сагалап торып аттым. Икесендә дә тидерә алмадым мин. Былтыр көзен Уфадан кайткан чагыңда да сагалап торган идем, син тагын алдадың, Усман юлыннан киттең. Мәгәр бүген котылу юк сиңа. Мин сине үз кулларым белән суеп шушы күлгә салам. Чегәннәр күленә, ишетәсеңме шуны? Илсез-җирсез чегәннәр күленә! Сиңа шул гына төс.

Артта Мәхмүт Илмурзинның усал, кыргый тавышы яңгырады.

— Ул минеке. Кул тидерәсе булма!

Гайсә үз өстенә гөнаһ алырга бик атлыгып тормый иде, күрәсең, ул «ихтыярың — бәрәңге» дигән шикелле, җилкәләрен селкетеп кенә, читкә китеп барды. Корбанны якты җиһан белән хушлаштырырга килгән мулла кыяфәтендә аның урынын Озын Закир алды. Ни галәмәт, бу юлы да аның кулларында нәни Коръән иде.

— Үзең кылган гөнаһларың өчен үкенү хисләре кичерәсеңме? — дип сорау бирүе дә озын гомер чиккән, зур тәҗрибә җыйган мулла-мунтагайлар тавышын хәтерләтте. — Алайса, үзеңнең партияңнән, сәвитеңнән баш тарт та Коръәнне үп давай.

Әмир тулысынча акылында иде. Гәүдәсен кыймылдатырлык, авыз ачып сүз әйтерлек җегәре булмаса да, ул күзләрен шар ачып Озын Закирның йөзенә карап ятты. Әмирнең күңелендә энә очы кадәр дә бер үпкә юк, ул Закирга карата ачу-нәфрәт тотмый, йөзе исә кунак каршыларга дип капка төбенә чыккан хуҗаныкы сыман тыныч, чиста иде.

— Мә, Коръәнне үп давай, иманыңны кайтар! — дип

ярсый-ярсый, Закир Коръәнне Әмирнең иреннәренә төрткәли башлады. Закир ярсыган саен, Әмир иреннәрен кыса гына барды.

— Ярар, юк белән булышма давай. Нинди Коръән, нинди иман ди ул? Камуниста иман дигән әйбер буламыни? Пүртәфил артыннан куу бар аларда, ялагайлану бар, бүтән бернәрсә юк. Көен-җаен белсәң, ясинның бер-ике сүзен әйт тә мин гомерен кыям бу хәсиснең. Җир пычратып, илне бутап яшәвенә чик куярга вакыт.

Шул рәвешчә сөйләнеп килгән Мәхмүт итек кунычы эченнән ярымайга охшаш пәке тартып алды. Йөзен бармакларына тидереп караса да, корбанын газаплап ләззәт алырга ният итте бугай. Пычагын яшел үлән өстенә ташлады да, җилкәсеннән күтәреп, Әмирне авылга таба каратып утыртты. Үзе мал чалырга җыенган сугымчы сыман арткы якка басты.

— Мин юлбасар, карак, башкисәр дип дан алсам да, үземнең туган авылыма тырнак очы хәтле дә зыян китермәдем. Ә син менә хәзер үзең туздырып ташлаган авылыңа соңгы тапкыр текәлеп бер кара да елап хушлаш давай.

Әмир ирексездән башын калкыта төште. Керфекләрен кысып, туган авылы ягына караш салды. «Әнә иртәнге эңгер-меңгер эчендә яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган карт-карчыклар кебек тирән йокыга чумып утыра ул. Элек көмеш айлы мәчете бар иде аның, үзләрен җирнең-илнең чын хуҗалары итеп тойган ирләре бар иде. Сабантуйларын гына түгел, бөтен бер илләрне ду китергән атлары бар иде. Егетләр төшеп кәләш эзли, кәләш көтә торган тугайлыклары, чишмәләре көлеп тора иде. Өй артындагы агач бакчаларында, авыл башындагы тирәк-сәрвиләрдә тургайлар бар иде. Ниһаять, тәүлек буена да йокыны белми торган, гел самавыр шикелле гөжләп яши торган чын авыл бар иде. Юк инде син хәзер, назлы, шаулы Төркәй. Риясыз, газиз улыңны да үз сафларына юмалап-алдап бастырган баскынчылар җимерделәр, тараттылар сине. Назлы Гөлтуташ әйтмешли, бигрәкләр дә прастуй һәм беркатлы булганмын мин. Гомерем, кем якты йөз күрсәтсә, шуның янында җанын асрап йөргән хуҗасыз этнеке шикелле, зая үтеп киткән... Минем бик тә, бик тә матур итеп яшисем килгән иде. Насыйп булмаган шул. Менә мине үзеңнең күкрәгеңә дә, туфрагыңа да сыендырмадың син. Ә шулай да барыбер гафу ит син, онытма мине, газиз авылкаем!..»

Байтак вакыттан соң, бик көттереп-сагындырып кына авыл өстендә якты нур сузыла башлады. Әмир генә моны күрә алмый, бу вакытта аның гәүдәсе инде кара күл төбендә ята иде.

*Чаллы, 2001 — 2002*

# Икенче кисәк



## БЕРЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Ике-өч атна буена Бәләбәй ягыннан шылт иткән тавыш та чыкмый торган иде, беркөнне бик тә сәер бер хат китереп ташладылар.

*«Мин төрмәдән качтым. Магнитогор дигән якка чыгып китәм. Анда кулак итеп куылудан качкан халык килеп тулган. Ата — улын, ана кызын белми, олы мәхшәр, диләр. Шул мәхшәр эчендә эз югалту ансат булыр сыман. Ялган паспорт ясап бирергә дә вәгъдә итүче бар. Аякланып киткәч, сезне дә үз яныма кайтып алмый калмам...*

*Мин бу хатны караңгыда гына, яшеренеп язам. Соңыннан тагын хәбәр салырмын. Ә хәзергә мине эзләмәгез, тавыш чыгармагыз».*

Гарәп хәрефләре белән тезелгән шушы хатны Гөлтуташ әүвәл үзе генә укып чыкты да ни кылырга белми, агач сын шикелле тын утырды. Йа Ходаем! Нинди хат инде бу? Әмир нигә качкан? Аның белән бергә әрәм булган Сөләйман унбиш көн чамасы элек үк кайтып төште бит инде. Күреп сөйләшкән чагында шул Сөләйман: «Кайтыр, кайтыр Әмир абый. Аның гаебе юк, бүген-иртәгә аны да чыгарырлар»,— дип кат-кат юатты бит. Нигә качкан инде, нигә качкан? Шул Әмир рәис, төп гаепле кеше — ул, дип, җанын-башын талкыттылар да, тагын дапрус юлына йөртеп үзәгенә үттеләр микән инде?.. Качкан, качкан... Ә качып хәзер кайда ята, кайда йөри икән? Ул, Магнитогор дигән җиргә барып урнашып, анда ни кырмакчы? Безне кайчан кайтып ала инде, алып китеп кая сыендыра? Андый мәхшәр оясында дүрт-биш җанны ничек асрамакчы? И-и, талымсыз тәкъдир! Тагын нинди генә хәсрәтләр китерерсең дә, без үксезләрне ничекләр итеп җәзаларсың икән?!

Киңәшердәй башка кеше юк бит, аптырагач Гөлтуташ шушы баш китәрдәй серне олы кызына чиште. Ни әйтсәң дә, Зифага хәзер ундүрт тулып килә, өстәвенә гаиләдә ул иң укымышлы кеше.

Зифа гарәп хәрефләрен тиз йөгертеп укый белмәсә дә, хатны ахырына чаклы оста ерып чыкты. Баланың куллары нык калтырый, күз карашлары юлдан-юлга күчеп ялт-йолт

килә иде. Йөзенә бәреп чыккан хәвефне дә яшереп маташмады.

— Ниндидер шик бар миндә, инәкәй. Безнең атай гарәпчәне күптән ташлады бит. Зәкия апай белән Хәсән агай өйрәткәннән бирле атайның яңалифтән гайре язу язганы юк. Моңа инде алты-жиде ел бит.

— Сың... сың... атаң яшеренеп кенә яздым, дип әйткән ләса, балам. Өтермәдән качтым, дип әйткән бит. Шулай булгач, эз яшергән инде. Шуңа менә гарәпчәгә күчкән.

Гөлтуташ алъяпкычының итәк очларын күз читләренә тидерә-тидерә ирен якласа да, Зифа балакайда каушау сизелмәде.

— Ә бу хатның конверты-фәләне бардыр бит, инәкәй. Анысын күрсәт әле.

Гөлтуташ күлмәк изүеннән алып бөгәрләнгән кәгазь тоттыруга, Зифа аңа күз йөгертеп кенә чыкты да, күзләрендә очкын уйнаклатып, шундук ярып салды.

— Әйттем бит, бик шикле хат бу, инәкәй, бик шикле хат. Менә конверт тышындагы язуларны кара. Монысы яңалифчә, иллә мәгәр атай кулы түгел. Пичәт тә берәү генә, Күчәрбай пучтысыннан. Ә безнең атай аны Күчәрбай авылына килеп салганмыни? Бәләбәйдән качкан, Магнитогорга чыгып киткән икән, монда шул яктагы берәр стансаның пичәте торыр иде.

— Сың... ни, кызым... мужыт ул хатны берәрсенә биреп җибәргәндер.

— Ай-һай, инәкәй. Төрмәдән качкан, эз яшергән кеше ничек инде күчәрбайлылар кулына хат бирсен, ди? Ю-у-у-к, безнең атай ул чаклы ук сантый бәндә түгел...

Ана белән кыз икесе тиң сүзсез калып байтак утырдылар. Гөлтуташ лыш-лыш килеп борын тарткалады, Зифа уңга-сулга китереп конверт әйләндерде. Ахырда, иң беренче булып, Зифа урыныннан купты.

— Мин бу Сөләйман абзыйны тагын бер мәртәбә барып күрим әле. Теге чакта син сораштырдың, ә мин сөйләшмәдем. Бу бала-чага ыштансыз дип, миңа берәр серне сатып җибәрмәсме...

Элекке бригадир ихатасына барып кергәч, Зифа әүвәл авылдашын танымыйча торды. Сөләйманның ике күз төбе тиң кара янып чыккан, өске ирене ярык. Зифаны шешеп беткән күз кабаклары астыннан текәләп күзәтте дә, боз чәйнәгән сымак өзек-өзек итеп, кистереп кенә әйтте.

— Анаңа бер әйттем. Әмирҗанны да чыгарырлар, дидем. Чыгарырлар, дигәч, чыгарырлар. Кайтыр... исән булса. Көтегез...

Бер-берсенең кочагына сеңеп яткан ана белән кызның тагын әллә ничә төне күз яшендә үтте.

## 2

Гөлтуташ көн-таң атса колхоз эшенә йөри, Зифаның иртәдән кичкә кадәр бөтен вакыты Чәрмәсән буендагы әрәмәлекләрдән «уф алла» белән чыбык-чабык ташуга үтеп китә. Өй эченә тәмам караңгы төшкәч кенә кайтып егылалар. Авызга кабардай юньле бер ризык юк. Үч иткәндәй, шул ризык турында ниндидер сүз әйтеп, котыртып китүчеләр табылып кына тора.

— Әнә Бөреледә Агыйделдән утын тотучыларга көненә бер олы буханка ипикәй белән раччут ясыйлар, ди.

— Әнә Түбәночтагы Фәхернисса Иванайга барган. Ямаулы, иске бер итәген базарда ике кадак онга алыштырып кайткан…

Гөлтуташ йортындагыларның инде күптән күмер өстендә көйдергән кишер чәенә калган чагы иде.

— Агыйделнең аръягында бер энәгә — бер дөя, ансат икән дөнья,— дип сөйләнде-сөйләнде дә Гөлтуташ, әле кышын ук яшереп куйган ике пар йон оекбашны алып, юлга кузгалырга карар итте.

— Ятып калганчы, атып кал, дигәннәр. Иванайга барып карыйм әле. Ичмаса, атагыз әйтмешли, чит-ят алдына барып баш иярмен. Алар, мужыт, биткә төкермәсләр…

Гөлтуташ юлда туктый-туктый хәл җыеп барган иде, Иванай урамнарына кергәч, сынатмаска теләп, дәртле генә китте. Ләкин бер урамда икенче йорт капкасын да үтеп китә алмады, ачыргаланып, яман чинап өргән эт тавышын ишетеп, тораташтай калды. Бәрәч, бәрәч, кинәт юкка чыккан Пальма тавышы түгелме соң бу?! Бу чаклылар өзгәләнеп кемгә генә өрәсең, җаныкаем?! Дөньяда бармыни әле син, исәнмени?

Гөлтуташ беркадәр вакыт кына исен җыеп торды, аннары, дөбер-шатыр китереп, олы тимер эшермәләр кагылган рус капкасын ачты. Ачса, олы, җирән сакаллы, дәү гәүдәле бер адәм кулына озын саплы, зур себерке тотып юл өстендә тора. Артта, ихата түрендә, озын чылбырын өзәрдәй булып сикерә-сикерә Пальма өзгәләнә.

— Пальма! Пальма, җаныкаем! — дип кычкырып җибәрүен Гөлтуташ сизмәде дә.

— Нельзя, нельзя! Собака покусает,— дип сөйләнә-сөйләнә җирән сакаллы рус агае себеркесен аркылыга куйды.

Гөлтуташның тагын да түзәрлек чамасы калмаган иде инде. Ул рус агаен ачу белән этеп җибәрде, томырылып барып Пальманы кочаклады. Пальма бертуктаусыз элекке хуҗабикәнең яңакларын ялый, Гөлтуташ үкереп елый — байтак

вакыт шулай интектеләр. Тынычлангач, тартмый-сузмый хуҗа аңлатып бирде.

— Миңа аны берничә ай элек таныш түгел татар китереп сатты. Бер олы арба каен утыны тутырып җибәрдем мин аңа. Урманнан алып кайтканны гына түгел, инде ярылганны, киптереп куелганны. Аннары бер яртымны да утырып эчте әле...

— Исеме кем иде? — дип, Гөлтуташ бугазына ябышырдай булып төпченә башлагач, хуҗа кеше, койрыгына сәнәк белән баскан елан шикелле, ялт-йолт боргаланды.

— Караңгы иде бит, мин аның кыяфәтен дә юньләп шәйләмәдем.

«Ләпәй түгел,— дип уйлады Гөлтуташ үзалдына.— Ләпәй булса, ул бу урыска бернәрсә дә аңлата алмас иде. Димәк, Ләпәй Пальманы ихатадан чыгарып кына биргән. Кемгә, кемгә биргән?»

Гөлтуташ ачыргаланып кычкыруга күчте.

— Буе нindirәк иде ул җир битнең? Кыяфәте нинди? Хәзер үк әйт. Югыйсә хәзер силсәвиттән пүнәтәйләр белән килеп җитәм!

Мондый һөҗүмнән соң хуҗа чынлап торып пошаманга төште, күрәсең, тегенең күз төпләре, иреннәре тартыша башлады.

— Озын буйлы иде. Ябык, кара. Адым саен кох-кох итеп тора. Бу чахотны кайда эләктердең, дип төпченгән идем дә, Себердә, ди.

— Хәбиме, әйт! — дип кычкырды Гөлтуташ янә бер мәртәбә.

— Исемен белмим. Валлаһидыр, белмим,— дип, бертуктаусыз тәкрарлады хуҗа.— Караңгы иде бит. Ул китерде, мин алдым. Бушка гына түгел. Ул, мөртәт, минем ике йөк каен утынымны төяп чыгып китте...

«Озакламый бишкә җиткерә бу»,— дип кенә нәтиҗә ясады да Гөлтуташ, әүвәл, җиргә тезләнеп, Пальманы кочаклады, борынын, күзләрен, колакларын үпте. Аннары капылт кына тезләреннән күтәрелде, лас-лос басып, капкага йөгереп китте. Чылбырда, җан бирердәй булып, Пальма өзгәләнә, ә лышык-лышык килгән Гөлтуташта артына борылып карарлык та көч-куәт юк иде...

## 3

Киптерелгән чөгендер, кул тегермәнендә иләнгән арпа ярмасы хакына ялланып эшли-эшли Гөлтуташ Иванайда бер атна чамасы торып кайтты бугай. Җимерелгән җил капка

аша аяк атлап узса, ихатада тагын бәхетсезлек, янә күз яшьләре.

— Өченче көн төнлә сыерны урлап киттеләр бит, әнкәй. Җан асрарга катык белән сөт тә калмады ла...

Өй эчендә бер Тимерҗан гына сер бирмәде, ә Гөлтуташ кочагына килеп сарылган Зифа белән Вәзирә байтак үкерделәр. Ләкин тәкъдир үксез-ятимнәргә күңел бушатырга әллә ни күп ирек-ара калдырмаган икән. Болай да чокыр уртасында утырган, өстәвенә әле ниргә бүрәнәләре черүдән тәмам тезенә чүккән йорт аламасы каршыннан дистәгә якын ир-ат йөгереп үтте. Кулына кайсы балта-пычкы тоткан, кайсы арба сөйри. Аларга бау, ыргак ише вак-төяк әләктергән хатыннары, арба үрәчәләренә, әниләре итәгенә ябышып теркелдәгән бер көтү бала-чага ияргән. Һәммәсе дә мунча кергән сыман кызарынып чыккан, гыж-гыж килеп, ат шикелле пошкырапошкыра элдертәләр генә. Өзек-өзек итеп ыргыткан сүзләреннән бер яңалык ишетелеп калды:

— Яшке үзенең хатыны белән утардан чыгып качкан. Усманныкылар белән Күчәрбайлар килеп Яшкенең йорткурасын ташый башлаганнар...

— Аһ, үзләренә күпме изгелек кылган Яков дәдәйнең утарын сүтәләр бит! — дип, Гөлтуташ әүвәл күз яшьләренә ирек куйган иде, икенче мизгелдә, баш түбәсенә күсәк белән орган шикелле, йөзе алышынды.

— Болар Җәкәү малын ташып бетерә бит, балакайлар! Анда ничәмә-ничә еллар буена атагыз бил бөкте, ул интекте. Батрак Әмир өлеше дә муеннан бит анда. Йоклап калмыйк әле. Үзебезгә тиешлене, әйдә, барып алыйк!..

Гөлтуташ Зифасы һәм Тимерҗаны белән бергә «уф алла»ны сөйри-сөйри килеп җиткән чакта, төркәйлеләр Яков утарының мунча белән лапасларын гына түгел, бер-берсенә терәп салынган ике йортын да нигезенә тикле сүткән иде инде. Берәү дә утын-такталарны «уф алла»сына яки ат арбасына төяргә һич ашыкмый әле. Иркен яланлыкта һәркайсы сутый-сутый кишәрлекне бүлеп алган, олысы-кечесе Яковның «үзләренә тиешлең малын шунда күчерәләр. Тәгамнең күзе туя беләмени, әнә хәзер инде Чәрмәсәнгә терәп салынган тегәрмән бурасын да сүтә башлаганнар.

— Балалар! Сез йорт калдыкларын карагыз, ә мин тегермәнгә. Такта әләгәме, ишек ниргәсеме — берсен-бер калдырмагыз. Иске чәйнек-тәлинкәләр килеп чыгуы бар. Безгә артык түгел, һәммәсен җыйнагыз. Атагызның өлеше бу, безнең дәхел. Әнә теге яр буена ташыгыз барын әүвәл. Соңыннан өйгә ничек тә ташып бетерербез.

Гөлтуташ шулай дип Зифа белән Тимерҗан тарафына

әмер-күрсәтмәләр ыргытты, үзе, янә котырынып дөрләгән ялкын эченнән балаларын коткарырга ташланган мәчедәге шикелле, җан ачысы белән тегермән бурасы ягына томырылды.

Әмма бушка килгән байлык сукыр калдыра шул. Инде Яков ихатасын сүтеп бүлешә-бүлешә тау-тау өлеш өеп куйгач та туймаганнар кешеләр. Әле берсе, әле икенчесенең өеменнән иске бау белән савыт-саба гына түгел, киртә-такта кисәкләрен дә урлаша башлаганнар.

— Монысы минем өем бит, нигә тыгыласың?

— Махсус тамга сугып калдырылган атаң малымы әллә? Барыбер Җәкәү килмешәктән калган хәрам мал бит, — дип, әүвәл кычкырыш-талаштан гына башлаганнар иде, тора-бара Түбәночтагы буйдак Харис белән Гөлтуташлар күршесендәге Әсфәндияр канга бата-чума сугышып та алды. Ахырда һәрбер өем янына аерым каравылчылар билгеләп, бүлгәләгән малны үз ихаталарына тота-каба ташый башладылар. Авыл белән элеккеге Яков утары арасында йөгереп йөргән чакта, Гөлтуташ күрше хатыннар авызыннан гаҗәп сәер хәбәрләр ишетеп артына ава язды.

— Синең Әмир белән бергә утырып чыккан Сөләйман авылдан чыгып качкан ди бит, шуны ишеттеңме?

Гөлтуташның кайнар аш йоткан шикелле сүзсез калуын күргәч, ялындырып тормый янә өстәделәр.

— Хәби белән теге Каты кабык Харис аңа тын алырга ирек бирдемени? Әүвәл Торна күле ягына алып чыгып ярганнар иде, аннары инде тәрәз-ишекләреңне кадаклап, йортыңа ут төртәбез, дип өнсез калдырганнар. Йә ашларына таракан булып төшкән инде Сөләйман тегеләрнең, йә бер-бер сер белә. Шуңа артына ут төрткәндәй чыгарып җибәрделәр...

Бу минутта Гөлтуташның барча уй-нияте Яковтан калган малны ташу белән мәшгуль, ул хатыннар әйткән сүзләрнең мәгънәсе-асылы, чи утынны ут алмаган сыман, аның зиһененә һич кенә дә үтеп керми иде.

## 4

Урак өсте җитте. Гөлтуташ быел да үзен эшкә ындыр табагына билгеләмәсләр микән, дип көтеп йөргән иде, бүтәнчә хәл иттеләр.

— Табор күле буендагы басуда арыш белән арпа өлгереп җиткән. Алар артыннан ук бодай белән борчак өлгереп килә. Бригадалар туплап, куна-төнә шунда ятмый булмас. Син дә, Гөлтуташ җиңгәчәй, биш-алты хатын белән бергә шунда барачаксың.

Вакытлыча бригадир булып йөргән Фазылбәк шулай тәмле телләнеп әйткәч, билгеле инде, Гөлтуташ та күнде. Быел инде Зифаны да эшкә йөртә башлаганнар иде. Аның ындыр табагында эшләячәген белгәч, Гөлтуташ әле сөенеп тә куйды. Зифа — мәктәп баласы бит, күлмәк бөрмәләренә ашлык яшереп кайтса, тентемәсләр әле...

Чыннан да, Табор күле буенда шалашлар корып, атна буе куна-төнә ятып эшләделәр. Әмир Бәләбәйдән тикле алып кайткан косаркалар гына җитешмәгәч, ирләр игенне чалгы белән чапты. Хатын-кызлар бил дә турайтмыйча көлтә бәйли-бәйли бөтенләй җык булды. Иртә таңнан алып кара төнгә чаклы эшләвенә түзәрләр дә иде. Хатын-кыз өчен иң ямьаны — тиргә батып бетү, тән керләнү. Алар ир-ат түгел, бил тиңентен чишенеп ташлый алмый. Ә утлы таба сыман кыздырып торган кояш астында аз гына селкенденме, эчке күлмәк, кофта дигәннәре шундук юешләнеп чыга, тузан басып китә, тир бөтен тәнне игәү сыман кыра.

Гөлтуташның алмашка төяп йөрерлек байлыгы бармыни, үзе белән нибарысы ике генә күлмәк алган иде. Алар ике-өч көн буена да кияргә ярамады, берсе шул юештән-тирдән нәкъ култык астыннан умырылып чыкты. Һәммә кеше үз шалашларына кайтып егылганнан соң гына, төнге караңгыда Гөлтуташ күлмәкләрен Табор күлендә чайкап кайткан иде. Түбәночтан килгән Бибигайшә көтелмәгән, куркыныч хәбәр әйтеп, аның өнен алды.

— Бүтән Табор күлендә юынма син, ахирәт. Хак булса, анда быел бер адәмне суеп салганнар, ди. Хактыр инде, халык белми әйтмәс. Әнә хәзер бер кеше дә юынмый бит анда...

Гөлтуташның йөрәгенә әйтерсең лә утлы энә белән китереп кададылар. Бибигайшә каршында янә сүз кузгатып сорашырлык куәте гел калмады аның. Күз алларын пәрдә каплап китте, зиһене томаланды. Шалаш почмагына кереп чүмәште дә үзе дә аңламый-нитмичә күз яшьләренә тыюсыз ирек бирде. Ә йөрәге әллә нишләп, гел бер сүзне әйтеп тибә иде.

— Шул, шул, шул...

**5**

Сентябрьгә керүгә үк, көннәр салкынайтты. Күчәрбай мәктәбендә укулар әле башланмаган иде. Зифа белән Тимерҗанның эшсез ятуыннан файдаланып, Гөлтуташ аларга яңа шөгыль тапты.

— Алма пеш, авызга төш, дигәннәре безнең өчен түгел.

Без ятимнәргә бер генә әйберне дә чит-ят китереп бирмәс. Кыш чыгарга юньле-рәтле утын юк, балалар. Яшкенең лапаслары урынында, ындыр артларында әллә ничаклы тирес өелеп калды. Шуны әрем, камыш, киндер үше чүп-чар белән буташтырып изеп, тирес кирпече сукмый булмас инде безгә...

Зифа белән Тимерҗан тагын, «уф алла» тартып, Чәрмәсән янына йөри башладылар. Тимерҗан унбер яшьтә генә булса да, барыбер ир-ат бит, аның кулына чалгы килешеп тора. Ул, әллә кайлардагы күл буйларыннан, чокырлардан чабып, әрекмәнен, камышын, әрем-сарутларны ташып тора. Зифа шуларны әүвәл балта белән турап, тирес белән бутап, озын көн буена боламыкны изә. Аякка киярдәй резин итек юк бит, сулар сибә-сибә буташтырган шушы боламыкны ялан-аяк көенә, ач көенә таптый бит берүзе. Боламыкны кичке якта гына калыпка салалар да, бер дистә кадак авырлыгындагы бәләк белән тукмарга тотыналар. Балалар өй эченә кайтып егылган чакта, җиһанны инде күзгә төртсәң дә берни күренмәслек караңгылык каплап киткән була.

Зарланырдай, хәлгә керердәй бер кеше дә юк, әниләре Гөлтуташны да колхозда тоташ балчык эшенә генә куалыйлар икән. Дөрес инде анысы, үпкә-зарны әниләре гел күңелендә генә саклап йөртми. Күршеләрнең әтәчләре беренче тапкыр кычкыра башлауга ук, күзен-башын ертып уяна да карт әбиләр шикелле үзалдына сукранмыйча калмый.

— И-и, ирдәге хатыннар әнә ындыр табагына йөри, молотилкага көлтә биреп тора, триерда икмәк җилгәрә. Ирдәгеләрнең авызлары икмәктән аерылмый. Ә мине, көн-таң атса, фирме сыларга да балчык эшенә генә куалыйлар. Яклар-ышыкланыр кешең булмагач, и-и, юк инде ул. Минем үше килмешәк, өстәвенә тол яшәгән хатынга бу авылда ни сан?!

Шулай да, октябрь ае башланып кичләр озынайгач, Гөлтуташ кинәт кенә батырайды да куйды. Зифа белән Тимерҗанның Күчәрбайда фатир торып яшәрлек чамасы юк, шуңа күрә алар да кич саен өйгә кайта иде.

— Бүген мәктәп мөдире булып йөргән Рәйсә фирмегә, безне әгитләргә килеп китте әле,— дип башлады Гөлтуташ бер кичтә, шактый читтән урап.— Җыен яшь-кыркынны спитәкел куярга әзерлиләр икән. «Галиябану» дигән тиатырны. Мәгәр Галиябануның үзен уйнардай кешеләре юк, ди. Гәрдән байның чибәр кызы Гөлсем хәерче Шәрифуллага ябышып калган иде дә бит, мәгәр бала тапкач, аның койрыгы чынлап торып бозга катты инде. Әллә булмаса, син тәвәккәлләп карыйсыңмы соң, Зифа балакаем?

Зифаның каймак чүлмәге янына якынайган мәче сыман күз уйнаклата башлавын күрүгә үк, әни кеше янә тезеп китте.

— Буең-сының килгән, яшең җиткән. Җырлап җибәрсәң, тавышың да чит-ят арасында хур булырлык түгел. Ятим бала, яклаучысыз-үксез дигәч тә, гел өйдә генә бикләнеп ятарга димәгән бит сиңа. Атаң өйдә булса, инде әллә кайчан сине ул тиатыр дигәннәренә сөйрәп илтер иде. Дошманнарның үте сытылсын, тәвәккәллә, балам!..

«Атаң өйдә булса» дигән сүзләр тәэсир итте, ахры, Зифа шундук ризалашты, Октябрь бәйрәменә туры китереп куйган спектакльләре дә гаилә өчен олы шатлык булып үтеп киткән иде. Ләкин бәхетсезнең чалкан егылса да борыны каный, дигәннәре хак икән шул. Ятимнәргә Төркәй урамнары буйлап бер тәүлек буена да елмаеп йөрергә ярамаган икән.

## 6

— Шәйсолтан кайтып төшкән, хәерче Шәйсолтан кире әйләнеп кайткан! — дигән хәбәр Төркәй урамнарын икенче көнне төш вакытында ук урап чыккан иде. Кичкә чаклы хәбәр тау битеннән тәгәрәгән кар йомгагы сыман бүселеп бетте, кабат-кабат Әмир исеме белән авыз чайкадылар.

— Кем кыйлана дисәң, шул Әмир мөгез чыгарып маташты бит инде. Шыр тиле Шәйсолтанны Лилингырат тиклем Лилингыратка җибәрәләрме соң? Ул томанадан каяннар гына килеп инчилерлар чыксын?

— Лилингыраттагы ачлык безгә караганда да яман, ди ләбаса. Әмир, явыз, аны анда ачка кыркылсын, дип озаткандыр инде. Әле ярый шыр томана булса да, Шәйсолтан шул арадан тикле качып кайта белгән...

Гөлтуташныкылар менә шушы хәбәрне җыеп, әтиләренең ниятләре җимерелүгә ачына-ачына, тезелешеп йокыга да яткаңнар иде инде. Мичкә ташланган тирес кирпечләр янудан туктамаган, шуңадырмы ишеккә дә келә салырга оныткаңнар иде.

Берзаманны дөмберт итеп ишек ачылуга, һәммәсе дә сискәнергә мәҗбүр булдылар. Кеп-кечкенә өй эче ярым караңгы хәлдә булса да, яктылык тупса аша атлап кергән кешене чамаларга гына җитә иде.

Шәйсолтан иде бу, әйе, кайчандыр Әмир белән бергә Афоньканы яравайлар йөргән, Әмирләрнең төп өенә күчеп утырган, Әмир Ленинградка укырга җибәргән, кеше итим дигән шыр хәерче, япа-ятим Шәйсолтан иде. Хәзер кыяфәт

үзгәргән инде моның. Чәчне озын иттереп үстергән, мыек җибәргән. Буйга да бер-ике илле чамасы үсә төшкән сыман. Өстендә яңа кием. Ниндидер хәрбиләрнеке төсле, чалбары-пинжәге пардан булган кием киенгән бу. Карашын каш астыннан гына сөзеп текәргә өйрәнгән. Ләкин ияге-авызы элеккеге сыман салынып төшкән, ирен читләреннән селәгәй агып тора.

Шәйсолтан исәнлек-саулык сорашып торуны кирәк санамады.

— Кайттым әле мин, Гөлтуташ апа, Лелингыратны ташлап кайттым әле. Әй, бөтен кешегә дә укып мулла булырга димәгән, мать якасын! Безнең башлар Төркәй җирендә дә әрәм булмый ла ул, ык... әйе, әйе. Менә кайтып керүгә үк үземне әллә кемнәр чакырып сыйладылар бит әле. Юк, безнең башлар барыбер әрәм булмый, ык... әйе, әйе...

— Эчеп килгәнсең бит син, җир бит! Сүзең булса, айныгач күренерсең. Хәзер кайт та йокла,— дип, Гөлтуташ түргә куелган караватыннан купмыйча гына аваз салган иде, Шәйсолтан моңа ыжлап та карамады.

— Нишләп кайтып йөрим, монда ятып йоклыйм. Бер кичкә кер мичкә, ди, монда гына калам, мать якасын! Шәйсолтан урам эте түгел, Лелингыратның үзендә бер ел буе укыган кеше әле. Не шути син безнең белән, эт шикелле куып сансызлама.

Шәйсолтан шулай сөйләнә-сөйләнә ишек төбендә таптанып торды да берзаманны, кисәк ыргылып, Зифа яткан юрган астына чумды. Кәлүшләрен кай арада салып өлгергәндер — моны кем шәйләсен?

Зифа әле һични аңламаудан тынсыз калган иде. Шәйсолтан гыж-гыж килеп кызның имчәкләрен кармалый башлады, «ә» дигәнче селәгәйле иреннәре белән аның яңакларын ялап чыкты. Кызның эчке күлмәк астында башка тотарлык нәрсә юк икәнен чамалады, ахры. Иләмсез куллары белән кендек астына ук төшеп җитте.

— Инәй, инәкәем! — дип, Зифа чырыйлап кычкыра башлауга ук, мич башыннан Тимерҗан сикереп төште.

— Разбуй салам хәзер, бар, чыгып кит, җир бит! — дип кычкыра-кычкыра Гөлтуташ та, карчыга шикелле очынып Шәйсолтанга барып ябышты.

Ләкин исерекме, түгелме, ир-ат ир-ат шул инде ул. Шәйсолтан кушаяклап бер генә тибеп җибәрде — Тимерҗан мич арасына, Гөлтуташ ишектән бөтенләй болдырга ук очты. Шәйсолтан инде үгез шикелле ярсыган, ул тотып тыешлы хәлдә түгел иде. Бар гәүдәсе белән сытып ятты да ул Зифаның ботларын як-якка аера башлады.

— Инәй, инәкәем! — дип чырыйлап кычкырган тавыш бөтен өйне күмде. Аңа кушылып болдырда Гөлтуташ чәрелдәгән тавыш урамны яңгыратты.

— Кар-рау-выл! Кар-рау-выл!

Каян, ничек пәйда булгандыр, икенче минутта ук өй эченә кулына чыбыркы тоткан Фазылбәк йөгереп килеп керде. Әүвәл бер секунд эчендә Шәйсолтанны караваттан сөйрәп төшерде дә икенче мизгелдә аны уңлап-суллап чыбыркы белән яра да башлады.

— Ит изгелек, көт явызлык шулай була икән. Менә сиңа, хәсис. Менә сиңа!

Берзаманны барыбер Шәйсолтан чыбыркы астыннан качып котылды да ишек ниргәләрен сөзә-сөзә тышка томырылды.

— Хәби белән Кара тавык сыйладылар аны бүген,— дип гыжлый-гыжлый тезеп китте Фазылбәк.— Шулар гына котыртты бу тилене, шулар котыртты. Аларның бергә эчеп утырганын күргәч тә күңел сизгән иде. Шуңа менә үз өемә кайтмый сезнең янда йөрдем...

Инде тынычланып ишек тоткасына үрелгәч, Фазылбәк өстәп куйды.

— Судка бирегез сез бу хәсисне, болай калдырмагыз. Кирәк икән, шаһит булып барам...

Юк, хөкемгә бирүнең кирәге калмады шул. Айнуга ук акыл кергән, ахры. Шәйсолтан авылдан таң белән үк чыгып качкан иде.

## ИКЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Ниһаять, җиденче класс та артта калды. Апагыз Төркәйдәге иң укымышлы кеше була хәзер! Күчәрбайның ШКМы, сау бул!

Зифа шундый уйлар белән очына-очына кайтып кергән иде, яраланган аккош шикелле, аны күк йөзеннән җир өстенә чүкеп төшерделәр.

— Син Күчәрбайда атна буе имтиханнар биреп йөргән чакта, безнең ахири Хәби-Хәйберахманны колхоз рәисе итеп утырттылар!..

«Кадалып кына китсен бу дөньясы! Синең кебек хәерчеятимәгә күк капусы ачыламыни соң ул?!»

Күңеленнән генә сыза-сыза Зифа янә үкенечле уйлар диңгезенә чумарга мәҗбүр булды.

«Аһ, нигә диеп кенә кире кайтарганнар инде бу Хәбине? Атасы аны Себергә бик тә дөрес олактырган иде бит югыйсә. Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, диләр. Тәгаме туймас Хәби кире әйләнеп кайткач, барыбер элекке кәсебенә ябышты бит. Бөтен тирә-юнь авыл кешеләре үргән чабаталарны кыш көннәрендә биш тиеннән җыеп ята да печән белән урак өстендә шул ук чабаталарны, шул ук кешеләргә унбиш тиеннән күз дә йоммый сата. Урак өстендә эш кешесенең яңа чабата үреп утырырга вакыты бармыни? Аптырагач, үзенең үк чабатасын өч хакына кабат сатып ала инде, мескен. Ә Хәби, убыр тәре, килештереп ках-кох килгән була, җитмәсә, әле кесәсенә содалы су салган шешә тыгып йөри. Имеш, ашказаны юньле-рәтле эшләми ул убырның. Имеш, аны Себер җибәреп эштән чыгарганнар. И юха җан!

Менә хәзер, йомышың төшә калса, шушы убыр янына бар инде син. Тыңлаячакмы ул сине, санга сугачакмы? Юк, битеңә төкереп кире борачак бит. Кеше кулына калган көнең — караңгы төнең, дип белми әйтмиләр шул. Хәби ише кара елан каршына барулардан Ходай Тәгалә үзе саклый күрсен...»

Әнисе дә берзаманны нәкъ шундый ук ут эченә төште. Әүвәл ул олы кызының авылда калырга җыенуын хуплаган да иде. Гаиләне таратмый-нитмичә саклыйлар, Зифа аңа олы терәк була, янәсе. Ләкин Зифага ике-өч көн буена да өйдә утырырга ирек бирмәделәр.

— Син мәктәпне тәмамлаган кеше, яшең җиткән, син калхуз эшендә катнашырга тиеш,— дип, хисапчы Зәмзәмбикә беркөнне таң атуга ук килеп керде.

Сатулашып торырга башына тай типмәгән, Зифа да җиң сызганып колхоз эшенә йөри башлады. Әүвәл әнисе белән бергә фермадан тирес чыгарып интеккәннәр иде, урак өсте кергәч, Зифаны ындыр табагына эшкә күчерделәр. Әвернә авызына көлтә биреп тору бер дә рәхәт түгел, биш-алты минут эшләүгә үк манма су буласың, ләкин буйсынмый да хәлең юк. «Саботажник» дигән сүз явыз Хәби теленнән бер дә төшми, әнә шул статьяны кулланып, сине Себергә озаттыру да аннан ерак йөрмәс...

Әмма август аена кергәч, Гөлтуташның түзем мичкәсе коргаксыды бугай. Теленә бөтенләй яңа сүзләр керде.

— Кызыкаем! Монда калсаң, сине изәләр бит. Атагыз сезнең һәммәгезне дә укытырга, башлы-күзле итәргә хыялланган иде. Ичмаса, син булса да авылдан кач, балам...

Шундый сүзләрдән соң тагын ике-өч көн буе иләс-миләс килеп йөрде дә Зифа беркөн таңда, тәвәккәлләп, Хәби янына китте. Элеккеге Әхтәм мулла йорты хәзер инде тулысынча

колхоз кәнсәсенә әйләнгән, Хәби шуның иң иркен бүлмәсендә, артлы урындыкта бәллүләп утыра иде. Зифа гозер белән киләсен көтеп торган диярсең, кадау җавапны бик тиз тезеп китте.

— Һе, синең белән бергә укыганнар, җиде класслылар шәһәрләргә чыгып китә, укырга кирә, дисең. Алар китәрләр ул. Аларга сәвит калхузларының нинди кадере бар? Ә безнең «Кызыл байрак» — синең атаң төзеп биргән калхуз. Атаң калхузы бу! Шулай булгач, атаңа хыянәт итеп, аннан ник качасың?.. Әллә... әллә хәзер инде синдә башка уймы? Атаң ялгышкан, калхуз кирәкмәгән, дип әйтергә җыенасыңмы әллә? Юкмы, кирәккәнме? Шуңа күрә беренче кердегезме? Алай икән, бүсереӊ чыкмас, эшлә!..

Бернинди җавап та табалмаудан яшенә буыла-буыла, Зифа янә ындыр табагына эшкә чыгып китте. Ләкин әнисенең алай җиңел генә тез чүгәргә исәбе юк икән.

— Бу ыштыр бит Хәби юри үчегә ул,— дип башлады Гөлтуташ бер кичтә, тупса аша атлап керүгә үк.— Әмирнең балалары укымасын, кеше булмасын, ди. Ю-у-ук, балакай, уң яңакка суккачтын сул яңакны куеп торып булмас. Басымчак, юаш сыерны иренмәгән һәркем тотып сава... Давай, иртәгә директорың Усманов янына барып карале син.

Беркадәр тын алды да Гөлтуташ үз карарын дәлилләп үк китте.

— Гаиләсе бик ишле, дип атаң аңа ике-өч мәртәбә он белән бәрәңге дә илтеп кайткан иде. Шулай булгач, атаңның изгелекләрен дә онытып бетермәгәндер, дип әйтүем. Аннары аны һәрвакыт бик гадел, бик ихлас укыта, дип кенә сөйләделәр. Хак икән, димәк, ул синдәй иң әйбәт укучысының киләчәк язмышы турында да уйламый яшәмидер. Һәрхәлдә, тиеш. Директорларның шундыйлары гына юньле буладыр ул...

Зифа үзе укыган мәктәп каршына килеп җиткәч торataштай калды. Кайчандыр Садыйк байныкы булып исәпләнгән йортны сүтеп бетергәннәр, элеккеге мәктәп урынында бәрәңге базлары белән янәшәдә олы мич морҗалары гына тырпаешып тора. Гаҗәп, сүтеп ташланган йорт ихатасында һичнинди сүс кисәге аунамый, бармак башы хәтле дә пыяла ватыгы юк.

Аңлатманы көянтә-чиләк асып чишмәдән кайтып килүче өлкән апа бирде.

— И-и, иске мәптекне денсез Усман җәй башында ук сүтеп ташлады бит инде. Әнә тегендә, Алатыр яланында яңа мәптек салып ята хәзер. Шәрип кулак йортын сүтеп шунда ташыттырды, Рәсим кулакныкын. Нәфсе дигәне туймаса да

туймый. Инде Харис мулланың яңа мунчасын да сүттерде, муены сынгыры, мәлгунь!..

Яңа мәктәп бинасын эзләп тапкач, Зифа янә бер шаккатты. Төркәйдә әтисе төзеткән фермалардан ким дигәндә биш-алты мәртәбә олырак икән бит бу. Бер-берсеннән бүрәнә стеналар белән аерылган егермеләп класс, бүлмә саен аерым ишек, аерым тәрәзәләр. Ярты урам чаклы озын, киң коридор. Бүлмә саен түгәрәк, биек мичләр. Их, менә шундый мәктәпләрдә укысаң икән бит ул!..

Директорның кайдалыгын өзеп кенә әйтүче табылмагач, Зифа аны яңа мәктәп тирәсеннән үзе эзләп китте. Ул әлегә кул тимәгән бүрәнәләр өеме артына кереп баскан, Зифа өчен бөтенләй дә таныш түгел бер ир белән сөйләшеп тора икән. Теге ир-ат кулына бәләкәй генә чыбыркы йомарлап тоткан, мөгаен дә, директорны күрергә дип кенә сугылган юл кешесе инде.

Зифаның бүрәнәләр өеме янына килеп басуын алар шәйләмәде. Юлчы ирнең ярым пышылдап, ярым кырыс тавыш белән тезгән сүзләре яңгырап ишетелде.

— ...Кировның башына җиткәч, тәмам азды болар. Чын мәгънәсендә ау башланды, туган. Уфада Ишмуратов белән Гайсинны алып киттеләр. Бәләбәйдә Сәләх белән Якуб юкка чыкты. Казанда Һади Атласины көнлекче хәленә төшергәннәр, диләр. Солтангалиевне Соловкидан Саратовка кайтарганнар анда кайтаруын, однакы ул хәзер бертуктаусыз надзор астында. Газиз белән Садри турында бер хәбәр юк. Сизәсеңме, безнең якта гел татарларны гына җыеп ала болар. Әйтерсең лә алар — аучы, ә без — кыр казлары. Чүплиләр, чүплиләр, и һаман гел татарны. Валлаһи, безнең өстә ниндидер тәҗрибә үткәрәләр сыман...

Бу минутта үзенең ирләр күзенә күренергә тиеш түгеллеген тәгаен нык чамалап, Зифа шыпан-шыпан читкә китеп барды. Беркадәр вакыттан соң директор үзе эзләп тапты аны.

— Тегендә эшчеләр сине бер чибәр кыз эзли, диделәр. Күз генә тимәсен, алар хаклы икән...

Комач кебек кызарудан арына алмыйча, Зифа тик бераздан гына үзенең гозерен әйтеп сала алды.

— Хәби укырга җибәрми, справкы бирми. Хәби аяк чала.

Усманов, бөртекләп сорашканнан соң гына, үзенә мөгаллим вазифасын алырга батырчылык итте.

— Юк, театральныйга кызыкма син, Зифа. Галиябану ролен уйнап карагансың, тавышың, буй-сының бар — хәлләреңне аңлыйм. Әмма ликин, дип сөйләшә иде безнең бер бабакай, әмма ликин... артист язмышы, миңа калса, синең

сукмак түгел. Синең арттан тагын энекәшең белән сеңелең үсеп килә. Әниең берьялгызы. Ул сабыйларны кеше итәр өчен аңа ярдәм кирәк. Әгәр син ташласаң, күзе ычкынган оекбаш шикелле, гаиләгез белән таралып китәсез бит. Аңлыйсыңмы шуны, кызыкаем?

И-их, аңламыймы соң! Аны ничаклы тибелгән, ничаклы кимсетелгән Зифа да аңламагач, тагын кем аңласын? Ләкин театр техникумы ярамагач, кая барырга, иң мөһиме, бу Төркәйдән кая гына чыгып качарга соң?..

Унбише дә тулмаган яшүсмернең суга төшкән чебеш хәленә калуын чамалады бугай, директор Усманов үзе тәкъдим итте.

— Иң яхшысы, давай, Бәләбәйдәге педтехникумга бар син, кызыкаем. Син теләсә кайсы фәнне дә бик тиз эләктереп аласың. Түзәргә өйрәнгәнсең. Ничек итеп Тимерҗанны сөйрәп йөртүеңә карап кына да әйтә алам — бала-чага белән бик оста эшли беләсең, сынаганым бик бар. Аннары ул педтехникумның директоры Ильясов та яхшы таныш минем, хәтта әшнә кеше. Аңа сүзем үтә. Тәгыйшту, дип сөйләнә иде безнең бер бабакай, тәгыйшту... уйла, үлчә дә тәвәккәллә, давай. Сиңа өч көн вакыт. Әмма ликин...— Усманов елмаеп куйды, ләкин теге сихерле сүзен кабатлап маташмады.— ...бүгеннән үк иманым камил минем, менә дигән укытучы чыгачак синнән, Зифа.

## 2

Ике көн үтүгә, Төркәйгә Галимҗан Усманов үзе килеп җитте.

— Җидееллык мәктәпне тәмамлаганга таныклык үз кулыңда. Менә сиңа авыл советыннан справка. Хәзер сине Хәби генә түгел, шайтан үзе дә тотып тыя алмый. Хәл иткәнсең икән, давай, Бәләбәйгә чыгып сыптыр, кызый. Мин белештем, анда кабул итү имтиханнары башланган да инде.

Зифа шатлыгыннан биеп җибәрә язды. Ә Гөлтуташ, бичара, тагын күз яшьләренә буылып сыгылды да төште.

— Хозер Ильясны юк дигән булалар, син икән бит, Галимҗан туганкаем. И-и, без ятимнәр өчен дә изге җаннар табылып куя икән!

Галимҗан ишек тоткасына үрелгән иде инде, капылт борылды да түш кесәсеннән яңа кәгазь алды.

— Онытып торам, сантый. Ильясовка тапшырырга дип махсус хат яздым бит. Педтехникумны эзләп табуга ук, иң беренче эшеңне син шуңардан башла. Вәт менә ул изге җан, ичмаса, ярдәм итми калмас.

Инде ишек япкач, болдырдан Галимҗанның хушлашу сүзләре яңгырап ишетелде.

— Озак сузма, иртәгә таңнан ук юлга кузгал, Зифа. Бәхет йокы чүлмәкләрен бер дә яратмый ул...

Гөлтуташныкылар янә бер мәртәбә сөенечтән балавыз сыгып алдылар, аннары, дәррәү кубып, сандыкка ябыштылар. Иске мендәр тышлыклары, бала киемнәре, яулык, оекбашлар — барысы чыгып очты, әмма шулар арасында күңел юатырдай бер генә чүпрәк кисәге дә юк иде шул.

— Син, мужыт, киләчәктә бик зур кеше хатыны булып куярсың да мине битәрләрсең. Ю-у-ук, техникум хәтле техникум каршына сине моның ише кылка күлмәк белән җибәреп булмый инде,— дип сөйләнде-сөйләнде дә, җен алыштырган шикелле, Гөлтуташ юлга ук җыена башлады.

— Аблай кул сузымында гына. Хәзер чыгып китәм, төнгә әйләнеп кайтам. Әтәй гел сантыйланып бетте инде бетүен, мәгәр кызын таныр, иске-москы булса да берәр күлмәк бүлеп бирер әле...

Гөлтуташ кабат әйләнеп кайтып кергән чакта, таң яктысы беленеп килә иде. Ни галәмәт, ул кулына ике көянтә озынлыгындагы, зәңгәрсу төскә ал чәчәкләр төшкән ситса тотып кайткан. Билгеле инде, авызы колагында.

— И-и, әллә Ходайның амин дигән чагына туры килде микән? Юлыбыз гел уңып кына тора.

Сукыр лампага ашыгып ут элделәр, яныпь-пешеп эшкә тотындылар. Гөлтуташ иске күлмәгеннән чамалап җиң, яка өлешләрен кисеп ала, Зифа бармак битләрен йөз кат тишкәли-тишкәли, итәк асларын бөрә-бөрә тегә. Төш җиткәнче баш калкытмый, кымшанмый утырдылар. Аның караву төш узганда, ишек төбендә өстенә яңа күлмәк, иске булса да кыпкызыл косынка, таушалган чабата, ап-ак оекбаш кигән бер чибәр кыз басып тора иде.

— Булды, кызыкаем, күз генә тимәсен, башкалар алдында ким-хур булырлык түгел,— дип, Гөлтуташ шундук сөенечен белдерергә ашыкты. Икенче мизгелдә үк үзендә инде әллә нинди һавалану купты.

— Тукта, тукта, нишләп минем балам Чишмә стансасына тикле җәяү йөрсен әле? Әз ара түгел, алтмыш чакрым ла ул. Әмир төзеп биргән калхуз, Әмир җыеп калдырган маллар бар бит әле. Ат бирми генә карасын, барам да менә болай итеп якасыннан алам!

Гөлтуташ шулай бик әтәчләнеп чыгып китсә дә, Хәби олаулы ат түгел, картайган кәҗәсен дә бирмәде шул аңа. Ана белән кыз — икесе тиң сукрана-сукрана, Хәбине эттән алып эткә сала-сала, кул арбасын юлга көйләделәр. Кич

җиткәндә арба әзер, ләкин ихатада аңа төярдәй бер байлык юк иде.

— Ничава, ничава,— дия-дия Гөлтуташ берникадәр вакыт үзен-үзе тынычландырып йөрде, тик берзаманны берни аңлатмый-нитми кулына иске-моски капчыклар җыя башлады.— Җан биргәнгә — җүн биргән, ди. Калхуз малы чутсыз. Без ятимнәр генә чәлдергәннән калхуз тагарагы коргаксымас әле.

Гөлтуташ әйдәкли-әйдәкли барып җиткәч кенә чамалады Зифа. Әтиләренең абыйсы — Әбелсаттар агай каравыллый торган яшелчә басуына килеп төшкәннәр бит. Әбелсаттарның төнлә генә түгел, көпә-көндез дә аяк өсте йоклап йөри торган бәндә икәнен һәр төркәйле белә. Курыкмыйнитми эшкә тотындылар. Хәтәр саллы гына ике капчык кишер, кызыл чөгендер, шалкан белән тулды. Шулар арасында «кулга ияреп кайткан» яп-яшь бәрәңгеләрне көлгә тәгәрәттеләр, өстәл тирәли утырмыйча гына тамак ялгадылар. Тора-бара барысы да язмыш белән качышлы уйный торган заман түгеллеген аңладылар сыман, яктырганны көтеп тормый-нитми, юлга кузгалдылар. «Уф алла»ны сөйрәгән көе алтмыш чакрым араны үтүләре, ай-һай, җиңел түгел.

Сарманай дигән бер авылның басу капкасы төбенә җитүләре булды, Гөлтуташ җирдә аунап яткан бүкән кисәгенә лас итеп барды да утырды. Ярылып беткән иреннәре арасыннан чак-чак ишетелгән сүзләрне чит-ят кеше аңларлык түгел иде.

— Бүтән... бер адым да... атлый алмыйм, балам... Ике аяк та... бот төбеннән... кисеп алган кебек... Куна калмый булмас...

Зифаның да җеп өзәрлек куәте калмаган иде инде калуын. Шулай да сынатасы килмәде, ни әйтсәң дә әнисе аның хакына интегә, газап чигә бит. Зифа яшь тана шикелле сикергәләгән булып, авыл урамына таба атлап китте.

— Син утырып кына тор, инәкәй, утырып тор. Дөнья гел Хәби сыман ишәкләрдән генә тормыйдыр әле. Кунарга кертүче изге җаннар табылмыйча калмас...

И-их! Чит-ят бәндәләрнең изгелегенә өметләнү язгы бозга таяну белән бер икән шул! Әле бер, әле икенче йорт капкасына сугылып карады Зифа, урамга чыгып сәлам алучы да табылмады. Кайсыдыр йорт тәрәзәсеннән бөтенләй тозсызимансыз җавап ыргыттылар.

— Бетеңне таратып йөрмә монда, әрвах! Куна керәм дигән булып берәр әйберне чәлдерериең бугай...

Ниһаять, мунча кебек кечкенә бер йорт ихатасында Зифага да капка ачучы табылды. Яман чирдән бите шадрала-

нып беткән ямьсез бер хатынкай, күз карашын читкә яшерә-яшерә, өсте печән белән ябулы лапас ягына төртте.

— Өебез бик бәләкәй, анда урын җитмәс. Тарсынмыйсыз икән, әнә лапаста төн куныгыз. Печән җәеп арбага ятсагыз да, сәндерәгә менсәгез дә була. Безне гаепләмәгез инде, өй эчебез тар бит...

Бер кичкә — кер мичкә, Гөлтуташ белән Зифа әнә шулай итеп печән түшәлгән арба өстендә төн үткәрде. Сабак алам дисәң, адәм баласы, бер адым да уйсыз йөрмә икән...

Иртән кузгалып Чишмәгә җиткәндә, төш вакыты якынлашкан иде инде. Әүвәл Гөлтуташ бик елгыр кыйланып вокзал эченә кереп киткән иде, биш-алты минуттан туп шикелле атылып кире килеп чыкты.

— Җыен сары урыс кереп тулган анда. Бер авыз сүз сорашырлык түгел, «чаплашка» диләр дә арт белән борылалар. Урысчаң ярыйсы, ичмаса, бар, син кер, син сораштырып кара инде, балакаем. Моның ише җирдә мин, сантый, шул «уф алла»ны каравыллаудан башкага ярамыйм да бугай...

Зифа кереп поездның кайчан киләчәге турында төпченә башлаган иде, касса төбенә җыелган яшь-җилкенчәк ихахайлап көлде.

— Нинди поезд ди ул? «Кәк-күк, кәк-күк!» Аның дөрес исеме әнә шулай була, эх, син, авыл гыйбады!

— Ә ни өчен «кәккүк»?

— Менә тавышы ишетелгәч үзең тыңлап кара...

Поезд тавышы бер-ике сәгатьтән соң гына яңгырады, ахры. Зифа шундук колакларын тырпайтты, сагаеп тыңлый башлады. Вәт әкәмәт! Стансага керә башлагач та, билгеле бер ара саен, паровоз гел икешәр гудок биреп кычкырта икән ләбаса! Җаена торып тыңласаң, валлаһи да, «кәк-күк, кәк-күк» булып ишетелә икән. Авыл гыйбады булып йөрмә, адым саен сабак ал, яшәргә өйрән, давай, Төркәй кызы Зифа Нәгыймова!..

Берзаманны, ниһаять, вагон эченә кереп урнаштылар. Гөлтуташ ут капкан шикелле тизрәк вокзал перронына сикереп төште. Ә Зифа поезд тамбурында әллә никадәрле вакыт балавыз сыгып торды.

— Кералмыйча кайтып хурлыкларга сала күрмә инде, балакаем. Атагыздан оят,— дип кычкырды аңа Гөлтуташ перрон уртасына баскан көе.— Галимҗан абыең да шуны теләп китте. Хурлыкларга гына сала күрмә...

Чүмәлә чаклы пар болытлары ыргытып паровоз кузгалды, вагон башмаклары шыгырдады. Зифа перрон буйлап атлый-йөгерә үзен озата килгән әнисеннән күз алалмый иде. Тәгәрмәч тавышлары арасыннан берни ишетелмәсә дә, ку-

лындагы кызыл косынкасын болгый-болгый, кат-кат кычкырды ул.

— Хәерле сәгатьтә, инәкәй, хәерле сәгатьтә! Мине оныта күрмә!

## 3

Зифаны техникум бусагасын атлап керүгә үк, өстенә кайнар су сипкәндәй өнсез калдырдылар.

— Документларыңны кабул итеп булмый. Имтиханнар тәмамланып килә бит инде. Иртәгә географиядән генә бирәсе калды. Моңа чаклы нишләп яттың, сантый?

Зифа үзе белән сөйрәп килгән капчыкларны ишек төбендә үк ташлап калдырды һәм шундук директорның кабинетын эзләп чапты. Ул нindидер ике яшь ир белән сөйләшеп утыра икән, Зифа аларны табанына ут капкан шикелле бертуктаусыз таптангалап көтте. «Их, боларга директор янында ни калган инде? Алар укырга керәсе кешеләр түгел ләса, нишләп утыралар? Атылып керәм дә якагызга ябышам бит хәзер. Чыгасызмы сез, юкмы?»

Ниһаять, берзаманны ишекне басу капкасыдай каерып ачып килеп чыкты болар. Зифа тарафына ник кырын гына булса да караш ташласыннар! Укытучылар микән инде болар, әллә Алланың башка төрле кашка тәкәсеме? Атлап йөрешләрен генә кара инде бу ике хөрәсәннең, дөнья кендекләре диярсең, үт-түт-тү-тү!..

Зифа артына ут капкан шикелле бүлмәгә атылып керде һәм бернинди дә кереш сүз ясап азапланмыйча, әзерләп килгән барча кәгазьләрен директорның өстәленә тезеп-җәеп салды.

— Менә таныклык, менә справкы, менә Усманов абый язып җибәргән хат. Ә алар анда минем документларны да кабул итмиләр, сөйләшмиләр дә. Имеш, имтиханнар беткән, географиядән генә бирәсе калган инде. Бик беләселәре килсә, мин бишбылтыр ук килгән булыр идем. Хәби бирмәде бит, Хәби аяк чалды.

Шул рәвешчә, тыр-тыр килеп тезеп чыккач кына Зифа директорның йөзенә караш салды. Менәтерәк! Зифаның документларына күз дә салмый бит бу! Ул ике кулын да күкрәк өстенә кушырып куйган, үзе каш астыннан гына Зифага текәлеп утыра. Җитмәсә, авызын колакларына хәтле ерып салган, менә-менә кычкырып көлә башлар сыман.

— Беттеме? — диде ул, чыннан да, бераздан йомшак тавыш белән көлә-көлә. — Хәбигә булган бөтен ачуыңны чыгарып салдыңмы? Тетеп бетердеңме әле мине?

Ихтыярсыз рәвештә Зифа да үзалдына елмаеп куярга мәҗбүр булды, оялудан иреннәрен каплады, тынып калды. Сантый димә инде! Синең Хәби ятьмәсеннән вакытында чыгып кача алмавыңда Бәләбәйдәге директорның нинди гаебе бар?

Зифаның тик бераздан гына директор тарафына караш ташларга кыюлыгы җитте. Директор аның бүлмәдә барлыгын бөтенләй оныткан диярсең, бар дөньясы белән йотылып ул Усманов язып җибәргән хатны укып утыра. Зифа менә хәзер генә игътибар итте. Карт түгел икән бит бу директор Ильясов та. Кырык-кырык биш тирәсе, Күчәрбайда калган Галимҗан абый белән яшьтәш булырга охшый. Бу да капкара чәчле, әмма маңгай өсте бозау ялап алган сыман шактый пеләшләнгән. Буйга Галимҗан абый, мөгаен, калкурактыр. Ильясов тәбәнәк, юантык гәүдәле, корсагы да ару сизелеп тора. Мәгәр моның куллары Галимҗан абыйныкы сыман бирчәеп беткән түгел, камыр басучы хатын-кызларныкы шикелле ап-ак, йомшак, чиста. Мөгаен, Ильясов шушы техникумыннан, мөгаллимлек эшеннән башка яши алмый торган бер кешедер инде. Зифаның чын зыялы кешеләр турында ишеткәне дә юк. Күрәсең, мул белемле, зур мәдәниятле кеше менә шушы Ильясов шикелле буладыр инде ул...

Ильясов хатны укып бетергәч, әллә нишләп, ике учы белән маңгаен, яңакларын сыпыргалап куйды.

— Яхшы яза, каһәр! — дип телгә килде ул, һич тә күтәрмәгәндә, үзенең карашы исә әле һаман хат өстендә иде.— Казанда укыган чагында ук алар, Шамил абый белән икесе, гел башкалардан аерылып тордылар. Ул чакта ук икесе тиң шәп язалар иде. Шамилләре юкка гына соңыннан чын язучы булып китмәгәндер инде.

Бераздан күк йөзеннән җиргә төште бугай, Ильясов Зифага текәлеп сүз башлады.

— Эх, соңгарак калып килгәнсең, сеңелкәем! Башкаларның бер генә имтихан бирәсе калды. Галимҗан синең турыда бик матур сүзләр яза язуын. Ярдәм итми калма, бер шәп мөгаллимне харап итәсең, ди, бик гозерләп сорый. Әгәр бу баланы алмасаң, моннан ары сиңа кул сузасым юк, дип янаган да әле. Абыйсына охшап, ә-әй, усал соң, каһәр!

Ильясов үзенең күңел хатирәләреннән бик канәгать иде, күрәсең, ул бар дөньясын онытып, туарылып көлде. Аның тешләре чип-чиста, ак, шуңа күрә аны күзәтү дә кызык, рәхәт иде.

— Галимҗан сүзе — закон! — диде ул бераздан, кулларына каләм белән кәгазь ала-ала.— Болай итәбез, кызым. Мин хәзер ике-өч мөгаллимгә записка язып бирәм. Ә син,

давай, иртәгә таңнан ук шуларны эзләп тап та кабинетларыннан чыкма. Мин укырга телим, миннән имтихан алыгыз, дип тыкырдап тик тор, и вәссәлам! Кирәк икән, өннәрен алу өчен әле Хәбине дә өстә.

Ильясов янә кеткелдәп көлә башлаганда, Зифаның да эченә җылы йөгергән иде инде. Директор рус һәм татар теле, тарих укытучыларына язу язып кына калмады, тулай торак коменданты Фәттахов дигән кешегә дә юллама язып тоттырды.

— Бу кешене тапкач, сүз арасында ничек тә җай чыгарып, син аңа комиссар дип эндәш,— диде Ильясов Зифага, бөтенләй үз кеше иттереп, күзен кыса-кыса.— Шуны ишетсә, бу абыең сиңа күк йөзендәге карлыгачның үзен тотып бирә...

Зифа капчыкларын сөйри-сөйри тулай торак дигән ике катлы йортка барып кергәч, Фәттахов атлы комендантны бик тиз эзләп тапты. Табуын тапты, ләкин аның килеш-кыяфәтенә караш ташлауга ук тораташтай калды. Йа Ходаем! Табигатьтә бу кадәр озын буйлы кешеләр дә булса була икән!

Каланча дисәң дә, каланча. Моның буе ким дигәндә ике метр бардыр. Җитмәсә, ул өстенә итәкләре идәнгә тиеп торган соры шинель кигән. Башында кып-кызыл йолдызлы олы буденновка. Кап-кара озын мыек, озынча, ябык йөз, бозауныкы сыман нечкә муен, көрәктәй зур куллар. Ильясов моның хакында юкка гына «ул сиңа күк йөзендәге карлыгачның үзен тотып бирә» димәгән икән шул. Әйе, ике катлы йортның өстәге тәрәзәләрен дә аяк очына басмый-нитми генә йолкып аладыр бу.

— Иптәш комиссар! Сезнең янга иптәш Ильясов мине шәхсән үзе җибәрде,— дигәч, комендант Фәттахов әүвәл ялт-йолт иттереп тулай торак коридорларына караш атып алды. Күрәсең, моның ише сүзнең күп колаклар алдында әйтелүен ул өнәми иде. Әмма икенче мизгелдә үк йөзенә яктылык иңде. Яраткан гадәте, ахры, мыек чылгыйларын сыпыргалап куярга да онытмады хәтта.

— Да, юллама боевой,— диде ул, Ильясов җибәргән кәгазьне пөхтә итәп кире төрә-төрә.— Һәммәсе тәртиптә. Ну, ә син, кызый, безнең карамакка нинди груз белән килеп җиттең? Бозыла, сасый торган продукция юкмы?..

Зифаның капка төбендә калдырган капчыкларын алар тулай торакка Фәттахов белән бергә алып керделәр. Менә шул чагында барына да төшенеп өлгерде Зифа. Ике чиләк бәрәңге салынган капчыкны ун адым күтәреп барса да, бурсык шикелле кызарып һәм шешенеп чыга икән бит Фәттахов. Менә ни өчен каланчадай зур гәүдәле ир-ат гап-гади

комендант булып эшләп йөри икән. Фәттахов үзенең хәлен яшереп маташмады. Зифаның икенче капчыгын күтәреп болдырга керүгә үк, ул шуның өстенә аякларын сузып утырды да, гыж-гыж килеп торган сулышын чак тыеп, үзе әйтеп салды.

— Сивашны кичкәч... Перекопта... әләкте миңа. Аклар... штык белән... туп-туры үпкәгә. Шуннан бирле... ярты гына кеше... Башкаларга... бик сөйләнеп йөрмә...

И-и, сөйләнәме соң! Юлы уң булсын да моның кебек изге җаннар адым саен очрап торсын иде әле!

## 4

Бәхет капусың бер ачылса, кулга алган туфрагың да алтынга әверелә, дигәннәре хак икән ул. Техникумда директорның сүзеннән чыгучы юк, күрәсең, икенче көнне бер генә укытучы да адашып калган кошны кире борып-фәлән маташмады. Зифа белән рус телендә әүвәл диктант үткәрделәр, татар теле буенча имтиханда ул Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы буенча инша язып бирде. Тарих кабинетын тапкач ук шикләнеп атылып кергән иде, анда әле кичә генә Ильясов бүлмәсендә очраткан мөгаллимнәрнең берсен танып бөтенләй коелып төште. Коелмаслык түгел, Солтанов атлы бу мөгаллим Зифадан чак кайтыш яп-яшь егет һәм, чыдамасаң җир тишегенә сикер, ул синнән күз карашын бер генә минутка да аермыйча көйдереп утыра икән. Менә шуңа күрә Зифа ул кушкан «Кытайдагы сары яулыклылар белән кызыл яулыклылар сугышын» хәтерендә яңартырга тырышудан бигрәк, аның карашына түзалмыйча комачтай кызарып утырды. Сөйләгәндә йөз кат буталып бетте, әмма барыбер дә сорауны ахырына тикле ерып чыкты.

Зифа география кабинетын атлый-йөгерә эзләп тапкан чакта, ишек төбендә ике-өч кенә яшь-җилкенчәк калган, имтиханнар тәмамланып килә иде инде. Яшьләрнең Зифаны чиратсыз үткәрергә исәбе юк, ә Зифага бу имтихан поездның соңгы вагоны булып тоела, монысына вакытында кереп өлгермәсә, бөтенләе белән поездан да колак кагар сыман. Зифа кыбырсып-тирләп бетте, имтиханга кереп утыргач та җавап бирергә әзерләнүдән бигрәк, ялт-йолт килеп, укытучыларны гына күзәтүен белде. Боларда миһербанлылык дигән әйбер бар микән ул? Теге сары марҗага туры килсәң, җелегеңне суырып бетермәсме? Менә бу кара башкорт бәхет юлыңа киртә салмас микән?

Имтихан алучыларның өченчесе аеруча усал, кырыс булып тоелды Зифага. Бу абзыйга илле яшь бар да бар инде. Ләкин әнә өстенә ул соры френч кигән, чәчен кырдырып ал-

ган. Гәләфи чалбар, йомшак күн итектән. Бөтен кыяфәте хәрбиләрнеке төсле. Күзләре дә җитди, уйчан моның. Әллә нигә гел Зифа ягына караш ташлап ала.

Көтмәгәндә нәкъ менә шул абзый үз янына чакырып алды Зифаны. Әүвәл үзе белән таныштырды, фамилиясе Ишбулатов икән. Элек башка оешмада эшләп йөргән идем, соңгы дүрт елда шушы техникумда географиядән генә укытам, ди. Ни хикмәт, ул тавышын гел киметеп, башкаларга комачау итмәскә тырышып сөйли иде. Зифа да ике-өч сүз белән үткән бөтен гомерен санап чыкты. «Әти юк, ятиммен. Күчәрбай мәктәбендә укыдым. Директорыбыз Галимҗан абый иде. Бирегә ул җибәрде».

— Беләм, яхшы беләм Усманов Галимҗанны,— дип кабынып китте Ишбулатов абзый. Гаҗәеп хәл, йөзенә елмаю нуры иңсә, ул бөтенләй дә кырыс түгел икән.

— Галимҗанда белем алган баладан беркайчан да начар кеше чыкмас. Моңа иманым камил. Ну, ә хәзер давай имтиханга тотын.

Зифага эләккән билет сораулары әллә ни катлаулы түгел иде. Урта Азиянең климаты, Уралдагы казылма байлыклар турында ул көнбагыш ярган шикелле тукталып та тормыйча ерып чыкты. Европадагы иң зур елгалар хакында сөйли башлагач та яхшы йөк аты шикелле элдереп кенә алып киткән иде.

— Син немец, француз елгаларын мактама миңа, үзебезнекен сөйлә,— дип бүлдерде аны берчак Ишбулатов.

Зифа Днепр, Дунай, Идел елгаларын санап китте, карта буенча һәммәсен күрсәтеп барды. Ә Кама елгасын атагач әллә нишләп төртелде дә калды. Әллә картасы кечерәк иде инде, әллә Ишбулатовның бүлдерүе чыгырдан чыгарды — анысын шайтан белсен. Ләкин Каманы эзли-эзли Зифаның бармак очы Кавказ тавына кадәр төшеп җитте.

— Нәгыймова, иптәш Нәгыймова! Безнең Кама елгасын Кавказга күчердең дә грузин белән әрмәннәргә бүләк иттеңме? — диде дә, Ишбулатов бүлмәне дер селкеткәндәй шаркылдап көлүдән дә тартынмады.

Алланың рәхмәте, әле ярый соңыннан барыбер дә «дүрт»ле куйды үзе. Тик кисәткән шикелле, көлә-көлә дәште.

— Ике-өч ел буе миндә укысагыз, менә дигән географ ясыйм сездән. Миндә укысагыз, әрәм булмассыз сез...

Шулай итеп, бер көн эчендә дүрт имтиханны ерып чыкты Зифа. Аннары яшьләр кулындагы барча кәгазьләрне укыту бүлегенә җыеп алдылар. Көн арты көн уза торды, газаплы, йокысыз көтеп йөрүләр башланды. Ничек итеп нәтиҗә ясарлар, кемнәрне генә сайлап алырлар бу техникум-

га? Әгәр Зифаны кабул итмәсәләр, ул Галимҗан абыйсының күзенә ничек итеп кайтып күренер? Керә алмый калса, газиз башкаена кайсы тарафларда гына урын эзләп карар? Ассалар-киссәләр дә, кабат Төркәйгә кайтмый бит инде ул, кайтмый, кайтмый! Тик кабул итәрләрме әле аны, кабул итәрләрме?..

Тулай торакка яшьләрне санап-нитеп тормый тутырганнар бугай. Арада төрлесе бар. Чишмә, Әлшәй, Бүздәк кебек район үзәкләреннән килгән «шәһәр» кызлары техникумга керү-кермәү турында ике дә уйлап бирми.

— Әй, бу Бәләбәй шәһәрмени соң ул? Тузан оясы и гапгади провинция инде! Кералмыйбыз икән, үкенмибез, кайтабыз да китәбез,— дип, бик эредән кубып сөйләнәләр.

Әмма кич җиттеме, шушы кызлар өсләренә соры төстәге юбка-гимнастерка, башларына зәңгәр берет киеп алалар да, бизәнеп-ясанып, әле клубларга, әле Бәләбәй елгасы ярындагы кечке уеннарга чыгып йөгерәләр. Кич боларга тузан да юк, провинция икәнлеге дә күзгә күренми, вәт осталар!

Зифаның аларга ияреп йөрердәй дәрте, дәрманы юк. Аның башында ике-өч кенә кайгы. Ул укырга керә алырмы да, Галимҗан абыйсы каршында хурлыкларга гына калмасмы? Икенче төп кайгы — ризык, тамак, ашау. Аның Әлшәй, Бүздәк кызлары шикелле иннек-кершән өчен түгеп йөрердәй акчасы юк. Ул алар шикелле ашханәләргә дә кереп утыра алмый. Аның әнисе төяп җибәргән бер чиләк чамасы бәрәңгесе бар да колхоз басуыннан урлап җыйган чөгендере белән шалканы бар. Менә шуларны тартып-сузып билгесез көннәргә чаклы яшисе бар. Өченче төп кайгы... Бәләбәйгә килгәнче анысы юк иде, Төркәйдә чагында онытылган иде. Менә монда килгәч янә калкып чыкты. Ул — әтисе.

Зифа хәзер үзе дә аңламыйча Бәләбәй урамнары буйлап чыгып китә. Бәләбәйдә карарлык, кызыгырлык бина да юк инде. Шул — хәтәр озын булып сузылган аракы заводы бар инде, тукымалар фабрикасы бар, аннары күз төшереп үтәрдәй икеме-өчме бина. Ә Зифаны, урамга чыктымы, әллә нишләп гел төрмә ихатасы үз янына тарта. Ул төрмә коймаларындагы ярык-йорыкларны күзләп йөри, кайчандыр шушында килеп йөргән көннәрен хәтерендә яңарта һәм бертуктаусыз әтисен генә уйлый. Кайда микән инде ул хәзер, кайда гына микән? Сөләйман дигән бәндә менә кайтыр, менә кайтыр, дип юаткан булган иде. Ни әкәмәт, әллә нигә авылдан чыгып качты. Әтисе исән микән дә аның, кайда гына газап чигә икән? Поездларның иң зурлары Бәләбәй аша үтә бит. Ялгыш бүген-иртәгә шушы Бәләбәйгә кайтып төшмәс микән?

Зифа әнә шуларны уйлый-уйлый көненә ике-өч мәртәбә вокзал тирәләрен әйләнгәләп кайта. Берәр поездддан әтисе килеп төшәр дә, кызының монда ятканын белмичә, туп-туры Төркәйгә кайтып китәр сыман. Шуңа күрә Зифа көн саен әллә ничә поездны озатып кала, вагон тәрәзәләреннән гел әтисен эзли. Тик алар өчен билгесезлек кенә хөкем сөрә шул. Эх, дөньясын!..

## 5

Ниһаять, утыз беренче август иртәсендә генә барча яшьләрне дә укыту бүлегенә кабат чакырдылар. Техникумга имтихан биргән һәркем бүген директор кабинетына җыелган олы комиссия каршында әллә нинди махсус әңгәмә узачак, шуннан соң гына укырга кергән-кермәгән икәнлегең билгеле булачак, ди.

Зифа техникумга янә дер калтырап барды. Директор кабинеты тирәсенә якын килмәле түгел — кара болыт. Адым саен әле бер, әле икенче район егетләре-кызлары төркем-төркем булып җыелышкан. Минут саен диярлек директор кабинетыннан чыгып тынычлыкны сакларга чакырып торсалар да, үзен алда эшафот һәм җәллад көткән шикелле, һәркем үзе генә сөйләп калырга ашыга. Берсен-берсе тыңлаучы, ишетүче юк, бар коридор умарта оясы шикелле гөж-гөж килеп тора. Аеруча шул Әлшәй белән Бүздәк кызлары телгә оста инде, чарт-чорт иттереп сагыз чәйни-чәйни теттерәләр генә.

— Әй, кердек ни, кермәдек ни — төкермибез дә без. Бәләбәй шикелле тузан оясының агач техникумында укып йөрү — зур дәрәҗә түгел. Үзебездә ФАШ* бар, культпросвет бар, кайттык-киттек...

Директор кабинетының ишек төбендә аерым спектакль. Кемдер коридорга атылып чыгып кулларын чәбәкли, кемдер тоташ күз яшенә баткан. Соңгыларының кыяфәтенә карап тору да газап. Язмыш уйный бүген, язмыш — Аллаһ.

Зифа күз яшьләрен күтәрә алмый иде. Ул техникумның бөтенләй буш бер коридорын эзләп тапты һәм тәрәзә төбенә басып үз тәкъдиренең сынау сәгатьләрен көтә башлады. Тышта томанлы яңгыр, караңгы көн, гүя табигать тә, бәхете булмаганнарга кушылып, күз яшьләрен коя. Күңел, көчле яңгыр алып килгән кара болыт сыман, икеләнү һәм шикләнү хисләре белән шыплап тулган. Кабул итәрләрме аны бүген, әллә

*ФАШ — фелдьшер-акушерская школа.

юкмы? Кире борып җибәрсәләр, Галимҗан абыйсының күзенә ни йөз белән кайтып күренәсе?..

Зифа директор кабинетына төш вакыты үткәннән соң гына керә алды бугай. Кабинетка өстәмә ике өстәл кертеп куйганнар икән, стена буйлары укытучы халкы белән шыгрым тулы. Зифа шулар арасында Ишбулатов белән Солтановны гына танып өлгерде, башкаларының йөзенә текәлеп күзәтердәй куәте юк иде. Ул география, тарих, рус-татар телләре буенча кырыкмаса-кырык төрле җавап әзерләгән, зиһенендә хәзер фәкать шулар гына бөтерелә иде. «Оренбург каласы Җаек белән Сакмар елгалары кушылган төштә урнашкан...» «Икенче Ялган Дмитрий исеме астына Гриша Отрепьев дигән хыянәтче монах яшеренгән булган...» «Иясе йә хәбәре төшеп калган җөмлә тулы булмаган җөмлә дип атала...»

Бу хәвефләнү-борчылуларның һәммәсе дә юкка булган икән. Сорау биреп торучы мөгаллим табылмады аңа. Кабинетта сүзне, нигездә, директор үзе генә, япа-ялгыз көе алып барды.

— Вәт, менә булдыргансың, кызым, имтиханнарыңның барысын да «дүрт»кә, «биш»кә генә биреп чыккансың бит. Галимҗан сабакташның йөзенә кызыллык китермәгәнсең икән, вәт маладис! Болай булгач, валлаһи да, менә дигән укытучы чыгуы бар синнән... Иртәгә иртән «Д» дигән класска кереп утыр. Иллә дә мәгәр монда да тырыш инде син, кызым, берүк сыната күрмә...

Зифа кабинеттан үзенең ни рәвешле очып чыкканын да абайламый калды. Коридор яшь-җилкенчәк белән шыгрым тулы булса да, араларында Зифа аның муенына барып сарылырдай, шатлыгын уртаклашырдай беркеме юк иде. Тышта яңгыр коеп яуганны да шәйләп тормады ул. Тулай торакта аның көненә ике-өч сүз булса да аралашып йөри торган берничә танышы бар иде, иңнәренә канат үскәндәй, шулар янына очты. Менә хәзер атылып кайтып керә дә комендант Фәттахов абыйсының иңенә сикерә ул. «Иптәш комиссар абый! Мин укырга кердем, Хәбиләрнең борынына чиерттем, котла, котла мине!» — диячәк ул аңа. Ә аннары... аннары яшереп кенә, саклап кына тоткан бер уч шикәр шакмакларын кулына алачак та тулай торакның кечкенә бер бүлмәсендә яши торган Фатыйха әбисе белән Шакирҗан карт янына очынып керәчәк.

Бу карт-карчык белән бик очраклы гына танышты ул. Әлеге дә баягы, шул Әлшәй белән Бүздәк чытлыклары кичке уенга типтерергә киткәч, Зифа олы бер бүлмәдә япа-ялгыз утырып калган иде. Башка бүлмәләрдә кызлар чутсыз, алар-

ның чыпчык көтүе сыман бертуктаусыз чыркылдашканы юка стеналар аша ишетелеп тора. Зифа аларны белми, шуңа күрә язгы оядагы ана каз шикелле берүзе каңгырап утырырга мәҗбүр.

Шул чагында сызак итеп ишек ачылды да ярыкта Фатыйма әбинең яртылаш кына сузылган йөзе пәйда булды. Зифа аны исемләп-фәлән белми, шулай да коридорда, баскыч төпләрендә ике-өч мәртәбә күргәне бар иде.

— И-и, берүзең генә утырасыңмыни, балакаем? — дип, һаман яртылаш сузылган көе генә сүз башлады әбекәй, аннары инде, гайрәтләнеп китеп, бүлмә эченә кергән сыман итте. Тик барыбер дә ул бүлмә идәненә сыңар аягы белән генә кереп баскан, ярты гәүдәсе коридорда торып калган иде.

— Алайса, теге нәсел айгырлары кайтканчы, мин бик тиз генә идәннәрне юып чыгыйм әле.

Алны-артны уйлап тормыйча, Зифа шулвакытта үзе сикереп купты.

— Юк инде, нишләп сиңа юдырыйм ди, апа. Бу бүлмәдә без яшибез ләбаса. Кая, чиләк белән чүпрәгеңне бир дә, мин аны үзем «ә» дигәнче җыештырып чыгам.

Әбекәйнең йөзе әүвәл яктырып китте, аннары кырау төшкән үлән сабагы сыман тагын шәлперәйде.

— Торна Фәттах күрсә... әрәмтамак диеп... бүлмәбездән куар...

— Юк инде, юк, беркем күрми-белми. Мин идән юуны Әстерхан юлы сымак озын-озак итеп сузып тораммыни? Шырпы янып сүнгән ара узмас, ялт-йолт итеп, маминт әйләнермен,— дип, Зифа аның каршына атлы казак кебек килеп баскач кына, ниһаять, әби кеше чиләк-чүпрәкләрен кертеп бирде...

Аннары алар кечкенә бүлмәгә кереп чәй эчтеләр. Соңыннан да Зифа әле ике-өч мәртәбә Фатыйма әбигә идән-тәрәзәләр юышты. Бушка эшли торган булышчыга Шакирҗан карт та шат иде, күрәсең. Зифа белән карчыгы чәй яңартаяңарта чөкердәшкән чакта, ул өстәл артында кет-кет көлеп утыра торган булды...

Әмма Зифага бүген карт белән карчык янында шатлык уртаклашу тәтемәгән икән. Тулай торак бусагасын атлап узса, барча бүлмәләрдә гүя пәри туе. Бер төркем яшь-җилкенчәк мендәр-матрас күтәреп баскыч буенча беренче каттан икенчесенә йөгерә, нәкъ шундый ук икенче бер төркем нәкъ шундый ук йөкне иңбашына алып икенче каттан беренчегә төшә. Барча бүлмәләрнең ишекләре ачык. Һәр бүлмәдә әл-

лә кемнәр әллә нинди кирәк-яракларын биштәрләргә, капчыкларга төйи. Бөтен җирдә тузан, мамык, чүп-чар. Һәр почмакта кычкырыш, акырыш, талаш.

— Минем зәңгәр итәк кая, итәк кая? Бик кызыгып карап йөридериең, син урлагансыңдыр әле, Миякә аңгырасы! Укырга кералмадым, ичмаса, берәр нәрсә чәлдереп качыйм, дигәнсеңдер инде.

— Ә-әнә Саниянең караваты астында аунап ята бит ул синең кылкаң. Күзең чыкканмыни, Туймазы кыңгыравы, юньләп кара!..

— Икенче кат икенче курстагылар өчен бит ул. Кая тыгыласың, син, салага!..

— Ә-әй, якташ, дим, якташ! Бу матрасны кемгә тапшырасы да, дакуминтларны каян гына барып аласы соң?..

Биредәге мәхшәр сәбәпләре Зифаның зиһененә тик бераздан гына барып җитте. Бактың исә, укырга керә алмаган бәхетсезләр имтихан чорына дип алган мендәр-матрасларын кире илтеп тапшырырга тиеш, шунсыз аларның документларын кулларына кабат бирмиләр, ди. Монысы инде аңлашыла сыман. Ләкин ни галәмәт, егет-кызларның укырга кергәннәренә — студент булганнарына да шул ук тәкъдир: син әүвәл вакытлыча алган мендәр-матрасыңның исән-иминлеген илтеп күрсәт, аннары сиңа шул ук әйберләрне, әллә нинди махсус карточкага тутырганнан соң гына, кире биреп җибәрәләр икән. Ә ул карточкаларны тутыручы «кәстиләнше» дигән ниндидер марҗа хатыны техникум ихатасындагы аерым складта утыра, ди. Болары гына бер хәл, өстәвенә бүген тулай торакка икенче курс студентлары кайтып тулган. Кем кайсы катта, кайсы бүлмәдә һәм ничәшәр кеше булып яшәячәк — моны эт тә белми. Бөтен кешенең авызында имеш-мимеш...

Тулай торакка комендант Фәттахов кайтып кергәч кенә, алда торган бурыч ачыклана төште. Фәттаховның йөзе мичтән чыккан сыман янып пешкән, үзе паровоз шикелле пуфпуф килеп сулый.

— Ике ат арбасы... карават алып кайттым... Кем укырга кергән... шулар чыгып алсын... Икенче каттагы дүрт бүлмә... икенче курсныкы... Быел кергәннәр... беренче каттагы биш бүлмәдә тора... Бүлмә саен... унбиш-уналты кеше... җайлап урнашыгыз...

Тагын артларыннан җен куган шикелле, ярты халык берьюлы тышка ябырылды. Тимер караватлар ташып аларны җыйнадылар. Култык асларына мендәр, юрган, матрас кыстырып техникум ихатасыннан тиз-тиз әйләнделәр. Идәннәр-

не юып-себерештереп, караватларны бүлешеп мендәр өстенә борын төрткән чакта, төн уртасы җиткән иде инде. Тик аруталуга зарланып авыз ачучы һичкем табылмады. Язмыш җиле уңай исеп торса, бәхет канатлары таламыни!

## 6

Яшен сыман ялтырап көн артыннан көн үтеп кенә тора, ә Зифаның әле һаман техникум тормышына ияләнеп китә алганы юк. Иң авыры — уку. Ходайның рәхмәте, әле ярый география, тарих, тагын бер-ике фән кергәндә, классларны икеләйгә бүлеп, яртысын — рус, яртысын татар телендә укыталар. Ишбулатов белән Солтановның мәкам-сөйләменә Зифа тиз ияләшеп өлгерде, география белән тарихны су урынына эчә дисәң дә, һич арттыру булмас. Зоология белән биологиядән укытучы Мортазинга да тел-теш тидererлек түгел. Авыл мәктәпләреннән килгәннәрнең карга баласы сыман авыз ачып утыруын күрсә, ул шундук татар теленә күчә, бер теманы һич тә иренмичә кабат-кабат сөйли.

Ну, ә ул геометрия, математика, химия, физикадан кергән марҗа хатыннары! Инде, инде! Йә ачуыңнан ядрә сыман шартлап үзең егыл да үл, йә телләрен өзеп ал шуларның!

Син чукындырудан качып урман эченә поскан чеп-чи татар авылыннан килгәнме, туган мәктәбеңдә урыс телен нинди дәрәҗәдә һәм кем укыткан сиңа — боларның черки борыны хәтле генә дә бер эше юк. Борау сыман бөдрәләтеп куйган чәчләрен ялдай җилфердәтеп ишек бусагасы аша атлап керәләр дә синең агач сын шикелле катып калган йөзеңә күз дә салмый сиптерәләр генә.

— Если «а» квадрат плюс «в» квадрат загнать под радикальный знак и извлечь корень...

— К соли кальций эс о четыре добавляем воду аш два о и получаем щелочь кальция «ка два о аш»...

Зифа, агу йоткан кеше шикелле, күзләрен акайтып тик утыра, марҗаларның бер сүзен дә калдырмыйча тыңлый, әмма бер генә җөмлә дә аның зиһененә тулысынча барып җитә алмый. Нинди тамыр да нинди генә селте соң инде ул тагын? Үлән тамыры була инде ул җир йөзендә, кан тамыры була. Әйе, дөрес, тамыразык дип атала торган чөгендер, кишер бар. Ә ул «а квадрат белән в квадрат» дигән нәрсәләрдә нинди тамыр булсын?.. Аннары, ниндидер тозга су китереп кушкач селте чыгамыни? Селтене бит аның әнисе суга көл тутырып ясый торган иде. Шул селте дигән нәмәрсә белән башын юган чакта ничекләр генә үкереп еламый иде Зифа! Ә монда... тоздан селте, имеш. Сантыйлар бар ди

сиңа Төркәйдә! Тозны ашка салалар, селтене көлдән ясыйлар ул безнең якта!..

Зифа күңеленнән генә рус укытучылары белән шулай әрепләшә, үзен-үзе юатмакчы була. Ләкин аның күңелендәге бу күренмәс кикрик, икенче дәрескә кергәч, капылт җимерелә шул.

— Сегодня будет отвечать... Сегодня будет отвечать,— дип, укытучылар дәрескә хәзерлекне тикшерә башлауга ук, Зифаның да, тагын дистәләгән егет-кызларның да борыннары түбән салына, лышык-лышык килә. Ә маржалар иске теманы кабатлап та тормый, телләрендә татарларга карата ике-өч кенә бәя:

— Дубина, пень, чурка!..

Татарларның да студентлар арасында төрлесе бар икән. Әнә Чишмәнең үзеннән — район үзәгеннән килгән Мәгубә Сыртланова дигән кызый техникумны, фән һәм дәресләрне өшкереп тә бирми. Аның әти-әнисе егерме беренче елгы ачлык вакытында ук әрәм булганнар, ди. Чишмәдәге ятимнәр йортында гел урысча укып һәм урыс башкисәрләре белән сугышып үскәнгәдер инде, Мәгубә өчен тормышта бөтенләй киртә-тоткарлык юк. Ул техникумга кабул итү имтиханнарын да тапшырып тормаган, аны ниндидер махсус фәрман буенча монда күчергәннәр.

Мәгубә үзе ятимнәр йортын берчакта да җылы сүзләр белән искә алмый.

— Ничек яшәдең соң анда, авыр булмадымы? — дип сорау бирделәрме, җавабы балта йөзе күрмәгән түмәрнеке сыман тупас, шыксыз.

— Хуҗасыз эт тормышы инде, кит, пычагым. Берсе «Маша» дип кычкырып мыскыл итә сине, икенчесе «Марго, Маргарита» дигән койрык такмак була. Уфа урамыннан тотып китерелгән Шакирҗан Мөхәммәтҗанов дигән бер сукбайдан, чукындырып-нитеп тормыйча да, Александр Матросов кушаматлы урыс ясадылар. Актаныш тирәсеннән килгән Котдус атлы ятим Николай Орлов дигән урыска әверелде. Анда шулай, сукыр көчек кебек юашланып торсаң, сиңа момент тәре кидерәләр. Аннары, бар, гомер буе дөя түгеллегеңне исбатлап йөр.

— Ә син үзең?

— Һе, миңа да Мария Сидорова дигән йөгән кидермәкчеләр иде. Аеруча Әрлән кушаматлы марҗа үзәгемә үтте. Ияге менә шулай итеп ике якка салынып тора иде аның. Борынын да менә болай итеп, өскә таба тырпайтып, сызгыра-сызгыра сулыш ала иде. Шуңа Әрлән дидек. Шул каныкты берчак. «Татарва булып йөрмә, перспективаң бетә, әйдә, мит-

рикәңне алыштырабыз» ди. Ну, берничә көн түзеп йөрдем дә, теге Әрлән йокларга ятып сызгыра башлауга ук чәченә ут төрттем.

— Ни эшләттеләр соң үзеңне?

— Берни түгел. Өч ай чамасы Чишмә төрмәсендә утырып чыктым...

Мәгубә техникумда да элеккечә елгыр. Дәресләрдә аңа кайсы фәннән генә сорау бирмәсеннәр, ул сукыр тычкан шикелле әле алай, әле болай иттереп тырмаша-казына, тик ахырда барыбер ерып чыга. Урыс телен белгәч, аңа рәхәт, аны «пень, дубина» дип рәнҗетмиләр.

Ни хикмәттер, Зифа менә шушы Мәгубә белән тулай торакта да бер бүлмәгә эләкте. Зифа үзе моны «Ходайның рәхмәте» дип бәяләгән иде, башка кызлар «афәт, каза» диядия, гел-гел мыскыл итте. Чынлап торып уйлый калсаң, ике як та хаклы булгандыр, шәт.

Мәгубә рус телендә суга чумган балык сыман йөзә, Зифа исә, шуннан файдаланып, әллә ничаклы темаларны тегеннән бөртекләп, җентекләп аңлаттыра иде. Дөрес анысы, Мәгубә, бүтәннәр шикелле, тулай торакта үткән теманы кабатлап, өйгә эшне үтәп азапланмый. Аның хәтере шәп, дәрестә укытучы сөйләгәнне, черки аулап утырган күл бакасы шикелле, йотып кына бара. Зифа төпченгән вакытта да китап-дәфтәр битен актарып тормый, күзе киткән оекбашны тартып сүткән сыман, хәтер йомгагын гына тәгәрәтеп җибәрә. Ә рус телен юньле-башлы аңламыйча калган Зифага шул да җиткән. Анысы өчен дә Зифа аның бер алдына, биш артына төшә.

Иллә мәгәр... иллә мәгәр шушы Мәгубәдә холык дигәннәре, ай-һай, коры инде. Нәкъ чакматаш! Теленә шайтан төкергән диярсең, юньле бер сүзе юк.

Бервакытны, ашханәгә кергәч, Рәкыйп Юнысов атлы Туймазы егете сыңар телем икмәген чәлдергән бит моның. Мәгубә шуның өчен аны бөтен курс студентлары каршында иләргә салынган тире сыман тетте.

— Кеше малына тагын бер мәртәбә үрелгәнеңне күрсәм, фәлән әйбереңне тартып өзәм, шакал! Ичмаса, синең ише хөрәсән, имгәкләрнең нәселе корымасмы?..

Шуннан соң бичара Юнысов атна буе бүлмәсендә гел бикләнеп ятты...

Мәгубә бүлмәдәге башка кызларга да тынгы, ирек бирми. Кичке сигез тирәләре җиттеме, үтүк-марля эше уртак малга кагыласы булма, ишек янәшәсендәге бердәнбер көзгене дә гел урап үт!

Үзе юкка чыккач, бүлмәдәге кызлар Мәгубәдән әллә нинди сырлар таба-таба көлә:

— Ни биле юк, ни кыяфәте! Борын астына ирләрнеке сыман мыек үсеп беткән.

— Бик кирәкле кишер яфрагы кебек көн саен кич чыгып киткән була. Моның ише ирдәүкәгә кем карасын инде? Хәтта ачлык елны алтын бирсәләр дә ялап караучы табылмый бит аны...

Кызлар бик кызып киткән чакларда Зифага да эләгә.

— Нигә дип кенә син шул ирдәүкә алдында тәлинкә тотасыңдыр? Җен башка, пәри башка дигәндәй, син бөтенләй дә иш түгел бит аңа, бүтән төрле чүпрәдән куелган камыр ласа...

Каршы әйтеп, кызган ташларына су бөркесә, тегеләрнең тагын әллә ниләр тезеп китүе бар, Зифа түзә, дәшми. Ярар, Зифа — камыр, ә Мәгубә ирдәүкә дә булсын. Иллә мәгәр, кызлар хәрәмләшә, Мәгубәне юкка, бер дә юкка шыксыз күрсәтәләр. Чынлап торып баксаң, Мәгубәдә егетләрне җепкә таккан сыман тартып китерердәй матур яклар байтак. Ул, Зифа шикелле, торна сыман озын, ябык түгел. Ботлар, имиләр таза, гәүдәсе тал чыбыгы сыман сыгылмалы. Көн саен кич яратып кия торган зәңгәр гимнастеркасын да элеп алса, Мәгубәнең күкрәкләре, икесе ике йомгак шикелле, үзенә тартып тора. Мәгубәдә чибәрлек тә хәттин. Күпчелек татар кызларыныкы шикелле озынча йөз; калын, мул иреннәр; көянтә сыман сузылган куп-куе каш; ике толымга үрелгән чемкара чәч һәм... шайтан уты кебек ялтырап-уйнап торучы карлыгандай күзләр. Э-э-эх! Моның ише чибәрлек-сылулык Зифаның үзенә тәтимени әле?!

Зифа чамалый, билгеле, кызлар кайчакларда «майга буяп ташласаң да, эт яламас нәстә», дип Мәгубәне нахак мыскыл итә. Үзләренең клубларга, кичке уеннарга чыкканнары юк бит, кызлар көнләшүдән шулай сөйләнәләр. Ә Зифа менә Мәгубә ахирәтенең барча серен белә. Соңгы көннәрдә Ярмәкәйдән килгән Сәйфи атлы егет белән сиптерә ул. Тегесе механизаторлар курсында укып йөри икән. Мәгубә аны: «Белый танец вакытында үзем каптырдым», — ди. Биюләрнең агы, карасы да була микәнни соң? Зифа моны һич тә аңлый алмый. Гомумән, күзе яңа гына ачыла башлаган эт баласы шикелле, күп нәрсәне аңламый әле ул бу дөньяда.

Менә шул ук Мәгубәне генә тыңлап кара.

— Сәйфинең килмәгән бер ягы юк. Үзе буйга гөрнәдирдәй озын, беләкләре гер тотырган сыман. Бозау шикелле мәлҗерәп тә тормый. Үбешкән чакта телне авыздан чүт суырып алмый.

(Зифа уклау йоткан шикелле хәрәкәтсез кала. Йа Хода-

ем! Тел чыгаргач, ничек итеп үбеп була да, андый үбешүләр нигә кирәк икән?)

— Яратам егетләрнең боевоен! — дип, Мәгубә кулы белән һаваны кисеп ала.— Егет булса, яшен ташы сыман үткер булсын, канса да канис. Однакы... однакы бу Сәйфи белән туйганчы бер гүләйт итеп тә калып булмас инде. Тагын ике ай гына укыйсы калды шул инде минем гөрнәдирнең. Аннары әллүр Сәйфи Ярмәкәйгә, Бәләбәйләр сау бул!

Зифа янә кайнар аш капкан шикелле коела да төшә.

— Бәрәч, бәрәч... Кавышырлык булмагач, Сәйфи белән нигә йөрисең соң?

— Нинди кавышу тагын? — дип, Мәгубә аны, әле ярый, куып алып китми.— Бөтен егетләр белән дә кавышу өчен генә йөриләрмени, надан? Җайларын өйрәнү, тегесен-монысын белү өчен дә тәҗрибә кирәк бит...

Менә шулай итеп Мәгубә көн саен диярлек Зифа белән «наданлыкны бетерү курслары» алып бара. Зифа — күндәм укучы, берчакта да аңа каршы килми. Әнә Шакирҗан карт кичләрен ихата капкасын бикләп куя башлагач, Зифа төн уртасы җиткәнче йокламыйча, Мәгубәнең кайтуын көтеп ята. Тегесе тәрәзәгә берәр балчык кисәге ыргытып шылт иттеме, Зифа, күктәге ай шикелле «ялт» иттереп, сикерә дә чыга. Кызлар ошатмыйлар. Телләрендә шайтан таягы кебегрәк гел кадау сүз.

— Шул ирдәүкәгә ничек түзәсеңдер? Шуның хезмәтчесенә әйләнеп беттең инде тәки...

Сизенә, аңлый Зифа: болар аның кайчакларда Мәгубәнең итәге белән оекларын чайкаганга төрттерәләр инде. Ләкин Зифа бер анысын гына юамыни? Саный китсәң, әнә икенче курстагы марҗа кызы Распутина да аңа атна саен диярлек юрган-мендәр тышлары белән бергә эчке киемнәрен дә кертеп ташлаштыра. Өстәвенә һәрбер шимбә-якшәмбе саен Зифа әле Фатыйма карчыкка да бүлмә-коридор идәннәрен пычак белән кыра-кыра юыша, ярдәм итә. Башка яктан кәтәрдәй кереме-табышы булмагач, Бәләбәйдә япа-ялгыз яткан унбиш ярым яшьлек кызый ни эшләсен? Менә шуңа күрә кайда өмет учагы кабынса, шул тарафка бил бөгәргә мәҗбүр. Аның каравы, әҗере дә бар бит. Марҗа кызы Распутина, беркадәр киелгән булса да, үзенең былтыргы бумазый пинжәген бирде әле аңа. Сентябрь үтеп бара, көннәр салкынайтты, әнисе тегеп җибәргән бер кат күлмәк белән генә инде түзеп булмый.

Ә Фатыйма карчык? Анысы бүтән төрле юаныч, икенче бер табыш. Дөрес инде, Фатыйма карчык белән Шакирҗан карт янына кереп тә бик еш кына тамак үткәрә ул. Техни-

кумда иртән бирелгән бер тәлинкә ботка, көндез өләшенә торган кәбестә шулпасы һәм төйгән бәрәңге белән генә торнаныкы сымак ябык, озын аякларны сөйрәп буламыни? Ялгыз көе яшәп яткан карт белән карчыкта да Гәрдән кулак өстәлендәге шикелле муллык юк инде ул югын. Кайчан керсәң дә, сине боларда шул бер телем кара икмәк белән сөтле чәй генә каршы ала, иллә мәгәр анысына да рәхмәт. Иң мөһиме — Зифаның тулай торакта яннарына кереп серен-хәвефләрен сөйләшердәй өлкән дуслары бар, чит-ят күзенә бик үк күрсәтергә ярамаган вак-төякне кертеп яшерердәй тыныч почмагы бар...

Әнә шулай әвеш-тәвеш килеп, укып йөри торгач, сентябрь ае да үтеп киткән икән. Бер шимбәдә Зифа мич башына куелган чабатасын кулына алган иде, теге бахырларның кыяфәтенә күз салуга, коелды да төште. Ике чабата да бер көтү ат тоягы астында калган шикелле изелеп, таралып беткән, табаннары ике-өч җеп очында «менә өзеләм, менә өзеләм» дип бәллүләп кенә тора. Дәрес башланыр минут якынлаша, тышта яңгыр, ни хәл итәсе соң?..

Зифа ике чабатаны да, яман болгап, янә мич башына атты. Үзе, парадка чыккан солдат сыман дөпе-дөпе басып, техникумга чапты.

Кире кайтып керсә, тулай торак баскычында ике кулы белән бөеренә таянган комендант Фәттахов моны көтеп тора.

— Иртәгә техникумда генеральни убуркы. Кем катнаша һәм дә анда дабрасавис эшли, шуңа өчәр тәңкә. Матри, кызый, килми генә кара...

Менә монысы — баласы, мичтә калган анасы, дигәндәй, Фәттаховның чыгышы көтелмәгән бүләкләрнең башы гына булган икән әле. Төнлә тәрәзә шылт итүгә чыгып капка келәсен ачса, Мәгубә моның изүенә ниндидер бер төргәкне көчләп-мәҗбүриләп тыкты да куйды. Тулай торак коридорына кергәч кенә күз салырга өлгерде Зифа. Нәкъ аның аякларына яраклы бер пар сандали бу. Әмма... яңа түгел. Кемдер, ничәдер көннәр буена өстерәгән моны...

Зифа төне буена керфек какмый чыкты. Нинди сандали бу, Мәгубә аны кайдан алып кайткан? Аңа — ике тиен бер акча, ул, гомумән, ташбаш. Әгәр чәлгән булса? Шулай икән, ул чагында бүгенме-иртәгәме Зифаның чыраена әллә нинди кешеләрнең килеп ябышуы бар бит. Ул чагында... ул чагында Зифаны техникумнан сасы пумала селтәп куачаклар. Аннан соң Зифа кая барсын?..

Икенче көнне Зифа сандалины Фатыйма карчыкларга кертеп яшерде дә тулай торактагы өмәгә янә яланаяк китте. Аның каравы, дүшәмбе иртәсендә Зифа инде техникум

баскычында өр-яңа резина итекләр кигән көенчә, авызын колакларына кадәр ерып, иң бәхетле кеше сыман басып тора иде.

## 7

Чып-чын асыл кышны унбишенче октябрьдә үк килеп җитәр дип кем уйлаган? Гәрчә быелгы беренче кар нәкъ шул көн иртәсендә килеп ятты да җир өсләре бүтән инде аннан арынмады.

Зифаның кышка киярдәй киеме юк иде. Култык асты сүтелгән, терсәк тирәләре тишелеп чыккан иске кофта биреп булса да, әле ярый Фатыйма карчык ярдәм кулын сузды. Хәер, аның көннәре дә студентлар өчен суык-салкыннарны сизә торган вакыт түгел иде. Беренче чирек ахырына якынлаша, көн саен диярлек әллә ничәшәр фәннән контроль эш, зачет, семинарлар. Тыштагы табигатькә, төнгә-таңга игътибар итүче юк. Һәммәсе тулай торак белән техникум арасында йөгереп йөри, һәр студент самавыр торбасы шикелле уттай кызган.

Ноябрь аена аяк баскач кына хәлләр берникадәр ачыклана төште.

— Миякәдән килгән Низам белән Флүрәгә алты фәннән «икеле» чыгарганнар.

— Тозлыкуштан килгән ике игезәк, Фәнисә белән Фәниләә, укырга акчабыз юк, дип кайтып киткәннәр, ди. Ә дөресе — рус теле белән химия укытучылары аларны зачетка да кертеп тормаганнар...

Тулай торак бүлмәләрендә урыннар бушый башлады. Киткәннәр урынына аерым фатирда торып чиләнгән яңалар кереп урнашты. Ләкин укыту бүлегендә санап-көтеп торганнардыр инде, беренче курстагы биш группа укучыларын бергә куштылар да, һичкемгә аңлашылмас, дөм караңгы җирәбә буенча, өр-яңадан дүрткә аердылар. «Д» классы шулай юкка чыкты. Ни хикмәттер, Зифа белән Мәгубә янә бер төркемгә эләккән, алар хәзер «Г»га күчкән иде. Бу хәлгә шатланырга гына кирәклеген Зифа бер-ике көннән соң ук тиз төшенде.

Дүртенче ноябрьнең кичендә беренче курс студентларын коридорга чыгарып тезделәр дә, тәүге чирекне уңышлы тәмамлаган студентларның исемнәрен санап, көзге каникулларга таралу хакында фәрман җиткерделәр. Яхшы укучылар исемлегендә үз фамилиясен ишетү, әлбәттә инде, Зифа өчен бәхет, ләззәт иде. Тик каникул турында әмер булгач кына, ике яр уртасында ишкәкләрен җуйган мескен көймәче шикелле, ул ни кылырга да белми утка төште. Каникул, бер

атна ял... Авылга кайтып, үзеңнекеләрнең хәлен белеп килсәң, әйбәт инде ул, әйбәт, күңелле эш... Мин студент дигән булып, күкрәкләрне гармун күрегедәй мул киереп, Хәбиләрнең, Кара тавыкларның капка төпләреннән үтеп китү үзе генә дә күпме ләззәт тора! Иллә мәгәр... иллә мәгәр, каһәреңне өшкерим, юлга чыгып китәрдәй рәте-куәте бармыни соң аның? Өстеңә кияргә киемең, юлга түләргә акчаң, синең ишектән бер күренүеңне биш күз белән көткән эне-сеңелеңә, газиз әниеңә чыгарып бирердәй өч тиенлек тә күчтәнәчең булмаган көенчә нинди йөз, нинди тәкәбберлек-көрпәлек белән туган авылыңа кайтмак кирәк ди ул?! Теше-егәре ауга ярамаган бүрене туганнары да сөйми. Чыдамасаң, ярдан суга сикер, бәкегә төш, әмма кичә генә үзеңне типкәләп йөрткән авылдашларың каршында эт талаган хәер эстәүче шикелле мескен, йолкыш, зәгыйфь булып күренмә инде син!..

Зифа йөрәгендә янган утны Мәгубә дә сизеп торган, ахры. Коридордагы күмәк линейка таралып китүгә үк, ул Зифаны үзе белән дәште.

— Түтәңне комсомол комитетына чакырганнар иде. Стенгазета чыгарасы бар, диделәрме шунда, Октябрь бәйрәменә концерт әзерлиләрме — аларны шайтан белсен. Барыйк, карыйк, аннары күз күрер, дип әйткән ди дөм сукыр бер бәндә. Әйдә, керик әле.

Зифаның ишеткәне-күргәне юк иде, комсомол комитеты урнашкан кечкенә бер бүлмә икенче катка менә торган баскычның астында гына икән. Монда озынча бер өстәл, алтыҗиде урындык, стенага тарттырып куелган ефәк кызыл байрак, зур итеп ясалган Сталин рәсеме һәм... кәндил-фәләнне мәңге дә күрмәгән-тәтемәгән сыңар электр лампасы.

Бүлмәдә ике яшь кыз белән нибары бер егет өстәл өстенә капланып утырганнар. Өстәлдә буеннан-буена сузып салынган чаршау чаклы кәгазь. Кызларның берсе линейка белән нindидер тамгалар билгели, икенчесе каләм башын тешләгән көенә гүя мәрткә киткән. Сыңар егет кулына биш-алты төстәге карандашлар тоткан, ул «чаршау»ның бер башына байрак, плакат сурәтләре сырлап маташа.

Әүвәл Зифага сәлам бирүче дә булмады, кисек чәчле кызлар Мәгубәгә генә бер-ике сүз ыргытты.

— Иртәгә комитет. Җидесе көнне колоннада узачак классларга урын билгелибез.

— Плакатларны да курсларга бүлеп чыгасы бар. Берүк онытма, Сыртланова, иртәгә кил инде син...

Зифага егет кеше генә игътибар итте сыман. Ул карандашларны тел очына тидерә-тидерә буявыннан кат-кат бүленеп, яңа кызга берничә мәртәбә караш ташлап алды.

Әлбәттә, Зифа да, үз чиратында, бу «рәссам» егеткә күз йөгертеп чыкты.

Зифаның үзе шикелле үк ябык, озын гәүдә. Моның муены да аккошныкы сыман озын, нечкә. Коңгырт чәче керпе энәләре шикелле төрле якка тырпаешып тора. Мыегы бик үк куе һәм мул да түгел, моңа унсигез яшьтән дә артык булмастыр, шәт. Күзләре җитен чәчәгедәй куе-зәңгәр. Киеме бик гади: сатин күлмәк, кемнеңдер иңеннән күчкән иске гимнастерка. Куллары бирчәеп беткән. Юк, әллә кем түгел, Зифа кебек үк гап-гади авыл гыйбады бу!..

— Һади, Һади! — дип эндәште аңа көтмәгәндә бер «кисекчәч».— Синең рәсемнәрең бетәме соң инде? Язмаларга урын билгелисе бар бит.

— Сез студентлардан эшкә яраклы берәр нинди шигырьмазар җыйдыгызмы соң әле?..

Шул чагында кызлар Зифага сагыз сыман булып ябыштылар.

— Сиңа камсамульски задәнҗә. Менә шушы төшкә куярга группаңнан берәр нинди шигырь табып китер.

Зифаның чалгы йөзенә эләккән үлән төсле кыелып төшкәнен сиземләде бугай, бу юлы да Мәгубә үз вакытында ярдәм кулын сузды.

— Задание бирергә не имеете право. Сез аны башта комсомолга алыгыз әле, аннан боерырсыз.

Каршыларына басу карачкысын китереп бастырганнар диярсең, ике кызның да күзләре шакмак сыман булды.

— Бәрәч, бәрәч, син әле комсомолка да түгелмени, кызый? Моңа хәтле урманда качып яттыңмы әллә? Техникум хәтле техникумга килеп җиткәнче нишләп әле син комсомолга кермичә йөрдең?

Зифа өчен тагын Мәгубә җавап бирде:

— Ул күрше авыл мәктәбенә йөреп укыган. Ә үзләренең унбиш-егерме йортлык авылында комсомол ячейкасы да булмаган, ди.

— Унбиш-егерме генә түгел бит инде, күбрәк! — дип, Зифа шундук чәчрәп чыккан иде, Мәгубә аның телен барыбер тиз тешләтте.

— Ярар, авылыгыз егерме йортлы гына түгел, зуррак тадыр инде. Однакы комсомол ячейкасы барыбер булмаган бит, менә шунысы хакмы?

Зифа сүзсез генә ияк кагып куярга мәҗбүр булды. Шуны күреп, кызлар янә кабындылар.

— Иртәгә балалар укытасы кешенең комсомолка булмавы позор! Моңа юл куймыйбыз, студентлар каникулдан килүгә үк алдырабыз сине.

Бераз гына вакыт көттеләр дә, бозылган пластинкага куелган энә шикелле, тагын иске эзгә кайтып төште болар.

— Сиңа задәнҗә шул ук. Менә бу төшкә куярга берәр шигырь китер…

Унбиш-егерме минут вакыт үтүгә, Зифа бүлмәгә сыңар кәгазь кисәге күтәреп кире килеп керде. «Кисекчәчләр» аның кулыннан йолкып алуга ук, шайтан сыман шәрран ярып кычкыра-кычкыра укый башладылар.

Минем алдымда китап,
Укысам, ул йобата.
Авылда әнкәй уятса,
Монда радио уята.

— Булган бит бу, булган! — дип кабат-кабат шәрран ярды кызлар.— Заманча дух бар, рифмасы шәп. Тора-бара менә дигән шагыйрь дә чыгар әле синнән. Болай булгач, алмый димени, алабыз без сине комсомолга!

## 8

Ноябрь азакларында Бәләбәйгә Гөлтуташ килеп төште. Әлбәттә инде, Зифа аны көтмәгән дә иде.

Дәресләрдән соң китапханә аша урый-урый тулай торак ихатасына кайтып керсә, баскыч төбендә иске яулык-шәлләргә төренеп беткән, яртылаш бөкрәйгән бер хатын утыра. Зифа аның карашын очратуга ук агарды да катты. Йә Илаһым! Аны дөньяга яраткан, төн йокыларын йокламыйча үстереп кеше иткән, алтмыш чакрым араны дилбегә озынлыгы да күрмичә, Чишмәгә тикле килеп, кырыкмаса-кырык төрле дога укый-укый озатып калган газиз ана бит бу!

— Ин-нәй! Инәкәем! — дип өзелеп кычкырды да, канатланган шикелле очып килеп, Зифа аны кочагына алды.

— Монда салкын бит, нишләп тышта утырасың, әнкәй! Әнә кулларың боз шикелле. Әйдә, эчкә керик, хәзер җылынырсың.

Гөлтуташ әле һаман бер сүз дәшми, ул өске ягы кисеп ташланган агач төбе шикелле кымшана да алмый утыра иде.

— Эчкә керик инде, әнкәй, эчкә керик,— дип Зифаның бертуктаусыз тыкырдатуына буйсынып аягүрә күтәрелгәч кенә, ниһаять, Гөлтуташның авызыннан беренче сүз чыкты:

— И кызым, кызыкаем! Әллә, ниме, әллә… эчкә кереп тормыйм микән, бәбкәм? Ни бит, ни бит, Зифа балакаем… Кешеләр алдында чишенердәй юньле киемем дә юк… Иптәшләрең алдында оят булуы бар…

Зифаның керфекләреннән беренче күз яшьләре, бәлки, нәкъ менә шул минутта тамгандыр да.

— Ни сөйлисең, әнкәй? — дип ачыргаланып, янып эндәште ул.— Ниткән кием ди ул, ниткән оят? Кешеләр каршында үз әнисе өчен хурлана торган бала буламыни?!

Ә бүлмәгә узып, әнисен ике-өч катлы шәл һәм яулыклардан арындыра башлагач, үзе дә сизми-тоймыйча, калай мич шикелле янды, кызарды ул. Э-э-эх! Әнисенең өстендә унбиш-егермеләп кыз каршында чишенеп күрсәтерлек юньле киеме дә юк икән шул. Терсәкләренә, култык асларына ямау салган бишмәт. Күкрәк өсте, якасы, итәкләре марля сыман теткәләнеп беткән, төсе уңган халат. Тез башлары икенче төстәге җепләр белән чуарланган иске йон оеклар. Ямаулы киез ката, ямаулы шәл, үзенең төгәл яшен инде әллә кайчан онытып бетергән иске соры кофта...

Зифаның хәленә керергә тырыштылар бугай, бүлмәдәш кызларның кайсыдыр кунак кешегә җиңел башмакларын китереп бирде. Кемдер чәйнек капкачларын дөбер-шатыр китереп чәй куярга чапты. Кемнәрдер саклап кына тоткан ризыкларын чыгардылар, ахры, бүлмәгә каклаган каз белән җиләк исе таралды. Ләкин иң гаҗәбе — «Кәҗә белән сарык» әкиятен башкардылар диярсең, бүлмәдәге кызларның әллә ничәсе шыпан-шыпан гына бүлмәдән чыгып сызды.

Ә Мәгубә, маладис, бу юлы да йокламаган икән. Кай арада, ничек кенә хәбәр итеп өлгергәндер инде, берзаманны бүлмәгә, кояш сыман балкып, Фатыйма әбекәй килеп керде.

— Әйтми дә торасыз, и-и, кунак бар икән бит. Самавырым әле генә кайнап чыккан иде. Мактап йөрисең икән, сеңелкәем. Бу сыбызгы борыннар янында юл кешесенә барыбер тынгы булмас. Әйдә, безгә керик.

Гап-гади авыл карчыгы булсаң да, олы җанлы, риясыз, миһербанлы икәнсең бит син, кул-аякларың сызлану белмәсен, мәңге яшә, яшә, апакаем!..

Гөлтуташ урыныннан кузгалган иде инде. Аны көтелмәгән уй айнытып җибәрде, күрәсең, ул, яшь киленнәр кебек бик җитез кыйланып, ишек катында торган зур төргәкне кулларына алды. Зифаның шулчагында гына күзләре ачылгандай булды. И-и, әнкәсе! Кышкы юл, туп-турыдан салсаң да йөз чакрым ара дип тормаган, ул әле авылдан күчтәнәч тә алып килгән икән!

Дүртпочмаклап бәйләнгән иске чаршауны сүтеп җибәрүгә, Зифа шатлыгыннан бүлмә буйлап колын сыман кушаяклап чабып китә язды. Карават өстендә әле яңа гына кайдадыр тектереп алынган сырган бишмәт, балтырлары беләк буе итеп бәйләнгән тула оеклар ята. И-и, кызыңның мон-

дый байлыкларга никадәр мохтаҗлыгын ничекләр генә сиздең дә, нинди акчаларга юнәтеп алып килдең боларны, инәкәем!..

Керфек очларына бәреп чыккан күз яшьләрен чит-ят каршында күрсәтәсе килми иде, ахры, Гөлтуташ кызының чытырдатып кыскан кочагыннан ипле генә итеп аерылды да Фатыйма карчыкка ияреп чыгып китте.

Кеп-кечкенә бүлмәгә кереп, бер-берсенә борыннарын терәп утырышкач кына Зифа әнисенә сынаулы күз ташлады. Эх, бирешкән бит, бирешкән инәкәе! Әнә ике яңагы да эчкә суырылган, күз төпләрен эреле-ваклы җыерчык яргалаган. Беләк-бармаклары мич башына җәйгән үлән сыман кипкән. Күз карашлары көл сипкән шикелле тоныкланып калган һәм... маңгаеның ике ягында да, чигә өсләрендә, берәр тотам чал чәч пәйда булган. Хәзер генә агарганмы алар, әллә элегрәк чаларып та, Зифа күрмәгәнме?..

— Уку — энә белән кое казу, дип борынгылар белеп әйткәннәрдер инде. Бирешкәнсең, балам,— дип, Гөлтуташ Зифаның маңгай-яңакларын сыпырып куйды.— Үсә, ныгый торган чагың бит. Ашау җитмидер инде, ашау җитми. Тәнеңдә чак җаның.

— Бардыр инде, инәкәй, бардыр. Көненә җидешәр-сигезәр сәгать буе укыталар бит, ат шикелле куалар, чыда гына.

— Чыда инде, балам, чыда инде. Атаңның, җаныкаем, аерата сине зур белемле итәсе килгән иде.

— Аннан берәр төрле хат-хәбәр юкмы?

— Юк инде, балам, юк. Суга төшкән балта кебек булды шул атагыз...

Тынлык. Учларын бер-берсенең кулларына алган Гөлтуташ белән Зифа байтак вакыт сүзсез утыралар. Тозлаган каз ите тоткан көе, сирәк кенә бүлмәгә Фатыйма карчык кереп-чыгып йөри.

— Бәрәч, сорарга да онытып торам, сантый,— дип, Зифа тынлык томанын тараткандай итә.— Ничек итеп килеп җиттең, әнкәй? Поезд беләндер инде, Чишмә аркылыдыр.

— Нинди поезд ди ул, балакаем, нинди Чишмә? Поездга утырам дип Чишмәгә чаклы җәяү тыркылдарга мин дүрәкме әллә? Төркәйдән Чишмәгә чаклы алтмыш чакрым ара. Ә Бәләбәйгә туп-турыдан ярсаң, бер йөз генә чакрым. Мин турыдан килдем, балакаем. Кайчак ат чанасы туры килде инде, күбрәк җәяү. Әй, юлга бер җыенып чыккан кешегә күпмени ул?

— Мине Октябрь бәйрәменә көткәнсездер инде?

— И, көтмәгән кая! Каникул буласы, дигәннәрен алдан ишеттек бит. Әле Галимҗан абыең да безне урап китте. Со-

рашырга, белешергә җыенгандыр инде. Син кайтмагач, балалар белән утырып, күп уйлаштык. Кияреңә кием, юлыңа акча юк бит. Кая сиңа кайту? Шуннан үзем җыенып киттем инде менә.

— Ә ул бишмәтне нинди акчаларга тектердең син, әнкәй? Тимерҗан белән Вәзирәнең кияренә юк бит... Үзеңнең дә ни... Үзегездән дә артмый бит, диюем. Нигә инде миңа расхутланасың?

— Ярар, ярар, без ил белән, балам, без ил белән. Илдә чыпчык үлми. Ә сиңа кеше арасында кешеләрчә киенергә кирәк...

Кич җиткәч, Шакирҗан карт белән Фатыйма карчык, ниндидер «туганнарының» хәлен белешмәкче булып, өйдән чыгып китте. Гөлтуташ белән Зифа озын төн буена керфек тә какмыйча чөкердәшеп чыкты. Хәер, күз яшьләрен тыя-тыя, күбесенчә Гөлтуташ тел дилбегәсенә ирек бирде бугай.

— Хәлләрегез ничек, дип сорашасың, балам. Яклаучысыз калган үксезләрнең хәле нинди булсын тагын? Эт тормышы инде, балам, эт типкесе. Хәби, хәсис, безне кешегә дә санамый бит хәтта. Ирле-терәкле хатыннар фермаларда эшли. Ындыр табагында ашлык сугучылар атлаган саен каравыл йортына кереп җылынып чыга. Ә мин көн-таң атса тышта, буран үзәгендә. Әле басудан салам алып кайтырга куа мине Хәби, әле тирес ташыйм. Соңгы көннәрдә менә ферма ярыкларын сыер кәкәе белән сылатып үзәгемә үтте... Соң, үзең уйлап кара, чатнама суык кышта, менә шушы куллар белән чиләккә салып изгән тизәк боламыгы ярыкларга ябышып торамыни? Иртән килдеңме, ул көрәк белән кырып алган сыман кубып төшкән була. Янә ферма буйлап тизәк җыеп йөрисең инде, балам, янә сылап чыгасың. Менә шулай сыер тизәге эчендә казынып үтә минем гомер. Башкайларыңны бирәр кая алып китеп котыл идең дә бит, безнең кебек үксезләрне кемнәр сыендырсын?! Бәхетсезлек — үләт белән бер икән шул. Бәхете булмаганны бер кеше дә куенына алмый...

Иртән Зифа әнисен басу юлына чаклы озата чыкты.

— Поездга утыр инде, әнкәй, җәяүләп интекмә. Болай да хәлең юк бит,— дип, Зифа кат-кат үгетләп-ялварып караган иде каравын, әнисе кулын гына селтәп җавап бирде.

— Мескенлегеңне кешеләргә күрсәтеп йөрүдән дә яманы юк, балам. Җәяү генә атлыйм. Җан биргәнгә җүн бирер, ди Ходай. Юлда изге кешеләр очрамыйча калмас, чаналарының үрәчәсенә булса да эләктерерләр әле...

Гөлтуташ чак беленеп торган чана юлы буенча атлап китте. Аркасында Фатыйма карчык җыйнап биргән кечкенә бер

төенчек. Кышның кайчы сыман кисеп-кисеп талаган усал җиленә бер як яны белән кырын борылган да, миһербансыз, кансыз язмышы белән әрепләшкән-җәдәләшкән шикелле, Гөлтуташ көрт буенча ыргылып-ыргылып атлый.

Байтак ара киткәч, кисәк борылып, ул Зифага таба кул болгады. Зифаның күзләрен ачы яшь каплаган, ул әнисен томан арасындагы шикелле чак-чак шәйли иде. Тик шулай да тоташ карга баткан басу уртасында кул болгаган ялгыз ана сурәте аның хәтеренә гомер җуелмаслык булып кереп калды.

## ӨЧЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Зифаның беренче курсны тәмамлап кайтасын әнисе көннәр-сәгатьләрне саный-саный көтеп торган, ахры. Зифа ишектән күренгәч, әүвәл күз яшьләренә ирек биреп алды да, икенче минутта инде, корт чаккан шикелле каударланып, ул кофта-күлмәкләрен җыештыра башлады.

— Юк, җитте, күп түздем мин. Тешләремне кан сауганчы кыса-кыса түздем. Мәгәр түземлекнең дә чиге бар лабаса! Чама белми бөксәң, яшь агач та сына. Ә мин агач түгел! Хәбәр салмасмы, кайтып алмасмы, дия-дия ничә айлар түздем. Җитте, тагын да түзәрлек бер тәкатем калмады. Сабыр савытларым агач мичкә сыман коргаксыды. Булды, бетте, китәм!

— Тукта, кызма әле. Кая, кая гына җыенасың, әнкәй? — дип бүлдергән Зифаның сүзләрен колагына да элеп тормады ул.

— Өй борынча әллә ничә тапкыр вербувчиклар йөреп чыкты инде. Телисең икән, Нижний Тагилга кит, телисең икән — Себергә. Әле, җитмәсә, «Бодай бу!» — дип кычкырып торган шәһәренә тикле чакыралар. Юлына да, баргач тернәкләнеп китәргә дә акчасын бирәләр, ди. Анда өч ел буена налуклар да түләмисең икән. Мин хәл иттем, язылам да атагыз әйткән Магнитагур дигән якка чыгып китәм. Чакыруын, хәбәрен көтеп җиткерергә барыбер насыйп булмады. Берәр марҗа кармагына эләксә, аның бөтенләй хәбәр салмавы бар. Ир бирмәк — җан бирмәк, ди. Юк, яңгыр көткән басу сыман кибеп ятып булмас. Чыгам, китәм! Табаммы, тапмыйммы, урап кайтыйм әле...

Чыннан да, икенче таңда ук Гөлтуташ күз күрмәгән, колак ишетмәгән якка чыгып китте. Зифа бер кич эчендә әнисенең бар дөньясын-халәтен аңлагандай булды: илдә ирсез

калу — олы афәт икән! Тезлән, шуыш, ялвар, әмма ир-тәрәксез, җан-йөрәксез калма икән син бу җиһанда...

Төркәйдә Зифаның җәйге ялга гына кайткан студент икәнлеген күз чалымына китерүче кеше табылмады.

— Анагыз, үгез сораган сыер сымак тәкатен җуеп, кәнтәйлеккә чыгып качтымы? — дип үкерде Хәби беркөн таңда, өй ишеген тибеп кенә ачып.— Сезне калхуз сыртында бушка асрап булмас. Каникулың су буедай озын, эш муеннан. Хан кызы түгелсең әле, батрак Әмир кызы. Укаң төшеп калмас. Үзегез төзегән калхуз, бүсерең чыкмас, эшләп аша, давай...

Зифа янә колхоз тәртәсенә җигелде. Көннәре йә иген басуында көлтә бәйләп уза, йә фермада. Алай да аз икән. Авылда «комсомоллар бригадасы» дигән төркем төзегәннәр. Шулар белән бергә Зифа төннәрен йә ындыр табагында ашлык җилгәрергә мәҗбүр, йә ат куалап басудан көлтә ташый. Ал юк, ял юк. Зифа өй эченнән бер үзе генә түгел, ундүрт яшьлек Тимерҗанга да йөгән кидергәннәр.

— Мине дә камсамулга алырга җыеналар,— дип, Тимерҗан төнге эшкә ярсу айгыр сыман ыргып кына тора.— Синнән калмыйм, мин дә камсамулга барыбер керәм, апа...

Үзләренең ихаталарында кыш көне мичкә ягардай бер әрдәнә утын, лар төбендә күзгә кырып салырлык та бер бөртек он йә икмәк юк, ә көннәре-төннәре менә шулай, колхозга бил бөгеп, һаман үтә тора, һаман үтә.

Ә комсомол бригадасындагылар, юри үч иткән шикелле, озын төн буена җыр сузалар.

Безнең колхоз бүлем-бүлем,
Уртасында зур болын.
Һичбер кемнән боздырмабыз
Ленин-Сталин юлын.
Их, яратам яз аенда
Җилфердәп искән җилне.
Даһи Сталин җитәкли
Бәхетле, матур илне.
Электрик лампалары
Нурланып яна кичен.
Эр-рәхмәт сиңа, Сталин,
Шат тормыш биргән өчен...

...Гөлтуташ айлар буена бер генә юллык та хат салмаган иде, җәй ахырында, шыр тузанга һәм күз яшенә батып, кире кайтып керде.

— Безнең ише ятимнәргә алтын таулары әзерләп куйганнар ди анда, тот капчыгың! И-и, прастуй халыкны сарык итмиләрме соң? Барсаң тернәкләнеп китәргә акча бирәләр, өч ел буе налук салмыйлар, имеш. Шул сүзләргә ышанып-өмет-

ләнеп килгән әрекмәндәй беркатлы, риясыз кешеләрне, ат көтүе сыман, баракларга куып керткәннәр дә көне-төне балчык ташыталар. Ашарыңа әрем суы сыман әчеп беткән кәбестә шулпасы да тозлы балык башы. Ни тамакка юк анда, ни акчасы. И-и сантый баш, буш вәгъдәгә ышанып, җәһәннәм астындагы Магнитагур эше җиргә кабат бараммы соң?

Әниләренең тын алырга тукталуын сизеп алуга ук өйдәгеләр, борчак сипкән сыман, берьюлы әллә никадәрле сорау яудырдылар.

— Әткәй... әткәй бармы соң анда?

— Әткәйнең берәр төрле эзен тапмадыңмы?

Гөлтуташ, балаларын җуйган аю сыман илереп, өр-яңадан күз яшенә батты.

— Таңын, бөтен кешедән дә иртә торып, ничәмә-ничә баракларны, карьерларны, цехларны урап чыктым. Күрүчебелүче түгел, аның исемен ишетүче дә юк. Суга төшкән балта сыман булды. Юк, юк анда атагыз! Башкайлары исән булса гына ярый инде...

Гөлтуташ өй эчендәге шыр ялангачлыкны күзаллаган, ахры.

— Быел кышка монда торып калсак, читлеккә ябылган тавык сыман ачка кыркылып үләчәкбез, балалар. Урам уртасына чыгып каравыл кычкырсак та, сыңар телем икмәк бирүче булмаячак безгә.

Гөлтуташ кич буе шулай зарланды-сукранды, ә икенче таңда, беркемгә дә әйтми-нитми, янә юлга чыкты. Төштән соң ул инде, алтын каурыйлы кош эләктергән кебек, балкып кайтып керде.

— Галимҗан туганкаем мине аш пешерүче итеп мәктәбенә ала. Сез дә Күчәрбайның үзендә торып укыйсыз, балакайлар. И-и, алай да бу җиһанда Хөзер Ильяс кебек изге Галимҗан бар! Яшибез болай булгач, яшибез, балакайлар!..

Ике-өч көннән соң, барлы-юклы байлыкларны «уф алла»га төяп, тиз-тиз күченделәр. Зифа бу юлы Бәләбәйгә Күчәрбайдан гына чыгып китте.

## 2

Бәла-явыз бер очракта да алны-ялны белми, урысларның «Ванька-встанька» дигән уенчыгы сыман сикерә дә тора икән, каһәр!

Беренче чирекне тәмамлый гына башлаганнар иде, тулай торакта «прапискага керү» дигән каза уйлап чыгардылар.

— Кем прописка үтми, аны тулай тораклан сөреп чыгарабыз.

— Яңа Конституция кабул итәргә хәзерләнәбез бит. Демократик илдә тәртип шундый, һәр граждан прописькада чутланырга тиеш...

Зифа янә бизгәк чире йоткан кеше кебек утка-суга төште. Пропискага керү өчен, иң беренче чиратта, синең кулда паспорт булу кирәк. Аны алыр өчен авыл советына кайтмый булмый. Күчәрбайда күренеп авыз ачсаң, анда сине күсәк сыман тик бер генә сорау көтеп тора:

— Колхоз җибәрәме? Справкы апкил!

Ә Хәбинең кулында хәзер — бөтен власть. Зифа ишетеп кенә калды, Мәскәүдә әллә нинди яңа закон чыгарганнар, ди. Авыл кешесе берәр кая китәргә җыендымы, иң элгәре, ул эшкә керәсе җиреннән «без аңа бик мохтаҗ, кабул итәчәкбез» дигән килешү кәгазе кайтарып бирергә тиеш икән. Эш шуңа тикле барып җиткән, авылда яшәүче кыз шәһәр егетенә кияүгә чыгасы килсә, колхоз рәисенә барып ялына, ди. Атаң-анаңмыни, сиңа никах укытырга колхоз рәисе рөхсәт бирсен әле! Көлке, кәмит бит бу, валлаһи, егыл да үл! Көлкесен көлке, ләкин читлек-тәгәрмәчкә утыртылган тиен язмышыннан ким җире юк моның. Йөгер, ялвар, чәчең белән ындыр табагын себер, телең белән яла, иллә мәгәр син атлап чыга алырдай киртә түгел инде. Чытырманлык дисәң дә чытырманлык, тагын ни әйтәсең!

Йә, баш түбәсенә сугып рәнҗетелгән мәэюс эт баласы сыман тезләнә-шуыша Хәби каршына кайтып кара инде. Хәлеңә керәме, тыңлыймы ул сине? Тот капчыгың! Куначага менгән әтәч кебек канат кына җилпиячәк сиңа.

— Әһ-һә! Авылыңнан качарга җыендыңмы? Атаң төзегән колхоз артыкмыни? Мин кыҗрап йөрмәдем, үзегез төзедегез. Хәзер койрыгыгыз бозга ябыштымы? Шул кирәккән сезгә. Бүсерең чыкмас, эшлә!..

Менә шулай, Төркәй-Күчәрбайга кайтса, аңа паспорт эләкми. Ә монда, тулай торакта, гөпелдәтеп артына тибәчәкләр.

— Паспортың юкмы? Прописка үтмәдеңме? А ну, давай, сыптыр!..

Берәр фатирга күчеп тә укып булыр иде, андый юл бар. Тик кесәңдә өч тиенлек тә байлыгың юк икән, сине кемнәр кертсен? Кемгә хаҗәт синең ише авыл хәерчесе? Ичмаса, бер стакан сөт бирә торган мур кыргыры кәҗә хәтле дә файда юк бит синнән! Шул инде, шул, бер генә юл синдәй галахларга. Бет белән кандаланны дагалап салган хәерче күтүмкәнне сыртыңа асасың да, әллүр җаным, Төркәй якларына! Якты, кояшлы Бәләбәйләр синең өчен түгел. Үрелмә, сикеренмә, Хәби казып куйган базда гына утыр!..

Зифаның йөзеннән бөтенләй нур качты. Ашы — аш, йо-

кысы йокы түгел, күзләрендә яшьнең кипкәне юк. Дәресләргә башка кызлар артыннан шәүлә сыман ияреп барган була, ә класста, укытучылар белән ике арага күзгә күренмәс пәрдә корып куйганнар диярсең, берни аңлый алмый.

Икенче чирекнең беренче көнендә үк аларга «хокук» дигән яңа фән керә башлады. Укытучылары Шарапова атлы яңа кеше, мөгаллимә түгел. Аны каладагы иң кырыс судья, диләр. Бардыр инде. Өстендә һәрчак соры итәк белән хәрби гимнастерка. Аягында — күнитек, билдә — каеш. Хәтта, ул башындагы зәңгәр беретын да дәресләрдә салмый. Аңлатканда тик торуны белми, зинданга ябылган кеше шикелле, бертуктамый ишек белән тәрәзә арасында йөри-йөри сөйли. Аның һәр җөмләсе саен класстагы һава, яшен чатнаган кебегрәк, чарт-чорт итеп тора.

— Мең тугыз йөз егерме дүртенче елда Советлар Союзы төзелгәч кабул ителгән Конституция искерде. Ул Конституциядә, төп максат булып, илдә социализмның тулы җиңүенә ирешү бурычы куелган иде. Башында халыклар атасы бөек Сталин торган Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә моңа ирештек без... Хәзер бөтен илдә бөек Сталин җитәкчелегендә әзерләнгән яңа Конституция проектын тикшерү бара. Ил буенча кырык биш миллионга якын кеше аны хуплап тавыш бирде инде. Озакламый ул Советларның чираттагы съездында кабул ителәчәк. Шуннан соң СССР Югары Советы безнең илдәге иң югары дәүләт органы булып исәпләнә башлый. Коммунистлар партиясе дәүләт төзелешендә нәкъ башка илләрдәге дистәләрчә партияләр белән бер үк дәрәҗәгә куела. Чөнки безнең ил — дөньядагы иң демократик дәүләт...

Әле аңкы-миңке йөргән Зифа гына түгел, класстагы бер кеше дә ерып чыга алмый. Бәрәч, бәрәч, халыклар атасы, бөек Сталин властьтан китәмени? Әллә... әллә аны СССРның Югары Совет рәисе итеп куялармы? Ник бу турыда сүз юк?.. Бик әйбәт яши идек бит әле, бары да әйбәт иде. Ләкин моннан ары безне кем әйдәкләр? Кая алып барыр?..

Класс шылт та итми. Судья хатынга сорау бирүче юк. Бер сүз кушсаң, яшен сугар сыман. Кыяфәт бик кырыс. Ничә көн буена лекция укый инде, иллә мәгәр елмаюны белми. Как шикелле кипкән тар иреннәр. Күзләрен кыса төшеп төбәгән боздай салкын караш. Агачтан юнып ясалган яисә битлек япкан шикелле һич үзгәрү белмәс, катып калган чырай. Яшен төсле чарт-чорт иткән тавыш.

— Советлар Союзы — дөньядагы иң демократик дәүләт...

Барча кеше, шәүлә сыман, тын да алмый йөри...

Шушы хатын үзе көннәрдән бер көнне Зифага сүз катар дип кем уйлаган?..

Терсәкләре янә тишелеп чыккан кофтасын кеше юкта гына кияргә исәпләп, Зифа ул көнне класста иң азакка калды. Судья хатын да чыгып китмәгән, ул тәрәзә буена баскан көе күз төпләренә, яңакларына акшар ягып азаплана иде. Класска арты белән торган Шарапова ничек күргән аны, ул Зифаны каян килеп белә?

— Нәгыймова! — дип, әмер тоны белән эндәште ул кинәт, аңа таба борылмыйча гына. — Әтиең турында ул-бу хәбәр юкмы?

Зифа без кадаган шикелле тораташтай катты. Нишләп әтисе турында сорый соң әле бу, аның югалуын ничек ишеткән ул? Нигә сорый, ни-нәмәрсә ачыкламак була?

— Ю-ю-у-ук.

— Югалттык без аны. Каядыр юкка чыкты.

Тишек кесәсеннән төшеп калган иске биш тиен хакында сүз алып барамыни, тавышында һичбер төрле хис йә җылылык юк. Зифа яшен суккан агач сыман селкенми дә торды. Судья хатын берзаман, ниһаять, аңа таба йөзе белән борылды, тик мондагы караш-тавышлар борынгы Рим Сенатына менгән консул-патрицийларныкыннан кайтыш түгел иде.

— Тәк, менә болай сөйләшәбез, ни, кем, Нәгыймова. Күреп торам, читтән ярдәм көтәрдәй терәгең юк синең. Менә сиңа адрес. Свердлов урамында гына торам, тиз табарсың. Мин көне-төне эштә. Чүпрәк-чапрак, аш-су белән кайнашырга тамчы да вакытым юк. Аннары минем икенче класста укучы балам да бар. Кул кулны, ике кул битне юа, ди. Син миңа килеп булышкалыйсың, ә мин сиңа. Шулай килештекме?

Һе, бу бит судья кеше, килешмичә кара! Зифа шул кичтә үк аның асравына әйләнгән иде инде.

Асрау дигәч тә, ул тәүге көннәрдә генә үзен беркадәр кимсетелгән кеше шикеллерәк тоеп йөрде бугай. Зифа аның бер кочак керләрен юа, өен җыештыра, Настя атлы кызын мәктәп белән ике арада тырылдатып йөртә. Ә Шарапова үзе йә төш вакытында, йә таң атканда кайтып күренә дә аннан эзе дә юк. Ул Зифага үзенең ак беретын, парус сыман каты тукымадан теккән ап-ак башмакларын, тезгә кадәр төшеп торган калын свитерын, тагын әллә никадәрле вак-төяген биреп бетерде инде, тик берчакта да, сыңар сүз дә дәшми.

Утыз җиденче елга аяк баскач, Шарапова бөтенләй сәерләнә башлады. Ул хәзер күбесенчә төнлә белән эшли, төш вакыты узгач өйгә кайтып ава. Аны йомшак түшәктә дә йокы алмый, күрәсең. Сикереп тора да бер фужер аракыны голт-голт эчеп куя. Аннары йокы аралаш сытып-изеп сүгенгән авазлары гына ишетелеп тора.

— Син Шәмсетдиновны ник яклыйсың, хәсис? Ул төрек шпионы бит, төрек шпионы!..

— Син унҗиденче елдан бирле качып калган контр! Сез икегез дә Фишер белән бергә халык дошманнары!..

Зифага көн-төн диярлек Шарапова фатирында яшәү шомлы, куркыныч була башлады. Бәлки, Шарапова моны үзе дә сизенгәндер. Беркөн кыйналган кеше шикелле сөйрәлеп кенә кайтып керде дә ул өстәлгә бер конверт ташлады.

— Булды, ерып чыктым. Менә сиңа паспорт, менә акча. Пропискага керү өчен үзең йөгерерсең. Кара аны, югалтасы булма!..

Ә бер атнадан соң Шарапова, өермә ялап алгандай, каядыр юкка чыкты.

## 3

Язга чыкканнан бирле бер хат-хәбәр дә булмагач, Зифа әнисе һәм эне-сеңелкәше хакында кайгырып яткан иде. Язмыш — урак икән, аны турайтып та булмый, ул сине урап та үтми.

Икенче курсның соңгы имтиханнарыннан котылып Күчәрбайга кайтса, тегеләр юк. Өр-яңа мәктәп ихатасына гүя үләт үтеп кергән, беркем бер сүз әйтми, сиңа якын килми. Тилмерүле караш белән ничек кенә алларына барма, синең күзеңә текәлеп караучы юк, җавап бирүче юк.

Ниһаять, сарай буенда утын әрдәнәләре өеп азапланучы бер карт хатын гына, урлашкан шикелле як-ягына каранып, пышылдап кына әйтте:

— Галимҗанны апкиттеләр, апаем, безнең Галимҗанны...

Зифа киселгән тал чыбыгы кебек җиргә егылудан чак сакланып калды. Кояш сүнгән кебек булды кинәт, гүя җир тетрәде. Галимҗан абыйсы... Абый, абыкаем!..

Юк дисәң дә, Бәләбәйдә колагына керә тора иде.

— Уфага Жданов килгән, Мәскәүдәге сы-ка секретаре. Бөтен партактивны җыеп өшкергән, ди. «Безнең алга баруыбызга аяк чалучы дошманнар күп. Социализм никадәр уңышка ирешә, аның дошманнары шулкадәрле күбрәк була бара. Сез аларны ачыкламыйсыз, сез йоклыйсыз. Провакаторлар сез, либерал һәм әрәмтамаклар!.. Безнең дошманнар бит югыйсә койган койма сыман. Баганаларын кисеп ташладыңмы, аның такталары үзе дә авып китә». Менә шундый сүзләр сөйләгән ди Жданов. Аның рече «Кызыл Башкортстан» гәзитендә дә басылып чыкты бугай, укымадыңмыни?..

— Шундый фәрман булгач, Чишмә белән Ярмәкәйнең беренче секретарьларын да, НКВД нәчәлникләрен дә җыеп ал-

ганнар, ди. Тегеләре япуннарга иң яшерен секретларны җибәреп яткан икән...

Менә сиңа мә! Галимҗан абыйга да чират килеп җиткән. Ул да япон шпионы йә халык дошманы булды микәнни соң? Күчәрбайда нинди «секрет» булсын инде, ниткән шпион ул? Әнисе әйтмешли, Хөзер Ильяс кебек изге Галимҗан абыйсы кемгә дошман булсын? Әллә... әллә... әллә...

Әниләре белән бәләкәчләр атна-ун көн чамасы элек үк иске йортка кайтып төпләнгәннәр икән. Билгеле инде, Гөлтуташ аны янә күз яшьләре белән каршылады.

— Дуска караганда дошман күбрәк. Бер кешегә бер сереңне белдерерлек, һичбер кемгә таянырлык түгел. Галимҗан абыеңны да дошманга чыгаргач, ничек яшәрбез инде бу дөньяда? Барып киңәш сорарлык та кеше калмады бит...

Гөлтуташ өендәгеләрнең барчасын да колхоз эшенә куып чыгардылар. «Эһ» яки «аһ» итеп тә каршы килүче кеше табылмады. Беренче көннәрдә барысы бергә печән җыю, кибән куюда катнашып йөргәннәр иде, аннары каз мамыгы урынына төрлесен төрле якка тараттылар. Зифа белән кечкенә Вәзирә ындыр табагында кайнашты, әниләрен һаман да шул Хәби әмере буенча фермада тирес эшенә җигә башладылар. Әтисенә охшап, әзмәвер гәүдәле булып үсеп җиткән Тимерҗанга гына бәйләп куярдай аран таба алмыйлар, ахрысы. Ул әле басудан көлтә ташуда, әле көтү көтә. Өйгә кайтып кергән чакта, хатын-кызларның җеп өзәрлек тә егәрләре калмый, бусага аша түргә узуга түшәккә егылалар. Ә Тимерҗанның артына бер уч борча ябыштырганнар диярсең, бер кичтә дә өйдә утыруны белми теге.

— Мин бүген ындыр табагында дежур.

— Бүген төнлә Торна күле янына каравылга чыгам. Анда бодай зуратлары сугылмаган әле...

Көн саен шуның ише сәбәп, кич саен яңа төр бер сылтау. Аңа хәзер сүз әйтергә дә кыймыйлар. Артыннан Галимҗан абыйлары йөри торгач, Тимерҗанны кыш көне үк комсомолга кабул иткәннәр икән. Хәзер аны хәтта Гөлтуташ та нык өлкәнгә саный, өстәлгә куярдай сый-хөрмәтнең иң майлысы аңа. Аннары... аннары Тимерҗанның борынына ис керү дә мөмкин. Егет кисәге генә булып күренсә дә, ул унбиш яшен түгәрәкләп килә. Тимерҗанга кичләрне-төннәрне ындыр табагындагы яшь кыз-кыркын белән үткәрү рәхәтрәктер. Әнә бит, кич саен аннан нинди генә җырлар ишетелми?

Алсу-кызыл байракларны
Чәчәкләргә бизибез,
Юлбашчыбыз Сталинга
Озын гомер телибез.

Бакчаларга керүләрем
Матур чәчкәләр өчен,
Җанымны да кызганмыймын
Сталин эше өчен…

Җәй уртасы үтеп китте микән, Төркәйне дә гүя аждаһа теле ялмарга тотынды. Ике-өч көн саен утлы хәбәр.

— Бүген төнлә Фазылбәкне алып киткәннәр. Ат менгән дүрт милиция Чәрмәсән яклап кына килеп алганнар, ди.

— Шәрифҗан белән Идрисне элеваторга ашлык илтә киткән җирләрендә тотып япканнар. Авылның беренче камсамуллары иделәр бит югыйсә. Гәрдән кулакның кызы Гөлсем хәзер чәчләрен йолкый-йолкый үкерә, ди…

Утыз өченче елгы ачлык кабат кайттымыни, күрше күршегә керми, беркем аралашмый. Кичә генә кунакларга, өмәләргә йөрешкән дуслар-ахирәтләр дә хәзер урамда угрылар шикелле бер-берсенә карамыйча үтә. Урамның уртасыннан, күкрәк киереп атлаулар онытылып бетте. Ә ул туй итүләр, театр куюлар, аулак өйгә җыелып утырулар хакында бөтенләй әйткән дә юк.

Гөлтуташ белән Зифа кичләрен өйалдына чыгып кына чыш-пыш елашалар.

— Шул Хәби хәсиснең кулы уйнамый микән, балакаем? — дип, әлбәттә инде, беренче чиратта әнисе шик түгә. — Бакчы, гел теге елларда атаңа булышып, аңа терәк булып йөргән кешеләрне җыялар бит болар. Хак булса, Фазылбәкнең хатыны сөйләнгән, ди. Фазылбәкне алып китәргә килгәч, милицияләрнең берсе аларга әллә нинди жалу күрсәткән, ди. Теге жалуда шушы ыштыр Хәби белән Озын Закирның куллары ярылып ята икән…

Зифа — тешләк, ул күбесенчә дәшми. Соңгы көннәрдә аны әле бүтән төрле кайгы корт шикелле талый. Әфсенләп бозганнар диярсең, Тимерҗанны һич танырлык түгел. Беркөн караңгыда Зифаны сарай артына чакырып алды да, акылы зәгыйфьләнгән кеше шикелле лыбыр-лыбыр сөйли. Ә күзләре, шайтан ияләшкән сыман, ялт-йолт янып тора.

— Тагын бер ай буе, бер ел буе йокламасам-йокламыйм мин, апа, мәгәр барыбер дә бу Хәбинең башына җитми калмыйм. Түбән очның малайлары юкка гына сөйләмидер инде. Табор күленә ниндидер кешене шушы Хәби суеп салган, диләр. Анысын ачыкламасам да, барыбер тынгы бирмим. Мин аның ике Усман кешесенә ун капчык ашлык сатып җибәргәнен күреп калдым инде. Мин комсомол кеше, барам, әйтәм! Халык дошманы ул, валлаһи, халык дошманы! Апкитсеннәр, апа…

— Тимерҗан, энекәем! Син бик яшь бит әле, берүк каты-

ша күрмә! Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең, ди. Урлашсын, тыгынсын, чукынып китсен Хәби! Син генә катыша күрмә, әрәм булуың бар.

Әнә шулай, алтындай телләрен дә кызганмыйча ялынып карады Зифа, ярдәме генә һич тимәде бугай. Тимерҗан элеккечә әле «дежурга», әле «каравылга» йөрүен дәвам итте. Шул сөйләшүдән соң ун-унбиш көн вакыт үтте микән, Хәбине дә алып киттеләр. Зифа әле моны ындыр табагында ишетмәгән иде, кич белән әнисе тагын аны өйалдына алып чыгып кына һәм, ни галәмәт, бу юлы да елый-елый чиште.

— И-и, кеше каргышы төшми каламы соң? Төшә ул, балакай, һәркемгә дә төшә. Әнә теге Хәбине дә безнең каргыш тоткан. Бүген төнлә аны алып киткәннәр, аңа да чират җиткән. Атагыз төзеп биргән колхозның сыртына бояр сымак менеп алган, ул туплаган малны сыер урынына савып яткан иде. Менә аның да бугазына сөяк булып утырды ул маллар. Безнең күз яшьләре, безнең каргыш барып төште аңа. Ул гына атагызның башын ашадым дип сөенмәсен әле, дөм караңгы урам уртасында без дә биеп калыйк...

Әнисе ни өчен аңа бу хәбәрне үксеп елый-елый, ачы күз яшьләре аша җиткергәндер, Зифа моны аңлап бетермәде. Ә икенче көнне җыенып эшкә барса, тагын бер яңалык, янә шаккатмалы хәбәр:

— Озын Закир авылдан чыгып качкан. Хәтта хатынына да әйтеп тормаган, ди...

Әледән-әле кешеләр югалуга Төркәй күнегеп бетте. Һавасы гына түгел, бар дөньясы дәһшәтле яңгыр, коточкыч гарасат көткән шикелле тынып калды кебек. Әйтерсең лә бөтен күк йөзе озон йә булмаса күкерт белән тулган. Берәр сантый ялгышып шырпы кабыздымы, бар тереклек күз ачып йомганчы янып китәр төсле. Йөрәктән кан тама, ә ыңгырашып тавыш бирүче юк. Кан тамырларында мизгел саен тик бер генә теләк:

— Безне урап үтсә иде... урап үтсә иде... үтсә иде...

## 4

Каян ишетеп, кемнән белешкәндер, утызынчы август иртәсендә әнисе Зифага олау табып бирде.

— Чишмәнең үзенә чаклы бара, балакаем. Безнең өйдә тәрбия күрердәй рәт булмагач һич кенә дә мантымаган идең, уңай килде әле. Ичмаса, алтмыш чакрым араны тәпиләрлек хәлең янга калыр, юлда өзлекмәссең...

Гөлтуташның әле олауга чыгып утырыр алдыннан, колактан-колакка гына җиткерә торган сүзләре бар икән. Аларны да, билгеле, онытмады.

— Авыз эчең тулы кан булса да, берүк кешеләр алдында төкермә, ничек тә түз. Бүреләр заманасы килде, балакаем. Дөньясына үләт төште сыман, һәрбер бәндә берсен-берсе ботарларга әзер...

Олаучы кеше алтмышларны узган өлкән абзый иде. Авызына йозак элгәннәр диярсең, ун чакрым буена сыңар сүз дә дәшми. Зифа берничә мәртәбә аны сөйләштермәкче дә булып карады, ләкин абзый кешенең җаваплары саңгыраунык сыман.

— Сез Чишмәгә берәр туганыгыз янына барасыздыр инде?

— Бик ялынгач, Гаптеринең Хәнәфие ат бирде бит, менә...

— Ике ел элек әнкәй белән без бу юлны җәяү узган идек.

— Ат юньләп атламый бит, ат атламый...

Шушылардан соң инде Зифа үзе дә сүз эндәшмәс булды. Йокымсырап киткән чакларында үрәчәдән егылып төшүдән «саңгырау» абзыйның кычкырып куюлары гына коткарып калды аны.

— На-а, табаныңны этләр ялагыры! Сиңа ияреп мәрткә китәбез бит...

Чишмәдә «кәккүк» поездларын әллә ничә сәгать буе көтәргә туры килде. Бәләбәйгә утыз бере көнне бик соңарып кына килеп төшсә, берьюлы дистәләгән күсәк сагалап торган.

Тулай торакта комендант Фәттахов урынында сап-сары бер марҗа. Адәм рәтле сөйләшүне белми, үзенә чит-ятлар якынлашудан өреккән көчек шикелле гел чәрелди генә.

— Өченче курсныкылар быел тулай торакка керми. Фатирда торып укысагыз да, чәнчелмәссез әле!

Зифа, сантыйлыгы белән, аны-моны уйламыйча авыз ачкан иде.

— Ә комендант Фәттахов кайда соң? Безнең комиссар абзыебыз кайда?

Сары марҗа он-камырны нәфсе белмичә сосынган күсе шикелле кабарынып чыкты.

— Эн-кы-вы-дыда сезнең Фәттахов! Аның кебек контр калдыклары тагын кайда булсын!..

Зифа хуҗасы берәр төрле ризык белән кызыктыра-кызыктыра чакырып китереп тә, соңыннан тибеп очырылган эт баласы кебек мескен хәлдә иде. Ул сары марҗаның йөзенә текәлеп тә карамыйча шундук чыгып качты.

Икмәк катысы булса да өмет көткән хәер эстәүче кыяфәтендә техникум ягына атлап киткән иде, ишек төбендә Мәгу-

бә көтеп тора. Ике ай буе күрешми яшәгәнне күз чалымына да китерми, ахрысы, йөзендә елмаю, сөенү дигән хисләрнең эзе дә юк.

Ул Зифаны терсәгеннән генә каптырды да, ялт иттереп, техникумнан читкә алып китте. Сөйләшүе дә эре, коры иде.

— Синең ише бозау ни эшләсен инде? Муенчак кидереп сөйрәгән шикелле монда килә, билгеле, тагын кая барсын? Имеш, Ильясов тулай торакка урнаштыра аны, һич югында фатир табып бирә. Тот капчыгың, кызый! Ильясов юк хәзер. Ишбулатов белән икесен дә җәй көнне үк килеп ялмаганнар. Торна Фәттахны да. Хакмы, юкмы, алар, троцкийчылар фиркасенә кереп, Сталинның үзен чәнчелдереп төшерергә җыенганнар икән. Башыңа бәла аласың килмәсә, моннан ары алар турында сорашасы булма...

Зифа кайнап торган казан капкачын саксыз ачып парга пешкән шикелле куырылып төште. Мәгубә шуны сизеп алды бугай, Зифаны елга ярына терәлеп утырган кечкенә, тар урамнар буенча сөйрәп китте.

— Түтәң сиңа фатир табып куйды. Сөйләшенгән, икебез торачакбыз. Акчаны күп алмыйлар. Техникум тирәсендәге фатирлардан ике тапкыр кимрәк. Йорты бик зур түгел. Өй эчендә сыңар карт та карчык. Иң шәбе шул, болар авызларына таш тутырган шикелле берни сөйләшмиләр. Алар бер җөмләне очлап бетергәнче техникум белән ике араны җиде тапкыр урап кайтып була.

Йорт хуҗалары, чыннан да, инде җиденче дистәне кырлаучы картлар булып чыкты. Ире Галимулла атлы, ә карчыгы — Бану. Икесе дә башкорт. Әллә кайдагы, Урал аръягындагы Учалы районыннан. Революция алдыннан ук ниндидер бер байга ат караучы булып күчеп утырганнар. Картны әле дә сабан туйлары алдыннан теге яки бу оешмага ат яравайларга чакыралар икән.

Боларның гомер буе балалары булмагандыр инде, ел саен берме-икеме студент кызны бәләкәй бүлмәләренә яшәргә кертәләр, ди. Монда ризык яшерү, аш бүлү дигән чирләрнең берсе дә юк. Хәзинәдә ни бар — һәммәсе дә уртак.

Карт белән карчык аеруча Зифаны якын иттеләр, күрәсең. Ул ишектән күренүгә, икесе дә «Дифа кыдыкаем», «Дифа аһылкосым», дип биеп кенә тора. Боларның «Дифа» дип сөйләшүләрен ишетү беркадәр сәеррәк, билгеле. Ләкин күзләрендәге җылы яктылыкны күрдеңме, андый сәерлекләр шундук онытыла. Учак сыман сихерле һәм тансык бу кечкенә йортка гел кайтасы килеп кенә тора. Тик әлеге карт белән карчык янына кайтып сыенулар көннән-көн сирәгәя, катлаулана бара.

Техникумда укый башлауның беренче атнасында ук эчкә суккан шикелле тынсыз калдырдылар.

— Тарих дәреслекләрендәге йөз дә уналтынчы биттән Тухачевскийның рәсемен ертып ыргытыгыз. Аның белән рәттән гражданнар сугышы геройлары дип саналган Якир, Уборевич, Коркалар — барысы да дошман. Пролетариат диктатурасының җәза кылычы булган НКВД һәммә мәкер йомгагының асылына төште. Тухачевский канаты астына җыелган бу хәрбиләр әле революция вакытында ук корытып бетерелмәгән контрлар һәм патша охранкасына ялланган этләр булган икән. Битлек кигән әлеге сатлык җаннар Кызыл Армиянең иң югары постларына үрмәләп менгәннәр һәм, хәрби көчләргә каршы корткычлык эшләп, аны эчтән таркатырга ният корганнар. Фашистик Германия разведкасына ялланган бу хәрбиләр гадел совет суды хөкеме буенча атып үтерелде...

Ике-өч көн үтүгә, яңа ачыш, яңа төзәтмәләр.

— Үзәк Комитетның Политбюро составында торган Чубарь, Косиор, Рудзутак, Постышев кебек барча юха елан атып үтерелде. Чит илгә качкан сатлык Троцкий җырын җырлаучы бу фашистлар кандала шикелле ярыкта посып яткан һәм халыклар атасы бөек Сталинны юк итәргә әзерләнгән булган. Партия тарихы буенча укытылган элеккеге дәреслекләр юкка чыгарыла. Алар урынына Кавказ партия оешмасының беренче секретаре Лаврентий Берия хәзерләгән яңа дәреслек укытыла башлый...

Техникумдагы һәр группа, барча студентлар биек коймалар арасына куып кертелгән мал хәленә төште. Әйтерсең лә әле теге яклап чыбыркы шартлаталар, әле бу тарафта синең сыртка камчы сыдыралар. Дәресләрдән соң көн саен кич җыелыш та митинг, тын алмалы түгел. Трибунада халык дошманнарын тетеп йодрык болгаучыларның бетеп торганы юк. Аеруча комсомол комитетын әйдәкләүче «кисекчәчләр» көн дә гайрәт чәчә.

— Зиновьев белән Каменевны былтыр ук, август аенда чәпәп дөрес эшләделәр. Япония белән Германиягә ялланган бу сатлыклар, Троцкий белән берләшеп, Совет хөкүмәтен чәнчелдереп төшермәкче, ә аннары Украинаны немецләргә, Көнчыгыш Себерне япуннарга биреп, капитализмны өр-яңадан кайтармакчы булган. Энкеведе наркомы Ягода гына вакытында эләктермәгән аларны, Ягода йоклап йөргән.

— Барча халыкларның атасы бөек Сталин энкеведеның башына иптәш Ежовны китереп куйганнан соң, күпме яңа дошман ачыкланды! Җаннарын Германиягә саткан Тухачевский группасы. Троцкий белән фашизм ялчылары Косиор-

лар, Рудзутаклар. Совет әдәбиятын капитализм пумаласы белән каралтып яткан Мейерхольд белән Кольцов шикелле җыен әрәмтамак. Һәм инде әле партия каршында гафу үтенгән булып, әле аңа кабер казып яткан Бухарин белән Рыков җитәкчелегендәге явыз «уң канатлар».

«Барча халык дошманын үземнең керпе энәләре кебек бияләйләрем белән себереп түгәчәкмен!» дип ант эчкән яңа нарком Ежов кына кулга алды ул Бухарин һәм Рыков кушаматлы ике этне. Ежов кына партиягә, бөек Сталинга каршы әзерләнгән барча корткычлыкның асылына төште. Элеккеге нарком Ягода да Бухарин белән Рыковның черек арбасына күчеп утырган булган бит. Шулар һәммәсе бергәләп Кировның башына җиткәннәр, Куйбышев белән Горькийны агулап үтергәннәр. Бу мәкерле җаннар ничәмә-ничә еллар буена Германия, Польша, Японияләргә хезмәт итеп яткан. Шушы явыз дошманнар, түнтәреш оештырып, бөек Сталинны үтермәкче булган...

Һәрбер җыелышны яңа җырлар өйрәтеп тәмамлыйлар.

Яшәсен шат тормыш бирүче,
Яшәсен безгә көн бирүче,
Яшәсен илгә нур бирүче —
Кадерле атабыз бөек Сталин,
Яшә, даһи Сталин!..

Һәр җыелыш саен техникумда мохит, мунча миченә су бөркегән сыман, кыза гына бара. Кайбер җыелышларда чая ташбашларны туктатмалы түгел, трибунага өр-яңа ораторлар сикерешеп менә.

— Ул Бухарин, Ягодаларга һаман суд булмады.

— Аларны, хөкем карары чыгарып тормыйча да, котырган этләр урынына аттырырга кирәк!..

Ай буена сузылган шушы җыелышларның берсендә Мәгубә дә сәхнәгә ук шикелле очып килеп чыкты. Яңаклары кызган, күзләре шар ачык. Үзе бертуктаусыз йодрык болгап сөйли:

— Кировны атып үтерделәр, бөек пролетар язучы Максим Горькийны агулап юк иттеләр. Ә Бухарин белән Рыковның үзләренә һаман берни дә юк, алар ана мәче шикелле, корсак үстереп, сәндерәдә ята. Җитәр, бездә дә түземлек Тын океан түгел! Мәскәүнең иң зур залларының берсендә алар өстеннән ачыктан-ачык суд үткәрергә дә, хөкем карары яңгыраугa, юк итәргә кирәк! Ичмаса, сукыр тычкан кебек яшеренеп кенә корткычлык иткән башка дошманнарга да сабак булыр иде...

Караңгы төн уртасында җитәкләшеп фатир ягына атлый башлагач кына Мәгубә сер чиште:

— Озакламый Мәскәүдә Бухариннарга суд булачак икән. Монысын бөтен Советлар Союзы өчен дә күрсәткеч суд иттереп үткәрергә җыеналар, диләр. Райкомолга чакырып шулай аңлаттылар. Сиңа да берәр җыелышта сүз алырга кирәк. Исән-имин яшим дисәң, шунсыз булмый, кызый...

Чираттагы җыелышта ук Зифа сәхнәгә чәчрәп чыкты.

— Ягоданы ничә ел буена нарком итеп зерә утырткан-нар. Нарком булуыннан файдаланып ничәмә мең кешенең башын ашаган ул, күпме зыян салган!.. Кешеләрнең күз яшьләрен дә, гомерләрен дә кире кайтарып булмый. Әнә дүртенче курста укыган Сабитова бик тә дөрес әйтте. Ил-халыкны нахакка рәнҗеткән явызларны котырган этләр урынына аттырырга кирәк! Ягодасын да, Бухарин, Рыковны да. Якты дөнья аларга төс түгел. Үлем генә төс аларга бүген, үлем, үлем!..

Зифаның күзе-башы тонган, теле ни сөйләгәнне зиһене тоймый иде. Сәхнәдән сикереп төшкәч тә ярсуыннан тыела алмады ул. Берзаманны Мәгубә килеп аны терсәгеннән култыклаган чакта Зифаның бар тәне әле һаман ут шикелле кызып яна иде. Галимулла карт белән Бану карчык фатирына алар көч-хәл белән генә кайтып элгәштеләр. Зифа, бусагадан атлап керүгә үк, түшәк өстенә утын түмәре шикелле тавыш-тынсыз ауды.

## 5

Зифа бер ай чамасы хаста булып ятты. Галимулла карт, каяндыр ат табып, аны хастаханәгә алып барган иде, табибә чир сәбәбен тиз аңлатып бирде:

— Өзлегү бу, җаным, тоташ хәлсезләнү. Эссе кояш астында бертуктаусыз сабан тарткан ат берзаманны яныл егыламы? Нәкъ шундый хәл синдә. Гемоглобиның коточкыч түбәнәйгән, каның сыек. Сиңа аксым, витаминнар җитми. Ашыгыч рәвештә моны туктатмасаң, хәлең яман. Бик җентекле тәрбия кирәк сиңа хәзер, юньле ризык кирәк...

«Әйе, бар инде ул бездә тәрбия, түтекәем,— дип, эченнән генә әче телләнеп утырырга мәҗбүр булды Зифа.— Бәрәңге белән дыңгычлап тутырылган колхоз капчыгы шикелле. Өстенә утырдыңмы, яннан тишелеп чыга. Бер-ике бәрәңгесен сиңа да ыргытмыйммы?»

Ә табибә ярым һушсыз хәлдәге әсирнең тырнак астына энә кадап интектерүдән ләззәт алучы җәллад кыяфәтендә акрын-салмак тезә:

— Ашау кирәк, җаным, ныклы ашау кирәк. Ит-май гына

димим. Яңа сауган сөт файдалы булыр, сыр, эремчек. Әче дигән булып кылтыкланып торма, шалканын да аша, суганын да...

Күңелендәге нәфсе белән тәгам инде елан булып боргалана башлаган иде, Зифа аны көч-хәл белән генә тыеп утырды.

— Аннары кара карлыган белән кара каен кайрысы, э-эх, бик тә, бик тә файдалы булыр иде, аларны бу вакытта кайдан аласың соң?..

Зифа бүлмәдән баш түбәсенә нахаксызга сугып рәнҗетелгән эт баласы кебек тавыш-тынсыз елый-елый чыгып киткән иде, Галимулла карт белән өйгә кайтып кергәч, авызын колакларына кадәр җәелеп китүдән чак-чак тыеп калды.

Зифалар яшәп яткан тар бүлмәдә түгел, ә карт белән карчыкның зал ягына чыгып ничәмә-ничә сабакташ мич буена, өстәл тирәсенә, хәтта караваттагы ястык өстенә тикле хуҗаларча җәелеп утырганнар. Комсомол комитетындагы бер «кисекчәч» (фамилиясе Гайнанова инде аның, Зифа күптән белә, шулай дип эндәшкәне генә юк), шул ук комитетта ике тапкыр типсәң дә бер сүз әйтми торган «рәссам» Һади, күрше группадагы чәрелдек Сабитова, Зифалар группасының иң зур «ләчәнниге» — староста Кыдрачев, тагын бер-ике сабакташ һәм ... әлбәттә инде, мулла песие кебек бер почмакта шым гына утыручы Мәгубә ахирәт. Ул ишек ягына карамаска тырышкан була, күз яшерә, тик белә бит инде, белеп тора Зифа: боларның барысын да бирегә Мәгубә алып килгән!

Бу минутта Мәгубә тел яшергәч, хуҗалар урынына тегеләр «сәламлиләр»:

— Син нишләп болай подкачать иттең әле, кызый?

— Уку елы уртасында... шушындый буй-сын белән...

— Килешми бит болай, килешми бит...

Барысыннан да бигрәк, староста Кыдрачевка үзенең «ләчәнниклегеен» күрсәтергә җай чыккан. Язгы ата каз шикелле үрле-бирле йөгереп бии генә теге!

— Тәк, менә һинең һырхаулап киткәнде исетүгә, осып килнек, Дифа. Группалагы иң сибәр кыд сирләп егылһын да, нисек килмәйһең ти? Бер гелә һыдгырдым, момент йыйылдылар. Сунһыд һис ярамай. Суңа ла иптәстәр, студенттар лабаһа бед. Сынлап әйтһәң, бер әсә балалары.

Ниһаять, башкалар да сүз куша башлады.

— Кайгырып ятма, чынлап чирлә, Зифа. Терелмичә, дәресләргә чыкма.

— Без сине барыбер ярдәмнән ташламыйбыз. Көн дә киләчәкбез...

Арада бер «рәссам» Һади гына тончыгып туктый-тук-

тый, интегә-интегә ими имгән сабыен күзәткән ананыкыдай наз һәм җылылык тулы карашын Зифага төбәгән көенчә сүз дә әйтми тора. Аның өчен дә бераздан башкалар җыр тезде.

— И-и, әйтергә дә онытып торабыз икән, сантый. Без әле кичә генә Һадины бөтен техникумның комсомол секретаре итеп сайладык бит. Безнең иң олы ләчәннигебез шушы була хәзер.

— Ләчәнник булса да, приказны без бирәбез. Нәгыймова Зифа техникумның иң әйбәт укучысы, гаилә ягыннан ярдәм күтәрдәй бүтән кешесе юк, дидек без аңа. Иң олы ярдәмне син оештырасың, Зифаны ташламыйсың, дидек. Килеп, укуда сиңа ярдәм итми генә карасын, ләчәнниклегеннән мамин шудырабыз...

Тәүге тапкыр болынга чыгарылган яшь колын шикелле ихахайлап дәррәү көлештеләр. Секретарь Һади элеккечә сүз әйтә алмый торды. Ул арада Бану карчыкның самавыры кайнап чыккан икән. Кунак сабакташлар әллә никадәрле бавырсак, эремчек, коймак, гөбәдия, каклар төяп килгән. Гөргөр килә-килә җыйнаулап чәй эчтеләр. Зифага хәл кереп киткән шикелле булды, күңеле күтәрелде. Дөньяда үзеңнең иң актыккы кеше булмавыңны, кемдер өчен бик якын һәм мохтаҗ икәнлегеңне тоеп-сизеп тору, и рәхәт шул!..

Кунаклар таралышкач, өй эче бушап калды, кинәт салкынайтты. Зифа хәзер күбрәк вакытын юрган астында үткәрергә ниятләгән иде, алай язмаган икән сиңа, кызый, һай, язмаган икән!

Сабакташлар икенче, өченче, аннан соңгы көннәрдә дә чиратлаша-чиратлаша гел хәл белештеләр. Күбесенчә староста Кыдрачев, күрше группадагы Сабитова һәм ... тәүге көннәрдә һич көтмәгән Һади килеп йөрде. Кыдрачев математика буенча мәсьәләләр чиштереп үзәгенә үтә, Сабитова техникумда узган тарих һәм әдәбият дәресләрен аңлата, Мәгубә үз чиратында көн саен диярлек рус теленнән сөйри. Һади — көчле географ һәм биолог. Ләкин гаҗәеп аз сөйләшә. Бүтәннәр таралып ялгыз калдылармы, бөтенләй дә дәшми. Зифаның кулларын үз учларына алып утыра-утыра да, берзаманны, уянып киткән сыман, ике-өч кенә сүз әйтеп куя.

— Э-эх, шушы куллар кайчан миңа чәй ясап эчерә башлар микән?!

Аңлап, тоеп тора Зифа: Һадиның, мөгаен дә, «күзем төште сиңа», «яратам, сөям сине», дигән сүзләрне җиткерәсе киләдер инде. Зифаның да шул сүзләрне, и-их, ишетәсе, тоясы килеп йөри. Ләкин йомыкый бит ул, җебегән бит ул Һади! Әйтми бит шундый сүзләрне, никләр генә әйтми?!

# ДҮРТЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

## 1

— Инәкәй, хат бар! Кибет янында туктатып, Гыйлмениса бирде, — дип, Вәзирәнең болдырдан ук шәрран ярып керүен ишеткәч тә, Гөлтуташның йөрәге ярылгандай булды.

«Әмир! Әмирдән... Табылдымы әллә? Исән микәнни соң, җаныкаем? Кайда булган? Ничек качып яткан? Кайчан кайтып, кая алып китәр?..»

— Менә, менә, инәкәй, Гыйлмениса бирде, — дип, Вәзирә зәңгәрсу түштәге конвертны кулларына китереп тоттыргач та, Гөлтуташның акыл очкыннары әле һаман бөтенләй кирәкмәс тишек-ярыкларны яктырткалап йөрде.

«Ну бу Вәзирәне! Шуның шайтан таягы сыман кадау телен кайсы сандалларга гына салып чүкетәсе?! Пучтальюн Гыйлмениса кырыкның аръягына чыккан хатын бит югыйсә. Шуны «апа» дип әйтергә тел җәлли, имансыз!»

Конверт тышындагы язуга күз салуга, Гөлтуташның йөрәге кабаттан жу итте.

«Нинди чит-ят кул бу? Әмир үзе әйтеп торып, башкага яздырганмы? Нигә яшеренгән? Әллә... әллә Әмир белән бәла-каза бармы?»

Ниһаять, конвертны ачып, Гөлтуташ хат юлларына капланды. Башыннан ахырына чаклы күз йөртеп чыкты, һични аңламады. Кайсы Зифа чирләп егылган? Ник чирләгән? Нинди карагат, нинди кара каен кайрысы хакында сораша бу кеше? Гомумән, Мәгубә дигән бәндәнең Гөлтуташ белән Зифага нинди катнашы бар?..

Хатны икенче мәртәбә, туктый-туктый укып чыккач кына, зиһене тәртәгә керде, күрәсең. Гөлтуташ түшәм сайгакларын кузгатырдай итеп үкерә дә башлады.

— И-и, бәхетсез башлар! Хәерченең чалкан егылса да борыны каный шул. Безнеңише хәерчегә техникумда уку язганмыни?! Апаң хаста булып егылган, балакаем! Атна буе укырга бара алмый, түшәктә аунап ята, ди. Дәрес калдырды дип, саботаж дип, техникумнан быжгыртып чыгарырлар инде аны, и-и, бәхетсез!

Тимерҗанны төн уртасына чаклы утны сүндермичә көтеп утырдылар. «Гаилә терәге» хатны шәхсән (!) үзе (!) укып чыгуга, бик тиз «рольгә» керде.

— Апаның хәле, чынлап та, шәп түгелдер инде, инәкәй. Хатны әллә нинди Мәгубәләр, ападан качырып кына язып ятмас иде. Апа күтәрәмгә калып, түшәккә ауган икән, эх, шәп түгел инде бу, эх, шәп түгел. Каникулга кайткач җүнле тәр-

бия дә күрсәтә алмадык бит. Мин гаепле инде моңа, мин булдыксыз!..

Бераздан Тимерҗан күрсәтмәләр бирүгә дә күчте.

— Тәк, болай итәбез, инәкәй. Син Күчәрбайдагы теге аксак Салихҗанны беләсең бит. Ну, аксак Салихҗан инде, мәктәптә каравылчы булып торган, мичләр ягып йөргән Салихҗанны. Вәт, Галимҗан абыйны алып киткәннән соң мәктәп бакчасын гел шул Салихҗан талады. Бакчадагы бөтен карлыганны Бәдрәш яклап өенә ташып торды. Әллә ничә төн буена очраттым мин аны. Ну, милициягә сатып йөреп вакланмадым инде. Безнең юлга каршы чыккан кеше түгел бит, нигә аны сатыйм? Өстәвенә, аксак. Вәт, иртәгә туп-туры менә шул кешегә барып кер, инәкәй. Шулай-шулай, диген, Тимерҗан тоткан, диген. Йә бер чиләк карлыган, йә вәринҗә чыгарып бирми икән, аңа кәюк...

Аксак Салихҗанның өметсез, мескен хәлен күз алдына китереп куйды бугай, Тимерҗан учларын бер-берсенә сугып, әтәчләнеп алды.

— Ә мин таң тишеге белән Килемгә чыгып китәм. Әткәй сөйли торган иде, андагы Җантурин бакчасында кара каен күп, дип. Башкалар аша да ишеткән бар. Керәм, туныйм! Бер Тимерҗан пәке тидергәннән генә коргаксымас әле. Корыса да, төкерәм мин аңа! Дуарян утырткан бакча, кәпитәлизем калдыгы!..

— Улыкаем! Килемгә тикле бит аңа егерме биш чакрым. Безгә ат бирүче юк, хәлгә керүче юк. Шушындый котыптай кыш уртасында җәяүле көйгә, ялгыз башың ничек барасың ди? Уенмыни, туда-суда илле чакрым ла ул.

Тимерҗан йодрыгы белән һаваны түшәмнән тезенә чаклы кырт иттереп ярып, сүзгә нокта куйды.

— Минем егерме җиде апам юк, фәкать берәү генә. Барам булгач, барам!..

Таң белән икесе ике тарафка карап юлга чыкты. Тимерҗан һич ялгышмый гөманлаган икән, аксак Салихҗан, ык-мык килеп тә тормыйча, Гөлтуташка өч литрлы банка чыгарып бирде. Канатланып киткән Гөлтуташ «ятып калганчы атып калыйм», дип кенә авыл советына кереп сораштырган иде, анда да ике иңенә канат үстерделәр.

— Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына. Иртәгә кич Зиннур белән Сәкинә Бәләбәйгә ударниклар слеты дигән җиргә китәләр бит. Прсидәтел ат та бирәм, диде. Син шуларга иярү ягын кара. Йә, инде гел булмаса, күчтәнәчләреңне шулар аша җибәрсәң дә була...

Гөлтуташ Тимерҗанны дүрт күз белән көтеп тилмерә башлады. Дуамал баш таш яра, дигән хикмәтле сүздә хаклык

юк дип әйтеп кара икән. Кич караңгы төшә башлаганда, май кояшы шикелле, авызын колакларына хәтле ерып кайтып керде теге.

— Ә мин Килемгә тикле Усманнарның олавында бардым. Кирегә җәяү. Әй, егерме биш чакрым — Каф тау арты түгел. Солдат буласы кеше лә, раз-два, раз-два, гүпчем сизелмәде. Аның каравы менә ярты капчык кайры. Рәхәтләнсен апа...

Керәшеннәр әйтмешли, гел маҗ гына килеп тормый икән. Гөлтуташ бик «бизәнеп-ясанып» чыгып киткән иде, ударниклар аны алмадылар.

— Безнең башта Шыгай авылына кереп чыгасы бар. Слетта катнашучыларга кием бирәләр, ди. Мишәйт итеп тә, трай тибеп тә йөрмә. Сантый түгел, күчтәнәчләреңне үзебез дә илтеп җиткерербез...

Гөлтуташның йөзенә төкерделәрмени?! Ике күзенә дә ачы яшь бәреп чыкты, ләкин сиздермәде.

— Баргач әйтегез инде, апаем, ныклап аңлатыгыз Зифага. Үзен бетермәсен...

Олау кузгалып киткәч, Гөлтуташ әле байтак ара буе арттан кычкыра-кычкыра аны озатып барды.

— Каен кайрысын Килемгә хәтле җәяү барып Тимерҗан алып кайтты. Шуны тапшыр, апаем, берүк оныта күрмә. Вәринҗәне дә Тимерҗан тапты, диген. Төп терәк шул безнең, берүк әйт, апаем...

## 2

Яшь чагында гомер елгасының акканы, һәй, сизеләмени?!

Зифаның да сырхаулап, кипшенеп йөргән вакытлары онытылды инде. Икенче яртыеллык башлануга, аны мәдәни-агарту комиссиясенә сайлап куйдылар. Концерт, спектакль, кичә әзерлибез дип мәш киләләр. Көн саен кич әле репетиция, әле бию. Комиссия кешесе дигән дәрәҗәне йөрткәч, әлбәттә, Зифа да һәркайсына диярлек барган була. Дөрес инде анысы, кылка-ярлы киеменнән хурланып, күбрәк вакыт стена буенда, кешеләр артына качыбрак торырга тырыша ул. Ләкин яшьлек, дәрт һәм дәрман үзенекен итә. Кешеләр җырласа, ул да кушыла. Биергә чакырып аның каршында тыпырдыйлар икән, ул да биеп китә. «Парлы танцы» дигәннәре генә аксаклый күп чакта. Педагогия техникумы булгач, монда егетләр аз. Утыз-кырык кешелек группада егет кисәкләре алты-җиде бөртек. Алар арасында да күбесенең буе Зифага йә муеннан, йә борыннан артмый.

Зифаны «парлы танцы»га, гадәттә, Һади гына дәшә. Ә Һади ул — күзле бүкән сыман. Маэмай шикелле төбәлеп гел карап тора, тик озын кич буена ярты сүз дә әйтми. Кызлар Зифадан әллә кайчаннан бирле бертуктаусыз көлә.

— Ни «айт» юк ул синең Һадиеңнан, ни «тайт» юк. Шул уҗым бозавына ничек түзәсеңдер?..

Ярар, уҗым бозавы да булсын Һади, бер сүз дә әйтмәсен ди. Аның каравы, Зифа клублардан башка кызлар кебек япа-ялгыз кайтмый! Бүтән кызлар артларына карана-карана, ишек-капка төпләрендә таптана-таптана тулай торакка, фатирларга кереп киткән чакта Зифа үзенең егете янында басып кала!

Көннәрдән бер көнне шушы уҗым бозавы язгы ташу сыман капылт уянды бит.

Техникумнан унлап студент кызны Бәләбәй читендәге хәрбиләр клубына ниндидер спектакль әзерләргә җибәргәннәр иде. «Тәкъдир кушу» дигәннәре шул булгандыр инде, исемлеккә «культмассовик» Зифа да эләккән. Карышу-тиргәшүне белү бармыни ул? Берничә кич буе шунда йөрде Зифа.

Хәрбиләр арасында Такаев атлы бер егет бар иде. Кыяфәт — егылмалы! Бастырыктай гәүдә, тәмәке көлен каккан чагында да йөгереп йөргән мускул, чегәннеке сыман кара бөдрә чәчләр, ауга чыккан сунарчыларга гына хас бертуктаусыз уйнаклап торган күзләр. И-и, ул аңа хәрби гимнастерка, каешларның килешеп торулары! Кызлар әйтмешли, кәртинкә тек кәртинкә инде, чыдамасаң, моның рәсемен фатирыңның берәр почмагына икона урынына эл дә куй, чукынчык!

Ике-өч көннән соң менә шушы Такаев, язгы ата каз шикелле, гел Зифа тирәсендә биеп йөри башлады.

— Кем чибәре буласың син, кызый? Чыгыш кайсы яктан? Әйдә, танышыйк инде.

Такаев, норсызланып, әле биленнән кочмаса, әле күкрәгенә килеп ышкынмаса, бәлки, Зифа аның белән сөйләшеп тә киткән булыр иде. Ә корчаңгылы үгез кебек гел ешынуны гына чамалап торган егеткә ни ышаныч?..

Такаев бермәлне Зифаны озатып куярга ымсына башлады. Арада елгыр-чая кызлар җитәрлек, әмәлен тиз таптылар.

— Без кием алыштырырга, бизәнергә дигән булып әнә теге бүлмәгә кереп бикләнәбез. Ә син арттагы тәрәзә аша выжт урамга!..

Бер-ике көн буе шулай алдадылар, аннары ниндидер әмер үтәргә йөреп Такаев үзе югалыбрак торды. Спектакль көн-

не техникумнан яшьләр бик күп килгән иде, Такаев Зифаның чыгып шылуын абайламый калды.

Бәлки, хәлләр шушының белән онытылыр иде. Ләкин икенче көнне соңгы дәрестән коридорга чыккач, Зифа тәрәзә буенда үзен көтеп торган Такаевны күрде дә каккан казык кебек үрә катты. Башка егетләр-кызлар хихылдаган, пышылдашкан булып урык-сурык үтеп йөриләр, ә Зифа, аякларына гер аскан шикелле, кымшана алмый тора. Шуны сизенгәндер инде, хәрби гимнастеркасының итәк очларын тарткалый-тарткалый Такаев үзе Зифаның каршына килеп басты.

— Зерә генә качасың син, сылукай. Мин бит чигенә белүче йомшак заттан түгел. Мине санга санамыйсың икән, урлап алып китәм...

Менә шул минутта комитет бүлмәсеннән Һади килеп чыкмасынмы! Ул берникадәр ара гына сүзсез басып торды. Аннары барысын да аңлагандыр инде. Башка чакта керфек астыннан юньләп күренмәгән күзләреннән хәзер очкын чәчеп Такаев каршына йөгерде дә килде.

— Ваянный булсаң, ваянный бул. Әйдә, техникумнан чыгып сөйләшәбез!

Такаев әүвәл борын астыннан гына бик мыскыллы итеп елмайса да, сүзсез ияреп китте. Аннан соңгы хәлләрне Зифага кич белән читләр җиткерделәр.

— Синең Һади сынык бер киртә күтәреп ярты Бәләбәй буйлап куып йөрткән теге ваянныйны. Менә сиңа «бозау»!..

Һадины Зифа үзе ике-өч көннән соң гына күрә алды. Егетнең бер як күз төбе кара янып тора, әмма ике арада булган сәер хәлне ул үзе әйтерсең лә күптән оныткан иде.

— Безне быел апрель ахырында практикага җибәрәләр бит, беләсеңдер инде, — дип, бөтенләй көтелмәгән сүз башлады Һади, гомер буе лекция укыган кеше шикелле ашыгып тезә-тезә. — Мин белештем, бер җирдә дә акча түләмиләр. Мәгәр урыс авылларына барсак отышлырак, урыс мәктәпләренә лимит юк, ди.

Зифаның «ә» дип тә, «җә» дип тә авыз ачмый торуы аптыратты бугай, Һади янә тезде:

— Йә Языковога барабыз, йә Туймазының үзенә. Языковосы синең авылыңа якын, унбиш чакрым ара. Туймазы — минем туган як. Сине алып кайтып туганнарга күрсәтәсе килә...

Апрель ахырында, ызгыш-талашларсыз килешеп, Языковога кайтып эшли башладылар. Төркәй кул сузымында гына булса да, Зифага әниләре янына кайтып күренергә җай чыкмады. Нәкъ шул көннәрдә район хәрби комиссариаты-

ның «яшь сугышчылар курсы»на ике йөздән артык татар егетләрен чакыртканнар икән. Зифа белән Һади — икесе тиң — көндез мәктәптә укытсалар, кич белән хәрби курсларга тыр-тыр йөгерделәр. Һади «сары томшыклар»ның күзләрен география буенча берникадәр ачкан сыман итте, Зифа тегеләрне рус теленнән тартты. Өйдә дәрес планы төзеп утыруны да исәпләсәң, ике яшь мөгаллимнең тын алырга да вакыты юк иде. Сөенече өч атнадан соң, тәүге карга охшап, көтелмәгән чаклы ишелеп төште. Хәрби курсларда укыткан өчен генә дә Зифаның берүзенә утыз тәңкә акча тоттырдылар! Зифаның куллары шул минутта ут шикелле янды, ә чигәсендә әйтерсең лә чүкеч биеп торды.

— Беренче зарплата... Утыз тәңкә акча... Утыз тәңкә, утыз...

Зифа иң олы бүләкне әнисенә алырга дип ниятләгән иде. Һади кире какты.

— Сезнең Тимерҗан уналтыны куа. Кызлар артыннан юырта башлаган чагы. Өстеңә җүнле киемең булмаса, мондый яшьтә, әй, гарьлек ул!.. Әниең үпкәләмәс. Иң олы бүләкне энеңә ал.

Базарда Һади белән бергә кием сайладылар. Унсигез тәңкә акча — Тимерҗан пәлтәсенә, тагын тугыз тәңкәсе әнисе өчен алган яшел кофта белән Вәзирәгә дигән ал күлмәккә китте. Һади «үзеңә менә монысын ал, тегесен ал» дип базарның буеннан-буена кыстап йөргән иде, Зифага җәйге туфли белән генә «әппәр» итеп куярга туры килде.

Аның каравы, өйдә шатландылар. Әлбәттә инде, беренче чиратта Тимерҗанның баш түбәсе җиде күккә тиде. «Рәхмәт сиңа, апа, рәхмәт сиңа» сүзен озын кич буена теленнән төшермәде. Ә әниләрендә һаман иске гадәт — илерә-илерә өзгәләнә, җаный.

— Ходай Тәгалә без ятимнәргә мондый бәхетләрне күпсенмәсен иде...

## 3

«Ач этнең өрүләре Ходайга ишетелсә, күктән ит явар иде» дип әйткән, ди, бер акыллы бәндә. Юк, Гөлтуташның илереп ялваруы җиде кат болытлар өстенә менеп җитмәде шул...

Тимерҗан озын җәй буена, артына сабын кыстырган шикелле гел кыбырсып йөрде. Нинди генә сүз әйтмә, йомыш кушма, күкерт сыман кабына да китә.

— Бөтен кеше Гайшә әрәмәлегеннән чыбык кисеп ташый, безгә дә кыш хәстәрен күрәсе бар, балам.

— Әй, таптың сүз, башны катырмале...

Чегән ат капшаган шикелле итеп, Гөлтуташ икенче яклап та җаена төшеп карый.

— Өй түбәсен яңа салам беләнябып куйсак, ә-әй, көнләшер иде күрше-күлән!

— Түбә кайгысымыни соң әле монда? Бөтен җирдә сыйнфый көрәш бара, һәр ярыкка дошман кереп тулган...

Тимерҗанның телендә гел шундый сүз. Аны тыңлап торсаң, баш бетмәле.

— Донбасс шахталарының кантурына халык дошманнары кереп тулган булган. Эшчеләргә ике-өч ай буе акча бирми торып, забастуфка әзерләп ятканнар, ди. Ярый әле, энкеведе уяу, Ежов йокламаган. Контрларны керпедәй бияләе белән ярыклардан сөйрәп чыгарган, ди.

— Урал аръягында элеккеге патша әфисәрләре йөздән артык паравызны юри ремутламый эштән чыгарганнар. Ежов маладис, тегеләрне стенага терәп аттырган бит...

Тимерҗан элеккечә ярты төн үткәнче әллә кайда йөри. Өрәк сыман ябыгып, суырылып калды. Аның көлүе дә көлү түгел хәзер, ә зәһәр кычыткан чагуга тиң. Өстәл артына утырса да, башкалар кебек тын алуны белми. Артыннан убырлы-пәриләр куалый диярсең, голт-голт итеп кенә йотып куя, аннары янә ниндидер дошманнарны каравылларга дип чыгып кача.

Җаны теләгән, елан ите ашаган, дигән сүз хак, күрәсең. Август ахырларында Тимерҗан өйгә таш кирмән яулаган сәрдәр сыман балкып-гөрләп кайтты.

— Булды, Чүпрәк Нәби белән Канкайны да озаттырдык әле. Егетләр кулы да тотып карамаган кызлар сымак гөнаһсыз булып йөрмәсеннәр. Безнең әтәй төрмә баландасын чөмерәме? Болар да татысыннар! Боларга да шул төс!..

«Боларга да» дип кабатлады Гөлтуташ, эчтән генә янып. Бәрәч, бәрәч, Тимерҗан үзенең туган әтисен дә дошманга чыгарган түгелме соң инде? Тимерҗанның мондый чире кая барып җитәр?..

Өй эченә елан кердемени, Гөлтуташ гел аш-йокысыз калды.

## 4

Тимерҗан егерме сигезенче октябрь кичендә Күчәрбайдан шыр пычракка батып кайтып керде. Йөзләре-күзләре ут шикелле яна.

— Иртәгә комсомол туган көн, инәкәй. Егерме еллыгы. Зурлап үткәрәбез. Митинглар, кансирт әзерләдек. Районнан килсәләр, деманстраси була. Таң тишегеннән чыгып йөгерәсе бар. Капкалап та тормыйм, ятыйм әле...

Ут сүндергәч бер сәгать тә вакыт үтмәгәндер, дөмберт итеп ишек шакыдылар. Урыннан купканчы ук тоеп алды Гөлтуташ: шулар бу, шулар, Әмирҗанны алып китүчеләр!

Мамык шикелле җебегән аякларын сөйрәп болдыр ишеген ачса, әзмәвердәй өч ир. Гөлтуташны корыган әрем сабагы урынына читкә эттеләр дә өйгә ыргылдылар. Гөлтуташ иң азаккы булып ишектән узган чакта, Тимерҗанны идәнгә йөзтүбән сузып салганнар, алтатар тоткан бер җанвары аның кулларын артка таба боргычлап та куйган иде инде.

— Воронеждагы Васнецов группасына ялланып, Сталинның башына җитәргә җыендыңмы, көчек? Сез, яшьләр, эрвәлүтсия ясаган иске коммунистларны чәнчелдереп атырга булдыгызмы? Менә сиңа, контр, менә сиңа!

Бу котырган җанвар Тимерҗанның муенын, иңбашларын алтатар түтәсе белән төя башлагач, Гөлтуташ аның чәчләренә ни рәвешле барып ябышканын сизмичә дә калды. Ишек катында торган ике ир аны шундук йолкып алдылар да, мич каршына болгап ыргыттылар.

— Үзеңнең дә Себер китәсе килмәсә, тик кенә тор, карчык. Ә без хәзер бу контрның... агызабыз!

Сәке түрендә Вәзирә чәр акырып үкерергә тотынган иде, башына юрган бөркәп аны да томаладылар. Тимерҗанның сыртына атланып утырган явыз, әледән-әле аны алтатары белән төя-төя, бар агуын чәчте:

— Мәскәүдән Шепелев төзеп җибәргән программагыз кайда? Бүздәктәге Насыйровка дип әзерләнгән гаризаңны кай тишеккә тыктың? Барысын да үзең чыгарып сал, юкса...

Алтатарлы җанвар авызыннан түгелгән шакшы, хәшәрәт сүзләрне ишетүдән Гөлтуташның колаклары ут шикелле яна башлады. Ә Тимерҗанның җаны бөтенләй юк диярсең, аскы иренен чытырдатып тешләп, тын чыгармый ята.

Ярым пеләш башлы бу җанвар да берзаманны түземлеген җуйды.

— Нәрсә, мәлҗерәп төштегез монда, анагызны... Сәетбаев миңа Нәгыймовның Насыйровка язган гаризасын табып китерегез, диде. Актарыгыз өйне! Астын-өскә китереп бетерегез!

— Өстенә менеп икебез бер сикерсәк, аны үзе дә өр-яңадан язып бирә бит ул,— дип, милицияләрнең берсе кул гына селтәмәкче булган иде, ярым пеләш бәндә янә бер үкерде:

— Анысы качмас. Яңа дукамит-фәлән табылмасмы, актарыгыз өйне!..

Тәрәзә кашагаларын кадакларыннан сөйрәп чыгардылар. Киштәләргә тезгән бөтен савыт-саба кырылып төште. Юрганнарны телем-телем итеп кисеп бетерделәр. Идән астындагы бөтен сөт-май балчык өстенә түгелде. Стенада-

гы көзгене тирәләп ябыштырган барча рәсем-кәгазьләрне йолкып ташладылар. Бөтен өйнең астын-өскә китереп бетерделәр, «программа», «гариза» дигән кәгазьләр табылмады.

— Ярар,— диде, ниһаять, бу ярым пеләш бәндә, «иманына килеп».— Моны сез әйткәнчә изми булмый инде. Әйдә, Бүздәк төрмәсенә алып китик, анда үтүкләрбез...

Болар алдан ук бар хәстәрен күреп килгән икән. Үзләре өчәү, ә урамда дүрт ат көтеп тора. Куллары артка каерып бәйләнгән Тимерҗанны запас ат өстенә чыгарып утырттылар. Дәүләкән-Чишмә яклап сызылып кына таң ата башлаган иде инде. Тимерҗанның ияк-иреннәре, колак тирәләре тоташ кан икәне күренеп тора. Күзләрендә өметсезлек, сагыш.

— Кайгырып ятмагыз, инәкәй,— дип тавыш биргән булды Тимерҗан, төн буена беренче мәртәбә авызын ачып.— Миңа берни булмый. Мин әйләнеп кайтам.

Гөлтуташның йөрәге шул минутта без кадаган кебек чәнчеп алды. «Кайтмый, кайтмый, балакаем,— дигән уй яндырып узды.— Әмирҗан да менә шундый вәгъдә биреп киткән иде, югалды бит. Тимерҗан да кайтмый. Бердәнбер улыкаемны соңгы тапкыр күрүләрем шушы микәнни соң?»

— На-а, ананңны этләр еккыры! — дип, ярым пеләш җанвар койрыгы бөкләп бәйләнгән айгырының касыгына типте.— Галәү, бу көчекнең атын син җитәклә!

Көзге пычракка тояклары белән лас-лос басып атлар атлап китте. Гөлтуташ ут эчендә. Китә, китә бала. Мәңгелеккә китә. Газиз күкрәк сөтен имезеп үстергән бердәнбер улыкаен моннан ары ул күрәчәк түгел. Шушылай, этләр кулына биреп, әрәм итәр өчен үстердемени соң ул аны? Ходай Тәгалә җәберләнгән, изелгән үксезләрне никләр генә күрми, ник якламый?..

Элеккеге Әхтәм мулла йортының капка турына җиткәч, Тимерҗан артына борылып күз ташлады. Шуны чакыру, әмер дип кабул итте, күрәсең, Гөлтуташ үзен-үзе белми алга томырылды. «Һич югы, тагын бер генә мәртәбә булса да карап калыйм. Әллә күрәм әле балакаемны, әллә үләм?..»

Җепкә таккан шикелле ияреп килгән ананы чамалауга, ияргә менгән җәлладлар атларын тизләттеләр. Юл Чәрмәсән ягына борыла, түбән төшә иде. Атлар вакыты-вакыты белән юырткалап алды. Аңа карап, Гөлтуташ белән ара кимемәде. Өстенә бишмәт-кофта да эләктереп тормаган ана янып пешә-пешә йөгерә үк башлады.

— Интегеп йөрмә инде, инәкәй. Бар, өйгә кайт! — дип, берзаман Тимерҗан ялварулы аваз да салып карады.

Юк, тыңламады Гөлтуташ. Тузгыган чәчләрен артка ташлый-ташлый һаман йөгерде, һаман иярде ул.

Чәрмәсәндәге буаны инде күптән җибәргәннәр иде. Җайдаклар тукталып та тормыйча елганы аркылыга кичә башладылар. Каршы ярга чыккач, әллә котырткан шикелле, әллә тантана итеп, ярым пеләш бәндә атларга барникадәр тын алырга ирек куеп торды. Тимерҗанның теленнән тарттылармыни, кычкырды бит шулчак:

— Э-эх, түбәне ябып булмады, инәкәй, сүзеңне тыңламадым. Тагын котып эчендә кыш чыгасыз инде.

— Ха-ха-ха! — дип кешнәп кычкырды да, пеләш башлы җәллад айгырын урыныннан сикереп кузгалырга мәҗбүр итте. Юк, айгырына әмер бирмәде ул, мескен, бичара анага ым кагуы булды.

Гөлтуташ нарасыен уттан коткарырга ташланган ана ярсуы белән Чәрмәсән суына томырылды. Кара көзнең суы боздай салкын, ул әле ике-өч адым атлауга ук Гөлтуташның бөтен тәнен-канын куырып алган иде. Мескен ана һични шәйләмәде. Зиһенендә, чаң авазы сыман, тик бер генә теләк шаулап торды.

— Тагын бер генә тапкыр, соңгы тапкыр күрим балакайны!..

Гөлтуташ өй эченә аякларын көч-хәл белән сөйри-сөйри кайтып керде дә, ут шикелле кызышып, түшәк өстенә ауды.

## 5

Техникумда соңгы вакытларда көн дә күңелле тантана, көн дә бәйрәм. Әле генә комсомол юбилеен, Октябрь бәйрәмен үткәргәннәр иде, бүген ике укытучы абыйларын Кызыл Армия сафына озаталар.

Зифалар курсы — техникумда хәзер иң өлкәне, алар студентлар арасында иң-иң абруйлылар. Кичә-бәйрәмнәр оештыру да күбесенчә шулар җилкәсендә.

Иртәгә Солтанов белән Мортазин абыйлары армиягә китә. Ерак Көнчыгыштагы ниндидер Хәсән күле буенда японнар белән сугыш башланган, ди. Чикне саклап калу, япон еланнарының койрыкларын өзеп ташлау өчен, армиягә иң булдыклы, чая ирләр кирәк. Мортазин белән Солтанов абыйлары нәкъ шундыйлар. Берсе биологиядән укытты, берсе тарихтан сөйрәде. Менә бүген, матур кичә оештырып, аларны озаталар. Концерт өлешендә башкарачак җырларны инде әллә кайчан өйрәнгәннәр иде.

Җил тимәсә, тибрәнмиләр
Наратның ылыслары,
Дошман килсә, башын кисә
Безнең ил кылычлары.
Туп аталар еракта,
Сугышлар булган якта,
Япуннарга бирешмибез
Сталин булган чакта.

Комсомол комитетыннан Һади кереп: «Бу гына аз»,— дигәч, искеләрен искә төшерделәр.

Туган илем чикләрендә
Сыйнфым өчен постта мин,
Безгә матур тормыш бирде
Бөек даһи Сталин.
Сандугачка җимнәр сиптем,
Сайрасын да ашасын,
Яңа закон иҗатчысы —
Даһиебыз яшәсен!..

Зифа да алдан ук, стена газетасына куярга дип, яңа шигырь язып биргән иде. Кичә башлангач, шул шигырьне аңа сәхнәгә чыгып та сөйләү йөкләтелде. Зифаның моңа чаклы сәхнә тикле сәхнәгә япа-ялгыз көе чыкканы юк иде. Шуңадырмы, залны тутырып утырган халык алдында әүвәл бик нык дулкынланды.

— «Ихлас сүз». Зифа Нәгыймова шигыре,— дигән кереш өлешне ике-өч мәртәбә кабатлады. Аның каравы куплетларны шома тезеп китте:

И кадерле мөгаллимнәр,
Илне уяу саклагыз!
Без монда яхшы укырбыз,
Сезнең йөзне акларбыз...

Шигырьне зал тоташ алкышларга күмеп каршылады. Янган-пешкән Зифа комачтай кызарып сәхнә артына йөгереп чыккан иде, караңгырак, аулаграк почмакка Һади кереп поскан. Тирә-юньдә бер җан әсәре юк. Батырланган Һади аны кочагына алды. Алар шунда тәүге тапкыр, качып үбештеләр...

Залга кабат кайтсалар, Зифаны укыту бүлеге мөдире көтеп тора. Ул техникумда үтә кырыс, усал хатын булып исәпләнә иде, ә бу юлы әллә нишләп карашы җылы, әмма йөзе уйчан.

— Нәгыймова! Сиңа бер хәбәр бар. Монда сөйләшеп булмый, кабинетка керик.

Бүлмәдә Зифа урындыкка җайлап утырганнан соң гына, мөдир хатын телеграмма суздды.

— Нык була күр, җаным. Әниең вафат булган...

## 6

Чишмә станциясендә төшеп калган чакта, юлларны-басуларны бүрек калынлыгы кар каплаган иде инде. Комсомолкамы, түгелме — татар баласы бит. Әнисенең өчесен, җидесен үткәрәчәкне исәпләп, Зифа Бәләбәйдән үк унике кадак он, ике кило чамасы сарык ите, учы-учы белән кара җимеш, йөзем төяп чыкты. Кышкы юлда япа-ялгыз көе, сыртындагы йөктән бигрәк, кайгы төягән хәлдә алтмыш чакрым ара атлап үтүләре бер дә җиңел түгел. Бу юлы да Сарманайда кунып, басу урталарында тукталгач, үкереп елый-елый, Зифа ике араны тәүлек ярым кайтты.

Өйгә килеп керсә, өзлеккән, кипшенеп беткән әнисенең гәүдәсе түр сәкедә ята. Яулык-шәлләргә төренгән унөч яшьлек Вәзирә сәкенең бер почмагына чүмәшеп утырган. Елыйелый алҗыгандыр инде. Хәзер йөзендә һичбер төрле хис юк, башына күсәк белән сугып миңгерәтелгән кеше шикелле, күзләрен әнисенә текәп тик утыра. Ишектән апасы килеп кергәч тә сикереп төшмәде ул. Бераз вакыт күзәтеп торгач кына, шәүлә сыман тавышсыз-тынсыз килеп, апасының кочагына сеңде.

Өй эчендә тагын ике кеше бар. Берсе — каршы якта, икенчесе күршедә япа-ялгыз яшәп ятучы Гөлсабира түти белән Шәмсекамал карчык. Икесе дә авызларына су капкандай бер сүз эндәшмиләр.

Зифа әнисенең гәүдәсе өстенә капланып өзгәләнгәч, шактый вакыт тып-тын утырдылар. Беренче булып Зифа айный башлады. Ул әле ишек ачканда ук сизеп алган иде — йорт мичենә соңгы көннәрдә берни ягылмаган, өй эче мәгарәдәй салкын. Гаепле кешене биетәсе килеп китте бугай, тәүге булып, Зифа сорау бирде:

— Ә Тимерҗан кайда? Тимерҗан ни карый?

Күрше карчыклар бүкән сыман селкенмичә утыруны белде, җавап сүзен Вәзирә ишеттерде.

— Тимерҗанны апкиттеләр, Зифа. Милиция алды. Әтәйнеке сымак, төнлә апкиттеләр.

Кайгы килсә, шулай була икән: бер әйтүдә аңлый алмый кеше. Зифа да, миңгерәү шикелле, кат-кат сорау тезде:

— Ничек инде, ничек апкиттеләр? Тимерҗанга уналты да тулмаган бит әле. Аннары… аннары инәң үлеп яткан чакта ничек апкитсеннәр?

Әбиләр телгә килеп сөйли башлагач кына, үзләренең өй эченә ишелеп төшкән кайгы-газапларның күләме-чамасы Зифаның зиһененә барып җитте сыман. Ул, иңенә Каф тавы яткандай, шундук бөгелеп төште. Гүя җиһан томаланды, дөнья

җимерелде. Ул үксегән чакта, ара-тирә күрше карчыкларның сөйләгәне ишетелеп торды.

— Тимерҗанны алып киткән чакта, инәң Чәрмәсәнгә барып кергән бит ул. Менә моннан, бил тиңентен ерып, ике тапкыр аркылыга чыккан. Җан җиренә салкын тигән аның, безнең йомшак җиргә. И-и, кызган баштан үктәбер суына керәләрмени, сантый?!

— Шундук безне чакырып әйткән булса, мунча ягар идек, тегеләй-болай итеп карар идек. Дәшмәде бит, наный, әһ, дәшмәде. Тимерҗансыз да калгач, уш дигәнен югалткандыр инде...

Икенче көнне ат сорарга идарәгә барса, колхоз рәисе урынында — Кара тавык! Җир йөзендә шулкадәр кабахәт, вак җаннар да булса була икән!

— Син безнеке түгел, пропискадан төшкән. Ниткән ат ул сиңа?..

Гөлтуташны чыптага төреп, кул арбасына салып сөйрисөйри, илтеп җирләделәр. Ни галәмәт, каберне, күршеләрендәге ике-өч ирне дәшеп, Әмирнең абыйсы Әбелсаттар казытты. Зираттан кайтып өй җыештыра башлагач та, беренче булып, нәкъ шул килеп керде.

— Сиңа укуыңны бетерергә кирәк. Вәзирәне юлга әзерләмә. Җәйгә чаклы бездә яшәп торыр...

Зифа Төркәйдә соңгы сәгатьләрне уздыруын аңлый, белә иде. Тома ятимә булып калган Вәзирәне кочагына кайнар кыскан килеш, ул төн буена илереп елап чыкты.

— Безгә монда калырга ярамый, апакаем. Инәкәй белеп әйткән, дуска караганда дошман күбрәк, алар безгә яшәргә барыбер дә ирек бирмәячәк. Башны алып чыгып качарга кирәк моннан. Булдыра алсак, бөтенләй Башкортстаныннан ук чыгып качарга кирәк.

## БИШЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Техникумда укуның соңгы көннәре якынлашкан саен, Һади әллә каян гына уйлап чыгарган сәер тәкъдиме белән Зифаның үзәгенә үтә башлады.

— Тире иләүчеләр урамында минем инәй яклап якын туганнар бар. Сине авылга апкайтып күрсәтергә тәки җай чыкмады. Әйдә, ичмаса, мондагы туганнарга булса да бер күреник инде.

Үзен базарда сатарга чыгарылган мал хәлендә тою Зифаның мин-минлеген сыта-изә иде. Тик аның артыннан чебен

көтүе сыман өерелеп йөрүче егетләр бармыни? Йә булмаса, «монысы миңа да, тегесе сиңа» дип, үзара ызгыша-ызгыша бер җәтмә балык бүлешкән әртил кебек, аның өчен тарткалашып торучы егетләр дә юк. Өлешенә тигән көмеше шул: аның карап торган, өмет тоткан бар байлыгы — Һади! Ябышып чыгарлыкмы, түгелме ул? Ләкин тәкъдир аның каршына әлегә фәкать шул егетне генә китереп куйган. Йә син аның тәкъдименә буйсын, йә...

Менә анысы Зифаның кодрәтеннән килми. Юк, кире кага алмый ул Һадины. Шыр хәерче, бер терәксез килеш син әле япа-ялгыз көе дә күтәрәмгә калган ат кебексең. Ә артыңда тагын дөм ятимә Вәзирә сурәтендәге бернигә яраксыз арбаң да бар. Мондый хәлдә ничек итеп сикеренмәк, боргаланмак, ялындырмак кирәк?..

Һадиның туганнары карап торышка мөлаем, тыныч кына кешеләр булып күренде Зифага. Утыз-утыз биш яшьләр тирәсендә болар. Ире Әгъләм исемле, хатыны Рәбыйга атлы. Һадиларга туган тиешле кеше Әгъләм абзый булгандыр инде. Һади аның хатынына «җиңгәчәй» ди. Тормышлары таза, йортлары алты почмаклы. Сарай, мунча, келәт тезелеп киткән. Алма бакчасы бар, бәрәңгенеке аерым. Ихаталарына коесына хәтле казыганнар. Әмма ихатага күрше-күлән кергәне һич күренми. Сөйләшә торгач, ачыклана төште. Гаиләдә хуҗа кеше Әгъләм абзый түгел, ә Рәбыйга икән. Әгъләм, җил искән шикелле, ярык калса гына сүз кыстырып куя, Рәбыйгасы бар тезгенне үз кулында тота. Сорауларны да, билгеле инде, ул яудырып тора:

— Әби-бабаларыгыз хәлле булганмы соң?

— Нәселегездә чирле кешеләр юкмы?

— Әби-бабаң азып-тузып йөрмәделәр микән?..

Танышу бу рәвешчә җиде бабалардан тамырлангач, Зифа инде мондый «дапруслауны» кара төн уртасына кадәр сузылыр дип хафага төшкән иде. Аш-су тирәсендә кайнаша башлауга, хуҗабикә эшне кызулатты.

— Гөбәдия камырына ничә калак май сала да, ничә йомырка кушып туглый иде әнкәң?

— Яңакларыңа кершәнне мул яккансың, бетчә чыгып җәфаламый торгандыр бит инде?

— Әниеңнең үлек бала тапканы булмадымы?..

Ахырда Зифаны капка төбенә хәтле чыгарып куеп, аркасыннан сөеп озаттылар.

— Килен була калсаң, кунакларга йөрешеп яшәргә язсын инде, бәбкәм!..

Зифа белән Һади болардан канатланып кайтып киткән иде. Ләкин берәр атнадан соң Һади кичләрен күренми баш-

лады. Техникумда очрашсалар, былтыргы гадәтенә әйләнеп кайткан сыман Һади бер сүз дәшми. Күзләрен керфекләре артына яшерә, карашы хәерче учагындагы ут шикелле сүрән. Зифа ни кыларга белми гаҗизләнә иде, сәер бу төенне Рәбыйга «җиңгәчәй» ансат чишеп бирде.

Зифа ул көнне техникумнан бик соңарып кына юлга чыкты. Җир өстенә эңгер-меңгер төшкән, күз бәйләнгән вакыт. Үзләренең урам очына килеп кергәч тә, Зифа әле як-ягына карап маташмады. Тагын ике-өч кенә капка турын үтәсе бар, аннан керә дә ава.

Шул чагында кайсыдыр ихатаның койма ышыгыннан аерылып, аңа каршы ялгыз шәүлә чыкты. Зифа адымнарын киметмичә генә үтеп китмәкче иде дә, шәүлә хуҗасы аның беләгеннән каптырып алды.

— Исәнме, сеңелкәем. Сине көтәм бит мин, кая ашыгасың?

Зифа моның Рәбыйга икәнлеген тавышыннан ук таныган иде инде. «Җиңгәчәй»нең аны түше кычытканнан гына сагалап тормавы күк йөздәй ачык, шуны чамалап, Зифа аңа җавап-мазар биреп вакланмады.

— Сиңа хатын-кызлар колагыннан колагына гына күчеп йөри торган бер сүзем бар. Урам уртасында тилиграм баганасы сымак үрә торып булмый, әйдә, җаным, урап килик әле.

Аркылы сузылган зур урамга чыккач, Рәбыйга хакыйкатьне туп-турыдан ярды:

— Безнең Һади, әрекмән колак, сиңа кагылышлы күп нәрсәне сөйләмичә йөргән. «Вәт, Зифа чибәр кыз кеше дә, Зифа яхшы иптәш». Тешен төшерердәй итеп сөйләгән бар сүзе шул булды. Соңрак сезнең техникумдагы бер марҗа хатыны аша гына әз-мәз белештем мин. Элегрәк белеп өлгерсәм, мин сине үзебезнең ихатага кертмәгән дә булыр идем, кызый. Синең атаң инде күптән өтермә чыпчыгы икән бит. Хәзер әнә энекәшеңне дә килеп җыйнаганнар. Сез бөтен гаиләгез белән халык дошманнары икәнсез лә, Һади, бозау, шуны әйтми йөргән. Ю-ю-ук, сезнең ише кешеләр белән туганлаша торган заман түгел. Синең атаң белән энекәшең юлыннан өтермәгә кереп черәп булмас. Безнең Һади тирәсеннән тәртәңне бор, кызый...

Зифа үзләренең капка төбенә җиткәнче өзгәләнеп елыйелый кайтты. «Качарга кирәк бу Бәләбәеннән! Башны алырга да, алны-артны карамыйча Башкортстаныннан ук чыгып олагырга кирәк. Кара сакалың кая барсаң да, синнән калмый, диләр. Барыбер көн юк миңа бу Башкортстанда. Кандала сыман кайсы гына ярыкка кереп качарга исәпләсәм дә барыбер көн юк. Качам, качам, качам...»

Әмма кулын капка келәсенә тидергәндә, Зифаның күз төп-

ләре, яңаклары янә җил ялап алган шикелле коры, чиста иде. Әнисенең васыяте бар бит. Әнисе аңа авызы тулы кара кан булса да, чит-ят каршында түкермәскә кушты...

Һади май ае башлангач кына аның янына кабат килде бугай. Куллары дер-дер килә, башын аска игән, мөгаен, ул Зифаның күзләренә күтәрелеп карарга да хурланадыр инде. Шулай да максатын-ниятен шактый бәйнә-бәйнә итеп аңлатты ул.

— Бүген-иртәгә безне кайсы якка эшкә җибәрүне билгеләү башланачак, Зифа. Мин Туймазыдан белешеп килгән идем. Үзибаш мәктәбенә әллә ничә укытучы кирәк. Биш куллап каршы алабыз, дип кат-кат чакырдылар. Анда дәресләр күп тиячәк, ызначит, акчасы да. Икебезгә дә эшкә юлламаны шунда алмыйбызмы?..

Зифа бик озак вакыт буена уйга чумып торды. Әмма җавабы кат-кат уйланылган һәм үлчәнгән иде.

— Без бер-беребезгә никадәр кирәклекне аңлап бетермәдек. Аерылып тору — иң зур сынау, диләр. Әйдә, икебез ике якта яшәп карыйк, Һади. Шуннан соң тормыш ни эшләргә кирәклекне үзе өйрәтә ул.

## 2

Зифаны әмер буенча Благовар районына җибәргәннәр иде, андагы мәгариф бүлегеннән Сарайлы дигән авылга озаттылар.

— Каланыкылар Сарайлыны өнәп бетермиләр, ә син авыл кызы,— дип дәртләндергән булды аны бүлектәге ир-ат.— Андагы мәктәп директоры исәпкә бар да инде ул, санга юграк.

Зифаның күзләрен чекерәйтә башлавын шәйләп өлгерде, ахрысы, оста гына үгетләүгә күчте:

— Сарайлыдагы бөтен хәят, барча тармак белән тик бер генә кеше идарә итә. Колхоз прсидәтеле Хәнифә Шәрипова. Сарайлылар өчен казый да, тукмак та — Хәнифә берүзе! Типичный солдафон! Иллә мәгәр аның белән уртак тел табуга ирешәсең икән, ашың пешүе бар. Моны искәреп кал, ни, кем, Нәгыймова...

Бераз акча эшләп булмасмы дип, Бәләбәйдә «яшь сугышчылар»ны укытып йөреп, Зифа билгеләнгән көннән шактый гына соңга калган иде. Сарайлыга шөлләп-хафаланып чыгып китте. Район үзәге белән авыл арасы егерме чакрымнар чамасы бар икән. Тәүге тапкыр яланга йөгәнсез чыгарылган ат шикелле, табигатьнең һәр почмагын күзәтә-күзәтә атлау — олы ләззәт.

Август әле борын гына ярган. Юлның ике ягыннан да җитлеккән бодай, арыш исе килә. Башактан-башакка сикереп төклетура оча. Кайдадыр саташып уянган чикерткәләр сайрый. Яндагы әрәмәлекләрдә бераз кызара башлаган шомырт, чия, балан, гөлҗимешләр исе. Адым саен, син кул бирмәгәнгә үпкәләп, каен җиләге, мәтрүшкәләр елап кала сыман. Күңелең белән үзеңнең дипломлы зур белгеч һәм бик кирәкле кеше булуыңны тоеп, шушындый оҗмах бакчалары яныннан атлап барулары, и-и, рәхәт соң!

Сарайлы һәрьяклап диярлек әрәмәлек, каен, зирек, усак агачлары белән әйләндереп алынган авыл булып чыкты. Хәтәр матур булып үзенә тартып тора, үкенә-сыкрана яшәргә туры килмәс, бәлки...

Җидееллык мәктәптә яндагы бакчада чокчынып йөрүче биология укытучысы Сара Садриевадан кала беркем дә юк икән.

— Сәяпеф Матаклыда, кодаларына китте. Дилехтырны әйтәм,— дип, аңлатма бирә башлады бердәнбер «каравылчы», балчыкка батып беткән зур куллары белән чәчләрен төзәткәләп. Зифа, күңеленнән генә, әллә кайчан яшәп киткән бабаларны сүкте. Матаклы! Ну, исемнәрне уйлап табарга маһир да соң татар!

«Каравылчы» Сара тыр-тыр килеп сөйләвен дәвам итте:

— Дилехтыр сиңа бүген үк кирәкмәс тә әле ул, апаем. Сәяпеф — түш, Хәнифә баш бездә. Прсидәтел Хәнифәне әйтәм. Шул рөхсәт итмәсә, безнең Сарайлыда яфраклар да селкенми, сыңар эт тә өрми. Кантурга бар да иң элгәре шуны эзләп тап син. Кемгә фатирга төшәсе, кем хисабыннан, кайчан, кем кулыннан, ничә кадак он барып аласы, кемгә сәлам бирәсе, кайсысын урап үтәсе — боларның җәмгысен дә Хәнифә хәл итә. «Айт» дисә җәфрәйтер сымак үрә катасың, «два» дисә фыластунча шуыш. Бездә менә шундый тәртип, апакаем...

Зифа, очкылык тоткан шикелле дер калтырый-калтырый, идарәгә китте. «Һади чакырганда иярмичә сантый булдым бугай. Килмешәк дип, монда артка типмәсәләр ярый инде тагын».

«Чапаев исемендәге колхоз рәисе, БашЦИК әгъзасы Шәрипова Хәнифә Шәрип кызы» дигән язулы ишек аша узгач, Зифа ирләр мунчасына килеп кергән сыман коелды да төште. Әттәгенәсе! Яшел сукно тарттырылган зур өстәл артында чәчен «керпе» фасоны белән ирләрчә итеп алдырган хатын утыра. Шоп-шома күн итек кигән аякларын янда торган урындык өстенә сузып салган. Өстендә хәрби гимнастерка белән зәңгәр бостон итәк, билдә портупея. Аларына гына,

бәлки, әле бик шаккатмас идең. Мәгәр моның авызында ирләр тәмәкесе! Революция паровозы диярсең, пошкырта гына!

— Нинди йомыш китерде? Кем буласың?

Моның тавышы да боз ашап утырган ирләрнеке сыман, тамак ярып, дәһшәт бөркеп чыга. Бу хатынның сиңа «һайт» дип өсләп, әмер биреп торуы да артык, сыңар сүзен ишетүгә үк, шәм шикелле катып каласың.

Зифа ир-ат кулы ишек шакудан коелып төшкән тол хатыннардагы бер каударлык белән тиз-тиз җавап бирергә ашыкты:

— Нәгыймова булам мин. Районнан җибәрделәр. Яңа укытучы.

Үзенә калса, Зифа хәтәр кычкырып җавап тоткан иде, дулкынлану сәбәпледер инде, барча сүзләр гыжылдаган аваз гына булып ишетелгән.

— Нәрсә? Келәчә ат сымак ниләр ермаклыйсың?

Иреннәрен ялап, Зифа тагын бер мәртәбә тезәргә мәҗбүр булды:

— Нәгыймова булам мин. Яңа укытучы. Рус һәм татар телләреннән, тарихтан укытачакмын.

— О-һо, «укытачак»! — диде дә, председатель хатын урыныннан капылт сикереп торды. Җен алыштырган диярсең, аның йөзендәге нур-яктылык гел икенче иде. Базарга чыгарылган малны бәяләгән сыман, ул Зифаны тирәләп йөри дә башлады.

— Укытучы диген, яңа укытучы. Рус телен дә, тарихны да белә. Тәк, ярыйсы инде бу, бик ярыйсы. Сүле генә ничә көнгә җитәр?

Председатель хатын Зифаның нәкъ каршына килеп тукталды һәм сыңар бармагын пистолет сыман төбәп, кискен сорап куйды:

— Дөресен әйт, ничә көнгә килдең?

— Көнгә түгел инде, бөтенләйгә. Ну, алсагыз инде, билгеле, монда калдырсагыз.

Председатель, ниһаять, Зифа көтеп торган һөҗүменә күчте.

— Кайсы якныкы буласың? Өйдә кемнәрең бар? Артыңнан кияү егетләр эзләп килмәсләрме? Монда кияү табып бирсәк, аңа ни әйтерсең?..

Һәм тагын менә шуның ише йөз егерме сорау. Зифаның Рәбыйга «җиңги»ләргә барып авызы бер кат пешкән иде инде, бу юлы һичбер нәрсәне яшереп маташмыйча, учына салып тезде. Председатель дә бозлы кисмәк яки җансыз бүкән түгел, үзәгенә үтсәң, ул да балавызны башка меңәрләгән хатыннар шикелле оялып-тарсынып тормыйча сыга белә икән.

Аның беренче әмере борын, керфек тирәләре кипкәч ишетелде.

— Йортым алты почмаклы, клуб сымак иркен, фатирга миңа керәсең. Өстәл уртак, акчаң кирәк түгел. Иртәгә колхоздан сиңа ат бирермен, сеңелеңне апкил. Монда егетләр белән азып-тузып йөрисе булма. Идәнгә сузып салырмын да, ике ботыңны ике якка менә болай итеп аерырмын! Ике кабатлаш юк, борыныңа киртлә!

Зифа кузгалырга ымсына башлагач, Хәнифә карашын читкә яшерә-яшерә, бик оялып кына серен ачты:

— Өйдә минем ун яшьлек бер ташбаш бар. Бер генә фәннән дә «бишле» алганы юк, гел «икеле». Каеш белән ничә тапкыр тотып ярдым инде, базга яптым. Тискәре кәҗә шикелле, берни әйткән керми. Давай, син аны да буксирга алып карале, Зифа. Ичмаса, тамчы хәтле генә булса да рәт кермәсме? Кешеләрдән оят бит, слушай, бар авылдан оят...

Көн яктысын айлар-еллар буена күрмичә зинданда интеккән бичарага баз капкачын ачып бер чыра ташлаучы табылса, тоткын өчен ул изге җан җир йөзендәге иң шәфкатьле алиһә, патшабикә, ханияләр булып тоеладыр инде. Әле ярты ел чамасы элек кенә бер терәксез калган Зифа да Хәнифәне хәзер кулларына күтәреп йөртергә дә, аның аяк астына туфрак булып җәелергә дә әзер иде. Мәгариф бүлегендәге тозсыз ир-ат мондагы рәисне «солдафон да солдафон» дип мыскыл иткән булды. И-их, бөтен җәмгыять, бар кешелек Хәнифә шикелле «солдафоннар»дан торсын иде әле!..

Икенче көнне Зифа Вәзирәне Сарайлыга алып килеп куйды. Хәнифә ундүрт яшьлек Вәзирәне дә бик ошатты, ахры, аңа беренче кичтә үк кызгылт төстәге халат китереп бирде. Апа белән сеңел кече якка кереп урнаштылар. «Ашау байдан, үлем Ходайдан» дигәндәй, боларның җиһанда кайгылары беткән кебек булды. Әмма, әмма... киртәне сикереп чыкмый торып, «һоп!» дип кычкырырга ашыкма икән бит ул!

Бер-бер артлы ничәмә-ничә көннәр үтеп китте инде, ләкин Зифа йорт хуҗасын һаман аңлый алмый. Урамга чыктымы, Хәнифә эчкән солдат сыман кырыс, дорфа, усал. Эштән качып йөргән бер кешене дә аралап-яклап тормый, иң юньсез ир-атларга гына хас җыен шакшы сүзне тегеләрнең өстенә чыгара да өя. Хәнифәдән авылда бөтен халык дер калтырап тора. Берзаманны ул, колхоз басуыннан печән урлап кайтучы бер каракны тотып, аның чанасына ут төрткән, ди. Бу хакта бер оешмага да хәбәр итеп-фәлән маташмаган. Хикмәт түгел диген, хәзер ферма-басулардан байлык урлаучы юк. Ләкин Хәнифә үзе моңа тулысынча ышанып та бетми, күрәсең. Ул һәр кич саен, «махсус әзерләнеп»,

басу-ферма юлларын, тыкрык-чокырларны бер кат айкап чыга. Аның әнә шул «махсус әзерләнүләрен» күзәтеп утыру кызык.

Хәнифә ул чагында өстенә дүрт-биш размерга олырак китель киеп ала. Җилкә өсләренә, күкрәк тирәсенә чүпрәк-чапрак тутыргандай итә. Баш түбәсенә олы фуражка элеп куя, кулына камчы тота һәм ... ул һәр кич саен итек кунычына чыра телә торган пычак тыгып китә.

— Кара Сәет авылы ягында ике трактор эшли. Хуҗалары кәрәчинне сатып ятмый микән?

— Кичә Заманнар тыкрыгындагы бөтен әрем сабаклары кыяклы печәнгә батып беткән иде. Бүген «уф алла» сөйрәп йөрүче берәрсе очрамасмы?..

Юк, бернинди дә карак эләкми инде аңа. Ул кич саен үзен юату һәм авыл халкы алдында бер маскарад уйнау өчен генә урап кайта сыман. Башкаларга этлек эшли торган явыз булса, Сарайлыдагы һәрбер ихатада сыер-бозау мөгрәр, бакча артларында печән, утын кибәннәре өелеп торыр идемени?! Никадәрле гарьлек! Төркәй авылында мондый татулык һәм муллык бөтенләй дә юк бит!

Менә шушы тикшерү-уеннардан соң өй эченә кайтып керә дә Хәнифә яңа төрле концерт куя башлый. Бәләбәйдәге судья Шарапованың кыланмышлары моныкы янында мендәрдән сыпылып чыккан сыңар мамык кебек кенә булган икән.

Хәнифә, барча ишек-тәрәзләрне томалап, иң әүвәл бер кырлы стакан шәрабны әйләндереп куя. Аннары кулларына Вараксин гармунын эләктереп ала, дөньядагы иң данлыклы филармониянең иң атказанган җырчысыннан да кәттә кыйлана башлый, якын киләм димә.

Озата барма, иркәм, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам.
Синең серле зәңгәр күзләреңне
Башка күзләр белән алмашмам...

Гармунда шулхәтле дә оста итеп, тәмен белеп, бөтен җаны-тәне белән бирелеп уйный, аны тыңлап утырулар үзе үк мең-мең рәхәт. Җырлауның да рәтен-җаен белә. Урамда кызлар аулап йөргән бушбугазлар кебек тамак ертмый, көчәнми, куаламый, ә сүзне-моңны йөрәк түреннән чыгарып, сагышын-назын бергә кушып суза:

Син киткән юлларга быел да
Май ае чәчәкләр китерде,
Беләм мин, кайтмыйсың, шулай да,
Нигәдер кайтырсың шикелле...

Сагыш чакырып утыру берзаман йөрәгенә барып җитә, күрәсең. Хәнифә гармун күрегенә капланып, стансага туктаган паровоз шикелле пуф-пуф килә-килә өзгәләнә башлый.

— Э-эх! Никләр генә җибәрдем синең сымак чиле-пешле белән Зөбәрҗәт балакайны? Никләр генә әрәм иттең минем газиземне?..

Зифа тора-бара гына Хәнифә «солдафон»ның бар кайгы-хәсрәтен белеп алды. Ул Госсам атлы бик тә үшән, бик тә йомыкый бер ир белән яшәгән, моннан ике ел элек гаиләдә хуҗа тиешле шушы кеше, кызы Зөбәрҗәтне алып, утынга киткән икән. Начар ният белән булмаган бит инде, ләкин, үз бәхетсезлегенә, арбага төягән утын өстенә унике яшьлек кызын утыртып куйган, үзе шул үшәнлеге, пошмаслыгы белән олау артыннан гына ияреп кайткан. Тәкъдир түгел диген, тау битенә якынайгач кына, әллә каян бер поши килеп чыккан да атны өркеткән бит. Дулаган ат тау бите буенча аска томырылгач, арба авып киткән, Зөбәрҗәт балакай дистәләгән бүрәнә астында калган... Сабыйны җирләгәч, Хәнифә белән Госсам бер түбә астында яши алмаганнар. Госсам хәзер Уфада, зур гына оешмада хисапчы, ди. Атна саен диярлек хаты килеп тора. Әмма Хәнифәнең аңа җавап та язганы юк, Уфага барып чыккан чакта янына да керми. Җавабы бер: җыр-моң юлларында.

Озата барма, иркәм, озата барма...

Беренче стаканны каплап куйгач, Хәнифә юмарт һәм киң күңелле әле. Әллә нишләп Вәзирәне бик нык ошатты бит, аңа әле оек, әле ике-өч кенә кат киелгән итәк чыгарып бирә. Аннары Хәнифәнең өстәленнән тәм-томның да өзелеп торганы юк. Хәнифә, БашЦИК әгъзасы, ай саен диярлек Уфага барып йөри. Кайткан саен күсәгәсе-күсәгәсе белән колбасалар, шәһәр бөккәннәре, кәнфит, шикәр, балык... Хәнифәнең үзенең ризыкка исе китми, ул авыз суларын корытып «уфалар»ны сөйли.

— Ну, уфалар нотыкка чос та соң! Трибунаны айгыр сырты сымак күреп менеп атланалар, аркан белән сөйрәп төшереп булмый!

— Уфалар укымышлы, куда чурт! Күпме аларча сөйләшергә өйрәнмәкче булам, барып кына чыкмый бит, слушай...

Хәнифә кылтая, салпы ягына салам кыстырганны көтеп шулай сөйләнәдер инде. Укытучы кеше, агитатор булгач, Зифаның инде берничә җыелыш-киңәшмәләрдә катнашканы бар. Йөргән таш әнә шулай шомарадыр инде, Хәнифә дә җыелышларда, дәрәҗәсен саклап, иң азактан гына сүз алса да, һәр җөмләсен сөзеп, бик дәлилләп сөйләргә күптән өйрәнгән...

Беренче стаканнан соң беркадәр вакыт узгач, өстенә халат йә бишмәт кенә бөркәнеп, Хәнифә ишегалдындагы лапас, келәт йозакларын, капка келәләрен барлап керә. Аннары ишек-тәрәзәләрне өр-яңадан яба, икенче стаканны «хәл итәргә» вакыт килеп җитә. Хәнифәнең моңа чаклы гармунга текәлеп, бер почмакта тын гына утырган улы Мәхмүт әнисенең холык-гадәтләрен күптән ятлап өлгергән, ул ипләп кенә мич артындагы такта ятак өстенә кыяклый. Зифа да Вәзирәне җәһәт кенә кече бүлмәгә чыгарып яткыра. Ә ул арада Хәнифә инде, күзен-башын тондырып, өстәл төя башлый.

— Абзал булып Абзал да халык дошманы булгач, бу дөньяда кемнең генә иңенә таянасы?

— Абзал Мөхетдинычны да дошманга чыгардылар, моңа никәк ышаныплар булмый бит, әй, слушай. Абзал Таһиров безнең БашЦИК рәисе генә түгел, ә язучылар башлыгы да булып торды ласа. Аның «Кызыл әрмисләр» дигән китабын егылып укыган бар. Тагын «Ямәлкә тавы» дигәнен. Анысы Пугачау явы турында. Завутта интеккән татарлар турында. Бәрәч, соң ул халыкны алдап язганмыни? Шуңа дошманмыни?..

Ике-өч кич янәшә утырганнан соң, Зифа күп нәрсәне аңлагандай булды. Афзал Таһиров дигән бер язучы байтак еллар буе хөкүмәт җитәкчесе булып торган, Уфага Мәскәүдән Жданов килгәннән соң, партия секретаре Карачурин белән икесен бергә кулга алганнар, ди. Ике ел үткән, Таһиров хакында һични белүче юк, ә Хәнифә аны һаман сагынып сөйли.

Зифа әүвәл: «Әллә бу Хәнифә түтәй ул Таһиров белән кети-мети уйнап йөрде микән?» — дип тә шиккә калган иде. Аннары колхоз рәисенең барча кыланмышын, холкынтабигатен күңелендәге бизмәненә салгач, шик томаны таралгандай булды. Юк, Хәнифә үз янына ир-ат халкын якын җибәрә торган җилбәзәк йә өстерәлчек түгел. Мәгариф бүлегендәге теге бәндә колхоз рәисеннән «солдафон» дип кычкырып көлгән иде, күрәсең, дөреслек бардыр. Хәнифә көнтөн диярлек иярле ат өстендә. Авызында — тәмәке, кулда — камчы. Хәтта берәр якка барасы булып тарантас такканда да бер ир-атны якын җибәрми, атына хәтле үзе җигә бит ул! Лапасындагы сыеры өчен дә печәнне, урман эченә кереп, үзе чабып ала. Шулай булгач, бу ирдәүкә Хәнифә белән БашЦИК рәисе Таһиров арасында нинди «кети-мети» туа алсын?..

Менә шулай итеп уйный-уйный, җырлый-җырлый җидесигез ай буе бер түбә астында, бер гаилә булып яшәгәннәр иде. Тәкъдир, явыз, монысына да кансыз чик сызыгын сызып

куйган икән. Иртәгә Беренче май дигән көнне, төн уртасында, Хәнифәне дә килеп «җыйнадылар». Ни галәмәт, аның белән бергә унбер яшьлек Мәхмүт тә гаип булды.

## 3

Зифа белән Вәзирә Хөмәйрә дигән ирсез хатын йортына күчеп яши башладылар. Ни хикмәттер, Зифа үзе фатир эзләп йөреп интекмәде. Беркөн бишенче класстагы рус теле дәресеннән чыгып килә иде, ишек төбендә ирләр кебек озын, зур гәүдәле хатын көтеп тора. Бик тә якын туганын күргән сыман, төче теллелекне дә онытмыйча, үзе сүз башлады:

— Хәнифә урынына Җәкәү авылыннан бер урысны китерәләр, диләр. Сезгә калхуз фатирында яшәп яту барыбер насыйп булмас. Килгәнеңнән бирле сынап, карап тордык, син азып-тузып йөрүләргә һәвәс, әрсез кеше түгел. Ходайга мең шөкер, йортым иркен, җылы. Әйдә, барып кара. Күңелең ята икән, миндә торып калырсың. Бергә-бергә сиңа да, миңа да күңеллерәк булыр...

Чыннан да, май урталарында бергә-бергә, тату гына яшәп киттеләр. Хуҗабикә Хөмәйрәнең бер урамда, капма-каршы йортта торучы Хөбәйбә исемле игезәк туганы бар икән. Хөмәйрә иртә-кичен савым фермасына эшкә йөри, көндезләрен туганы Хөбәйбә ихатасында казынып үткәрә. Зифаның үз кайгысы. Вәзирә быел җиденче классны «ерып чыга», аның таныклыгына юньлерәк билгеләр төшертергә кирәк.

Сак белән Сок шикелле аерылып киткән Һадидан беренче айларда хатлар даими килеп торды. Узган ел ул Субаш дигән авылда җидееллык мәктәп директоры булып хезмәт юлын саллы гына башлап җибәргән иде. Ике айданмы соң, әүвәл аны Саратовтагы хәрби курсларга алып киттеләр, аннан Ленинград ягына. Ул төбәктә финнар белән сугыш башлануын Зифа газета битләреннән дә укып белә, шуңа күрә Һади өчен хафаланган иде. Кайгы-михнәт болар янына чебен көтүе сыман иялəнгән, ахры, февраль аеннан бирле Һадидан бер хәбәр юк.

Җәй урталарында гына, ниһаять, хат килде. Выборг дигән бер шәһәр янындагы госпитальдә яткан, җитмәсә, ниндидер «тикшерү, карантиннар» белән җәфалыйлар икән. Ул «карантиннарында» татарча укый-яза белүчеләр юктыр инде, үзенең хәлен аермачык язган.

*«Февраль ахырында чолганышка эләктек. Диңгезчеләр генә килеп коткардылар. Мондагы кырык градуслы суыкка итек белән түзеп буламыни? Әллә ничаклы солдатларның аякларын, гангрена дип, йә тезеннән, йә бот төбеннән кисеп*

*ташладылар. Мин аякны өстәге күлмәккә хәтле салып төргән идем, барыбер өшеткәнмен. Сул аяктагы өч бармакны кисеп ыргыттылар. Элек тә мин дип егылып китми идең, хәзер гарип кешене бөтенләй дә яратмассың инде...»*

Шулай да хат азагында батырайган Һади.

«Башка җиргә күченгән булып, миннән эз югалтма. Советлар Союзыннан чыгып кача алмассың әле, барыбер тапмый калмам!..»

Зифа әле көлде, әле өзгәләнде. Өч бармак кистеләр дип, Һади ничек гарип калсын инде? Кешене аяк бармакларын санап яраталармыни? Иң гаҗәбе шул: Һади һич югы хат аша да өйләнешү-кавышу хакында бер киная ташламый, вәгъдә бирми, ә Зифага хуҗа булмакчы бит. Җиде диңгез, кырык дәрья аръягындагы Һади-сабакташны нинди киләчәккә, нинәрсәгә өметләнеп көтеп ятмак кирәк? Хәер, монда, Сарайлыда да, Зифа артыннан тагылып йөрүче егетләр юк әле...

Ике-өч атнадан соң Зифа кулына тагын бер сәер хат китереп тоттырдылар. Монысы Чиләбедән, мәрхүмә әниләре Гөлтуташның элек Уфада яшәп яткан бертуган энекәше Бикмөхәммәт язган. «Монда качканыма унсигез ай, трактор заводына урнаштым, акча көрим»,— дигән.— «Җан җылытыр өчен бер ягы шәп: монда татарлар аз, берсен-берсе сатып ятучы юк. Ике татар мәктәбе ачканнар, мөгаллимнәр җитми. Уйга керсәң, давай, күченеп кил...»

Зифа әүвәл утка-суга төште. Бикми агай йорт та сатып алган, аның янына барып бер түбә астында, ныклы терәк тоеп яшәү шәп инде ул. Чиләбе зур шәһәр, мөгаен, анда Вәзирәгә эш табу да җиңел булыр иде. Ләкин... ләкин... Әйтсәң — сүз, төртсәң — күз, Бикми-Бикмөхәммәт агай өчен Зифа белән Вәзирә Чиләбедә дә артык кашык, сансыз кашык бит. Бүген йөз белән сиңа кешеләр, иртәгә арт белән. Шулай була калса, чит-ят җирдә, урыс арасында, кем янына барып борын төртерсең соң? Ә монда, ичмаса, үз җиребез, үзебезнең халык. Чат итмәсәләр дә, ят итмәсләр, бәлки. Аннары... аннары Һадиның да әллә ни уйлавы бар. Түз син, Зифа, качак сыман сансыз булып йөрмә...

Шул рәвешчә уйлады-үлчәде дә, Зифа икенче елын да Сарайлы авылында торып калды. Төп кайгысы үзе түгел, гел Вәзирә иде. Ходайның рәхмәте, мәгариф бүлегендә Сәяповка Вәзирәне ярты штатка лаборант итеп алырга рөхсәт биргәннәр. Яманмы-яхшымы, апалы-сеңелле көе икесе дә Сарайлы мәктәбендә эшләп йөргән була.

Октябрь бәйрәме якынлаша төшкәч, Зифаны күрше авылларга йөгертә башладылар.

— Син тарих укытучысы, иптәш Нәгыймова. Бүләк бе-

лән Карасуга барып Сталин Конституциясе турында лекцияләр уку синең өстә.

Карасу белән Буләк зур авыллар түгел, аларда башлангыч мәктәпләр генә эшләп килә, халыкның аерым фән укытучыларын күргәне юк. Алардагы лекцияләр язгы ерганаклар шикелле келтерәп кенә, шома үтеп китте. Чыбыксыз телефон бу хакта Сәяповка бик тиз китереп ирештергән, ахры. Башка елларда Сарайлыда гел үзе укыган лекциясен бу юлы ул яшь укытучыга бирде.

Алтынчы ноябрь кичендә авыл клубы халык белән тулды. Бәйрәм кичәсен Зифаның бер сәгатьлек лекциясе ачты. Аннан ике сәгатьлек концерт. Соңыннан клуб уртасын эскәмия белән урындыклардан бушаттылар да төрле бию, уен-җырлар башлап җибәрделәр. Зифа лекция дә укыгач, өстәвенә, әле концертта да Вәзирәне ияртеп ике җыр җырлагач, игътибардан бик арыган иде. Уен-җыр вакытында кешеләр артынарак качып, күбрәк читтә торды.

Берзаманны, каршысына килеп, әзмәвердәй гәүдәле чит-ят моряк аны биергә чакыра башлагач кына, капылт айныды ул. Йа Ходаем! Түгәрәк читенә утырган гармунчы тырышып-тырышып «Яблочко»ны сибә. Зифаның каршында ялт-йолт килеп торган погоннары, каешлары белән чибәр моряк бии. Каян килеп, кайчан клубта пәйда булган да, Зифа аны ничек күрмәгән соң?!

Әмма моряк бии. Тәҗрибә шәп моның, куллары белән әле тез өсләрен, әле ботинка яңакларын чәбәкли-чәбәкли, теттерә генә, каһәрең! Күзләре дә, битләре дә уттай янып тора. Иреннәре мәрҗәндәй ак тешләрне ачып, әле җәелеп китә, әле борын астына килеп бөрешә дә юри үрти, мәсхәрәли сыман. «Дөньяда менә шундый кәттә егетләр дә бар ул, кызый. Рәтең булса, әйдә, бер сынашып кара!»

«Һей, син генә Алланың кашка тәкәсе булып кыйланмәле! Без Бәләбәйдәге хәрбиләр клубына тиккә генә барып йөргәнмени?!»

Зифа бик озак ялындырып тормады, сикерде дә чыкты. Тезгә чүгә-чүгә, кырын баса-баса байтак биеделәр. Берзаманны ыспай морякның да рәте бетте бугай. Кулын чабып көйне туктатты да ул Зифаны янә иптәшләре янына озатып куйды.

— Молодцом, чибәркәй! Тихоокеанский дембельнең борынына шәп чиерттегез!..

Сорашып-белешеп торасы калмады. Яңа уен-җырлар башланугa, яндагы яшь кызларның һәммәсе Зифаның колагына иелеп безелдәде:

— Безнең авыл егете Хәйбери бу. Бер атналык отпуска-

га кайткан. Киткәненә биш ел тула инде, озакламый бөтенләйгә кайта.

— Ну, морякны телсез иттең, кызый! Хәзер тигәнәк шикелле ияртә бу сиңа...

Юк, Хәйбери тигәнәк шикелле ияреп маташмады. Яшьләр әле җыр-биюдән туктарга да уйламыйлар иде, Хәйбери, зал, кичә уртасы дип тормыйча, Зифаның каршына ук килеп басты.

— Бывалый морякка кызлар куып йөрү непристойно сыман. Сезне подручком алып, досрочно отшвартоваться итәргә ярыйдыр бит, сылу?

Боргаланып, ялындырып торырдай алиһәмени соң ул? Зифа Хәйберигә иярде дә чыкты. Кешеләр алдында тәвискүркә сыман кәпрәйсә дә, ялгыз калгач, Хәйбери әллә кем түгел, гап-гади бер авыл егете икән. Сорау-фәлән көттереп тормыйча, күңелендәген үзе ачып салды.

Хәйберинең әти-әнисе белән сеңелләре утыз өченче елгы ачлык вакытында ниндидер агулы корт ашап кырылганнар. Әтисе бик җиткелекле итеп торгызган яңа, олы йортта әби-баба белән Хәйбери генә яшәп калган. Утыз биштә флотка алып киткәч, әбисе белән бабасы да дөнья куйган инде. Хәзер хуҗалыкны Яхья атлы абыйсы белән апалары гына карап тора икән. Кайтса, өйләнмәкче. «Миңа мал караучы түгел, ә укымышлы, чибәр кыз кирәк» ди. Сайлануның сәбәбен дә бик нигезләп сөйли. Хәйбери сәүдә флотында хезмәт итә икән. Японияне, Таиланд, Кытай, Вьетнам, Кореяне, тагын әллә нинди илләрне барып күргән. «Миңа сагыз чәйни торган хатын кирәк түгел, минем хатын подручком алып йөри торган булсын»,— дип ул максатын бик өздереп әйтә.

Хәйбери сөйләшкәндә Зифаның йөрәген чеметердәй бер сүз ычкындырды.

— Миңа синең хакта «Зифа ялгыз түгел, кучеры бар» диләр. Ә мин төкермим дә. Йортым иркен, Сарайлының клубы бер як читтә торсын. Чөкердәшеп яшәп китү язса, синең сеңел генә сыяр әле...

Зифаны нәкъ Бәләбәйдәге Рәбыйга кебегрәк корт чаккандай булды. «Әһ-һә! — дип күңеленнән генә тагын бер сыкрады.— Вәзирә «кучер» икән. Мин үз-үземә хуҗа кеше түгел, Вәзирә — өстәмә йөк. «Кияүгә чыкмыйсыңмы, бергә торабызмы?» — дип әйтеп маташу юк. Шундук башка күсәк. «Минем йортым бик шәп, әмма сеңелеңне аткар». Акылы кот монының. Менә сиңа Корея, Японияләрне барып күргән моряк!..»

Хәйбери авылда өч кич кенә торды. Әлбәттә инде, Зифа белән көн дә очраштылар, йөз кат үбештеләр. Моряк — шо-

марган таш, хәйлә табып, Зифаны әллә ничә тапкыр кулларына алды.

— Мондый салкында хуҗасыз эт сымак урамда көрешкәнче, әйдә, өйгә керик. Мин сине авыл буйлап менә шулай кулларыма күтәреп йөртергә дә риза.

Эх! «Кеше өстендә йөрмә, минем өемдә кал, кайткач бергә яши башларбыз, өйләнешербез» дия белмәде бит. Зифаның исә тәүге кичтә үк күңеле каткан иде. Алданмады, бирешмәде Зифа. Хәйбери соңгы кичтә, инде хушлаша башлагач кына, ашыгып-ашыгып әйтте:

— Күңелемә бик нытытып кердең, онытырлык түгел. Тормышка чыгасы булма, көченеп китмә. Башка берәүгә кияүгә чыгасың икән, өч еллык хатын булсаң да, аерып алачакмын, бик белеп тор...

## 4

Нинди көз булгандыр инде бу, атна-ун көн үтүгә, Сарайлыга өр-яңа бер хәрби кайтып төште. Мәктәп эчендә кунатөнә ятып, Зифа аның турында ишетмәгән иде. Беркөн кич белән өйгә кайтып керсә, түрдәге өстәл артында, иң олы кунак булып, чит-ят ир утыра.

Ул, Зифа күренүгә үк, аягүрә басты. Башы түшәмгә тия язып тора, моның буе ике метр бардыр. Гәүдәгә, нәсел үгезе шикелле, бик таза, нык. Өстендә куе яшькелт төстәге гимнастерка, билдә каеш, погоннарда сап-сары «Т» хәрефе. Чәчен бик кыска итеп алдырган, маңгай өсте керпе энәләре кебек тырпаешып тора. Кашлары кап-кара булса да, күзләре зәңгәрсу, ахрысы. Зифа һәммәсен дә бәйнә-бәйнә карап өлгермәде, хәрби кеше, гәүдәсе белән бар җиһанны каплап, аның каршысына килеп басты.

— Сезнең турыда мин Хөмәйрә белән Хөбәйбә апалар язган хатлар аша берникадәр беләм бугай инде. Әйдә, таныш булыйк. Мин — Үрәзмәтов Ислам, пограничник.

Зифа көтелмәгән кунакның күзләренә күтәрелеп карый алмады, коелып төште. Менә сиңа мә! Хөмәйрә хуҗабикә аның үзенә бер кавым сүз әйтмәгән көе Зифа хакында чит-ят кешегә хәбәр юллап яткан. Димәк, хуҗабикә барысын да алдан ук үлчәп-бизмәнләп, әүвәл Зифаны үз йортына керткән, аннары, ярәшелгән кыз хәленә куеп, аны саклап яткан була түгелме соң?

Дөрес инде анысы, Хөмәйрә белән Хөбәйбә читтәге энекәшләре турында сирәк-мирәк әйткәләп, искә алып тордылар торуын.

— Безнең Ислам — «старшина» дигән чиндәге әфисәр.

Ул хөкүмәткә тиеш өч елын биреп бетергәч тә, гырницада калды. Җәһәннәм аръягындагы Кәмчәтке дигән җирне япуннардан саклый.

Хәзер инде Ислам Үрәзмәтов үзе турында үзе хәрбиләрчә кыска сөйләп бирде. Ул, чыннан да, чик буе заставасында старшина икән. Казармалар, аерым офицер йортлары урнашкан төп яшәү урыны Камчаткада, ә дозорга Курил утрауларының иң якындагысы — Шумшу каршындагы Лопатка борынына барып йөрибез, ди. Шумшу — японнар кулында, Лопатка борыны советныкы, ике чикне унике-унөч чакрым озынлыгындагы бугаз гына аерып тора икән.

Зифа аның ни өчен «җәһәннәм аръягындагы» Камчаткада яшәп калуы турында сорашыр дип гөманлады бугай. Ислам анысын да артык җәелеп тормыйча шундук ачып салды:

— Монда мине бәйләп тотардай нигез ташым юк бит. Әти белән әни, абыйларым гражданнар сугышы вакытында кырылып беттеләр. Менә, Хөмәйрә апа белән Хөбәйбә апа гына исән калган иде, алар белән дә бергә үсәргә насыйп булмады. Мин әүвәле, беспризорник булып, урамнарда йөрдем. Аннары ятимнәр йортына сөйрәп апкиттеләр. Шуннан әрмиягә. Старшина кеше, командир бит. Бәләкәй генә булса да барыбер тигез җирдә түмгәк. Нишләп инде мин, эт типкесе булып йөрергә дип, монда кайтып керим?..

Зифа «әһә, эре бәрәңге ашаган бу», дип бәя биреп бетерергә өлгермәде, ишектә Хөбәйбә апа белән аның ире Мөстәкыйм күренде. Болар инде Ислам белән күрешкәннәр икән, хәзер булары бәреп торган бер чүлмәк аш күтәреп кергәннәр. Хөмәйрә апа, вакыт сузып тормыйча, бәлеш чыгарып куйды. Ислам да «җәһәннәм аръягыннан» хәзерлексез генә кайтмаган. Ашъяулык өстенә беләк буе берничә кызыл балык, бик кыйммәтле коньяк, кәгазьләренә әллә Кытай, әллә Корея хәрефләре сырланган шәраб шешәләре, өч-дүрт төрле консерва тезелеп китте. Ислам — ике-өч ел буе кайтмый тилмерткән бик кадерле кунак бит, аңа урын түрдән. Зифаны, кыстый-кыстый, нәкъ аның каршына китереп утырттылар. Стакан-чынаяклар чыңлый башлады, аш состылар. Зифа өстәлне каплаган сыйларның берсеннән икенчесенә күз йөгертә-йөгертә Вәзирәне сүкте. «Кайда йөри инде бу нәгаләт? Кич җиттеме, клубка чыга да югала, каян килгән гадәт?»

Беренче сүзне (ир кеше бит!), әлбәттә инде, Мөстәкыйм абзый башлап киткән булды:

— Безгә бүген... бүген безгә... Тихаакианный флотның, ягъни мәсәлән, Кәмчәткенең чикләрен саклаучы туганыбыз

кайтты. Уен-муен түгел, чик саклаучы пограничник көн дә кайтып тормый... Тагы да килеп, җитмәсә әле ул безнең баеуай старшина. Афисир ул, ягъни мәсәлән, и без аның белән закунны горурланабыз. Афисирский старшиналар авыл саен, капка саен чыкмый. Афисирский старшина эзвәнҗәсенә ирешкән кешеләр бик тә сирәк. И шуның өчен Ислам туганыбыз бик тә якын безгә. И шуның өчен тотып куйыйк без, туганнар, менәтерәк...

Зифа аяк терәп, үҗәтләнеп каршы торып маташкан иде дә, Хөмәйрә белән Хөбәйбә апалар, ике яклап кыстап, барыбер сындырдылар. Зифа ярты чынаяк кызыл шәрабны сөзәсөзә эчәргә мәҗбүр булды. Кул-аяклар буйлап җиңелчә кайнарлык йөгерде, рәхәт булып китте. Каударлана-каударлана ашка тотындылар. Зифа каш астыннан гына гел игътибар итеп утырды: Ислам кыстаганны көтми, салган бер стаканны җиңел генә бушатып куя икән. Ләкин үзе исерми, йөзендә-күзләрендә хәмернең эзе дә юк.

Байтак кына ризыкны урып куйгач, Мөстәкыйм абзый кулына гармун алды. Әлләниләр сырлап маташмады, авыл көен сузды.

Һаваларда очкан аккош кебек
Ярсый-ярсый канат кагынып шул,
Туган илем, кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

Җырга Хөмәйрә белән Хөбәйбә апалар кушылган булды, әмма куыз ыргыткан шикелле тоелмады. Бер-ике тапкыр Ислам да ияреп карады, тик ул сүзләр белми, җырлавы да шул «ып-ып» дип утыруга гына калган иде. Ниһаять, мондый газаплану аны туйдырды, күрәсең. Ул көй-фәлән дә көтеп тормыйча, үзе җыр сузып җибәрде:

Тучи над городом гуляют,
В воздухе пахнет грозой,
Из далекой морской заставы
Парень идет молодой.

Зифа игътибар итте: Ислам шактый калын, тупас тавыш белән җырласа да, ул моңның эченә кереп, һәрбер сүзне үзәгенә алып җырлый. Зифага ул инде күңеле белән әллә кая, Ерак Көнчыгышка киткәндер кебек тоела иде, ай-һай, чик сакчысы янда гына һәм һич тә онытылмаган икән бит.

Давай, пожмем друг-другу руки,
На дальний путь, на долгие года.

Менә шушы сүзләргә Зифа да кушылып киткән иде, Ислам аның кулларын үзенең учларына алгач кына айны-

гандай булды. Абау ла! Ислам керфекләре арасыннан карашын төбәгән дә, көйдерә генә бит. Зифа үзен без өстенә утыргандай тойды. Чукынып кына китсен, әллә нинди — сыта, изә, үзенә берсүзсез буйсындыра торган ихтыяр бар монда!

Берзаманны Хөбәйбә апа белән Мөстәкыйм абзый урыннарыннан куба башладылар. Мондый хәл, гадәтенчә, һич тә көтмәгәндә кузгала һәм кунак кешеләр гел бер чама кыйланалар инде.

— Әстәгыфирулла, ярты төн уртасы җиткән бит инде! Ниемә дип аракы шешәсенә карап чукынып утырасың?!

Шул рәвешчә әүвәл Хөбәйбә апа Мөстәкыйм абзыйны табаларга тотынган иде.

— Бәрәч, бәрәч! Чынлап та унике тулган бит, нишләп утырмага килгән кодагый сымак җебедем соң әле? — диядия Мөстәкыйм абзый да җиз кыңгыраулы гармунын кочагына алды.

Болар гына чыгып югалган иде, Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкиятендәге шикелле, хәзер инде Хөмәйрә тышка кыякларга әзерләнде.

— Безнең Вәзирә кайтмады бит әле. Тагын теге Түбән очтагы Әхкыям малае белән капка баганасын терәтеп тормыймы икән? Карап керим әле...

Өй эчендә ялгызлары гына утырып калгач, Ислам пионер малайлар сыман нәзакәтләнеп, назланып маташмады. Ул әүвәл Зифаны күз чалымына да китереп тормыйча өстендәге гимнастеркасын, аякларындагы итеген салып атты. Аягүрә торган килеш кенә өстәлнең читендәге ике чынаякка коньяк койды. Ике чынаякны ике кулына тоткан көе Зифаның нәкъ каршына килеп басты. Ислам пәһлеваннан бер дә кайтыш түгел, гәүдәсе белән бар җиһанны каплап баскан иде. Аның каршында үзен мескен үрдәк баласы гына итеп тоясы килмичә, Зифа да ирексездән урыныннан купты. Курка-курка гына кунак егетнең йөзенә караш ташлап алды. Йөзе тыныч күренсә дә, бик нык уйчан, җитди иде Ислам.

— Эчәсеңме? — дип, керешсез-нисез рәвештә, тик бер генә сорау бирде ул. Зифаның балавыздан ясалган сын шикелле хәрәкәтсез торуын күргәч тә, бөтенләй аптырамады.

— Молодец, эчкән хатыннарны җенем сөйми. Ә мин эчәм.

Ислам үзенә тиешле чынаякны голт кына итеп әйләндереп куйды да, икенче мизгелдә ялт иттереп Зифаны кочагына суырып алды һәм, чәчәк таҗына кунган бал кортына охшап, озак итеп, тәмле итеп кызның иреннәреннән үбеп торды. Аерылган минутта ул ныклы карарга килгән иде инде.

— Ә хәзер утыр, Зифа. Синең белән җитди итеп сөйләшәсем килә.

Зифа аның күзләреннән карашын алалмады. Юк, көчле иде Исламдагы ихтыяр, аңа буйсынмыйча мөмкин түгел иде. Зифа яндагы урындык өстенә сүзсез-карышусыз чүгәргә мәҗбүр булды. Ислам аның каршына килеп урнашты, кулына һичбер төрле ирек куймыйча сүз башлады:

— Миңа егерме җиде тула инде, Зифа. Аңлыйсыңдыр, адәм рәтле кешегә өйләнергә вакыт. Мин дә яшермим, аннары инде үзең дә аңлагансыңдыр: Хөмәйрә апа белән Хөбәйбә апалар сине миңа булачак кәләшем урынына саклап тотты. Шулар мине «давай, өйлән» дип, тугыз мең чакрым арадан чакырып кайтардылар. Алар язган буенча да күңелемә күптән кергән идең. Инде үзем күрдем, без бер-беребезгә пар килгәнбез, Зифа. Миңа инде күпме буйдак булып интегергә була? Әйдә, кавышыйк без.

Зифа әллә ни көттереп маташмады.

— Минем йөргән егетем бар бит, Ислам. Аның якныкылар инде туйга әзерләнә бугай. Сарайлыдагы бик күп кеше хәзер шулай сөйли.

Ислам каушамады, хәтта, киресенчә, йөзе яктырыбрак та китте бугай әле.

— Рәхмәт, алдамадың, дөресен үзең әйттең. Димәк, эчкерсез син. Димәк, саф күңелле кыз, тагын бер кат рәхмәт. Әйе, тиздән Хәйбери кайтачагы турында да, Яхъя абыйларның туйга әзерләнеп йөрүләре турында да сөйләделәр миңа. Хәтта бертуктаусыз хатлар яудырып торучы Һади хакында да танышмын мин. Ләкин карарым нык, кире чигәрлек түгел. Минеке бул, Зифа.

— Алар да бит миннән көтәргә вәгъдә алып киттеләр,— диде Зифа янә кыюсыз гына, сузып.— Көтмәгәндә берәрсе кайтып төшсә? Хәйбери белән икегез белепме-белеп таза. Ялгыш, эләгешсәгез?

— Ха-ха-ха! — дип, Ислам әүвәл туарылып көлде.— Шул гынамы кайгың? Авылдаш ике егет бер-берсе белән уртак тел тапмыйча калмас. Аннары... аннары егерме җиде ел көткән бәхетемне мин чит-ят кулына калдырам димени?

Ислам әнә шундый сәер генә бер җөмлә әйтеп ташлады да, икенче минутта ук Зифаны көчле кулларына күтәреп алды. Зифа әле һаман берни аңламый, аңа Ислам сөйләшү тәэсиреннән очына кебегрәк кенә булып күренә иде. Әмма Ислам атлап барышлый ук утны сүндерде дә, Зифаны түрдәге киң караватт өстенә китереп салды.

— Ислам, тукта, нишлисең? Минем көтәргә дип вәгъдә биргән егетләрем бар бит,— дигән сүзләрнең һәммәсе дә ка-

раңгылык эчендә сүнеп калды. Ислам аюдай иләмсез гәүдәсе белән каплап яткан, Зифаның исә аны үз өстеннән әйләндереп төшерердәй куәте юк иде...

Зифа тынычлана алмый озак өзгәләнде. Ни галәмәт, Ислам аны юатырга ымсынып та карамады. Инде байтак вакыттан соң гына Зифа тынычлана төште һәм акылына килде сыман.

— Ичмасам, утны яндырыр идең,— диде ул сулык-сулык итеп сулыш алуыннан туктап.— Хөмәйрә апаның кайтып керүе бар бит.

— Менә анысы ярамый,— дип, тәүге тапкыр телгә килде Ислам, ләкин бу юлы да сүзләре Зифа өчен гаҗәп сәер иде.— Ут яндырырга ярамый безгә, Зифа. Ут яндырсак, Хөмәйрә апа белән Хөбәйбә апа момент килеп керә. Шулай сөйләштек без.

Зифаның тавышына шундук курку хисе бәреп чыкты.

— Нәрсә сөйләштегез?

— Шулай килештек. Әгәр мин ут яндырам икән, димәк... синең эшең күптән беткән була:

— Берни аңламадым,— диде дә Зифа урыныннан куба ук төште.

— Ну, әгәр синең эшең миңа хәтле беткән була икән, ул вакытта мин ут яндырам.

Зифа үз колакларына үзе ышанмыйча торды, әмма тавышына зәһәрлек тә өстәлгәндәй булды.

— Әһ-һә, сез әле шулай апаларыгыз белән сүз беркетеп мине браковать итәргә җыендыгызмыни? Ә кем мине эштән чыгарырга тиеш иде соң сиңа кадәр?

— Хәйбериме анда, Һадимы — аны кемнәр белсен?

— Аһ, оятсыз! — диде дә Зифа янә яшьләренә буылып Исламның күкрәген, муенын, беләкләрен йодрыклап төя башлады. Шул чагында гына Ислам аны күкрәгенә сосып алды да, бу юлы инде җылы итеп дәште:

— Өметне алдамадың, рәхмәт сиңа, Зифа. Болай булгач, без синең белән хәзер мәңге бергә инде...

Тәрәзә артында таң сызыла башлагач, хәрби киемнәрен киеп алган Ислам хәрбиләрчә төгәл күрсәтмәләр тезде:

— Безнең арада ни булганын һичкемгә ычкындырма, хәтта апаларга да. Мин Яхъя абыйларның туйга әзерләнеп йөргәннәрен беләм. Алар хәтта бер сарыкны симертергә куйганнар, ди. Димәк, Хәйберинең бүген-иртәгә кайтып төшүе бар. Мәгәр мин бер генә минут вакытны да бушка уздырмыйм. Әүвәл Уфага барып Владивостокка хәтле билетларга бронь бирәм. Аннары райүзәккә кереп завроно белән дә, милиция начальнигы белән дә сөйләшеп чыгармын. Һәм соңгы чиратта гына авыл советында язылышу мәсьәләсе. Шушы-

ларның җәмгысына өч көн. Өч көннән соң штык шикелле ялтырап кайтып төшәм. Борыныңны салындырып йөрмә, тыныч кына көт.

Исламны капка төбенә хәтле озата чыккач кына, анда да һаман кыюсыз рәвештә генә Зифа яңа йомыш такты.

— Вәзирә дә бар бит әле, Ислам. Аны монда ташлап калдырып булмый ласа. Уфада аңа яраклы берәр нинди эш белешеп карамассыңмы икән?

Ислам көлде генә.

— Есть, матурым. Мәгәр син белгәнне мин күптән кип-тереп элгән кеше бит инде. Ягъни мәсәлән, Вәзирә турында да, әлбәттә, уйладым мин. Кайгырма, аны монда ташлап калдырыш юк. Үзем Владивостокка китми торсам-торам, мәгәр балдызны барыбер дә урнаштырам инде.

...Ислам егет икән. Ул, чыннан да, дүртенче көн дигәндә, кире кайтып керде. Әмма ялгыз түгел. Үзе пар атлы тарантаска утырган, янында үзеннән гәүдәгә чак кайтыш кучеры бар. Өстәвенә, болар янында ияр өстенә менеп алган тагын ике җайдак. Хөмәйрә белән Хөбәйбә апаларының, Зифа белән Вәзирәнең аптырашып торуын күргәч, Ислам үзе аңлатмалар бирде:

— Сез бернәрсә дә күрми-белмичә ятасыз, ә мин кичә кич белән тозакка каба яздым. Сарайлының әнә теге Бүләккә китә торган ягында Яхъя абыйның ике малае күсәк белән көтеп торалар бит. Аларның Зифаны бушлай гына биреп җибәрергә бер дә исәбе юк. Менә шуңа Боергандагы Гыйлай абыйларга кереп, подкрепление белән кире борылып кайттым. Хәзер инде ул кадәр көч белән бер взводка каршы торып була. Яхъя абый бөтен Сарайлыны күтәргәнче, давай, немедленно юлга җыеныгыз, Зифа...

Ярты сәгатьтән соң, гомер буе белешкән туганнар шикелле, Зифа белән Хөмәйрә, Хөбәйбә апалар елый-елый гына аерылыштылар. Авыл урамыннан бик җайлы чыгып киткәннәр иде дә, Болан Мөгезе дигән чытырманлык янында күсәк тоткан ике егет кенә түгел, атка менгән Яхъя абый үзе һәм тагын ике туганы көтеп тора икән. Ислам олавы алар белән тигезләшкәч, күсәкле ике яшь егет бик кыбырсый башлаган иде, әмма ияреңдә таш сын сыман утырган Яхъя абзый бөтенләй кымшанмады. Бу минутта ул чит-ятка карамый, күзләре гел Зифа белән Вәзирәдә иде. Апалы-сеңелле ятимәләр карашында нидер тойды, күрәсең, ул кулындагы камчысын ипләп кенә читкә атып бәрде. Соңгы сүзләрен дә ул, карашын күтәрмичә, читкә карап дәште:

— Э-э-эх! Кеше каргышлары төшмәсә генә ярар иде сиңа, балакаем!

## 5

Каф тау артына сәяхәт кылулар — ул хыялларда гына җиңел икән. Яшьләр өчен Башкортстаннан чыгып ычкыну да олы газап булды.

Ислам: «Новосибирск каласыннан Көнчыгышка ары үтәр өчен махсус пропуск кирәк»,— дип, башта ук әйткән иде. Әлбәттә инде, моның өчен, иң әүвәл, ЗАГСта язылышырга һәм хезмәт урыныңнан чыгарга кирәк икән. Әкәмәт бу дөнья! Язылышу белән эштән чыгу дигәнең ярты көн эчендә хәл иттеләр. Ут-су кичү дигән газаплары менә шуннан соң башланды да инде.

Ислам райүзәктә милиция башлыгы янына бик эре, тәкәллефсез генә кыйланып кереп киткән иде. Ул Камчатка хәтле Камчаткада чик буен саклаучы бик кыйммәтле белгеч, Уфа белән Камчатка арасында да бер айлык юл үтәсе бар, хәзер аның хәленә керәләр дә пропускларны тоткарлыксыз-нисез чыгарып салалар, имеш. Табылган Алланың кашка тәкәсе, тот капчыгың!

— Нәчәлник түгел, бер идиот утыра анда. «Дәлни Бастукка прапускы алыр өчен зәяфкене ун көн алдан биреп куярга кирәк. Мин закун бозалмыйм, бездә тәртип шундый» дип, гел бер чүбекне чәйни дә чәйни инде. Чыдамасаң, бәр дә үтер шушы хәреф кортын,— дип, Ислам милиция бүлегеннән сөмсер коеп чыкты.

Ишек ачылган-ябылган вакытларда Зифа үзе дә шәйләп калган иде. Өтек кенә гәүдәле, йөзе карага каткан, төссез-нурсыз бәндә иде бу башлык. Буе кәтәнәй кешенең эче мәңге ваклык, хөсетлек, мәкер белән тулы була. Бу да шулай җелекләренә төшеп җәфалар инде аларны.

Ләкин Исламның чигенергә исәбе юк икән. Төштән соң ул райүзәк кибетләреннән иң шәп кәгазьле шәраб, коньяк шешәләрен, иң кыйммәтле балык консервларын җыеп чыкты да, башлык кеше эштән бушануга, эзенә бастырып, өенә үк китте. Бу юлы, кире әйләнеп чыкканда, моның да мыек һәм карашлар майлы иде инде.

— Коры кашык авыз ерта, дип, юкка гына әйтәләрмени? Булды, майладык абзыйны. Иртәгә үк пропускларны кулга алабыз да әллүр!..

Чыннан да, икенче көнне пропускларны тавыш-тынсыз гына чыгарып тоттырдылар. Алда хәзер Уфа, хәзер аның тайгак баскычларын яулыйсы бар иде. Ислам теге барган чагында ук белешеп кайткан икән. Кайчандыр аның белән бергә урамнарда сукбай булып йөргән берәү хәзер медицина техникумында директор, ди. Вәзирәне шунда урнаштырырга

өмет ачылган бит. Сукбайлардагы дуслык шултикле көчле булыр дип кем уйлаган?

Вәзирәне кертеп күрсәтүгә, алды да куйды бит бу. Инде Вәзирәгә тулай торакка юнәлергә әмер биргәч кенә, апалы-сеңелле ике ятимә бер-берсенең кочагына ташландылар да, яуга озатышкан ярлар шикелле, үкерә башладылар.

— Ике кат күлмәктән тыш бер әйбереңне дә үзең белән алмыйсың,— дип, Ислам гына айнытты аларны.— Синең җыен чүп-чарыңны тугыз мең чакрым буе күтәреп йөрисем юк. Барысын да сеңелеңә калдыр.

Авылдан-авылга, фатирдан-фатирга күчеп йөри-йөри җыелган ястык-юрганнар, кышкы пальто, әле генә бастырып алынган өр-яңа киез ката, үзе бәйләгән свитер, алты-җиде итәк, ике пар туфли, галош, чемоданнар — һәммәсе дә Вәзирә торачак бүлмә уртасында өелешеп калды. Әллә шушы хәтле байлык «яву» ушын алды инде, Вәзирә Зифаны вокзалга озаткан чакта да еламады.

Вокзал, гадәтенчә, сынау урыны, анда тагын мәхшәр. Әле ярты ел элек кенә Ерак Көнбатышта фин сугышы бара иде бит, дип тормыйлар, артларына ут капкан шикелле, кешеләр әле Себергә, әле Урта Азиягә агыла. Аларның берсен дә, бер якта да җәннәт бакчалары көтеп тормый бит инде югыйсә, кая ашкыналар?

Владивосток ягына да билетлар бөтенләй юк икән. Исламның үз вакытында заставага кайтып җитәсе бар бит, ул ут йота инде.

— Владивостокның үзенә бер атна буе поезд булмый, диләр. Юлдагы берәр зуррак шәһәргә булса да барып эләгергә кирәк. Соңга калам икән, долой башка.

Ислам тагын коньяк-шәраблар җыеп вокзал башлыгы янына кереп карады, файдасы юк. Хәтта коньяк-шәрабларын да алып тормаган теге, кире борган.

— Син пограничник, син Советлар иле сакчысы, сатлык япон түгел, держи марку,— ди икән.

Новосибирскка кадәрле ике билетны спекулянтлар кулыннан алырга туры килде. Исламда акча чутсыз иде, тартышып-сатулашып та тормады ул. Күмәк вагонга кереп эләгүгә дә ул шат-канәгать, хәзер инде буфет-рестораннар турында белешә башлаган иде. Зифа гына тамбурның бер як ишегенә чыгып сөялде дә, тимер күпер артында калган Уфа ягына карап озак өзгәләнде.

И язмышлар! Белемле, бәхетле итмәкче булып кайчандыр әтисе шушы Уфага китергән иде бит аны. Имеш, председатель баласы укымышлы, зур кеше булырга тиеш. Юк, белеме дә эләкмәде, бәхете дә. Зифа бер урыс белән бер

башкортның татар ирен суеп үтергәннәрен карап торды да, кире кайтып китте. Ашкына-ашкына шушы Уфадагы җыелышларга килеп йөргән әтисе юкка чыкты. Бәләбәй төрмәсендә чакта ук башын ашадылармы аның, әллә кабат карауларын сорап Башглавсудка гариза язгач, шушы Уфага китереп йоттылармы — моны кемнәр белсен? Ә газиз энекәше, япь-яшь Тимерҗан кайда? Исәнме, түгелме? Ул да шушы Уфа төрмәләрендәге газап-михнәтләрне кичердеме икән? Гомумән, кайда, кайда соң сез, аталы-уллы газиз Нәгыймовлар? Әнкәй, бәгърем, сезне көтеп җиткерә алмады бит инде. Ә миңа... миңа сезне күрергә насыйп булырмы? Әллә... әллә җиде диңгез артындагы Камчаткаларга киткәч, сез — минем, мин сезнең эзләрне бөтенләй югалтырбызмы? «Эх, чыгып качарга иде бу Башкортстаннан» дия идем дә бит, бактың исә, туган җирне, туган илне ташлап китүләр дә рәхәт түгел икән. Рәнҗешем күп сиңа, Башкортстан, әмма һич каргамыйм. Бәхетсез итүен күптән иттең инде. Ләкин шушы ук синең туфрагыңда туып-үскән Ислам Үрәзмәтов бәхетем түгел микән? Хатын-кызның бәхете ир кулында, диләр бит. Әйдә, көтик әле.

## 6

Исламда холык, табигать дигәннәре бер дә дан түгел икән шул. Тора-бара, юлда ачылды ул. Каян алган гадәттер, станция саен диярлек төшеп, кибетләрдән төянә дә менә. Берсендә — Зифага ялык-йолык килеп торган өр-яңа туфли, икенчесендә — кофта. Тукталган саен кочак-кочак колбасалар, шпрот, консервлар. Зифага яңа кием алу, әлбәттә, бик күңелле, кешеләр алдында рәхәт. Очраклы сәфәрдәшләр генә булсалар да, игътибар итми калмыйлар бит, телләрендә мактау:

— Ох, сез үзегезнең барышняны ничек иркәлисез, иптәш пограничник!

— Сезнең барышня бик тә лаек моңа, ул бит үтә матур!..

Аның ул колбаса, шпротларын санасаң, алары да әйбәт. Зифа моныңише ризык күргән кеше түгел, өстәвенә, чит-ят алдында юри нәзбереклəнгән булып, ялындыра-ялындыра ашавы да ләззәт. Ләкин... юкка тотылган акчалар кызганыч бит, ох, кызганыч!

Һәм иң аянычы: Ислам аракы-коньякларга түккән акча кызганыч, эчкән саен ул куптарган тавыш-гаугa газап! Нинди гадәттер бу? Ислам эчеп ала да, җиңнәрен сызганып, йодрыкларын төйнәп, поезд буйлап әллә нинди «дошманнар» эзләп йөри башлый. Имеш, купе яныннан узып барышлый фәлән кеше Зифага ач күз белән караган да, фәлән кеше

аның хатынының түшенә ышкылып узып киткән икән. Чит кешеләр һәммәсен күреп торалар, әмма тыгылмыйлар. Ә Ислам Зифаның ялваруларын колагына да элми.

— Син татар хатыны. Татар хатыны үз иренең аягын гына юып яшәргә тиеш ул. Син миңа йөгән кидерергә маташма. Шөпшә шикелле быжгымый гына утыр...

Эзли торгач, үз башына тәки бәла тапты. Беркөн төш вакытында ул Зифаны ресторанга алып киткән иде. Бик тә ыспай кыяфәтле бер очучы белән күрше өстәлгә туры килделәр. Тегесенә дә игътибарсыз гына калса ярамады, сөяркәсен очраткан шикелле авыз ера.

— Здравствуй, молодушка наша, красотушка!

Котырган үгезгә кызыл чүпрәк күрсәттеләрмени, Исламга нәкъ шул гына кирәк. Ыспай очучыны сукты да очырды. Әллә каян килеп чыккан дежур офицерлар, кул-аягын бәйләп, Исламны каядыр алып та киттеләр. Икенче көнне, төптөгәл бер тәүлектән соң гына, нәкъ шулар ук китереп тә куйды.

— Теләсә кайсы станциядә төшереп комендатурага тапшыра ала идек тә, сезне кызгандык. Сез бит әле япь-яшь кәләш икән,— диләр.

Ислам да, Алланың рәхмәте, шушы хәлдән сабак алды бугай. Владивостокка җиткәнче ул башкача хәмер-мазар белән шаярмады.

## 7

Новосибирскттан соң тагын ун тәүлек буе теркелдәп бара торгач, ниһаять, Владивостокка килеп төштеләр. Тимер юл вокзалыннан портка кадәр ара ерак икән, Ислам ниндидер очраклы машинага акча түләп озаттырып куйды. Зифаның эше йөк саклау бит инде, ул утырып калды, Ислам каядыр ашыга-ашыга китеп янә юкка чыкты. Бер сәгать юк теге, ике, өч сәгать. Зифаны инде: «Әллә, эчеп, комендатурага-фәлән эләкте микән?» — дигән корт кимерә башлады, ә Ислам күренми дә күренми. Зифа, аптыраганнан яр тирәләрен әйләнә башлады, шәһәргә күз атты.

«Владивосток бик еракта, әмма ул бит барыбер безнең шәһәр» дип Ленин кадәр Ленин горурланып әйткән кала менә нинди икән! Тау өстендә тау, тирә-ягы томан. Ике-өч катлы таш йортлар бик сирәк. Шәһәр күбесенчә агач йорттан хасил. Мәгәр биредә бер генә йортның да ихатасы күренми. Йортлар, бер-берсен терәтмәсә авып китәр сыман, бик тә, бик тә еш утырганнар. Йортлар арасында бәдрәф кебек кенә вак-вак сарайлар бар, ә агачлар бөтенләй юк диярлек.

Әкәмәт, монда Башкортстандагы, Уралдагы шикелле егерме-утыз метрлы агачлар, гомумән, юк икән. Монда агачларның иң биек дигәне дә дүрт-биш метрдан узмас. Юан кәүсәләре күренми, һәммәсе дә бөкре әби сыман җиргә иелгәннәр. Боларда кара туфрак шулай ук һич күренми. Кая карама, таш та ком, янә кызыл балчык. Җир-җир дия-дия моның нәрсәсе өчен генә кан койдылар микән?

Тукта-тукта, безнең Бикми-Бикмөхәммәт абзый да шушы якта гомер сөреп ятты түгелме соң? Владивосток янында гына Артем бар, мин Лиза апагызны шуннан табып кайттым, дип мактанырга ярата торган иде. Анда бәрәңгесен, кыяр, кәбестәсен үстердем, дип тә сөйләнде бит әле. Бәрәкалла! Мондый тоташ ком-таш өстендә ул кәбестә-кыярларны ничек кенә үстереп була икән?..

Дүрт-биш сәгать буе югалып торганнан соң, ниһаять, кичке караңгылык эченнән Ислам килеп чыкты. Берьялгызы түгел. Ниндидер ике солдатны иярткән, тегеләр сыртларына берешәр олы капчык күтәргәннәр. Ислам да, тегеләр дә янган-пешкән.

— Давай, әйберләрне җыйна,— дип, Ислам шундук, гыжгыж килә-килә, әмер дә бирә башлады.— Озакламый причалдан военно-грузовой бер пароход китә. Әле ярый, капитаны таныш булып чыкты. «О, иптәш Уразметов! Сине бер тиен түләтмичә алып китәм»,— ди. Менә шулай, без дә төшеп калганнардан түгел, апаем, бик белеп тор. Старшина Уразметовны бөтен җирдә хөрмәт итәләр ул.

Үзенең урынсыз шапырына башлавын аңлап алды, ахры, Ислам солдатларга таба ияк какты.

— Син мине трай тибеп йөргән дип уйлый күрмә тагын. Юк, менә бу ике солдат белән бергә кибетләрдән-кибетләргә йөгерә-йөгерә ризык җыйнадык без. Тушенкалар, консервалар, каклаган балык, ит, сохарилар. Военно-грузовой пароходта ресторааннар юк бит. Ә юл озын. Ничә тәүлек буе барасын да төгәл әйтеп булмый. Юлга запассыз-нисез көенчә чыкмассың бит инде...

Хәрби-йөк пароходы дигәннәре шактый зур гына кораб булып чыкты. Озынлыгы — авылдагы урам буе бардыр, биеклеге тугызар-унар катлы йортлар чаклы булыр. Төн уртасы дип тормыйлар, төрле яктан прожекторлар элеп куйганнар да палуба өстенә йөк төйиләр. Урамны аркылы түшәп чыгарлык озын, шәп такталар һәм шпаллар; чехолларга төрелгән туп һәм пулеметлар, зур-зур тачанкалар; берсе-берсе бәләкәй мунча чаклы солдат казаннары; яллары тигез итеп кыркылган, тояклары дагаланган, сыртларына «РККА» дип тамга сугылган гаярь, вәкарь атлар; чәчләре тап-таз итеп ал-

дырылган йөзәрләгән некрут... Юк, боларны санап-айкап бетерерлек түгел.

Төялгән йөкнең бик күбесен трюмнарга тутыралар икән. Монда мәзәк: трюм катлы-катлы һәм һәр катта, умарта оясына охшап, аеры тормыш кайный. Әнә бер катта яшь егетләр-некрутлар үзләренә ашханә урыны корып йөри, икенче катта — күчмә госпиталь, ерак почмакларда хәрби ат араннары, сугыш кирәк-яраклары тутырылган күп-күп складлар. Хәрби гарнизон һәм заставалар төзелеше өчен кирәк булган төзелеш материаллары тутырылган вак-вак сарайлар да санап бетергесез. Зифа белән Ислам да әнә шул күчмә сарайларның берсенә, тигез итеп өелгән шәп-шәп такталар өстенә менеп урнаштылар.

Төнге сәгать икеләр тирәсендә пароход кузгалды. Ни өчендер озын-озакка сузылган гудок-сиреналар биреп тормадылар. Юл ыгы-зыгысы бик арыткан иде, Зифа тизрәк йокларга хәзерләнде. Ислам гына һаман, тешләк бабай сыман, гел ысылдап йөрде:

— Монда хатын-кызлардан сез өчәү-дүртәү генә икән. Кара аны, юлда күз-башыңны уйнатасы булма...

Иртән палуба өстенә күтәрелгәч, Зифа хәйран калды. Кайсы якка гына карама, гел су да су, офыктан күзләреңне күпме генә чекрәйтеп эзләсәң дә, уч төбе чаклы да коры җир әсәре юк. Бер уйласаң, бу иксез-чиксез су дөньясының искитмәле һичнинди кызыгы-гүзәллеге дә юк инде. Ә Зифа зур сулар, диңгезләр күргән кеше түгел бит, аңа барыбер рәхәт. Ул, палубаның бер ягыннан икенчесенә күчә-күчә, һаман нидер эзли, тынчу трюм эчендә интеккәнче монда күпкә җиләс.

— Япон диңгезе бу,— дип аңлатып барды Ислам.— Монысы — диңгезләрнең баласы гына әле.

Юк, баласы гына булмаган икән шул. Охот диңгезенә алып чыга торган Лаперуза бугазына җитә башлаганнар иде, ике як офыкта ике япон крейсеры күренде. Шул минутта ук бар пароход өстен капитанның корыч әмерләре айкап чыкты:

— Тревога! Бөтен команданы палуба өстенә! Хәрби әһәмияте булган бар әйберне трюмнарга төшереп яшерегез! Нинди бала-чага, хатын-кызлар, карт-коры бар — һәммәсен палуба өстенә чыгарып бастырыгыз!

Бар пароход, таяк тыгып болгатылган кырмыска оясы шикелле, бер җилкенеп алды. Палуба өстендә барган айгырларның, тачанка һәм тупларның барчасын да биш-ун минут эчендә трюмнарга төшереп бетерделәр. Шул трюмнарның кайсы катындадыр Камчаткага берничә офицер гаиләсе, ике-

өч шәфкать туташы бара икән. Көндәлек киемдәге бу юлчылар палубалар кырыена тезелешеп басты. «Без бернинди дә хәрби-йөк корабы түгел, без иң тыныч халык, безгә тимәгез», янәсе. Тот капчыгың, японны алай җиңел генә сантыйга чыгардың ди!

Берзаманны бу ике крейсер да билгеле бер ара белән совет корабын кысып бастылар да капитаннар арасында һичкем аңламаган сигналлар телендә сөйләшүләр башланды. Японныкылар үзәгенә нык үттеләр, ахры. Бер минутта совет капитаны рубкасыннан сикереп төште дә, палуба читенә баскан бала-чага яки хатын-кызның һәркайсын стройдан аера-аера, өр-яңа баштан урыннан-урынга сөйрәп-күчереп чыкты. Аны гына да азсынгач, тачанка-туплардан чистарынып калган ачыклыкка килеп, үзалдына гына биегәндәй итте. Тик япон капитаннары барыбер дә ышанмады бугай. Ике яктан китереп кыскан һәм тупларын төбәгән көенчә, алар әле Лаперуза бугазы буена совет пароходын озата бардылар. Охот диңгезенә күченгәннән соң гына, ниһаять, ике дошман крейсеры да аерылып калды.

Менә хәзер инде Исламның кисәтүе дә аклана башлады. Әйе, Япон диңгезе — ул зур суларның баласы гына булган икән, анда пароход бәллүләү, пароход уйнаклау дигән әкәмәтләрнең эзе дә юк иде. Ә Охот диңгезенә чыгулары булды, пароход җимерелеп беткән урман юлына эләккән ат арбасы сыман сикергәләргә тотынды. Валлаһи, әле агач төбенә килеп менгән, әле бил тиңентен чокырга төшеп киткән арба белән бер икән бу кораб. Әле бер таба янтая, әле икенче якка сикерә. Трюм эчендә утырмалы түгел. Әллә кемнәр укшый, әллә кайлардан коелган такта кисәкләре, тимер тәгәрмәчләр, зур-зур чемоданнар, «менә сытам, менә изәм» дип янаган шикелле, ике стена арасында биеп-очып йөри.

Палубада барыбер дә рәхәтрәк. Монда һава саф, җиләс, Зифаны бик укшытмый. Ислам, үзе косып туктаган араларда, гаҗәпләнеп көлә.

— Син ярамаган ризык ашаган песи баласы кебек икәнсең. Ул да шулай бит. Хет башына сук син аның, хет авызын каер — космыйм дисә, космый.

Зифа үзенең организмын игътибарны читкә юнәлтеп алдарга тырыша. Күзәтердәй кызык-галәмәтләр шактый. Пароходны даими рәвештә күктә бер көтү кош, диңгездә исәпсез-хисапсыз балык агымы эзәрлекләп бара. Охот диңгезендә бервакыт давыл купкач, тугыз катлы йорт биеклегендәге кораб су өстендә кечкенә тагарак хәленә калып сикерә башлады. Әле бер яны белән диңгездән суны чөмереп ала бу, әле икенче яны белән диңгез өстенә сузылып ята. Зур-зур сол-

дат казаннары, биек шпал өемнәре сүс арканнар ярдәмендә ничек кенә шәп итеп беркетелгән булмасын, берзаманны болар һәммәсе дә палуба өстеннән диңгезгә чыгып очты. Менә шундый гарасат вакытында сәер адымнары белән Зифаны кошлар шаккаттырды. Мондый көчле җил-давыл белән көрәшә-көрәшә очу бик читен, күрәсең. Көтмәгәндә кошлар берәм-берәм палуба өстенә утыра башладылар. Кайсы тырнаклары белән сүс арканнарга ябышкан, кайсы тимер борт өстендә агач сын шикелле селкенми дә утыра. Җай табып, Зифа бер-икесенә куллары белән кагылып караган иде, тәмам аптырады. Юк, очып китмиләр тегеләр, ике кулыңны борын төпләренә китереп чәбәкәйләсәң дә, исләре дә китми, тып-тын утыралар.

Пароход артыннан ияргән балык көтүен күзәтү аеруча төнлә бигрәк кызык. Араларында электрлы балыклар да күп, күрәсең. Менә шулар сикереп уйнаган чагында, бөтен су өсте ялт-йолт итеп тора. Шул очкыннар уйнаклавын ташлап, кереп китеп булмый.

Ләкин беркөнне диңгездә давыл тынуга, әлеге вак-вак балык көтүләре кисәк юкка чыкты. Күпчелек халык бу хәлгә игътибар да итмәгән иде. Берзаманны пароход артында ниндидер сәер гүелдәү пәйда булды. Китми дә, басылмый да бу гүелдәү, һаман көчәя-көчәя эзәрлекләп бара. Халык аптыраша, хәвефләнә башлады. Юкка булмаган икән. Палуба өстен күпне күргән, утлар-сулар кичкән карт диңгезчеләр фикере урап үтте:

— Безгә акулалар көтүе иярде. Корабта йә үле, йә өметсез хаста булып яткан бер юлчы бар. Акулалар шуны сизгәннәр дә, яман тавыш чыгарып, шул кешене таләп итәләр...

Капитан бик кычкырмый гына фәрман бирде бугай, хәрби санитарлар трюмнардагы барча катларны да айкап-тентеп йөри башладылар. Корбан да табылды. Камчаткадагы офицер янына баручы бер гаиләдә җиде-сигез яшьлек малай әле корабка утырганда ук авыру булган икән. Гарасат вакытында, пароходны йомычка урынына очыртып йөргән чакта, җан биргән бу. Әнисе диңгезчеләр канунын белә икән, юри беркемгә дә әйтми яшереп барган, газизен коры җир өстендә җирләмәкче булган. Ирек бирмәделәр. Мескен баланы җилкән чүпрәгеннән тегелгән олы бер капчык эченә тыктылар да, янына тимер тәгәрмәч бәйләп, диңгезгә ыргыттылар. Пароход туктаган сыман әкренәйгән иде, икеөч гудок бирде. Көтелмәгән корбан белән шулай хушлаштылар. Ана кеше һушсыз булып ауды. Акулалар көтүе юкка чыкты...

Шушы коточкыч хәлләрне тавыш-тынсыз гына күзәтеп

барган Зифа миңгерәгәндәй булды. Аның палубаны ташлап керердәй куәте юк иде, Кара диңгез суларына текәлгән көенчә торараштай калды. Берзаманны күкрәгендә ярсу өермә кузгалды. «Нишләп бу кадәрле кансыз кыйланды соң әле бу диңгезчеләр? Нишләп алар мескен ана күкрәгеннән аның нарасыен суырып алдылар да, нигә аңа үз баласын коры җиргә чыгарып җирләргә ирек бирмәделәр?» — дип ул әүвәл пароходтагы барча кешене ачулы карашы белән айкап чыккан иде. Аннары күңелендә кинәт икенче хис уянды. «Тукта, акула көтүенең котыруы — ул безнең җәмгыятьнең көзгедәгедәй чагылышы булды түгелме соң? Акулалар гына түгел, кешеләр дә шулай торып-торып вәхши тәгамнәрен тыгар өчен корбан сорыйлар бит. Юк, бер дә тыныч кына, килешеп, ипле генә яши белми бит бу кешелек җәмгыяте. Утызынчы елны Уфада канга сусаган кыргый урыс белән башкорт, үзләренә буйсынмаган, аларны тиң күреп, бергә җырлашып бармаган өчен, гөнаһсыз татар ирен тотып суйган иде. Утыз өчтә гөнаһсыз Әмирнең башын ашадылар. Батраклыктан котылып колхоз рәисе кәнәфиенә менеп алган өчен, башкалардан өстен булган өчен. Әйе, үзләрен узып киткән, аларга караганда булдыклырак булган өчен дә үч алучылар, синең гомереңне кыярга әзер торучылар байтак шул бу дөньяда. Кансыз, вәхши, кыргый бу кешелек. Адәм баласы да нәкъ акула сыман. Аңа да кан кирәк, корбан кирәк, аяусыз яу кирәк...»

Өч көннән соң пароход алдында зур җир пәйда булды.

— Авача бухтасы. Петропавловскка җиттек,— диде Ислам.

Зифа әле түбәсенә кар яткан биек сопкадан тыш берни күрми иде. Хәер, алданиләр көткәнен дә белми иде бит ул.

## АЛТЫНЧЫ БӘЙЛӘМ

### 1

Ислам хезмәт итә торган гарнизон Петропавловск каласыннан тугыз-ун чакрымда урнашкан булып чыкты. Монда да, нәкъ Владивостоктагы шикелле, сопка өстендә сопка. Шул сопкалар арасындагы ерымнар буенча шпал һәм такта блоклардан беркетеп ясалган берәр катлы бараклар тезелеп киткән. Боларда тәрәзәләр бөтенләй юк диярлек, нәкъ урта бер җиргә уелган ишекнең як-ягында гына мунча төнлегенә охшаш форточкалар бар.

— Солдат казармалары бу, — дип, аларга таба ияк кагып кына аңлатып бирде дә, Ислам бик тә сәер итеп авыз ерып куйды. — Абзаң биш-алты ел буе шушы баракларда чиләнде, газап чикте инде. Шабаш, старшина Уразметовка да эт тормышына чик куярга вакыт. Мин башлы-күзле булган кеше инде хәзер, бик солидный кеше. Казармага моннан ары аяк атлыйсым юк. Уразметов кебек белгечләр кирәк икән, даешь миңа аерым бүлмә, иптәш командир!

Ислам бараклар арасына әнә шулай үзалдына сөйләнә-сөйләнә килеп керде. Зифа инде берьяк тау битенә тезелешеп киткән икешәр катлы дүрт агач йортны күз алдыннан кичереп өлгергән иде. Ислам, аны бер кулыннан җитәкләгән көенчә, нәкъ менә шул йортларның иң кырыйдагысына таба атлап китте.

— Армияда шулай: чит-ят кешегә барып керергә ярамый. Давай, үзебезнең командир ротага кереп доклад бирик инде.

Беренче каттагы бер ишектән уздылар. Инде кичке караңгылык төшеп килә иде, һәммәсе дә өйдә. Арттагы толымнарын баш түбәсенә өеп кечкенә «кибән» корган, колак тирәсендәге чәчләрен бөтәркәләп «кабатланмас мода» ясаган, шактый бизәнгән-ясанган бер хатын шундук ишек төбенә килеп каршы алды.

— Ого, Уразметов, уже с невестой прибыл? Поздравляем, поздравляем!

Аның тавышына каршы бүлмәдән өлкән лейтенант дәрәҗәсендәге чибәр генә ир, берсеннән-берсе бәләкәйрәк өч сабый бала йөгерешеп чыкты. Ислам белән командирының мөнәсәбәтләре бик якын, күрәсең. Бер-берсенең аркаларыннан шап-шоп сөя-сөя, кочаклашып күрештеләр болар. Аннары хуҗа Зифаның каршына килеп кулын сузды.

— Будем знакомы, Бабурин. Виктор Николаеч. Можно «Витя».

Яшьләрнең ни өчен монда килеп керүләрен аңлагандыр инде, икенче минутта ук барча билгесезлеккә чик тә куелды.

— Сезгә аерым бүлмә юнәткәнче бездә торачаксыз, шулайдыр бит, Шура?

Хатынының исеме Шура икән, тегесе дә, эчкерсез елмая-елмая ияк какты. Эчтәге кечкенә бер бүлмәне яшьләр өчен дип бушаттылар. Зифа белән Исламның гаилә тормышы Камчаткада шулай борынлады.

Бер ай чамасы Бабуриннар өстендә торгач, аларга да шул ике катлы йортларның берсеннән аерым бүлмә бирделәр. Киңлеге — өч, озынлыгы дүрт метр чамасындагы кечкенә бер торак, ләкин ул аерым, аңа кеше күзе үтми, яшьләр шу-

ның белән дә бик канәгать иде. Тик... тик Зифага аерым бүлмәдә дә бәхет кичерергә туры килмәде шул.

Исламдагы тилелек, холыксызлык — аңлап бетергесез. Тәүге көннәрдә әле гел бертөрле генә таләп куя иде:

— Мин егерме җиде яшькә җиткәнче гел столовой ашы белән генә яшәдем. Булды, җитте, шабаш! Моннан ары күмәк аш ашыйсым юк. Мин эшкә чыгып киткәндә, пары чыгып торган кайнар аш китереп куярга күнек. Мин кайтып кергәндә дә, шундый ук кайнар аш белән көтеп тора торган бул...

Йорт офицерларныкы булып исәпләнсә дә, моның ни суы, ни үзәкләштерелгән миче, ни электры-мазары юк бит инде. Һәрбер бүлмә саен аерым бер «буржуйка», һәрбер фатир саен ихатада кеп-кечкенә сарай. Ислам, әлбәттә, хатын алып киләчәген күзаллап яшәмәгән, боларга әләккән сарайда утын түгел, чыра әсәре юк. Ә урамда зәһәр кыш уртасы. Камчатканың кышы да адәм рәтле генә кыш түгел икән бит. Буран кузгалдымы, ким дигәндә бер атна буена котырына, ихатадагы сарайларны, үзәнлектәге казарма-баракларны түбәсенә кадәр кар күмеп китә.

Тирә-юньне рәтләп белмәсә дә, Зифа беренче көннәрдән үк якындагы сопкаларга чыгып коры-сары җыеп кайта торган булды. Аларны сарайга кайтарып тутыруы була, нәкъ шуны гына көтеп торган шикелле, буран кузгала һәм бер-ике сәгать эчендә кар күмеп китә, Зифа исә инде сәгать дүрттә үк торып сарай капкасын кардан арчырга, һәр таң саен балта белән утын ярырга мәҗбүр. Исламның сарай белән балта-утыннарның кайда икәнлеген дә белгәне юк. Ул кичке сигез-тугызларда гына кайтып керә, Зифа аңа хәтта сүз кушарга курка.

Ул әле кар көрәү, утын яру, аш хәзерләүләрне генә уйламас та иде. Монысы — физик җәфа, анысы җаңга үтә. Ә менә инде Исламның тиктомалдан көнләшүенә чыдамалы түгел. Зифаны кәнизәк урынына өй эченә бикләде дә куйды.

Зифа гарнизонга әле яңа гына килеп төшкән кеше, дуслары-ахирәтләре юк бит. Тарсынып-ятсынып утырмасын, диптер инде, кайбер кичләрдә аның янына бөтенләй чит-ят офицер хатыннары да килеп керә.

— Бүген гарнизон клубында кино күрсәтәләр, бергә бармыйбызмы?

Зифа нишләсен инде? Ул кыяр-кыймас кына Исламга күз ташлый, ә тегесе усал ата каз шикелле теш арасыннан гына ысылдап җавап бирә:

— Барып кына кара, аягыңны сугып сындырырмын!..

Хатыннар керми башлады. Зифаның хәзер тәүлектәге

егерме дүрт сәгате дә диярлек дүрт стена эчендә, япа-ялгыз үтә. Ул укытучы белеме алган кеше бит, гарнизондагы китапханәне бик бай диләр, аның китап укыйсы килә. Әмма Исламга бу турыда киная кузгаттыңмы, янә елан теле сыман чагып алу, тагын төртмәле җавап:

— Ирләр белән танышырга җай эзлисеңмени?..

Зифа ялгыз гына бикләнеп утырган чакларында үзен тилергәндәй тоя башлады. Кайчакларда урында утырган җирендә алга-артка китеп бәллүли-бәллүли елый, кайчак җырлый:

Салкын чишмә, ятып эчмә,
Ятып эчми нишлим соң?
Тиң түгеллеген дә белдем,
Язмыш кушкач нишлим соң?

Гарнизонда яши башлауларына ай ярым, ике ай чамасы вакыт үткәч, Башкортстаннан берьюлы дүрт хат килеп төште. Иң үзәк өзгечен Сарайлыда бергә балалар укытып йөргән ахирәте Фатыйма язып җибәргән.

«Сез чыгып киткән көнне кич белән үк авылга Хәйбери кайтып төште. Авыл башына кергәч тә, кемдер сезнең хәлне әйтеп өлгергән моңа. Хәйбери чемоданын шул йорт ихатасына гына болгап ыргыткан да Яхъя абыйларга очып кайтып кергән. Шулай, шулай, дигән Яхъя абзый аңа. Синең кәләшеңне бер командир Камчаткага урлап китте, дигән. Хәйбери өстәлгә капланган да үкереп елый башлаган. Яхъя абзый аңа бер стакан аракы биргән бугай. Шуннан соң гармун тарта-тарта кич буе җырлап утырганын үзем дә ишеттем.

Сандугачым, сизәсеңме,
Баскан талың кисәләр.
Сикереп утларга төшәрсең,
Сөйгәнеңне сөйсәләр.

Икенче көнне иртән Хәйбери сезнең арттан Уфага чыгып китте. Икесенең берсен поезд астына салам, дип әйткән ди. Анда синең сеңлең Вәзирәне эзләп тапкан. Мәгәр бу егерме дүртенче ноябрь көнне булган, ә сез инде егерме икесендә үк китеп баргансыз. Менә шуңа гына таба алмаган ул сезне. Тапса, валлаһи да, поезд асларына салыр иде. Әле хәзер дә мине күргәч елый. Кибеп,ябыгып бетте. Без, авыл яшьләре, монда бик нык аптырашабыз. Әгәр аның рәнҗешләре дә төшмәсә, дөньяда рәнҗеш дигәннәре бөтенләй юк икән, дибез...»

Шушы хат бәгырен пычак белән телгән сыман итте. Зифа янә кайгы-моңга батты.

Туса да тусын шул ир бала
Ат өстендә сикереп уйнарга.
Тумаса да тумасын, әй, кыз бала
Ят каршында үкереп еларга...

Мондый газап тагын күпме дәвам итәр иде микән? Аңа, һич тә көтмәгәндә-уйламаганда, Бабуринның хатыны чик куйды.

Зифа белән Ислам ул кичне дә, дүрт стена эченә бикләнеп, сүзсез генә утыралар иде. Көтмәгәндә кемдер тәрәзә пыяласына чиертеп узды. Исламның өстенә кайнар су койдылар диярсең, мәче җитезлеге белән сикереп кузгалды да Зифаның бугазына килеп ябышты.

— Кайчан, кайсысы белән танышып өлгердең? Кем чакыра? Хәзер үк әйт! Юкса җаныңны кыям!

Исламның ирен читләреннән селәгәй агып чыккан, күзләрендә нур юк, тәне дер-дер килә. Зифа аның кулын да каергалап карады, юк, ычкындырырга һич уйламый теге. Бераз тотса, чынлап торып үтерергә мөмкин.

Нәкъ шул минутта ишектән Шура атылып керде. Тәрәзә аша күзәтеп торган икән. Керүгә үк, карчыга шикелле атылып, Исламның чәчләренә килеп ябышты. Зифадан йолкып алды да, Исламны доң-доң китереп, башы белән стенага бәрә.

— Ах, әле син хатыныңны колчура урынына тота торган алпавытмыни, хәсис? Зифа сиңа крепостной малмыни? Әле коммунист булып йөргән буласыңмы? Полк яки дивизия командиры янына барам да штрафбатка озатам мин сине!..

Коммунист икәнлеген искәртү, штрафбат белән янау тәэсир итте бугай, Ислам коелып төште. Ул бер почмакта пуф-пуф килеп сулыш алып утыра, Зифа икенче почмакта елый.

Шура моны гына да азсынган икән. Ул йөгереп чыгып китте дә ике-өч минуттан соң үзенең ире Бабурин белән батальон командиры капитан Петровны ияртеп килеп керде. Тегеләр дә кызган. Бабурин керә-керешкә үк Исламның яңагына чалтыратып җибәрде.

— Мин сине кеше дип йөргән идем, ә син бер үзбәк феодалы икәнсең, падла!

— Зифа, безнең хатыннар арасында иң укымышлы кешеләрнең берсе, ул, алтындай табылдык. Син, акылың булса, аңа солдатларны укытырга ирек куяр идең. Ул ятим көе дә белем алган бала. Чынлап баксаң, синең ише томанага әрәм.

— Партиядән чыгып очасың яки командирлыктан ычкынасың килмәсә, Зифага моннан ары кул сузасы булма. Без дә бүкән түгел, тиешле урыныңа момент утыртырбыз!..

Бабурин белән Петров әнә шундый нотык укып киткәч, Ислам берникадәр үзалдына йомылгандай булды. Гарни-

зон үзенең кибете белән гел дан тота иде, Зифага шунда йөрергә ирек ачылды. Хатын-кыз нинди хәлдә дә хатын-кыз бит инде ул, чүпрәккә, киемгә кызыкмыйча калмый. Ә Зифаның мондый кибетне бөтенләй күргәне юк. Бәләбәй, Сарайлы кибетләренең киштәләрендә шар тәгәрәтеп уйнашлы иде, ә монда алар малдан сыгылып тора. Драп, бостон, шевиот материаллар, сатин-ситсаларны әйткән дә юк. Төрле-төрле яулык, шәлләр, туфли, мех итекләр. Кызыл балык, керосин, чәй, шикәр, төрле-төрле балык уылдыклары, консервлар, сыер гына түгел, хәтта болан ите... Санап кына бетермәле түгел. Зифа бер әйбер алмаса да, көненә ике-өч мәртәбә шул кибеткә сугылып чыга иде. Мондый хәл дә Исламның үзәгенә үтә башлады бугай. Ул үзе кибеткә кереп төп-төгәл бер йөз тәңкәлек товар сайлап алды да аны Зифаның алъяпкычы өстенә кайтарып өеп куйды.

— Минем кадерне барыбер бәяләмәссең инде. Шулай да боларны Вәзирәгә сал син. Ул ялгызы. Ятимлектән газап чикмәсен...

Бик күп көннәрдән соң беренче тапкыр бугай, кайнар кочаклашкан көенчә йокладылар. Зифага җылылык-наз күптән тиеш, ул берничә ай буе көмәнле булып йөри иде инде.

## 2

Егерме икенче июнь — якшәмбе көн. Камчаткада җәй бик соң килә. Гарнизонда яшәүчеләр, ниһаять, кояшлы-назлы якшәмбене көтеп җиткерделәр дә, таң сәгатеннән үк кырга ашыктылар. Монда колхозга колхоз терәлеп утырмаган, Башкортстандагы кебек түгел. Бөтен Камчаткасына алтыҗиде колхоз-совхоз ише хуҗалык бар, диләр. Алары да күбесенчә балык тоту, балык эшкәртү белән шөгыльләнә. Ә күл буйлары, үзәнлекләр, урман эчләрендә эреле-ваклы аланлыклар — барысы да кыргый, ягъни хуҗасыз-нисез көенчә, ташландык хәлдә ята. Тик дөнья көтәргә, тамак туйдырырга исәп тоткан инсан бар чагында нинди дә булса ризык үстерердәй ул ташландык җирләр хуҗасыз һәм сансыз каламыни?

Күпләр инде якын-тирәдә үзләренең кечкенә генә басуларын, кишәрлекләрен булдырганнар икән. Гел Зур Җирдән пароходлар белән китерәчәк ризыкларга гына исәп тотып яшәп булмый бит. Өстәвенә, япон кордоннары аша үтеп йөрү көннән-көн авырлаша. Пароходларга тутырып китерелгән кипкән бәрәңге, суган, кишер, чөгендерләрнең тәме дә юк. Менә шуңа күрә инде бик күпләр үз кишәрлекләрендә байтак яшелчә-җимешне үзе үстерергә гадәтләнгән.

Дөрес, монда туфрак көлсу, җитмәсә, ул әле вак ком-таш белән дә аралашкан. Әлбәттә, кара туфрак дигәннәренең эзе дә юк. Әмма ният иткән кеше берәр төрле хәйлә тапмый каламы соң? Зифаны да күрше хатыннары язга чыгуга ук өйрәтә башладылар.

— Монда бәрәңгене көрәкләр белән ялт-йолт утыртып булмый. Һәр төп өчен аерым оя ясап, туфракны тирес белән бутап утыртырга кирәк. Ул гына да җитми. Әле тагын һәрбер төпне озын җәй буена иң төп байлык белән сыйлап торасы бар. Анысы... колагыңа гына әйтәм... адәм нәҗесе инде.

Зифаның күзләрен шакмак сыман итеп төбәвеннән үк аңладылар бугай, ирен читләрен уч төпләре белән каплап, алар янә тезде:

— Анысын, дускаем, сараегызга чиләкләр чыгарып куясыз да җыйнап барасыз инде. Сиңа көлкедер дә, мәгәр аның хикмәте уңыш җыеп алган чакта беленә ул. Ышанмасаң, кара.

Зифага үзләренең базларындагы бәрәңгеләрне чыгарып күрсәттеләр. Зифа авыз ачты да катты. Орлыкка калдырырдай бер вак бәрәңге юк, барысы да чәйнек, йодрык чаклы.

Оялып-кыенсынып кына Зифа белән Ислам да чәчү өстенә шулай «әзерләнде». Ислам гарнизоннан өч чакрым ераклыктагы күл буенда өч сутый чамасы буш җир табып кайткан иде. Егерме икенче июнь көнне таңда Ислам бер капчык бәрәңгене җилкәсенә алды, көмәнле Зифа көрәк, ризык кына күтәренеп барды. Баш та күтәрмичә төш вакытына кадәр казындылар да, чәчүне очлап чыктылар. Әмма берсе дә кире гарнизонга кайтырга ашыкмады. Табигатькә тәүге тапкыр чыгулары иде. Ислам якындагы урманга кереп әллә никадәрле кедр ботаклары җыеп чыкты. Күл суы чишмәнекедәй салкын, чиста иде. Артып калган ике-өч бәрәңгене турап аш казаны астылар, чәйнек утырттылар. Икесе тиң, учактагы ялкынга төбәлгән көенчә, уйларына чумды. Ара-тирә генә, уянып киткәндәй, табигатьнең хозурлыгын күзәтеп утырдылар.

Әйе, ни әйтсәң дә, Камчатка — ул сиңа Башкортстан түгел. Монда йөзьяшәр карагайлар, наратлар, битләренә кершән яккан ап-ак каеннар, якут алкаларын ялтыратып утыручы баланнар да юк. Меңәрләгән елкыларның көтүләрен сыйдыра торган иксез-чиксез далалар да, суында аккошлары йөзгән, тирәсендә торналар хисләнеп бии торган матур зәңгәр күлләр дә юк биредә.

Монда табигать кырыс, монда мәйданнар тар. Кая гына күз атма, сопка өстендә сопка. Бик күбесенең түбәсендә, бүрек кигән шикелле, әле дә кар ята. Тау битләре буенча уры-

ны-урыны белән агачлык сузылган. Күбесе — кедр аламасы һәм вак-вак куаклыклар. Ни гаҗәп, бер генә иңкүлектә дә чишмә-инешләр очрамый. Кар суларыннан җыелган җәйге күлләрендә кош-корт әсәре юк. Күпме генә тырышып эзләсәң дә, монда бал кортлары, чәчәк табып булмый. Комташ арасыннан калкып чыккан бар яшеллек — йә мүк, йә Башкортстандагы әрем шикелле биек, әмма ярым корыган үлән. Аның каравы монда кыргый сарымсак чутсыз. Тәм ягыннан чын сарымсак яки суган кебек түгел инде түгелен. Ләкин ашка тәм бирергә барыбер ярап куя. Гарнизондагы һәр гаилә аны кышка чиләге-чиләге белән тозлап куя икән...

Тамак ялгап алгач та кузгаласылары килмәде.

— Иренмәсәң, тагын кедр алып килеп өстә әле, Ислам,— дип үтенде Зифа.— Без моның ише утын күргән кешемени? Без тал чыбыгы белән кипкән тирес, йә булмаса салам ягудан башканы белмәдек бит.

Зифаның сәер хатирәсе тәэсир итте бугай, Ислам янә кырмыска шикелле төянеп килеп җитте. Учак өстенә берничә ботак ташлагач, Зифа һич тә көтмәгәндә Исламга үзенең этисе турында сөйләп китте:

— Сиңа элек бер дә сөйләмәдем, Ислам. Йә кимсетерсең, йә җәлләрсең, дидем. Ә минем эткәй, исән булса, төрмәдә утыра бит...

Шуннан соң Зифа бер-ике сәгать эчендә үзләренең башыннан кичкән бар михнәтне сөйләп чыкты сыман. Хәбиләрне, Кара тавыкларны калдырмады, туган абзый булып саналырга тиешле Әбелсаттарны да. Бәхетле чакларын да бәян итте, тоташ кайгысын да. Әтисен, Тимерҗанны алып китүләре турында сөйләп бирде. Бер кызгач, хәтта Афонькаларны ничек үтерүләре турында да тезеп салды.

— ...Арт ягына утлы кисәү тыкканнар аның, Ислам. Шул турыда хәбәр алуга ук, мин утарга чаптым. Барсам, башын-аякларын сузып салып, җирдә ята, җанкай. Арт ягы шешеп чыккан, бөтен җире үлек. Үзе һаман җан бирә алмый интегә, бәгырькәем. Күзендә яшь. Мине күргәч, башын күтәргәндәй итте. Иреннәре белән кулларымны ялый. Мин бер телем икмәк алып килгән идем. Шуны да ашый алмады. Яшьле күзләрен миңа төби дә пошкыра, миңа төби дә пошкыра. Хушлашуы шул булгандыр инде...

Алар җир өстенә салкын һава яткач кына урыннан кузгалдылар. Ислам кайнар кысып Зифаны кочагына алды. Ни гаҗәп, пәһлевандай гәүдәле ирнең керфекләрендә дә яшь ялтырый иде.

— И-и, нинди генә газаплар кичермәгәнсең икән син, Зифа! Нигә боларны миңа бер дә сөйләмәдең?

Бераз торгач, үз соравына үзе үк җавап тапты бугай, усал, кансыз тавыш белән сүгенеп тә алды.

— Мин кайчак үз-үземне күралмыйм, Зифа. Беләм, синең бер гөнаһың да юк. Гомумән, син гөнаһы кыла ала торган кеше дә түгелсең. Ләкин менә шул көнләшү чиреннән арына алмыйм. Күрәсең, ялкаулык белән көнчелек — икесе дә мәңге дәвалап булмый торган чирдер инде ул...

Гарнизонга кайтып бүлмәләрендә юрган-ястыкларны түшәгәннәр генә иде, боларның йортына бер-бер артлы вестовой солдатлар йөгереп килеп җитте.

— Тревога! Германия гаскәрләре Советлар Союзына бәреп кергән!

— Сугыш! Сугыш!..

Һәр җан иясе кайнар суга пешкән кебек булды. Бөтен кеше сикереп аягына басты да плацка җыйналды. Ирләр — кайсы җәяүләп, кайсы атка йә велосипедка атланып — Петропавловскка чыгып йөгерделәр. Алда ни көткәнен һичкем белми иде, әлегә берәү дә хушлашырга ашыкмады. Хатын-кызлар төне буе мәйдан уртасында җыелышып торды, һичкем таралмады. Һәркем әкрен генә елый, баш очында хәвеф-хафа сөреме. Майор, полковник дәрәҗәсендәге офицерларның хатыннары гына әз-мәз сөйләшәләр.

— Әле былтыр гына Германия белән үзара сугышмау турында пакт төзегән идек бит. Ул немецлар ничек дәүләтара килешүне боза алдылар микән?

— Гитлер явыз бит, шул азына. Ярты Европаны йотып бетерде, тәгаме туя белми.

— Дошманны бүрекләр белән дә бәреп чыгарабыз, дип җырлый идек бит. Нишләп немецларны чик аша үткәрделәр микән?..

Таң атса, эчләрне жу иттерердәй өр-яңа хәбәр:

— Кибеттә бер ризык, бер товар калмаган. Хәзер һәрбер төрле ризык карточка буенча, паек итеп кенә биреләчәк икән...

Көндез полк штабыннан бөтенләй дә таныш булмаган политрук килеп җитте. Хатын-кызлар таралмаган иде. Моннан ары булачак тәртипләрне шул аңлатты.

— Германия безгә юлбасарларча, астыртын һөҗүм итте. Эшче-крестьян кызыл армиясенең бөтен көче хәзер немецларга каршы юнәлтелә. Моннан Япониянең дә явызларча файдаланырга омтылуы мөмкин. Гәрчә без апрель аенда гына Япония белән үзара тынычлык солыхы төзесәк тә, Япония Германия һәм Италия белән хәрби союз корды. Үзегез беләсез, япон солдатлары кул сузымында гына. Аларның иң якын

хәрби частьлары Шумшу утравында тора. Ирләрегезнең бөтенләйгә Лопатка борынына күченүе мөмкин. Ул очракта мондагы бөтен тормыш сезнең өскә кала. Камчаткада тыл юк. Сез барыгыз да иң алгы фронттагы сугышчылар.

## 3

Сугыш дөньяның астын өскә әйләндереп куйды. Гарнизонда офицерлар, солдатлар бөтенләй калмады диярлек, барысын да Лопатка борынына күчереп бетерделәр. Аннан өзек-өзек хәбәрләр генә килештереп тора.

— Болар урнашкан җир Петропавловсктан илле чакрым икән. Барысы да җир астына землянкалар казып яшиләр, ди. Ни төнлә, ни көндез учак якмыйлар, утлар яктыртмыйлар. Ризыкны читтән ташырга тиешләр дә, ләкин җүнле атлар фронтларга алынып беткән, техникалар өчен керосин-бензин юк, ди. Томан төшкән чакта учак ягып була, ә күп вакытта ирләр ач көенчә утыралар икән...

Ачлык гарнизондагы хатын-кызларны, бала-чагаларны да тиз бөтереп алды. Икмәккә карточка керттеләр, әмма анысы да көн дә булып тормый, сирәк кенә килә. Хатыннар ни табалар, шуны тупларга, тозларга тырышалар. Петропавловсктан кул арбасы тартып килүче кешеләр ешайды. Күбесенчә кета, горбуша сыманрак балыклар китерәләр. Йортында кем ни таба — кул йә булмаса стена сәгатеме, алка-беләзек, итек-туфли, тун йә бүрек, кофта-күлмәкме — барысын да ризыкка алышалар. Бер-берсен котырткан-өсләткән хәбәрләр чыгып кына тора.

— Майор Курбатов хатыны өч мичкәгә йөз килограмм балык тозлап куйган инде.

— Полковник Шеремеевның хатынына дивизиядән ике капчык сохари белән ике ящик тушенка җибәргәннәр.

— Капитан Котовның хатыны...

— Лейтенант Голубевныкылар...

Гел боларны тыңлап йөрсәң, көнләшүдән шартлап китүең бар. Зифа игътибар итмәскә тырыша. Күз тимәсен, үзе дә тик ятмый әле. Тәрәзә пәрдәләрен, мендәр-юрганнарны алмаша-алмаша кырык литрлы мичкәгә балык тозлап куйды. Аннары, гел ризык турында гына кайгыртырга вакыт та бик күп әләкми. Йортлар янында тәүлек буе сакта тору тәртибен керттеләр. Чиратлашып, төн саен икешәр хатын агач йортларның түбәсендә утырып чыга. Буш кына булмасын, формасы килсен, дигәннәрдер инде, июль азагында һәр йорт түбәсенә ком ташып өяргә чыгара башладылар. Зифаның көмәне шактый гына сизелә иде инде югыйсә, ләкин ташлама

ясап, кызганып торучы кеше табылмады. Зифа авыз эченнән генә саный-саный ташыды: ул берүзе генә дә йорт түбәсенә ике йөз чиләк ком мендереп куйды.

Бу эш бетүгә, бар халыкны бомбоубежище казырга куа башладылар. Йортлар янында түгел, гарнизоннан өч йөз, дүрт йөз метр читтәрәк, урман арасында. Җиренә күрәк тыкмалы түгел. Хәллерәк хатыннар әүвәл кәйлә белән ташны ватып чыга, аннары учлары, тырнаклары белән шуны чиләккә тутырып ташыйлар. Иртәнге биштә эшкә чыгалар, төнге ун тулганда гына туктыйлар. Көндез солдатларга тиеш паек күләмендә бер кат тамак ялгау. Бөтен кеше өйләренә көчкә кайтып ава.

Сентябрь башына монысын да ерып чыктылар. Җир астында колхоз фермаларына биргесез сарай хасил булды. Инде Петропавловск тирәсендәге бакчалардан кәбестәдән калган яфракларны җыеп тозларга гына ябышканнар иде, яңа әмер җиткереп сафка бастырдылар.

— Гарнизондагы һәр офицер хатыны шәфкать туташы курсларын тәмамларга тиеш. Япония белән сугыш чыга калса, һәркайсыгыз госпитальләргә эшкә күчәчәксез...

Көн буена сузылган укулар башланды. Тын алырга җай юк. Шулай да тырмаша, яшәргә тырыша кешеләр. Кичке караңгы төшкәч булса да барып, үз кишәрлекләреннән бәрәңге ташыйлар. Көмән борынга җитеп килә бит инде дип тормады, Зифа да көянтәләп бар бәрәңгесен ташып бетерде. «Зиннәтле тирес»нең хикмәте юк диген, бәрәңгеләрнең һәрберсе бала башы кадәр. Шатлык-елмаюны оныткан кешегә бу да зур сөенеч...

Ноябрь аена аяк басканнар гына иде, Зифаны тулгак тота башлады. Бабуринның хатыны көненә биш мәртәбә килеп хәлен белә иде, Петропавловсктагы дивизия штабына да телефон аша шул хәбәр иткән. Ләкин андагылар дөньяда бала табу дигән хәл дә барын онытканнар бугай, телефонның теге очындагы түрәләр ыжлап бирмәгәннәр. Шуннан яман яңалык әйтеп тегеләрнең өнен алган Шура:

— Уразметова аерым исәптә тора. Ул берьюлы өч игезәк табарга тиеш. Элек аны карап киткән врач шулай диде. Алай-болай була икән, трибунал китәчәксез!..

Ике-өч техниканың бензинын бергә җыйнап, бер йөк машинасын китереп җиткергәннәр. Хатыннар Зифаны бик тиз генә кабинага чыгарып утырттылар. Шофер юлда курка-йолка гына сораштырып бара:

— Чынлап та өч игезәк көтәсезмени сез? Корсагыгызга караганда бер дә алай түгел.

Зифа тора-бара гына аңышып өлгерде, рәхәтләнеп көлде,

әмма шоферга аны-моны сиздермәде. Кич белән җиһанга инде яңа кеше аваз салган иде...

Исламга ике-өч көннән соң гына хәбәр итеп өлгергәннәр, ахры. Розаның тууына нәкъ бер атна тулганда, ул да кайтып төште. Хатынының кайсы палатада ятуын сорашып ачыклый алмагандыр инде, Зифа аны тәрәзә аша гына күреп алды. Кайсы тәрәзәгә килеп сугылырга белмичә, бакча эчендә каңгырып йөри теге. Тышта яңгыр, пычрак, диңгездән җелегеңә үтәрлек җил исә. Әмма Ислам китми, һаман хәбәр көтә.

Зифа тәрәзә шакыгач шундук йөгереп килде. Ачлыктан бик нык интегәләр бугай, Ислам шешенеп беткән. Үзе бернигә игътибар итми, авыз гына ера.

— Ничәү анда синең, әллә өчме?

Зифа да бар дөньясын онытып көләргә мәҗбүр булды.

— Өнең алынмасын инде, пока берәү генә.

— Кем соң? Кызмы, малаймы?

— Кыз. Исемен Роза куштым.

— Молодец! Рәхмәт сиңа, Зифа!..

Зифа белән Роза икенче көнне генә хастаханәдән чыкты. Ислам машина әзерләп куйган иде инде, ләкин Розаны кочагына алуга ук, Зифаны читкә дәшеп, җитди сүз башлады:

— Японнар Владивосток белән ике араның миллион җиренә кордон куеп бетерде. Владивостоктан Камчаткага ни йөк, ни транспорт корабының килеп җиткәне юк. Инде менә ничә ай буена ризык китермиләр. Солдатлар ач, Петропавловсктагы бар халык ач. Үзеңә генә әйтәм, Лопаткада ике солдат шул ачлыкка чыдамыйча асылынып үлде. Менә, һәммәбез шешенә башладык, үзең дә күрәсеңдер...

Зифа һәммәсен дә күрә, әмма Исламның тел төбен генә һич кенә дә аңлый алмый иде. Тешен кысып көтте.

— Фронтта да эшләр хөрти, немец Мәскәүгә якыная, диләр. Мондагы бер-ике полкны Мәскәү тирәсенә күчерүләре мөмкин. Үзләре гариза язып биргән кешеләр иксез-чиксез. Монда ачлыктан аяк сузганчы фронтка китү хәерлерәк сыман. Мин дә гариза яздым. Алай-болай мине алып китсәләр, ялгызың каласың бит. Шуңа уйлап йөрим. Сине монда мин өстерәп алып килдем, димәк, мин үк сине моннан озатырга тиеш. Навигация сезоны тәмамланып килә, тиз арада Петропавловсктан соңгы пароход китәчәк. Әйдә, йә дивизия командиры, йә диңгез базасының башлыгы янына кереп чыгыйк. Ышанам, алар сабый бала күтәреп кергән хатынга каршы килəчәк түгел.

— Сине ташлап мин соң кая барыйм? Юк, мин китмим, — дип, Зифа авызын җәеп елый да башлады. Мондый адым Исламны ярсыта гына төште.

— Җүләрләнмә инде, Зифа, сиңа әйтәм. Мин полктагы беренче снайпер бит. Инде алтымы, җидеме гариза язып бирдем. Бүген булмаса, иртәгә мине барыбер фронтка алачаклар. Мин дә китсәм, сез, Роза белән икегез, Камчатка уртасында ачтан үләсез бит...

Ислам кат-кат үгетли торгач, ниһаять, Зифа сынды. Петропавловсктагы диңгез базасының башлыгы контр-адмирал Пономарев икән. Ни хикмәттер, Ислам белән Зифаны тоткарлыксыз-нисез кабул итте. Кулларына тотып кергән гаризага да шундук тамга салды.

— Әйе, сезгә яшь балагыз белән туган җирегезгә кайту хәерлерәк булыр, — диде ул әллә нигә Зифаның йөзенә күтәрелеп карамыйча гына. — Мондагы хәлләрнең катлаулanып китүе дә бар бит...

## 4

Соңгы пароход нәкъ бер атна үтеп киткәч кенә юлга чыкты. Ислам ул арада махсус сандыклар ясатып өй эчендәге бар байлыкны шуларга тутырып кына калмаган, аларны алдан ук Петропавловскка китереп тә куйган иде инде.

— Монысында кием-салым, монысында ризык, — дип катат аңлатты ул. — Байлык дип чукынма, Роза белән синең гомер өчен кирәк икән, барысын да ашамлыкка алмаш. Байлык килә дә китә, гомер бер генә ул...

Трап янында елашмыйча гына, җиңел хушлаштылар. Күбесенчә Ислам тезде инде:

— Юлда үзеңне дә, баланы да сакла. Мин фронтка китсәм дә, миңа пычак та булмый. Мин полктагы беренче снайпер, миңа каршы торырдай бәндәнең дөньяга туганы юк. Минем өчен кайгырып ятма, берзаманны буран сыман ажгырып кайтып керәчәкмен. Башкортстанга, иң яхшысы, кире Сарайлыга кайтып керүең әйбәтрәк тә инде. Мәгәр алай итмә, лутшы Сүнәйгә кайт. Анысы минем инәйләрнең авылы, ярты авыл туган. Илдә чыпчык үлми, сезне дә сыендырырлар...

Юлчылар Шумшу утравы белән Лопатка борыны арасындагы бугаз аша үткән чагында ук капылт сагайдылар. Ике якта да биек яр өстенә зур-зур көпшәле туплар тезелешкән. Бер якта совет флагы җилферди, утрауда — японныкы. Болар ут ачса, Зифалар утырган бәп-бәләкәй «Ильич» пароходы белән аңа ияргән «Минск» йөк корабын гына түгел, бер-бер урнашкан сопка-биеклекләрне дә күз ачып йомганчы кырып бетерер сыман.

Пассажирлар арасында зур-зур офицерларның да ха-

тыннары бик күп. Шумшу утравы ягына карап, шулар, иреннәрен кысып, усал сөйләнәләр:

— Бу японнары да, чепи күзләр, тик кенә ятмыйлар бит. Ике арада пакт бар дип тормыйлар, ничә совет корабын батырдылар инде. «Ангара», «Беларусь», «Обь», «Балтика», тагын әллә ничәү.

— Әнә Шумшу ягына ныклап текәлеп карагыз. Әнә теге Алошд вулканы ягына. Яр астында бер кораб күренәме? Японнар сайлыкка куып керткән безнең танкер бит ул, «Мариуполь» танкеры. Безнең башны да ашамасалар гына ярый инде...

Шулай хәвефләнеп юлга чыгып китү юкка булмаган икән. Охот диңгезен үтеп Лаперуза бугазына кергүгә, «Ильич» белән «Минск» корабларының икесен дә өчәр-дүртәр япон крейсеры әйләндереп алды. Болар азган, былтыргы шикелле генә кыйланмыйлар. Ике шлюпка белән килгән япон моряклары әүвәл «Ильич»тагы бөтен каюта-трюмнарны айкап чыкты. Моның пассажирлар корабы икәнлегенә инандылар бугай, аны җибәрделәр. Ә «Минск»ны болар кичкә кадәр, кат-кат тентеделәр. Алай да канәгать калмадылар, ахры, «Минск»ны тимер арканнарга тагып, әллә кайдагы базаларына тикшерергә алып киттеләр. Зифаның төягән бөтен сандыклары «Минск»та иде, ул шуңа ут йотты. Ләкин японнар бернәрсә дә таба алмаганнар, күрәсең, берәр тәүлектән соң рация аша «Минск» азат» дигән хәбәр килеп җитте.

Владивостокка унике тәүлек дигәндә генә килеп элгәштеләр. Тимер юл вокзалына төшсәләр, андагы халык умарта күче сыман. Кайсы Советская Гаваньнан килеп төшкән, кайсы Находкадан. Һәммәсенә йә Мәскәү ягына, йә Урта Азиягә китәргә билет кирәк. Кайберләре инде ике ай буена шушында ята икән. Владивостоктан фәкать хәрби эшелоннар гына китеп тора, бер генә дә пассажир йә булмаса йөк поездлары туры килгәне юк, ди.

Зифа кайгырмады. Әле «Минск» пароходын көтеп җиткерәсе, андагы сандыкларны эзләп табасы бар бит. Уен-муен түгел, «Минск»та шыплап тутырган бер сандык ашамлык, бер сандык кием-салым. Икенче сандыктагы байлыкны да ризыкка алыштырсаң, озын кышны бер кайгысыз көе чыгып була.

Ләкин бер тәүлек узып китте, икенче, өченчесе, ә «Минск» пароходы һич күренми. Юлчылардан өч-дүрт хатын җыелып порт башлыгы янына кергәннәр иде, теге кул гына селти.

— «Минск» әүвәл Находкага кереп күмер төяргә тиеш, аннан гына монда килеп җитә...

Күзләрен талдырып, «Минск»ны бер атна көттеләр. Теге төнлә килде. Экипажы ярга коелды да шәһәргә таралып бетте, Петропавловск хатыннары белән сөйләшүче кеше табылмады.

Икенче көнне төш вакыты җиткәч кенә трюмнардагы йөкне бушата башладылар. Камчаткадан килгән барча халык шунда, һәммәсе дә дүрт күз белән үз байлыгын көтә. Менә яр өстенә дистәләгән мичкәләр тезелешеп басты, чемодан-капчыклар өелде. Һәркем үз квитанциясенең номерын кычкыра-кычкыра тартмаларын, мичкәләрен, капчыкларын эзли. Табучыларның авызлары ерыла, алар бәхетлеләр.

Зифа пирс өстендә уңга-сулга йөгереп көтә иде, аның лар шикелле зур-зур сандыклары да пәйда булды. Исламның «монысы — ашамлыклар» дип тамгалаган сандыгында йозаклар исән-имин, ә кием-салым дигәнендә йозак бөтенләй юк, тимер бикләрен дә умырып ташлаганнар. Сандык эчендәге байлыктан, әлбәттә, җилләр искән, андагы кием-салым урынына кирпеч тутырганнар.

Зифа бетон пирс өстенә сыгылып төште дә ачыргаланып-үксеп еларга тотынды.

— Совет моряклары түгел, пират бит сез. Үзегезнең совет кешеләрен, хәрбиләрнең хатыннарын талыйсыз. Без моны болай гына калдырмыйбыз, порт начальнигына кереп әйтәбез, милициягә әйтәбез! — дип, берничә офицер хатыны капитан белән аның ярдәмчеләренә янап-кычкырып та карады, корабта моңа ыжлап бирүче кеше табылмады. Бичара Зифа исән калган ашамлык сандыгын өстерәп китәргә мәҗбүр булды...

Тимер юл вокзалында бер айга якын вакыт интектеләр, ә Мәскәү ягына кузгалучы бер поезд юк. Беркая китеп булмый, көннәре-төннәре гел вокзалда үтә. Розаның тәненә диңгез җиле үтеп кергән, ахры. Сабыйның ике як яңагы, муены шешеп чыкты, юньләп имә дә алмый. Үз генә йоклап ала да уянуга илереп-илереп елый. Зифа аның белән шәһәр хастаханәләренә дә, порттагы һәм вокзалдагы медицина пунктларына да сугылып карады. Берсендә дә юлчы сабыйны рәтләп караучы, юньле-башлы дару бирүче юк. Зифа шәһәр хатыннарыннан ярмага, шикәргә алыштырып алган кура җиләге суы белән генә рәткә кертте аны.

Инде Розаны савыктырган сыман булган иде, үзе чирләп егылды. Яңа гына бала тапкан көе юлга чыгу, диңгез салкыны кырын суккан, ахры, Зифа берзаманны ут шикелле яна башлады, хәтта вакыт-вакыт аңын да югалтып тора. Ходайның рәхмәте, әле ярый пароходта бергә килгән бер офицер хатынының Владивостокта туганы бар икән. Теге офицер

хатыны белән бергә кайтып, шунда урнаштылар. Түшәктә ауный-ауный бер ай чамасы вакыт үтеп китте. Аякка басса, тимер юл вокзалында Исламнан телеграмма:

— Безне фронтка җибәрмәделәр, беркая да китмә. Озакламый махсус йөк алырга Владивостокка барачакбыз. Сезне дә үзем белән кире алып китәм...

Ислам килгәнче янә бер ай үтеп китте бугай. Бу вакытта Петропавловсктан төяп килгән ризыкларның эзе дә калмаган иде инде. Әмма Ислам килеп төшкәч, бары да онытылды. Алар ач-ялангач, ләкин элеккечә бергә, шуның белән бәхетлеләр иде.

## 5

Кырык бишенче елның маенда көнбатышта сугыш тәмамланды.

Унынчы май төне башланган, Лопатка борынындагы хәрбиләр землянкаларына кереп ауганнар иде инде. Кисәк кузгалган канонада тавышын ишетеп, һәммәсе дә тышка атылып чыкты. Һәрбер сопка саен зениткалар тора, шулар ак-караны күрмичә, урата-урата төрле якка ут яудыра иде. Солдатларны хәвеф чолгап алды.

— Әллә японнар десант-мазар ташладылар микән?

— Мөгаен дә, Япония белән сугыш башлангандыр...

Беркадәр вакыттан соң гына штабтан офицерлар йөгереп килеп җитте.

— Ур-ра, җиңү! Фашист Германиясе белән сугыш тәмамланды!

Барча кеше кычкыра, елый, бер урында тора алмыйча бии үк башлады. Дүрт ел буе землянкада яшәү аеруча Камчаткада гаиләсе булган хәрбиләрнең үзәгенә үтеп беткән иде. Шулар җиңү шатлыгыннан гаиләләре янына кайтырга, күрешергә рөхсәт көттеләр. Тик болар турында уйлаучы табылмады. Хәрби фәрман һәр очракта кырыс, аны тикшереп маташулар, гөманлаулар рөхсәт ителмәгән.

— Япония белән мөнәсәбәт үтә киеренке. Союздашы Германиянең җиңелү кайгысыннан йә булмаса Советка үч итеп, Япониянең һөҗүм башлавы бар. Һәрбер солдат белән һәр офицер үз постында кала. Барча кешегә беренче номерлы сугышчан хәзерлек...

Атна артыннан атна үтә торды. Һәр тарафта билгесезлек, төшенкелек кенә хөкем сөрә. Һичкемне җыючы, берни аңлатучы юк. Июль ае кергәч кенә беренче кайнар хәбәрләр ишетелә башлады.

— Германия белән сугыштан бушаган гаскәрләрне

Көнчыгышка күчерәләр, Япония белән сугыш башланачак икән.

— Ерак Көнчыгыш хәрби округының Башкомандующие итеп маршал Василевский билгеләнгән. Японнарга каршы округ кадәр округ төзеп куйгач, хәлләр була инде...

Шундый хәбәрләрдән соң Камчаткадагылар да үзләренә өстәмәгә полк-дивизияләр, туп һәм зениткалар, өр-яңа кораблар өмет иткән иде. Тот капчыгың! Камчаткада да совет кешеләре яшәп ятуын онытканнар, күрәсең. Владивосток ягыннан армада-флотилияләр түгел, сыңар катер да юк. Аның караවы акланулар-юатулар чутсыз.

— Япон самурайлары бик агрессив, Камчаткага таба бер кораб үткәрмиләр, аларны порттан чыгуга ук бомба яудырып батыралар икән.

— Япон — юньсез. Сугыш вакытында, антын бозып, совет шәһәрләрен-авылларын биш йөз мәртәбә бомбага тоткан бит...

Алтынчы август кичендә рация аша коточкыч хәбәр килеп иреште.

— Американыкылар Япониянең бер шәһәре өстенә атом бомбасы ташлаганнар...

Тугызынчы августта берьюлы ике хәбәр:

— Американыкылар Нагасаки шәһәренә нәкъ шундый ук бомба ташлаганнар.

— Совет гаскәрләре Япониянең Квантун армиясенә каршы сугыш ачкан...

Солдатлар, офицерлар арасында күзгә күренеп киеренкелек артты. Камчаткадагы командирлар да капылт батырайдылар. Көненә әллә ничә мәртәбә Лопатка борынындагы диңгез тупларыннан Шумшу утравы өстенә ядрә яудыралар. Японнар да җавапсыз гына тормый. Дага сыман җәелгән Нанагава бугазының ике як ярында урнашкан туплардан аткан ядрәләр блиндажларны, землянкаларны әйләндереп сала. Японнар Лопатка борынының картасын шәп белә, күрәсең. Алар ут ачкан саен, Лопаткада мәхшәр, канонада саен үлем-китем.

Лопаткада хәзер һәркөн саен, колак тырпайтып, яңа хәбәр көтәләр. Ходайга мең шөкер, яңалыклар сәгать саен агылып кына тора.

— Совет гаскәрләре Маньчжуриядә Квантун армиясен бирелергә мәҗбүр иткәннәр.

— Генерал Пуркаев белән адмирал Юмашев гаскәрләре Көньяк Сахалин белән Төньяк Кореяны япон самурайларыннан азат иткән...

Ниһаять, унбишенче август кичендә иң көтелгән хәбәр:

— Япониянең хөкүмәт башлыгы Судзуки үзенең гаскәрләренә берсүзсез бирелү турында фәрман биргән. Империалистик Япония белән сугыш тәмамланды...

Шул сәгатьтә үк офицерлар, солдатлар арасында сугышканнан соң гына, йодрык болгаучы калай әтәчләр күренгәли башлады.

— Бәрәч, бәрәч! Самурайлар белән сугыш беттемени инде? Шушылай мылтыктан бер тапкыр атмыйча да кайтып китәбезме? Вәт әкәмәт! Туганнарың, авылдашларың каршына ни йөз белән кайтып күренерсең?

— Нишләп Мәскәү генераллары безне күз чалымына да китереп тормады соң әле? Без дүрт ел буе землянкаларда бет үрчетеп кенә яттыкмыни? Хәзер буш түш, коры кесә белән кайтып китикмени? Гарьлек, гарьлек!..

Юк, гади солдат белән сержантлар гына бу рәвешчә уйламаган икән. Шул унбишенче августның төнендә үк дивизия штабыннан фәрман килеп җитте.

— Йөз дә беренче полкка кичекмәстән Петропавловскка чыгарга! Барча төр сугышчан коралны үзегез белән алырга!

Петропавловскка таң атканда килеп җиттеләр. Шундук коммунист офицерларга өлкә комитетына җыйналырга әмер булды. Ислам инде кырык беренче елның көзеннән үк взвод командиры иде. Плащ-палатка астындагы старшина погоннарын бик ялтыратмыйча гына ул да комитет бинасына кереп китте.

Зал халык белән шыгрым тулы. Гади костюм-чалбар кигән унлап ир-ат, ике-өч хатын-кыз бар, калганнары бары да хәрбиләр. Арада күбрәк полковниклар, майорларның погоннары ялт-йолт килеп тора. Һәммәсе дә тәкәббер һәм аз сүзлеләр.

Сәхнәгә куелган президиум өстәле артына бервакытны җитәкчеләр, генерал-адмираллар тезелешеп чыкты. Ислам Камчаткада ун ел хезмәт итә бит инде, күбесен яттан белә. Партия өлкә комитетының секретаре Елисеев, хәрби-диңгез базасы башлыгы адмирал Пономарев, Исламнарның дивизия командиры генерал Дьяков, Камчаткадагы барча хәрби көчләр Башкомандующие генерал Гнечко, тагын бер-ике түрә. Ни хикмәттер, беренче сүзне генераллар түгел, өлкә комитет секретаре алды:

— Япониянең премьер-министры Судзуки үзенең гаскәрләренә корал ташларга фәрман бирсә дә, самурайлар һәр җирдә дә аңа буйсынырга ашыкмыйлар әле. Япониянең императоры бер сүз дәшми, ә самурайларның флотилиясе белән авиациясе, шуннан файдаланып, Тын океандагы, Охот һәм Япон диңгезләрендәге безнең корабларны утка тота. Соң-

гы бер атнада гына да япон самолетлары безнең Находкадагы, Совгаваньдагы егермеләп корабльне батырганнар, диләр. Курил утрауларында да, Япониянең иң төньяктагы Хоккайдо утравында да дистә меңәрләгән самурайлар сугышчан хәзерлек хәлендә тора, аларның корал ташларга, совет командованиесенә буйсынырга һичбер исәбе юк. Без ике сәгать элек кенә радио аша Генераль штабтан җентекләп аңлатылган күрсәтмәләр алдык. Америка президенты Трумэн белән аларның башкомандующие генерал Маккартур, безнең союзниклар булуга карамастан, Курил утрауларының берсен эләктерергә һәм анда үз аэродромнарын төзеп куярга хыялланалар икән. Без, әлбәттә, моңа юл куя алмыйбыз. Курил утраулары ул гомер-гомергә рус җирләре, безнең байлык иде. Японнар ул утрауларны утыз-кырык ел элек кенә кулга төшерделәр. Без аларны кабат японнардан азат итәргә тиешбез. Бу — киләчәк буыннар каршындагы тарихи бурыч. Дүрт ел буе землянкаларда газап чиккән совет солдатлары да самурайлардан үч алырга сусаган, һәр сугышчы, ярсу ат шикелле, яуга ыргылып тора. Камчаткадагы хәрби көчләр дә Бөек Ватан сугышы тарихында мактаулы, зур җиңүләр белән эз калдыруга лаек. Яуга сусаган совет солдатларының сугышчан рухы, горурлыгы, дәрте белән шаярырга һичбер хакыбыз юк. Партия өлкә комитеты һәм Камчаткадагы ныгытылган хәрби район «кичекмәстән Курил утрауларын японнардан азат итәргә» дигән карар кабул итте. Хәзерлек башланды, без ике-өч көннән соң яуга керәчәкбез...

Аннары, хәрби дәрәҗәсе буенча тиеш булгач, Камчатканың иң төп генералы Гнечкога сүз бирделәр. Монысы, әлбәттә, нотыгын кыска, төгәл тотты, күбесенчә алда торган бурычларга аңлатмалар бирде:

— Иң беренче чиратта, безгә Лопатка борынына каршы торган Шумшу утравын японнардан бушатырга кирәк. Шунсыз аннан ары тезелешеп киткән Парамуширга да, Онекотан, Матуа, Уруп, Итуруп, Кунашир утрауларына да юл юк, алар йозакка бикләнгән. Японнар кулындагы утрауларга разведчиклар ярдәмендә үтеп керә алмадык, самолетлардан күзәтүләр генә алардагы көчне беркадәр ачыклады. Озынлыгы егерме, киңлеге унөч чакрымга сузылган бер Шумшу утравында гына да сигез меңгә якын самурай тупланган. Утрауда кечкенә-кечкенә генә биш аэродром, Нанагава бугазының ике як ярында, дот-дзотлар белән ныгытылган Кокутан һәм Котомари борыннарында ике хәрби-диңгез базасы бар. Японнарның төньяктагы барча хәрби көчләр башлыгы генерал-лейтенант Фусаки да Котомари базасында тора. Башлык

шунда булгач, билгеле ки, утрауны үзләренчә мәңге яулый алмаслык крепостька әверелдергәннәр. Авиация хәбәр итүе буенча, Шумшуның бер үзендә генә дә алтмышка якын дот һәм дзотлар, бетонга төрелгән өч йөзләп туп һәм пулемет ноктасы бар, ди. Дөрес булса, самурайлар җир астында госпитальләр, электр станцияләре, элемтә үзәкләре, бомбоубежищелар, складлар төзеп бетергәннәр. Җир асты тоннельләренең тирәнлеге урыны-урыны белән илле метрга кадәр төшеп җитә икән. Әмма япон самурайлары совет солдатларының үченнән качып калу, котылу турында юкка хыяллана. Совет солдатларының штыклары үтеп керми торган бастион юк. Совет солдатлары мәңге үтә алмаслык булып күренгән кыяларны да яулый...

Ислам киңәшмәдән соң диңгез порты ягына юнәлде дә, яр өстенә басып, гел шаккатып торды. Порттагы дүрт причалның һәркайсына берешәр кораб бәйләп куйганнар. Һәрбер кораб, һәр причал өстендә кеше кайный. Гимнастеркалары тозланып чыккан солдатлар, причал докерлары, брезент алъяпкычлар киеп алган балык комбинаты эшчеләре, чаналарының табаннарына күн кидереп, этләр җигеп килгән камчадаллар, шәфкать туташлары курсларына укырга йөрүче яшь-җилкенчәк... Барысы да, артларына ут капкан шикелле ашыга-ашыга, кораб бушаталар. Сүзсез дә аңлашыла, әлеге корабларны Шумшу утравын штурмларга әзерлиләр инде. Әнә диңгез култыгындагы рейдта тагын унбиш-егермеләгән кораб көтеп тора. Ләкин нинди‍ләр бит? Кайсы бортлары-палубалары тишелеп беткән йөк корабльләре, кайсы еллар буе ятьмә тартып йөргән балык тотучылар. Арада үзйөрешле баржалар, эреле-ваклы катерлар, хәтта моторлы шлюпкаларга чаклы бар. И Ходаем! Мондый ярык тагараклар белән ничек итеп японнарның бетон дот-дзотлар белән ныгытылган крепостьларын алып булсын инде?..

Үзе дә аңламый-тоймыйча Ислам уйга калды. Судзуки корал ташлау турында әмер биргән, япон императоры берсүзсез капитуляция актына кул куярга әзерләнә, диләр. Соң, сугыш бетте, кан кою тәмамланды, дигән сүз бит инде бу. Алай булгач, бу Елисеев, Гнечколар кая ашкына соң? Түшләренә өстәмә медальләр, погоннарына яңа йолдызлар әләктерергәмени? Ләкин нигә гади солдатлар гомере хакына, кара гавам бәрабәренә? Институтлар, академияләр тәмамлап тору да кирәкми. Сукыр булмаган, аек акыллы кеше болай да чамалый. Ярык тагарак бәрабәрендәге бу баржалар, катерлар, шлюпкалар белән япон позицияләрен, япон дзотларын яулап булмаячак. Сарык көтүе сыман куылып кертсә-

ләр дә, чебен урынына кырылачак халык. Шуны белә торып, шуны күрә торып, бу генераллар ниемә дип яуга ашкыналар? Алар үзләре ут астына керми, алар кабинетларында, йомшак кәнәфиләре өстенә утырып торачак, ә яу кырында меңәрләгән гап-гади солдатлар, яклаучысыз кешеләр һәлак булачак бит. Нишләп болар чит-ят кешеләрнең гомерен кызганмыйлар?

Ярар, ул Шумшу, Итуруп, Кунашир утрауларын японнардан тартып алырга, кабат үзебезгә кайтарырга кирәк булсын да, ди. Мәгәр сугыш хәрәкәтләре туктатылды, ул Маньчжурия, Корея, Сахалиннарда гына да меңәрләгән самолетлар тик тора бит инде. Германиядән бирле төяп килгән бомба-снарядлар эшелоны-эшелоны белән артып калган булырга тиеш. Соң, менә шул бомбаларны төяп, кырык-илле самолетны Шумшудагы Фусакилар, башка япон түрәләре өстенә җибәреп булмыймыни? Курил утраулары алай бик кирәк икән, әнә шул самолетлар, шул бомбалар белән көннәр буе, атна буе чүке, из, бетер, юк ит самурайларны! Иманнарын тет, самурайлар үз гомерләрендә кабат кулларына корал тотарлык булмасыннар! Ләкин бер гөнаһсыз, бөтенләй хәзерлексез совет солдатларын гына тоташ ут яңгыры, үлем дәһшәте астына илтеп кертмә!..

Ислам кичкә кадәр порт буенча әрле-бирле сугылып йөрде дә, бөтен дөньясына төкереп, кулын селтәп гарнизонга, Зифа белән Розасы янына кайтып китте.

— Рөхсәт бирмиләр икән, бирмиләр. Трибунал тек, трибунал. Үз газизләрем белән дә хушлашмыйча үлем авызына кереп булмас инде. Әллә калам әле, әллә үләм? Ичмаса, соңгы тапкыр суырып бер үбәрмен.

## 6

Ислам кайтып кергән чакта, Роза йоклый иде. Әтисенең санаулы минутларга гына кайтканын сизеп алды бугай, ишек шыгырдап ачылуга сикерде дә торды. Бернинди күчтәнәч тә өмет итми, балакай. Әүвәл әтисенең муенына барып асылынган иде, Ислам карават почмагына утыргач, куян баласы кебек бөгәрләнеп, куенына сеңде. Зифа һич югы айга-елга бер мәртәбә булса да иренә кайнар аш ашатмакчы булып кузгалды, тик Ислам аны да туктатты.

— Мин бик азга, сезне күрергә генә кайттым. Хафаланма, чапма. Әйдә, тик кенә утырыйк та бер-беребезгә карап калыйк әле.

Зифа каршына килеп утыргач, Ислам аның ике кулын да

учларына алды. Әле бармак битләре белән сыйпады аларны, әле берәм-берәм иреннәренә тидереп, уйга батып торды. Шактый вакыт буе хәрәкәтсез-сүзсез утырганнан соң гына, ипле, йомшак тавыш белән Ислам телгә килде:

— Бик тә авыр, бик хәвефле чорда кавышсак та, миңа хатын назы, гаилә җылысы күрсәтергә өлгердең, рәхмәт сиңа, Зифа. Егерме җиде ел гомерем сукбайлыкта, буйдаклыкта үтеп киткән иде. Соңгы берничә айларда булса да ятимлектән, ялгызлыктан арындым, шуңа нык сөенәм. Инде минем белән алай-болай була калса, бала турында кайгырт. Кеше үз тормышында нинди генә югалтулар кичерсә дә, иң мөһиме, әнисеннән аерылмасын икән ул. Берүк, берүк Розаны ташлый күрмә, гомереңнең соңгы сулышыңача аның хакына яшә.

— Сугыш бетте бит инде, Ислам. Нишләп үлемгә-яуга китәргә җыенган кеше шикелле сөйләшәсең әле? — дип, Зифа бүлдергән иде дә, бармакларын иреннәренә тидереп, Ислам аны шундук туктатты.

— Канга сусаучылар җанварлар арасында гына түгел, кешеләр арасында да җитәрлек. Без йә иртәгә, йә берсекөнгә яуга керәбез, Зифа. Шумшу утравын барып яулаячакбыз. Ләкин бу турыда мин сиңа берни әйтмәдем, Зифа, авызыңны бикләә. Хәер, пароходларга төялә башлагач, моны барыбер халык күзеннән яшерә алмаслардыр. Мөгаен, озатып калучы хатыннар, якыннар да табылыр. Күз яшьләрен, елап аерылышуларны минем җенем сөйми. Мине менә шушында гына озатып калырсыз. Кабат шушында кайтып керергә язсын...

Берәр сәгать чамасы утырганнан соң, Ислам урыныннан купты. Роза аның кочагында йоклап киткән иде, чут-чут суырып үбеп, Ислам аны янә уятты.

— Йокы — кешелекнең беренче дошманы, Ястыкбикә булулардан сине Алла сакласын, кызым. Бәхетеңне йоклап үткәрә күрмә.

Ишек катына юнәлгәч, Ислам Зифаны кайнар кысып кочагына алды. Карашлары дымлы, уйчан иде.

— Мин сезнең белән бик бәхетле булып яшәдем. Гомеремнең иң шатлыклы көннәре сезнең белән үтте. Рәхмәт сиңа, Зифа. Ул-бу була калса, миңа рәнҗеш-үпкәләүләреңне саклап йөрмә. Ничек булдыра алсам, шулай сөйдем. Ничек булдыра алсам, шулай яшәдем. Калганы, бәлки, миннән дә тормагандыр. Хуш һәм бәхил бул, газиз Зифакаем.

Ислам Роза белән Зифаның икесен дә кайнар итеп суырып үпте дә караңгылык эченә атлап чыгып китте.

## 7

Петропавловскта пароход-катерларга төялү ике тәүлек буе туктаусыз дәвам итте. Унсигезенче август кичендә барча командирларны да диярлек «Дзержинский» дигән корабка чакырдылар. Бу — шәһәр каршында рейдта торган хәрби корабларның иң олысы, аның берүзенә генә дә уналты туп урнашкан һәм, иң мөһиме, Курил десантына җитәкчелек итәчәк иң төп штаб шул корабта икән.

Шлюпкага утырып Ислам корабындагылар килеп җиткән чакта, «Дзержинский»ның өске палубасына өч йөзгә якын офицер һәм старшиналар җыйналган иде инде. Күбесе лейтенант, капитаннар. Полковник, подполковник дәрәҗәсендәгеләр бик санаулы гына. Адмирал-генералларның исе дә юк, дияр идең, палуба уртасына чыгарып куелган зур өстәл артында сыңар генерал-майор утыра. Бу кеше йөзе белән борылгач, Ислам гаҗәпләнеп куярга мәҗбүр булды. Генерал — Исламнарның дивизия командиры Петр Дьяков иде.

— Генерал Дьяков Курил десанты белән җитәкчелек итәчәк. Петропавловсктан Шумшуга кадәр корабларны ул әйдәкләп барачак,— диделәр.

Ислам аптырап баш чайкады. «Дьяков — коры җирләр, заставалар башлыгы бит. Аның үз гомерендә диңгездә йөзгәне юк. Хәзер, десант вакытында, корабка менгән тавык үрдәкләрне суда йөзәргә өйрәтәчәкмени?..»

Дьяков офицерларны корабның алгы күперчегенә чакырды.

— Совет халкының каһарманлыгын карагыз, күрегез, иптәш командирлар. Партия өлкә комитеты белән Камчатка хәрби районы җитәкчеләре тиз арада алтмыш дүрт данә һәртөрле кораблар, катерлар, шхуналар тапты. Шуны бөтен шәһәр халкы белән берлектә ике тәүлек эчендә төяп бетерделәр. Һәрбер йөзү средствосында япон позицияләрен утка тотар өчен туплар, пулеметлар бар. Солдатларга Шумшу утравында тизрәк хәрәкәт итү, авыр орудиеләрне сөйрәп йөрү өчен зуррак корабларның трюмнарына утыз баштан алып илле башка кадәр атлар да яшерелде. Империалистик япон самурайларына каршы яуга ыргылучы ирекле сугышчыларны тотып туктатырлык түгел. Ләкин алтмыш дүрт йөзү средствосына барлыгы егерме мең сугышчы утыртылды инде, артыгы белән җиткән. Ярты сәгатьтән соң строй белән юлга чыгабыз. Корабларда утлар яндырмаска! Безнең төп отыш — сиздермәстән һөҗүм. Шумшу утравының Кокутан белән Котомари калкулыкларына беренче булып совет байрагы кадаган геройларны алтын медаль көтә...

Кабат шлюпкага төшеп киткәнче, Ислам Авача бухтасында рейдка тезелешеп баскан корабларны тагын бер мәртәбә күздән кичереп чыкты. Сугыш-яу өчен бөтенләй әзерләнмәгән «Север» дигән йөзү базасы, «Аккош» белән «Полярный» дигән гидрографик суднолар, алты-җиде үзйөрешле баржа, биш-алты катер, өч тральщик, җиде-сигез моторлы шлюпка. Шулар янәшәсендә әле ярый унбиш-уналтылап десант кораблары, унга якын чик буе катеры бар. Арада бер генә крейсер да юк, линкор да юк, торпеда катеры юк. Йа Ходаем! Шушы адмирал Пономарев, генерал Дьяковлар шапырынган нинди армада, флотилияләр булсын инде?

Ислам кораб-катерларны тиешле состав белән тутырган чагында да күзәтеп торды бит. Кемнәрне, нинди бәндәләрне генә җыеп бетермәделәр? Үз гомерендә хәрби кораб палубасын күрмәгән чик сакчылары, диңгез туплары һәм эре калибрлы пулеметларның кайсы ягыннан килергә кирәклеген дә белмәгән балык комбинаты белән җеп эрләү фабрикасы эшчеләре, причал докерлары, чаналары белән этләреннән аерып утыртылган җирле камчадаллар, җиде-сигез айлык шәфкать туташы курсларының ике-өч аен гына ерып чыккан япь-яшь кызлар... Шушындый «десантчылар, каһарманнар» белән бетон япон дзотларын ничек яуларбыз соң?..

Ислам, кораблар кузгалгач та, яшь кенә солдатларны, докерларны, эшчеләрне күзәтә-күзәтә, гел аптырап йөрде. Әллә каян гына корабларга метры-метры белән кызыл төстәге чүпрәкләр китергәннәр. Палуба, трюм саен әллә ничәшәр егет гимнастерка астыннан күкрәгенә шул чүпрәкне урый. Болар, валлаһи да, беренче булып ярга сикерергә, сопкалар өстенә байрак кадарга, ахырда алтын медаль эләктерергә исәп тота инде...

Әмер булгач, әлбәттә, юлда капитан күперчекләренең, прожекторларның барысын да сүндереп бардылар. Корабларның кильватер утлары гына вакыты-вакыты белән кушылып алды, аларына карт моряклар зәңгәр капкач кидергәннәр иде. Петропавловск белән Лопатка борынына кадәр булган араны да хәвеф-хәтәрсез генә уза алмадылар. Төн уртасында күзгә төртсәң күренмәслек булып куе томан яткач, «Диңгез мәчесе» атлы хәтәр исем йөрткән катер белән бер десант корабы бәрелеште. Десант корабы бортын тишкән, трюмга су тула башлаган икән, «Диңгез мәчесе» аерылып калды.

Кораблар Лопатка борыны янына килеп җиткәч, коры җирдә урнашкан барча диңгез туплары Шумшуга төбәп ут ачты. Коточкыч тавышлары белән генә дә чәчләреңне агар-

тырлык туплар егерме биш минут буена япон позицияләрен «үтүкләде». Томан аша һични күренмәсә дә, утрау ягыннан дөп-дөп, чарт-чорт килеп шартлаган ядрә авазлары ишетелеп тора, шуннан алган тантана һәм дәрт хисләре булачак десантчыларны да җилкендерә иде.

Төнге сәгать икеләр тирәсендә Шумшу утравының Нанагава бугазына килеп керделәр. Төн бик караңгы булса да, куе томан ятса да, урыны-урыны белән, Кокутан һәм Котомари калкулыкларында урнашкан япон хәрби базаларының утлары җемелдәп күренеп ала.

— Корабларны бушатырга һәм штурмга әзерләнергә! Әмма яр өстенә чыгып җиткәнче ялгыш та ут ачмаска! — дигән әмерләр ишетелде.

Юк, яр буена барып җитә алмадылар. Әле ярга йөз, ике йөз метрлар калганчы ук кораблар чытырдап-гөпелдәп сайлыктагы ком-таш өстенә утыра башладылар. Командирлар да, политруклар да кызган иде инде. Шауламаска тырышып, гыж-гыж килеп җиткергән әмерләре төнге тынлыкта яңгырап ишетелде.

— Сугыш кирәк- яракларын үзегез белән алыгыз да суга сикерегез! Ярга чыгу белән, мөмкин кадәр зуррак плацдарм эләктерергә. Алга, иптәшләр, алга!

Десантчыларга инде юлда барган чакта ук унбишәр-егермешәр килограмм йөк бүлеп бирелгән иде. Кемгә тартмасытартмасы белән снарядлар, кемгә рация һәм элемтә кабельләре, кемгә гражданнар сугышыннан калган «Максимкалар». Моның өстенә, һәркайсында дүртәр-бишәр граната, көрәк, ком капчыгы, мылтык йә автомат.

Беренче десантчылар суга сикерүгә үк бата башладылар. Елгырраклары шундук ком капчыкларын салып ташлады, снаряд йә кабель кәтүкләрен дә ыргытты. Рәтле елга-инеш күрми үскән өч-дүрт сугышчы шундук су төбенә китте. Моны палубадан күзәтеп торган байтак десантчылар сугым малы сыман аяк терәп карышырга тотынды.

— Мин Себер тайгасында үскән кеше лә, иптәш лейтенант, мин бит йөзә белмим!

Кеше гомере белән чутлашып торудан узган иде инде. Офицерлар, политруклар солдатларны берәм-берәм диңгезгә тибеп төшерә башлады. Кемдер акырып елый-елый яр буена таба чәбәләнде, кемдер батып калды...

Ислам взводы «Медный» дигән чик буе катерында иде. Петропавловскта чакта йөк төяү барышын Ислам шәхсән үзе күзәтеп тормады. Нанагава бугазына килеп җитәрәк трюмдагы сугыш кирәк-яракларын бүлешергә тотынганнар иде,

анда эт — баш, сыер — аяк. Снарядларны-пулеметларны иң аска калдырганнар, алар өстенә санитар носилкалары, юрганнар, шинельләр өелгән. Ислам сүгенә-сүгенә шуларны диңгезгә чыгарып атты. Снарядларны-пулеметларны бүлешә торгач, башкалардан беркадәр соңардылар. Ислам взводы суга сикергән чакта, бүтән бер-ике кораб десантчылары яр өстенә чыккан иде инде.

Ислам гаҗәпләнә-гаҗәпләнә йөзде. Нинди әкәмәт бу, нигә мондый тынлык? Японнар боларның кораб-катерларын әлегәчә күрмәгәннәрмени? Нишләп бетон дотларыннан, дзотларыннан ут ачмыйлар да, нишләп диңгез суында бака туе сыман әвәрә килгән десантчылар өстенә ядрә яудырмыйлар? Әллә бу чепи күзле самурайлар берәр төрле мәкер корып көтеп ятамы соң?

Минут арты минутлар узып китә торды, ә япон позицияләрендә йокыдан уянучы дзот һаман күренмәде. «Лопаткадагы туплар ут яудыра башлагач, валлаһи, илле метр тирәнлегендәге тоннельләренә кереп поскан болар».

Ул арада Ислам сугышчылары ярга килеп җитте. Мөгез сыман тырпаеп торган сопка өстенә үрмәли башладылар. Кайсыдыр «батыры» түбәтәй чаклы калкулык өстенә гапгади чыбыкка киертелгән әләм кадап китте. Сопка итәге буйлап болан сыман сикергәләп үрмәләрлек түгел. Гел ком да таш, аяк тая да китә. Тау итәге буйлап анда-монда сибелеп утырган вак-вак куакларның да һичбер ышанычы юк. Шуларга тотынып тартылмакчы булдыңмы, төбе-тамыры белән суырыла да чыга.

Шулай да алдарак кузгалган бер-ике корабның сугышчылары япон позицияләренә барып җитте бугай. Кайдадыр югарыда, бер як читтә ялгыз совет автоматының тавышы яңгырады. Әллә куркудан ут ачкан моның хуҗасы, әллә курокка ялгыш баскан.

Бер-ике минуттан соң бөтен япон дзотлары телгә килде. Сопкалар өстендә көчле прожекторлар кабынды. Сайлыкта хәрәкәтсез утырган кораб-катерлар өстенә снарядлар ява башлады. Берьюлы икеме-өчме корабка ут капты. Кайсыдыр катерда снаряд тартмаларын палуба өстенә өеп өлгергәннәр, күрәсең, берзаманны шулар ярыла башлады, янда торган янә ике катерны ут чолгады. Катерларда калган моряк һәм тупчылар, ялкын дип тормыйча, трюмнарга төшереп яшерелгән хәрби атларны палуба өстенә куып чыгарырга тотынды. Өннәре алынган малкайлар ак-караны аерып тормыйча су өстенә сикерде, ләкин аларны да япон пулеметларыннан агылган кургаш яңгыры кырып салды...

Чарасызлыкка чумган, яртылаш ялкынга чорналган кораблар кул астына эләккән барча туп һәм пулеметлардан япон позицияләренә төбәп ут ачтылар. Ләкин боларның кырык биш, алтмыш миллиметрлы көпшәләрдән чыгып очкан ядрәләре ике йөз метр биеклеккә менеп җитә алмый, алар, кыска дуга ясап, нәкъ совет солдатлары сыенып утырган чокырлар һәм иңкүлекләр өстенә килеп төшә иде. Һәр тарафта ирләр колакларны сытып сүгенделәр.

— Туры наводка белән үзебезнекеләр өстенә аталар бит, аналарын сатыйм! Үлем көтеп утырып булмый бит инде. Алга, иптәшләр, алга!

Телиләрме-теләмиләрме, сугышчылар кыеклап, уратып сопкалар өстенә менүен дәвам итте. Бер-ике урында инде дзотлар авызына гранаталар да ыргыттылар. Беркадәр юл ачылган сыман булды, сикерә-сикерә алга ыргылдылар.

Ислам Кокутан белән Котомари сопкаларының уртасынарак туры килгән иде. Биредә тау итәкләре сөзәгрәк, әмма японнар Нанагава бугазының нәкъ уртасы дип исәпләгәннәрдер инде, монда бетон койма артына корылган пулемет оялары, кыяга уеп ясалган дот-дзотлар күбрәк. Ике-өч метр араны да сикереп үтә алмыйсың, әле бер, әле икенче яссылыктан кургаш яңгыры сызгырып оча башлый.

Исламда гайрәт чиксез. Танкка каршы граната бәйләмнәре ташлап, ул инде ике дзотның авызларын йомды. Өстәрәк урнашкан бетон койма тишекләреннән күзәтеп торганнардыр инде, бер мизгелдә Ислам сыенып яткан чокыр тарафына озын агач саплы граната ыргыттылар. Ислам югалып калмады, гранатаны очып төшкән көенә сикереп эләктерде дә янә нәкъ шул койма артына очырды. Тагын бер пулемет оясы шулай юкка чыкты. Янә ыргый-ыргый югарыга таба үрмәләделәр.

Сызылып кына таң ата башлады, томан юкка чыкты. Нанагава бугазы өстенә әйләнеп карыйсы да килми. Йөрәк сыкрап-сыкрап яна. Дага булып җәелгән култык уртасындагы җиде-сигез корабны ут чолгаган, тагын ун-унике катер-баржаларның кара сөремгә баткан корпуслары гына утырып калган. Су өстендә һәм яр читендә ат үләксәләре, кеше мәетләре...

Дошман пулеметлары тынып торган бер арада Ислам янына әле Петропавловскта чакта гына партиягә кергән солдат Вилков шуышып килде. Алар дүрт ел буе землянкаларда бергә аунаганнар, партиягә тәкъдимнамәне дә Ислам аңа үзе биргән иде.

— Тәмәке бир әле, старшина,— дип, бөтенләй көтмәгән

сүз башлады Вилков, ә үзенең карашында-йөзендә усал очкын. Тәмәкесен дә ярсып-ярсып суырды, аннары сыңар кулын диңгез ягына изәп, тиз-тиз тезеп китте:

— «Дзержинский»ның кайда торганын күрәсеңме, Ислам? Әнә бухта эченә кереп тә карамады, япон снарядлары барып җитмәслек ераклыкта тора. Менә шулай эшереп бирә безне начдив Дьяков та, башка генераллар да. Без — алар өчен пешка һәм туп ите. Без меңәрләп юкка кырылабыз, ә аларның күкрәк-погоннарына орден-йолдыз ява. Бу комташтан хасил Шумшу утравы синең белән миңа нигә кирәк иде? Пычагымамы? Шул-шул, пычагыма. Һәм без, туганкаем, сукыр бер тиенгә дә кирәкмәгән шушы утрау өчен башны салачакбыз...

Исламнарның нәкъ баш түбәсендә, унбиш-егерме метр биеклектә япон пулеметы телгә килде. Ислам да, Вилков та калкынып күз ташлады: бетон калыпларга төренгән дзот эченнән ярдагы яңа бер команда өстенә ут яудыра дошман. Ярдагылар кай тарафка барырга белми әрле-бирле килеп йөгерәләр, икеме-өчме солдат җир өстенә егылып калды инде.

— Эх-ма! — дип кычкырды шул чагында Вилков. — Безнең башлар ниләр генә күрми. Әйдә, үлем белән көч сынашыйк әле.

Вилков көтмәгәндә сикереп кузгалды да, су коенучы кызларның күлмәкләрен урларга җыенган малайлар шикелле кыеклап кына барып, әүвәл дошман дзотының авызына граната бәйләме ыргытты. Тик бер минут чамасы гына тыныч торды дошман. Аннары янә ут яңгыры, тагын атыш. Вилковның ачыргаланып кычкырган тавышы яңгырады.

— Юк, мине җиңә алмассың!

Вилков шул минутта япон амбразурасына барып капланды...

Ислам белән тагын бер-ике солдат әлеге дзотның ишеген җимереп керсәләр, пулеметка чылбыр белән богаулап куелган япон самурае дер-дер елап утыра. Куркудан балавыз сыгамы ул, көчсезлек елатамы? Һични аңламассың. Хәер, Ислам аннан ни дә булса сорашып маташмады, киерелде дә приклад белән түбәсенә орды...

Иң кызу, иң әшәке яу төш вакытыннан соң башланды. Бу вакытка дошманның инде унга якын склады шартлатылган, җир өстендәге икеме-өчме казармалары дөрләп яна иде. Берничә тоннель авызында ак әләм болгаган солыхчылар да күренеп-күренеп алды. Югарыдан алар белән сөйләшүләрне шып тыйдылар.

— Бернинди солых төзү һәм аңлашулар юк! Самурайларны пленга алмаска, кырып бетерергә!

Япон солдатлары арасында камикадзелар пәйда була башлады. Билләренә гранаталар бәйләме ураган көенчә йөгереп чыгалар да, безнең унбиш-егермеләп десантчы яшеренгән чокыр эченә ташланып, үзләрен шартлаталар. Аларны тыеп та, алардан котылып та булмый. Бу яман чир советныкыларга да йокты.

Генерал Гнечко Петропавловскта чакта «Шумшу утравында биш аэродром бар» дип сөйләгән иде, төш вакытындарак совет солдатлары шуларның берсен эләктерделәр. Мондый югалту самурайларга бик кырын сукты, күрәсең, алар резервта булган унбиш-егермеләп танкларын һөҗүмгә ташладылар. Совет сугышчыларының кулында бер генә туп та юк. Башка чара калмагач, гранаталар, бензин шешәләре тотып каршы ыргылдылар. Башта ротада парторг булып саналган сержант Черепанов граната бәйләме белән япон танкы астына сузылып ятты. Аннары Баландин, Солтанов, Тюрин, Савушкин фамилияле сугышчылар танклар астына ыргылып үз-үзләрен шартлатты. Мондый хәлне күреп башка танклардагы самурайлар өнсез калды бугай. Танкларын тиз-тиз борып, шундук чигенделәр. Ләкин аларга ышыкланып, аэродром өстенә ике йөзләп солдат килә иде. Исламның яртылаш исән калган взводы менә шулар белән тигезсез яуга керде.

Әүвәл зур-зур ташлар, бетон плитәләр артына качып, бик уңышлы каршы торды алар. Әмма берзаманны совет десантчыларының кулларында патроннары бетте. Ә чепи күзле самурайлар килә дә килә һаман. Шул чагында Ислам сикереп басты.

— Тере көенчә биреләсебез юк! Штык белән сугышка, алга, дуслар!

Ислам үзе кул пулеметы тотып баскан иде. Пулеметны көпшә ягыннан эләктереп алды да, самурайлар уртасына ыргылып, күсәк сыман болгый да башлады. Менә кан чәчрәтеп бер самурай ауды, икәү, өчәү... җидәү. Исламның күзе-башы тонган, ул үгез сыман ярсыган, берни күрми иде. Тагын да гайрәт чәчәргә ирек бирмәделәр. Берьюлы әллә ничә автомат чытырдады, Ислам, камыш кебек киселеп, җир өстенә ауды. Пәһлевандай гәүдә алай да бирешергә теләми, вакыты-вакыты белән корт чаккан шикелле тартыша иде әле...

Кичке сәгать дүрттә генерал-лейтенант Фусаки үзе ак төстәге әләм күтәреп чыкты. Ату тавышы тынды. Ләкин старшина Ислам Үрәзмәтов боларның берсен дә күрми, аның тынгысыз җаны пәһлевандай гәүдәсен ташлап очкан иде инде.

# ҖИДЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

## 1

Зифа Уфа вокзалына кырык бишенче елның егерме җиденче декабрендә кайтып төште. Төнге сәгать ике. Күкрәгендә бала, янында капчык-капчык, сандык-сандык тауар. Ә урамда эт тә юк, вокзал буп-буш. Чыдамасаң, «каравыл» кычкыр.

Аллага шөкер, җир йөзендә изге кешеләр очраштырып тора, юлчыны шул яшәтә. Көтмәгәндә вагоннар арасыннан бер ир килеп чыкты.

— Товарищ, товарищ! — дип, тизрәк сүз кушты аңа Зифа.— Минем әйберләремне саклау камерасына илтешә алмассызмы?

Теге ир каршына килеп баскач, аның йөзеннән үк төсмерләде Зифа. Татар кешесе бу, үзебезнең кеше, ышанычлы кеше!

Ә татар ире Зифага төбәлеп чекерәйде дә катты.

— Син кайчаннан бирле Уфаның саклау камераларына ышанасың, бәбкәм? Син әйберләреңне андагыларга илтеп бирдең ни дә, суга салдың ни. Аермасы юк бит.

Зифа ни кылырга белми коелып төшкән иде, татар агае үз тәкъдимен җиткерде:

— Син бик ерактан кайткан булырга охшыйсың. Күреп торам, монда каршы алырдай туган-тумачаң да юк икән. Әгәр йөз чөермәсәң, давай үзебезгә кайт. Без апаң белән икебез генә торабыз. Төн чыгарга ярар.

Зифадан «рәхмәт инде, рәхмәт» дигән сүз ишеткәч, татар агае батыраеп китте.

— Хәзер бер капчыгыңны сыртка салып китәм. Калганнарын чана белән ташымыйча булмас...

Әле чана белән дә Зифа тауарларын ике-өч мәртәбә кайтарырга туры килде. Соңгысында үзе дә чемодан-тартмалар өемен яннан тота-тота кайтарышкан иде. Вокзалда тимер йозак белән бикләнгән авыр сандык кына торып калды. Шуны алырга дип кабат әйләнеп килсәләр, сандык янында әзмәвердәй бер ир басып тора. Электр лампалары бик якты янмаса да, шактый ачыклардык: карашында нур юк моның, юньле кеше түгел.

Тавышы да баздан чыккан сыман, гөмбердәп ишетелде.

— Әй, чәчби! Сандыгыңа таш тутырдыңмы әллә? Давай күтәреп салышам. Мәгәр мул түлисең.

— Без үзебез, без үзебез,— дип, Зифа сөйләнә башлаган иде, татар агае чабуыннан тартты.

— Рәхмәт инде, Хисам, рәхмәт, рәхмәт. Түли бу хатын сиңа, түли, түли...

Хисам, чыннан да, сандыкны чана өстенә күтәрешеп куйды да, кулын сузып, акча көтеп тора башлады. Зифа бер кызыл утызлык чыгарып бирергә мәҗбүр булды, теге кулын алмый, авызын оятсыз итеп ерган да тик текәлеп тора. Зифа икенче утызлыкны чыгарып салгач кына, артына борылып карамыйча да, сызгыра-сызгыра китте. Шунда гына телгә килде агай:

— Беләсеңме бу кем? Уфаның бөтен Затон ягын, вокзал янын кулында биетеп тотучы атаклы бандит Хисам булыр бу. Аның шайкасындагы каракларның саны гына да утызга җитә, диләр. Бу Хисам, кирәк икән, теләсә кемне көпә-көндез акырта да суя. Суд юк, чурт юк. Ә син утыз тәңкә акча җәлләп торасың...

Уфа Зифаны менә шулай «иркәләп» каршылады.

## 2

Икенче иртәдә Зифа элек язган адресы буенча Вәзирәне эзләп барган иде, ярык тагарак каршына китереп утырттылар.

— Сеңлең бер ай элек кенә кияүгә чыгып, Татарстанга күчеп китте бит. Китәр алдыннан ул сиңа икеме-өчме хат та язган иде. Син алмадыңмыни?

Зифа ни көләргә белмәде, ни еларга. Тугыз-ун мең чакрым юл кайтып сеңлеңне очрата алмау күңелсез, ләкин аның күзле-башлы булып куюы бер дә начар түгел. Ә бу хуҗаларга үзеңнең кырык көн элек юлга чыгуыңны, михнәт чигә-чигә кайтып җитүләрне сөйләп утыру нигә кирәк инде?

Зифа саубуллашты да китте. Планлаштырып куйган бердәнбер урыны бар иде, туп-туры мәгариф министрлыгына төбәп юл тотты. Зифа Алланың кашка тәкәсе түгел, министрлыкта да аны көтеп саргаймыйлар икән.

— Хәзер уку елы уртасы бит, җаным,— диде аңа ярым пеләш иптәш.— Уфа мәктәпләрендә урын табу хакында сөйләшеп тә тормыйк. Алар шыгрым тулы, нәчәлник хатыннарын тыгарга да тишек табып булмый. Ә авыл районнарының берәрсендә, берәр мәктәпкә эшкә җибәрү турында уйлап була әле. Карт укытучылар пенсиягә чыга. Кемдер бала таба, кемдер күчеп китә. Икенче яртыеллык башында ук урын табылу бар. Әмма ләкин... җаныкаем-дустым, синең паспортыңның срогы чыккан бит инде. Аны яңартмыйча, сине беркем эшкә алмаячак...

Менә сиңа авыртмаган башка тимер тарак! Кайчандыр хәйләләр, майлаулар белән аңа судья Шарапова паспорт алып биргәнгә дә ун ел үтеп киткән. Тау елгасы сыман тотып

тыйгысыз рәвештә ага, уза гомер. Исән микән инде син судья Шарапова? Кайда гына михнәт чигәсең дә, ни кырасың икән?..

Зифа документ яңартуның тәртибен-җаен сорашмакчы булып юлда очраган беренче милиция бүлегенең паспорт өстәленә сугылды. Юк кына бит, әйкәем, дилбегәң бер мәртәбә койрык астына керсә, кабат-кабат шунда эләгә икән.

Паспорт өстәлендә эшләүче марҗа хатын Зифаның төпченүен үзенчәрәк аңлап алды бугай.

— Паспорт белән уйный торган заманамыни хәзер? Бер генә туган-тумачаңа паспорт ясап бирсәң дә, Себер җибәрәләр. Ю-у-ук, искесен күрсәтеп кенә яңа паспорт чыгарып бирүче булмаячак, иптәш! Өр-яңадан авылыңа кайтып, өр-яңадан митрикәләр, катлы-катлы белешмәләр алып килсәң генә юл ачыла сиңа.

Чәчләрен лаклар белән ялтыраткан марҗа хатынының шушы нотыгыннан соң Зифа эченнән генә яман сүгенә-сүгенә чыгып китте. «И-и, совет, совет, дип шапырынган илебездә крепостнойлык җәмгыяте бетмәгән, без барыбыз да һаман кол икәнбез бит әле. Искесе урынына яңа паспорт алыр өчен дә, Кучәрбай-Төркәйләргә кайтып, митрикәләр җыеп йөр инде, адәм тәганәсе!»

Урамнарда йөри-йөри Зифа тынычланды. Кичкә таба зиһенен бөтенләй башка төрле уй-ниятләр бораулый башлады. «Вәзирә Татарстанның Актаныш районына барып урнашкан. Бүздәк белән Актаныш — җәһәннәм арасы түгел. Башка төшкәч, Камчатка белән Уфа араларын да ава-түнә үттек бит әле. Эшкә бер урнашып алсаң, әллә табыла вакыт, әллә юк. Ичмаса, берочтан сеңелкәшне күреп, аның дөньясын да белеп кайтырмын...»

...Кечкенә Розаны җитәкләгән Зифа килеп кергәч, Вәзирә килен булып төшкән йорттагылар, әлбәттә, аһ иттеләр. Барыннан да бигрәк, Вәзирә күз яшенә батты. Кулына һичбер төрле савыт-сабаларны тота алмый, алъяпкыч-тастымалларны йөзенә каплап, үкерә дә елый.

— Син дә тол хатын булып калдыңмыни, апа? Инәй кебек син дә гомер буе япа-ялгыз көе интегерсең микәнни? Буыннан буынга күчеп тол кала торган нинди нәсел соң бу?

— Авызыңнан җил алсын! Бөтен нәселеңә толлык юрап утырмале, хатын! — дип, ире Шаһинур өстәл төйгәч кенә Вәзирә берникадәр басылгандай булды.

Вәзирә янында өч кич кундылар. Зифа адым саен игътибарлап йөрде: кияү тиешле Шаһинур ипле, юньле адәм. Чибәрлек буенча авылларында аңа җиткән кеше бөтенләй юк бугай. Әзмәвердәй гәүдә, әбиләр әйтмешли, «гөрнәдирдәй»

буй-сын. Чем-кара чәч, иртә-кичен алсуланып торган тулы яңак, туктаусыз җылылык-нур сирпүче шаян күзләр. Иң гаҗәбе: бу кеше берчакта да кул кушырып утыруны белми. Югыйсә колхозның баш агрономы бит инде, болай да көн-төн эштә. Ләкин, юк, ихатага кайтып кердеме, һаман хәрәкәттә. Утын яра, кар көри, мал карый, боз чаба, һич югы, ишек төбен, капка алдын себерә. Моңа тәүлегенә өч-дүрт сәгать йокы да җитә икән. Бу өлкәдә гел кабатлый, кистереп әйтә торган сүзе дә бар:

— Йокы — кешелекнең беренче дошманы. Йокы белән ялкаулык — дәваланмас чирләр...

Зифа Шаһинур холкында Исламга хас чалымнарны күреп шөбһәләнә башлады. Вәт әкәмәт, бу да, нәкъ Ислам шикелле, авызны пешерә торган кайнар ашны гына ризыкка саный, үшәнрәк аш китерсәң, аны өстәл өстеннән сыпырып төшерергә дә күп сорамый икән. Боларга өстәп, тагын Ислам кебек көнле, талый да торган булса, ничек түзмәк кирәк?

Зифа соңгы иртәдә, Шаһинурга ияреп чыгып, ихатада кияү кешегә сөйләп-аңлатып калырга ашыкты:

— Ирдән-иргә йөрү гадәте безнең нәселдә юк. Вәзирә әүлия түгелдер-түгелен, иллә мәгәр түз син. Ул тугыз-ун яшеннән ятим калган бала. Аерым тәрбия-игътибар күреп үскән иркә кеше түгел. Сугыш елларында япа-ялгыз көе үз башын исән-сау көе саклап кала алгач та олы рәхмәт әле... Ир какканны мир кагар, ди халык. Вәзирә — авылыгыз өчен килмешәк кеше. Берүк какма аны, Шаһинур. Утардагы малны кыйнасаң да, ул үчле һәм рәнҗешле була. Рәнҗеш җыйма берүк. Син бик гайрәтле кеше, Вәзирәне үз ышыгыңда йөрт. Без болай да кайгы-михнәтләрне бик күп күрдек инде. Берүк, берүк син дә өсти күрмә...

Зифаның юлга җыена башлавын чамалауга ук, Вәзирә дә капылт сикереп купты.

— Юк, ул Күчәрбай белән Төркәйдәге елан оясына мин синең берьялгызыңны гына җибәрәмме соң? Анда көпә-көндез адәм суя торган Илмурзиннар бар, бүтән дошманнар җитәрлек. Сиңа алай-болай, берәр төрле этлек эшләсәләр, аннары мин бу җир йөзендә ничек итеп яшим ди? Юк, барам булгач, барам!

## 3

Төркәй каршындагы үр өстенә җиткәч, авылга текәлделәр дә, үз күзләренә үзләре ышанмыйча, шаккатып тик тордылар. Урамнарында, тугайлыкларында алар уйнап үскән авыл кая киткән?

Торна күле ягында, элек унлап йорты белән балкып утырган урам бөтенләй юк. Элек Рөстәмбәкләр, Гәрдән кулаклар, Йосыф байлар яллап ясата торган буа буйлап та өч-дүрт йорт кукраеп утыра иде, алардан да хәзер җилләр искән. Авыл буйлап явыз үләт, йә булмаса канлы яу үткән сыман. Төркәй хәзер күп дигәндә бер чакрым озынлыгындагы сыңар урам гына булып утырып калган. Анысын да урам дип олылау бик урынлы микән? Бик күп йортларның ихаталары, койма-киртәләре юк. Әллә ничә йортның тәрәзәләренә аркылы-торкылы такталар кадакланган. Дистәләгән йортлар, аксак-гарип сыман, бер якка янтаеп, кыегаеп утыра. Һәр йорт саен тишек салам түбә, һәр ихата саен кыегайган абзар.

Зифа, күзләрен чекерәйтеп, үзләре ташлап киткән бәләкәй өйне эзләп караса да, таба алмады. Сугыш елларында күршеләр, күрәсең, аны да сүтеп якканнардыр инде. Аңа ни сан? Әнә Гәрдән кулак, Йосыф бай, итче Мирсәяф, кибетче Ибни карт йортларының да берсе-бер күренми бит.

— И-их, безне талап кына бер дә баемагансың икән шул, авылкаем, — дип, түзмәгәч ухылдап телгә килде Зифа. — Җелегеңне суырып алганнар, беткәнсең син, Төркәй...

Урамда яшь бала җитәкләгән ике хатын пәйда булу Төркәй халкын байтак вакыт буе уятмады әле. Һичбер йорт ишеге ачылмый, бер-берсенә керүче-чыгучы юк. Зифа белән Вәзирә, элек Әхтәм мулланыкы булып исәпләнгән йорт каршында тукталып, кая барып сугылырга белмичә аптырашкан көе тик тордылар.

Ниһаять, Яшке утары очыннан аякларын көч-хәл белән генә кыймылдатып килүче бер карчык күренде. Тәнендә чак җаны гына калган мескенкәйнең, ике-өч атлый да, гыжгыж килеп, тын алырга туктый. Шулай да, көттереп-ялындырып дигәндәй, кичәге авылдашлары каршына килеп туктады бу. Бер кулын каш өстенә куеп күздән кичереп чыкты, ләкин танымады. Зифаның күзләре елгыррак, ул әбине төсмерләп өлгергән иде инде. Кайчандыр, моннан унбиш-егерме еллар элек, Зифа Афонька өстеннән очып төшеп кул тайдырган чакта аның янына килеп «муйның өзелгере» дип каргаган Гайнавал карчык бит бу! Ходай Тәгалә кайбер адәмнәргә гомер дигәнен бирсә дә бирә икән!..

— Кем буласыз соң сез, оланнар? Кемгә кунакка килдегез? — дип, Гайнавал карчык сорау яудыра башлагач, Зифа чабуыннан тартырга өлгерә алмый калды, Вәзирә тезеп китте:

— Бәрәч, бәрәч, шушы авыл кешеләре, Әмирҗан белән Гөлтуташның кызлары булабыз ласа. Танымыйсыңмыни, әбекәем?

Авызына әрем каптырганнар диярсең, Гайнавал карчыкның йөзе шул минутта кара көеп чыкты.

— Ә-ә, теге имансыз, денсез Әмирнекеләрмени? Шул сезнең атагыз җимерде бит инде безнең манараны, шул мәчетсез итте.

Зифа ни әйтергә белми коелып төшкән иде, Вәзирә исә кызыл чүпрәк җилфердәтеп котырткан әтәч шикелле сикерде дә кунды.

— Аһ, син әле бүгенге көнгә хәтле контрмыни, әби? Бер аягың җирдә, икенчесе гүрдә, сиңа һаман мәчет кирәкмени? Әйдә, силсәвиткә!

Гайнавал карчыкны бер секунд эчендә алыштырып куйдылар, гыжлаулары кул белән юып алгандай шундук юкка чыкты. Икенче минутта әби, җитез теркелди-теркелди, кабат үз очына элдерә иде инде...

Берәр сәгатьтән соң юлчыларны кайчандыр Әмирнең уң кулы булып йөргән Фазылбәкнең хатыны Зәкия чәйгә алып китте. Үткән гомерләрне искә ала-ала байтак яшь түктеләр. Чынаякларны каплап куйгач кына, Зәкия һич тә көтелмәгән сүз башлады:

— Сезнең берәр кеше аша атагыз турында ишеткәнегезмазар булдымы соң?

Зифа белән Вәзирә ялт итеп бер-берсенә караш ташладылар, һәр икесе уклау йоткан сыман хәрәкәтсез калды, йөзләре агарып чыкты. Зәкия һәммәсен дә күреп тора иде, кызгану хисләрен онытып янә дәвам итте:

— Әмир абзыйны авылга кайтып килгән чакта сагалап торган булырга тиешләр. Күчәрбайдан Илмурзиннарның Мәхмүте, ата бандит. Безнең авылдан теге мәңге зимагур хәлфә булып йөргән Озын Закир. Кырхабур Хәбинең энекәше Кара тавык Гайсә. Дүртенчесе — хатынын колхоз үгезе сөзеп үтергән Ката кабык Харис...

Зәкия боларның йөзендә нинди үзгәреш булыр икән, дигән сыман ике кунакка да күз йөгертеп чыкты. Ләкин Зифа белән Вәзирә таш сын шикелле селкенмичә утыра, күрәсең, алар әтиләре турында хәбәрләрнең иң хәтәрен көтүгә дә күптән әзер иде.

— ...Әмир абзыйны Торна күле янына күтәреп илткән чакта боларны колхоз көтүен көтеп йөргән Сакау Ләпәй белән Бозау Фәхри күргән. Фәхрие кырык өчтә кар астында калган башакларны ашап үлде инде, мәрхүм. Ә Ләпәе әле булса исән, барып сораша аласыз...

Зәкия янә тукталды, кунаклардан ниндидер сүз көтте. Тик Зифа белән Вәзирә авызларына су капкан шикелле тыптын утырдылар.

— ...Ләпәй белән Фәхри өсләренә килеп чыккан чакта, тегеләр Әмир абзыйны Торна күленә салырга исәп тоткан булган. Боларга юлыккач бик нык янаганнар да Табор күленә алып киткәннәр. Ләпәй белән Фәхри антлар эчеп әйтте, болар күтәреп барганда, Әмир абзый исән булган әле. Мәгәр бик нык кыйналган, канга батып беткән. Авыз ачып, Ләпәйләргә бер сүз әйтә алмаган. Икенче көнне, яңа көтүгә чыккач, Ләпәй белән Фәхри Әмир абзыйны Табор күле камышлары арасыннан эзләп караганнар. «Күл буенда элек ватык бер арба тәгәрмәче ята иде, ул юкка чыккан, ә су өстендә бер урын караланып тора иде» дип сөйләде икесе дә соңрак. Күрәсең, теге җанкыярлар Әмир абзыйны, арба тәгәрмәче бәйләп, күл төбенә салганнардыр инде. Ул күл суында ничә еллар буена кер чайкаучы кеше дә булмады бит...

Зифа белән Вәзирә итәк очларына каплана-каплана үксеп утырды. Һични аңламаса да, аларга кушылып кеп-кечкенә Роза да берничә мәртәбә ярсып-ярсып алды. Ахырда Вәзирә, беренче тынычланып, усал сорау бирде:

— Бу хакта безгә элегрәк сөйләсәң телең корыр идемени, Зәкия апай? Ичмаса, инәкәй атай язмышы турында белеп китәр иде.

— И-и, апаем! Ә без атаң хакында кайчан белгән дисең? Аны Ләпәй белән Фәхри авыл халкына сугыш башлангач, теге җанкыярлар юкка чыккач кына җәелеп сөйләде бит. Озын Закир утыз җиденче елдамы соң авылдан чыгып качты. Харис белән Кара тавык Гайсәнең кырык бердә үк «Мәскәү янындагы яуда кырылганнар» дигән хәбәрләре кайтты. Ә ата бандит Илмурзиннар турында бөтенләй ишеткән юк. Алар ничә карасаң төрмә юлында. Йә ристан, йә арестант алар. Дүртесенең дә югалу хәбәре килгәч кенә Ләпәй белән Фәхри авыз ачарга кыйганнардыр инде. Тегеләр исән чакта кычкырып йөрергә аларның башлары ике түгел ләса...

Урамга чыккач, Зифа белән Вәзирә Табор күле буена барырга җөрьәт итмәделәр. Әүвәл алар, зиратка кереп, әниләренең каберенә сәҗдә кылып чыкты. Аяклары бөтенләй тартмаса да, хәтер саклап һәм «әйдә, бездән калмасын» дигәндәй, Әбелсаттар агайларга да кереп хәл белделәр. Авыл өстендәге үргә кабат менгәч, икесе дә Төркәй ягына борылып күз ташлады.

— Бәхет-шатлыкларны, и-и, аз күрсәттең, Төркәй. Үзең туган авыл да, бер үк вакытта үги авыл да син. Кабат сиңа кайтып күренүләр насыйп булырмы икән?

## 4

Гыйнвар азагында министрлыктагы ярым пеләш иптәш Зифаны, бик тә кирәкле кишер яфрагы сыман, елмаеп каршылады.

— Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына, ди. Сиңа да менә дигән эш табылды бит әле, камчадалка. Әнә Тәтешле районының берьюлы ике мәктәбеннән яшь укытучылар кияүгә чыгып киткән. Беренче февраль көне белән фәрманга кул куйдырам, давай, шунда сыптыр. Тарих фәнен укытырсыңмы анда, әллә урыс теле белән татар әдәбиятынмы, синең ихтыярда...

Камчаткадан бирле төяп кайткан малның кайсын ярты хакына сатып, кайсын ризыкка алмашып, Зифа янә төянәкүтәренә юлга чыгып китте. Фәрман кулда, ул да янә, Ходай рәхмәте белән, Башкортстан укытучысы булачак бит! Юл бирегез, якташ мөгаллимнәр!

Зифа әнә шулай очына-очына Тәтешленең мәгариф бүлеге мөдире бүлмәсенә барып кергән иде, тере елан өстенә баскандай агарды да катты. Өстәл артында ... аның әтисен күл төбенә салган, кайсыдыр елларда «хәлфә» дигән исем чыгарып авылдан авылга куылып йөргән Озын Закир утыра. Дөрес, буйга бирәр карыш чамасы кайта төшкән инде бу, корсак белән икенче ияк тә үстереп җибәргән. Башы пеләшләнгән, борын очында күзлек. Ләкин бу барыбер дә Зифа өчен күрергә җирәнгеч булган, мәңге-мәңге гафу итә алмас җанкыяр, әшәке җанлы Закир. И-и, нинди генә чүп-чар белән тизәкне су өстенә күтәреп чыгармагансың да, нинди генә әтрәк-әләмгә ил язмышын тапшырмагансың икән син, явыз, кансыз сугыш?!

Ак кеш тиресеннән тегелгән шәп бүрек, каракүл тун кигән бик тә кәттә кыяфәтле хатынны мөдир Закир бөтенләй танымады.

— Рәхим итегез, иптәш, әйдә, утырыгыз,— дип, ул урыныннан сикереп торган чакта, Зифа җил-җил атлап аның каршына килеп басты да лач иттереп тегенең битенә төкерде. Аннары кәс-кәс басып кире чыгып та китте. Шушылай итеп, дошманының йөзенә бер төкерер өчен генә йөзәр чакрым ара үтүләре дә аңа бөтенләй кызганыч түгел иде.

## 5

Министрлыктан яңа юлламаны Зифа Чишмә районының Арыслан дигән авылына алды. Арыслан зур авыл, монда егермегә якын класслы җидееллык мәктәп икән. Директоры

унбиш ел буе шушында эшләгән, бик тә тәҗрибәле хатын булып чыкты. Кыска гына танышудан соң да Зифаның бар язмышын, хәл-әхвәлен аңлап алды бугай, үзе үк тәкъдимнәрен, киңәшләрен тезде.

— Монда тарих укытучысы да кирәк, татар теле белгече дә. Дәресләр саны күп булырга мөмкин, димәк, мул итеп акча алырга җай бар. Иллә мәгәр фатир яклары бик тә авыр монда. Якын-тирәдәге авыллардан бөтен кеше шушында агыла, шуңа Арыслан нык зурайды, хәзер монда ташландык бер йорт та юк. Ә сез әгәр озак еллар буе бер урында эшләргә, төпләнергә ниятлисез икән, бездән дүрт чакрымда гына Кадрәк авылы бар. Анда башлангыч мәктәп, бер генә укытучы. Аеруча рус теле дәресләре утырып елар дәрәҗәдә аксый. Сез байтак еллар буе рус халкы арасында яшәгән кеше, сезгә рус телен укыту шактый җиңел бирелергә тиеш. Кадрәктә аерым колхоз, председателе гаять ипле-җайлы кеше. Үзегезгә аерым йорт тергезү турында кайгыртмыйча калмас. Әйдә, сезне шундагы мәктәп мөдире итеп билгелик тә, председательне дә тора-бара үз ягыбызга аударырга тырышып карыйк әле...

Зифа шул рәвешчә башлангыч мәктәп мөдире булып китте. Кадрәк бәләкәй дә, искитмәле зур да түгел, йөз илле чамасы йорттан хасил уртача бер авыл. Ул Өршәк елгасы буена урнашкан. Өршәкнең бу ягы Чишмәнеке, теге ягы Бозаяз районына керә икән.

Авылда ташландык ике-өч йорт бар, әмма түбәләре тишек, мичләре җимерелгән, урыны-урыны белән идән-түшәм сайгаклары куптарып алынган. Зифага Бәдыйгол атлы ялгыз башкорт хатынына фатирга керергә туры килде. Чын исеме Бәдыйгөл булгандыр инде моның. Ләкин аңа алай дип эндәшүче юк, авыл өчен ул Бәдыйгол гына.

Хуҗа кеше ата ялкау, өстәвенә озын куллы хатын булып чыкты. Килен итеп алып кайткан татар ире сугышта ятып калгач, бу Бәдыйгол элеккерәк елларда да дөнья сөйрәп көч түкмәгән, адым саен авылын ташлап, карт әти-әнисе янында кыш уздырып гомер чиккән икән. Менә соңгы елда ничектер монда кыш чыгарга җөрьәт иткән теге. Хәтта шактый мул сөтле сыер да сатып алган. Әмма бер сәнәк тә саламы-печәне юк. Зифа өйдәш булып керүгә үк аның үзәген корыта башлады.

— Һедгә буска гыла һөт өстәре менән май асатып булмас. Фәлән әйберең өделеп төсеп калмас, минем һыерыма бесән менән он табып кайт!..

Зифага мөдирлек өчен йөз, дәресләр өчен биш йөз тәңкә тирәсе түли башладылар. Ислам өчен Розага тагын йөз илле

тәңкә пенсия килгәли. Җәмгысы — җиде йөз илле тәңкә керем. Ә базарда бер пот арыш яки тары онының хакы — ике йөз сум. Шулай булгач, Зифа каян акча табып оннар алсын инде? Аптырагач, ул төн аралаш колхоз басуына ... печән-салам урлашырга йөри. Укытучы кеше...

Ә Бәдыйгол Зифа мәктәптә чакта аның сандыгыннан, чемоданнарыннан Камчаткадан бирле төяп кайткан әйберләрне урлап рәхәтләнә. Бәдыйгол ике-өч көн саен ләх исерек. Зифа әйберләрен юллый башладымы, йә алтын путалы керәч тәлинкәләр юк, йә япон яулыгыннан җилләр искән. Зифа ничарадан бичара кыяфәттә һәр иртәдә әйберләрен берәмберәм мәктәп шкафына күчерергә мәҗбүр.

Боларына гына, мөгаен, әле түзәр иде. Берзаманны өйдә төн уртасында гел-гел кабатлана башлаган шомлы, сәер хәлләр тәмам йокысын-өнен алды.

Бәдыйголның өе зират янында гына. Зифа иртәгәге дәресләргә план төзергә йә укучыларның дәфтәрләрен тикшерергә утырдымы, керосин лампасындагы ут леп итә дә сүнә. Зифа бишәр-унар тапкыр керосинны, филтә тасмаларын тикшереп чыга, шырпы сызып кабат ут кабыза. Тәрәзәләрдән бернинди җил өрми, өй эчендә әйләнгән-селкенгән бернәрсә юк. Ләкин Зифаның өстәл артына иңеп кулына каләм алуы гына була, тагын шул ук хикмәт, янә ут сүнә.

Зифа түшәккә сузылып ятса, яңа сәер хәлләр. Ун-унбиш минуттан соң тышта гүя кемдер тәрәзә пыяласына таш кисәге белән ышкый башлый, шыгыр-шыгыр. Күзеңне шар иттереп ачып төбәсәң дә, кулларыңны пыялага китереп терәсәң дә, һич туктамый тавыш, һаман шыгыр-шыгыр. Янда Роза манма тиргә батып уяна, ыңгыраша башлый. Ярты сәгать чамасы шулай интектергәннән соң гына тавыш юкка чыга, Роза йоклап китә.

Зифа әлеге сәер хәлләр турында хезмәттәше Миңсылуга авыз ачкан иде, тегесе Сабур авылында мулла булып йөри торган бер картны алып килгән. Карт бусага аша атлап керүгә үк, почмактан почмакка төкерә-төкерә, өй эчен әфсенли-өшкерә дә башлады, үзе тыр-тыр сөйли:

— Өй иясен, әйе, йорт иясен рәнҗеткәнсең, кызым. Син килгәч, өй иясе сиңа чыдамыйча зиратка чыгып качкан. Мөгаен дә, син кичләрен ут яндырып кяфер китапларын укып утырасыңдыр. Утың шуңа сүнә. Кяфер китапларын укуыңны ташла. Аннары менә караватыңны тәрәзәгә аркылы китереп куйгансың бит. Ә йорт иясе, мөгаен дә, шушы тәрәз аша кайтып йөри булыр. Караватыңны күчер, өй иясенә юл ач. Аннары, аннары, апаем, мондый хәлләрдә тәрәз башына артыш таягы белән болан-поши кабыргасын кую бик савап-

лы, диләр. Артыш таягын үзем алып килдем, поши йә булмаса болан кабыргасын син үзең тап. Шунсыз йортыгызга тынычлык иңмәячәк...

Зифа шул көнне үк бер аучыдан поши мөгезе алып кайтып куйды, караватын икенче почмакка күчерде, рус телендәге китап-дәфтәрләрне ачып карамады. Ни әкәмәт, шул кичтә үк лампадагы ут гел сүнмичә янды, тәрәзәдә шыгырдау юкка чыкты, Роза изелеп йоклады. Хәзер фән-техника заманасы, ә әфсен-төфсеннәр, мулла-абыстай килеп өшкерүләр искелек калдыгы, барысы да сафсата, диләр. Вәт ышанып кара!

## 6

Адәм баласы үзен алда ни көткәнен белми, ләкин аңа иртәгәге көн турында кайгырта-кайгырта яшәргә омтылу хас. Зифа да яз көне үк озын кыш айларына азык туплау өчен байтак адым кылды.

Сугыш елларында чәчүлек мәйданнар нык кимегән, авыл тирәсендә, Өршәк буенда алабута, әрем баскан ташландык басулар исәпсез-хисапсыз иде. Зифа шуларның берсендә ярты гектар чамасы җирне сайлады да, ике ирне яллап, әүвәл сабан сөрдерде. Аннары Дәүләкән базарыннан бер капчык тары алып кайтып, шуңа орлык чәчте. Июнь башларында хәтәр тигез булып уҗым калка башлады. Өмет пәйда булды. Яшәү өчен кымшанырга, тырмашырга кирәк. Тырышмыйча булмый.

Сабан туйлары турында сүз кузгалуга ук Бәдыйгол, иске биш тиен сыман ялтырап, тагын әти-әнисе янына кайтып китте. Алдагы кышка берәр әрдәнә утыны бармы, юкмы — моңа барыбер. Зифа Кадрәк тирәсендәге урманнарда каравылчы булып исәпләнгән чулак картны инде апрель аенда ук сыйлап куйган иде. Бала-чаганы таратып, мәктәпне бикләп куйгач, билбау итеп ураган яулыгына балта кыстырды да, чын ир-атлар сыман, Зифа агач егарга китте. Ни үкенеч, җансыз агач булып җансыз агачлар да санга санамады ялгыз хатынны. Ни каен төбе, ни имәне балта белән аударырга бирми. Балта, суккан саен, агач өстендә туп шикелле сикергәләп тора. Бөтен уч төбен, беләк-иңбаш сөякләрен яңгыраткач кына, төкеренеп-сүгенеп, Зифа бастырык, киртә юанлыгындагы усакларга күчте. Боларның якканда җылысы юклыгын да белеп тора үзе, әмма усак кисәргә, турарга бик уңай. Өч көн дигәндә төп-төгәл бер йөз агачны егып чыкты.

Инде ихатага кайтарып җиткерү кайгысы. Йөз суларын түгә-түгә иртәле-кичле ялынгач, колхоз абзарында бер үгез-

не җигеп бирделәр. «Фермаларда кул арасына кертердәй атлар калдымыни? Әйдә, бу да ярар».

Үгез тәртә арасына җигеп йөртүгә өйрәтелгән иде өйрәтелүен. Әмма җир өстендә коточкыч челлә хөкем сөрә, кигәвен болыт-болыт. Урман эченә килеп керүгә, шулар күче белән килеп ябырылалар, үгез ике-өч минут та түзеп тора алмый. Йә тибенә-тибенә, арбага Зифа салган барча агачларны коеп, чытырманлык эченә барып керә, йә юлда нинди күл очраса, шунын суына муеныннан чума. Бичара үгезне тыңлатмалы түгел.

Адәм баласыннан дә хәйләкәррәк тереклек бармыни? Әле Камчаткада чагында ук тозга бик тилмергәч, Зифа Дәүләкән базарында туры китергән ике-өч кисәк мал тозын әләктереп кайткан иде. Моның ише байлыкны колхоз абзарында тотмыйлар, малларга тоз бик тә, бик тә тансык — Зифа монысын гына белә. Бер мизгелдә, караватастында яткан әнә шул тозны исенә төшерде дә, күлгә кереп чумган бичара үгезне ташлап, Зифа өйгә чапты. Ә үгез, мескенкәй, ярты сәгатьтән соң кер сабыны зурлыгындагы тозны ялатуга, майлагандай булды.

Хәзер Зифага рәхәт, эш көйләнде. Урманга таба иң алдан ул элдерә, артында тоз. Беркатлы үгез борынын сузып чаба. Урманда Зифа тозны җир өстенә сала, үгез шуны алтын чәлгән бур шикелле ялый. Өстенә күче-күче белән, болыт-болыт булып кигәвеннәр куна, үгез кымшанып та карамый. Зифа агачларны төяп бетерүгә, тоз тагын аның кулына күчә, үгез сабый бала сыман арттан иярә. Юлда тукталып тору юк, һау-һаулау юк. Кич җиткәнче усакларны ялт иттереп ташып бетерделәр. Зифага күршеләргә сөйләү өчен мәзәк кенә калды.

Утын мәсьәләсендә җан инде беркадәр тынычланган иде, чәчкән тарыны көтеп җиткерүдә исәп. «Башка якларда корылык, ачлык икән» дигән хәбәрләр килеп ирешә. Зифа үзе чәчкән шул тарысы өчен бик кайгырды. Ләкин җиһанда Зифадан тыш та ул тары хакында кайгыртучылар табылган, бәхетсезлек дигән яман зәхмәт янә тол хатын каршына кара тунын киеп чыгып баскан икән.

— Раюннан Галикәев дигән упалнамуч килгән, шул сине кәнсәгә чакырта,— диделәр.

Зифа барса, колхоз идарәсенең зур өстәле артында алтыҗиде ир-ат тезелеп утыра. Арада бер-икесе генә Кадрәкнекеләр, күбесе таныш түгел. Күкрәгенә икеме-өчме медаль планкасы таккан гимнастеркалысы тетеп алып китте:

— Илдә ачлык хөкем сөрә, раюны-раюны белән халык ачлыктан кырыла, панимаешь, ә монда башлангыч мәктәп мө-

дире — кулак, единоличник. Или хезмәт урыныңнан колак кагасың, ни, кем, Уразметова, или чәчкән тарың безгә. Ике сөйләшеп торыш юк. Ачлык кергәч, баеуай вакыт хәзер.

— Юк инде, мин бит грамотасыз, томана кеше түгел. Сезгә инде тары, сезгә, сезгә,— дип ризалашудан башка чарасы бармыни? Зифа ашыга-ашыга әнә шундый җавап кайтарды да, колхоз идарәсеннән тиз-тиз чыгып сызды. Ә үзе юл буена күз яшьләренә буылып, җанын сыкрата-сыкрата, җырлыйҗырлый кайтты:

Сары алтын да кыйммәт,
Кара алтын да кыйммәт,
Нигә миңа гына килә
Кайгылар белән михнәт?..

## СИГЕЗЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

### 1

Кадрәк уртасындагы бердәнбер йортта бүген ут сүнмәгән. Биек урыс капкалары, хәрби кирмәннекедәй тоташ койма артына кереп поскан өчәр-дүртәр тәрәзәле зур-зур йортлар күптән йоклый инде. Рәтле кешеләрнең мунчасы зурлыгындагы шушы өй аламасында гына һаман ут җемелди. Тәрәзәдән төшкән сүрән яктылык кабыгы да салдырып өлгермәгән өр-яңа, әмма бик тә сирәк тотылган коймалардан, кешеләрнең бәдрәфеннән чак кына мулрак булган ялгыз сарай такталарыннан кайтарылып уйный. Сарай артында койма да юк, аннан-моннан сугылган киртәләр генә тезелеп киткән. Әз-мәз тормыш күргән кешегә җиңел абайларлык: дөньяның артына тибеп яши торган хуҗа ихатасы түгел инде бу, түгел, түгел...

Өй эчендә Зифа берьялгызы. Ул Розаны көтә. Бүген Уфадан аның кызы кайтып керергә тиеш. Юк, Уфадан гына түгел. Согуд Гарәбстаныннан, Кувейт, Мисырдан. Роза ярты ел буена әнә шул илләрдә сәяхәт кылып йөрде. Юк ла инде, бүтән кеше балалары сыман акчасын да, вакытын да җилгә җилгәреп, трай гына тибеп йөрмәде ул. Роза быел аспирантураны тәмамлый, ул Көнчыгыш Азия тарихы буенча кандидатлык диссертациясе яклаячак, шуңа белем туплап йөрде. Ике-өч көн элек Уфага кайтып төште инде. Телеграммасы килде. Бүген, мөгаен дә, монда кайтып керер.

Зифа күптән әзер, горурланырлыгы бик бар. Роза чит илләргә чыгып киткән чакта, бу ихата урынында әле бура гына утырып калган иде, хәзер менә өр-яңа нарат сайгаклар

тезелгән йорт көтеп тора. Дөрес, бурасы усак агачыннан. Дөрес, Зифа бәрәңге бакчасына койма да коя алмады, анда киртә генә. Дөрес, өй түбәсенә туфрак саласы бар әле. Сарайда тавыклар өчен кетәклекләр ясап куясы бар. Кәҗә өчен кышкылыкка печән чабасы бар. Көтеп торган эш-мәшәкатьләрнең чуты-чамасы юк. Ләкин, Ходай насыйп итсә, барына да чират җитәр, бары да төгәлләнер. Иң мөһиме, хәзер Роза кайтып керергә, кадрәклеләр алдында күкрәк киереп яшәргә аерым йорт, аерым ихата бар! Чит-ят өендә кысылакимсетелә көн күрүләр тәмам!..

Тиздән Роза кайтыр. Ул гел төнлә йөри. Зифа аны ничә мәртәбәләр ачуланып карады, колагына да элми.

— Мин көндез эшлим, кич укыйм бит, әни. Юлга тик төн генә кала,— дип авыз ера да тора.

— Соң, син кыз бала бит. Төнлә юлында әллә нинди явыз этләр очрап куюы бар,— дигән кисәтүләрне ишеткәч тә, кычкырып кына көлә.

— Коры сөякне эт тә яламый, дигәннәрен ишеткәнең юкмыни? Мин ыслаган вобла шикелле нык ябык ла, әнкәй.

Дөрес инде анысы, Роза Исламга охшап буйчан, үзе коры сөяк. Шул, көн-төн таш күтәрмичә эшләү белән уку галәмәтедер. Әмма үз сөяге булса да чамалый бит Зифа. Чибәр, сылу аның Розасы, бер дә ир-ат күзе төшмәслек кыз түгел.

Менә Каһирәдән дә хәтәр кинаяле хатлар язып ятты. Әүвәл «монда бер латыш галиме бар, артымнан бик юырта» дип кенә язып җибәрә иде. Соңрак «теге латыш минем кулны сорый» дип тә язып салды. Болар — яшьләр, яңа буын кешеләре бит, аларныкын белмәссең. Боларның кисәтми-нитмичә дә, парлап-култыклашып кайтып төшүе бар.

Ярар, ни язса да, хәере белән булсын. Табын әзер, чит-ят каршында да кызарырлык түгел. Зифа бер тавык суйдырды, күршеләрдән ике-өч кило сарык ите сатып алып куйды. Өстәлдә гөбәдия, бавырсак, бал, май, вареньелар тезелешеп тора. Каклаган каз ите турап куярга мөмкин. Кыз сорап кайта торган кияү егетенә тагын ни кирәк ди? Иң мөһиме, кайтсын, кайтсын иде әле! Аның Розасына егерме биш яшь тулып килә, Зифага да кияү каршында «Әпипә»гә биеп йөрергә вакыт җитте ләса!

Дөрес, аның Розасында акыл керәле-чыгалырак. Иртәгә нинди адым ясыйсын чамалавы читен. Моннан ике ел элек, Урта Азиягә археологик казынулар үткәрергә баргач, бөтен Башкортстанны аһ иттергән номер ясамадымыни?

Тегендә Үргәнеч дигән иске кала урынында казыну үткәргәннәр. Роза соңыннан гына аңлатты, Үргәнеч уникенче гасырда Мөхәммәт шаһның башкаласы булып торган, Чың-

гыз хан аны унсигезенче елда сугышып алган икән. Шушы кала өчен яу атналар буена дәвам иткән, шунда әллә никадәр төмәнбашлар, нойоннар һәм солтаннар башын югалткан, ди. Үргәнеч — башкала бит, анда бүтән төрле байлыклар да мул булгандыр инде.

Роза ул елны археологларның бригадиры булып барган иде. Сарысу елгасы ярыннан, нәкъ Роза күрсәткән төштән, асылташлар белән бизәлгән алтын каеш тартып чыгарганнар. Башкаларның кеше өлешенә керәсе килмәде микән инде, әллә курыкканнармы? — табылдыкны фәкать Роза исеменә генә язып теркәгәннәр. Билгеле ки, кыйммәтле каешны Ташкенттагы музейга тапшырганнар, ә ике айдан искитмәле хәбәр:

— Археолог Роза Үрәзмәтовага алтын каеш тапкан өчен җиде мең сум махсус бүләк тиеш!

Розаны дәүләт кешеләре генә түгел, гәзит-журнал хәбәрчеләренә тикле эзләп килгән. Ә Роза гел бертөрле сүз такрарлап, һәммәсен дә шундук кире борган:

— Мин хезмәт куеп йә тир түгеп ясаган каеш түгел. Әгәр дәүләт тарафыннан акча тиеш икән, аны Уфадагы берәр ятимнәр йортына гына күчерегез...

Дәүләт кешеләре артка егылганнар. Уен-муен түгел, илдәге иң шәп «Москвич» та биш мең торган вакыт. Ә монда төп-төгәл җиде мең тәңкә акча! Шундый байлыктан шыр хәерче студент кызый баш тартсын әле!..

Республиканың әллә ничә гәзитендә «изге җанлы» Роза Үрәзмәтованың фоторәсемнәре басылып чыкты. Өйгә кайтып кергәч, Зифа тегене утлы таба өстенә бастырмакчы булды.

— Җиде мең тәңкәдән колак каккансың, әллә башыңа тай типтеме, Роза?

Кызы ике дә офтанмыйча җавап бирде шулчак:

— Ятим үсүләр үзәгемә үтте. Ичмаса, унбиш-егерме ятимгә бер айлык булса да бәйрәм ясадым, әнкәй, миңа ачуланма...

Розага укуында да, эшендә дә айлар-еллар буе җиңеллек китерә алмавын белеп яши иде бит, дәшми калды Зифа.

Менә шушы җилбәзәк тә, иртәгә галимгә әйләнердәй укымышлы да кызын көтеп тилмерә ул. Кемнәр белән, ни рәвешле кайтып керер дә тагын нинди мөгез чыгарып куяр әле?

## 2

Роза таң алдыннан гына кайтып керде. Каһирәдә ятып карачутырга әверелеп беткән, элеккечә ябык, йөзе бик талчыккан, әмма һаман сиздерәсе килми.

— Поезд Кадрәк разъездында туктамады, Дәүләкәнгә чаклы китәргә туры килде. Шуннан ун чакрым араны җырлый-җырлый кайттым,— дип шаяртып котылмакчы була.

Кувейтта алтын бездәге бакыр бәясе дә тормый икән. Роза бүләккә бик зур якут ташлы йөзек алып кайткан. Шуны чыгарып салды, әллә ничаклы күчтәнәчләр тезде, ә йөзендә һичбер төрле шатлык чалымы юк. Ана кешенең күңелен алдап буламы соң? Күзләренә бәреп чыккан яшьләрен дә яшермичә сораштырды Зифа:

— Күңелеңдә хафа бар бит, барын да сизеп торам. Ниләр яшерәсең? Әйдә, сөйлә миңа.

Роза әүвәл күзләрен уңга-сулга уйнаклатып, әнисенә туры карарга базмый утырган иде дә, бер минутта түземлеге сынды. Ул кинәт Зифаны кысып кочагына алды, аннары кайнар күз яшьләрен әнисенең күкрәгенә тамыза-тамыза, эчке серен түкте:

— Мин алдандым, әнкәй. Египетта, Кувейтта чакта мин Инвардны өйләнмәгән кеше дип белгән идем. Артымнан бик юыртып йөргәч, каршы тора алмадым. Ә монда, Уфа вокзалына кайтып төшсәк, перронда ике сабыен җитәкләгән хатыны көтеп тора. Инвард тегеләр янына бармый. Мин алар белән яшәмим, барыбер аерылам, ди. Мин битенә төкердем дә качтым. Бер-ике сәгать үтүгә, тагын килеп җитте. Әйдә, бергә торыйк, дип ялвара, тау-тау вәгъдә тезә. Ә минем күз алдымда һаман перронда торучы ике сабый гына. Чит кешеләрнең шатлык сараен җимереп, үзеңә бәхет шалашы корып буламыни? Мин ничек шул ике сабыйны ятим калдырыйм ди? Юк, мин андый адымга бара алмыйм, әнкәй...

Бик озак елаганнан соң гына Роза батыраеп әйтте:

— Минем дүрт айлык авырым бар, озакламый бала табам, әнкәй. Мәскәүдә чакта тикшертеп тә чыктым. Мин кыз алып кайтам.

Зифаның көтелмәгән кайгылардан башы каткан иде, теленә эләккән беренче сүзләрне генә әйтеп сала алды:

— Әпәйт кыз. Нәгыймовлар фамилиясе артыннан Үрәзмәтовларның да нәселе сүнә икән. Корый, кими татар. Читятны үрчетәбез...

Ә Роза, тилергән шикелле кычкырып көлә-көлә, һаман юата бирде:

— Син мине япа-ялгыз көе үстердең бит әле. Гарип тә түгелмен, томана да түгел. Ничава, бер баланы гына ничек тә үстерербез. Менә Уфада тиздән фатир алырмын, син күчеп килерсең. Тездән тезгә күчерә-күчерә барыбер үстерербез. Ничава, ничава...

## 3

Сиксән бишенче елда Зифа белән Розаны Камчаткага кунакка чакырдылар. Рәсми кәгазь Оборона министрлыгының бик тә зур бер генералыннан килгән, Курил утрауларының берсендә кырык бишенче елда һәлак булган десантчылар истәлегенә махсус һәйкәл ачарга җыеналар икән.

Зифа Затондагы Роза фатиры белән Саескан тавындагы шифаханә арасында кайта-килә интегеп йөри иде. Роза хат ташучы китергән чакыруны сузгач сытып-сытып сүгенде.

— Мөселман үз якыннарын аларның вафатыннан соң өченче көнне үк искә ала. Ә болар кырык ел узганнан соң, ниһаять, ушка килгән. И-и, бу илдә сансыз да соң халык!..

Зифа — гаиләдә хәзер төп командир. Тынычлана төшкәч күрсәтмәләр тезде:

— Мин ерак юлга ярамыйм, сиңа йөк булып, интектереп йөрмәм. Ә син ваянный комиссар янына бар да өстәл төеп сора. Хөкүмәт хисабына гүләйт итүләр гел-гел насыйп булмас. Комиссарның үз акчасы түгел, министрлыкныкы бит. Сиңа Владивостокка чаклы поезд, ә аннары пароход белән барырга билет бирсен. Бу — атаң белән мин үткән ара. Гомергә бер тапкыр. Атаңа кире кайтулар насыйп булмады. Менә хәзер шушы ике араны нәкъ атаң эзләренә басып үт син. Шунда гына атаңның сугыш юлларын аңларсың, һәммәсен күзалларсың... Петропавловскта, качарга җай чыкса, гарнизонга барып кайт. Әгәр булса инде. Булмаса, сопкаларны, күл буйларын кара. Синең күзең шунда ачылды, син шул җирдә тәпи атлап киттең... Әгәр Шумшу утравына алып барсалар, бер уч туфрак алып кайтырга онытма. Анысы — атаң башын салган урын, шунда әрәм булды. Миңа андагы җир алтыннан да кыйммәт. Туфрак алып кайтмасаң, кире өйгә кертмим. Шуны уйлап йөре...

Роза Владивостокка кадәр сигез тәүлек эчендә, җайлы гына барып җиткән иде. Владивостокта — киртә. Камчаткага кадәр пассажир теплоходлары әле һаман йөрми, иртәгә ул тарафка транспорт корабы гына кузгала, анысы да юл уңаенда Япониянең Хоккайдо утравында тукталып, полиэтилен чималлары бушатачак икән. Бушка гына, өстәвенә берьюлы Японияне дә, Камчатканы да күрү бәхете һәркемгә тәтеп тормый, билгеле ки, Роза транспорт корабына эләгергә шундук риза булды.

Корабка пассажир рәвешендә утырган хатыннарның һәммәсен дә диярлек өчәр-дүртәр кешелек каюталарга урнаштырдылар. Бара-бара Япон диңгезе дә, Лаперуза бугазы да

артта калды инде. Ә Роза, әнисе хатирәләренә нигезләнеп, гел диңгезнең шашынуын, гарасат-давылларны көтеп йөрде. Хәзерге кораблар гаять зур һәм бик куәтле, әллә шуның йогынтысы инде, Розаларныкы да су өстендә бәллүләп кенә барды. Ни сикертү-уйнату юк, ни акула йә балыклар көтүе күзгә чалынмый. Розага хәтта вакыты-вакыты белән диңгез төссез һәм күңелсез булып тоела башлады. Әмма хикмәтле һәм ушкитмәле хәлләр совет корабын япон утравында көтеп торган икән.

Беркөнне таң атканда кораб дуга булып яткан бухтага килеп керде. Палубалар буйлап инде йөзәрләгән кеше йөгерешә иде, Роза да сикереп торды.

— Асахига җиттек, алда Асахи, Асахи! — дип кычкырып үтте кемдер.

Роза атылып палубага чыкты. Күз күреме әләктергән бөтен су өстендә меңәрләгән кораб. Краннарын торна муены сыман югарыга сузган зурлары бар, тагарак шикелле вак көймәләр, җилкәнле яхталар, поезд вагоннары кебек бер-берсенә тирәтеп тезелгән катерлар, шхуналар бар. Болар уч төбе кадәрле бухтага ничек сыялар да, хуҗалары аларны ничек кенә табып бетерәдер?

Бухта артында, нык еракта, түбәсе болытлар эченә кереп поскан сопка. Ул тау түгел, әледән-әле үзен искәртеп-янап торучы усал вулкан икән. Биеклеге ике мең ярым метр, исеме Асахи, ди. Вулканның тирә-ягында ылыс урманнары, өсләре кайчы белән кырыккандай тип-тигез, вак-вак куаклыклар. Ара-тирә генә үзәнлекләрдә кулъяулык зурлыгындагы басулар күренеп тора. Алар тоташ яшел, мөгаен дә, японнар анда дөге-мазар игәләрдер инде.

Шәһәрнең диңгез яклап күренеп торган районы әллә ни зур түгел. Шырпы каплары сыман тезелеп киткән пөхтә, матур йортлар, тимерчыбык тарттырып сузган шикелле тип-тигез, төз урамнар. Йортлар арасы саен, һәр ихата саен үләнлекләр. Һәрбер ихатада ниндидер куак һәм агачлар, адым саен чәчәк түтәлләре. Боларда һәр карыш җир уңыш бирә сыман.

Берәр сәгатьтән соң совет корабын причалга уткәрделәр. Япон докерлары үзләре йөк бушатырга керештe. Хәер, боларда кешеләр бөтенләй күренми дә. Тигез гүелдәп краннар гына эшли.

— Чит ил паспорты булмаган пассажирлар портка чыгарылмый, — дигән фәрман җиткерделәр. Розаның һәм аның шикелле йөзләп бәхетсезнең борыны салынып төште. Аның каравы корабтагы моряклар бөтенләй танымаслык. Старт сызыгына баскан чабыш атларымыни, борын яфраклары

киерелгән, күзләре төнге ябалакныкы кебек ялт-йолт килеп тора.

Төш вакыты җиткәндә, моякларга корабтан төшәргә рөхсәт булды бугай. Берсен-берсе таптый-таптый алар трапка ябырылды. Ә ике-өч сәгатьтән соң болар инде дөя шикелле төянеп кире кайтып керде. Кемдә иске тегү машинасы, кемдә мотоцикл. Кайберләре япон машиналарының моторын төяп кайткан, кемдер суыткыч, телевизор... Болар японнарның ташландык техника зиратын тапканнар, байлык шуннан икән...

Диңгез өстенә кичке караңгылык иңә башлагач, совет корабына ниндидер юл белән япон эшмәкәрләре килеп менде. Берсе киштә-киштә итеп тезелгән китаплар күтәргән боларның, Роза йөгереп шуның янына килде. Кемнәр янына керәсен алдан чамалагандыр инде, япон эшмәкәре киштәләренә күбесенчә русча китаплар тутырган. Деникинның «Офицер язмалары», эмиграциягә качкан Хара-Даванның мәшһүр «Чыңгыз хан»ы... Һәммәсе дә совет илендә әле күренмәгән, шаукымы-даны колакларда гына яңгыраган сирәк китаплар. Әлбәттә инде, бик күбесе Франциядә, Югославиядә, Америкада гына басылганнар.

Роза бер почмакта Мөхәммәт Йосыф-Гәрәй атлы авторның «Башкортстанны Россиягә кушу» дигән китабын күреп алды да шуңа чат ябышты.

— Безнең илдә мәңге ишетелмәгән китап бит бу! Хакы күпме тора?

Япон эшмәкәре сантыймыни сиңа? Ул Розаның карашында кабынган шайтан утын шундук күреп алды. Хәзер авызын ерган да бармакларын чарт-чорт уйнаклатып, мыскыл иткәндәй тора.

— Мани, мани.

Роза әүвәл кулындагы сәгатен салып бирде. Япон эшмәкәре балавыз сын шикелле хәтта кымшанмый да. Роза ашыга-ашыга берсе якут, берсе мәрҗән кашлы алтын йөзекләрен салды. Муенындагы алтын чылбырын салды, алтын алкаларын. Япон һаман дәшми. Карашы Розаның җиң очыннан ялтырап күренгән көмеш беләзегенә текәлгән. Чыдамагач Роза аны да салып бирде. Шуннан соң гына япон эшмәкәре эреп елмайды да киштәдәге китапны алып сузды.

Роза каютага алтын каурыйлы мәңгелек кош эләктергән шикелле очына-очына кайтып кергән иде. Юлчы хатыннар Роза салган байлыкларны тәңкә чутына күчереп исәпләделәр дә, әйтерсең лә битенә төкерделәр.

— Якут-мәрҗәннәрне хисапласаң, ким дигәндә бер мең

биш йөз тәңкә. Беркадәр тотылган ярты машина хакы. Арт якны сөртергә дә ярамаган үтил китап өчен шултикле байлык әрәм итә торган юләр дә бар икән! Китчәле, кит, адәм мәсхәрәсе!..

## 4

Петропавловскта Розаны ап-ак төстәге гаҗәеп мәһабәт диңгез лайнерына күчереп утырттылар. Бөтен хәрбиләр парад кительләре кигән, иңнәрендә алтын җепләр белән елкылдап торган погон. Адъютантларыдыр инде, күрәсең, арада берәү иң зур корсаклылар белән таныштырып йөри.

— Запастагы генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое Алексей Романыч Гнечко.

— Ике мәртәбә Ленин орденнары кавалеры генерал-майор Дьяков Петр Иванович.

— Советлар Союзы Герое контр-адмирал Пономарев Дмитрий Георгиеч...

Розаның әнисе авызыннан бу кешеләр тарафына бик күптөрле сүгенү-нәфрәт яуганын ишеткәне бар иде, алар ягына елмаеп карарга да үзендә көч тапмады. Өстәвенә Хоккайдо утравында алган сабак та нык таушаткан, җегәрен бик суырган иде. Роза Шумшу утравына барып төшкәнче, томан эчендә шикелле, башкаларга ияреп, йөзеп кенә йөрде.

Шумшуда шул ук Кокутан белән Котомари дигән ике борын уртасындагы бугаз эченә кереп туктадылар. Генерал Дьяков дигәннәре репродуктор аша бөтен корабльне дер селкетеп сөйли:

— Безнең данлы совет гаскәрләре берьюлы алтмыш дүрт сугышчан кораб, крейсер һәм линкорлар белән шушы бугаз аша япон самурайларына каршы һөҗүм башладылар. Кокутан сопкасындагы япон позицияләрен майор Курбатов җитәкчелегендәге бер батальон санаулы минутлар эчендә яулап алды. Майор Курбатов тәненә гранаталар бәйләнгән көе япон орудиесенә ташланып үзен һәлак итсә дә, аның легендаларга күчәрдәй батырлыгы һич тә онытылмады. Майор Курбатов соңыннан Сугышчан Кызыл байрак ордены белән бүләкләнде, элеккеге Кокутан борыны хәзер Курбатов исемен йөртә...

«Йөртә, пычак! Юлга чыгар алдыннан гына ничәмә-ничә ил картасын актардым бит. Аларның һәммәсендә Курил утрауларындагы һәр атама япон исемнәре белән аталып йөри».

Махсус ясап куелган мәрмәр баскычлар буенча утраудагы тау яссылыгы өстенә күтәрелделәр. Беркадәр ерактарак Алаид вулканының түбәләре ачылды, биеклеге ике мең дә өч

йөз метр икән. Янда балыкчылык флоты капитаны киемен кигән бер ир сөйләп бара. Алаид әлегә йоклый, әгәр уянып лавасын бер атса, утрауны аркылысыннан буена көйдерәчәк икән. Менә сиңа мә! Күрә-белә торып, утлы күмер йә булмаса туп ядрәсе өстенә ятып йоклау бит бу!

— Монда берәр нинди хуҗалык йә авыл бармы соң? — дип, Роза ирексездән сорарга мәҗбүр булды.

Кунак хатынның халәтен аңлады, күрәсең, балыкчы капитан көлемсерәп кенә җавап бирде:

— Авыл юк инде, билгеле. Биш-алты йорт кына. Әнә-ә тегендәге күлне күрәсезме? Шуның ярына сыенып утыралар. Анда вахта ысулы белән китерелгән балыкчылар яши. Ай саен алышынып торалар. Монда махсус хуҗалык юк бит. Бер бригада гына. Диңгездә ватылып туктаган, Лопатка йә Петропавловскка кадәр тарта алмаган тральщикларны шушы утрауга сөйрәп китерәләр дә, балыкларын әнә шул йортларның берсендәге цехка бушаталар. Тозласалар, тозлап өлгерә инде вахтачылар. Ә диңгездә шторм кузгалса, бөтенләй дә өйләреннән чыгып йөрмиләр. Сасыган балыкны соңыннан диңгезгә ыргытабыз. Суда җанвар чиксез, ашап бетерәләр...

Роза утрау эчендә хасил булган кечкенә күл өстенә текәлеп карап торды. Исеме Беттоби, ди, японнар кушканнан калган атамадыр инде. Күл суы ачык-зәңгәр, ләкин яр буенда сыңар агач та юк. Гел ботакларына мүк сарган шикелле яфраксыз куак өстендә куак. Аяк астында таш, ком һәм көл шикелле туфрак. Берәр әйбер янганнан соң чәчелгән көлме бу, әллә табигыймы? — мәңге аңламассың...

Дүртпочмаклы биек обелискны күл буена ук барып җитмичә, бетон мәйдан уртасына ясаганнар икән. Балыкчы капитанга хуҗа кыяфәтендә йөрү бик ошады бугай, хәзер дә Розаның колагына иелеп тиз-тиз пышылдап алды.

— Безнекеләр сакчыл, акча коеп азапланмадылар, һәйкәлне японнардан калган бетон өстенә генә китереп утырттылар. Игътибар белән карагыз, заманында японныкы булган аэродром бу...

Обелиск янындагы микрофон тирәсен, әлбәттә инде, алтын погонлы генераллар, адмираллар түгәрәкләп басты. Берсен-берсе уздырып сүзгә керештеләр:

— Безнең данлы совет гаскәрләре япон самурайларының сугышчан позицияләрен санаулы минутлар эчендә яулап алды...

— Безнең данлы совет гаскәрләре, бик аз санлы югалтулар кичереп, яуда чын каһарманлык үрнәге күрсәтеп сугыштылар...

Роза, янда торган башка кунакларга ышкылып уза-уза, обелиск янына ук җиткән иде инде. Таш диварга беркетелгән пыяла тактадагы исемлеккә текәлде дә катты. Баландин, Вилков, Еремин, Курбатов, Савушкин, Солтанов, Тюрин... Бөтенесе кырыкка якын гына фамилия. Монда старшина Ислам Үрәзмәтовны искә алучы да юк. Ахырда вак-вак итеп язган юл гына бар.

«Шумшу утравын яулау вакытында ике мең дә биш йөз алтмыш өч совет сугышчысы һәлак булды».

Син шушы гомуми сан эчендә генә исәпкә кергәнсең бит, татар батыры Ислам Үрәзмәтов! Менә сиңа «бик аз санлы, вак-төяк югалтулар»!..

Роза ярсу һәм гарьләнү хисләрен ят күзләргә күрсәтмәс өчен читкә чыгып китәргә мәҗбүр булды. Беттоби күле кул сузымында гына булып күренә иде, шуңа таба карап йөгерде дә, аның ярына капланып, хисләренә тулы ирек бирде.

«Эх, син, Ватан, каһәр суккан Ватан! Үзең өчен һәлак булган ирләреңне дә барлый белмәгәч, чит-ят җирләр ник кирәк соң сиңа? Минем газиз әткәм — Ислам Үрәзмәтов — ни хакына шушы тоташ ком-таштан гына хасил, һәр секунд саен Алаид вулканы менә бетерәм, менә бетерәм, дип янап торган кеп-кечкенә утрау өчен башын салган инде? Японнар Курил утраулары хакында бәхәс кузгаттымы, син «алар борынгыдан килгән рус җирләре» дип кычкырасың, Мәскәү. Ә үзең печән кибәне өстенә менеп яткан явыз эт шикелле. Барыбер кадерен белмисең, барыбер ташландык бит бу кыргый, чит-ят утрау. Хуҗаларына кайтар син аларны, кабат японнарга бир. Ичмаса, японнар аннан гөл бакчасы ясарлар. Бәлки, шуңа карап синең халкыңда гарьлек хисе туар. Бәлки, морякларың яңа Шумшуны күреп, аннан иске телевизор, ватык суыткычлар урлап ташымаслар. Сиңа да, иң әүвәл, үз җиреңә хуҗа булырга, адәм балаларының гап-гади бәхете, бөтенлеге, иман саулыгы турында кайгыртырга вакыттыр бит инде! Уян инде, уян, мескен Ватан!..»

# Соңгы сүз

Гөлзифа апа соңгы көннәрдә тоташ ут эчендә. Бил сызлаулар, үпкә сызгырулар каядыр юкка чыкты. Сырхау-мырхауларны искә алып торырдай, иркен вакыт түгел. Бала табу йортыннан менә-менә Инга кайтып керергә тиеш. Тугыз-ун көн элек Инга бәбәйләде. Гөлзифа апа әби генә түгел, башкортларча әйтсәң, карт әсәй дә, карт әби дә хәзер!

И-и, хәтер яңартып алсаң, Инга өчен дә ничәмә-ничә айлар, еллар буена «безнең сымак япа-ялгыз кала» дип кайгырып һәм ут йотып йөргәннәр иде бит. Чөнки институтын тәмамлап чыкканчы, Инга бер генә егеткә дә әйләнеп карамады. «Нәсел чиредер монда» дип, Гөлзифа янды-көйде. «Мин ялгыз хатын бит. Егетләргә йогышлы итеп аны мин үстерә белмәдем» дип, Роза гел-гел генә үзен табалады.

Мәгәр юк, Белорет каласына юллама алып киткәч, Инга ике-өч ай эчендә кияүгә чыгып куйды. Төп-төгәл өч айдан әйләнеп тә кайтты.

— Аның әнисе шәһәр хакименең урынбасары, әтисе — завод директоры. Малайларына аерым фатир алып бирмиләр. Мин аларның асраулары сыман керләр юып, идән себереп гомер итә алмыйм...

Җавап кайтарып аны җиңәрдәй дәлилләре юк иде, тешләрен кысып, сүзсез уздырдылар. Ләкин әби белән ана кешенең икесе дә эчтән генә ничә айлар сызды. «Их, берәр яр тапсын иде дә, башлы-күзле булсын иде бит инде бу! Безнең сыман япа-ялгыз интегүләр язмасын иде моңа!»

Менә былтыр, янә ике-өч ел көткәч, фатирга Марат атлы ирне җитәкләп кайтып керде Инга. Марат — башкорт егете, Ингадан төп-төгәл ун яшькә өлкән. «Ярар, чукынсын, тик бездә генә яшәп калмасын» дип хафага төшсәләр, чикләвек дигәннәре имән агачының кәүсәсендә икән.

— Минем берсе — сигез, берсе алты яшьлек ике малаем бар. Хатыным, безне ташлап, чит илгә чыгып качты,— диде дә, Марат баш түбәсенә авыр күсәк белән органдай, икесен тиң идәнгә лып утыртты.

Боларның миңгерәвен күреп, Инга элеп алды:

— Мине үгетләргә маташып тел әрәм итмәгез. Мин инде ике-өч ай буена аларга барып йөрим. Маратның ике малае да мине күптән үз итteләр. Мин аларны кызганганга түгел, һәр өчесенә гашыйк булып барам. Алда ни көтсә дә, сезгә үпкәм-битәрем юк...

«Бик озакка түзмәс, менә кайтыр, менә кайтыр» дия-дия көтеп карадылар. Юк кына бит, әйкәй, «чит балалар карыйм» дип, Инга һичбер тапкыр сыкрап күрсәтмәде. Мара-

ты да ипле, тыныч. Җаена гына тора. Менә шулай, башкаларны көнләштерерлек итеп, яшәп китте болар. Инде менә уртак җимешләре бар. Аңа бала тудыру йортында ук «Юлия» дип исем кушканнар, ди. Мөселманча булмаса да, әйдә, ярар инде. Тик озын гомерле һәм бәхетле була күрсен.

Роза: «Бәлки әле безгә кайтып төшәрләр»,— дип җим ташлаган иде, менә хәзер яшь киленнәр төсле тыз-быз йөгерәләр. Сабый баланы аерым түшәккә салырга йә тегесе җитми, йә монысы. Өстәвенә табын. Роза әле бер кибеткә чыгып чаба, әле яңасына. Гөлзифа апа ишек ачарга чак җитешә аңа.

Менә тагын кухня ягында кыңгырау чылтырады. Җилҗил атлап чыкса, ишектә беркем дә юк, ә чылтырау тавышы һаман дәвам итә. Кадалып кына китсен, монысы телефон икән. Йөгереп шуңа килде.

— Әл-лү, кем бар анда? Әй, кем кирәк, дим.

— Ха-ха-ха-ха! Картайдыңмы әллә, Гөлзифа яшьтикәем?

Тагын Зыя Максуд чылтырата икән бит, иманы коргыры! Кара, «картайдың», дип мыскыл иткән була. Аңа бу юлы нигә кирәк булдым икән?

Зыя көттереп азапланмады, гыж-гыж килә-килә, барысын әйтеп салды:

— Бу юлы сине һич тә алдаламыйм, тәк менә вәт, диген. Син барып йөри торган Саескан тавындагы бүлнискә йөз яшьлек карт кергән. Кенәгәгә теркәп утыручы медсестра кызлар тәгаен җиткерделәр. Бу карт — сезнең авыл янындагы Күчәрбайдан Мәхмүт Илмурзин, ди. Акылы үзе белән. Ул синең атаң турында белә дә белә инде. Ятып калганчы атып кал, дигәннәр. Бар да бәйнә-бәйнә сораш. Йөзеңә төкереп кире кумас әле...

Гөлзифа апа тоташ калтырап чыкты. Илмурзин Мәхмүт, яндагы Күчәрбайдан. Аның әтисен Табор күленә тотып салган явызларның берсе. Авыл өстендә «Әмирне күлгә суеп салганнар» дигән хәбәр урап йөрде. Әтисен, чыннан да, күл төбенә суеп салганнармы, әллә болай гынамы? Шуларның кайсысы дөрес? Бер уйласаң, әллә ни зур аермасы да юк инде. Ләкин beләсе килә бит. Әтисенең җанын кыярга кемнең генә кулы күтәрелде икән?..

Роза кайтып керде. Янган-пешкән. Гөлзифа апаның туктаусыз кабатлавыннан чак абайлап алды: кайсыдыр хастаханәдә аның бабасын суючы Мәхмүт ята икән.

— Ярар, Мәхмүт табылган. Ярар, ул синең әтиеңне, минем бабайны суеп күлгә салган, ди. Шуны күреп сорашсаң, сиңа ни җиңеллек? — дип, Роза пыр тузынды.— Үлгәннәр артыннан кабат үлеп булмый. Әтиеңне дә җир өстенә кабат кайтара алмыйсың. Юк-бар белән башымны катырмачы, ән-

кәй. Менә-менә Инга кайтып төшә, сиңа онык тиешле бәбәй кайтып керә. Әллә нинди Илмурзиннар турында уйлар вакытмыни?..

Гөлзифа апа үзенең бүлмәсенә кереп чумган төсле булды. Тамак кырган тавышы да ишетелми, һич тыны юк. Розага тагын әллә нәрсә кирәк булды бугай, ачкычларын чылтырата-чылтырата янә чыгып сызды. Гөлзифа апага нәкъ шул кирәк иде, ул да каударланып урыныннан купты.

...Саескан тавындагы хастаханәдә аның сер сыйган иң якын кешесе шәфкать туташы Гөлдания иде.

— Сезнең бүлнистәге кайсыдыр палатада Мәхмүт атлы бер карт ята, диләр. Аны күрмичә ярамый, шуның янына алып кер син мине,— дип ялынды ул аңа.— Иллә мәгәр безне ташлап китмә, йөрәгем бик авырта...

Гөлзифа апаның кайчандыр Мәхмүтне күргәне бар. Хәзер дә ул аны шундук төсмерләде. Палатаның иң түрдәге караватында нәкъ шул ята булыр. Ләкин хәзер инде бу кешедә кибеп беткән гәүдә, ап-ак чәчләр. Шулай да, Гөлзифа апаны күрүгә, карашында аек ут кабынды. Тамчы да ашыкмый бу, иренен кысып көтә.

— Мин Нәгыймов Әмирҗан дигән кешенең соңгы сәгатен күргәннәрне эзлим,— дип, Гөлзифа апа турыдан ярып салды.— Аның гәүдәсен Торна күле буенда күтәреп йөргән чакта, сине Сакау Ләпәй белән көтүче Фәхри күргән. Шуннан арысын белүче-күрүче юк. Гомер сәгатьләребез бик күп тә калмагандыр, йә, әйт инде. Нәгыймов Әмирҗанны ничек үтерделәр? Якты җиһан белән ул ничек саубуллашты?

Мәхмүт Илмурзин башын калкытты да кет-кет итеп көлде. Бу албастыга йөз яшь якынайса да, куәте бар икән.

— Нәгыймов җан биргән чагында, мин Бәләбәй төрмәсендә утыра идем бит. Нидер бутыйсың, миңа нахак яла ягасың, сеңелкәем.

— Төрмәдә утыргач, син Нәгыймов Әмирнең кайчан җан биргәнен каян алып белдең?

— И-һи, төрмә телеграфтан шәбрәк эшли бит ул. Анда барысы да көнендә беленә, сеңел.

— Алай булгач, Нәгыймов Әмирҗанны син суймадың инде?

— Алла сакласын, Алла сакласын, сеңел. Ничек инде адәм җанын кыйыйм? Минем хәтта тавык та суйганым юк...

Тагын да төпчеñү бер файдасыз иде. Гөлзифа апа Илмурзинның йөзенә төкерде дә, тыелып елый-елый ишектән чыгып китте. Илмурзинның кинәт кенә карават тимеренә ябышуы Гөлданияне тукталырга мәҗбүр иткән иде. Ярсыган, кызган Илмурзин ике-өч минуттан соң гына тынычлан-

ды бугай. Аның күбрәк үзалдына сөйләнгән сүзләре яңгырап ишетелде:

— Әмирнең Гөлзифасы үзен танымаска мине шыр дивана, дип белде бугай. Ашыкмый тор, кәбәм. Атаңны мин суйдым, дип гаебемне танып торырга мин әле дүрәк түгел. Алда яшисе бар...

Гөлдания эзләп чыккан чакта, Гөлзифа апа хастаханәне ташлап китәргә өлгергән иде инде. Ике-өч көн үткәч, «сер сөйлим» дип эзләп баргач та, соңарды Гөлдания. Ахирәт шәфкать туташы өйләренә килеп кергәндә, Гөлзифа апа түшәк өстендә хәрәкәтсез ята, ә аның пыялаланган күзләре әтисенең стенадагы бердәнбер рәсеменә төбәлгән көенчә катып калган иде...

Залда моннан ары гомер буе марҗа булып саналып йөртеләчәк Юлия аваз бирде.

*Чаллы, 2001—2003*

## Эчтәлек

Ул — язар өчен яши. *М.Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Беренче кисәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Икенче кисәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229

Литературно-художественное издание

*Имамов Вахит Шаихнурович*

*Соленая рана*

Роман

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *И.И.Әҗемов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 27.01.2004.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16+форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 20,79. Нәшер-хисап табагы 22,71+форз. 0,36.
Тиражы 5000. Заказ Э-15.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.